ISSN 0206—418

# Казан утлары

6.1987



*КПСС өлкә комитеты бюросы*
*һәм Татарстан АССР*
*Министрлар Советы карары*

# 1987 ЕЛ ӨЧЕН ТАТАРСТАН АССРның Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА



Язучы М. Х. Зарипов



Художник Т. Г. Хаҗиәхмәтов

Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты тәкъдимен караганнан соң, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карар бирәләр:

1987 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирергә:

1. **Зарипов** Марсель Харисовичка — язучы, «Республикам адымнары», «Файдалы әйләнеш» дигән очерклар һәм әдәби публицистика китаплары өчен.
2. **Хаҗиәхмәтов** Тавил Гыйниятовичка — художник-график, 1981—1985 елларда басылган китаплардагы художество-графика бизәкләре өчен.

КПССның Татарстан
өлкә комитеты
секретаре

**Г. И. УСМАНОВ.**

Татарстан АССР
Министрлар Советы
Председателе

**М. Ш. ШӘЙМИЕВ.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АИЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

**6**

**1987**

## *Бу санда*

В. НУРУЛЛИН. **Җавап бир, кеше.** *Повесть* . . . 3
Г. АФЗАЛ. **Урманнарга керәм...** *Шигырьләр* . . 62
М. ХӘБИБУЛЛИН. **Таңана.** *Хикәя* . . . . . . 67
Н. НӘҖМИ. **Париж өстендә.** *Шигырьләр* . . . 83
Б. КАМАЛОВ. **Күрәчәк күз ачтыра.** *Хикәя* . . . 86
Ә. МӘХМҮДОВ. **Әни.** *Шигырьләр* . . . . . . 91
М. ВӘЛИЕВА. **Гарлавач.** *Хикәя* . . . . . . . 93
Н. АКМАЛОВ. **Кый-гак-к.** *Шигырьләр* . . . . . 106
Н. ӘХМӘДИЕВ. **Рафис.** *Хикәя* . . . . . . . . 110

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

А. А. ЕФРЕМОВ. **Тау ягы** *(Кама Тамагы)* . . . 119

Җ. РӘХИМОВ. **Алмагачның алмасы** . . . . . . 122

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Л. ИХСАНОВА. **Табигатькә һәйкәл** . . . . . . 126

БИБЛИОГРАФИЯ

Х. МИҢНЕГУЛОВ. **Әдәбият тарихын өйрәнү юлында** . . . . . . . . . . . . . . . 130
Ф. МИҢНУЛЛИН. **Яңа сүзлек** . . . . . . . 134

КОНКУРСКА

Ф. БӘШИРОВ. **Әхлакый эзләнүләр** . . . . . . . 137
Р. НУРЕТДИНОВ. **Вакытлар чиксез, гомерләр кыска** . . . . . . . . . . . . . . . 139
И. БӘДРЕТДИНОВ. **Яшәү җаваплылыгы** . . . . 142
Ә. ГАБИДИ. **Хыял ат канатында...** . . . . . . 144

ТЕЛ ГЫЙЛЕМЕ

Ф. ХИСАМОВА. **Хәзинәдә ниләр бар?** . . . . . 145

СӘНГАТЬ

К. МИҢЛЕБАЕВ. **Төсләр балкышы** . . . . . . . 151

ОРЕНБУРГТА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

**Багъбостан Мөэминова мәктәбе.** З. МӨХӘММӘТЖАНОВА *рәсеме* . . . . . . . . . . . 156

Ф. САЛИТОВА. **Театр һәм музыка** . . . . . . . 158

ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

С. АЛИШЕВ. **Күренекле тарихчы һәм әдип** . . 161

ФАЗЫЛ ТУЙКИННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ә. ШӘРИФУЛЛИНА, Җ. МИҢНУЛЛИН. **Бүген дә хәрәкәттә** . . . . . . . . . . . . . . 164

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

ВАРИ РӘХМӘТНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Р. МИҢНУЛЛИН. **Балачак шагыйре** . . . . . 169

ГАЗИ КАШШАФНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Р. НУРУЛЛИНА. **Тугрылык** . . . . . . . . . 172

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Р. КОРБАНОВ. **Сабан туенда.** *Шигырьләр* . . . 174

**Укучы сүзе** . . . . . . . . . . . . . . 176

ЮМОР-САТИРА

М. САТТАРОВ. **Эштән чыгарылган түрә бәете.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . 181
Л. ЛЕРОН. **Пародияләр** . . . . . . . . . . 182
Ә. САФИУЛЛИН. **Ияләнеп киткәч...** *Хикәя* . . . 183

АЕК БУЛ — ЗАМАНГА ЛАЕК БУЛ!

З. НУРИ. **Шигырьләр** . . . . . . . . . . . 184
**Аракы эчү, исерү һәм исерек башлар турында халык мәкальләре** . . . . . . . . . . . 185

**Каләмдәшләребез — СССР Язучылар Союзының яңа әгъзалары** *Р. Юныс, Н. Хәсәнов* . . . 186

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . 187

КИТАПЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

**Хатыгызга җавап** . . . . . . . . . . . . 190

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Повесть В. НУРУЛЛИНА «Бабье лето», исторический рассказ М. ХАБИБУЛЛИНА «Тан-ана», рассказы: Б. КАМАЛОВА «Судьба», М. ВАЛЕЕВОЙ «Гарлавач», Н. АХМАДИЕВА «Рафис».
Стихи Г. АФЗАЛА, Н. НАДЖМИ, А. МАХМУДОВА, Н. АКМАЛОВА, Р. КУРБАНОВА.
В рубрике «Татарстан — родной мой край» выступление первого секретаря Камско-Устьинского райкома КПСС А. А. ЕФРЕМОВА.
Очерк Дж. РАХИМОВА о женщине труженице.
В рубрике «Литературная критика» статья Л. ИХСАНОВОЙ «Памятник природе». «Библиография» — рецензии на II том книги «История татарской литературы», на «Русско-татарский словарь», на книгу Н. Валеева «В мире нравственных исканий», А. Сафина «Взгляд», Р. Юнусова «Живу на земле», Г. Садэ «Год любви».
В рубрике «Языкознание» статья Ф. ХИСАМОВОЙ.
В рубрике «Искусство» статья К. МИННЕБАЕВА о художнике Т. Хазиахметове, статья Ф. САЛИТОВОЙ «Театр и музыка».
«Памятники татарской культуры в Оренбурге»: школа Багъбостан.
В номере отмечаются 100-летия Г. Губайдуллина, Ф. Туйкина; 90-летие Б. Рахмата и 80-летие Г. Кашшафа.
Отклики читателей на опубликованные в журнале произведения.
«Юмор и сатира»: Стихи М. Саттарова, пародии Л. Лерона, рассказ А. Сафиуллина.
«Трезвость — норма жизни»: стихи З. Нури, татарские народные пословицы.
Новые члены Союза писателей СССР.
Дневник культурной жизни.
В мире книг.
На наших обложках — образец татарского ювелирного искусства — подвески. Памятник А. С. Пушкину.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.*

Производствога бирелде 30.03.1987 ел. Басарга кул куелды 20.05.1987 ел. ПФ 05178. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 67149. Заказ М-139. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1987 ел.

# Вакыйф Нуруллин

# ҖАВАП БИР, КЕШЕ

ПОВЕСТЬ

## I



Иртәнге сәгать уннар тирәсе. Күк йөзе чалт аяз. Йомшак, җылы җил исә. Зәңгәрсу ефәк дулкын булып, салмак кына рәшә тирбәлә. Әбиләр чуагының соңгы көннәре. Котылгысыз якынлашып килгән көз белән җәйнең соңгы тартышы. Тиздән, бик тиздән шушы зәп-зәңгәр һәм биек күк йөзен кургашындай авыр, соры болытлар каплап алачак. Кояш атнага бер-ике тапкыр гына күренгәли башлаячак. Түбә калайларын дөбердәтеп, тәрәз капкачларын йолкып атардай булып ачы җилләр исәчәк...

Шул көннәрне күз алдына китергәч, капка төпләрендәге карама бүкәндә утырган Ханәфигә инде хәзер үк салкын өрә башлаган шикелле булды: тәннәре калтыранып, бала йоннары кабарып чыкты. Ул өстендәге кайры туннның якасын күтәреп куйды, бүрегенең колакчыннарын төшереп бәйләде, олтанлы киез итегенең яңа чагында ук кайтарып куелган кунычларын күтәрде, кулларын кушырып, җиң эченә тыкты. «Хәзердән үк болай булгач, салкыннар җиткәч, ничек түзәрмен икән?» — дип хафага калды.

Әйе, көзге салкыннар, кышкы суыклар бер дә файдалы түгел Ханәфигә. Көзге салкыннар аңа бик нык сызланулар алып килә: болай да туктаусыз борчып торган радикулиты — бил һәм аяк буыннары авыртуы көчәя аның. Инде менә җиденче елын чиләнә шул каһәр төшкән авыру белән. Ни хикмәттер, көз җиттеме, котырына да китә шул кабих нәрсә: үзәкләргә үтеп, йөрәкләрне чәнчеп-чәнчеп сызларга тотына. Сызлавы гына бер хәл иде, иң яманы — кыймылдарга да ярамый: бер яктан икенче якка борылып ятулары әҗәлгә тиң була кайчакларда. Ә узган ел, октябрь аенда, бөтенләй аяктан ук язды ул. Председатель Нургазиз район больницасына салып дәвалаттырмаган булса, ихтимал, аягына бүтән баса да алмас иде. Больницада ай да ун көн яткач кына азрак адәм рәтенә кереп кайтты. Шуннан бирле, шөкер, үзен-үзе йөртеп килә әле. Хәер, йөрү дигәне әллә нәрсә түгел: өй белән капка арасы гына инде.

Хәер, йөрер рәте булган тәкъдирдә дә барыр җире юк Ханәфинең. Авыллары кечкенә: нибары унбер йорт. Алары да, Ханәфи авызындагы

---

ВАКЫЙФ НУРУЛЛИН *(1935) — прозаик, РСФСРның атказанган культура работнигы. «Шинельсез солдатлар», «Әгәр син булмасаң...», «Һәлакәт» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

тешләр шикелле, сирәгәеп калган, анда бер, монда бер булып кына утыралар. Өй белән өй арасы йөз иллешәр метр булганнары бар. Ханәфи яшь чакта картлар сөйли торган иде: моннан туксан еллар элек шушы Куралык авылында ике йөздән артык йорт булган. Болай да тау өстендә утырган авылның иң биек урта бер жирендәге мәчет манарасы егерме биш-утыз чакрымнан күренеп торган. Ул манараның алтын йөгертелгән ае, жәйге аяз көннәрдә кояш нурларын чагылдырып, көндез дә Чулпан йолдыз шикелле балкып утырган.

Ханәфи аны-моны аңлый башлаганда, ае гына түгел, мәчет үзе дә юк иде инде. Гражданнар сугышы вакытында аклар аның манарасын аударып, аен үзләре белән алып, авылга ут төртеп киткәннәр. Авылның яртысы һәм мәчет шул чакта янып беткән. Йортлары янган кешеләрнең күбесе яңа өй торгыза алмаган. Кайсылары Донбасс якларына — шахтага, кайсылары Казахстан, Үзбәкстан якларына китеп барган. Шуңа авыл бик нык кечерәеп калган.

Егерме беренче елгы ачлык һәм аның артыннан килгән тиф чире авылны тагын бер тапкыр бик нык үзгәрткән: күп кенә семьялар, ачтан үлмәс өчен, Урал, Себер якларына чыгып китеп, шунда төпләнгән. Авылда калганнарының да байтагы ачлыктан һәм тифтан кырылган.

Шулай да әле илленче еллар башында Куралык үзе бер колхоз булып яши, анда алтмышлап хужалык бар иде. Һәрхәлдә, Ханәфи колхоз председателе булып эшли башлаган илле икенче елда илле жиде йорт бар иде шушы Куралыкта. Ә хәзер — нибары унбер! Колхоз эшенә ярардай ир-атлар тик жиде бөртек. Шуларның бишесе колхозда түгел, Үшемкә ПМКасында эшли. Бишесе дә тракторчы. Үшемкә — Куралыкка алты чакрым. Көн саен кайта-китә йөриләр. Һәркайсы үз тракторы белән йөри. Әле син тракторлары нинди диген: барысыныкы да — «К-150». Шулай итеп, көн саен жиде йөз илле ат көче куып, алты чакрымга баралар, алты чакрымнан кайталар. Үзем тапкан мал түгел, колхозныкы жәл түгел! Ул ПМК житәкчеләре ни карый торгандыр — шайтан белсен! Утынга яки печәнгә трактор белән йөрүне әйтеп тә торган юк инде, хәтта бер кап шырпы өчен дә күрше авыл кибетенә трактор белән баралар. Эчә торган суларына тикле чишмәдән трактор белән ташыйлар.

Ә син шуларга иң тәжеле йомыш белән, әйтик, инде акчасын түләп куйган әзер утынны алып кайтып бирегез әле дип барып кара, мең төрле сәбәп табып, кире борып жибәрәчәкләр.

Ир-атлар гына түгел, авылның хатын-кызлары да өнәми Ханәфине. Аның чишмәдән су алып менә алырлык рәте булмаганын барысы да белеп-күреп тора. Үзең ялынмасаң, ник шунда берәрсе үзе белеп бер көянтә су алып менеп бирсен! Һәй, кая анда су алып менеп бирү, хәтта Ханәфи менә шушы бүкәндә утырып торганда да аны күрмәмешкә салышып үтә ул тубал башлар! Ярый яшьрәкләре, Ханәфинең элек кем булганын белмәгәннәре шулай мәнсез дә булсын ди: хәзерге яшьләрдә олыларны олы итү дигән нәрсә юк инде ул. Алар тик үзләрен генә ярата, тик үз мәнфәгатьләрен генә кайгырта. Ханәфи шикелле өлкән буын кешеләренә чүп итеп кенә карыйлар. Анысы — күптән билгеле нәрсә. Тик шунысы гажәп: яшь-жилкенчәкләр генә түгел, элек, Ханәфи председатель булып эшләгән чагында, аның өчен чукынырга әзер торган үз кордашларына хәтле белмәгән-күрмәгән булып кыланалар. Менә шунысына гарьләнеп бетә алмый Ханәфи...

Әһә, әнә, заманында Ханәфи өчен гарешкә ашырга торган хатын-кызларның берсе — Хөснижамал капкаларыннан килеп чыкты да бу якка таба килә. Инде иллесен тутырды, ә аяк атлаулары утыз яшәр хатын-кызныкыннан бер дә ким түгел: шундый жиңел итеп, уйдырып-уйдырып атлый.

Ханәфи, инде менә дүртенче елы, рәтләп йөри дә алмый. Хөснижамал янында ул бөтенләй бабай булып күренә. Ә Хөснижамал әнә...

Тормышы да җиңел булмады бит үзенең, сыңар канат белән гомер итте. Тик ир-атлы хатыннардан бер дә ким яшәмәде: чәчәктәй матур итеп киенде, йорт гутырып, мал-туар асрады, җимертеп колхоз эшен эшләде, кызын укытып, кеше итте. Әнә, һаман әле яшь килен шикелле җилкенеп-җилкенеп килә. Кулына тавык тоткан, суйдырырга килүе булса кирәк. Кияве белән кызы кайткан, күрәсең. Берәр эшен эшләп китәргә кайтканнардыр инде. Тавыгын Ханәфигә суйдырырга килүе булса — эшләре хөрти Ханәфинең. Берданн, кымшанырга да ярамый — биле авырта. Икенчедән, үз гомерендә тавык суйганы юк. Җан кыярга теләмәүдән түгел. Андый вак-төяк эшләр белән булашып торырга вакыты булмый иде аның. Ә тавык итен ярата иде үзе! Заманында көненә икешәр тавык ашаган чаклары булды. Ярар, әгәр суеп бир дисә, гозерен кире кагып булмас инде. Пычагын Хөснижамал үзе алып чыгып бирсә, ничек тә суясы булыр. Башын өзә алса — бик җиткән...

Туктале, аның янына килүе түгел ахрысы бу хатынның. Әнә бит, бу якка гел дә карамыйча, күрмәгәнгә салышып үтеп бара! Һич югы, күнел өчен булса да: «Нихәл, абзый?» — дип, исәнләшеп кенә китсә дә ярар иде. Юк, ыжлап та бирми үтеп китте әнә!

— Сәлам дә бирмичә үтеп китүеңмени, Хөснижамал?

Туктады. Үзенә дә уңайсыз булып китте ахры: кызарып чыкты. Ләкин артыгын коелып төшмәде:

— Ә-ә, син икәнсең әле, Ханәфи абзый. Бик ашыгадырыем шул, күрми дә үтеп барам икән. Утын кисешергә дип балалар кайтканые. Шуларга төшке ашка тавык суйдырырга йөрүем.

— Үзем дә суеп бирә алырыем.

— Мәшәкатьләп торасым килмәгәние шул сине. Аннары хәлең дә бик шәптән күренми. Ярар инде, Хисами картка гына суйдыртып алырга булдым. Аның кулы да бик тәмле, догасын да белә.

— Минем белән хәл белешеп, бер-ике авыз сүз сөйләшеп китәргә дә вакытың юк хәзер, ә?

— Сөйләшәсе сөйләшенеп беткән инде безнең, Ханәфи абзый.

Шулай диде дә үз юлы белән китеп барды. Кара син аны, ә: сөйләшәсе сөйләшенеп беткән, имеш. Заманында шушы Ханәфи абзаңны бер күрер өчен генә дә утка керерлек булып йөргәнеңне онытгыңмыни соң, чәчбикә?! Ханәфи абзаңның билләренә каеш урынына уралып, аның күкрәкләренә башыңны салып: «Ташла, бәгырем, шул Хәлимәңне. Ул сине минем кебек барыбер кадерли белми. Әйдә, безгә күч тә, тора башлыйк бергә, матур итеп гөрләшеп. Мин сине кадерләп-назлап кына торырмын!» — дип жылый-жылый ялынганнарыңны оныттыңмыни?!

Ханәфи абзаң тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә килеп керсә дә, аңа минуты белән табын әзерләп, куанычыңнан кая басканыңны белмичә өтәләнеп йөргән кеше син түгел идеңмени?.. Син идең бит ул, җаным, син идең!.. Сөйләшеп сүзең, сөешеп, назың бетми торган иде. Ә хәзер «сөйләшәсе сөйләшенгән...»

Дөресен генә әйткәндә, син үзең дә бит әллә кем түгел инде, Хөснижамал. Син дә сулыгып барасың. Юк, Ханәфи абзаң белән чуалган еллардагы Хөснижамал түгел син хәзер! Алай бик һаваланырга кирәкмәс иде. Ханәфи абзаң яныннан үткән чакларыңда сәлам дә бирмичә үтү — килешә торган эш түгел. Аңлый Ханәфи абзаң, Хәлимәне ташлап, синең белән тормаган өчен үпкәң зур булуын бик әйбәт аңлый. Бу хакта бик күп уйланганы бар аның. Шул чакта, сине тыңламыйча, ялгыш иттем ахры, дигән фикер дә башына килгәләгәне булды. Ләкин бит узган эшне кире кайтарып булмый аны. Бәлки, чыннан да, ул чакта Хәлимә белән кешеләрчә аерылып, синең белән кешеләрчә язылышып тора башлау хәерле булган булыр иде. Шулай иткәндә, ихтимал, Ханәфи абзаң бу көнгә калмас: сау-таза булыр, матур гына яшәп, әйбәт кенә эшләп йөрер иде... Бәлки, киресенчә килеп чыккан булыр иде. Кем белә аны...

Анысы шулай. Ләкин хәзер бер нәрсә ачык: Ханәфинең шушы

хәлгә калуына иң элек Хөснижамал сәбәпче булды. Әгәр аның белән бәйләнешеп китмәсә, ихтимал, ул бүтән беркем белән дә бәйләнешмәс, үзенең Хәлимәсе белән матур гына яшәп яткан булыр иде.

## 2

Аның Хөснижамал белән мәтәвекләнеп китүе ул көткәнгә караганда бик күпкә гади һәм ансат килеп чыкты. Сүз дә юк, Хөснижамал чибәр кыз иде. Ләкин бит һәр чибәр кыз Ханәфинеке булырга димәгән. Аннары килеп, Ханәфи инде өйләнгән, бала атасы булган иде. Ә ул егет чакта Хөснижамал әле яшьрәк, өлгереп-ачылып житмәгән, шуңа бер дә алай күзгә бәрелеп тормый иде. Соңгы елларда гына чибәрләнеп китте ул. Аны күргән саен, Ханәфинең йөрәге дерт итеп куя, һәм ул: «Шушы кыз минем хатыным булса, дөньяда миннән дә бәхетле кеше булмас иде. Их, ашыгыбрак өйләнелде шу-ул!» — дип офтана-үкенә торган иде.

Ханәфи председатель булып эшли башлаган елларда авыл жирендә кунакханә дигән нәрсәләрнең әле исе дә юк, районнан килгән кешеләрне фатирга зуррак өйле, бала-чагасызрак, чистарак яшәп торган хуҗалыкларга урнаштыралар иде. Ул яктан Хөснижамалның әнисе Гөлжамал апа бик тә кулай: бердән, өе бик чиста, икенчедән, Ханәфи кайчан мөрәҗәгать итсә дә, кире борып чыгармый, колхоз кунакларын һәйбәтләп ашатып-эчертеп, кирәк булганда кундырып та жибәрә иде. Ә иң мөһиме — аш-су пешерергә бик оста иде. Моны инде район начальствосы да белә, Куралыкка килгән чакларында туп-туры шуларга туктала лар иде.

Олырак кунакларның үзләрен генә калдырып булмый, алар белән Ханәфигә дә Хөснижамалларга кергәләргә туры килә. Өйдә булганда Хөснижамал да әнисенә булышып, кунакларга хөрмәт күрсәтеп йөри торган иде. Әнә шундый чакларның берсендә, тәмәке тартырга чыккан жиреннән кереп килешли, караңгы өйалдында очрашты аның белән Ханәфи. Шунда, форсаттан файдаланып, кызны кочаклап ук алды. Дөресен әйтергә кирәк, әле кайчан гына райкомда эшләгән, хәзер исә колхоз тикле колхозның житәкчесе булган кешегә артыгын кыланырга ярамавын, хатын-кыз мәсьәләсендә аеруча сак булырга кирәген, чөнки ул начальствоның байтагы нәкъ менә шул юлда «янганын» белә иде Ханәфи. Ә ул кичне Хөснижамалларда район милиция бүлеге начальнигы үзе кунак булып утыра, кыз алай-болай тавышлана башласа, эшнең күңелсезгә әйләнеп китүе дә бик мөмкин дип шүрләп тә куйган иде Ханәфи. Әмма, бәхетенә каршы (әллә, киресенчә, бәхетсезлегенә каршы микән?), кыз тавыш-тын чыгармады гына түгел, шуны көтеп торган шикелле, үзе дә Ханәфигә сыенды...

Менә шуннан китте инде эшләр! Алар атнасына алтышар мәртәбә очраша башладылар. Ханәфи өчен үлеп тора иде Хөснижамал, кая чакырса, шунда килә. Хикмәт шунда: ул үзе дә Ханәфине яшьтән үк яраткан, сиздерергә генә оялып йөргән булган икән.

— Син армиядән кайткач, сиңа күренер өчен, турыгыздан тугызар тапкыр үткән чакларым булды. Шуны бер дә сизмәдеңмени соң? — диде ул бер көнне Ханәфигә.— Юк йомышларымны бар итеп, син кайткан көннәрдә көн саен диярлек өегезгә кереп йөрдем. Шуннан да берни чамаламадыңмыни?

— Һе, армиядән кайткан егет тирәсендә чуалучы кызлар күп була инде ул. Бер син генә түгел, бүтән кызлар да бик бөтерелеп йөрде ул чакта минем тирәдә. Тик ул көннәрдә мине кызлар түгел, эшкә кая һәм ничек урнашу мәсьәләсе борчый иде. Аннары килеп, син дә бит ул чакта хәзерге шикелле пешкән алмадай чибәр түгел, чандыр гына, оялчан гына бер кызчык идең. Мин өйләнгәч кенә, шушылай сылуландың син.

— Шул шул менә: сез, ир-атлар, хатын-кызның тышкы матурлыгын гына күрәсез. Һәм бик соңлап күрәсез!

— Ә шулай да табыштык бит әле менә! Табыштык һәм бер-беребезне яратабыз. Безгә тагын ни кирәк?

— Уйлап караган кешегә бик күп нәрсә кирәк. Ә безнең синең белән телгә алып әйтерлек бер нәрсәбез дә юк. Иң әлек безнең арада синең Хәлимәң бар! Аннары... синең малаең бар! Ә безнең менә шушылай, кеше күзеннән кача-поса, курка-калтырый очрашып йөрүебез бозыклык дип атала. Ә ул бозыклыкның башы синдә: хатынымны аерам, бергә булабыз без синең белән дип, син алдадың мине.

Андый чакта Ханәфи ни дип әйтергә дә белмичә аптырап кала, сүзне икенчегә борып җибәрергә тырыша торган иде.

Авыл җирендә яшерен эшне озак саклап буламыни? Ханәфи белән Хөснижамал арасындагы бәйләнеш хакында да халык арасында башта чыш-пыш, имеш-мимеш китте. Аннары ачыктан-ачык сөйли башладылар. Әлбәттә, бу хәл Ханәфинең хатыны Хәлимәгә дә ирештерелгән иде. Гөнаһысы кирәк түгел, Хәлимә сабыр хатын булып чыкты: бүтәннәр шикелле тавыш-гауга куптарып, Хөснижамал белән әчелешле булып йөрмәде. «Әгәр шушы эшең чын икән, гомер-бакый бәхиллегем юк, Ханәфетдин!» — дип үкси-үкси бер җылады да шуның белән тынды.

Ә менә Хөснижамал үзе бик авыр кичерде. «Кыз килеш кеше теленә керттең, дөньяда яшәрлегемне калдырмадың. Син бит ир кеше, миннән олы кеше, бала атасы. Шулай булгач, ни буласын белергә тиеш идең. Ә син минем яратуымнан явызларча файдаландың да хәзер берни булмагандай йөри бирәсең! Әйдә, хатыныңнан аерыл да өйлән миңа!» — дип, теңкәсенә тиде Ханәфинең.

Ханәфи аңа: «Мин бит житәкче кеше, миңа аерылышып, хатын алыштырып йөрергә ярамый. Без бит бер-беребезне яратышабыз. Кеше сүзенә карамабыз, җае чыкканда очраша торырбыз. Мин сиңа ярдәм итеп торырмын»,— дигәч: «Миңа синең ярдәмең кирәк түгел, син үзең кирәк. Кеше арасында синең белән бергә булу кирәк. Кача-поса сөешеп яшәгәнче, бу дөньяда яшәмәвең мең артык. Әгәр миңа өйләнмисең икән — я суга төшеп, яки асылынып үләм!» — дип тә куркытып карады.

Ләкин Ханәфи бирешмәде, каты торды: «Синең шикелле алданган һәр хатын үлә торган булса, бу дөньядагы хатын-кызларның уннан өче генә исән булыр иде. Син миңа әкият сөйләмә, яме!» — диде ул аңа.

Шушы сүзләреннән соң Хөснижамал тагын ныграк балавыз сыга башлар дип көткән иде. Алай булмады. Хөснижамал кинәт усалланып, күзләрен ялтыратып беркавым карап торды да: «Әһә, син әле шулаймы? Их, син, бөҗәк!» — дип, чалтыратып, ике тапкыр Ханәфинең яңагына чапты һәм кырт борылып китеп барды.

Берничә көннән, инде тынычлангандыр дип, Ханәфи очрашырга итеп караса да, Хөснижамал аны якын китермәде.

Берәр ай чамасы үткәч, Сабан туе чорында, Арча якларындагы туганнарына китеп барды да шунда бер егеткә кияүгә чыгып калды. Ләкин...

Бәхеткәйләрең булмаса, табып булмый эзләп тә дип, юкка гына җырламыйлар икән. Кияүгә китүенә ел тулганда аерылып кайтты ул. Үзе генә түгел, ике айлык кыз бала да күтәреп кайтты.

Ул арада башкалар белән мавыгып, Ханәфи Хөснижамалны бөтенләй диярлек оныткан иде инде. Кайтып төшкәч тә, ул колынлы бия белән ни эшлисең дип, бер дә алай исе китмәгән иде. Ләкин колхозга килгән кунакларны әле һаман фатиргә шуларга урнаштыралар, Ханәфигә, теләсә-теләмәсә дә, Хөснижамал белән очрашырга-туры килә иде (шунысын да әйтергә кирәк: Гөлҗамал апа, ни хикмәттер, Ханәфи белән Хөснижамал хакында гайбәт чыккан чагында да, соңыннан да ни актан, ни карадан Ханәфигә теш агартып сүз әйткәне булмады). Ә очрашкач сөйләшмичә булмый бит инде. Башта — «исәнме — исән», «кайттың-

мы — кайттым» белән генә чикләнделәр. Аннары Ханәфи: «Тора алмадыгызмыни, кайсыгызда булды гаеп? Ирендә булгандыр инде. Югыйсә синең холкың кешегә ярамаслык түгел иде»,— диде.

Хөснижамал аның белән килешер, хатын-кызга хас булганча, ирен яманлап зарлана башлар дип көткән иде. Ләкин алай булмады.

— Гаеп анда түгел, үземдә,— диде Хөснижамал.— Торып булмаслык кеше түгел, торырга буладырые. Ни бер авыр сүз әйткәне, ни ачулы караш күрсәткәне булмады. Күземә генә карап торадырые. Минем урында бүтән хатын булса, рәхәтләнеп яшәр, куанып бетә алмасые. Ә мин тора алмадым. Чөнки сине сагындым. Шуңа кайттым менә!

Дөресен генә әйткәндә, тыштан битараф булып кыланса да, Ханәфи үзе дә тансыклаган иде Хөснижамалны. Үзенең әчкерсезлеге, тыйнаклыгы белән күңелен тартып тора иде ул аның. Ләкин Ханәфи моны Хөснижамалга әйтүне кирәк тапмады:«Хатын-кызга йомшаклыгыңны сиздер генә — хәзер иңеңә менеп атланырга тора алар!» — дип, юри кискен итеп:

— Кайтасы булгач, бозау ияртмичә генә кайтырга ярамый идемени аны? Бу дөньяда синекеннән башка да ятимнәр бетәсе түгел бит! — диде.

— Ятимнәр, әйе, житәрлек. Ләкин алар ике төрле була: бар атасыз ятимнәр, бар аталы ятимнәр. Аталы ятим булуга караганда, атасыз ятим булу хәерлерәк, минемчә. Әгәр анда калса, минем кызым аталы ятим буласы иде. Чөнки кызның атасы ул түгел. Дөрес, ул бу турыда белми. Кыз үземнеке дип, башы күккә тиеп йөри иде. Ләкин мин — ана кеше, бала аннан түгел икәнен беләм бит. Шуны белә торып, ничек итеп тыныч кына яшәмәк кирәк бу дөньяда? Әгәр шулай яшәсәм, минем өчен моннан да зур җинаять булмас, гомерем буена үземне үзем каһәрләр идем. Менә шуларны уйладым да, аталы килеш ятим булып йөргәнче, атасыз ятим булсын дип, алып кайттым кызымны, Ханәфи абзый. Әтисе икәненне белмәсә дә, сине күреп үссен дип алып кайттым!

Әле дә хәтерендә Ханәфинең: Хөснижамалның бу сүзләрен ишеткәч, тәннәре чымырдап, эсселе-суыклы булып китте.

Ул коты алынып:

— Әллә син ул баланны миңа такмакчы буласыңмы? — дигәнен үзе дә сизми калды.

Тик, шөкер, куркуы урынсыз булып чыкты. Хөснижамал аңа үтергеч итеп карап алды да, мыскыллы елмаеп:

— Курыкма, мин аны сиңа беркайчан да такмаячакмын! Үзем дә тагылып йөрмәячәкмен. Намусың белән оятың юк икән, мин сине ни эшләтим? Яшә! Тик шуны бел: шушы хәлеңдә дә мин сине яратам!— диде.

Менә монысы ярый. Монысы аның икенче мәсьәлә инде. Ханәфи үзе дә бик тели иде Хөснижамалны. Шулай да сер бирмәде:

— Син, давай, шаярма минем белән. Җыен юкны лыгырдап йөреп, минем афтаритка сугасы булсаң — яхшылык көтмә! — дип кисәтеп куйды.

Тагын кеше теленә керүдән шикләнеп, берәр ай аның янына бармыйча йөрде.

Әмма үзенең яшьлеге-чибәрлеге белән Хөснижамал аның күңелен һаман магнит шикелле тартып тора иде. Элекке кебек еш булмаса да, алар тагын очраша башладылар. Башта Хөснижамал аңа бернинди шарт куймады, һичнинди дәгъва белдермәде. Ләкин хатын-кыз үзенең ахмаклыгын итми калса — хатын-кыз буламыни? Тора-бара теге тагын: «Ташла Хәлимәңне, күч безгә дә, гөрләшеп яши башлыйк»,— дип әгъваларга тотынды.

Мондый хәлдә шуннан да яхшысы булмас, эшләр тирәнгә киткәнче котылып калырга кирәк бу чәчбикәдән дип, Ханәфи шуннан соң аның янына бүтән бармас булды...

Хөснижамалның «кыз синеке» дигән сүзе хак булып чыкты: кызы, суеп каплагандай, Ханәфигә охшаган иде. Ханәфинең күз алдында үсте ул кыз. Үскән саен, аңа күбрәк ошый барды. Кызым, дип әйтәсе килгән чаклары булды Ханәфинең. Ләкин йөрәге җитмәде, кешедән курыкты... Ул кызның инде үзенең дә баласы бар. Кияве бик уңган нәрсә булып чыкты. Түбән Кама химкомбинатында смена башлыгы булып эшли ди. Яшь кенә булса да, инде машина сатып алырга да өлгергән. Атна саен диярлек кайтып, Хөснижамалга булышып, әле тегесен, әле монысын эшләп китә. Кирәк нәрсәләрен апкайтып тора. Әнә, бүген дә утын кисешергә кайткан ди бит әле. Хөснижамал өчен үлеп тора кияве. «Әби» дип түгел, «әни» дип кенә йөри. Берәү үз әнкәсен дә болай хөрмәт итми. Мисалга әллә кая барасы түгел, Ханәфинең Хәсәнен генә ал. Үги малае түгел, үз малае ул Ханәфинең. Әмма үги ата урынына да күрми Ханәфине. «Әти» дип әйткәне юкка да егерме еллап бардыр инде. Студент чагыннан ук авылга әнисе янына каникулга кайткан вакытларында Ханәфине бөтенләй күрмәмешкә салышып китеп бара торган иде. Тик соңгы ике-өч елда, Ханәфинең хәле тәмам начарланып, йөрер рәте калмагач кына, язын бәрәңгесен утыртып, көзен бәрәңгесен алып китәргә кайткалап йөри башлады. Анда да бүтәннәр шикелле вакытында түгел, я кирәгеннән тыш иртә, яисә бик соңарып кайта. Инде менә әбиләр чуагының соңгы көннәре. Авыл халкы бәрәңгесен алып бетереп килә. Кызы белән кияве Хөснижамалның бәрәңгесен үткән атнада ук алып киттеләр. Бүген, әнә, коры чакта утыннарын кисеп куярга кайтканнар.

Ә Ханәфинең Хәсәне һаман юк. Ханәфи аны үткән атнаның үткәнендә үк көтә башлаган иде инде... Кайтса, дөрес, үзе генә кайтмый Хәсәне: хатынын, олы малаен һәм Хәлимәне дә алып кайтачак инде ул. Бер көн эчендә бәрәңгене алып бетереп китә инде алар китүен. Тик нигәдер кайтып җитә алмыйлар шул әле. Инде кояш төшлеккә якынаеп килә. Төш турына да кайтып җитмәсәләр, ничек алып бетерә инде алар ул унбиш сутый бәрәңгене? Киләсе атнага калсалар, яңгырлар китүе дә бар лабаса. Их-их-их! Үз балаң ата итмәүдән, үз хатының ир итмәүдән дә яман хәл бармы икән бу дөньяда?!.

Яшь чагында Ханәфинең башына да килмәде шул мондый көннәргә калыры. Дөнья гел үз кулында булыр, тормыш гел ул дигәнчә барыр шикелле иде. Кем уйлаган аны ялгызлык белән көн иткән Хөснижамал шушындый матур тормышка тиенер, ә Ханәфи шушы тикле кадерсезлектә калыр дип?.. Кара, Хөснижамал дигәннән, нигә озаклады соң әле ул? Тавык суйдыртырга гына киткән иде бит. Хисами картның анда-монда киткәне күренмәде — өйдә булырга тиеш иде. Әллә карт бакчаларында бәрәңге алуда булды, Хөснижамалның тавыгын шунда гына суеп бирде микән дә тегесе, Ханәфи яныннан үтәргә теләмичә, ындыр артлатып кына кайтып китте микән? Мөгаен шулайдыр. Югыйсә бер тавыкны бу кадәр озак суймаслар иде...

Ә бит урамнан үтсә, Ханәфинең Хөснижамалга әйтәсе сүзе бар иде. «Сөйләшәсе инде сөйләшенеп беткән безнең дип, син бик алай кукыраеп йөрмә әле, Хөснижамал,— димәкче иде аңа Ханәфи.— Кызымнан уңдым дип куанып йөрисең дә бит, ул кызның атасы мин икәнен онытма. Шулай булгач, синең бүгенге бәхетле тормышыңда минем дә өлешем зур. Шул кызың булмаса, аның әйбәт кияве булмаса, ялгызың ни эшләр идең?.. Ә син, панимаеш, минем белән исәнләшергә дә теләмисең! Йөри алмаганымны беләсең, хәлемнең шәптән түгел икәнен күреп торасың. Һич югы берәр көянтә су апменеп бирсәң дә ярар иде ичмасам. Яшь чагыбызда бергә булган рәхәт минутларны бөтенләй үк онытырга кирәкмәс иде сиңа. Аларын оныткан булсаң, ахыр чиктә балаңның атасы булган өчен генә дә аз-маз ярдәм иткәләр идең аны!» — дип тә исенә төшермәкче иде Ханәфи.

Бәлки, бакча артлатып кына кайтып китеп, дөрес тә иткәндер ул хатын. Төптән уйлап караганда, ни хакы бар Ханәфинең аңа дәгъва

белдерергә? Хөснижамалдан туган теге кыз үзенеке икәнен белә идеме Ханәфи? Белә иде! Ул баланы бер башы тәрбияләү Хөснижамалга җиңел булмавын белергә тиеш идеме ул? Тиеш иде! Аз гына, күңел өчен генә, сирәк-мирәк кенә булса да ярдәм иткәләргә тиеш идеме Ханәфи ул баланы үстерергә? Тиеш иде! Моңа мөмкинлеге бар идеме? Ничек кенә бар иде әле! Ул елларда хәзерге шикелле председательнең ни эшләгәнен тикшереп-исәпләп тормыйлар, колхоз мөлкәтен теләгәнчә тотарга була иде. Үз кесәсеннән бер тиен чыгармыйча да рәхәтләнеп ярдәм итә ала иде аңа Ханәфи. Ә ул, ахмак, Хөснижамалның ни үзен, ни аның кызы Гөлинәне бар дип тә белмәде. Алай гынамы соң әле? Кара-каршы очрашканда, Хөснижамалга хәтта сәлам дә бирмичә үтә иде ул. Шулай булгач, хәзер үзеңә кирәк булгач кына, ничек итеп аңа дәгъва белдермәк кирәк? Хөснижамал — юләр хатын түгел, барысын да белә, барысын да бик яхшы хәтерли торгандыр...

Анысы шулай шулаен, ләкин Ханәфинең хәлен аңлап, күңел өчен генә булса да, тукталып бер сөйләшеп, һич югы үзенең үпкәсен әйтеп, орышып китсен иде ичмасам. Анда да бераз җиңелрәк булыр иде Ханәфигә. Югыйсә бигрәкләр кыен бит аның менә шушылай битарафгорур булып йөрүен күреп торулары. И-и-их, ун гына ел гомерен кире кайтара алсын иде менә хәзер Ханәфи!..

### 3

Урам тып-тын. Адәм заты түгел, хәтта эт тә күренми. Берәр эт булса, шуның белән сөйләшеп утырыр иде Ханәфи. Эт дигән җанвар барысын да аңлый ул, тик сөйләшә генә белми. Яхшысын да, яманын да аңлый. Яманлыкны бигрәк тә. Аңлап кына да калмый, яманлык кылучыны фаш итәргә дә тырыша: өрә ул андый чакта. Котырып-котырып өрә. Көндез, син тиешле эш белән дөрес юлда йөргәндә, бар дөньясына битараф-гамьсез булып, башын алгы аякларына салып, капка төбендә тик ята. Хәтта койрыгына бассаң да ырылдамый андый чакта. Ә менә берәр төрле яшерен эш белән йөргәндә, әйтик, берәрсенә кереп, шыпырт кына салып чыгарга кирәк булганда, әллә кайдан гына сизенеп, шундук артыңнан килеп җитә дә, чалбар төбеңне умырып алырдай булып, һау-һауларга тотына.

Авыл этләренең әнә шул этлекләре аркасында ниятен гамәлгә ашыра алмыйча калган чаклары байтак булды Ханәфинең. Ләкин этлеккә калгач, Ханәфинең үзендә дә этлек җитәрлек иде. Авылдагы этләрнең нәселен үчерде ул: умарта каравылчысы Хафиз карттан мылтык алып торып, сигез этнең сигезен дә үз кулы белән атып үтерде.

Колхоз председателен гадәттә «хуҗа» дип йөриләр. Ә хуҗа кешегә ара-тирә берәр түшкә сарык ите алып кайтырга гына ярыйдыр, шәт. Ханәфи алып кайткалый иде. Ә менә теге эт дигән җанварлар шул бик гади хакыйкатьне һич аңларга теләмиләр. Берәр нәрсә алып кайтып килгәнеңне шундук белеп, капкадан кереп киткәнче артыңнан өреп киләләр. Әнә шуларына бик нык ачуы чыга иде Ханәфинең. Шуңа, эһ тә итмичә, барысын да атты ул аларның. Шуннан бирле авылга эт заты кергәне юк...

Ә менә хәзер аңа иптәшкә берәр эт булса, бик шәп булыр иде. Һич югы шуның белән сөйләшеп утырып, күңелен бушатыр иде Ханәфи. Көннәр буе менә шушылай япа-ялгыз утырулары бигрәк кыен бит. Беркем килми аның янына. Җәй көне ичмаса урамда бала-чага була торган иде. Үзе белән сөйләшмәсәләр дә, шуларга карап юанып утыра иде Ханәфи. Хәзер алар да юк. Яңа сауган сөт эчәргә, саф һава суларга дип, шәһәрдән җәйгә авылга, әби-бабалары янына кайткан ул балаларны кайсын балалар бакчасына, кайсын мәктәпкә укырга әти-әниләре алып китеп бетерде. Ә авылның үзендә имгә дисәң дә мәктәпкәчә яшьтәге

бала юк. Мәктәп яшендә ике кыз, бер малай бар барын, тик алар эш көннәрендә Укмас мәктәбендә интернатта, ял көннәрендә әти-әниләре янында булалар. Урамга чыксалар да, Ханәфиләр тирәсенә якын килмиләр. Әти-әниләре шулай куша торгандырмы, үзләре өнәмиләрдерме — шайтан белсен.

Хәер, авылда балалар күбрәк булса, урамына да чыгарлар, Ханәфи янына да килерләр иде. Мәктәп тә булыр иде. Әнә, урамның аргы ягында, Ханәфиләргә каршы гына мәктәп бинасы. Сүтеп ташламасалар, тагын утыз ел рәхәтләнеп торачак әле. Ләкин, инде ун елдан артык, аның ишеген ачып кергән кеше юк. Чөнки укырга балалар юк. Бөтен хикмәт шунда: яшь ата-аналар юк авылда. Кайсы Казанга, кайсы КамАЗга, кайсы Түбән Камага китеп беттеләр.

Ә бит заманында гөрләп торган авыл иде шушы Куралык. Дүрт класслы мәктәбе бар, класс саен унсигезәр-егермешәр укучы була иде. Кырык сигезенче елны хәтта беренче класска утыз бер бала укырга кергәне дә хәтерендә әле Ханәфинең. Сугыш алдыннан, кырыгынчы елны туган балалар иде алар. Шул утыз бер баланың егерме өче малай булып, тик сигезе генә кыз иде. Гаҗәп бит ә! Әйтерсең, әтиләре сугыш кырында сибелеп калачагын табигать алдан белгән дә, нәселләрен саклап калу өчен, махсус шулай ул малайларны дөньяга күпләп тудырган.

Ул балалар хәзер кырык алтыда. Дөнья бүген шулар кулында. Политиканы шулар алып бара. Җаваплы урыннарда — алар. Матди байлыкларны тудыруда да җиң сызганып шулар эшли. Мораль яктан иң тотнаклы буын — шулар буыны. Теләсә ни әйтсеннәр, әмма Табигать дигән бөек көчнең нindидер без белми торган серле могҗизасы — алдан белеп-күреп эш итү сәләте барына инанмыйча мөмкин түгел! Авылда яшәсә дә, дөньядан бөтенләй үк артта калган кеше түгел Ханәфи: радиосы бар, авыру сәбәпле эшкә ярамагач, буш вакыты — тәүлегенә егерме дүрт сәгать. Дөнья хәлләрен тыңлап-белеп бара. Галимнәр әнә үзләре үк әйтеп торалар: күп нәрсәгә табигатьтән өйрәнергә кирәк әле диләр. Күп кенә зур ачышлар табигатьне өйрәнү нәтиҗәсендә туа диләр... Әйе, табигатьтән бик күп нәрсәгә өйрәнергә кирәк әле адәм балаларына.

Тик шунысы кызганыч: кырык сигезенче елны беренче класска укырга кергән теге утыз бер баланың бүгенгесе көндә нибары дүртәве генә Куралыкта яши. Шуларның өчесе — хатын-кыз. Дүртесе төрле сәбәпләр белән вафат булган. Башкалары — читтә. Шулай булгач, ничек үчмәсен ул авыл? Әйе, үчә Куралык, үчә.

Ник үчә, нинди сәбәпләр аркасында үчә? Яле, һәйбәтләп уйлап да, шул сорауларга җавап бир әле, Ханәфетдин? Ләкин алдашма, дөпдөресен әйтеп җавап бир! Авылның кайчан һәм нилектән тарала башлавын бүген теләсә кемгә караганда син яхшырак беләсең. Чөнки ул синең күз алдыңда таркалды. Аны тарката башлаучы кеше кем иде?.. Кызганыч, әлбәттә, ләкин ул кеше — син бит, Ханәфетдин җаным! Онытканга сабышып, үзеңне-үзең алдап утырма. Барысын да хәтерлисең син. Ничек кенә хәтерлисең әле!

## 4

Син колхоз председателе булып эшли башлаган илле икенче елда шушы Куралыкта ничә йорт бар иде? Илле җидеме? Шул илле җиде йортта колхоз эшенә яраклы житмеш тугыз кеше булуын да бик әйбәт хәтерлисең, шулай бит? Ул чакта Куралык үзе аерым колхоз һәм аның исеме «Кызыл үрнәк» иде. Син председатель урындыгына утырганда, «Кызыл үрнәк» язгы чәчүдә яки урып-җыюда, туңга сөрүдә яки көзге чәчүдә булсын, дәүләткә ит һәм сөт тапшыру ягыннан булсын — рай-

онда гел алдынгы урыннарның берсен тотып килә иде. Ә хезмәт көненә түләү ягыннан исә районда аңа тиңләшерлек хуҗалык юк. Иң аз дигән елны да бер хезмәт көненә өч кило ашлык бүлеп бирмичә калмый иде «Кызыл үрнәк». Биш йөз җитмеш өч гектар сөрү җиренә йөз дә утыз бер баш аты бар иде колхозның. Ат башына нибары дүрт бөтен йөздән утыз җиде гектар җир туры килә, шуңа колхозның МТС тракторларына мохтаҗлыгы юк, җирне үз көче белән эшкәртә. Шулай булгач, дәүләткә натурплата түлисе түгел, планда каралганын тапшыралар, кирәк кадәр чәчүлек һәм фураж салалар да калганын колхозчыларга бүлеп бирәләр иде. Ә иң мөһиме шул: колхозчылар арасында эшкә ирену дигән нәрсә юк, эш сайлап тору яки анда эштә низаглашып йөрү юк. Бар халык бер гаилә кешеләредәй тату булып, бер-берләреннән уздырырга тырышып эшли иде. Әйтик, кул белән арыш уруның көнлек нормасы — унсигез сутый, әмма уракчылардан берәү дә норма үтәү белән генә калмый, утызар-утыз бишәр сутый уручы хатын-кызлар була иде. Хәзерге хатыннар арасыннан, бар, табып кара син утыз биш сутый арыш урырдай берәрсен! Хәзергеләрнең күбесе урак уру түгел, урак дип аталган эш коралының нинди икәнен дә белми. Чөнки урак дигән нәрсәне бөтенләй чыгармыйлар хәзер. Һәрхәлдә, соңгы биш-ун елда Ханәфинең кибетләрдә урак күргәне булмады. Ул колхоз председателе булып эшләгән елларда ике мең гектар чәчү мәйданы булган колхозларда бер «Коммунар» комбайны булса, сөенеп бетә алмыйлар, алар бай санала һәм алдынгылар рәтендә йөри иде. Ә хәзер, әнә, шушы Куралык авылы карый торган бер «Кызыл юл» колхозында гына да утыз ике комбайн бар. Комбайн башына нибары сиксән тугыз гектар иген туры килә, диделәр быел. Бик хәтерендә әле Ханәфинең: ул председатель булып кайтасы елны «Кызыл үрнәк» колхозы урып-җыюны өченче сентябрьдә төгәлләгән иде. Ә быел, шул тикле комбайннары була торып, «Кызыл юл» колхозы игенне унынчы сентябрьдә генә җыйнап бетерә алды. Кайбер колхозлар аннан да соңгарак калды. Эһ-һе-һе, ялкауланды халык! Ваемсызланды. Машина эшләр әле дип, шефлар килеп эшләр әле дип, тик яталар. Ник шунда бөтен үстергән ашлыгың җир өстендә ятып калмый. Болай булса, кая барып чыгарлар — белгән кеше дә, ул хакта кайгырткан кеше дә юк. Ә бит сугыш афәте килеп чыгып, иген игү, урак уру эшләре кул көченә, хатын-кызларга калса, ни эшләр икән болар? Юк, урак урудан бөтенләй үк биздермәскә иде аларны. Ичмаса мәктәптә хезмәт дәресләрендә булса да урак тотарга өйрәтәсе иде авыл балаларын.

Әгәр үз кодрәтендә булса, Ханәфи нәкъ менә шулай эшләр иде дә... Һе, «эшләр иде!»... «Кодрәтендә булса!».. Ә бит кодрәтле заманнары булды аның. «Кызыл үрнәк» колхозының дилбегәсен кулына алганда, аңа нибары егерме җиде, җир җимертеп йөри торган чагы иде. Заманына күрә белеме дә аз түгел, җиде класс укыган иде. Кырык дүртенче елдан алып соңгы көненә кадәр сугышта булган, өч медаль, бер орден тагып, лейтенант чины алып кайткан егет иде ул. Кайтуына ай да үтмәде, финагент итеп районга алдылар үзен. Анда эшли башлавына дүрт ай дигәндә, азык-төлек кибетендә сату итүче йомры гына, житез генә бер кызга — Хәлимәгә өйләнде. Әтисе сугыш кырында чехлар җирендә ятып калган, әнисе белән икәү генә яши иде Хәлимә. Әнисе дә, Хәлимә үзе дә бик ипле, бик итагатьле кешеләр, берсе кияү дип, икенчесе Ханәфетдин җаным дип кенә торалар, ни әйтсәң — шуңа риза, ни эшләсәң — шуңа канәгать иделәр. Артык чибәр булмаса да, нәкъ менә шушы Хәлимәгә өйләнгәненә куанып туя алмый иде Ханәфи. Өйләнешүләренә ел дигәндә, уллары Хәсән туды. Ул чакта җир йөзендә Ханәфидән дә бәхетле кеше юк иде. Чөнки аның яраткан баласы, сөекле хатыны, аны үз улыннан болай якын күрә торган әбисе һәм ул әбинең торак дигән нәрсәсе бик кытлык булган шул заман өчен зур-зур ике бүлмәле фатиры бар иде. Финагент булып дүрт ел чамасы эшләгәч,

зуррак эшкә дә сәләтле икәнен күреп, Ханәфине башта райкомга инструктор, аннары бүлек мөдире итеп күтәрделәр. Әйе, ул елларда аның ни эш ягыннан, ни тормыш ягыннан зарланырлык урыны юк, тик бер генә борчуы бар: әнисе Куралыкта ялгызы гына тора, бик еш авырый, шуңа Ханәфине семьясы белән үз янына авылга кайтарасы килә иде. Аларның авылга кайтуына Хәлимәнең әнисе дә каршы түгел, ә Хәлимә үзе атлыгып тора. Тик Ханәфи генә, анда кайтып, кайда эшләрмен икән, гади колхозчы булып йөрмәм бит инде дип, тәвәккәлли алмыйча йөрде. Озакламый анысының да җае чыкты: илле икенче елның башында Куралыкның колхоз председателе йөрәк авыруыннан кинәт кенә үлеп киткәч, райкомның беренче секретаре Василий Митрофановичка Ханәфи шуның урынына кайтырга теләвен әйтте. «Беренче» аны хөрмәт итә, аңа ышана иде: теләгенә каршы килмәде һәм Ханәфине туган авылына, «Кызыл үрнәк» колхозына председатель итеп кайтардылар.

Шулай итеп, дөнья түгәрәкләнгән, бар тырышлыгын биреп, эшлисе дә эшлисе иде аңа. Ләкин...

## 5

Ханәфи авылга председатель булып кайтканда, әнисе алты почмаклы өйдә бер ялгызы яши һәм ул өй әле рәхәтләнеп егерме ел торырлык иде. Аны әтисе, мәрхүм, Ханәфигә дүрт яшь тулган елны җиткергән һәм үзе урман каравылчысы булып эшләгәч, сагызы алынмаган нарат бүрәнәләрдән бураткан иде. Ә Ханәфи нишләде? Кайтып җитәргә өлгермәде, үзенә яңа йорт салдыру артыннан чабарга тотынды! Аңа кадәрге председатель, җиде ел эшләп тә, үзенә өй салдыру хакында уйламаганын, җитеп килә торган дүрт баласы белән искереп барган кечерәк кенә бер өйдә яшәгәнен, ләкин аңа карап дәрәҗәсе бер дә кимемәвен, киресенчә, исеме бөтен районга билгеле булуын белә иде бит кана Ханәфи. Шуннан үрнәк алырга кирәк иде аңа. Тик алай итмәде. Райкомда бүлек мөдире чагында колхозларга шактый еш чыгып йөри, шунда колхоз председательләренең өйләре авылда бер булып, калай түбәләре белән балкып утыруын күрә һәм шуларга кызыга иде ул. Тик шул әйбәт йортлы председательләр җитәкләп бара торган колхозларның экономик хәлләре, гадәттә, арттагылар рәтендә булуына игътибар итмәде һәм шуннан үзенә тиешле нәтиҗә чыгармаган иде. Ә кирәк иде, ай кирәк иде аңа шулардан гыйбрәт алырга!..

Дөрес, Ханәфи алар шикелле үк комсыз кыланмады: йортын колхоз чутыннан салдырмады анысы. Районда эшләгәндә, бердән, хезмәт хакы әйбәт кенә, икенчедән, командировка еш булганга, ашавы күбесенчә авылларда үтә, ә кайтышлый я дәүләт бәясенә, яки гел дә бушлайга итен-маен, бәрәңгесен-онын алып тора, шуңа күрә аның үз хезмәт хакы бөтенләе белән диярлек янга калып бара иде. Тик Хәлимә генә ул яктан дөньяның рәтен белеп бетерми. Аның шикелле азык-төлек кибетендә эшләүче сатучылар үз тамакларын гына түгел, бөтен туган-тумачаларын туендырып торалар, ә бу үзе өйдән ташып ашый һәм бер тиен табыш та алып кайтмый.

— Гөнаһысыннан куркам. Кешенең тиене дә кирәк түгел. Соңыннан барыбер бише белән чыга ул. Болай ичмаса җаным тыныч. Теләсә кемнең күзенә туры карап сөйләшә алам,— дия иде ул.

Шулай итеп, дүрт-биш ел вакыт эчендә байтак кына акчасы җыелган: материалын дәүләт бәясеннән алганда әйбәт кенә йорт салдырырлык рәте бар иде Ханәфинең. Әмма йортны ул зурдан кубып, унга-ун итеп салдырырга тотынды. Дөрес, элекке танышлык аркасында район башлыклары хәленә керде: үзе сораган кадәр агачын да, түбә калаен да, хәтта мич чыгарырга кирпечен дә берсүзсез яздырып бирделәр.

Әмма йортны ул барыбер үз көче белән генә салмады. Әгәр пред-

седатель булмаса,— Ханәфи утырган җиреннән кыенлык белән булса да борылып, өйләренең бизәкләп эшләнгән тәрәз капкачларына, киң итеп һәм шулай ук бизәкләп эшләнгән кәрнизләренә күз салып алды — ул бу йортны елап үлсә дә, менә шушылай гүрнәчә шикелле итеп, бөтен шартын китереп салдыра алмас иде. Эш урыныннан файдаланып, шушылай эшләтте. Ул елларда авыл халкы матди яктан инде шактый тернәкләнгән, тамак өчен дип кенә яшәми, йорт-җир яңарту артыннан да йөри башлаганнар иде. Сугыш елларында да колхоз икмәк бүлеп килгәнлектән, Куралык халкы аерата хәлле яши: һәр өч хуҗалыкның берсе яңа йорт салдыру, яисә искесен яңарту белән мәшгуль, шуңа күрә авылда балта осталарына кытлык зур иде. Ләкин Ханәфи өчен бу мәсьәлә дә бик ансат хәл ителде. Балта осталарының берсе, авылның атаклы куштаны Кукы Габдулы үзе килеп: «Бер дә читтән кеше яллап йөрмә, Ханәфетдин. Минем янга тагын авылыбызның дүрт-биш кешесенә әйтсәң, бер ай эчендә курчак өе ясап бирәбез сиңа»,— диде. Шул чакта Хәлимәң: «Председатель кешегә үз кулы астындагы осталардан өй эшләтү ярый торган нәрсә түгел, атасы. Андый эшнең соңыннан барыбер сасысы чыга аның. Әйдә, тыңла сүзкәйләремне, тотыйк та Үшемкә урысларыннан салдыртыйк шул өйне!» — дип каршы килеп караган иде. Әнисе дә Хәлимәнең шул фикерен куәтләде. Дөресен генә әйткәндә, аның әнисе авыл осталарыннан салдыруга гына түгел, йортлары булган өстеннән йорт салырга йөрүгә гел дә каршы иде. Әмма Ханәфи Хәлимә белән дә, әнисе белән дә исәпләшеп тормады ул чакта.

Ә Кукы Габдулы сүзендә торды: ай да унике көн дигәндә, клуб хәтле менә шушы йортны салып бирделәр аңа. Әнә — Ханәфи тагын бер тапкыр йорт ягына карап алды — әле хәзер дә нинди нык һәм матур ул! Утыз өч ел инде салынуына. Тагын утыз ел утырса да, берни булмаячак. Чөнки түбәсе, гомерлек итеп, цинкланган калай белән ябылган, кәрнизләре киң: бәреп яуган яңгыр вакытында да стеналарына су тиярлек түгел. Су тимәсә, агач аз дигәндә дә ике йөз елга чыдый ул...

Анысы алаен алай да, тик шушы болын хәтле йортта торыр кеше калмады шул. Инде өченче ел, өй пәрие шикелле, тик берүзе яши Ханәфи. Бик китәр иде дә — барыр җире, сыендырыр кешесе юк.

Соңгы елларда гына түгел, баштан ук куанычын күрә алмады ул бу өйнең. Салып бетергәч, башта әнисе: «Мин әтиең салган үз өебездә калам. Шушындый әйбәт өйне ташлап чыгарга күңелем тартмый»,— дип, яңа йортка күчмичә, күпме нервысын бозды Ханәфинең. Дөрес, ул барыбер үзенекен итте: «Бер семьяга ике йорт тотарга ярамый, райкомнан берсен бетерергә кушалар»,— дигән булып, Янтык авылы кешесенә шактый кыйммәт бәягә сатты әтисе йортын. Тик ул акчаның игелеге булмады: күзгә күренерлек бер генә нәрсә дә алмады аңа Ханәфи. Районга, Казанга барган чакларында рестораннарда типтереп йөреп, ул акчаның ничек беткәнен сизми дә калды...

Акчасы аның бер хәл, анысына әллә ни шаккатмаска да була. Һәм Ханәфи аңа артык әһәмият бирмәде. Беткән мал — беткән дип, шул ачудан тагын бер тапкыр Казанга барып «жилләнеп» кайтты да тынычланган иде. Ә менә председатель буларак еллык эшенә халык алдында исәп-хисап ясар вакыт килеп җиткәч, йокылары качты. Ревкомиссия мәгълүматларына караганда, ул җитәкчелек иткән унбер ай эчендә колхозда утыз җиде баш сарык, ике сыер суелган, йөз житмеш кило бал, йөз кырык тугыз кило атланмай тотылган булып чыкты. Әлбәттә, бүгенге колхозлар мөмкинлегеннән килеп караганда, бу чыгым — пүчтәк кенә. Хәзерге колхозларның иң фәкыйрь дигәне дә язгы чәчү, урып-җыю чорларында бер ай эчендә моннан күбрәк азык-төлек тота. Ә бай тормышлы колхозлар урып-җыю вакытында механизаторларны һәм кыр эшендә эшләүчеләрне ашатырга ике көн саен бер сыер яки тана суеп торалар. Аларга беркем бер сүз әйтми. Тик эшләре генә барсын, тик игеннәрен вакытында чәчеп, вакытында җыеп алсыннар да дәүләт ал-

дындагы йөкләмәләрен тиешенчә үтәсеннәр генә. Ә Ханәфи заманында эшләр башка иде шул. Чөнки ул чакта колхозларда ашханәләр юк. Кырчылык эшендә эшләүчеләрне ашату юк. Колхозга ярдәм итәргә шәһәрдән килгән шефларны ашату юк. Ул елларда, киресенчә, авыл үзе шәһәргә шефлык итә: кыш көннәрендә колхоз шоферлары машиналары белән шәһәрдәге завод-фабрикаларда эшли иде. Ул елларда колхозның ит-мае тик бер нәрсәгә — колхозга килгән район вәкилләрен туендыруга гына тотыла иде. Колхоз аларны бушлай ашата, алар тукталган фатир хуҗаларына шулай ук колхоздан хезмәт көне язып барыла иде. Бәлки әнә шул ашау — байдан, үлем ходайдан булгангадыр, ул елларда вәкилләр авылда айлап-айлап ята, колхозларда берәр вәкил булмаган көннәр ел әйләнәсендә бармак белән санарлык кына иде.

Ләкин, ни генә димә, теге утыз җиде баш сарыкны, ике сыер түшкәсен, шуның өстенә тагын шактый гына бал-майны вәкилләр генә ашап бетермәгән, аларның байтагы колхоз начальствосының үз кирәкярагына тотылган иде. Колхоз хисапчысының тамагы бармы? Бар. Һәм ничек кенә иде әле! Бер ашаганда икешәр кило ит ашый, икешәр шешә хәмер эчә иде ул елларда хисапчы булып эшләгән чатан Әхәт. Шул чамасыз күп эчүе аркасында үз башына үзе житте дә: кышкы салкында исерек килеш районнан кайтышлый, чалу урында чанасыннан егылып, катып үлде, мәрхүм... Инде килеп, колхозда завхоз бармы? Бар. Колхоз мөлкәтенә кагылышлы мәсьәләдә син аны берничек тә читтә калдыра алмыйсың. Чөнки барысы да — аның кулында. Дөрес, анысы алай эчә торган кеше түгел, хатын-кыз иде. Әмма чүпрәк-чапракка, кием-салым җыю мәсьәләсенә килгәндә — әчкече ир-атлардан да комсызрак иде. Шактый күп имде ул хатын колхозны...

Ә шулай да теге мөлкәтнең иң күп өлеше Ханәфинең үзенә китте ул елны. Йорт салдырган елы иде бит. Кырык бер көн хуҗа исәбеннән ашап эшләгән балта осталарына гына да дүрт сарык түшкәсе, сыер арт санының яртысы китте. Моңарчы район җирендә яшәгәч, Ханәфинең үз терлекләре юк, барысы да колхоз маллары иде алар. Районнан килгән инспекторыдыр, чуртыдыр-муртыдыр, барысы да итенмаен сорап тора. Бөтенесенә үк булмаса да, аларның да кирәге чыгар, файдасы тиярдәйләренә яртышар түшкә сарык ите биреп җибәрелгәләнгән иде. «Синең колхоздан дүрт ат, сигез кеше бер ай юл төзү эшендә эшләргә тиеш. Ярар, аларны җибәреп тормассың инде. Казаннан сабантуйга кунаклар кайтасы бар, ит бик кирәк иде, бер сарыгыңны биреп җибәр дә, шуның белән синең планың үтәлгән булыр»,— дип, районның доротдел начальнигы бер баш сарыкны тереләтә алып китте. «Казаннан иптәшләр килә,шуларга шашлык пешерәсе барые»,— дигәч, райбашкарма председателе урынбасарына да бер сарык түшкәсе илтеп бирергә туры килгән иде.

Ләкин отчет җыелышында халыкка боларны әйтеп булмый бит инде. Ниндидер саллырак, ышандырырлыграк сәбәпләр уйлап табарга кирәк Ханәфигә. Исәп-хисап көне якынлашкан саен, куркуы арта барды аның. Әнә шул көннәрдә генә исенә төште ул җәй көне өй салып йөргән чагында Хәлимәсе әйткән сүзләрнең ни кадәр дөрес икәне. Колхоздан икенче түшкәне алып кайткач, әйткән иде аңа Хәлимә: «Син боларны ташыйсың ташуын да, ахыры ни белән бетәрен уйлыйсың микән соң? Алгач-алгач, ичмаса акча түләп алыр идең инде син аларны!»

Инде менә шул «хикмәтләрен» халык алдында йолып калырлык нинди дә булса бер җаен табарга кирәк, ә җай һич тә күренеп тормый. Җитмәсә ревкомиссия председателе дә ишәктәй кире адәм булып чыкты. Җитмәгән мөлкәтне отчетта бөтенесен дә күрсәтеп тормыйк диюне ишетергә дә теләмәде:

— Мин — камунис, иптәш Хәйретдинеф. Алдаша алмыйм, турысын әйтәчәкмен, бигайбә! — диде.

Һәм ул адәм сүзендә торды: ревкомиссия отчетында барысын да

ничек булган — шулай күрсәтеп үтте. Ә бит, югыйсә, Ханәфинең отчет доклады шома гына үтеп киткән иде: беркем дә аны-моны сизмәгән, берәү дә төрткеле сорау бирмәгән иде. Бөтен эшне шул ревком председателе бозды. Җыелыштагылар, тегенең отчеты беткәнне дә көтмичә:

— Ул тамаша ит кая киткән соң?

— Шул тикле бал-майны кая куеп бетерделәр икән? — диешеп, ризасызлык белдерә башладылар.

Аннары:

— Син ривкум прсидәтеле, син ул мөлкәтнең кая киткәнен ачыкларга тиешсең!

— Давай, шуны әйтеп бир безгә! — дип, ревком председателенең үзен тыкырдата башлаганнар иде, ләкин ул адәм эшне бик кыска тотты:

— Минем эш — булган фактны күрсәтеп бирү. Сез миннән шуннан артыгын сорамагыз, җәмәгать. Патамушты дукумитларда ул ит-майларның кая тотылганы күрсәтелмәгән. Анысын сез, әнә, персидәтел белән зафхуздан сорагыз! — диде дә котылды.

Ә завхоз хатын, күрәсең, эш шулай четереклегә әверелеп китәрен алдан ук чамалагандыр — җыелышта юк, бертуган апам үлем хәлендә ята икән дип, Казанга китеп барган иде. Кыскасы, мәсьәлә әнә шулай кабыргасы белән куелган, башка кешегә ышанып урын юк, җавапны Ханәфи тик үзе генә бирергә тиеш иде. Уйлап-уйлап та, акланырлык сәбәп таба алмагач:

— Шаулашмагыз, иптәшләр. Тынычланыгыз! Ул продуктыларның граммы да исрафка китмәгән. Барысы да колхоз хаҗәтенә тотылган алар. Бер өлеше районнан килгән вәкилләрне ашатуга, укучы балаларга, Октябрь һәм Май бәйрәмнәрендә колхозчыларга бәйрәм ашлары әзерләүгә киткән. Ә бер өлеше общепитка тотылган! — диде Ханәфи.

Халык ышаныр дип түгел, аптыраганнан, бөтенләй дәшми калганчы нидер әйтергә кирәк булганга гына әйтте ул боларны. Ләкин, гаҗәп хәл, шуннан соң халык тынычланып калды. Тик бер кыбырсык тимерче Шәмгун гына, арткы рәттән башын сузып:

— Минем алай зурлап сөйләрлек сүзем җук җугын. Шулай да бер нәрсәне ачыграк аңлатып китүегезне сорарыем. Ярый, районнан килгән кешеләрне ашатырга тотылган дигәне аңлашыла инде анысы. Барыбыз да беләбез, алары бик еш килеп тора. Айлап-айлап колхоз өстеннән ашап китәләр. Анысы — хак. Әмма мин шунысын бик үк аңнап бетермәдем: теге упшипитка киткән дигәне нәрсә була инде аның? — дип, инде җайланып бара дигән эшне боза башлаган иде башлавын. «Ни дип җавап бирергә инде бу озын тәрегә?» — дип уйлап алган мизгелдә Ханәфинең маңгаена хәтта салкын тир бәреп чыкты. Ни тырышып та, адәм рәтле җавап таба алмагач, тегенең үзенә һөҗүм итеп карарга булды ул:

— Син нәрсә, Шәмгун иптәш Шакиров, иллегә җиткән олы башың белән балалар да бирмәстәй сораулар биреп, җыелышны читкә каерып, дошман сүз сөйләп утырасың? Общепит — общепит була инде ул. Аның башка мәгънәсе юк! — диде.

Ә үзе: «Тагын төпчәнә башласа — беттем!» — дип, эченнән дер калтырап тора иде.

Халык алдында надан булып күренүдән шикләнде булса кирәк, Шәмгун шуннан ары сүз озайтып тормады:

— Ярар, рас шулай икән — шулайдыр инде. Син миңа ачуланма, персидәтел. Төшенеп җитмәгәнгә генә соравымые,— диде дә шыпырт кына урынына утырды. Һәм ул хакта бүтән сүз куертучы булмады. «Апшипитка» киткән продуктларны шул җыелыш карары белән расладылар, идарә эшен канәгатьләнерлек дип таптылар һәм Ханәфине тагын председатель итеп калдырдылар.

Әмма бу мәсьәлә моның белән генә бетмәде, аның исе тагын бер тапкыр чыгып алды әле. Кайсы барып тишкәндер, отчет-сайлау җыелы-

шыннан ары атна-ун көн үтү белән, Ханәфине райкомга чакыртып алдылар. Икенче секретарь чакырткан иде. Бик коры, әмма гадел, кыйшык-мыйшык эшләрне җаны сөйми торган Мансур Сабирович иде ул. Чакыртып алды да:

— Синең өстән жалоба бар, егет,— диде.— Әйт әле дөресен генә, кая куйдың син шул кадәр продуктны? Механизаторларга ашаттым дия алмыйсың, чөнки синдә алар юк! Башка колхозлар шикелле, язгы чәчү, урып-җыю чорында кырда эшләүчеләреңә төшке аш ашату да оештырмаган идең! Ә утыз җиде сарыкның, ике сыерның башына җиткәнсең! Моны ничек аңларга кушасың, Хәйретдинов?

Ханәфинең, әлбәттә, аны ышандырырлык җавабы юк һәм була да алмый иде.

— Үзем ашап бетермәдем инде шул тикле әйберне, колхоз кирәгенә тотылды,— диген булды ул, авыз эченнән ботка пешереп.

— Син миңа әкият сөйләмә, яме! — диде секретарь, аның сүзләренә тамчы да ышанмыйча.— Яхшылап торып тикшертә башласак, бик тиз табачакбыз без ул сарыкларның кая киткәнен! Ул чакта, беләсеңме, сиңа нәрсә булачак? Партбилетың белән саубуллашу турында әйткән дә юк, төрмәдән башың чыкмаячак! Кара аны, яшьлегеңне, председатель булып нибары бер ел эшләвеңне исәпкә алып кына бу юлы эшне зурга җибәрмибез. Алдан ук искәртеп куям: шундый кырын эшең тагын бер генә сизелсә, бездән яхшылык көтмә! Бер уңайдан шунысын да әйтергә тиешмен: председатель буларак та канәгать түгел без синең эшеңнән! Хуҗалык белән, кешеләр белән җитәкчелек итүең әлегә бернигә тормый. Бөртекле ашлыкны узган елдагыга караганда гектарыннан ике, борчакны өч центнерга ким алдың. Гомергә өченче урыннан түбән төшкәне булмаган колхозны ит һәм сөт түләү буенча тугызынчы урынга төшердең. Кара аны: шушы сөйләшүдән тиешле нәтиҗә ясап, тиз арада эш стилеңне үзгәртмәсәң — безгә үпкәләмә!

Аның бу сүзләренә каршы Ханәфи берни әйтә алмады. Чөнки секретарь әйткәннәр барысы да хак иде...

Әлбәттә, болар Ханәфи тарафыннан юри шулай эшләнгән нәрсәләр түгел иде. Бүтәннәрдә булган мин-минлек анда да бар. Ул да үзе җитәкләгән колхозның алда баруын тели. Ләкин коры теләк белән генә әллә кая барып булмый, аны гамәлгә ашырырдай эшен эшләргә дә кирәк шул. Бу яктан аның мактанырлыгы юк. Бердән, агрономия өлкәсендә белеме сай. Икенчедән, халык белән уртак тел табып, киңәшеп эшләргә тырышмый. Дорфалык белән, команда бирү юлы белән генә алдырмакчы иде ул. Өченчедән, үзенә йорт салу артыннан йөреп, колхоз эшенә тирән чумарга вакыты да калмады. Ниһаять, ул елгы уңышсызлыгының тагын бер бик җитди сәбәбе бар: көн саен диярлек салып, Хөсниҗамал белән чуалып йөрү дә аның эшенә бик нык комачаулаган иде...

Мансур Сабирович бик шәплэп «борычлап» кайтарып җибәргәч, Ханәфи юлда әнә шушыларны уйлады һәм киләчәктә акыллырак булырга: эшне начальство теленә менәрлек хәлгә җиткермәскә, итәк-җиңнәрне җыебрак йөрергә дип, катгый нәтиҗәгә килгән иде.

Колхозны алдынгылар рәтендә алып барырга теләгән кешегә шуннан башка юл юк, ә ул «Кызыл үрнәк»не алдынгылар рәтендә күрергә тели иде.

Теләвен тели иде дә...

### 6

Сугыш елларыннан ук эшләп килгән ферма мөдире — Гөлбагар исемле, инде олыгаеп барган, бик үзсүзле бер хатын мөдир исемен йөртсә дә, ферма эшен гади фермачылар белән рәттән торып эшли,

мөдирлек өчен аңа аена нибары җиде хезмәт көне артык языла, ә җаваплылыгы зур: сыерларның сөте кимесә дә, сарыкларның йоны аз булса да, сыер-таналар кысыр калса да, маллар арасында үлем-җитем булса да — ул җавап бирергә тиеш. Шуңа ул хатын мөдирлек вазифасын алып барырга бер дә теләми, киресенчә, азат итүне үзе сорап йөри.

Ханәфи дә аның бу теләгенә каршы түгел иде. Чөнки ферма терлекләренең баш санын ферма мөдире исәпләп бара. Аңа сиздермичә, сыер-тана түгел, тавык та суеп булмый. Ә ит мәсьәләсен нәкъ менә ферма мөдире белән аңлашып эшләгәндә генә ревкомиссия сизмәслек итеп хәл кылырга мөмкин. Шуңа күрә Гөлбагарны ул урыннан азат итәргә Ханәфи бик теләп риза, тик ышанычлы кешесен табарга гына кирәк иде.

Бер җае килсә килә бит. Озакламый анысы да табылды. Фермасын китерү өчен генә кияүгә барып кайткан, алпут байталы шикелле тулып-ташып торган, төскә-биткә дә хәйран гына Фәйрүзә исемле бер хатын, Ханәфи председатель булганнан бирле, аның тирәсендә ышкынгалап йөри, шуның белән ботка пешереп булыр төсле иде. Тотты да шул хатынны ферма мөдире итеп куйды Ханәфи.

Һәм ялгышмады. Ым кагып, юнәлеш биреп торасы да булмады: Ханәфи көткәннән дә акыллырак булып чыкты ул нәрсәкәй. Бик тиз арада иң ышанычлы кешегә әверелеп китте. Ханәфигә кирәк чагында сарыгын да, бозавын да, хәтта танасын да суйдыртa. Ә Ханәфи аларның итен, керемгә алдыртып тормыйча гына, кая кирәк, шунда тота. Шуның өстенә бит әле колхозга килгән вәкилләргә ашату өчен дә маллар суйгаларга туры килә, аларыннан да шактый йогылып кала иде.

Җәйгә чыккач, эшләр тагын да җайланды. Үзләренә чыбык очы тиешле чулак Зыяны ферма терлекләрен көтүче итеп куйды Ханәфи. Яше инде алтмышка җитеп килсә дә, «кабарга» бик ярата иде Зыя абзый. Шешә күрсә, күзләре ялтырый, куллары калтырый башлый, көтүдәге иң зур сарыкны сайлап алып, үзе суеп бирә торган иде.

Шул ук вакытта үзен дә онытмый иде ул агай. Бервакыт шулай тана хәтле сарыкны Качкалак урманы буенда тунап яткан чагында өстенә барып чыкты Ханәфи. Ни эшләр икән, ни дип акланыр икән дип, аның өчен оялып-уңайсызланып калган иде. Ә картның төге дә селкенмәде. Ханәфи, ни әйтергә белмичә, каушап-тотлыгып торган арада, авызын ерды да:

— Һе, син икәнсең әле, олан. Килереңне күңелем сизеп, сиңа дип әзерләвемие бу итне,— дип тик тора. Кызармый да ичмаса! Ә үзенең бер-ике кочак печән төялгән кул арбасы шуннан ерак та түгел, чикләвек куаклары артына шыгайтып куелган. Ханәфи килеп чыкмаса, сарык түшкәсен шул арбадагы печән арасына тыгасы да кичен, көтүдән кайтышлый, иплап кенә өенә алып кайтасы инде үзе!..

Нишлисең, ул картта оят юк икән, Ханәфидә бөтенләй үк бетеп житмәгән иде әле ул нәрсә.

— Бик әйбәт булган, Зыя абзый,— дигән булды ул, картның хәленә кереп.— Какраз Пучинкә әртиленә колхозга көпчәк ясату хакында сөйләшеп кайтыйм дип чыгып баруым иде. Әртил директоры белән сөйләшкәндә, ярап куяр бу!

Чынында исә Ханәфинең ул мәсьәләне инде хәл итеп, Пучинкәдән кайтып килүе иде.

Ә теге сарык түшкәсен ул шул ук көнне Корноух больницасы ашханәсенә сатып кайтты...

Мондый эшләре күп булды Ханәфинең. Ә фермада сарыкларның баш саны кимеми: суйганнары урынына исәннәре бәрәнли тора иде...

Шулай да җаны тыныч түгел иде Ханәфинең. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә белеме, җитәкчелек эшендә тәҗрибәсе булмау өстенә, көн

саен диярлек сәрхүшләнеп, хатын-кыз тирәсендә кайнашу да эшенә бик нык комачаулый. Аннары килеп, никадәр генә сак кыланырга тырышса да, халык аның ул шухыр-мухырларын сизенә иде. Хатын-кызның бит һәркайсы сине тик үзенеке генә итеп тотарга тели! Ә Ханәфинең алай буласы килми. Чөнки ул — ир кеше, аңа ирек, ул дигәнчә булу кирәк. Тегеләр шуны һич аңламый. Бер-берсеннән көнләшәләр. Бигрәк тә әлеге шул ферма мөдире Фәйрүзә дигәненең көнче иде. Дөресен генә әйткәндә, нәкъ әнә шул ахмак баш аркасында бөтен авылга фаш булды да инде Ханәфинең кыек эшләре. Шулай ук башсыз булырга кирәк бит: шул Фәйрүзә, көнләшүенә түзә алмыйча, тоткан да Хөснижамал белән сүзгә килешеп, кычкырышып киткән. Моңарчы да нидер сизенеп, шикләнеп йөргән Хәлимәгә дә барып ишетелгән боларның гаугасы. Әгәр Ханәфи үзе каты торып:

— Минме соң инде андый эш белән пычранып йөри торган кеше? Безнең матур тормышыбыздан көнләшә алар, шуңа төрле гайбәтләр уйлап чыгаралар,— дип, Хәлимәне җайлый алмаган булса, эшнең зурга китүе дә бик мөмкин иде.

Шул чакта Ханәфи: «Бу гаугадан котылсам, бетте — ша! — бүтән берсе янына да бармыйм»,— дип ант иткән иде. Ләкин ун көн уздымы икән, тагын үзенең иске гадәтен куа башлады.

Ә аннары Фәйрүзә белән урманга кергән чагында өсләренә Хәлимә үзе килеп чыкты. Икенче көнне үк авыл советына барып, аерылырга гаризасын биреп кайтты.

Аерылышу Ханәфи файдасына булмаячак: никадәр генә куштан булса да, ничек кенә яхшатланып йөрсә дә, Фәйрүзә йорт-җир эшен алып бару ягыннан булсын, тыйнак-сабырлык ягыннан һәм башка якларыннан булсын, Хәлимәне алыштыра алмаячак иде. Хатын аерып йөргән җитәкчене халык та яратмый, начальство да бик өнәми — ул ягын да искә алмыйча булмый иде. Ничек тә семьясын саклап калырга кирәк иде Ханәфигә. Шуңа ул:

— Әллә ничек ялгыш кына килеп чыкты инде шунда. Элеккесе-актыгы шул булыр. Бер юлга кичер, алтыным. Кеше көлдереп, дошман сөендереп, аерылышып йөрмик. Мондый юләрлекне бүтән беркайчан да кабатламам! — дип, Хәлимә алдына тезләнеп ялынырга мәҗбүр булды.

Тик шуннан соң гына гаризасын кире алып кайтты Хәлимә.

Әмма бу хәлләр авыл халкына инде мәгълүм һәм, колхоз председателе буларак, Ханәфинең авторитетына бик нык суккан иде.

Җитмәсә тагын колхоз эшләре дә көйсезләнгәннән-көйсезләнә бара. Ә бит башта, председатель булып кайткан чорда, колхозчылар Ханәфине ничек хөрмәт итеп, күзенә генә карап торалар иде! Хәзер исә аяк терәп әйткәләшергә дә күп сорамыйлар. Күз алдында ук булмаса да, үзе юкта гайбәтен дә саталар. «Кияү егете» дигән кушамат та тагып куйганнар иде үзенә.

Тагын да ямакрагы шул: аның шулай егетләнеп йөрүенә хәсрәтләнеп, болай да авыру әнисе бөтенләй урынга ук яткан иде. Ханәфи иртән идарәгә чыгып киткәндә, ут йотып, балавыз сыгып кала, кич кайтып кергәндә күз яше түгеп каршы ала. Чөнки Ханәфи көн саен сәрхүш кайта, кыек юлдан һаман чыга алганы юк һәм болар барысы да ана кешегә ишетелеп тора иде.

Ә вакыт һаман үз җаена ага торды: тагын ике ел үтеп китте. Ләкин ул еллар да Ханәфигә куаныч китермәде. Иген уңышы ягыннан булсын, ит-сөт җитештерү ягыннан булсын, «Кызыл үрнәк» тагын да түбәнгәрәк төшкән иде.

— Икмәк планын үтәмәсәң, без әйткәнне көтеп торма: председательлектән бушату хакында гаризаңны алдан ук язып куй да, башка эш эзли башла, Хәйретдинов! — дип, урак башланган көннәрдә үк кисәтеп куйган иде аны Мансур Сабирович. Аның белән шаярырга ярамый: әйткән сүзен үтәмичә кала торган кеше түгел иде ул. «Кызыл үр-

нәк»тә эшләр шәптән тормаганын бик яхшы белә: аңарчы да авылга я үзе килеп, я райкомга чакыртып, күп тапкырлар тузанын какканы бар Ханәфинең. Хатын-кыз һәм хәмер мәсьәләләрендә «йомшак» булуыннан да хәбәрдар иде. Инде килеп, икмәк планын да үти алмаса, урыныннан мамык урынына өреп очыртачаклар иде үзен.

Ә аның һич тә «очасы» килми. Белеме һәм көче җитмәгәнен дә сизә, булдыра алырдаен булдыру өчен тиешенчә тырышмавын да белеп тора, тик барыбер председатель урындыгыннан төшәсе килми. Ә анда утырып калу өчен, ул елны аңа ничек итеп булса да икмәк планын үтәргә кирәк иде.

Һәм ул планны үтәде. Начальстводан беркем дә сүз әйтә алмаслык итеп, 102 процентка үтәде ул аны. Ләкин колхоз малларына бер грамм фураж калдырмыйча, хәтта чәчүлеккә дигән икмәкнең дә бер өлешен тапшыру хисабына үтәде. Председатель булып озак утыра алмаячагын Ханәфи үзе дә чамалый, шуңа алдагы көн өчен кайгыртмый да, кайгыртырга исәбе дә юк. Аңа бүгенгесе кыйбат. Шуңа ул тик бер теләк белән: хуҗа булып утыруны мөмкин кадәр суза төшү уе белән генә яши иде.

Ул елны икмәк планын колхозның амбар төбен кырып-себереп, көчхәл белән генә үтәгәч, ә алда эшне яхшырту җәһәтеннән һичнинди перспективасы күренмәгәч, Мансур Сабирович бер акыллы киңәш биреп караган иде аңа:

— Болай барсаң, ерак китә алмассың син, энекәш,— дигән иде ул Ханәфигә.— Дүрт ел эшләдең, әмма колхозны аз гына да алга җибәрә алмадың түгел, киресенчә, танымаслык дәрәҗәдә артка калдырдың бит! Син әле яшь, җитәкчелек итәргә өлгерерсең. Әллә Казанга барып, укып кайтасыңмы? Мөмкинлек тә бар: синеңише яшь председательләр өчен авыл хуҗалыгы институты каршында берьеллык курс ачылырга тора, һич югы шунда укып кайтсаң да, колхозыгыз өчен дә, үзең өчен дә файдага булыр.

Ул моны Ханәфидән тизрәк котылырга теләп түгел, аның язмышы өчен кайгыртып, чын күңеленнән әйткән иде.

Әмма Ханәфи риза булмады.

— Дөрес әйтәсез, Мансур Сабирович: әйе, уку зыян итмәс иде миңа. Белемем җитмәгәнен үзем дә сизәм. Рәхәтләнеп укып кайтыр идем дә, әнием бик каты авырып тора шул. Аны калдырып китә алмыйм,— дип алдашты Ханәфи. Әнисе, чыннан да, авырый иде. Ләкин, өйдә булганга карап, Ханәфи — аңа ярдәм итә торган кеше түгел, киресенчә, көн саен эчеп, соңарып кайтулары белән борчу, авыруларын арттыра гына ул аның. Акыллы кешенең сүзен тыңлап, шул чакта укырга китеп барган булса, әнисенә, ихтимал, җиңелрәк булган булыр иде. Ул, бичара, Ханәфи аңа көн саен китереп торган борчу-хәсрәтләргә түзә алмыйча, шул елны үлеп тә китте.

Ул арада сизелмичә генә тагын бер ел үтте. Ханәфигә, председатель буларак, колхозчылар алдында дүртенче тапкыр хисап бирер вакыт җитте. Ә колхозның бер генә бөтәйгән җире дә...

## 7

Ханәфинең уйларын бүлдереп, авылның аргы башында машина кычкыртканы ишетелде. «Хәсән түгел микән?» — дип, күңеле дерт итеп куйды Ханәфинең. Өмет тулы карашын Качкалак юлыннан авылга кереп килә торган машинага текәде. «Жигули» икәнен шәйләп алгач, күңеле суынып китте: аның Хәсәне «Волга» белән кайта торган иде.

Өмете өзелсә дә, Ханәфи теге машинаның килеп җитүен кызыксынып көтте: «Кем икән? Ни эшләп йөри икән?». Менә машина алар турына килеп җитте һәм... үтеп тә китте. Тизлеген дә киметеп тормады

ичмаса. Шулай да танып калырга өлгерде Ханәфи: Түбән очның Маһисәрвәр малае, Исмәгыйль иде ул. Хатынын, ике баласын утыртып кайтып килеше тегенең. Әй, заманалар, заманалар!.. Әле кайчан гына кешеләр белән юньләп сөйләшә дә белмәгән юеш танаулы, мокытрак кына бер малай иде шушы Исмәгыйль. Сигез классны авырлык белән генә тәмамлап, ары таба гел дә укырга теләмичә, эленке-салынкы гына колхозда вак-төяк эштә йөргән иде. Яшьтәшләре арасында абруе бөтенләй юк, «Елак Исмай» дип кенә йөрттеләр үзен. Кыз-кыркын хакында инде әйтеп тә торасы түгел: якын да китермиләр иде.

Әнә шул малай армия хезмәтенә китте дә ике ел эчендә бөтенләй яңа кеше булып: акыл утыртып, бик нык үсеп-тазарып, чын егет булып кайтты. Куралыктан яшьләр яңа төзелешкә китә, шуңа күрә эшче кулларга кытлык башланган чор иде. Бүтән җирдә котайта алмаса да, ат җигеп йөрергә, фермага азык ташырга булса да ярап торыр дип уйлаганнар иде, шушы Исмәгыйль хезмәттән кайткач.

Ә ул малай, кайтып, әнисе янында атна-ун көн генә торды да Чаллыга китеп барды. Армиядә шундыйрак һөнәргә өйрәнеп кайткан булса кирәк, Чаллыда телевизорлар ремонтлау остаханәсенә урнашкан бу. Кичен укып, башта унны тәмамлаган. Аннары, Казан авиация институты филиалында укып, югары белем алган. Шул ук вакытта эшендә дә гел үсә, гел остара барган. Хәзер менә шул телевизор остаханәсенең башлыгы, бөтен Чаллыга атаклы телевизор остасы икән. Телевизорларын шушы малайга төзәттерү өчен, кешеләр айлар буена көтеп, чират торалар, ди... Машина алганына да өченче елы инде. Менә сиңа Елак Исмай!

Әле син аның үз-үзен тотышын күрсәң. Ханәфи белән очрашканда, кулын да теләр-теләмәс кенә бирә. Ә кайчакта гел дә күрмәмешкә салыша. Әнә бит, хәзер дә тукталып тормыйча, бик важный булып, баш кагып кына исәнләшеп үтеп китте. Олы кеше янына туктап, адәмчә кул биреп, күңел өчен генә булса да, эшләрең ничек, Ханәфи абый, дип, хәлеңне белешеп китсә — ни була инде?! Юк, туктамый! Күрәсең, малай чагында Ханәфи белән ике араларында булган пүчтәк кенә бер вакыйганы оныта алмый, шуңа һаман үпкә саклап йөри булса кирәк.

Ул малай җиденчедә укый идеме, әллә сигезенчедә укыганда микән, Ханәфи чыннан да бераз рәнҗеткән иде аны. Башка колхозлар инде икмәк планнарын үтәп бетереп килә, хәтта үтәгәннәре дә бар, ә «Кызыл үрнәк»нең планы үтәлергә бик күп кирәк иде әле. Әнә шул хакта Ханәфине районга чакыртып алып, бик һәйбәтләп «борычлап» җибәргәннәр, аның шуннан кайтып килеше иде. Күрәчәгенә каршы, шул чакта Исмәгыйль туры килде аның юлына. Кул арбасы белән бер арба кипкән печән алып кайтып бара. Какраз шуннан атна-ун көн элек кенә колхоз идарәсе, колхозның печән әзерләү планы тулмыйча торып, колхозчыларга колхоз кырыннан бер грамм да печән алып кайтмаска, дигән карар чыгарган иде.

— Син, анаңнан ялангач туган малай, печән апкайтмаска дигән карар барын белмисеңмени? — диде Ханәфи, тегенең үңәченнән алып.

— Беләм, Ханәфи абый! — диде малай, батыр гына итеп.

— Соң, шулай булгач, бу печәнне кая алып барасың, селәгәй?

— Өйгә апкайтам!

— Юк, өегезгә апкайтмыйсың! Син бу печәнне хәзер үк колхоз фермасына, печән өя торган җиргә илтеп аударасың, ишеттеңме?

— Мин бит аны колхоз кырыннан түгел, урманнан, каравылчы Вафа абый күрсәткән аланнан чаптым. Ул аны безгә узган көз юкә орлыгы җыйган өчен бирде.

Ихтимал, чыны да шулай булгандыр. Юкә орлыгы, зелпе тамыры, имән чикләвеге җыеп тапшырган кешеләргә урманчылыктан чабулык җир дә, утынлык агач та биргәлиләр. Шушы малай юкә орлыгы алып кайткан чакларны Ханәфинең дә күргәләгәне бар иде. Әмма теге көнне,

районнан нервысы бик нык бозылып кайтып килеше, шуның өстенә тагын яхшы гына «кабып» та алган булу аркасында, мәсьәләнең ул якларын уйлап тормады: «Илтәсеңме?» — дип тагын бер тапкыр сорады да, теге малай: «Юк, Ханәфи абый, илтмим, чөнки колхоз җиреннән җыйган әйбер түгел ул»,— дигәч: «Әһә, илтмисеңме? Алайса менә болай итәбез аны!» — дип Исмәгыйльнең печәненә ут төртте.

Коры печән күкерт шикелле кабынып китте һәм биш-ун минут эчендә арбасы-ние белән янып бетте. Арбаны гына булса да коткарып калырга итсә дә, Ханәфи малайны утка якын китермәде: саклап торып яндырды. Һаман әле Ханәфидән рәхим-шәфкать көтеп, тилмереп, үкси-үкси елап, арбаның тугымнары таралганчы карап торды теге малай. Шуннан соң гына өметен өзеп: «Ну, Кияү тәре! Белеп тор: моның өчен үскәч, иманыңны укытам әле мин синең!» — дип, тыелгысыз аккан күз яшьләрен күлмәк җиңе белән сөртә-сөртә, өйләренә чабып китте.

Шуннан бер ай чамасы үткәч, төнлә өйләренә кайтып килгән чагында артыннан таш җибәреп Ханәфинең башын тиштеләр. Башы тишелеп кенә калмаган, мие дә селкенгән иде. Унике көн больницада ятып чыгарга туры килде аңа. Кем аткандыр ул ташны — Ханәфи төгәл генә әйтә алмый. Аңа ачулы кешеләр бер Исмәгыйль генә түгел, байтак иде ул елларда. Тәгаен генә белмәгәч, берәүне дә төртеп күрсәтеп, җавапка тарттыра алмады. Шулай да Исмәгыйль эше булды бугай дигән шик күңеленә сеңеп калган иде аның. Әмма юк, ул булмаган икән. Моның шулай икәне әле шушы ел башында ачыкланды.

Ханәфи — үзе гомерендә дә йорт-җир әйбере алган кеше түгел. Элек, яшь, сәламәт чагында да, әзергә-бәзер булып, бүтәннәр алган әйберләрдән файдаланып яшәде. Хәзер дә Хәлимәдән калган йортта, ул калдырып киткән дирбияләрдән файдаланып яши. «Рекорд» маркалы иске телевизоры да — аннан калган иске телевизор иде. Иске булса да, бөтенләй юк ише үк түгел, кабызып куйганнан соң, яртышар сәгать кызгач, хәйран күрсәтә башлый, шуның аркылы илдә, дөньяданиләр булганын күреп-белеп бара иде Ханәфи. Аңа, дус-ише, туган-тумачасы булмаган һәм халык арасына чыгып йөри алмаган кешегә, чын мәгънәсендә бер юаныч иде ул телевизор. Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, узган ел Октябрь бәйрәме көннәрендә ул да сафтан чыкты: сурәте генә түгел, тавышы да бетте. Районга алып барсаң, төзәттереп кайтырга булыр иде дә, Ханәфинең андый эшләр белән йөрер рәте юк. Ә авылдашларына әйтеп-әйтеп караган иде, берсе дә тыңламады. Җитәкче булып йөргән елларындагы кыланышын онытa алмыйлар.

Исмәгыйльнең телевизор остасы икәнен белә иде Ханәфи. Аның Яңа елга авылга кайтырга тиеш икәнен дә ишеткән һәм ике көзен дүрт итеп көтеп торган иде. Кайтты ул чакта Исмәгыйль. Ханәфинең алар өенә барып йөрер хәле юк. Исмәгыйльне урамнан узганда туры китереп, дәшеп кертергә генә мөмкин иде. Көн буе диярлек тәрәзәдән карап, шуның үткәнен көтеп утырды Ханәфи. Күпме көтсә дә көтте, тәки туры китереп, чакырып кертте тегене. Ләкин, беләсезме, нәрсә диде аңа Исмәгыйль? Телевизорның арткы ягын ачып, бер-ике җирен боргалап кына карады да әйтте:

— Бик иске нәрсә икән бу Ханәфи агай. Чыгарып ташларга да, яңаны алырга кирәк сиңа. Хәзерге телевизорлар бик әйбәт бит.

Аның шулай икәнен, әйтерсең, Ханәфи үзе белми! Ләкин бит алтмыш ике сум пенсия акчасына бик алай иркенәя алмыйсың аны. Ун сутый бәрәңгесеннән тыш, тавыгы да юк бит Ханәфинең. Барысын сатып алып ашыйсы. Аннары шактый бәяле даруларын да алдыргалап торырга туры килә. Шунсыз булмый. Ярый әле фельдшер кыз Сәвия рәхимле. Медпункт колхоз үзәгендә. Атнасына бер тапкыр Кече Елгадан килеп, Куралык халкының хәлләрен белеп, авырулар булса, дарулар биреп китә. Ханәфигә кирәкле даруларны да район аптекасыннан ул алып



А. Тимерғалина рәсеме

кайтып бирә... Шулай булгач, яңа телевизор алырлык акча Ханәфигә каян килсен?

— Син, энем, Исмәгыйль, миңа шуны әйт: төзәтеп буламы бу телевизорны?

— Ник булмасын. Теләгәндә яңага алыштырмаслык итеп була моны.

— Мин сиңа алай ук дип әйтмим, сурәтен күрсәтә торган итеп бирсәң, үлгәнче рәхмәт укыр идем, энем! Бәясеннән тормам. Анлык кына акчам бар, әле өченче көн генә пенсиямне китерделәр.

— Эш акчада түгел, Ханәфи агай,— диде теге, беркавым уйланып, күзгә карап торгач.— Үзең кеше булган булсаң, мин моны бер тиенсез төзәтеп бирер идем. Ләкин мин сиңа моны мең тәңкә бирәм дисәң дә, төзәтмим!

— Нәрсә, теге чакта печәнеңне яндырган өчен ачу саклыйсыңмыни?

— Онытырлык кына булдымыни: арбасы-ние белән яндырдың бит син аны!

— Кызулык белән эшләнгән эш булды ул, энекәш. Салган баштан. Соңыннан үзем дә бик үкенеп йөрдем. Хәзер дә бик үкенәм. Кичер син мине, энем, аның өчен!

— Кичерерлек кенә булмады шул, агай. Ярый, каның кызган чак та булсын ди. Ярый, салмыш чагың да булган булсын, ди. Ярый, печәнен яндыр да, ди. Тик нигә соң аның арбасын да яндырырга иде сиңа? Ул елларда кул арбасы авыл халкының иң кирәкле, иң кадерле әйбере икәнен, андый арбаларның базарда бик сирәк булуын, булса да кечерәк бер мотоцикл бәясе торганын син, председатель кеше, белми идеңмени?

— Аларын ук уйлап торылмаган шул инде, энем. Ярар, алай булгач, оныт дип әйтмим. Авыру кеше бит мин. Шуның өчен кызганып булса да ясап бир шушы телевизорны.

— Хәлеңне аңлыйм, агай. Кызганам да үзеңне. Хатының исән-сау булган килеш, шундый зур урында эшләүче малаең була торып, картаймыш көнеңдә болын хәтле шушы өйдә берүзең каңгырап яшәүләре җиңел түгелдер. Ләкин, нишлим соң, акылым белән шуны аңласам да, күңел кичерә алмый бит теге чактагы этлегеңне. Гаеп итмә инде син мине, яме, агай.

— Син дә әҗәтле булып калмадың бит ул чакта. Ачуыңны алдың.

— Кайчан? Ничек итеп?

— Төнлә мин өйгә кайтып барышлый башыма таш белән бәреп, больницага кerткәнеңне онытгыңмыни?

Исмәгыйль бер мәл аһ итеп, сүз әйтә алмыйча торды.

— Син нәрсә, агай? Аны чынлап та минем эш дип уйладыңмыни әле?

Бернинди дәлиле булмаган килеш шулай кистереп әйтүе уңайсызрак килеп чыкканын Ханәфи үзе дә сизеп алды. Ләкин хәзер чигенергә урын юк, башлаган уенны ахырына кадәр дәвам иттерергә кирәк иде:

— Уйладым гына түгел, хәзер дә шул фикердә торам! — диде ул.

Исмәгыйль ачуыннан бурлаттай кызарып чыкты.

— Их, син, адәм актыгы! — дип, тешләрен шыгырдатып, сугып үтерердәй итеп, Ханәфигә карап торды да: — Авыру булмасаң, бу сүзең өчен танавыңны җимерә идем җимерүен, шул авыру булганга гына кулымны пычратып торасым килми. Шуны бел: безнең нәселдә арттан китереп сугу гадәте юк! Сугышсак, без дошман белән йөзгә-йөз килеп кенә сугышабыз! — дип, ишекне шартлатып ябып чыгып китте.

Ләкин Ханәфи аңа әллә ни үпкәләмәде. Үзен хаксызга рәнҗетсәләр, ул үзе дә нәкъ шулай эшләр иде...

Әнә шул Исмәгыйль бүген тагын кайтты. Әле күптән түгел генә әнисенә кышлык утын кайтарып киткән иде. Бу юлы бәрәңгесен алышырга кайткан булса кирәк. Бәхете олы Маһисәрвәрнең картаймыш көнендә! Малае гына түгел, килене дә бик ипле, бик уңган нәрсә булып чыкты.

Икесе дә әни дип үзелеп торалар. Аз куйганда да аена бер тапкыр кайтып китмичә калмыйлар. Каралты-курасын төзәтеп, мал-туарына кышлык печән әзерләп торалар. Быел яз көне генә өен сипләтеп, түбәсен калай белән яптырып киткән иде шушы малай. Инде менә бәрәңгесен алышырга кайткан.

Их, шайтан малай, Ханәфиләр турыннан үтеп китешли тукталып та китмәде ичмаса шул Исмәгыйль! Туктаса, Ханәфи теге чактагы дорфалыгы өчен гафу үтенеп, тагын бер тапкыр телевизорын төзәтү хакында сүз кузгатып карамакчы иде. Бәлки, бу юлы миһербаны килеп төзәтеп бирер иде. Туктамады шул. Күрәсең, Ханәфинең башын тишү аның эше булмаган. Нахак сүз кемгә дә авыр тия шул ул. Шуңа шулай выжлатып кына үтеп киткәндер.

## 8

Ханәфинең Хәсәне һаман кайтып житә алмый әле. Яз көне, Хәлимә белән кайтып, бәрәңгесен утыртып киткәннәр иде, шуннан бирле эзләре дә юк. Бәрәңге төбен өяргә дә кайтмадылар. Ул эшне Хәсән Нуржамал малае Хариска кушып, эш хакы өчен акчасын да калдырып киткән булган икән. Ханәфинең бәрәңгесен ат белән шул малай күтәртеп бирде. Аның бит әле шунысы да бар: әллә нигә бер кайткан чакларында да ни Хәлимә, ни Хәсән менә шушы өйләренең бусагасын атлап кермиләр. Күрше Гайнелхаятларда тукталып, шунда ашап-эчеп китәләр, әмма өйгә берсе-бер керми. Бүтәне бүтән, аның бит авыл халкы алдында хурлыгы ни тора! Кешеләрнең үги балалары да килгәләп, этиләренең хәлен белеп, ярдәм итеп йөри. Ә болар, берсе — ничә ел бергә торган хатыны, икенчесе законлы үз малае була торып, җиде ят урынына да күрмиләр...

Исмәгыйле дә, килене дә Маһисәрвәр өчен үлеп торалар. Сыер-сарык асрап, берүзенә бер өй җылытып, иза чигеп ятма, егерме сигез ел фермада эшләгәнең дә бик житкән, инде рәхәтләнеп ял итәргә вакыт сиңа дип, үзләре янына Чаллыга алып китәргә дә бик чакырып торалар. Фәгирләры да иркен, зур-зур өч бүлмә ди. Тик Маһисәрвәр үзе китәргә теләми. «Балаларым шушылай ярдәм итеп торганда, үземнеүзем йөртерлек көчем булганда, авылда яшисем килә әле. Туган-үскән җирләрне ничек итеп ташлап китмәк кирәк? Ялгызлыктан мин курыкмыйм. Хәзерге заманда кеше ялгыз буламыни? Тәүлек буе диярлек тилибизыры эшләп, илнекен генә түгел, бөтен дөнья хәлләрен әйтеп күрсәтеп бара. Күрше-күләннән өзелгән юк. Урманы авылга орынып тора. Яз-җәй көннәрендә, шул урманга кереп, кош сайрауларын тыңлаулар, җиләк вакытында җиләккә йөрүләр — үзе бер гомер бит ул»,— дип, авылда яши бирә...

Хәер, ялгыз яши дип тә булмый аны. Авылның бар хатын-кызы, карчык-корысы, балга җыйналган чебен шикелле, буш вакытларында гел шул Маһисәрвәр янына килә. Чөнки аның самавырында беркайчан чәе суынып тормый. Кем килеп керсә дә, үз туганы килеп кергән шикелле куанып, самавырын яңартып җибәрә. Шуңа киләләр аның янына. Шуңа дөньядагы бар яңалыкны вакытында ишетеп-белеп тора ул. Шуңа кызык аның өчен авылда яшәү. Шуңа шәһәргә китәсе килми аның... Хәлимәсе менә шушында авылда булып, Хәсәне атна саен диярлек кайтып торса, Ханәфи дә менә шушылай, канаты каерылып калган ялгыз торна кебек, капка төбендә каңгырап утырмас иде, билгеле. Маһисәрвәрнеке шикелле төсле телевизоры булса, Ханәфи дә шулайрак сөйләнер иде. Ә болай, көннәр буе капка баганасын саклап, бер ялгызың утырырга калгач, бигрәкләр читен икән шул!..

Һәй, шәһәргә чакырып торучы булса, менә хәзер, шушы минутта ук чыгып китәр иде Ханәфи. Аның Хәсәненең Казандагы фатиры

Маһисәрвәр Исмәгыйленеке шикелле өч бүлмәле генә түгел, полнометражный дүрт бүлмәле бит! Исмәгыйль шикелле телевизор төзәтүче генә түгел, эше дә бик зур, бик дәрәҗәле Хәсәннең: Казан районнарының берсендә райисполком председателе ул. Аның мөмкинлекләре Исмәгыйльнекенә караганда йөз мәртәбә артыграк. Тели икән, Ханәфинең үзенә аерым фатир оештырып бирү дә берни тормас иде аңа. Теләсә, үз фатирында да тота алыр иде.

Әмма... үз янына Казанга алдыру түгел, Хәсәне аңа фатирының кайда икәнен әйткәне дә юк. Әйтергә җыенмый да! Хәсән үзе, ихтимал, алай ук каты кыланмас, һич югы кыш чыгарга гына булса да Казанга алып китеп, үзләренә сыендырып торыр иде. Бөтен явызлык Хәлимәдә. Ул бик каты тора Ханәфигә карата. Әйтерсең, заманында алар яратышып өйләнешмәгән, әйтерсең, бер-берсен сөешеп тормаган, әйтерсең, Хәсән аларның уртак балалары түгел... Өйләнешкән еллврында бер-беренең күзенә карашып кына торалар, бер генә тәүлек күрешмәсәләр дә, бер ел күрешмәгәндәй сагынышалар иде. Бигрәк тә Хәлимә куанып бетә алмый: «Бездән дә бәхетле кешеләр юктыр бу дөньяда!» — дип йөри иде.

Хәзер әнә ат чаптырырлык шул фатирларына торырга алдыру түгел, кайда торганнарын белгертергә дә теләми Ханәфигә. Сүз дә юк, гаеп Ханәфинең үзендә дә булды. Күпме хәсрәт-борчулар, күпме кимсетүхурлык китерде ул Хәлимәгә... Я, кем шоп-шома гына, бер дә тайпылышсыз, туп-туры гына яши бу дөньяда? Әллә Ханәфинең үзен кимсеткәннәре булмадымы? Ничек кенә булды әле!

## 9

Бер елны пенсиягә чыккан укытучы урынына Кече Елгага читтән яшь кенә укытучы килгән иде. Тыгыз-йомры гәүдәле, шомырт кара күзле, утызлар тирәсендәге сөйкемле генә хатын иде ул. Кияүдә булганмы-юкмы, анысын шайтан белгән, әмма икенче класста укый торган малае да бар. Ханәфи ул чакта председателен председатель, әмма колхозныкы түгел, Кече Елгада авыл советы председателе булып эшли иде. Телиме-теләмиме, Зәйтүнә атлы ул укытучы иң элек Ханәфи хозурына килгән, чөнки аңа фатирга урнашырга кирәк иде. Зәйтүнә ул чакта әле ялгызы гына килгән, малае бары-югы билгесез, әмма шул беренче күрүдә үк ошаткан иде аны Ханәфи. Шуңа күрә Кече Елгадан Куралыкка үз янына тарантаска утыртып алып кайтты ул аны.

Нindirәк нәрсә икән дип, кайтышлый ук кылларын чиртkәләп карады. Әмма тегенең кулга килер чамасы күренми иде: Ханәфинең шаяртуын кабул итмәде. Моңарчы беркайчан хатын-кызларның салкын карашына юлыкканы булмаганга, тегенең үзен шушылай битараф-кырыс тотышы бер дә ошамады, Ханәфинең мин-минлегенә тиде. Шулай да бу хәлгә артык шаккатмаска тырышты: «Ничава, синең ишеләрне генә күргән бар, җаным, ничек тә ияләштерербез без сине кулга. Районга барырга ат, ашарыңа ит-май, мәктәбеңә һәм фатирыңа ягарга утын кирәк була башласа, бик алай хан кызы булып йөри алмассың!» — дип уйлады ул. Җае чыккан саен, сүз кушып, сөйләштергәли торды тегене. Ә бер көнне, кызыйның ронога барасын белгәч, һичнинди йомышы булмаса да, мине дә чакырганнар иде дигән булып, тагын үз янына тарантаска утыртып алып барды. Җаена төшенеп булмасмы дип, юлда барышлый тагын «җим» сибеп караган иде, нияте барып чыкмады. «Әгәр тагын шушылай кул озайтып, килде-китте сөйләшеп барсагыз, бүген үк өстегездән райкомга керәм!» — дип, мәсьәләне бик кискен китереп куйды. Ә соңыннан, Ханәфи белән кайтырга да теләмичә, Олы Елга мәктәбе директоры белән мотоциклга утырып кайтып китте...

Монысы инде икенче зур хурлык иде Ханәфигә. Ләкин ул өметен

өзмәде. Яхшылык белән алдыра алмагач, катылык белән эш итеп карарга булды: шул хатынга укытучы буларак тиешле дүрт кубометр утынны башта кайдан алырга икәнен әйтмичә, аннары аны алып кайтырга ат бирмичә тинтерәтмәкче иде. Тик бу планы да барып чыкмады: Зәйтүнә ике тапкыр гына Ханәфи катына килеп, утын хакында сорашып карады да, Ханәфидән юньле сүз ишетмәгәч, райкомга, беренче секретарьның үзенә жалоба белән киткән. Беренче райбашкарма председателен чакыртып алып, нигә кадрларыңны тәэмин итүне кайгыртмыйсың, синең эшне мин эшләр дип көтәсеңмени дип, һәйбәтләп пешекләп чыгарган. Ә райбашкарма председателе, үз чиратында, Ханәфине чакыртып алып: «Иртәгә төштән соң лично үзем авылыгызга барып карыйм. Мин барганда, Мифтахова Зәйтүнәгә утын китерелмәгән булса, үзеңне председательлектән азат ителгән дип сана! Бер кешегә утын кайтартмаган өчен әллә ни эшли алмаслар дип ялгыша күрмә. Синең өстән болай да жалобалар җитәрлек, тик моңарчы мин аларга хут кына бирмәдем»,— дип, утлы табага бастырып җибәрде.

Аның белән шаярырга ярамый: тоткан җиреннән сындырмыйча кала торган кеше түгел иде ул.

Авыл советының кистереп куйган утыны бар барын. Ләкин ерак — егерме тугыз чакрымдагы Яңарыш урманында. Бик теләсәң дә, ярты көндә алып кайтып җиткерү мөмкин түгел иде. Ханәфи ул чакта Зәйтүнәгә тиешле утынны тимерче Шәмгуннан әҗәткә алып торып кына бәладән котылды.

Котылуын котылды, әмма моның ни өчен шулай эшләнгәнен бөтен авыл халкы белгән һәм, бу хәл Ханәфинең болай да бик чамалы авторитетына тагын бер кат суккан иде. Шул көннән соң хәлләр үзгәрде. Авыл халкыннан берәрсе белешмә-мазар дип инәлгәндә, буш кул белән килсә, Ханәфи аны: «Бүген булмый, вакытым юк. Иртәгә килерсең», — дип борып җибәрергә итә башласа, элекке шикелле дәшми-тынмый гына кайтып китүләр бетте. «Вакытың булырга тиеш, прсидәтел! Син шуның өчен акча аласың! Без сине шуның өчен сайлап куйдык!» — дип, аяк терәп сөйләшә башладылар.

Ә бит шул Мифтахова дигән укытучы Куралыкка килгәнче, эшләре тәгәрәп кенә бара иде Ханәфинең. Вакытым юк дип, белешмә бирмичә борып җибәрелгән кешеләр икенче көнне үк «акылга утырып», кесәләренә ярты кыстырып килә яисә: «Әйдәле, парин, әйдә, күптәннән кергәнең юк, сөйләшәсе сүзем дә барые», — дигән булып, өйләренә алып кереп, һәйбәтләп сыйлап чыгаралар иде. Әнә, шул килмешәк хатын аркасында көе китте эшнең.

Менә шуңа күрә дә, үзенең мин-минлеген канәгатьләндерү һәм авыл халкы каршында күзгә күренеп югалып барган авторитетын кайтару нияте белән, Ханәфи тегене ничек тә үз ягына аударуны максат итеп куйды һәм шул ниятен гамәлгә ашыру артыннан чабарга тотынды. «Мәктәпне яхшылап җыештыралармы, тиешенчә ягалармы», — дип, атнасына алты тапкыр сораштыра башлады Зәйтүнәдән.

«Кече Елга кибетенә фәлән нәрсә кайткан, кирәк дисәң, әйдә, барып алып кайтабыз»,— дип тә куштанланды. «Ашау-эчү якларың ничек? Ит-фәлән кирәк булса әйт: үзем яздырып алып кайтып бирермен», — дип тә ялагайланып карады.

Ләкин Зәйтүнә боларның берсенә дә капланып төшмәде. Дөрес, алай оялып-читенсенеп тормый иде үзе. Ханәфи белән үз тиңедәй кыю һәм дустанә сөйләшә. Тәкъдим иткән нәрсәләрдән дә баш тартмый. Тарантаска утырып, Ханәфи белән Кече Елгага да, район үзәгенә дә бара. Акчасын түләп, итен-маен да алгалап тора. Әмма, шул ук вакытта, Ханәфигә иркенәеп китәргә хут та калдырмый. Үзе шунда: «Сезне бик һавалы, рәхимсез кеше дигәннәр иде, Ханәфи Хәйретдинович. Баштарак миңа да шулай күренгән идегез. Ә сез әнә нинди игътибарлы һәм ярдәмчел кеше икәнсез!» — дип мактап та җибәрә иде. Андый чакта ул хатын

шундый ягымлы, шундый якын була, Ханәфи ни әйтсә дә каршы килмәс, барысына да ризалашыр төсле тоела башлый иде. Ә чынлыкта... Инде була, менә-менә чиертә кармакка дип торганда, кинәт кенә бөтен өмет-ышанычны юкка чыгара да куя! Шунысына җен ачулары килә иде Ханәфинең.

Ачуы килә, әмма максатына ирешү мәсьәләсендә берни дә эшли алмый. Кайчакларда бөтенләй өметсезләнеп: «Ярар ла, булмаса булмас! Ахыр чиктә ул да әллә нәрсә түгел, ул да башкалар ишедер», — дип онытырга итеп тә карый. Әмма, юк, оныта алмый. Отыры алгысыйкотырына бара: «Барыбер минемчә булырга тиеш!» — дигән фикер аның миен корт шикелле туктаусыз кимереп тора. Бер заман Ханәфи шул хәлгә килеп җитте ки, бүтән эшләрен бөтенләй онытып, Зәйтүнәне кулга төшерү артыннан гына йөри башлады. Тырыша торгач, бер көнне тегене эләктерергә җае да чыкты, мин сиңа әйтим...

Июль урталары: бар табигатьнең хуш исле яшеллеккә, чәчәккә чумып утырган вакыты, кура җиләге өлгергән чак иде. Зәйтүнәнең, бер төркем бала-чага ияртеп, урманга җиләккә кереп барганын күреп, шуның артыннан китте Ханәфи. Балалардан аерылыбрак киткән чагын чамаларга иде исәбе. Ләкин бала-чага, тагылган шикелле, гел тегенең тирәсендә кайнаша, якын килергә һич тә мөмкин түгел. Шулай да, көтә торгач, ниһаять, җае чыкты: ялгызы гына бер читкәрәк китте теге нәрсә. Шуны гына көтеп торган Ханәфи ыслан җитезлеге белән аның артыннан ыргылды, кысып кочаклап алды да, тавышын балалар ишетмәсен өчен, пышылдап кына: «Зәйтүнә, бу — мин! Курыкма, мин сиңа тимим... Әйтәсе сүзем генә бар. Әйдә, анавындарак китик әле!» — дип, кешекара бик керми торган куелыкка алып кермәкче булды.

Зәйтүнә, ни булганын аңламыйча, башта телсез-өнсез калып торды. Үзе сулышын еш-еш ала, борчак-борчак ак төшкән зәңгәр ситсы күлмәге аша кайнарлыгы шул тикле җанга рәхәт биреп тора — сөйләп бетермәле түгел иде. Ул көннән соң инде ничә еллар узган булуга карамастан, менә хәзер дә аермачык хәтерли Ханәфи аның күкрәкләренең тыгызлыгын!..

Кызганычка каршы, ул бинибая рәхәт мизгел берничә секунд кына булды шул. Ә аннары... Исенә-аңына килеп, эшнең нәрсәдә икәнен төшенеп алгач, Зәйтүнә шундук усал җанварга әверелде. Балалар ишетмәсен өчен, артык кычкырмыйча, әмма котыңны алырлык җан ачуы белән: «Кит, кабахәт!» — дип Ханәфи кочагыннан ычкынырга талпынды.

Ханәфигә аны ычкындырырга һич ярамый. Бу юлы да ычкындырса, Зәйтүнәне ул бүтән беркайчан да үзенеке итә алмаячагын бик яхшы белә иде. «Зәйтүнә, җаным-бәгырем, мин бит сине килгәнеңнән бирле яратып йөрим. Әйдәле, дүрт-биш кенә минут сөйләшеп утырыйк әле!» — диде ул ялварып һәм тегене урман ешлыгына таба сөйрәп. Әмма теләгенә ирешә алмады. Елан урынына бөтерелеп, Зәйтүнә Ханәфи кочагыннан шуып чыкты. Аннары, бөтен урманны яңгыратып, аның яңагына чапты. Шундый каты чапты, көпә-көндез бер көлтә ут бөркелде Ханәфинең күзеннән!..

Нияте гамәлгә ашмасы инде көн кебек ачык, шулай булгач, үз хәлен үзе белеп, шыпырт кына китеп барасы иде Ханәфигә. Ә ул, ахмак баш, яңагы авыртудан бигрәк, хатын-кыздан кимсетелү хурлыгына түзә алмыйча, Зәйтүнәгә үзе дә берне чәпәде. Зәйтүнә аннан бу юләрлекне көтмәгән иде булса кирәк, егылып ук китте. Ләкин мәче тизлеге белән шунда ук сикереп торды да:

— Әһә, син әле шулаймы? Ир башың белән хатын-кызга кул күтәрәсеңме? Алайса күрсәтермен мин сиңа күрмәгәнеңне, сасык! — дип чәрелдәп Ханәфинең битен тырмарга тотынды.

Балалардан берәрсе килеп чыкмасын, шаһиты булса, судка бирергә дә күп алмас бу зобани дип, тизрәк шылмакчы иде Ханәфи. Лә-

кин хәзер инде Зәйтүнә аны җибәрми: тигәнәк урынына ябышкан да тырмашуын дәвам итә иде.

Алар шулай мәтәвекләнеп торганда, Ханәфинең колак төбендә генә:

— Ни эшләвең бу, председатель агай? — дигән тавыш ишетелде.

Борылып караса, узган ел Ханәфине үлемнән алып калган әлеге шул районның баш врачы Фарук Сәләхович басып тора иде алар янында. Ул чакта Фарук әле врач та, Сәләхович та түгел. Ул чакта ул әле тракторчы Сәләхи малае, унны яңа бетереп, институтка керергә әзерләнеп йөри торган гап-гади бер авыл егете генә иде.

Фарукны күргәч, кинәт хәле китеп, Зәйтүнә җиргә утырды да:

— Энем, җаным, зинһар ташлап китә күрмә, яме! Коткар мине шушы кабахәттән! — дип елап җибәрде.

Фарук эшнең нәрсәдә икәнен инде аңлап алган һәм, их, агай-агай, хатын-кыз белән сугышып тору ир кеше эшемени дигәндәй, мыскыллы елмаеп карап тора иде. Аннары ул:

— Әйдә, апа, торыгыз! Еламагыз, — дип, Зәйтүнә янына чүгәләп, аны юатырга тотынды. Ул арада апаларының тавышын ишетеп, Зәйтүнә белән җиләккә килгән балалар да җыйнала башлаган иде. Ярый әле, башы җитеп, Ханәфи аларны өркетеп җибәрде. Аннары ул, ахмаклык эшләп ташлавына үзе дә үкенеп, Зәйтүнәне торгызырга ярдәм итмәкче иде. Фарук ирек бирмәде:

— Юк, агай, кирәкми. Барыгыз, китегез моннан! — диде.

Фарук шул сүзләрне әйтмәсә, Ханәфи, ихтимал, китеп тә барыр иде. Ләкин шул малакасуның шулай дип әйтүе Ханәфинең болай да соңгы чиккә җитеп тартылган нервыларын бөтенләй өзеп үк җибәрде. Ул, үзенең ни кыланганын да белештермичә:

— Син кемгә акыл өйрәтеп торасың әле? Бар, аттыр моннан! — дип, Фарукның үңәченә ябышты. Фарук каршылык күрсәтмәсә, шул килеш кенә җибәрмәкче, киреләнә башласа, бераәрне «ямап» алырга иде исәбе. Тик ул уйлаганча барып чыкмады. Фарук ялт итеп Ханәфинең уң кулын эләктерде дә шундый итеп артка каерды, Ханәфи «алла!» дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.

— Я, — диде аннары Фарук, — яхшы чакта, кеше-кара күргәләгәнче, үзең кайтып китәсеңме? Әллә менә шушылай кулыңны артка каерган килеш, Хәлимә апа янына өегезгә үзем кайтарып куйыйммы?

Ханәфинең аңа карышып торыр хәле юк, яшь булса да, Фарукның куллары бик нык, боргыч белән борып алгандай иткән иде.

— Ярар, — дигән булды Ханәфи, эшне шаяртуга кайтарып калдырмак итеп, — булды. Уен күп булмый. Җитте, энем. Җибәр кулны!

— Җибәрәм. Тик бер нәрсәне колагыңа киртләп куй, агай: моннан ары беркайчан да Зәйтүнә апаны кимсетмисең, яме!

Ул малай әйтмәсә дә, пәри комалаган Зәйтүнә ягына бүтән әйләнеп карыйсы кеше түгел иде инде Ханәфи. Тик бер нәрсәдән — бу хәлне Фарук халыкка таратмагае, дип кенә курыккан иде. Әмма акыллы булып чыкты ул малай: Ханәфинең данын сатып, вакланып йөрмәде.

## 10

Ханәфи үзе шул Фарук белән икенче бер очрашкан чагында егетлек күрсәтә алмады менә. Кайсы елны икәнен тәгаен генә әйтә алмый, тик шунысы бик яхшы хәтерендә: июль башлары, дөньяның хуш исле хәтфәгә уралып, игеннәрнең шаулап үсеп утырган чагы иде. Сабынлап югандай чип-чиста зәңгәр күккә эленгән тургайлар, иген араларындагы бытбылдыклар шул хозурлыкка куанып җырлаганны тыңлап, дөньяда яшәүнең рәхәтен бөтен җаны-тәне белән татып, үзе дә күңеленнән җырлап, тарантаска утырып, районнан кайтып килеше иде Ханәфинең. Шул

чакта очрады аңа Фарук. Ике кулына ике чемодан тотып, аркасына туристлар биштәре асып. Анаташ тавына күтәрелеп бара иде егет. Соңыннан белде Ханәфи: институт тәмамлап кайтып килеше булган. Ат пошкырганны ишетеп, Ханәфи әле аның артыннан җиткәнче үк борылып карады Фарук. Ханәфине шундук танып алып, куанып, чемоданнарын җиргә куйды һәм биштәр капчыгын сала башлады. Әлбәттә, Ханәфи атына утырып кайтырга иде егетнең исәбе. Әлбәттә, үзе әйтеп утыртырга тиеш иде аны Ханәфи. Андый чакта үз авылдашыңны түгел, бөтенләй белмәгән-күрмәгән кешене дә ташлап китмиләр. Ләкин Ханәфи алай итмәде. Теге елны Зәйтүнә аркасында урманда булган хәлләр исенә төште дә: «Бөтен эшне шушы малай бозды ул чакта. Үзенең кем юлына аркылы төшкәнен белсен әле!» — дип, Фарукны бөтенләй күрмәгәндәй кыланып, выжлаттырып узып китте. Егетнең: «Тукта инде, Ханәфи абзый! Үземне утыртмасаң, ичмаса чемоданнарымны ал», — дип, артыннан кычкырып калганын да ишетмәгәнгә сабышты...

Хәзер менә шул чактагы кыланышларын исенә төшерергә дә оят Ханәфигә. Ул ташлап киткәнгә карап кына Фарук юлда егылып калмаган иде. Шул көнне, ике-өч сәгатьтән үк кайтып керде ул. Туры килеп торуын әйт син: урамда, Мәһисәрвәрләр турында, алар тагын йөзгә-йөз очраштылар! Фарукның әле яңа кайтып килеше, ә Ханәфинең инде тамак туйдырып, ял итеп, берәрсенә кереп баш төзәтү нияте белән урамга чыккан чагы иде.

Фарук шунда эт итеп сүгеп китсә дә, Ханәфи аңа каршы бер сүз дә әйтә алмас иде. Фартук алай эшләмәде. Әмма сүккәннән дә болайрак итеп:

— Мин сине халык яратмаганын белә идем, Ханәфи агай. Ләкин ни өчен яратмауларын белми йөргәнмен. Инде аңладым! Рәхимсез, таш йөрәкле адәм икәнсең син! — дип әйтеп китте ул.

Әти-әниләре янында берәр ай ял иткәч, шул егет район больницасында врач булып эшли башлады. Өч-дүрт ел эшләгәч, баш врач урынбасары итеп күтәрделәр үзен. Ә хәзер, инде алтынчымы-җиденчеме елы, районның баш врачы. Узган ел шул егет дәваламаган булса, ихтимал, Ханәфи дөнья белән инде саубуллашкан булыр, чөнки билләре-аяклары сызлауга һич тәкате калмаган, дуга шикелле уртага бөгелеп килгән иде. Фарук урынында Ханәфи үзе булган булса, ай-һай, дәшмичә түзә алыр идеме икән? Ә Фарук урманда булган хәлләр турында да, юлда утыртмыйча китү турында да теш агартып ник бер сүз әйтсен ичмаса! Онытkандыр димә: андый хәлләр гомергә онытылмый ул! Ханәфи болай да тиешле җәзасын алган — чыкмаган җаны гына калганын күреп, кәефен җибәреп, вакланып торасы килмәгәндер инде. Да-а, уйланган кешегә уйланырлык нәрсә бар монда!..

Сентябрь — ни әйтсәң дә сентябрь шул инде. Кояш төшлеккә җитеп килә, ә кызуы әллә ни түгел. Җәй айларында төш турында бар дөнья тынып, эсселектән чайрап-оеп кала, яфрак селкенерлек тә җил булмый торган иде. Хәзер киресенчә: иртән тып-тын була, төшкә таба җил кузгала. Менә бүген дә шактый җилли башлады. Җил чыктымы — озакламый яңгыр буласын көт тә тор. Быел агач яфраклары да гадәттәгедән иртәрәк саргая башлады. Әнә авыл зиратындагы Нәҗметдин хәзрәт каены моннан берәр атна элек кенә ямь-яшел булып утыра иде. Инде шул яшел бөркәнчеген алтын тәңкәләр таккан өрфия япмага алыштырып та өлгергән. Димәк, кыш иртә килмәкче. Тагын бер җәй үтеп китте дигән сүз, шулай итеп. И-и-их, бигрәк тиз җитә башлады бит әле бу көзләр! Әллә Ханәфи генә түгел, дөнья үзе дә картая, авырый инде шунда...

Хәсән белән Хәлимә һаман кайтып җитә алмыйлар әле. Кайтмаска булдылар микәнни? Бүген дә кайтмасалар, тагын бер атнасыз кайта алмыйлар бит инде алар. Аңарчы яңгырлар башланып китсә, ни эшли инде Ханәфинең бәрәңгесе? Аңа ярдәм итәргә берәү дә бик алай атлы-

гып тормый. Дөрес, председатель Нургазиз — рәхимле кеше. Ханәфинең бәрәңгесен кар астында калдыртырга юл куймас анысы. Колхозның үзенеке алынып беткәч, яшь-җилкенчәк комсомолларны кушып, ничек тә алдыртып бирер. Ләкин... Бердән, колхозның үзенең дә аласы бәрәңгесе — дөнья. Икенчедән, кеше алган бәрәңге — кеше алган бәрәңге инде ул. Анда сиңа җирдә бәрәңге калмасын дип тә, алган бәрәңгең чиста булсын дип, балчыгыннан аерып торучы да булмаячак. Ашык-пошык казып, аннан-моннан җыеп, базыңа тутырачаклар да китәчәкләр алар...

Ахыр чиктә мәсьәлә анда гына да түгел. Үзләре якын итмәсәләр дә, Хәсәнне дә, Хәлимәне дә, киленен дә күрәсе килә бит Ханәфинең. Бил-аякларының сызлавы һаман шушылай үзәккә үтеп торса, кышны әллә исән чыгыла, әллә юк. Шулай булгач, менә хәзер, күздән, бер күрешеп калу зыян итмәс иде алар белән. Ни әйтсәң дә, үзенекеләр бит. Ханәфи авыл советы председателе булганнан соң гына бозылды ич Хәлимә белән аралары. Аңарчы хәйран матур гына торганнар иде. Аннары килеп, авыл җирендә кемгә кайткан — аңа кайткан, кем кайткан — ул кайткан дигән нәрсәнең дә әһәмияте бик зур бит әле аның.

Көткән кешеләрең кайтмый дип тормый, тамак дигән нәрсә үзенекен итә: ашыйсы килә башлады Ханәфинең. Кереп, берәр нәрсә әзерләргә кирәк булыр. «Берәр нәрсә» дигәне я шул бәрәңге, яки ботка инде. Шуннан башканы әзерли белми ул. Ипи салырга өйрәнде өйрәнүен. Ашыйсы килгәч, өйрәнми ни эшлисең. Кече Елгада әнә пешкән икмәкне кибетләренә китереп саталар. Көн саен яңа пешкән икмәк ашап торырга була. Кечкенә авыл булгач, Куралык халкына андый нәрсәләр тәтеми шул. Ярый әле колхоз онын биреп, беткән саен, газын китереп тора. Тегермәннәргә барып йөрисе, көненә икешәр-өчәр тапкыр казан астына ягып чиләнәсе түгел. Газ плитәсен кабызып җибәрәсең дә, ун минут дигәндә, чәе кайнап чыга, ярты сәгать эчендә бәрәңгесен пешереп алырга була.

Ярар, бүген алай бәрәңгеләр пешереп тормас инде Ханәфи. Иртәннән калган йомырка тәбәсе бар, шуны ашар төшкегә. Улы белән хатыны кайтса, капка төбендә булуың хәерле: бөтенләй үк беткән икән дип уйламасыннар.

## 11

Кайтканнарын күрми калмагаем дип, йомырка тәбәсен дә жылытып тормыйча гына ашап чыккан иде. Чыкканына инде сәгатьтән артты, тегеләр һаман юк әле. Гаҗәп, ни булды икән соң боларга? Беләләр бит инде Ханәфинең йөри алмаганын. Белә торып тилмертмәк булалар микәнни? Әтәчләнеп, кияү егете булып, тәүлекләр, айлар, еллар буе безне ташлап, бәйрәм итеп йөргән чагында без аны бик күп көттек, хәзер ул да безне көтсен әле, диләр микәнни? Ну халык! Ну этлек бу адәм баласында! Менә шушылай Ханәфи хәлендә, аның урынында бер генә сәгать көтеп утырып карасын иде алар. Белерләр иде аннары көтү дигән нәрсәнең никадәр зур газап икәнен... Ичмаса аракысын да бетерделәр. Әлек, эчүчелеккә каршы карар чыкканга хәтле, рәхәт иде: кайчан телисең, күпме телисең, рәхәтләнеп чөмер, беркем сиңа бер сүз әйтми иде. Турысын гына әйткәндә, файдалы әйбер түгел ул, билгеле. Файдалы әйбер булса, иң элек Ханәфи күрер иде аның файдасын. Ул эчкән хәмерне бергә җыйсаң — кечерәк бер күл булыр иде. Кешегә сиздермәсә дә, үзе бик белә: атналар буе сәрхүш булып, томан эчендә йөргән чаклары аз булмады аның. Аңа карап нәрсәсе артты? һе, «артты»! Кая анда арту! Ә менә югалтканын санап бетерерлек түгел. Эчмәгәндә, финагент, инструктор, бүлек мөдире булып эшләгән елларында нинди авторитетлы иде ул! Кая барса да сүзе үтә. Бар җирдә хөрмәт итәләр. Районда иң перспективалы кадрлардан санала иде. Ханәфи председа-

тель булып авылларына кайтырга теләк белдергәч, райкомның икенче секретаре Мансур Сабирович әйткән иде аңа: «Без синең анда китүеңә каршы түгел. Хәзерге вакытта синең шикелле яшь, энергияле егетләр колхозга бик кирәк. Ләкин без сине башта авыл хуҗалыгы институтына җибәреп, укытып кайтармакчы булып тора идек. Ун класс белән генә ерак китеп булмаячак. Югары белемле кадрлар кирәк булачак киләчәктә. Уйла әле тагын бер кат яхшылап. Без синнән колхоз председателе генә түгел, зуррак, җаваплырак эшләргә сәләтле кадр чыгар дип өметләнәбез», — дигән иде...

Аның сүзләрен тыңласа, Ханәфи бүген шушындый аяныч хәлдә утырмас, берәр җаваплы эштә эшләп йөрер, халык арасында абруе, семьяда кадере булыр иде. Укырга теләмәде шул. Тизрәк җитәкче булырга ашыкты. Хәер, колхоз председателе чагында да теләсә укый ала иде ул. Әнә, аның замандашлары кайсы эштән бүленеп торып, кайсы читтән торып укыдылар бит. Аларның да гаиләләре бар иде. Әмма укырга да вакыт таптылар, эшләрен дә гөрләтеп алып бардылар. Турысын гына әйткәндә, Ханәфинең бәласе югары белем алмауда гына да түгел. Әнә, әле бүген дә районда югары белемнәре булмаган ике председатель бар. Берсе инде утыз бишенче елын эшли. Икесе дә эшләрен менә дигән итеп алып баралар: колхозлары алдынгылар рәтендә. Әнә, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое, почетлы академик Терентий Семенович Мальцевның хәтта урта белеме дә юк. Үзен бөтен дөнья белә!.. Ханәфинең иң зур хатасы — әлеге шул аракы белән артык мавыгып, эшенә тиешенчә әһәмият бирмәүдә, заман, тормыш таләпләрен тоеп, шул таләпләр югарылыгында эш итә алмауда булды.

Шулай да менә хәзер берәр стакан кызылны гына булса да кабып куйганда, шәп булыр иде аңа. Хәсән белән Хәлимәсен көтә-көтә, бу араларда тәмам эштән чыккан нервылары бушанып, билләре бераз язылып, сызлаулары кимеп китәр иде шикелле.

Төштән соң ару гына җилли башлады. Күктә аксыл-соры болытлар пәйда булды. Салкынайтып та җибәрде. Бозыла болай булгач көннәр, бозыла. Шулай да өйгә керәсе килми Ханәфинең. Малае белән хатынын көткәнгә генә түгел, гомумән, башка вакытта да, шушылай капка төбендә утыруны яратарак төшә ул. Сөйләшер кеше булмаса да, урамда ичмаса чыпчыклар чыркылдашканны, күрше-күлән тавыкларының чирәм чүпләгәнен, комда актарынганын, шул тавыклар белән әтәчнең җитәкчелек итүен карап, вакыт ничектер тизрәк үткән шикелле була. Өенә бер дә керәсе килми, чөнки котсыз аның өе. Хатын-кыз заты булмаганга, юып-чистартып тормагангадыр, күрәсең, һавасы да бик авыр: кабер исләре килә. Урамда, ичмаса, бердән, һавасы саф, икенчедән, сирәк булса да, тере кешеләр үткәләп тора. Аннары әнә тавыклар, әтәчләр...

## 12

Әтәч димәктән, әтәч халкы да икмәкне бушка ашамый икән. Шушы капка төбендә көннәр буе карап утырганы бар Ханәфинең, белә: әтәчнең эше тавык та чүпләп бетерерлек түгел аның. Тавык дигән нәрсә бик ваемсыз икән ул. «Ка-ка-ка» килеп, чирәм чүпләп йөри торгач, онытылып, күрше әтәч биләмәсенә кереп китү берни тормый аларга. Ә анда кердеме, күрше әтәч хәзер тотып таптарга гына тора. Кайсы әтәчнең үз тавыкларын чит әтәчтән таптатасы килсен? Шулай булгач, хуҗа әтәчкә бер генә минутка да сизгерлекне югалтырга ярамый: үз хуҗалыгындагы тавыкларны гел күзәтеп-барлап тору хәерле. Аннары ул тавыкларның арканын өзеп, койрык чәнчеп, ындыр артыннан кайтып килүче бозау аягы астында тапталып калулары да мөмкин бит. Шуңа күрә бу мәсьәләне дә һәрдаим истә тотарга һәм сизгерлекне арттырырга туры килә...

Аннары килеп, хуҗа әтәч формаль яктан гына түгел, чын мәгънә-

сендә этәч икән, аның карамагындагы тавыкларның йомыркалары аталы булырга тиеш. Ветеринария фәне аңлатуынча, бу бурычны гамәлгә ашыру өчен, ун тавыкка бер этәч кирәк. Ләкин йорт хуҗалары синең ветеринарияң белән исәпләшеп тормый, егермешәр, хәтта утызар тавыкка тик бер этәч асрыйлар. Шулай итеп, бер этәчкә ике-өч этәч вазифасын башкарырга кирәк була. Һәм алар бу эшне һич тә зарланмыйча, намус белән үтәп килләләр...

Йомырка салып төшкәннән соң тавыкларның нигә шулкадәр нык кытаклавын беләсезме соң әле сез? Бердән, алар йомырка салу шатлыгыннан шулай итә. Йомырка салулары җиңел түгел аларга! Йомырка да — тавыкның булачак баласы. Табигать шулай яраткан: бер генә җан иясенә дә бала тудыру җиңел түгел. Ни өчен шулай эшләнгәнме? Сәбәбе бик гади аның: җан ияләре бер-береннең кадерен белсен, бер-береннең хөрмәт итсеннәр өчен шулай яраткан моны табигать. Әнә шуңа ояларыннан төшкәч, авыр эшне уңышлы башкарып чыгуга куанып кытаклый ул тавыклар.

Ләкин аның өчен генә дә түгел. Тагын бер хикмәте бар моның: йомырка салганнарын этәч белсен өчен дә кытаклый алар. Хәбәр бирүен бирсәләр дә, табигать шулай итеп яраткан — бер тавык та этәч янына үзе килми. Аларны, артларыннан чабып, куып тотарга яки үзләрен чакырып китерергә кирәк. Ә алар чакырганда гына килергә ашыкмыйлар. Этәч башта җим табарга, шуннан соң гына аларны чакырырга тиеш. Егерме-утыз тавык артыннан чабып йөри башласа, этәчкә күптән аягын сузарга кирәк булыр иде. Шуңа күрә этәч хәйлә белән эш итәргә мәҗбүр: бик шәп симез суалчан яки анда алтын бодай бөртеге тапкандай хозурланып, кот-кот-кот дип, тавыкларны үз янына чакырып китерә ул. Болай эшләү бик үк егетлек түгел, әлбәттә. Әмма тавыкларның йомыркасын атасыз калдыру ярамый.

Болардан тыш та эше күп әле этәч халкының. Авыл җирендә йорт саен кимендә бер оя чебеш була да була инде ул. Соңгы елларда бу яктан эшләр аеруча ансатлашты: әзер чебиләрне инкубатордан гына алып кайталар. Тавык астында чыгарганда иң күп дигәне дә ун-уникедән артмый торган иде ул чебиләрнең. Ә инкубатордан аларны утызар да кырыгар данә алып кайта башладылар. Аларның барысына күз-колак булырга кирәкме? Кирәк! Югыйсә, үзләрен карга-козгын бик тиз чүпләп бетерәчәк... Аннары тагын, үз карамагындагы тавыклар да җитеп ашкан булуга карамастан, этәч халкының нәфесе күрше тавыкларына да төшкәләп куя. Әнә шундый чакларда, үч иткән шикелле, хуҗа этәч килеп чыга да ике арада сугыш китә. Кай көннәрне хәтта канга баткан-чы сугышырга туры килә... Юк, җиңел түгел этәчләрнең тормышы. Икмәкне бушка ашамый алар. Эшләп, көч түгеп ашыйлар. Аннары бик гадел алар. Адәм балалары кебек сайланып, тавыкларның берсен тибеп, берсен сөеп, кыланып йөрмиләр. Барысына тигез карыйлар. Шуңа күрә бер генә тавыкның да этәчкә дәгъва кылып, бер генә этәчнең дә тавыклар белән низаглашып йөргәнен күрмәссез. Адәм балаларына, бигрәк тә Ханәфи хәлендәге ир-атларга, уйланырлык нәрсәләр бар монда, бик бар. Әйтик, картайган көнендә ялгыз калган этәчне сез беркайчан да күрмәссез. Ни өчен шулай бу? Чөнки этәч — картайгач та этәч булып кала. Аны хуҗалары суеп ашарга мөмкин, төлке тотып ашарга мөмкин. Әмма үз тавыклары аннан беркайчан да баш тартмый. Шулай ук ташлап та китмиләр. Адәм балаларына исә үз этиләрен ташлап китү, хатын-кызларга үз ирләреннән баш тарту — берни түгел икән! Ә бит заманында Ханәфи тирәсендә дә бөтерчек урынына бөтерелеп йөргәннәр иде. Ярый, аның теге Хөснижамал, Фәйрүзә шикелле вакытлыча гына булганнарына артык үпкә дә юк инде. Дөресен генә әйткәндә, Ханәфи аларның үзләренә дә телгә алып әйтерлек игелек күрсәтмәде. Киресенчә, аларныкын ашап-эчеп йөрде. Шулай булгач, аларыннан әллә ни рәхим-шәфкать көтеп булмый. Ә Хәлимәсе? Ул бит аның законлы

хатыны. Балалары да аның фамилиясендә йөри. Һич югы шуның өчен генә...

## 13

Ханәфинең уйларын бүлеп, урамның каршы ягындагы йортка, Бибисараларга, әрҗәсенә өеп каен утыны төягән йөк машинасы килеп туктады. Әһә, Бибисараның үги малае Миргазиз икән. Әнисенә утын китерткән. Күрәсең, ишегалдында гына булгандыр, Сара үзе дә килеп чыкты. Малае да, Сара да, куанышып, тыйнак кына исәнләштеләр дә утын бушатырга тотындылар...

Гаҗәп инде уйлап карасаң. Берәүнең үз баласы да эти-әнисен бар дип белми. Берәүнең үги баласы да эти-әни дип үлеп тора. Менә шушы Миргазизне генә ал. Сарага үги малай гына бит ул. Миргазизнең үз әнисе Миңлегөл икенче балага узганда үлеп киткәч, этисе Сәхибетдин ире сугышта үлеп калган менә шушы Бибисарага өйләнде. Сараның үзенең дә ике баласы бар иде, Сәхибетдингә шуларны ияртеп килде. Сәхибетдиннең сул кулы белән уң аягы йөрми (сугыштан яраланып кайткан), беренче группа инвалид иде. Әмма, шулай булса да, сәламәт ир-атлардан болайрак эшли: сыңар кул белән утынын да яра, каралтыкоймасын да карап-төзәтеп тора, абзарын да җыештыра, тиресен дә түгә, хәтта чалгы сабының бер башын күкрәгенә таккан элмәккә элдектереп, печән дә чаба иде. Төнлә амбар каравыллый һәм хезмәт көнен сәламәт кешеләрдән ким алмый иде. Бер-берен сөешүдән бигрәк, тормыш итәргә кирәк булганга кавышсалар да, Сәхибетдин белән Бибисара яшьтән йөреп өйләнешкән кешеләрдән матуррак итеп тордылар. Ләкин, сугыштан алып кайткан ярасы көчәя барып, Сәхибетдин илле өченче елны вафат булып китте. Сара берүзенә биш бала белән калды (Сәхибетдиннән бер кыз тапкан иде). Шул биш баланың олысы — Миргазиз. Үги әни дип тормады: дүртенчене бетергәч, Сараның үзенә генә тормыш алып барулары авыр икәнен күреп, зурлар белән рәттән колхозда эшли башлады.

Сара шактый кырыс холыклы хатын: иркәләп үстермәде Миргазизне. Дөрес, какканы-сукканы да сизелмәде алай. Ничек кенә булмасын, ул малайны Сара үз балаларыннан якын күргәндер дип әйтеп булмый бит инде. Аннары Миргазиз армиягә китте. Шуннан шоферлыкка өйрәнеп кайтты. Авылда машина юк, Куралык инде бригада булып кына калган иде. Әмма җаен тапты Миргазиз: районга барып, больница машинасына шофер булып урнашты. Хәзер дә шунда эшли. Мактап туя алмыйлар үзен. Фарук Сәләхович та бик ярата икән. Сеңелләрен-энеләрен үстереп кеше итү өчен дә Сарага күп ярдәме тиде шушы Миргазизнең. Сараның туктаусыз ягып торсаң да өч еллык утыны бар өстенә, шул малай әнә тагын бер машина шыңгырдап торган каен утыны алып кайткан.

Ә Ханәфинең күп куйганда да берәр айлык утыны калды. Аннары ни эшләр, кыш чыгарлык утын каян алыр — шайтан белсен. Узган кыш, утыны беткәч, тезмә агачларын алып ягарга туры килде. Инде алары да бетеп бара, катып үләргә генә калган иде, ярый әле менә шушы Миргазиз райтоптан үзенә дип яздырып, ике кубометр утын алып кайтып бирде. Май башларына тикле җитте шул утын. Аннары Гайнелхәят малае Каюм ярдәм итте: үзләренә утын алып кайтышлый Ханәфигә дә берәр кубометр чамасы һәйбәт имән утыны калдырып китте. «Бригадир чагында безгә эшләгән этлекләрең күп булды булуын, Ханәфи абый. Шулай да миннән булсын яхшылык: мә, як рәхәтләнеп!» — дип чеметтереп куйды куюын. Тик ни хәл итмәк кирәк, утынын биргәч, анысына гына түзәсең инде аның. Каюм дөрес әйтә: әйе, аны рәнҗеткән чаклары булды Ханәфинең. Бервакыт шул Каюм төнләләтеп, еларлык булып, Ханәфи

катына килде: «Әни бик каты авырып китте, Ханәфи абый. Больницага илтәсе иде, — ди. — Трактор белән илтер идем, кабинага утырып барыр хәле юк. Ат белән илтмичә булмый. Берәр ат биреп тор әле, зинһар?» — ди.

Ул чакта Ханәфи — бригадир. Авылда әле тугыз баш ат бар. Аларның дүртесе гел җигелми, чөнки җигеп йөрер кеше юк. Теләсә кайсы атны биреп торырга була иде Каюмга.

Ләкин ул: «Юк, булмый, малай, бирә алмыйм. Патамушты син колхозда эшләмисең. Әнә, эшли торган җиреңнән, Ушемкәдән сора син ул атны!» — дип, тегене борып җибәрде.

— Мин эшләмәсәм, әни шушы колхозда эшли бит, — дип тә караган иде Каюм. Барыбер тыңламады Ханәфи. Бүтән юньлерәк җавап таба алмагач, дорфалыкка күчеп: «Син миңа акыл өйрәтмә, ярыймы! Ни эшләргә кирәген мин үзем беләм!» — дип куып ук чыгарды. Чөнки ул чакта Ханәфинең кечтән эчкәннән башы бик каты авырта, ә Каюм аның катына буш кул белән килгән иде...

Әнә шуңа күрә утын калдырып киткәндә Каюм ыргыткан әлеге авыр сүзләргә каршы берни әйтә алмады Ханәфи.



## 14

И-и-и-их! Шушындый ук мескенлеккә калырмын дип уйлаган кеше идемени ул? Киресенчә, гомере буе җитәкче булып, башкаларны өйрәтеп-эшләтеп, бәйсез-иркен яшәр, берәүгә дә мохтаҗлыгы төшмәс, барысы да тик аның рәхим-шәфкатенә мохтаҗ булырлар шикелле иде. Чөнки ул иң акыллы сүзне мин сөйлим, иң эшлекле тәкъдимнәрне мин кертәм дип исәпли. Шуңа да кешеләр белән киңәш-табыш итми, башкалар әйткәнне колагына алмый. Ә инде үзенә карата чак кына тәнкыйть сүзе әйтүчеләрне кан дошманы итеп күрә, аларга ничек тә берәр төрле явызлык эшләмичә калмый торган иде. Хәзер менә бик тынлар иде ул аларны — эш узган. Шулай булгач, заманында ул кыерсыткан кешеләрнең хәзер аңа карата чит-битараф булулары бер дә гаҗәп түгел. Гаҗәбе шул: элек Ханәфине алла урынына күреп, ул ни әйтсә шуны эшләп торганнарына хәтле бөтенләй башкача сөйләшә башладылар. Әнә, авылның югары очында кырый йортта яшәүче Нурмыйны гына ал. Гомере буена гади колхозчы булып, атлы эштә эшләде. Бүтәннәр җикми торган иң чыгымчы атны ул җикте. Иң начар арбаны, иң начар чананы аңа бирәләр иде. Ә ул беркайчан зарланмый, үпкәләми. Атна-ун көн эчендә арба булса — арбасын, чана булса чанасын бүтәннәрнекеннән әйбәтрәк итеп үз кулы белән үзе теләгәнчә төзәтеп куя. Нинди эшкә кушсаң — шунда бара, карышып торуның ни икәнен дә белми. Аннары бик ярдәмчел иде. Ханәфи өчен аеруча үлеп тора: утын-печән алып кайтасы бармы, тегермән тартасы бармы, каралты-кура төзәтәсе бармы — бөтенесен шул Нурмый эшләр иде. Колхоз җыелышында берәрсе Ханәфигә каршы берәр сүз әйтсә дә, иң элек аны яклап чыгучы кеше шул Нурмый була. Шуңа күрә халык аны бик үк яратып та бетерми. Үз артында, Мокыт Нурмый, алла бозавы дип кенә җибәрәләр иде...

Ханәфи авырып китеп, бригадирлыктан төшерелгәч, әнә шул «алла бозавы»на тикле танымаслык булып үзгәрде: Ханәфи белән сөйләшкәндә үз тиңе шикелле итеп тота, кирәксә-кирәкмәсә дә «без — фронтаукилар», «без фрунтта булган җылларда» дип күкрәк кагып сөйләшә торган булып китте. Алай гынамы, хәтта Ханәфигә акыл да өйрәтмәкче була кай чакларда. Әле атна-ун көн генә элек, урамнан үтеп барышлый менә шушында Ханәфи янына тукталган иде. Хәл-әхвәл сорашканнан соң Ханәфинең авыруы хакында сүз чыккач, әйтә бу:

— Килүе генә тиз, китүе озак сузыла шул ул авыру дигән нәрсәнең, Ханәфи парин. Чамасызрак кыландың шул заманында, үзеңне-үзең бер

дә саклый белмәдең. Салу белән, хатын-кыз белән артык хиресләнү яхшыга алып бармый шул, — ди.

Әйтерсең, боларны Ханәфи үзе белми инде!

— Син миңа вәгазь укыма, ичмаса азрак ярдәм ит, алай бик кызгансаң. Көрәкнең сабы сынган анда, шуңа яңа сап куеп бир!

Элеккерәк елларда булса, баш өсте дип кенә торыр иде. Ә теге көнне бер дә исе китмичә генә:

— Үз гомеремдә көрәк-сәнәкләреңне күп сапладым инде мин синең, — ди. — Әмма рәхмәт ишеткән чакларым, ай-һай, булды микән? Ну мин алай үпкә саклап җөри торган кеше түгел. Тәгышту бер бу юлы гына гозереңне кире кагып булмас. Тик бүген үк түгел. Хөсниҗамал тырма кирәк дигәние, бүген шуны ясап бирәсем бар. Аннары килеп, синең юньле балтаң да, көрәк сабы ясардай рәтле агачың да юк бит. Кая, көрәгеңне үзем белән алып китим дә, шу'ны ике-өч көн эчендә ничек тә ясап китерергә тырышырмын, — дип ялындырыбрак кына алып китте.

Әллә бөтенләй онытты инде Мокыт тәре: бүген бишенче көн, ә аның ни көрәк саплап китергәне, ни үзе күзгә-башка күренгәне юк. Ханәфи «рульдә» утырган чак булса, сәгате-минуты белән саплап китерәчәк иде ул аны. «Ачуланма инде, Ханәфетдин туган, килеп җитмәгән җире булса. Кул астында шушыннан да әйбәтрәк саплык булмады», — дип гафу да үтенгән булыр иде әле. И-и-их! Кешенең утырган урынына карап, ник болай тиз үзгәрә икән бу адәм баласы. Нурмый булып, Нурмый шулай... Тукта, әнә, бу таба килүче кеше шул үзе түгелме соң? Ул бит. Әнә, кулында көрәге дә бар. Кара син аны, ә? Әллә үзе турында уйлап утырганны сизгән дә шуңа килүе микән? Ярабби, бирсә дә бирә икән табигать адәм баласына тазалык-саулыкны! Алтмыш дүртенче яшенә чыккан дип кем әйтер шушы Нурмыйны: утыз биш яшьлек ирләрдән җиңел атлап, нык басып килә бит! Ни гәүдәсендә, ни кыяфәтендә картлык галәмәтенең эзе дә юк. Әгәр чигә чәчләре дә агармаган булса, аңа әле кырык-кырык биш яшьтән арыны бирәү дә бирмәс иде.

Әнә, гадәтенчә, бу юлы да ерактан ук елмаеп килә. Әйдә, башлап үзе сүз катсын әле. Көрәкне бик озак тотты бит. Ни дияр икән?

— Нихәлләр бар, Ханәфи энекәш?

Ханәфи теләр-теләмәс кенә кул бирде: тегенең «энекәш» дигәне ошамады. Шул ук вакытта дорфалык күрсәтергә дә ярамый иде. Ни дисәң дә, көрәкне саплап китергән бит.

— Минем хәл билгеле инде, — диде ул. — Сызланудан баш чыкканы юк.

— Озаккарак китте шул авыруың. Түз инде, бәлки үтәр әле, боерган булса.

— Их, шулай булсачы!

— Үтәр-үтәр. Тик күңелеңне генә төшермә. Менә, көрәгеңне саплап китергәнием, ошатсаң.

Ханәфи көрәкне кулына алып, көрәк сабын бик җентекләп караптикшереп чыкты. Сүз тидерерлек җире юк, сапны коры әлмә агачыннан бик һәйбәтләп шомартып ясаган иде.

Ләкин Ханәфи мактарга ашыкмады:

— Болай ярыйсы шикелле күренә, кулга тотып эшли башлагач, ни әйтер тагы, — диде ул вәкарь белән генә. — Нигәдер бик озак тотып китердең.

— Шулайрак булды шул, парин. Башка эшләрем барые. Аннары Казанга да барып кайтырга туры килде. Ике көнем шунда үтте.

— Ниең калган анда?

— Татваянкум чакыртканые.

— Ни хаҗәтең булган аларга?

— Үрдин бирергә дәшкәннәр.

— Кемгә?

— Мине дәштергәч, миңа була торгандыр инде.
— Бирделәрме соң?
— Ник бирмәсеннәр, дастуин булгач. Татваянкум күкрәккә үзе такты. Маладис, иптәш Нурисламов: тыныч тормышта әйбәт эшләп, Хезмәт Кызыл Байрагы ордине белән бүләкләнүеңне беләдерием. Сугышта да сынатмагансың икән, менә монысы шуның өчен. Рәхмәт, агайэне! — дип мактап та җибәрде әле.
— Нинди орден бирделәр соң?
— Кызыл Йолдыз ордены.
— Анысы ни өчен инде тагы?
— Кырык икенче елда бер сугыш вахытында пулык командирын коткарып калган өчен диделәр.
— Ник соң аны кырык биш елдан соң гына бирергә булганнар. Ник вакытында бирмәгәннәр?
— Ул сугышта яраланып, гүспителгә эләккәнием мин. Ярам төзәлгәннән соң пулыкка кире кайтмагач, күрәсең, мине таба алмаганнардыр. Әй, баш исән-сау булгач, анысы әллә ни мөһим түгел инде аның.
— Син бит фронтта ат җигеп, ездовой булып кына йөрдем диген иден түгелме? Кайда, ничек коткардың ул командирны?
— Һи-и-и! Ездавай дигәч тә, син аны кайдадыр артта, тылда, тыныч җирдә генә йөри торган эш дип уйлыйсыңмы әллә? Әгәр бик беләсең килсә, передовойга караганда да җаваплырак, хәвефлерәк аның эше. Пулык камандиры гына түгел, дивизия белән командалык итүче гиниралларның да кул биреп күрешкән чаклары булды шушы Нурмый абзаң белән! Тәгыйшту... Ә пулык камандирын мин дошман пулык штабына көтмәгәндә һөҗүм иткән чакта коткарып калдым. Мина ярчыгы тиеп, бот сөяген чәрдәкләгәние. Әдүтантне үтергән үк ие. Әнә шул чакта аркама салып шуышып, сугыш кырыннан апчыктым мин аны.
Нурмый сөйләгәннәрне шыпырт кына тыңлап торырга да, «бик әйбәт, молодец, булдыргансың», дип ездовойның фронтта тоткан урыны хакындагы гәпне шуның белән иплән кенә очлап куярга иде Ханәфигә. Ә ул, ахмак, тегенең орден алуына көнләшүдән, телен тыеп кала алмады:
— Да-а-а, уйлап карасаң, гаҗәп инде бу дөнья хәлләре! Шулай бит Нурмөхәммәт, ә? — дип көрсенеп куйды.
— Гаҗәпнең дә гаҗәбе инде, парин. Күпме кеше, күпме ат, күпме техника кырылды бит ул сугышта. Күпме байлык, күпме шәһәрләр, күпме авыллар көлгә әйләндерелде. Файдасы кемгә тиде? Берәүгә дә булмады. Фашистлар җиңелде. Без җиңүен җиңдек тә, ләкин бик кыйммәткә төште ул безгә җиңү. Сугыш булмаган булса, бүген болай гына яшәр идекмени без? Бөтен җир шарында безнең илдән бай ил булмасые. Кырык бер ел үтте, әле һаман беткәне юк шул сугыш китергән афәтнең яралары.
— Туктале, Нурмый, кеше чалгы белән чапканда, син урак белән урма әле алай. Мин бит ул хакта түгел, бөтенләй башка нәрсә хакында әйткән идем!
— Ниткән башка нәрсә инде ул тагын? Нәрсә, мин дөрес әйтмәдем мәллә?
— Ярый-ярый, синеке дә дөрестер. Ләкин мин сиңа бу дөньда гаделлек белән тигезлек дигән нәрсә юк ул, барысы да очраклылыкка, начальствоның сиңа нинди мөнәсәбәттә булуына корылган дип әйтмәкче булган идем.
Нурмый, гаҗәпсенеп, Ханәфигә карап куйды:
— Тел төбеңне бик үк аңнап җитә алмыйм әле мин синең, парин.
— Менә сиңа бер минутлык батырлыгыңны онытмыйча, кырык биш елдан соң да орден биреп кайтарганнар. Мин менә утыз биш ел буе гел җаваплы эштә эшләдем. Күпме нервы, күпме көч түктем. Орден дип әйтмим, хәтта бәләкәй генә бер медаль дә эләкмәде миңа. Алай гынамы соң? Авырып эшли алмый башлагач, эштән киткәндә, хәтта рәхмәт тә

әйтмәделәр! Шул ук вакытта сиңа — кешеләр белән житәкчелек итеп нервы бозмыйча, гомереҗ буе ат җигеп, тыныч кына, кеше кушканны гына эшләп йөргән кешегә — моннан өч ел элек кенә орден биргәннәр иде. Быел миңа икенчесен, тагын да дәрәҗәлерәген биргәннәр. Шулай булгач, кайда монда гаделлек тә кайда тигезлек?!

— Ә-ә-ә, — диде Нурмый, исе китеп. — Менә нәрсәдә икән хикмәт! Күптән шулай дип әйтәсең барые аны. Менә хәзер аңнашылды: көнчелегеңә көч килгән икән бит синең, парин. Рас алайга киткән икән, давай, мин дә әйтим инде әйтәсе сүземне. Ул орденнарны ни өчен сиңа түгел, ни өчен миңа биргәннәрен, бәлки, шуннан үзең аңларсың.

Әйе, син гомереңә буе гел нәчәнник булып, гел акыллы булырга тырышып йөрдең. Башта финагент булып, халыктан налук, заем җыйдың. Аннары калхузда персидәтел булып, сиңа хәтле бөтен Татарстанга гөрләп барган калхузны өч-дүрт ел эчендә тәмам таркатып бетердең. Аннары авыл сәвите персидәтеле булып, халык исәбенә эчеп, типтереп җөрдең. Бүтәнен әйткән дә жук, хәтта үзең көн саен суын эчә торган чишмәнең бурасын да яңарттыра алмадың. Зират рәшәткәсенә дип халыктан җыйган акчаны исраф иттең. Персидәтелдән чыгарылгач, бригадир булып җөргән булдың. Нәрсә кыдырдың инде син анда? Утын, печән алып кайтырга, тегермәнгә барырга ат биргән кешеләрдән хәмер эчеп йөрүдән башканы белмәдең бит син! Ничә хатын-кыз белән мәтәвекләнеп карадың, шуларның кайсы белән адәм рәтле итеп тора алдың? Юк, сытма әле син чыраеңны, тыңлап бетер әле минем ачуланып түгел, үз итеп, сине кызганып әйткән сүзләремне. Тыңла да нәтиҗә ясарга тырыш. Тек, вәт, ни аллага, ни муллага дигәндәй, җәмәгать эшләрен юньләп алып бара алмавың өстенә, үз тормышыңның да рәте-башы булмады. Хәзер дә жук. Хуҗасы куып чыгарган карт ишәк хәлендә яшисең бит. Шуның өстенә авыруың да бар. Сүзләремне авырга алсаң алырсың, әмма ләкин боларның барысына да иң элек үзең бинават, Ханәфи. Шулай булуга карамастан, бик акыллыга салышып, мине гаепләп, халыкка, хөкүмәткә үпкәләп, эшемне күрмәделәр дип лыгырдап утырган буласың. Күрердәй эшең булмагач, кем күрә ди аны?.. Кәнишне, мин — алай, синең шикелле, гомер буе нәчәнник булып җөргән кеше түгел. Гомерем буе гади калхузчы булдым мин. Үзең беләсең, кая кушсалар, шунда бардым, ни кушсалар — шуны эшләдем. Синең үзеңә дә гомергомергә мин булыша килдем түгелме: ягарыңа утынны мин апкайтып бирдем. Утыныңны мин кистем. Каралты-кураңны сипләтергә кирәк булса, шулай ук миңа әйтә торганыең. Аллага шөкер, аңа карап, укам коелмады. И һәм синнән ким дә яшәмәдем. Бүгенгесе көндә дә, шөкер, тормышым кешенекеннән ким түгел. Көненә егерме-егерме биш литр сөт бирә торган бура хәтле сыерым бар. Шуның янына танам, унбиш баш сарыгым, ишегалды тулы каз-үрдәгем бар. Рәхмәт хөкүмәтебезгә, эшләгән кешенең кадерен белә башлады соңгы елларда: мал асраган кешегә курмысын кызганмый, прәме өйгә китереп бирәләр. Тик иренмә, асра гына. Ә мин иренмим. Малын да асрыйм, инде менә икенче ел пенсиядә булсам да, башка эшен дә эшлим. Нәрсәгә тотынсам, шуны булдырам, аллага шөкер. Шуңа күрә хөрмәт тә итәләр. Шуңа күрә мөлкәтем дә бар. Кирпечтән салган гаражымны үзең күреп торасың. Инде дүртенче ел шул гаражда «Жигули»ем тора. Дөрес, үзем йөрер өчен түгел ул. Бу яшькә житкәч, миңа аның белән булашып йөрүнең хаҗәте юк. Малай өчен дип тотам мин аны, авылга кайтып тора башласа гына бирәчәкмен. Пока малайның кайтасы гына килми. Чаллыда шофер булып эшли. Аңламассың хәзерге яшьләрне. Хатыны, ике баласы белән шунда бер бүлмәле бәләкәй генә фатирда чиләнеп ятса ята, әмма авылга, алты почмаклы, болын хәтле өйгә кайтасы килми. Балаларны укытырга мәктәп юк ди. Әйтсәң сүз, төртсәң күз чыга: мәктәпне дә син бетерттең бит, Ханәфи. Авылда мәктәп булса, минем малай да, бүтәннәр дә кайтырые. Күбесе бөтенләй китмәгән дә булырые. Шулай

да өметне бөтенләй үк өзеп бетермим әле: кайтыр ул минем малай. Балалары үсә төшеп, Кече Елгага йөреп укырлык булгач кайтыр. Хәзер бит авылда да шәһәр жиреннән ким түгел. Кара син бу иркенлекне! Кара син бу саф һаваларны! Газы бар, электыры бар, тилибизыры бар. Әнә, өемдә жиде йөз тәңкәлек төсле тилибизырым эшләп тора. Илдәген генә түгел, жир шарының аргы ягында булган хәлләрне көнсәгате белән күрсәтеп торалар. Турысын әйткән өчен авырга алма, парин, синең бит шушы искереп барган өеңнән башка мәчең дә юк лабаса! Менә шуннан үзең фикер итеп кара инде: син күпме эш күрсәткән дә бу дөньяда мин күпме эш күрсәткән? Мин бит ишегалдым тулы малтуарны үзем генә ашап бетермим. Карчык белән миңа күпме генә кирәк? Үзебездән арткан сөтен дә, итен дә дәүләткә сатып барабыз. Ә син, панимаешь, ни аллага, ни муллага дигәндәй, семьяңа да, дәүләткә дә юньле эш күрсәтмәдең, киресенчә, гомерең буе үзең халык өстеннән туенып йөргән башың белән бөтен дөньясына үпкәләп, тигезлек юк, гаделлек юк дип зарланып утырган буласың. Әйбәтләп уйлап карагандә, бер дә кешегә үпкәләрлегең юк синең, Ханәфетдин. Гомерең буена калхуз жилкәсен кимереп ятканың өчен, ил алдында үзең оялырга тиеш син, бик беләсең килсә. Калхузның күпме мөлкәтен рисвай иткәнеңне белмиләр дип уйлыйсыңмы әллә? Ялгышма, барысын да беләләр. Төрмәгә эләкмичә, исән-имин пинсиягә чыгып котылуыңа куанып, артыңны кысып тик кенә утырасы урында, орденнар өмет итеп хыялланып жөрмә инде, яме. Тагышту...

Нурмый булып Нурмый шулай сөйләнеп торгач һәм аның әйткәннәренә каршы куярлык һичнинди дәлиле булмагач, түзмәде Ханәфи:

— Житте сиңа, Мокыт тәре, тукта! Гомерең буе миңа ялагайланып, надан башың белән минем аркада кеше булып йөргән килеш, алай бик белдекле булып утырма монда! Бар, хәзер үк кит янымнан! — дип куып жибәрде.

Китте Нурмый. Әмма әйтәсен мәңге онытылмаслык итеп әйтеп китте:

— Һәй, куркыттың! Һәй, котымны алдың! — диде ул, беркайчан да булмаганча ярсып һәм үпкәләп. — Үзеңне кешегә санап, яныңа килеп утырганга рәхмәт әйтәсе урынга, кодрәтләнеп торган буласың әле тагы. Миннән башка эт тә килми бит синең яныңа. Ярар, китәм. Миңа нәрсә. Ят шунда берүзең сөрсеп!

## 15

Нурмый киткәнгә дә байтак вакыт узды инде. Әмма Ханәфинең ике күзен дүрт итеп көткән кешеләре һаман күренми әле. Юлда ватылып яталар дияр идең, Хәсәннең яңа «Волга» алганына ике ел да юк әле. Эшендә берәр төрле тоткарлык килеп чыккандыр дисәң, ата кеше хакына аның да берәр рәтен табарга тиеш иде ул.

Нурмый да үпкәләп китеп барды ичмаса. Юкка үпкәләтте аны Ханәфи. Әйткән сүзләре авыр тоелса да, ничек тә түзәргә иде аңа. Һич югы уен-көлкегә алган булып үткәреп жибәрәсе иде. Әллә ни зур акыллы кеше булмаса да, вакыт үткәреп, тегесен-монысын сөйләшеп утырырга ярый иде әле шунда. Менә шушылай япа-ялгыз утырулары, ай-һай, яман бит...

Әйе, алай дорфа кыланмаска иде аңа Нурмый белән. Чынлап торып исәп иткәндә, ул әйткәннәр дөрес бит. Колхозны тараттың дип, артты-рыбрак жибәрде жибәрүен. Ханәфи генә таркатмады аны, чор, заман таркатты. Чөнки ул чакта мәсьәлә ил күләмендә шулай куелган иде: эреләндерергә! Ә менә шул «Кызыл урнәк»не алдынгылар рәтеннән артка калдыру Ханәфи эше булды. Анысын беркая куя алмыйсың. Лә-

кин ул бит юри шулай эшләнгән эш түгел. Алдынгылар рәтендә булырга Ханәфи дә теләгән иде. Әмма җаен таба алмады, нидер җитмәде аңа, нәрсәдер комачаулады. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә алыш-биреше бик сай булуы — анысы билгеле. Әмма хикмәт анда гына да түгел. Әнә, Ханәфи председатель булып эшли башлаган елларда шәһәрдән килгән утызмеңчеләр арасында иң артта калган хуҗалыкларны да кеше иткән председательләр әллә аз булдымы? Аларның да күбесенең авыл хуҗалыгы өлкәсендә махсус белемнәре юк иде. Ләкин колхозларга килеп эшли башлау белән, шул хәлне аңлап, укырга тотындылар. Ханәфи, мин авыл малае, мин җир кешесе дип, укуны кирәк санамады. Ә гомер үтә, заман үзгәрә, таләпләр арта торды. Һәм ул заман арбасыннан төшеп калганын сизми дә калды... Халык белән дә уртак тел таба алмады. Үзе эшнең рәтен белмәсә дә, эш рәтен белгәннәргә җикеренеп, акыл өйрәткән булып, аларның гайрәтләрен чигерде. Шуңа күрә колхозның эше алга бармады. Ул колхоз председателе булып эшли башлаганның өченче елында «Кызыл үрнәк» бөртекле ашлык уңышы ягыннан булсын, ит-сөт җитештерү ягыннан булсын, районда иң арттагы колхозлар рәтенә калды. Авыл халкы шул елны ук аны председательлектән төшерергә ниятләгән иде. Райкомның икенче секретаре Мансур Сабирович алып калды. Ханәфинең моңарчы юньле эш күрсәткәне булмаса да, нигәдер ышана иде ул аңа. Ханәфинең колхоз белән тиешенчә җитәкчелек итә алмавы вакытлы хәл генә, киләчәктә үзгәрер, әйбәт председатель булып китәр дип өметләнә иде. Шул фикерен ул «Кызыл үрнәк»нең илле алтынчы елның февраль аенда үткәрелгән отчет җыелышында колхозчыларга да әйтте. Район халкы арасында авторитеты зур иде Мансур Сабировичның. Аңа ышанып кына калдырганнар иде Ханәфине. Алдагы елда Ханәфи үзе дә эшен яхшыртырга ниятләгән иде. Мансур Сабировичның сүзен аклау өчен генә булса да, колхозны һич югы урталагылар рәтенә кертергә кирәк иде аңа. Ләкин... Ниятенә ирешә алмады гына түгел, киресенчә, ул елны «Кызыл үрнәк» барлык күрсәткечләре ягыннан тагын да арткарак калды. Моның өчен иң элек Ханәфи җаваплы, иң элек аннан сорарга тиешләр һәм, әлбәттә, аны урыныннан очырачаклар иде. Бәхетенә каршы, колхозларны эреләндерү кампаниясе башланды. «Кызыл үрнәк»не, «Кызыл юл»га кушып, бригада итеп калдырдылар. Эреләндерелгән колхозның рулен Ханәфигә тоттыру хакында сүз дә булмады, билгеле. Шулай да бөтенләй үк этеп тә екмадылар. Чөнки Ханәфи район җитәкчеләре белән сөйләшә белә: алар кушканны эшләргә вәгъдәне мул бирә, районда үткәрелгән җыелышларда чыгыш ясамый калмый. Куштанлыгы да бар: начальство авылга килгән чакларында тиешенчә каршы алып, тиешенчә кунак итеп җибәрә белә. Аннары килеп, ул елларда җитәкче кадрлар да бик алай артып тормый иде. Ханәфи — ни генә дисәң дә, заманында райком аппаратында эшләгән кадр иде бит. Шуңа күрә аны үтилгә үк чыгарып ташламадылар. Эшсез калуына ай да үтмәде, авыл советына председатель итеп сайладылар.

Әгәр колхозның эше Ханәфигә кадәрге председатель вакытындагы шикелле әйбәт барган булса, «Кызыл үрнәк»не каядыр кушу хакында сүз дә булмас, ихтимал, ул әле дә элеккечә алдынгы колхоз булып, гөрләп утырыр иде. Әгәр инде, җире аз, андый колхозда идарә аппараты тоту экономик яктан файдалы түгел дип, башка берәр колхозга кушкан булсалар да, колхозның үзәге Куралыкта булыр, һәм ул менә шушылай үчүгә бармас, киресенчә, зурайган, матурланган булыр иде. Мисалга ерак барасы түгел, әнә, Чирмешән авылын гына ал. Кырык биш-илле йортлы кечерәк кенә бер авыл иде теге елларда. Бүген шул авылда йөз дә егерме өч йорт бар. Ике йөз илле кешелек тамаша залы, ындыр табагы хәтле спорт залы, унсигез меңгә якын китабы булган китапханә, төрле түгәрәкләр өчен әллә нича бүлмәле менә дигән культура йорты эшләп тора. Чөнки ул — колхоз үзәге. Аның шулай үзәк булып калуы элекке председатель — Ханәфинең замандашы Газизов Гыйлемхан аркасында булды.

Гыйлемханның булсын дип тырышып йөргәнен райком да, халык та белә иде. Аның колхозын зуррак колхозга кушып, үзен шунда председатель итеп куярга уйлаганнар иде башта. Ләкин Чирмешән халкы да, Гыйлемхан үзе дә кушылырга теләмәделәр. «Әгәр безне бригада итеп калдырасыз икән, ул чакта мин председатель булып эшләмәячәкмен!» — дип, Гыйлемхан мәсьәләне бик конкрет куйды.

Райкомның андый председательне югалтасы килми иде, шуңа аның белән исәпләшмичә кала алмадылар. Аннары килеп, кушыласы колхозның колхозчылары да Газизов председатель булуны телиләр иде. Шуңа алар да үзәкне Чирмешәндә калдыруга каршы килмәделәр. Тик эреләндерелгән колхозга алар колхозының исемен бирүне генә шарт итеп куйдылар. Анысына ике як та риза булды. Шулай эшләп, һәр ике як та отты: эреләндерелгән «Алга» колхозы Гыйлемхан Газизов җитәкчелегендә күзгә күренеп алга барды. Бүген дә ул колхоз — районда гына түгел, республика күләмендә алдынгыларның берсе: ел саен алып килә торган саф табышы гына да миллион ярымнан ким булганы юк!..

Гыйлемхан — әле дә шул колхозда председатель. Дүрт ордены бар инде. Партия съездына делегат булып барды. Хәзергесе көндә — республика Верховный Советы депутаты. Начальство каршында да авторитеты зур: кая барса да сүзе үтә. Халык та ярата үзен: ни әйтсә — шуны тыңлап, авызына карап торалар. Ә бит председатель булып Ханәфи белән бер тирәдә утыз меңче булып эшли башлаган кеше иде бит ул. Аның да, Ханәфинеке кебек үк, авыл хуҗалыгы буенча махсус белеме юк. Ул да нибары җиде класс бетергән иде. Аерма тик шунда: Ханәфи колхозга райком аппаратыннан үз теләге белән кайтты, ә Гыйлемханны бригадир булып эшләп йөргән җиреннән председатель итеп мәҗбүри диярлек күтәрделәр.

Ә хәзер Ханәфи кем дә Гыйлемхан кем? Куралык авылы нинди дә Чирмешән авылы нинди? Аерма — җир белән күк арасы. Хәзер инде искә алырга да оят хәтта... Гомерне шул кадәр дә заяга үткәрергә кирәк бит! Шул кадәр дә мәгънәсезгә үткәрергә кирәк бит бер генә тапкыр бирелә торган гомерне!..

Уйланган кешегә уйланырлык вакытлар булмады түгел. Гыйлемхан башта авыл хуҗалыгы техникумын, аннары институт тәмамлаганны Ханәфи күреп-белеп тормадымыни? Ничек кенә белде әле. Техникумга керергә җыенганда, Гыйлемхан аның янына үзе килеп: «Әйдә, агай-эне, бергә барыйк, алай күңеллерәк тә булыр, үзара ярдәмләшеп тә укырбыз», — дип әгъвәләп караган иде. Ханәфи аны тыңламады гына түгел, киресенчә: «Ә нигә вакыт уздырып, чабата туздырып, мәшәкатьләнеп торырга? Әнә, шәһәрдән килгән председательләр укысын. Ничу безгә анда барып, авылны күргәннәре дә булмаган «белгечләр»нең авыл, колхоз тормышын ничек алып бару турында акыл сатканын тыңлап утырырга. Аннары шунысын да онытма: хәзерге заманда колхоз председательләрен алыштыруны чүпкә дә санамыйлар. Аның өчен район начальствосына каршы нибары бер сүз әйтү җитә. Укып йөреп тә начальствога ярый алмасаң — ул укуның нигә кирәге кала? Син теләсәң ни әйт, Гыйлемхан, бармыйм мин ул техникумга. Сиңа да киңәш итмим», — дип, аның да күңеленә корт салып җибәрде. Ул чакта Ханәфи, чыннан да, шулай дип уйлый һәм, шулай уйлап, бик дөрес эшлим дип исәпли иде...

Ялгышты, бик нык ялгышты Ханәфи. Эх, шул елларны кире кайтарып була торган булса, Гыйлемхан Ханәфине түгел, Ханәфи үзе башлап аны укырга әгъвәләр иде...

Әлбәттә, Гыйлемханга да җиңел булмады. Бүгенге дан-дәрәҗәгә ирешкәнче кәҗә майларын байтак чыгарырга туры килде аңа. Гыйлемхан техникумга керик дип килгәч Ханәфинең аңа әйткән сүзләре өлешчә расланды. Өч баласы, юктан гына кылтаерга торган хатыны булган, шул ук вакытта колхоз тикле колхозны җитәкләп алып барган кешегә читтән торып уку болай да җиңел түгел. Шуның өстенә тагын ул

елларда, гәрчә җанын-тәнен биреп колхоз эше өчен тырышса да, Гыйлемханны райкомның беренче секретаре бик үк өнәп бетерми; җае чыккан саен, аны кимсетеп тора, ә уңышларын бөтенләй күрмәмешкә сабыша иде. Сәбәбе шул: Гыйлемханның начальствога ялагайлана торган гадәте юк, кемнең кем булуына карамастан, турысын әйтә, ә Беренче андыйларны яратмый, чөнки тик үзен генә белдекле саный, кешеләр фикере белән бөтенләй исәпләшми. Шуңа күрә үзенә ялагайланучы председательләрне, гәрчә тегеләренең эше әллә ни дан булмаса да, яклый һәм мактый, аларга һәрьяклап ярдәм итә. Ә Гыйлемхан ишеләргә кадер-сан юк: бик мөһим мәсьәлә белән килгән вакытларында да андыйларны кабул итмичә җибәрә иде.

Дөрес, Гыйлемханның холкы май да бал түгел, ул да үзен артык горур тота. Район күләмендәге киңәшмәләрдә булсын, райком бюросында булсын, башкалар шикелле шабыр тиргә батып, тын алырга да куркып утырмый. Әйтәсе сүзен әйтә, үзе инанган эшне эшли. Үзе инанмаганны, әллә нинди карарлар белән мәҗбүр итәргә тырышсалар да, эшләми иде. Әнә шуның өчен башта аңа елына икешәр-өчәр шелтә бирә килделәр. Аннары эшеннән алдылар. Монысы, нәкъ Ханәфи юраганча, Гыйлемхан авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап кайткан елны булды. Бүгенгедән чыгып караганда, Гыйлемханның ул чактагы «гаебе» бөтенләй көлке булып күренергә мөмкин: «колхозчыларга колхоз кырыннан печән бүлеп биреп, башбаштаклык кылганы, шуның белән башка колхозларның колхозчыларына начар үрнәк күрсәткәне» өчен алдылар аны эшеннән.

Шулай бер көнне ул, райкомнан кайтышлый, Чирмешәнгә сугылып, Гыйлемханның хәлен белеп, юатып чыгарга булды.

Әле кайчан гына типсә тимер өзәрдәй таза, йөз дә ун килолы Гыйлемхан унбиш-егерме көндә күзгә күренеп ябыккан, элек тә ике метрлы буе тагын да озынаеп киткән шикелле тоелды. Ханәфи аның аракы эчмәгәнен белә. Ләкин элек грамм да капмаган кешеләрнең дә мондый хәсрәтле вакытларында эчүгә сабышканнарын күргәләгәне бар иде аның. Гыйлемхан да түзә алмагандыр, ычкынып киткәндер дип уйлаган иде Ханәфи. Бераз салып, сөйләшеп утырырбыз дип, район кибетеннән бер шешә «күчтәнәч» тә алды.

Ләкин, гаҗәпкә каршы, ул уйлаганча булып чыкмады. Көннәр әле салкын, март башы гына булса да, Гыйлемхан йоннан бәйләгән свитердан гына калып, ишегалларында сарай бурап ята. Ындыр табагыдай киң җилкәсенә ап-ак булып бәс сарган иде. Гадәтенчә сабыр гына елмаеп каршылады Ханәфине. Кул биреп күрештеләр. «Исәнме?», «Исән», — дип хәл сорашып алдылар. Болай да сүзгә әллә ни юмарт булмаган Гыйлемханның Ханәфине өйгә дәшү түгел, ишегалдында да җәелеп китәр чамасы күренми иде. Минем синең белән бүтән сөйләшер сүзем юк дигәндәй, бүрәнәгә каптырып куйган балтасын алды да бүленеп калган эшен дәвам итә башлады.

Кирәге чыкканда җылырак булсын дип, тун кесәсенә тыгып куелган теге нәрсә Ханәфинең күңелен бик хәтәр кымырҗытып торса да, мондый хәлдә үзе башлап ул хакта сүз кушу килешми иде. Чәй эчеп чык дип әйтмәгән Гыйлемхан яныннан Ханәфинең тизрәк китәсе килә, әмма хаксызга кимсетелгән кордашының хәленә кермичә, аңа нindидер юату сүзләре әйтмичә, капыл гына китеп бару да ничектер уңайсыз иде.

— Син алай бик бетеренмә инде, Гыйлемхан, — диде ул, тегенең күңелен табарга тырышып. — Мин бит беләм: синдә гаеп юк. Дөрес итмәделәр сине эшеңнән алып. Хата эшләде Беренче.

— Кызганып, хәлемә кереп кагылуың өчен рәхмәт, Ханәфи. Тик хәзер ул хакта сөйләшеп торудан ни мәгънә?

Шуны гына әйтте дә тагын үз эшен дәвам итте Гыйлемхан. Кайгысын уртаклашырга дип, якын итеп килгән кешегә аның шушылай битарафлыгы бер дә ошамады Ханәфигә: мин-минлегенә сукты. Аның

янына Гыйлемхан өйләренә дәшмәгәнгә күңеленә кереп калган үпкә хисе дә килеп кушылгач, Ханәфинең ачуы ныклап ук кабарып китте. Ул да, үз чиратында тегеңә төрттереп куярга булды:

— Анысы шулай. Әйе, эш үткәч, сөйләп торудан әллә ни фәтвә юк. Ләкин бит, күптән узган хәлне хәтереңә төшерүем өчен гафу ит, мин сиңа моннан дүрт ел элек биргән акыллы киңәшне тотмыйча бик нык ялгыштың син, Гыйлемхан. Исендәдер, укып-укып та, ахырдан эшеңнән алып атсалар, ни кылырсың дигән идем мин сиңа ул чакта. Өч-дүрт ел чиләнеп, техникум бетерүеңнең ни кирәге калды инде менә. Кая барырга, ни эшләргә хәзер ниятең?

— Бүтән кайгың булмаса, минем өчен хәсрәтләнмә, — диде Гыйлемхан, гомерендә булмаганча кискен итеп. — Укыганыма һич үкенмим. Булган белем зыян итмәс. Эше дә бетмәс. Ни тотсам, шуны эшли алам ич мин. Минем бит әти урман каравылчысы булмады. Синең шикелле, әтиемә ияреп, кая барсам, анда кунак булып үскән егет түгел мин. Өч яшемдә атасыз, тугыз яшемдә бөтенләй ятим калып, кем сыендырса — шуңа сыенып, ни кушсалар — шуны эшләп үскән кеше. Шулай булгач...

— Ярар ла инде. Мин бит сине үпкәләтергә дип түгел, якын итеп әйтүем генә. Күпме көч куеп, тәмам бетеп барган колхозны кеше итеп житкергәч кенә урыныңнан чыгарып ташлауларына жаным әрнеп кагылуым. Менә минем колхозга агроном кирәк. Син — агрономия факультетын бетергән кеше. Райкомга барып, Беренче белән шул хакта сөйләшеп карасам, миңа агроном булып күчәргә ризамы дип, ниятеңне белеп китәргә уйлаган идем.

Ханәфигә агроном, чыннан да, кирәк. Ләкин аның Гыйлемханны алырга исәбе юк, чөнки «буялган» кешене эшкә алырга дип йөри башласа, үзе дә шул «буялганнар» исемлегенә эләгәчәген ул бик яхшы аңлый иде. Безгә киләсеңме, дип, Гыйлемхан алдында яхшы атлы булып күренү өчен һәм бүтән акыллырак сүз тапмаганнан гына әйтүе иде.

Ләкин, бар, алдарсың Гыйлемханны!

— Беренчедән, — диде ул, — бу мәсьәлә белән син Беренчегә артыңнан мылтык терәп торсалар да керәчәк түгел. «Гаепле» кешене яклап сүз әйтергә йөрәгең житмәячәк. Чөнки синең үз урындыгың да бик нык түгел: бүген очырып төшерерләрме, иртәгә алып ташларлармы дип, дер калтырап утырасың. Икенчедән, райкомнан рөхсәт ителгән тәкъдирдә дә мин синең белән эшләргә риза булмас идем. Син бит кешеләр белән эшли белмисең. Нәкъ Беренче кебек, тик үзеңне генә яратасың. Тик үзеңне генә акыллы дип санайсың. Ә минем бүтәннәрне дә акыллы дип санап торган житәкче кулы астында эшлисем килә.

Гыйлемханның бу сүзләренә Ханәфи шул тикле гарьләнде, кесәсендәге теге нәрсәгә үрелүдән бик авырлык белән генә тыелып калды һәм:

— Ярар, яхшылыкның кадерен белмисең икән, көт инде алайса шундый заманнар килгәнен! — дип, саубуллашып та тормыйча, капкага юнәлде. Гыйлемхан аның артыннан, гадәтенчә, сабыр гына әйтеп калды:

— Көтәм, Ханәфи, көтәм. Ул заман килергә күп калмады инде. Бушбугазлар чоры үтеп бара, кемнең кем икәнен ни сөйләвенә карап түгел, ни эшләвенә карап билгели башлаячаклар тиздән.

Гыйлемхан шактый дөрес чамалаган булып чыкты. Заман әллә ни нык үзгәрмәсә дә, шул көнге сөйләшүдән ике-өч ай үткәч, районда начальство үзгәрде: узган ел, районның икмәк планын тутыру артыннан куып, фуражга саласы ашлыкны да дәүләткә тапшыртып бетергәнгә, язгы якта колхозларда бик күп маллар ачтан кырылгач, аннары килеп район язгы чәчүне дә вакытында башкарып чыга алмау сәбәпле, Беренче секретарьны эшеннән бушаттылар да моңарчы икенче секретарь булып эшләгән Мансур Сабировичны Беренче итеп куйдылар.

Электән белгән кешесе булгач, Ханәфи бу хәлгә бик нык куанган иде. Ләкин куанычы коры куаныч кына булып чыкты. Әлеге шул Ман-

сур Сабирович Беренче булып эшли башлаганга ел да үтмәде — Ханәфине колхоз председателе урындыгыннан шудырдылар. Аның әле иң гаҗәбе шул: моны Мансур Сабирович шәхсән үзе шулай эшләде. Колхоз председателе булып калмаячагын сизенгәч, Ханәфи, аның янына барып:

— Ничек була соң инде бу, Сез бит мине күптәннән беләсез? Мин бит әле үземне күрсәтергә дә... — дип үпкә белдерә башлаган иде, тыңлап тормады теге.

— Нәкъ менә күптәннән белгәнгә күрә дә ул эштән азат итәргә булдык без сине. Безнең заманда биш ел вакыт — күп гомер ул. Үзен күрсәтергә теләгән кешегә күрсәтергә була иде бу вакыт эчендә. Шул биш елда бүтән председательләр иң артка калган колхозларны да алдынгылар рәтенә күтәрделәр. Ә син иң алдынгы колхозны таркатып бетерә яздың. Без сиңа эшли башлавыңның беренче елыннан әйтә килдек. Ләкин тиешле нәтиҗә ясамадың. Шулай булгач, үзеңә үпкәлә. Моңарчы түзеп торганыбызга рәхмәт әйт тә, эшеңнән азат итүләрен сорап, колхозчыларның гомуми җыелышы исеменә гариза яз! — диде.

Гади колхозчы булып калсам, нишләрмен дип коты алынган иде Ханәфинең. Ләкин Мансур Сабирович миһербанлы кеше, этеп екмады. Эшсез калуына ай да үтмәде, Ханәфине авыл советы председателе итеп куйдылар.

Ә менә Гыйлемханның эшләре Ханәфинең уена да килмәгәнчә булып китте. Чирмешәнгә әле председатель куя алганнары юк, чөнки авыл халкы аны председательлектән төшерүгә риза түгел, шуңа күрә Чирмешәннең үзеннән бераү дә аның урынына утырырга теләми, ә читтән кеше китерүгә чирмешәннекеләр үзләре каршы иде. Председатель вазифасын вакытлыча партоешма секретаре үтәп килә, ләкин, башка яктан уңган кеше булса да, бу эшкә аның сәләте дә чамалы, теләге бөтенләй дә юк. Менә шул кеше, Мансур Сабирович Беренче булып эшли башлаганга атна-ун көн үтү белән, райкомга барган да әйткән:

— Гыйльметдинов Гыйлемханны бары тик эллекке Беренчегә ошамаган өчен генә эшеннән алганнарын сез беләсез, Мансур Сабирович. Эшен ул белә һәм ярата. Халык та хөрмәт итә аны. Дәүләткә дә бик кирәк андый кадрлар. Шулай булгач, әйдәгез, Гыйльметдиновны яңадан үз урынына куйыйк. Бер дә шикләнмичә әйтәм, ул сезнең йөзгә кызыллык китермәячәк. Тагын да тырышыбрак эшләячәк. Халык та канәгать булачак.

Ай ярым дигәндә, яңадан председатель итеп куйдылар Гыйлемханны. Ул тагын канатланып эшли башлады. Техникум белән генә канәгатьләнеп калмыйча, читтән торып институт тәмамлады. Шул ук вакытта колхозы да елдан-ел алга барды.

Ханәфи аның бу уңышларына башта артык исе китмичә, очраклы хәл, бәхетенә шулай туры килеп тора дип карый иде. «Әйдә, тырыш-тырыш, ләкин син дә әллә кая китә алмассың. Бер дә бер көнне теге чактагы шикелле шалт иттереп урыныңнан чөеп атканнан соң, үзең дә аңларсың. Нигә шул кадәр ахмак булып, җан-фәрман тырышып йөргән булдым икән дип, үкенеп бетә алмассың әле», — дип, астыртын гына Гыйлемханнан көлеп һәм шулай булуын көтеп йөргән иде Ханәфи. Шулай булган тәкъдирдә икенче көнне үк аның өенә барып: «Әйткән идемме мин сиңа, колхоз дип ул кадәр үк тырышма, үзеңне үзең бетермә, дип. Менә, күрдеңме инде, ни эшләттеләр?» — дип, күзенә терәп әйтеп, тегенең ачуын чыгарып, үзенең күңелен тынычландырып кайтмакчы иде...

Ул көннәрдән бирле инде чирек гасыр гомер үтте. Ләкин Ханәфи теләгәнчә булганы юк әле. Булыр төсле дә күренми. Чөнки Гыйлемхан әле дә председатель урындыгында нык утыра. Колхозчылары алдында да, дәүләт алдында да кадер-хөрмәттә йөри. Орденнары гына да дүртәү инде...

## 16

Ярый әле алтмышка җиткән кешеләрдән: «Җавап бир, кеше: шушы яшеңә җитеп, халкыңа, илеңә, гаиләңә нинди яхшылыклар эшләдең? Үзеңнән соңгы буыннарга сине сагынып искә алырлык нинди мирас калдырып китәсең?» — дип сорау алу юк. Әгәр шулай булса, Ханәфи ише бәндәләр оятларыннан кая керер тишек таба алмас иде...

Ә ул сорауларга җавап бирүне гамәлгә кертү һәм җавапны алтмыштагылардан түгел, бәлки адәм баласы илле яшькә җиткәч бирдертүне мәҗбүри итеп кую начар булмас иде. Илле яшьтә инде кемнең нәрсәгә сәләтле икәне ачыкланган: адәм баласы кулыннан килердәй эшләрнең күбесен эшләгән була. Шул ук вакытта яшьлектә җибәргән хаталарын төзәтергә һәм, гомумән, киләчәктә акыллырак эш итәргә кимендә тагын ун ел вакыты кала аның. Ун ел вакыт — үзе бер гомер ул. Зур максат куеп, ныклап торып тотынган кеше ун ел эчендә бөтен дөньяга мәгълүм булырлык эшләр эшли ала. Әгәр шундый имтихан сыман бер нәрсә кертелсә, адәм балалары үз гомерләрен мәгънәлерәк, оятка калмаслыграк итеп үткәрергә тырышырлар иде шикелле. Һәр хәлдә шулай тоела миңа хәзер Ханәфигә.

Анысы шулаен шулай да, ләкин кылган гамәлләре, эшләнмәгән эшләре, тормышка ашмаган ниятләре өчен җаваплылыкны адәм баласының бирүзенә (бу очракта, мәсәлән, Ханәфигә) кайтарып калдыру да бик үк дөрес булмас иде. Аның менә шушы аяныч хәлгә калуына башкаларның, атап әйткәндә, начальствоның да өлеше зур булды лабаса. Колхоз председателе чагында Ханәфинең күңеле эштә түгел, җил-далада булуын, атнасына җиде көн сәрхүш булып йөргәнен күреп тормадымыни алар? Ләкин ни эшләделәр, нинди чара күрделәр Ханәфине менә шушы хәлгә төшүдән саклап калу өчен? Бар «чаралары» шул булды: Ханәфинең һәр яктан бозыла баруын бик яхшы күреп-белеп торсалар да, дүрт ел буе берни әйтмичә, күрмәмешкә сабышып килделәр. Ни өчен шулай булды? Чөнки ул чорда алар үзләре дә хәмер дигән нәрсәне яраталар иде. Диңгез баштан болгана, ди. Ул чорда Беренче булып эшләгән иптәш кайчан күрсәң дә мәрҗән шикелле кып-кызыл булып йөри торган иде. Вакыты иркенрәк булып, табигать кочагында «ял итеп» утырган чакларында исә тәмам туарылып китә дә аннары икешәр-өчәр көн махмырлап ята иде. Теләсә кем белән алай түгел, әлбәттә. Үзенә тугрылыклы, ышанычлы кешеләр белән булганда. Ә Ханәфи аның иң ышанычлы кешеләреннән иде. Беренче шашлык яратканны белә, килгән чакларында, уттай кызу эш өсте булса да, һәйбәтләп шашлык белән сыйламыйча җибәрми иде...

Ләкин Ханәфинең менә шушы бүгенге хәлгә калуына бер ул гына гаепле түгел. Мансур Сабировичка да үпкәсе бар Ханәфинең. Беренче секретарь булып утыру белән Ханәфине председательлектән төшерүен төшерде, ләкин авыл советы председателе итеп куйдыртты бит ул аны. Кәҗәне кәбестә бакчасына кертеп җибәрү белән бер булды бу. Ни өчен дигәндә, авыл советы председетеленә хезмәт хакын акчалата һәм ай саен түләп баралар. Аты, тарантасы үз кулында. Ә эше, җаваплылыгы колхоз председателенеке белән чагыштырганда, бик күпкә аз. Аның бит әле ярдәмчесе — авыл советы секретаре да бар. Көндәлек эшләрне ул алып бара. Председательгә атнага бер-ике тапкыр кереп, күренеп китсә — бик җиткән. Авыл советына ун көнгә бер генә килгән чаклары да була иде Ханәфинең, анда да эше тукталып калмый, тавыш-тын чыгаручы юк иде. Председатель председатель инде ул. Теләмәсәләр дә, аның белән исәпләшми мөмкин түгел. Кемгә барып керсә дә ипи-тоз, якты йөз белән каршы алалар. Ым гына как — шешәсен дә чыгарып утырталар.

Әнә шул җиңел эш һәм рәхәт тормышның да зыяны күп булды Ханәфигә. Әгәр Мансур Сабирович Ханәфине колхоз председательлеген-

нән төшергән чагында чын коммунистларча принципиальлек белән әйтсә: «Безгә үпкәләрлегең юк, Хәйретдинов: без синә үзеңнең сәләтеңне күрсәтергә мөмкинлеген дә, вакытын да җитәрлек бирдек. Ләкин син ышанычны аклый алмадың: юньле җитәкче чыкмады синнән. И һәм чыкмаячак та!» — дисә һәм аны гади колхозчы итеп кенә калдырсалар, халык өчен дә, Ханәфинең үзе өчен дә йөз тапкыр әйбәтрәк булган булыр иде.

Сүз дә юк, болай иткәндә, Ханәфигә башта бик кыен булыр: мине аңламадылар, урынсызга җәберләделәр дип, барысына да үпкәләп, ачу тотып йөрер иде. Ләкин үпкәсе озакка бармас, үтәр иде әле. Чөнки ул чакта Ханәфи нибары утыз өчтә — мөгезеннән каерып, үгезне егар чагы иде. Рядовой колхозчы булып калу башта аңа түбәнлек булып тоелса да, тора-бара анысына да күнегер, ул да бүтәннәрдән ким эшләмәс иде. Аның шикелләләр эшләделәр бит. Әнә, дүрт ел бер парта арасында Ханәфи белән бергә утырып укыган Фәрзетдинне генә ал. Бишенче класска барып та тормады. Абыйсына ияреп, унөч яшеннән атлы эштә эшли башлады. Аннары тракторга утырды. Инде алтмышка җитеп килә, һаман шул эшендә эшли. Кирәк чакта комбайнын да, машинасын да йөртә. Әле һаман көчле-куәтле, яшьләргә алыштыргысыз.

Әйе, ялгышты ул чакта Мансур Сабирович Ханәфине авыл советы председателе итеп куйдырып. Гомерлек зур зыян ясады Ханәфигә...

Карап торышка әллә ни төшемле урын күренмәсә дә, файдалана белгән кешегә авыл советы председателенең мөмкинлекләре шактый аның. Колхозда эш барышы өчен конкрет җавап бирәсе булмаса да, колхоз тормышына кагылышлы һәр нәрсәгә катнашырга аның тулы хокукы бар. Чөнки ул, бердән, колхоз идарәсе члены. Икенчедән, авылда совет властен гәүдәләндерүче кеше. Башка вәкаләтләре хакында әйткән дә юк, аның хәтта хуҗа хатыннарның кер юган суны кая түгүенә тикле тикшереп-белеп торырга кирәк дип тапса, ул суны да үзе кушкан урынга гына түктерергә хакы бар. Келәт яки гараж төзиме авыл агае, алар өчен дә иң элек ул авыл советы председателеннән рөхсәт алырга тиеш. Авыл халкыннан берәрсенә белешмә-мазар кирәк булмый калган көннәр, ай-һай, ел тәүлегенә ничәү генә була икән? Тормыш бит ул: кайсы туа, кайсы үлә, кайсына паспорт алырга, кайсына базарга ит-май сата барырга, кайсына пенсия юлларга белешмә кирәк булып кына тора. Укырга җыенсалар да, өйләнешсәләр яки аерылышсалар да авыл советыннан башка беркая бара алмыйлар. Ягарларына утын, өй салырга бүрәнә, түбәләрен ябарга шифер кирәк булганнары — шулай ук авыл советына килергә мәҗбүр. Мал-туарына бер-бер хәл булса яки анда йорты янып китсә дә, страхование акчасын алыр өчен, эшне иң элек авыл советыннан башларга кирәк авыл кешесенә. Әлбәттә, йомыш белән килүчеләрнең үтенечен күп очракта авыл советы секретаре үзе генә дә хәл итеп җибәрә алыр иде. Ләкин Ханәфи тарафыннан шулай куелган — секретарь аннан башка бер генә белешмә дә бирә алмый. Ни өчен шулай куйган моны Ханәфи? Шуның өчен шулай куйган, моның белән ул, беренчедән, колхоз председателе булган вакытында бик нык төшкән авторитетын күтәрмәкче, икенчедән...

Халык бит ул кемнең кем икәнен, кайдан ничек эш итәргә кирәген бик тиз чамалап ала. Печән-утын алып кайтырга, тегермәнгә барырга ат сорап килгән вакытларында Ханәфи иң элек колхозчыларның «кесә»сенә карарга яратканны Куралык халкы инде күптән, ул колхоз председателе булган вакыттан ук белә иде. Авыл советы председателе булып эшли башлагач та ташламады ул гадәтен. Сүз дә юк, хәзерге заманда Ханәфи алай иркен кылана алмас, урыныннан бик тиз чөеп ыргытырлар иде. Әмма ул елларда барысы да бата иде. Ул чорда халык та хәзерге шикелле вак түгел: һәр нәрсәне гадел итеп, законга туры китереп эшләгәнне таләп итеп, төпченеп йөрми, ни әйтсәң — шуңа риза, ни кушсаң — шуны эшли торган иде. Ханәфинең менә

шушы бүгенге кызганыч хәлдә калуында халыкның да гаебе зур. Әгәр ул халык, үз хокукын белеп, үзенә кирәк нәрсәләрне майлаусыз-җайлаусыз гына таләп иткән булса, Ханәфи алай ук йөгәнсезләнеп йөри алыр идемени? Көн саен кияү егете урынына сыйлап, куштанланып, халык үзе бозды аны!..

Ә бер бозылгач тыелу кыен иде инде. Тора-бара эшләр шуңа килеп җитте, берәрсе дәшеп салдырмый калган көннәрдә Ханәфи халыкның зиратка койма тотарга дип җыйган акчасына хәтле эчә башлады. Соңыннан әнә шул нәрсәнең исе чыгып, эшләр чак кына зурга китмичә калды...

«Бу бәладән хәвеф-хәтәрсез котылсам, бүтән андый эшкә якын да бармас идем»,— дип антлар эчкән иде ул чакта Ханәфи. Бөкрене кабер генә турайта, дип белмичә әйтмәгәннәр шул — күп тә үтмәде, тагын шул халык өстеннән сыйланып йөрү юлына басты Ханәфи. Шулай да бу юлы инде саграк, як-ягына каранып эш итте һәм җитмеш алтынчы елга кадәр авыл советы председателе булып утырды әле ул.



## 17

Хатын-кыз кавеменә дә үпкәсе бик зур Ханәфинең. Ходайның һәр бирмеш көнендә салып, сәрхүшләнеп йөргән кешенең башына ни килмәс. Андый чакта ир-атның күңеле хатын-кыз ягына каерылу әллә кайчаннан билгеле нәрсә. Ханәфи алла бозавы түгел ләбаса. Аның да жаны бар, ул да шул тубал башларга тартыла иде. Ә алар Ханәфигә караңгы чырай күрсәтми генә түгел, киресенчә, үзләре дәшеп торалар иде. Әгәр үз дәрәҗәләрен белеп, хатын-кыз горурлыкларын саклап, катыраккырысрак торсалар, алай ук иркен кылана алыр идемени ул?! Юк, ни генә димә, күп булды ул чәчбикәләрнең Ханәфигә зыяны, бик күп булды. Аның илле дүрт яшьтән менә шулай корышып калуына иң элек әнә шулар сәбәпче булмады микән әле?

Югыйсә илле дүрт яшь — ир-атның самый өлгереп-ныгып җиткән чагы. Ханәфидән олыраклары да бүген умыртып эшләп йөриләр әле. Әнә, Ханәфиләргә ике өй аркылы Хисами картны гына ал. Сиксән икенче яше белән бара. Моннан өч ел элек, җитмеш тугыз яшендә чакта, хатыны Бәдерниса карчык үлеп киткәч, ике-өч ай да үтмәде, алтмышка якынлашып килгән малае Мөбинне:

— Гел болай ялгыз яшәп булмас, улым. Кырык бишләр-илләләр тирәсендәге ару гына бер тол хатын кирәгие бит,— дип тыкырдата башлаган.

— Сиксәнгә җиткәч нинди өйләнү инде ул, мәшәкать арттырып. Әнә, намазыңны укы да, тыныч кына тик ят инде! — дип каршы килеп тә караган Мөбине.

Карт барыбер үз дигәнен итте: Гобәй авылыннан илле бер яшьлек чибәр генә, тыйнак кына, тупырдап торган тол хатын алып кайтты. Шуннан бирле яшь килен белән яшь кияү шикелле, чөкердәшеп яшәп яталар. Хисаметдин карт әле һаман яшьләреннән болайрак итеп колхоз эшен эшли: трактор, машина арбаларына яңа әрҗәләр, яңа салынган йортларга тәрәзә наличниклары ясарга ни Кече Елгада, ни Куралыкта аннан оста кеше юк. Ә хатынын шул тикле ярата, хәтта колхоз эшендә эшләтми дә. Тегесе пенсиягә тикле генә эшлим инде дип әйтеп караган икән дә, монысы риза булмаган: «Ярар, Гөлзәйдә матурым, ватылып йөрмә. Моңарчы ватылганың да җиткән: утыз ике ел рәттән сыер саву шүтке түгел ул сиңа. Курыкма, яшең җиткәч, пенсиясен дә бирерләр. Аңарчы сине туйдырырлык кына эшлим мин. Аннары кенәгәм дә бөтенләй үк буш түгел: унҗиде мең тәңкә акчам бар кассыда. Синең белән минем гомергә генә аныеы да җитә аның»,— дип әйткән ди.

Дөрестер: алдаша торган карт түгел ул. Гомерендә бер тамчы хәмер капканы, бер төрем тәмәке тартканы булмады. Гомере буена ат урынына эшләп килде. Колхоз эше белән генә чикләнми, авыл халкына тәрәзә рамнары ясап, сарай-мунчалар да бурап бирә әле ул. Куралыктагы һәркайсы үзенчә бизәкләп ясалган тәрәзә наличниклары — шулай ук аның эше. Шуңа колхоз житәкчеләре дә, халык та бик хөрмәт итәләр үзен.

Әйбәтләп бер ял итеп кайт дип, узган кыш председатель Нургазиз Казан тирәсендәге «Крутушка»га хатыны белән икесен ял йортына җибәргән иде. Аның урынында бүтән берәү булса: «Вәт, малай, бар икән ул дөньяның җәннәт урыннары: иртүк торып эшкә чыгасы юк, мал-туар карыйсы, ишегалларын җыештырасы, утын кисәсе юк. Ашыйсың да йоклыйсың, йоклыйсың да ашыйсың. Көн саен киносын күрсәтеп торалар. Биергә теләгән кешегә көн саен танцысы бар»,— дип мактап туя алмас иде. Ә бу кайтып килешли үк председатель янына кергән дә: «Нинди ачуың барые, олан, миндә? — ди икән тегеңә.— Ни дип андый ялкаулар йортына җибәрдең син мине? Барып, ике көн тору белән, эшсезлектән тәмам алҗып, ярый әле дум уддыхның башлыгы янына кердем: «Мин, энем, болай эшсез ятарга өйрәнмәгән. Давай, берәр эш тап миңа! Ишек төбенә төнге каравылчы итеп булса да куй! Миңа акчасы кирәк түгел, миңа тик кешеләргә файда китерә торган эше генә булсын,— дим.— Әгәр берәр эш тапмыйсың икән, иртәгә үк хатынны ияртәм дә кайтып китәм»,— мин әйтәм. Шулай дигәч, хәлне аңлады теге: ишегалды җыештыручылары ялга киткән булган икән, шуның урынына куйды бу мине. Шундагы эш белән юанып кына кайтыр көнебез җиткәнче түзеп тордым. Кара аны, мине бүтән андый эшсез ята торган җиргә җибәрәсе булма!» — ди икән.

Менә сиңа сиксән яшьлек карт!..

Ә Ханәфи, эш эшлисе урында әтәчләнеп йөреп, яшь башыннан менә шушылай картаеп калды. Хатын-кызлар янына бара алмавына алтынчы ел китте инде...

Хатын-кыз димәктән, ул тубал башларны да әйтерең бармы! Бер Мәрфуга дигәне генә дә ярты картайтты Ханәфине. Шул сихер капчыгы ымсындырып-тартып тормаган булса, семьясын ук ташлауга барып җитәсе кеше түгел иде ул. Шул Мәрфуга миңгерәйтте аны.

Бөгәлчән шикелле нечкә билле, тоныкзәңгәр күзле, әле утызы тулмаса да, ике рәт кияүдә булып кайткан, сары гына, чибәр генә, читтән (Чүпрәле якларыннан) килеп чыккан бер нәрсә иде ул. Ханәфинең авыл советы председателе чагы, ә теге хатын клуб мөдире булып килгән иде.

Иптәш булырсың дип, фатир кертергә теләүче ялгыз карчыклар булса да, алар янына кермичә, буш тора торган бер өйдә ялгызы гына яши иде ул хатын. Кайчан килеп керсәң дә йөзе якты, сүзе татлы, сые әзер була иде. Башта Ханәфи аның янына болай гына, ничек яши икәнен белергә дип кенә кергән иде. Ләкин...

Күрәчәк күз йомдыра дигәннәре шулдыр инде: ул хатынның кояштай балкыган йөзен һәм бар җире дә искиткеч төгәл итеп яратылган сылу тәүдәсен күргәч, үзенең кем икәнен онытып, кыз катына беренче кат килгән егеттәй, каушап калды Ханәфи. Ул шулай аңгыраеп торган арада: «Ой, Ханәфи Хәйретдинович, изге кеше икәнсез сез! Мин сезне үзем чакырырга бик теләсәм дә, кыенсынып тора идем. Ә сез менә үзегез килеп кердегез. Бүген минем туган көнем бит!» — дип сөйләнәсөйләнә, күз ачып йомганчы табын әзерләп, өстәл уртасына өч йолдызлы нәрсәкәй китереп утыртты. Шуннан соң гына азрак һушына килеп, түргә үтте Ханәфи, хәл-әхвәл сораштыра башлады. Инде болай да матур гына «капкан» өстенә тегенең коньягын да берәр йөз грамм салып куйгач, теле бөтенләй үк ачылып китте. Мәрфуга аңа кырык хур кызының берсе, аның да иң сылуы булып күренә, ә ул үзе шул хур кызының колы булырга әзер иде инде...

Шуннан китте инде эшләр. Берәр төрле күрсәтмә бирергә кергән атлы булып, Ханәфи ул хатын янына көн саен диярлек кереп йөри башлады. Яңгыр яки кар явуны сылтау итеп, яки җыелыш булган иде дә бик озакка барды дигән булып, Куралыкка кайтмыйча калган көннәре дә була иде. Тора-бара Мәрфуга аны шундый итеп үз мохитенә бөтереп алып кереп китте ки, шул Мәрфуганы ешрак күрер өчен, хәтта законлы хатыны Хәлимәсен ташлап, Кече елгада фатир торып яши башлады Ханәфи.

Ләкин авыл советы председателе булгач, эше төшкәләп тора: Куралыкка кайткалап йөрергә дә туры килә. Шул чакларда өйләренә дә кагылып, ашап-эчеп чыга. Сирәк-мирәк кунгалап та кала. Әмма ни Хәлимәгә, ни малае Хәсәнгә һичнинди ярдәм итми иде.

Хәлимә аның Мәрфуга белән чуалганын инде күптән белә, әмма бәйләнеп интектерми. Тик бер тапкыр гына: «Мине дә, малаеңны да оятка калдырып, кәҗә тәкәсе шикелле өйдән-өйгә йөргәнең өчен гомер буе рәхәт күрмәсәң иде»,— дип каргый-каргый елады да шуның белән тынды. Кергән чакларында Ханәфине ашата-эчертә. Кунарга калганда үзенә аерым урын җәеп бирә. Шуннан башка якынлык юк. Ул бичара Ханәфинең әнә шулай сирәк-мирәк кергәләп йөрүенә дә риза булып, тавышсыз-тынсыз гына яши иде. Аңа Ханәфине катырак тотарга, яхшылык белән игә китерә алмаса, хәтта райкомга ук барып җитәргә кирәк булгандыр. Шулай иткән булса, мөгаен Ханәфи акылына килер, өйләренә кайтып, матур гына тора башлар иде. Тик Хәлимә беркая бармады һәм шуның белән зур хата эшләде: Кече Елгада торуына Хәлимә әллә ни сүз әйтмәгәч, өстеннән жалоба белән йөрмәгәч, Ханәфи артыгын иркенәеп китте һәм Мәрфугага йортка кереп, ачыктан-ачык аның янында тора башлады.

Болай да бик каты кайгырып, эчтән сызып йөргән Хәлимәнең шуннан соң түземе шартлады. Беркөнне Куралыкка кайткач, Ханәфи хуҗаларча бик ышанычлы атлап өйләренә кереп килә иде, кай арада күреп алгандыр, Хәлимә аның каршына өйалдына чыкты да ишеккә аркылы басты:

— Юк, Ханәфетдин, кермисең!

Бу хәл Ханәфи өчен шул тикле көтелмәгән булды, башта ул телсез-өнсез калды. Хәлимәнең йөзе шулкадәр җитди, әйткәннән кайтмаячагы аермачык күренеп тора иде. Тик Ханәфинең моңа ышанасы килмәде: болай гына, хатын-кыз гадәте буенча, формасы килсен өчен генә кәҗәләнергә булгандыр, үтәр, җайланыр дип уйлады:

— Я, я, шаярма әле! — дигән булды ул, мәсьәләне уенга алырга теләп.— Әйдә, өйгә керик әле. Сөйләшәсе сүз бар.

Селкенеп тә карамады Хәлимә.

— Ә минем синең белән сөйләшер сүзем юк!

— Ну бит минем үз өемә керергә хакым бардыр! — дип Ханәфи тегенең кулы астыннан иелеп үтеп китмәкче иде, Хәлимә Ханәфине ишек яныннан этеп үк җибәрде. Ишекне шартлатып ябып, эчтән бикләде дә:

— Колагыңа киртләп куй, «җегет»: менә шушы минуттан алып, синең бу йортта эзең дә булырга тиеш түгел! — диде.

«Ярый, мин дә сиңа бик алай ялынып йөрмәм! Кертмисең икән — үзеңә үпкәләрсең!» — димәкче булып, Ханәфи ишегалды як тәрәзәгә килгән иде, сүзен әйтә алмыйча, тотлыгып калды: малае Хәсән шундый моңсу итеп, шундый нәүмизләнеп әлеге шул ишегалды як тәрәзәсеннән карап тора, аны күрсә, хәтта таш йөрәкле кеше дә битараф кала алмас иде. Йөрәге чәнчеп, тәннәре чымырдап куйды Ханәфинең.

— Әниең кертми бит, улым. Чык әле минем янга! — диде ул, үзен гаепсез итеп күрсәтергә тырышып.

«Ни булды, әнием, нигә кертмисең әтине»,— дигән шикелле итеп, Хәсән, борылып, әнисенә карап алды. Ул арада Хәлимә өстәл җыештырырга тотынган иде — малаеның карашын күрмәде. Тәрәз төбеннән ялт кына сикереп төшеп, Хәсән әнисенең итәгенә барып сарылды:

— Керт инде, энием, этине!

Бик авыр минутлар иде бу Ханәфи өчен. Хәлимәгә дә җиңел түгел иде булса кирәк: аның хәтта күзләре дә яшьләнгән иде. Шуны Ханәфигә күрсәтмәс өчен, Хәлимә малайны җитәкләде дә, аркасыннан сөя-сөя, кече якка кереп китте.

Бәлки җайланыр, малай сүзен тыңлап булса да, ачар ишекне дип, Ханәфи шактый гомер тәрәз буенда көтеп торды. Әмма ишек ачылмады. Шуңа бик гарьләнде Ханәфи. Җен ачуы белән:

— Ярый әле ачмадың: барыбер керми идем! Моннан ары бу йортта минем эзем дә булмаячак дип әйтергә генә килгән идем мин! — диде дә Кече Елгага Мәрфуга янына китеп барды...

## 18

Сүзендә торды Ханәфи: авыл советыннан чыгарылып, үз авыллары Куралыкка бригадир булып кайтканчы, шушы йортның бусагасын атлап кергәне булмады. Керергә теләмәүдән түгел. Хәсәнен алдына утыртып сөяргә теләгән чаклары күп булды аның. Хәлимә пешергән ашларны ашыйсы килгән вакытлары да күп булды. Ләкин ул боларның берсен дә эшли алмый, чөнки Мәрфуга аны бик каты тота иде. Ханәфи авыл советы эше белән Куралыкка барасы булганда, бауга таккан шикелле, аңа ияреп килә һәм, адым да калмыйча, артыннан йөри. Шул кадәр нык көнче, Ханәфигә Хәлимәне күреп сөйләшергә түгел, хәтта улы Хәсән янына барырга да ирек бирми иде.

Ә үзенең таза ир-ат күрсә, күзләре майлана. Бигрәк тә районнан килгән башлыклар алдында чытлыкланырга ярата иде. Шул тикле ярарга тырыша аларга, йөреш-торышлары гына түгел, хәтта тавышларына кадәр үзгәрә. Ә тегеләргә аның шул кыланышы нигәдер бик ошый: бер тиенлек эшләре булмаса да, Кече Елгага сугылып китәргә тырышалар иде. Мәрфуга алар килгәнгә һәрвакыт шат. Ханәфи өйдә булмаган чакларда да аларны бик теләп кабул итә, кунак итеп, әйбәтләп сыйлап җибәрә. Алар белән үзе дә сыйлана торган иде...

Билгеле, Ханәфинең моңа ачуы килә: «Син миңа законлы хатыным белән законлы малаемны күреп сөйләшергә дә рөхсәт итмисең. Булды. Җитте. Икенең берсен сайла: я мин өйдә юкта моннан ары беркемне кертмичә, минем белән юньле генә итеп яши башлыйсың, яки мин үземнең улым белән хатыным янына кайтып китәм!» — дип мәсьәләне кабыргасы белән куярга теләгән чаклары да булгалады Ханәфинең. Ләкин Мәрфуганың әллә нинди явызлыклар китереп чыгаруыннан куркып, берни белмәгән, берни күрмәгән атлы кыланырга туры килә иде.

Мәрфуга белән ачыктан-ачык бергә тора башлауларына бишенче ай киткәндә, ул хатын Ханәфигә бер малай «алып кайтты». Ханәфидән булгандырмы ул бала, башка берәүдәнме — анысын бер алла белә. Әмма шунысы хак: малай, әнисенә охшап, гаҗәеп дәрәҗәдә тере булды. Ай үсәсен көн үсте. Малайларга, гадәттә, тел ике яшь тулганда гына чыга. Ә бу яшь тә ике айлык чагында ук чытырдатып сөйләшә башлады. Аннары бик зиһенле дә: күргән-ишеткәнен шундук отып ала. Дүрт яшькә житкәндә, олы кеше акыллары бар иде ул малайда. Аның шул зирәклегеннән Мәрфуга бик оста файдалана: Ханәфи Куралыкка барган чакта, аңа күз-колак булу өчен, малайны ияртеп җибәрә торган булды. Ә малай әнисенә караганда да көнчелрәк: этием дә этием дип кенә тора, һәм, чабуга таккан шикелле, ияреп йөри.

Әнә шул чакларда Куралык урамында малайлар белән уйнап йөргән Хәсән дә күрә иде боларны. Күреп ала да, бер сүз дә эндәшмичә, читтән генә карап тора. Ә иптәш малайларының теле тик тормый: «Хәсән, Хәсән, әнә, этиең кайткан бит. Энеңне дә алып кайткан! Ни карап торасың, бар инде тизрәк яннарына!» — дип көлешәләр.

Хәсәннең үзенең дә Ханәфи янына килеп, «әти» дип сыенасы килгәне әллә кайдан күренеп тора. Ләкин ул Мәрфуга малае Шәрәфи шикелле кыю түгел. Хәлимәгә охшаган: хисләрен ачыктан-ачык белдерми. Кызарып-уңайсызланып, шул ук вакытта Ханәфи килеп башыннан сыйпамасмы дип өметләнеп, сабыр гына карап тора. Ханәфи моны бик яхшы сизә. Аның үзенең дә Хәсәнне кочагына алып, туйганчы бер сөясе килеп, бәгырьләре өзгәләнеп куя. Әмма ул моны эшли алмый. һәй, кая ул синдә куенга алып сөю! Хәсәнгә шулай ерактан карап торган өчен дә көнләшә Шәрәфи. Шундук: «Син нигә ул малайга карыйсың? Карама аңа. Миңа гына карап тор. Мине генә ярат. Әйдә, кайтыйк инде Әни озак тормаска кушты!» — дип, Кече Елгага сөйри башлый.

Шунын кыланышларын күрәсе килмичә булса кирәк, соңга таба Ханәфи Куралыкка кайткан чакларда Хәсән аңа күренмәскә тырыша: кара-каршы очрашырга туры килгәндә я берәрсенең ишегалдына кереп, яки башка берәр җиргә посып кала иде.

Ә гомер сизелмичә генә үтә торды. Көтмәгәндә генә Ханәфине авыл советыннан да шудырдылар. Тик бу юлы да этеп җыкмадылар, Куралыкка бригадир итеп куйдылар. Ханәфигә хәзер, теләсә-теләмәсә дә, көн саен Куралыкка барып йөрергә туры килә. Әмма ул, Хәлимә белән тагын бер тапкыр әйбәтләп сөйләшеп карарга нияте булса да, Мәрфугадан куркып, анда керми, төшке ашны Нурмыйларда ашый да кичкә Кече Елгага кайтып китә иде. Инде Хәсән дә егет булып житкән: эти килеп, башымнан сыйпармы дип, күз нурларын түгеп Ханәфигә карап тормый, киресенчә, аның янына Ханәфи үзе барырга теләгәндә дә, күрмәмешкә-ишетмәмешкә салышып, читкә китеп бара торган иде.

Бригадир гына булып калгач, авыл халкы да Ханәфи белән бик алай исәпләшми башлады. Ул кушкан эшкә барасылары килсә — баралар, барасылары килмәсә — юк. Ә авыз ачып сүз әйтә башласаң, җаваплары әзер: «Бик кирәк икән, үзең барып эшлә. Югыйсә, шушы яшеңә җитеп, эшкә кул тидереп караганың юк. Гомер буе кешегә акыл өйрәтеп, күрсәтмә биреп йөрисең!» — дип кенә җибәрәләр. Әйтерсең, барысы да алдан сүз берләшеп куйганнар.

Элекке еллар түгел, усаллык белән берни эшләтеп булмый тегеләрне. Йон уңаеннан сыпырып кына торырга туры килә. Ә бу нәрсә гарьләндерә, мин-минлегенә тия Ханәфинең. Шундый вакытлары була — барысына төкереп, авылдан бөтенләй китеп барыр чиккә җитә торган иде.

Хәзер, менә шул хакта уйлап утыргач, күренә: чыннан да, каядыр китәсе булган ич... Чөнки ул чакта аңа әле илле дә тулмаган, әле сау-таза, авыруның ни икәнен дә белми иде. Тәвәккәлләп, КамАЗга яки башка берәр шундый төзелешкә китеп барса, ул менә шушы бүгенге мескен хәлгә калмас иде. Белеме, һөнәре булмагач, дөрес, анда алай зур начальник була алмас иде алуын. Начальниклар Ханәфидән башка да җитәрлектер анда. Шулай да заманында райком аппаратында эшләгән кеше, бөтенләй үк рядовой эшче булып йөрмәс, һич югы берәр тулай торакка комендант булып урнашыр иде әле. Әгәр инде салуын ташлый алмаса, азык-төлек кибетенә товар бушатучы булып керер иде дә шунда әкрен генә эшләп, чамасын белеп кенә салгалап йөрер, көне төре кешеләр арасында үтәр иде. Ничек тә бүгенгедән начар булмас иде әле... Ә ул, ахмак баш, шул чакта тәвәккәлли алмады. Ә менә Мәрфуга...

## 19

Шуны гына көтеп торган диярсең, Ханәфине председательлектән төшереп, бригадир итеп калдыргач, аңарчы да инде бик нык явызланган Мәрфуга бөтенләй санга сукмый башлады аны. Нәрсә тели —

шуны эшли, кая тели — шунда бара. Казанга дип чыгып китеп тә атналап-атналап югалып тора. Районга китеп тә икешәр-өчәр көн торып кайта. Өйдә чагында да Ханәфигә бәйләнергә сәбәп эзләп кенә йөри иде. Ханәфи эштән кайтырга аш-су әзерләп кую, кием-салымнарын юу дигән нәрсәләр дә онытылды. Әйтә башласаң: «Кирәк икән, әнә, пешер дә аша үзең!» — дип кенә җавап бирә.

Ә бервакыт, туган-тумачаларымны күптән күргәнем юк, дип туган ягына китеп барган җиреннән әзмәвердәй бер ир-ат ияртеп кайтты бу. Кайтты да, күзен дә йоммыйча: «Таныш булыгыз, Ханәфетдин абзый. Бу иптәш минем ирем булыр: кияүгә чыгып кайттым»,— диде.

Башка да сыймаслык бу хәлгә ни дип әйтергә белмичә, Ханәфи шаккатып торган арада Мәрфуга үзе кирәк дип тапкан әйберләрне алып чыгып, теге Әзмәвернең капка төбендә торган «Жигули»ена төядeләр дә китеп бардылар...

Мәрфуга Шәрәфине дә үзе белән алып китте. Алып китеп бик әйбәт итте. Ханәфи малае булып саналса да, аның фамилиясендә йөрсә дә, ул малайның кыяфәтендә Ханәфигә тамчы да охшашлык юк: Кавказ ягы халыкларыныкы кебек, кара бөдрә чәчле, коңгырт зур күзле, кәкре дәү борынлы, каратут чырайлы бер малай иде ул. Ә Ханәфи үзе аксыл-сары чәчле, зәңгәр күзле, тупыйк борынлы, чандыр гына бер кеше. Шәрәфинең Ханәфигә охшамаганын халык та бик яхшы күреп тора һәм, җае чыккан саен, астыртын елмаеп: «Кемгә охшап болай бөдрә булган соң сезнең бу малаегыз?» — дип, Ханәфинең болай да авыртып торган күңел ярасына тоз сибәләр иде. Шуңа күрә Мәрфуга малаен үзе белән алып киткәнгә сөенде генә Ханәфи: хәзер инде теге үтергеч сорауны биреп тинтерәтмәячәкләр иде.

Мәрфуганың китеп баруы шундый да көтелмәгән, шундый да кинәт кенә булды ки, Ханәфи аннан ник китәсең дип түгел, кая китәсең, кем соң синең бу Әзмәвереӊ, дип сорарга да өлгерә алмады. Соңыннан Кече Елга халкы арасында йөргән имеш-мимешләргә караганда, эш болай булган. Теге Әзмәвер — Мәрфуганың авылдашы икән. Яшь чакларында алар үзара сөешеп йөргәннәр, өйләнешергә дә сүз куешкан булганнар. Ләкин Мәрфуга эшне бозып ташлаган: авылларына кунакка кайткан бер офицерга ияреп китеп барган. Шуның ачуыннан Әзмәвер дә авылларыннан чыгып киткән дә, болар бер-берсен бөтенләй югалтканнар. Әмма икесе дә, бер-берен оныта алмыйча, сагынышып яшәгәннәр. Мәрфуга авылларына кайткан вакытта Әзмәвернең дә кунакка кайткан чагы булган. Әзмәвер шуңарчы өйләнми йөргән булган икән. Әнә шулай очрашканнар, сөйләшкәннәр дә кавышырга булганнар, имеш.

Чыны шулай булгандырмы, әллә халык уйлап чыгарган әкият кенә идеме бу — шайтан белсен. Тик шунысы хак: тегенең китүенә куанды гына Ханәфи. Югыйсә тагын әллә ниләр кыланып, Ханәфинең башын бөтенләй дә миңкетеп бетерер иде. Аңарчы кайнаштырганы да бик җиткән ул хатынның. Шул елларда булган хәлләрне исенә төшергәч, менә хәзер дә күңелләре болганып куйды Ханәфинең. Шул юха елан башын әйләндермәгән булса, болай ук адәм хурына калмый иде ул. Һәм рухи яктан, һәм физик яктан сөлек урынына суыру өстенә, Ханәфи тапкан акчаның да тиененә хәтле үзенә йомып, җилгә очырып торды ул, иблис кавеменнән яралган нәрсә! «Сәламәтлегем шәп түгел, врачлар шулай куша»,— дигән булып, җәй саен диңгез буена ялга йөри, анда алып киткән акчасын туздырып бетерә дә, кайтыр юлга акчам калмады дип, телеграф аша сорап алдыра иде.

Әнә шуңа күрә, ярый, китеп баруы яхшы булды әле, бер дә әллә кем түгел, ир-ат алдында кылтаеп куштанланып йөрүдән башканы белми иде, котылдым ичмаса дип, куанган иде Ханәфи. Әмма куанычы күпкә бармады. Китеп, күп тә тормады, Ханәфине судка биреп, Ханәфигә тырнак очы кадәр дә охшамаган Шәрәфиенә алимент түләттерә башлады ул имансыз хатын.

## 20

Бердән, Мәрфуга китеп баргач, икенчедән, эш урыны инде күптән Куралыкта булганга, Ханәфигә Кече Елгада яшәүнең мәгънәсе калмады. Куралыкка кайтып яши башларга кирәк иде аңа. Үз өйләренә кайтырга теләвен белдереп, кеше аркылы Хәлимәгә сүз катып караган иде — якын да китермәде хатыны. Малае Хәсән ул елны инде университетның икенче курсында укый иде. Аптырагач, аның аша эш итеп карарга булды Ханәфи. Октябрь бәйрәме көннәрендә авылга әнисе янына кайтканын көтеп торды да, урамда туры китереп:

— Мин теге завклуб хатыннан киттем. Авылга кайтырга иде исәп. Әниең белән сөйләшеп кара әле, улым,— дип сүз башлаган иде Ханәфи. Хәсән кырт кисте:

— Юк инде, абзый! Кайтасы булгач, элегрәк, әни белән безгә кирәк чагында кайтырга иде аны. Хәзер синең хаҗәтең бер тиен! — диде.

Үз каныннан яралган, үз токымын дәвам итәргә тиеш булган бердәнбер баласыннан шундый сүзләрне ишетү бик авыр булды Ханәфигә. Болай дип әйткәнче, яңагына сугып китсә, җиңелрәк булыр: бер авыртыр да бетәр иде. Ә ул малай сукмыйча ангырайтып китте...

«Тыныч сөйләшүләр» юлы белән эш чыгара алмагач, Ханәфи йортка дәгъва кылып, судка бирде. Инде ничә ел аерым яшәсәләр дә, закон каршында ул әле Хәлимәнең ире санала, шулай булгач, йортның яртысына дәгъва кылырга хакым бар дип уйлаган иде. Аннары килеп, ул бит йорт бүлүне таләп итми, шунда кереп яшәргә генә тели иде.

Бу юлы да эш ул дигәнчә барып чыкмады. Инде ничә еллар өегездә семьягыз белән яшәмәгәнлектән, сез ул йортка дәгъва кылу хокукын югалткансыз дип, суд Ханәфинең үтенечен кире какты.

Күрәсең, Ханәфинең ир-ат башы белән шулай вакланып йөрүенә ачуы чыккандыр, күп тә үтмәде, аерылышу хакында Хәлимә үзе судка бирде.

Аерылу үз файдасына булмаячагын сизә иде Ханәфи. Шуңа күрә аерылышырга ризалык бирмәде. Аннары тагын судьясы да бөтенләй үк күз күрмәгән кеше түгел, әшнәсе үк булмаса да, күптәнге танышы: Ханәфи колхоз председателе чагында да, авыл советы председателе булган чакта да килгәләп йөргән кеше иде. Шуңа да карамастан, суд аларны берсүзсез аерды. Чөнки Ханәфинең инде ничә еллар Кече Елгада Мәрфуга белән торуын бөтен район, шул исәптән, судья да белә иде. Мәсьәләне Хәлимә файдасына хәл кылуда әнә шул факт эшне хәл итте. Аның әле шунысы гаҗәп: суд барышында судья гел Хәлимә ягыннан торды. Эшне аның файдасына хәл итүе генә җитмәгән, ул әле Хәлимәне кызганып, акыл өйрәтеп утырган була:

— Нигә соң сез,— ди,— ирегез бүтән хатын-кыз белән тора башлагач ук аерылмадыгыз? Шул чакта аерылсагыз, гражданин Хәйретдиновтан балагызга алимент алып торган булыр идегез,— ди.

«Каян килеп андый нәрсәгә башы җитсен ул тубал башның?!» — дип, эченнән генә көлеп-куанып куйган иде шунда Ханәфи. Әмма алданрак куанган булып чыкты. Хәлимә судьяга менә ничек җавап бирде:

— Беренчедән, аның эшләгәне эчүгә һәм сөяркәләренә дә җитми иде. Икенчедән, мин аннан алимент түләттереп торган булсам, соңыннан ул үзе дә малайдан алимент алып канын корытачак иде. Болай, ичмаса, улымның киләчәге өчен җаным тыныч!

Менә сиңа мә! Йөр син аны тубал баш дип. Дөрес, башта, әле район үзәгендә яшәгән чакларында, кибеттә эшләгәне, исәп-хисап белән алыш-биреш иткәне бар иде Хәлимәнең. Куралыкка кайткач та, «Кызыл үрнәк»не «Кызыл юл»га кушып, авылда кибетне бетергәнгә кадәр, кибетче булып торды. Аннан соң инде күпме вакыт үтте бит.

Соңгы ун-унбиш елда ул, кая кушсалар, шунда барып, гади колхозчы булып кына эшләде. Кешеләрдән акыл алгандыр дияр идең, елына берәр тапкыр Казанга барып кайтуларын санамаганда, читкә, зур дөньяга чыкканы да юк. Шуңа күрә Ханәфи аны бик тә надан һәм томанага санап йөргән иде. Ә ул, әнә, Ханәфидән акыллырак булып чыкты: барысын да алдан күреп эш иткән! Әйтәм аны теге чакта Ханәфине өйалды ишеге төбеннән борып җибәргәннән бирле актан да, карадан да дәшмичә, шыпырт кына йөргән иде. Барысын да эченә җыеп, ачуын алыр өчен көне-сәгате килеп җиткәнен көтеп йөргән икән, явыз...

## 21

Шулай итеп, йорты бар килеш торыр урынсыз, үз авылында чит кеше булып калды Ханәфи. Ул көннәр исенә төшкәч, менә хәзер дә тәннәре чымырдап, эсселе-суыклы булып китте. Чөнки ул көннәрдә күргән-кичергәннәре әле дә бик ачык хәтерендә саклана иде.

Ханәфи Куралыкка кире кайтырга теләгән ул чорда авылда хуҗалары читкә киткән дүрт йорт буш тора иде. Вакытлыча гына кереп торырга рөхсәт сорап, Ханәфи аларның хуҗаларына хат язып караса да, әйтерсең алдан сүз берләшеп куйганнар, берсе дә ризалык бирмәде. «Гаеп итмә, Ханәфи туган, рөхсәт бирә алмыйбыз шул. Үзебез кайтырга җыенабыз»,— дип җавап бирделәр. Ләкин Ханәфи белә: берсе дә кайтырга җыенмый иде аларның. Ханәфинең председатель чагындагы кыланышларын оныта алмыйлар. Әлбәттә, Ханәфинең аларга карата гаделсез чаклары, кайбер очракларда хәтта тиешсезгә кимсеткән көннәре дә булгандыр. Тик нигә инде шул вак-төяк нәрсәләрне гомер буе күңелдә саклап, кинә тотып йөрергә кирәк?.. Һәй, болай булырын белгән булса, алай гына кыланыр идемени ул! Кандала урынына сытар иде аларны! Колхоз председателе чагында теләсә кайсын «эпипә»гә биетә ала иде бит ул аларның!

Амбар хәтле йорты була торып, туган авылында сыенып урын таба алмыйча интеккәч, аралары инде күптән суынган булса да, элекке дуслык хөрмәтенә бәлки сыендырып торыр дип, Хөснижамал хозурына да барып караган иде Ханәфи. Тик ул хатын да: «Юк, булмый Ханәфи агай, кешедән ару түгел. Әллә ни сөйләүләре бар. Аннары, үзең күреп торасың, кызым да үсеп җитте»,— диган булып, күзен дә йоммыйча борып җибәрде. Ә бит заманында: «Ханәфием-җаным, Ханәфием-бәгырем. Синнән дә акыллырак, синнән дә көчлерәк, синнән дә сөйкемлерәк ир-ат юктыр. Синең белән очрашмасак, бу дөньяда яшәүнең тәмен белмичә үләсе идем. Ярый әле, бәхетемә, сине туры китерде ходай!»— дип, Ханәфи өчен куккә ашарга әзер булып, кая басканын белмичә бөтерелеп йөри иде. Ә хәзер, кулыннан власть киткәч, Ханәфинең аңа кирәге калмаган, ул аны вакытлыча гына сыйдырып торырга да теләми. Их-ха-ха! Хатын-кызга ир-атның үзе түгел, биләгән урыны, дәрәҗәсе кирәк икән шул...

Ул елларда колхозлар экономик яктан шактый ныгыган, читтән килгән яшь белгечләргә: агрономнарга, укытучыларга, өйләнеп башка чыккан яшь механизаторларга, хәтта кайбер гади колхозчыларга да колхоз исәбеннән (бәясен акрынлап соңыннан түләү шарты белән) йортлар салып бирә башлаган иде. Ә Ханәфидән соң эшли башлаган председатель җитәкчелегендә «Кызыл юл» колхозы бу җәһәттән тагын да алгарак китте: шәһәрчә бөтен уңайлыклары булган, өчәр, дүртәр бүлмәле типовой йортлар төзергә кереште. Ханәфи,— бердән, гади колхозчы гына түгел, бригадир кеше. Икенчедән, аңа Кече Елгадагы шикелле дүртәр бүлмәле таш йорт кирәк түгел, үзләренең Куралыгында ару гына бер агач йорт булса, бик җиткән иде. Менә шул ният белән ул, Куралыкта үзенә йорт салып бирүләрен үтенеп,

колхоз идарәсе исеменә гариза язды һәм шул бәләкәй генә үтенечен берсүзсез канәгатьләндерерләр дип уйлаган иде. Моменты да бик уңай: «Кызыл юл»ны республика күләмендә алдынгылар рәтенә чыгарган, әмма нигәдер Ханәфине бик үк өнәп бетерми торган элекке председатель пенсиягә киткән, аның урынына Ханәфигә хөрмәт белән карый, аннары аңа бераз чыбык очы да тиешле әлеге шул Нургазизне председатель итеп куйганнар иде.

Ләкин Нургазиз, Ханәфинең гаризасын идарә утырышына куеп та тормыйча, үзенә кире кайтарып бирде:

— Юк, Ханәфи абый,— диде ул, аның гаризасына күз салу белән.— Бу эшне колхоз үз өстенә алмаячак. Расходыннан куркуда яки сине санламауда түгел мәсьәлә. Хикмәт башкада. Хәтереңә төшер әле: Куралыктагы сарык фермасын Кече Елгага күчерттерү өчен заманында кем тырышып йөргән иде?

— Кем дип... идарә карары белән эшләнгән эш иде инде ул.

— Дөрес, идарә карары белән эшләнгән. Ләкин синең тәкъдим белән чагарылган бит ул карар. Аннары килеп, әле ун ел элек кенә Куралыкта егермеләп ат булганын мин үзем дә хәтерлим. Алар кем инициативасы белән бетерелде? Синең күрсәтмә белән! Инде килеп, Куралыктагы башлангыч мәктәпне яптыру кем эше булды? Анысы да синең эш! Ә бит авылда укучы балалар аз булганга килеп чыккан котылгысыз хәл түгел иде бу. Сезнең авылда ул елларда ел саен тугызар-унар бала укырга кереп тора иде. Ул балаларның аталары колхозда түгел, Үшемкә ПМКсында эшли, шулай булгач, балаларын да шунда алып барып укытсыннар, дигән сылтау белән яптырдың син ул мәктәпне. Перспективасы юк дип, син хәтта Куралыкның үзен дә Кече Елгага күчертергә йөргән идең. Авыл халкы Верховный Советка язып кына коткарып калды аны... Ә хәзер, атлары, фермасы, мәктәбе булмау аркасында авыл яшьләре читкә китеп беткәч, Куралыкның үсү перспективасы, чыннан да, юк инде. Шулай булгач, мине санламыйлар, кимсетәләр, йорт салып бирмиләр, дип син идарәгә үпкәләмә, Ханәфи агай. Беркем кимсетми сине. Хөрмәтебез дә бар. Ничек булса да, гомереңне буе җитәкче эштә эшләп килдең. Анысын бик яхшы беләбез. Телисең икән, һич тә кызганмыйча, Кече Елгада яшь белгечләргә дип салынган йортлардан бер бүлмәле фатирны иртәгә үк бирә алабыз. Анда торып, Куралыкта эшләү авыр булыр дисәң, рәхим ит, кайта-килә йөрер өчен үзеңә бер ат та беркетергә мөмкин. Әмма Куралыкта йорт салып бирү турында сүз дә була алмый, агай.

Әнә шулай иплән кенә Ханәфинең авызын томалап куйды ул егет. Аңа каршы килеп булмый, чөнки әйткәннәре барысы да дөрес иде, кызганычка каршы. Хәзер инде искә алырга да оят: Куралыкны менә шушы бүгенге аянычлы хәлгә калдыру шулай кирәк булганнан яки өстән кушып эшләнгән эш булмады ул. Фәкать Ханәфинең үз мәнфәгатен кайгыртуыннан килеп чыкты. Куралыкны Кече Елгага күчергән тәкъдирдә, беренчедән, Ханәфи Хәлимәнең горурлыгына бик каты сугачак иде: «Теге чакта өеңә дә кертмичә, әллә кем булып, бусагаңнан кире борып җибәргән булдың. Ханәфи белән шаяру яхшылыкка алып бармый ул: менә хәзер өең белән бергә минем янга Кече Елгага күчеп килдеңме инде?»— дип әйтмәкче иде ул, Хәлимәнең йөзенә бәреп.

Аннары килеп, Куралыкны күчерүнең Ханәфи өчен тагын берничә уңай ягы бар: һәр ел саен авылның ике чишмәсен төзәттереп, буасын буздыртып йөрисе булмый; инде бик нык тузган зират коймасын төзәттерүнең кирәге калмый; авылга электр кертик, радио үткәртик дип, Куралык халкы Ханәфине бимазалаудан туктаячак иде.

Авылны күчертергә йөрүенә югарыдан каршылык юк, киресенчә, хуплап торалар, чөнки ул чорда гомуми курс шундый иде. Әнә, ышанмаган кеше алып карасын ул елларда чыккан газета-журналларны. Укып карасын шул елларда басылган китапларны. Кечкенә авыллар-

ның перспективасы булмавы, шәһәр белән авыл арасындагы аерманы бетерү юлында кечкенә авылларның киртә булып торулары, шуңа күрә аларны тизрәк зур авылларга күчерү кирәклеге хакында күпме мәдхия язылган анда!..

Хәзер генә ул бәләкәй авылларны бетерергә ярамавын, аларны да сакларга кирәклеген күтәреп чыктылар, чөнки һәр авылның кабатланмас матурлыгы, тарихы, традицияләре бар. Колхозларның алга таба үсешендә алар киртә түгел, киресенчә, файдалы булулары хакында яза да, сөйли дә башладылар. Әйтергә кирәк, белеп язалар, белеп сөйлиләр. Менә шушы Куралык авылын гына ал. Үзе зур булмаса да, тарихы борынгыдан килә. Ул тарих авыл зиратындагы кабер ташларына язып барылган. Бер кабер өстендәге таш әнә Болгар дәүләте заманында ук куелган ди. Казаннан килгән археологлар тикшергән иде, шулар әйтте. Аннан соңрак куелган бүтән гыйбрәтле ташлар да байтак анда. Ханәфинең үзенең дә биш бабасы шунда күмелгән. Ике бабасының кабере әле дә билгеле (Ханәфи кечкенә чакта әтисе күрсәткән иде). Тик алар инде иңеп, җир белән тигезләнеп килә. Ул каберләрне Ханәфи бары өсләрендә үсеп утырган агачларыннан гына таный. Элек, көчендә-куәтендә чакта, шуларга кабер ташы куйдырырга башына килмәгән. Хәзер бик куйдырасы да, әмма рәте юк. Үзе авыл советы председателе чагында уйларга иде аңа боларны. Яңартасы иде бит шул зиратның коймасын дип, халык Ханәфигә күпме әйтте. Ханәфи ул эш белән мәшәкатьләнеп йөрергә теләми иде: «Яңартасы иконен үзем дә беләм, лəкин акча юк бит»,— дип, тегеләрдән ансат кына котылырга теләде. Шуннан соң халык үзара сөйләшеп, акча да җыйган иде. Ханәфигә тик баганалыкларын һәм коймалык такталарын гына юллап бирәсе калган, ә рәшәткәсен ирләр бушлай тотып бирергә дә риза иделәр. Ул, ахмак баш, шуны да эшләмәде... Алай гына да түгел, ул хәтта зиратка койма тотарга дип җыйган халык акчасын исраф итеп, эчеп бетерде. Моннан да зур җинаятьнең булуы мөмкинме соң? Гөнаһысы зур кешеләрне җир йота торган булса, Ханәфине инде күптән йотар иде, ярый әле җирнең андый гадәте юк...

Хәзерге авыл советы председателе, әнә, баганаларын да, җепсәлекләрен дә, рәшәткәлек тактасын да үзем табам, эш хакын да түлим, тик коймасын гына коеп бирегез шул зиратның дип, күпме ялварып йөрде. Авылда аны эшләрлек кешеләре дә бар. Әхмәтгалиләр, Нурмыйлар, Мөбиннәр, пенсиядә булсалар да, үзләренә кирәкне яшьләреңнән болайрак эшлиләр. Зиратка койма тотарга берсе дә теләмәде шуларның. «Хәзер аңа койма коюдан ни мәгънә? Авылны үчермәскә кирәгие. Авыл үзе беткәч, аның зираты агач рәшәткә түгел, бетон койма корсаң да бетә инде ул»,— диделәр. Ә үзләре берәрсенең капка төбендәге такта өстенә җыелып, хатыннар күк, көннәр буе ләчтит сатып, кәрт уйнап, тәмәке пыскытып утыралар. Шул хәлгә эче пошып, быел җәй бер вакыт тегеләрне оялтмакчы булып караган иде Ханәфи, ник авыз ачканына үкенеп бетә алмаслык иттеләр:

— Үткән тарих белән киләчәк буыннар хакында кайгыртырлык акылың булгач, нигә соң син ул зиратны әлегрәк, үзең авыл советы персидәтеле чакта, халык үзе сорап торган чакта, авыл әле таралмаган чакта рәшәткәләтмәдең? Хәзер нәрсә? Хәзер күмәр кеше дә бетеп бара бит инде ул зиратка! — дип көлделәр генә.

Һәй, кая анда Ханәфинең сүзен исәпкә алу, хәтта сиксән яшьлек Хисам карт сүзен дә колакларына да элмәделәр.

— Курыкмагыз, аңа гына бүсерегез төшмәс. Багана төпләрен казышып, баганаларын утыртышсагыз, коймасын үзем дә мәтәштерәм мин аның!— дип тә караган иде Хисами карт. Ыжлап та бирмәделәр. Шуннан ары Хисами карт:

— Кадалып китегез инде алай булгач!— дип лачкылдатып бер

төкерде дә, күрше авылдан кешеләр яллап, зират коймасын үз акчасына тоттырды. Аннары район үзәгендәге көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатына барып, ике кабер ташы алып кайтты. Берсе — үзенә, берсе — Гөлзәйрәсенә. Ташларга үзләренең исем-фамилияләрен, туган елларын да яздырган, үлгән елларын язарга урын калдырган. Анысы ашыгыч түгел, ахырдан яздыртырсың дип, Гайнелхәят малае Каюмга алдан ук акчасын биреп, ул яктан да эшен бетереп куйган. Бәдерниса карчыкка үлгән елында ук таш куйган иде инде. Ә чардуган куюны ул кирәк дип санамый. Үлгәч тә башкалардан аерылып торырга теләгән ахмаклар уйлап тапкан нәрсә генә ул ди.

Ни гомер начальник булып йөреп, Ханәфи үзенең газиз әнкәсе каберенә тәки ни чардуган, ни таш куйдыра алмады. Бабалары хакында әйткән юк инде. Ә бит зират — адәм баласының төп йорты. Беркем, шул исәптән Ханәфи дә, анда бармый калмаячак. Биле белән аяклары һаман шушылай йөрәккә төшеп сызлап торса, быел кыш ук китеп бармагае әле. Ярты дөньяны яулап алган патшалар да каршы тора алмаган үлемгә... Алай-болай булып китсә, авыл халкы казыр инде анысын. Ә менә каберенә таш куючы булмас! Алдан хәстәрле башлыйсы иде дә... Бу хәлдә кая аның артыннан йөрү! Утырган урыныннан кубып китәргә дә коты чыгып утыра әле менә. Ай-һай, яман икән бу радикулит дигән нәрсә!..

Ә бит бу каһәр суккан авыру аңа үз ахмаклыгы аркасында эләкте.

## 22

Куралыкта электән калган ферма өе бар иде. Авылда фатир таба алмагач, Ханәфи ул елны шул өйдә тора башлады. Инде бик нык тузган-кыйшайган, авылдан читтә берүзе боегып утырган зур, шыксыз бер өй иде ул. Каралты-курасы түгел, хәтта янында бәдрәфе дә юк иде аның. Авыл советы председателе чагында Ханәфигә: «Сиңа әнә шул йортта берүзең яшәргә туры киләчәк»,—дисәләр, ул моңа ышанмас, кычкырып көләр генә иде. Ә теге елны исә әнә шул ярым җимерек йортка куанып урнашты ул. Авылның чүплек чокырына чыгарып ташланган бер иске тимер караватны төнлә, кеше-кара күрмәгән чакта, шул өйгә алып кайтып, үзенә ятак әзерләде. Комбайнчылардан калган ватык өстәлне алып кайтып, рәтләштереп куйды. Әлүмин кәстрүл, тәлинкә, кашык, чүмеч сатып алды да шул өйдә көн күрә башлады.

Башта бик күңелсез һәм шомлы булды аңа. Төнлә берәр үчлесе үтереп чыгар сыман яки, караңгыда тышка чыкканын саклап торып, бүре буып китәр шикелле иде. Шулардан куркып, төннәр буе йоклый алмыйча ятты. Тора-бара ияләште тагы...

Бригадир эше авыл советындагыга караганда бөтенләй дә җиңел булып чыкты. Тегендә көненә йөз кеше төрле мәсьәлә белән килеп, башны катырып бетерәләр иде. Ә монда, эшкә ярый торган тугыз бөртек колхозчыны көндәлек эшкә кушу, ике-өч көнгә бер тапкыр Кече Елгага барып, председательдән күрсәтмәләр алу, кайтышлый авыл кешеләренә дигән хатларны, гәҗитләрне алып кайтуның бер кыенлыгы да юк, ә хезмәт хакын башка бригадирлар белән тигез түлиләр иде.

Тик бер нәрсә — ашарга әзерләү мәсьәләсе кыен иде Ханәфигә. Иллегә җитеп килсә дә, аның бит шуңарчы аш пешерү, икмәк салу түгел, хәтта бәрәңге әрчеп караганы да булмады. Башына төшкәч, башмакчы буласың икән ул: аларына да өйрәнергә туры килде. Һәрхәлдә, шул ялгызак тормышка ул инде тәмам күнегеп килә, болай яшәүнең хәтта уңай ягы да бар: кайчан кайтып керсә дә, кайда булдың, ни эшләп йөрдең дип, Мәрфуга шикелле допрос алучы юк иде. Әмма...

Җәйләр, көзләр үтеп, кышка кергәч, хәлләре хөртиләнде Ханәфи-

нең. Ничә еллар хуҗасыз торганга, мүкләрен кош-корт йолкып, тычкан кисеп, нигезен кумак тишеп бетергән, аннары миче дә бик искергән ул өй, күпме яксаң да, җылынмый иде. Күрше авылдан кеше яллап стеналарын мүкләтүнең дә файдасы тимәде. Мичен яңартырга кирәк иде.

Кирәген кирәк тә, бу заманда мич чыгаручы табу җиңел эш түгел шул. Түләвен дә әйбәт түлиләр кана үзләренә: икмәк миче чыгару йөз илле тәңкә тора. Аннары килеп ашау-эчүе дә хуҗа өстеннән, үзләреннән бер тиен акча чагарасы түгел. Миччене өенә барып алалар, эшен бетергәч, илтеп куялар. Тәҗрибәле мичче иң зур мичне дә көн ярымике көн эчендә эһ тә итмичә салып бетерә. Шулай итеп, ике көндә бригадирның бер айлык эш хакын кесәсенә сала да кайтып китә. Ханәфинең хәзер ала торган пенсиясеннән түлисе булса — ике айлык пенсия кирәк. Ләкин юк, мич эшенә өйрәнергә, ни хикмәттер, бер дә атлыгып тормый хәзергеләр. Авыр эш, пычрак эш дип карыйлар, күрәсең. Ә бит оста мичче кулын да буямыйча эшли ул эшне. Аның бит балчыгын хуҗалар үзләре изә, кирпечен дә миччегә алар биреп тора...

Интекте ул елны Ханәфи кеше эзләп. Кече Елгада мичче бар иде барын. Ләкин, кыш өстеннән эшли торган эш түгел ул дигән булып, асылда исә Ханәфигә яхшылык итәсе килмичә, риза булмады. Инде ни эшләргә дип, ут йотып йөргәндә, җае чыкты тагы. Үшемкә ПМКсында тракторда эшләүче үз авыллары егете, майның үндүртенче кичәсе кебек түм-түгәрәк табак битле, сап-сары чәчле, сирәк ак кашлы Рәшитнең мич чыгарганы бар икән. Гозерли торгач, шуны көндерде Ханәфи. Бер тотынгач, эшне бик тиз тотты егет: уналтынчы декабрьдә иртәнге сәгать сигезләрдә башлаган иде, унҗидесендә кичке бишләргә чыгарып та бетерде. Кар әле аз, әмма җир бик нык туңган, төннәрен суык унҗидешәр градуска җитә иде ул көннәрдә. Куралыкка электр уты Ханәфи авыл советыннан киткән айда ук кертелгән булса да, ферма өенә чыбык сузылмаган иде. Шуңа күрә шул суыкта теге егет ничек эшләр икән дип борчылган иде Ханәфи. Аның да җаен тапты Рәшит: үзе ясаган тимер миче бар икән, мич чыгарганда, Ханәфинең өен дә, измә ясыйсы суны да шул мич белән җылытып тордылар. Аның әле тагы шунысы гаҗәп: башка вакытта хәйран гына салып йөри торган Рәшит Ханәфи кыстап торганда да: «Эшләгәндә — эчмибез, эчмәгәндә — эшлибез. Кыстама, агай»,— дип, мич чыгарганда бер грамм капмады. Эш хакын да башкалар шикелле каерып түгел, бик арзан — нибары илле сум гына алды. Ә мичнең стенасын шундый тигез итеп салган — карап кына торырлык! Гомер буе мич чыгарып йөргән атаклы осталарның да кайчакта эшләре уңышлы булмый, морҗалары төтенне суырмаса, яңадан сүтеп чыгарырга туры килә иде: Рәшит чыгарган миччә ул яктан да тел тидерерлек түгел иде: чыгарып бетергәч, беренче тапкыр ягып җибәргәндә үк завод торбасы шикелле гөрләтеп кенә суырып алып китте. Куанып бетә алмаган иде моңа Ханәфи.

Тик менә җылы тотмый торган булып чыкты ул мич. Яккан чагында, дөрес, кул тидереп булмаслык дәрәҗәдә кыза. Ягудан туктап, морҗа калагын томалауга, ике-өч сәгать үтми — суына да бетә. Авыл җирендә, гадәттә, олы мичкә тәүлегенә бер тапкырдан ары ягылмый. Ә моңа икешәр тапкыр ягудан да файда юк. Аптырагач, әллә шуннан суына микән дип, Ханәфи юшкә калагы өстенә киез дә каплап караган иде, барыбер нәтиҗәсе булмады. Иртән торуга чиләктәге суларга хәтле бозланып ката, ишек җепсәләрен ап-ак сыкы каплый иде.

Әнә шул чакта эләкте Ханәфигә радикулит. Аңарчы ул әле саутаза, бер тапкыр да врачка барып караган кеше түгел иде. Грипп-фәлән эләгеп, азрак чирли башласа, тозлап-борычлап бер стакан акны салып ятып йоклый да, иртән торуга, авыруы юып алгандай була торган иде. Шул салкын ферма өендә торган елны гына харап булды Ханәфи. Яңа елга каршы төндә шундый «төшереп» кайтылган, Ханәфи хәтта өенә кайчан һәм ничек кайтып кергәнен дә хәтерләми иде.

Төннең бер вакытында башы ярылырдай булып авыртканга уянып китсә — ишек бусагасы төбендә идәндә ята бу. Өстен чишенүен чишенгән, әмма урынга барып ятарлык хәле булмаган, күрәсең, бусага төбендә как идәндә йоклаган. Ток тоткандай, дер-дер калтырый иде ул. Җитмәсә тагын бик хәтәр укшыта да иде. Шунда берәр йөз грамм салып куйса, яисә кайнар чәй эчсә дә бераз хәлләнеп китәр иде. Ләкин, күрәчәгенә каршы, бер грамм әйбере дә калмаган, ә чәй кайнатырлык хәле юк иде Ханәфинең. Караватына да көч-хәл белән генә барып ятты ул. Иртән бөтенләй тора да алмады һәм унике көн рәттән урын өстендә ятты. Ярый әле, хәленә кереп, Нурмый ярдәм итте: Ханәфи аякка басканчы иртә-кич аның мичен ягып, ашарына әзерләп торды (ни әйтсәң дә, Ханәфи ул чакта кирәкле кеше — бригадир иде бит әле). Әнә шуннан гарипләнеп калды ул.

Моңа барыннан да элек Ханәфи үзе гаепле иде, әлбәттә. Акылың җуярлык хәлгә җиткәнче лыкынгач, шулай булмыйча ничек булсын? Дөрес, ул көнге эчүе бөтенләй үк сәбәпсез түгел, сәбәбе бар иде аның. Урып-җыю чорында планнарын арттырып үтәгән комбайнчылар, шоферлар, тракторчылар белән бергә, Ханәфигә дә шактый гына премия тиде ул көнне. Шуны «юганнар» иде. Ләкин бит премия алдым дигәч тә дуңгыз булганчы эчәргә димәгән! Ул көнне премияне Ханәфигә караганда биш тапкыр артык алган комбайнчылар булды. Аңа карап, берсе дә Ханәфи хәленә төшмәгән, барысы да вакытында өйләренә кайтып ятканнар лабаса!..

Шулай да аңа авыру эләгү бер исереклек аркасында гына булмады. Ни өчен дигәндә, ул бит, ничек кенә сәрхүшләнмәсен, юлда егылып калмаган, өенә кайтып егылган. Әгәр шунда өе бүтән кешеләрнеке шикелле җылы торса, идәндә йоклаганнан гына әллә ни булмас иде аңа. Азрак салкын тиеп, йөткергәләп йөрер иде дә шуның белән үтеп китәр иде. Ә менә болай, өе сулар катарлык салкын булгач, авыру эләгү генә түгел, бөтенләй катып үлүе дә бик ихтимал иде ул чакта Ханәфинең. Шунда өнсез-аңсыз килеш «ычкынган» булса, менә шушылай, кымшанырга да куркып, сызланып яшәү җәзасыннан котылган булыр иде ичмаса! Инде ничә ел чиләнә бит өзми дә, куймый да җелеккә төшеп торган шушы сызлану белән. Әле тагын күпме чиләнәсе бардыр. Яшерен-батырын түгел, билләре-аяклары сызлануга түзә алмыйча, үзенә-үзе кул салыр чиккә җиткән чаклары була Ханәфинең. Берәүгә дә кирәгең калмыйча, бернинди максат-өметсез яшәүнең ни кызыгы бар да ни хаҗәте бар? Авыру кешеләрнең кайберләре, алда ышаныч-өметләре булмаса да, яшь-егәрле чакларында эшләгән эшләрен, кешеләргә кылган яхшылыкларын хәтерләп, шулар белән рухланып яши. Икенче берләре гаилә тормышы белән юанып, хатыннары, бала-чагалары хөрмәтен тоеп, шуңа тотынып тора. Кайберләре хәлләреннән килердәй берәр файдалы шөгыль таба һәм шуның белән гомер үткәрә. Ханәфинең исә ни горурланып искә алырлык эшләгән эше, ни гаиләсе, ни дус-ише, ни шөгыле юк. Ул беркемгә дә кирәк түгел. Чөнки ул, шушы яшенә җитеп, берәүгә дә игелек күрсәтмәгән. Ә хөсетлекне күп эшләгән.

Әлеге шул миченең җылы тотмавы да Ханәфи кайчандыр кылган миһербансызлыкка җавап йөзеннән эшләнгән эш булып чыкты. Табак бит Рәшит эше. Анасыннан шәрә туган ул малай Ханәфи морҗасының төтен юлын калактан читтә үтә торган итеп чыгарган булган. Шуңа күрә мичнең җылысы морҗа калагы ябык булганда да һавага очып барган. Табак бит соңыннан Ханәфигә моны үзе әйтте. Әйтте генә түгел, килеп, морҗаның төтенен калак аша үтә торган итеп рәтләп тә китте. Ханәфи аңа:

— Нигә дип шулай кыландың, малай? Ни үчең барые миндә? — дигән иде, авызын ерган да көлә теге:

— Үчем юк, агай, ну ачуым бар иде. Исеңдәме, колхоз предсе-

дателе чагында урманнан утын алып кайтырга безнең әнигә ат бирми интектергән идең?

Ханәфи, әлбәттә хәтерләми иде. Аз булдымыни аның ат сораган кешеләргә ат бирмәгән вакытлары.

— Бирмәгәнмен икән, димәк, мөмкинлеге булмаган! — диде ул. Табак битнең шуны да аңламавына җене чыгып.— Шуның өчен генә ачу саклап йөрмәсәң дә ярар иде!

— Юк шул, агай,— ди теге.— Мөмкинлегең барые синең ул чакта. Ләкин син атларны я өенә дәшеп эчергән, яки ат сорарга килгәндә кесәләренә шешә кыстырып килгән кешеләргә бирә идең. Безнең әнинең сиңа аракы алырлык акчасы юк иде. Шуңа күрә син аны көн саен, бүген булмый, иртәгә килерсең, дип унбер көн тинтерәтеп йөрттең.

— Ну бит утынсыз калмагансыз: уникенче көнне барыбер биргәнмен!

— Хикмәт тә шунда, утынсыз калдык шул. Син ат бирмичә йөрткән арада безнең ул утынны урлап алып киткәннәр иде инде. Үкси-үкси җылады шул чакта әни. Исән-сау үсеп кенә житим, үзенә дә бу «әҗәтне» кайтарам әле мин ул персидәтелгә дип, әнә шул көнне үземә-үзем сүз биреп куйган идем. Шулай булгач, син миңа ачуланма, агай, әҗәтне кайтару гына бу!— ди.

Ни эшләтәсең аны? Авызың кыек булгач, көзгегә үпкәләп булмый. Ә мичне начар салмаган иде ул Табак бит. Төтен юлын калак аша үтә торган итеп төзәткәч, тәүлеккә икешәр тапкыр ягып азапланунын кирәге калмады, бер якканы да бик житә иде.

Эмма... ул арада Ханәфинең рәте киткән иде инде. Авыруы болайга ук барып житәр дип, башта ул уена да китермәде. Менә бетәр, менә үтәр дип ышанып йөрде. Эшләр шушылайга ук китәрен чамалаган булса, белә торып җинаять эшләгәне өчен, Ханәфи ул Табак битне шатырдатып торып судка бирер иде дә, аңа гомере буе акча түләп тора торган иттерер иде. Кызганычка каршы, мондый көннәргә калырын белмәде шул...

Ә авыруы елдан-ел көчәя барды. Икенче группа инвалид булып калганына да инде ике ел тулып килә. Башта биш елдан артык теге ферма йортында ялгызы торып чиләнде.

Хәзер ул яктан зарланырга урын юк: инде менә өченче елы, ферма йортында яшәү газабыннан котылды: Хәлимә, Хәсән янына Казанга киткәндә, Ханәфигә йортын калдырып китте. Электры да, газ плитәсе дә бар. Газын китереп торалар. Аракы эчмәсәң, башка кирәк-яракларыңа житәрлек пенсиясе килеп тора...

Анысы шулаен шулай, тик менә тормышының кызыгы, яшәвенең мәгънәсе юк Ханәфинең. Алтмышка житкәндә ни хатының, ни балаларың, ни дус-ишләрең булмыйча, карт бүре шикелле бер ялгызың тереклек итүгә калгач, нинди тормыш инде ул?

Гомер буе гел житәкче булып йөреп, картаймыш көнендә авылдашларың хөрмәт итәрлек тә авторитет казана алмагач, хатының — ир, балаң — ата итәрлек тә абруең булмагач, бу дөньяга килеп, ипи черетеп йөрүең ни хаҗәте булды икән? Их-их-их-их!..

## 23

Менә тагын бер көн үтеп китте. Күңелсез, авыр уйлардан башка, бу көн дә, башкалары кебек үк, бернинди куаныч китермәде Ханәфигә. Ике күзен дүрт итеп көткән кешеләре — Хәсән белән Хәлимә кайтмады. Бил-аякларының сызлавы кимемәде. Алынмаган унбиш сутый бәрәңгесе бүген дә шулай түтәлендә торып калды. Көнозын шушы капка төбендә утырып, Мокыт Нурмыйның нервы бозып китүеннән башка янына килеп хәл белешкән, дөнья хәлләрен сөйләшеп утыр-

ган кеше булмады. Үзе эндәшеп туктатмаган булса, Хөснижамал булып Хөснижамал да күрмәмешкә сабышып узып китәсе иде бит...

Әнә, көтү дә кайтып килә. Халык мул яши хәзер. Һәр йортта сыер, сигезәр-унар баш сарык. Сыер өстенә таналы-бозаулы кешеләр дә бар. Хатын-кызлар хәзер гөбердәтеп сыер сава башлаячак. Авылга җылы сөт исе таралачак. Ә Ханәфинең хәтта кәҗәсе дә юк. Узган ел кеше аркылы инкубатордан унбиш чебеш апкайттырып асрап караган иде, ашатып-эчертеп йөрүе авырга килгәч, аларны да суеп ашап бетерде...

Болай булгач, кайтмауларыдыр инде Хәлимә белән Хәсәннең. Кайтасы кеше моңарчы калмас иде.

Болытлар куерганнан-куера бара. Җиле дә көчәйде. Салкынайтып та җибәрде. Мөгаен, төнлә яварга ниятли. Әбиләр чуагы күпкә бармый шул ул. Тиздән көзге яңгырлар китәр. Тәрәзә капкачларын йолкып атардай булып, салкын-ачы җилләр исә башлар. Андый көннәр Ханәфигә бер дә файдалы түгел. Аның бит әле кыш ягарга утыны да юк. Хәсәне юллап кайтартмаса, харап Ханәфинең хәлләре...

Ярар, монда утырудан мәгънә чыкмас. Ничек итеп булса да кузгалып, өйгә керә башларга кирәк. Дөрес, анда кереп кенә хәле яхшырмас яхшыруын. Шулай да өй өй булыр әле, капка төбендә төн үткәреп булмый лабаса...

*Казан — Переделкино — Корабельная роща*

*1985—1986 еллар*

## Гамил Афзал

# УРМАННАРГА КЕРӘМ...

❁

Тәрәзәдән ай караган төндә
Тупыл яфраклары шыбырдаша.
Дөнья даһилары яши миндә,
Тавышлары килә еллар аша.

Тупыл яфраклары шыбырдаша
Талгын гына искән төнге җилгә.
Еракларга карыйм еллар аша
Тәрәзәдән ай караган төндә.

Дөнья даһилары яши миндә,
Һәр күзәнәк саен берәр бөек,
Эндәшәләр кебек айлы төндә,
«Син дә уйла, син дә эшлә!» — диеп.

Тавышлары килә еллар аша,
Сәламнәре килә искән җилдә.
Тупыл яфраклары шыбырдаша
Тонык кына ай караган төндә.

❁

Нинди генә җилләр иссә дә лә,
Нинди генә еллар килсә дә,
Бер гомерлек озын постта торам,
Бер гомерлек мандат кесәдә.

Ленин биргән мандат кесәдә ул,
Дөнья бара безнең иңсәдә...
Бер гомерлек озын постта торам,
Нинди генә җилләр иссә дә!

❁

Җиңел генә бурыч бурычмыни,
Җиңәсе дә килми җиңелне.
Җиң сызганып, җиде селтәндек без,
Җиде башлы дию җиңелде.

---

ГАМИЛ АФЗАЛ *(1921) — шагыйрь, «Өф-өф итеп», «Ышанычыз», «Айлы кичләр», һ. б. егермедән артык шигырь китабы авторы. Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Әлмәттә яши.*

Җидегән йолдыз юлларында киңлек,
Җиде кат тир кипте җилкәдә.
Җиде кат күк каршылыгын җиңдек,
Җиде дошман каршы килсә дә!

❁

Биек тауга менеп нишләмәдең,
Тирән упкыннарга төшкәләдең,
Саф, пакь көе һаман сагына сине
Син су эчкән яшьлек чишмәләрең.

Сикәлтәле икән гомер юлы,
Табулар һәм югалтулар тулы.
Яшел яфракларың лепердәшкән
Яшьлек чишмәләрең көмеш сулы.

❁

Вакыйга һәм кеше язмышлары
Тирбәлдерә безнең күңел кылын,
Шуңа бәйле уҗым арышлары,
Кәккүкле һәм кузгалаклы болын...

Вакыйга һәм кеше язмышлары,
Өянкеләр шавы күз алдында,
Җан сызлавы, сөю сагышлары,
Кеше дәрәҗәсе уйландыра.

❁

Ерак еллар аша алып килдем
гомер шатлыгын мин.
Иң биеккә байрак итеп элдем
нәфес сафлыгын мин.

Саф чишмәләр аккан һәр төбәктә
яфрак саен бизәк.
Хозурланды күңел, һәр йөрәккә
ак бәхетләр теләп.

❁

Елау белән көлү арасында
Фикер йөртә адәм баласы:
Бөек даннар яулап аласы бар,
Нинди юллар белән барасы?

Сөю, хезмәт — яшәү чарасы да,
Ил намусы — күзең карасы.
Ә бездән соң кемнәр каласы? — дип,
Бер тирәнтен уйлап аласы...

❁

Әйдә, чәчләрең агарсын,
Яшь гомер үтсен, иптәш,
Талгын су булып агарсың,
Таллы ярларга җиткәч.

И ерак таулар күгелҗем,
И биек ярлар текә.
Энҗеләр булып түгелдең,
Үрләрен үтә-үтә.

❁

Болгана да тына агым сулар,
Агым сулар кебек моң булсын.
Ил алдында сүзнең кодрәте бар,
Ташка баскан сүзең чын булсын!
Иң акыллы сүзне әйтәсем бар,
Соң булса да уң булсын.

❁

Урау-урау еллар катламыннан
Ургып-ургып аккан моң дисәм,—
Уралымнан урап кайтамын да,
Улакларга ятып, су эчәм.

Мин күңелдә йөрттем Лермонтовны,
Тукай белән бергә Пушкинны,
Бу күңелне шулар чиста тотты,
Дулкынында шулар юшкыны.

❁

Кечкенә шигырьдә олы фикер
Ак канатлы уйлар уйлата:
Күбәләктәй ярдан-ярга сикер,
Агым сулар булып моң ята.

❁

Бу ямьнәрдә бардыр минем өлеш,
Бу гамьнәрдә — минем йөрәк ярам.
Бөтен дөнья серен белгән килеш,
Сары яфракларга басып барам.

❁

Бу шәһәрдә Ленин урамы бар,
Яшел урам, төзек, киң урам.
Киң урамнар кебек уйларым бар,
Ленин урамында мин торам.

❁

Яманнан яхшы туса — тиңе булмас,
Яхшыдан яман туса — име булмас,
Бабайлардан калган акыллы сүз —
Менә ипи, әнә кояш.

❁

Чын күңелдән әйткәнемә ышан:
Зәңгәр-зәңгәр һаваларга очам.

Ай калыккан урман өсләрендә,
Ак болытлар керә төшләремә.

Таң җилләрен көлеп алкышладым,
Тын күлләрдә йөзә аккошларым.

Иркен сулап, урманнарга керәм,
Һәр яфрагы миңа сәлам бирә.

Ат уйнатып, үтәм авыр юлны,
Патша кызы миңа гашыйк булды.

❁

Урманлы офыклар алсу,
Һәр яфрак саен бөре.
Һәр куак төбендә калсын
Яшәүнең яшел сере.

Илаһи серле бу үрләр,
Сагаеп, сокланып йөр:
Йолдызлы күгендә серләр,
Һәр чәчәк чугында сер.

❁

Көзге урманнарга сызгырып кер,
Моңаеп йөр шәрә урманнарда,
Үткәннәрне уйлап, сызланып йөр,
Киләчәккә кара хыялларда.

Нинди өмет белән яши урман,
Ниләр уйлый сары яфрак иле?
Тынып калган үзәннәрдә томан,
Өзеп-өзеп исә җиләс җиле.

❁

Бездән соң да дөнья матур булыр,
Киткән казлар кире кайтыр әле.
Болыннарга яшел шаукым тулыр,
Тукранбашлар чәчәк атыр әле.

Болын чәчәкләрен җилләр сөеп,
Исән-таза торсын җир-су гына.
Киткән кызлар кире кайтмый диеп,
Ак болытлар агар моңсу гына.

❁

Мин туганчы, миң ел торган бу тау,
Мин үлгәч тә калыр тау булып.
Бакыр табак кебек ай калыккан,
Пугач патша килгән яу булып.

Йокымсырап яткан күксел дала,
Төнбоеклар үскән су кебек.
Ак болытлар, күк болытлар ага,
Әйтеп булмый торган уй кебек.

❁

Мин дә җиң сызганып план кудым,
Эшче класс идем үземә күрә,
Тимер юна торган станогым
Әйләнә дә, төшләремә керә.

... Чүпрәк белән тәгәрмәчен сөртәм,
Крестьян атын сөйгән кебек.
И, егетләр, утыз биш ел үткән,
Бер әйләнеп кенә килгән кебек.

Ышанычлы бүгенгебез,
Ышанычлы иртәгебез,
Шуңа күрә авыр йөкне
Җиңел итеп күтәрәбез.

Сискәндерә, ымсындыра
Тирәнлекләр, биеклекләр.
Һәр яңа көн сорап тора
Кыюлыклар, егетлекләр.

Бер карасам үткән көннәремә,
Үкенечләр төшә хәтергә:
Бик күп, бик күп яхшы кешеләргә
Онытканмын рәхмәт әйтергә.

Үткән көннәремнең соры төсен
Әкиятләрем белән әйбәтләдем.
Болыннарда гөлләр булып үссен
Әйтелмичә калган рәхмәтләрем!

Заман куша ил сайлаган юлдан
Таптанмыйча алга барырга.
Кайсы чорда юллар такыр булган?
Хәвефле дә булыр, авыр да.

Иң кадерле сүзен әйтте халык,
Өмет белән әйтте нык уйлап:
Шешә тотып булмый алга барып,
Җиңү яулап булмый күз буяп!

Урман артларында кояш баткан
Зәңгәрләнеп килгән кич иде.
Кыяр-кыймас кына чәчәк аткан
Бик оялчан, изге хис иде.

Уйлап килгән сүзләремне җуйдым,
Шаулый иде нарат урманы.
Кулларыннан тоттым,
Көлгән булдым,
«Яратам» дип әйтеп булмады.

Мин үземдә нәфис сафлык тоям,
Авыр эшнең качмыйм берсеннән дә.
Кеше җанындагы тапны юам,
Көлә-көлә юам, көрсенәм дә...

Тагын бер кат Тукай килсен иде
Кыңгыраулар таккан пар атларда.
Тагын бер кат Тукай килсен иде...
Симез яңакларны яңакларга!

Әй, дала иркен, дала иркен,
Болытлар ага төркем-төркем.

Әй, сулар тирән, сулар тирән,
Тормыш турында уйлар тирән.

Әй, таулар биек, таулар биек,
Олы максатлы гомерләр кебек.

## Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ТАҢАНА

хикәя



Вавилоннарны буйсындыргач, мидәннәр шаһы Бөек Кир массагетларны яуларга уйлады. Алдагы дошманы хакында күбрәк хәбәрдар булу өчен, ул сараена вәзирен чакыртты. Каршысына килеп басу белән, шаһының ни теләвен аның сүз сөрешеннән үк аңлап алган вәзир болай диде:

— Бөек Кир, массагетлар — күп санлы, батыр халык. Алар гүя җирнең үзеннән туалар. Кирәк чакта тиз арада елга-тугайлардан, чүл-далалардан, тау араларыннан бер төбәккә җыелалар да өермәдәй яуга чыгалар. Атлары житез, мәргәннәре күп, кылычлары үткен, сөңгеләре озын, калканнары җиңел, нык. Бер кузгалгач, кырылып бетсәләр дә, туктый белмиләр. Орыш кырында үлү алар өчен дан санала. Илләре бездән төньяк-көнчыгыш тарафта, Чулман елгасы тирәләрендә. Массагетларны греклар «скиф» дип, ә табгачлар «сөн» дип йөриләр.

Шаһ аны бүлдермәде, игътибар белән тыңлый бирде.

— Чынында исә, шөһрәтлебез, массагетлар сак һәм сок кабиләләреннән тора. Сак дигәннәре мал-туар асрап көн күрә, сок дигәннәре иген игә, калаларда яши, һөнәрчелек белән көн итә. Гореф-гадәтләре дә, тоткан йолалары да бер үк. Саклар да, соклар да ат өстендә орышалар, җәяүле алайлары да бар. Кораллары — ук-җәя, сөңге, айбалта, чукмар, кылыч, ятаган, хәнҗәр. Көнкүреш әйберләрен күбрәк алтыннан, җиздән ясыйлар. Очлымнары, путалары, калканнары, орыш киемнәре, ат кирәк-яраклары кадәр алтын белән бизәлгән. Янә шуны өстәп әйтәсем килә, шөһрәтлебез, массагетлар беркайчан да дошманнарына әсир төшмиләр: я орыш кырында ятып калалар, я үз-үзләрен үтерәләр.

Вәзир беравык тынып торды, аннары, шаһка түбәнчелек белән баш иеп, сүзен дәвам иттерде:

— Бөек Кир, массагетларның гайрәт-данын илләргә тараткан батыр илтабарлары Шөгер ата табгачлар белән орышта башын сала. Аның урынына яраткан хатыны Таңана утыра. Сәүдәгәрләр арасында Таңананың гүзәллеге хакында адәм ышанмаслык имеш-мимешләр йөри. Аны бер күргән ир-ат йокыдан кала, дөньяви ихтыяҗларын онытып, дивана хәлендә шул хатынга багышлап җырлар чыгара башлый имеш. Берәүләр аны ай-кояшның үзенә тиңли, икенчеләре, күргәннән соң, акылдан яза икән. Әмма, сез, шөһрәтлебез, аллаларга тиң зат булгач,

---

МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИН *(1927) — прозаик, ТАССРның атказанган культура работнигы, «Чоңгыллар», «Сулар үргә акса да», «Кубрат хан» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

хәвефләнер сәбәп юк. Шуңа күрә сезгә, шөһрәтлебез, бер киңәшем бар: массагетларга яу чапмагыз сез, әнә шул ай-кояшка тиң хатынга яучылар җибәрегез. Моның белән сез, шөһрәтлебез, ике отарсыз: беренчедән, гүзәллеге белән дөньяда тиңе булмаган хатын сараегызны бизәр; икенчедән, массагетларның балыкка бай елга-күлләренә, хәтфә үләнле далаларына, җәнлек-җанвар тулы урман-тауларына ия булырсыз. Бары тик гүзәлләрнең гүзәле Таңана сезгә кияүгә чыгарга разый булмаган очракта гына массагетларга яу чабарсыз...

Вәзир шөһрәтле шаһына тагын бик күп нәрсәләр сөйләде. Сөйләгән саен Бөек Кир бу ил белән ныграк кызыксына барды. Ул бернәрсәдән дә курыкмады. Кыска гына вакыт эчендә ул ни куәтле вавилоннарны, аккадларны, лидияләләрне яулады. Шунлыктан, массагетларны да җиңәчәгенә шикләнми иде. Нинди генә илгә яу чапмасын, ул һәрчак җиңде. Шул сәбәпле аңа шаһиншаһ (патшалар патшасы) Бөек Кир дигән исем бирделәр. Әнә шул кеше ниндидер варвар хатыннан куркып торсынмы? Гүзәл булмагае! Аның бик күп зифа һәм сылу хатыннар кочагында ятканы бар. Ул иң әүвәл — хаким. Хакимне яратмаска хаклары юк. Гүзәлләрнең гүзәле булса да, Бөек Киргә кияүгә чыгар ул хатын. Чыкмаган хәлдә, илен-халкын көчләп буйсындырыр, ай-кояшка тиң хатынга көчләп өйләнер.

— Вәзир, мәхәббәт — ни ул?

— Мин сезне аңлыйм, шөһрәтлебез, ул нәрсә сезгә яттыр. Аллалар дәрәҗәсенә ирешкән шәхес мәхәббәткә мохтаҗ түгел. Бу — хакыйкать. Аның өчен сезгә гади кеше булу кирәктер.

— Шушындый зур дәрәҗәгә ирешкән шәхес гади кеше була аламы соң?

— Юк, шөһрәтлебез. Тау башына менгәч, кеше гади була алмый. Сез бүген дөньяның иң биек тау башында торасыз.

— Дөрес уйлыйсың, вәзир. Әйт әле миңа: Таңана гади кешеме соң?

— Ул хатын-кыз, шөһрәтлебез. Массагетларча уйласак, хатын-кыз шаһинә булуга ирешсә, тәңрегә тиңләшә икән.

— Мин бик күп илләрнең патшаларын буйсындырдым. Алар арасында бер генә хатын-кыз да булмады, вәзир.

— Әүвәлге сүземә куәт өстим: җибәрегез яучыларыгызны Таңанага. Ышаныгыз, тиздән массагетларның гүзәле сараегызда булыр.

— Син хаклы, вәзир. Ил башында хатын-кыз утырган дәүләтне кан коймыйча да яулап булыр. Массагетлар илен буйсындыргач, Мисыр фиргавеннәренә — иң куәтле дошманыма юнәлермен!

— Хыялыгыз татлы, шөһрәтлебез. Массагетларны да канат астына җыйгач, олуг Мисыр дәүләте беркая да китә алмас.

Бөек Кир вәзиренең киңәшен тотты. Аның үзен баш яучы итеп, массагетлар иленә яучыларын җибәрергә булды. Бүләк-малны кызганмады, мул итеп төятте, массагетларның шаһинәсен байлыгы белән шаккатырырга ниятләде.

— Таңананы күреп кайт,— диде ул илчесенә.— Чынлап та ай-кояшка тиң гүзәлме икән? Сәүдәгәрләр сөйләгәнчә үк матур булмаса, илен кылыч белән яулармын.

* * *

Сарман углан Алтынтоякның тезгенен бушатты. Атка юл таныш. Моннан аның күп тапкырлар үткәне бар. Әүвәлге иясе Шөгер ата белән Кандыр ата бертуганнар иде, аралашып яшәделәр. Туган иленә кайтып баргангамы, җайдак тыныч кебек иде. Әмма Алтынтояк — бик сизгер ат, иясе тезгенгә кагылдымы — юыртып китә, ә инде тезген бушадымы — адымга күчә. Ул да түгел, иясе уянып киткәндәй:

— Һоп, Алтынтояк! — дип дәшә.

Юртакка шул житә кала, томырылып, алга оча. Шул мәлдә ат белән җайдак күләгәсе рәшә тибрәлгән офыкка барып тоташа, ут ялкынына әверелеп, тоташ алсу тәскә керә, дала тулып дулкынланган кылганнар диңгез сыман кинәя, чиген югалта, ат тоягы астыннан утлы очкыннар чәчри. Ат иясенә гүя канат үсә, һәм ул, күңеле тулышудан әсәрләнеп, кычкырып җырлап җибәрә:

Тауда йөрер юлбарыс,
Яуда йөрер баһадир.
Яуда йөргән баһадирга
Гүзәл кызлар багадыр.
Ана күңеле — балададыр,
Бала күңеле — далададыр...

Иясе җырлап туктауга, Алтынтояк дәртләнеп пошкыра, башын чайкап куя, шул чак йөгән җизләре зыңлап китә. Зыңлауда үз аһәңен табыпмы, әче итеп йомран сызгыра, куе кылган арасында тычкан аулаган карсак төлке бер мизгелгә сагаеп кала, өч аягына баскан килеш, сискәнеп, җайдак ягына күз сала, ул да түгел, ат аягы астыннан диярлек куян баласы сикереп чыга да, арт санын сәер сикертә-сикертә, үлән арасына кереп югала, күңелне җилкендереп, пырлап, кыр тавыклары күтәрелә. Гомере далада узган Алтынтоякның берсенә дә исе китми, өркеми, бары тик һәр тавышка, һәр ят хәрәкәткә: «Ә-ә, синмени әле бу!» — дигәндәй, очлы-сизгер колакларын әле бер якка, әле икенче якка тырпайткалап ала. Ә бит әлеге гадәти тыныч далада Алтынтоякның хәтәр хәлләргә дучар булганы бар. Ул сызгырып очкан дошман укларына күп тапкырлар каршы чапты, килер шәптән Ра (Идел!), Аракс, Җаек, Чулман, Ык, Ярсу (Агыйдел!) елгаларын йөзеп кичте. Курку белмәс, батыр йөрәкле әүвәлге иясе бер тапкыр да аны рәнҗетмәде. Еш кына алар бергәауга чыктылар, соры-саргылт сыртлы дала бүреләрен, канат куйсаң очып китәргә житкән җәйраннарны кудылар. Иясе аларның кайсыларын укка алды, кайсыларын чукмар белән орды. Былтырларны көнчыгышка таба яу чапканда, дошман белән очрашып, батырга батыр чыкты иясе һәм шунда башын салды. Яудан кайткач, аны иясенең угланы Сарманга бирделәр. Әүвәл яңа иясенә баш бирмәскә теләде Алтынтояк. Үрле-кырлы сикерде, ятсынып, читкә тайпылды. Шунда аның янына, ягымлы-татлы һәм йомшак итеп дәшә-дәшә, элгәреге иясенең хатыны килде. Ул шундый итеп дәште ки, Алтынтояк ирексездән шул хатынның кулларына үрелде, йомшак иреннәре белән уч төбендәге эремчекне ялап алды. Шуннан соң тылсымга ия хатын Алтынтоякның тезгенен угланы Сарманга бирде. Бу адәмдә дә таныш ис тойды Алтынтояк, бу адәм кулыннан да эремчекне йомшак иреннәре белән кабып кына алды. Иң мөһиме, ул аны ягымлы тавышлы хатын атланып йөри торган Кашка биядән аермады. Алтынтояк Кашка бия белән бергә болында утлады, аның белән бергә юл чыкты.

Алтынтояк җай гына юыртып китте. Кояш баешка таба тәгәри, ә аларның үтәр юллары шактый иде әле. Ләкин иясе тезгенгә кагылмады, уйланып бара бирде.

Әйе, уйланырлык иде массагетларның ермак алай баһадиры Сарман угланга. Бер атна элек Төп илгә мидәннәр шаһыннан яучылар килеп төшкәч, ул тәмам йокыдан калды. Берничә тапкыр анасы чатырына керергә теләде, әмма Таңананың җан сакчылары һәрчак юлын бүлә тордылар. Өч көн, өч төн кунак итте Таңана дөньяга даны таралган Бөек Кир яучыларын. Бу көннәрдә Сарман углан ни кылырга белми ярсынды, ахыр ачынуын анасына җиткерде — кабул итмәсә, ул Кандыр ата ярына китәчәк. Шуннан соң гына Таңана угланны кабул итте. Анасы аңардан берни дә яшермәде, барысын да сөйләп бирде. Мидәннәр шаһы Бөек Кир аңа өйләнергә тели икән.

Таңана боларны сөйләгәндә, Сарман углан анасының күзләренә күтәрелеп карарга базмыйча торды. Ә бит бу алтынга бизәлгән тәхеттә ул утырасы иде. Әмма ыруның аксакаллары башкача хәл иттеләр:

Сарманны яшьсенеп, углан балигъ булганчы дип, Таңананы илтабар итеп күтәрделәр. Таңана тәхеткә утыруга, Төп илгә табгачлардан яучылар килде. Көнчыгыш Табгач иленең олуг ханы Таңананың кулын сораган иде. Таңана, бу хакта киңәшү өчен, чатырына Сарман угланны, аксакалларны җыйды. Ул чакта Сарман углан дәшмәде, ә аксакаллар исә Табгач ханына Таңананың кияүгә чыгуын хуп күрделәр. Әмма Таңана үзе риза булмады. Ханның яучылары буш кул белән кайтып киттеләр. Монда ни?! Миданнәр шаһы яучылары янына Таңана берәүне дә кертмәде, хәтта Сарман угланны да. Әллә соң бу миданнәр шаһы Бөек Киргә кияүгә чыгарга риза булуымы?.. Әнә шул сорау борчый иде анасы каршына килеп баскан угланны. Тавышын тыярга тырышып һәм алдына тезләнеп:

— Анам,— диде ул,— сез миданнәр шаһы Бөек Киргә кияүгә чыкмассыз ич?

Сарман углан тәхеттә утырган анасы белән ике арага алтын йөгерткән очлымын, тимер хәнҗәрен, билендәге ятаганын салды. Бу аның ана теләге белән килешмәү билгесе иде.

— Углан, ни дигән сүз бу?!

— Анам, яучылар ерак китмәделәр әле, мин аларны куып җитәрмен... Боерыгыз!

— Углан, йөгән кидермәс борын атка атланмыйлар, егылып имгәнүең бар. Әйе, углан, миңа миданнәр шаһы Бөек Кир яучылар җибәргән. Мәгәр шаһның хәйләсе билгеле: миңа өйләнеп, канаты астына ил-халкымны да җыймакчы. Яучыларга тимә, углан, китә бирсеннәр — мин аларга ризалыгым бирмәдем. Бер-ике ел сабыр итәргә куштым. Сыныйсым килә: ихласмы Бөек Кирнең мәхәббәте? Ихлас булмаган хәлдә, яучылары кайткач ук, ул безгә яу чыгар. Бөтен дөньяны канат астына җыйган Бөек Кир бу гарьлеккә чыдамас, татулык белән буйсынмаган массагетлар илтабарын көч белән алырга тырышыр. Без моңа әзер булыйк, углан. Мин сиңа йомыш-йөк салам: кардәш ыру Кандыр атага бар. Төп илне йоларга килсен. Кандыр ата — миданнәр белән орышкан кеше. Мин бүген аның ярдәменә мохтаҗ, углан.

— Анам, Кандыр ата килерме? Син аны, Бөек Кирне рәнҗеткән кебек, бик нык рәнҗеткән идең...

— Йөрәккә йөгән кидереп булмый, углан. Кандыр атага мин түгел, алтын тәхет кирәк иде. Аны исә мин сиңа саклыйм, углан.

— Кандыр ата монда килергә риза булмаса, анам...

— Углан, йөрәге булган ир-ат мәхәббәт дәшкән җиргә килми калмый.

— Син аны яратасыңмы, анам?

— Мин сиңа алай димәдем, углан. Мин түгел, ул мине ярата.

— Анам, аңладым. Бүген үк китимме?

— Бүген үк, углан. Менә сиңа биш таш.— Таңана Сарман угланга ялтырап торган ташлар бирде.— Һәр тумыш көндә берсен ташлый барырсың. Бишенчесен ташлаган көнне илдә булырсың!

— Анам, бишенче таш атылган көнне угланың илдә булыр. Игелегең бир!

— Кандыр атага әйт: миңа ачу тотмасын. Хаким кешенең мәхәббәте акылдан өстен була алмый.

Таңана, тәхетеннән күтәрелеп, Сарман углан янына килде, аны аягына бастырды, кояш сурәте төшкән алтын тәңкәне муенына асты, аннары келәмдә яткан коралларын алып бирде.

— Кош канатсыз, ир коралсыз була алмый. Юлдашың Тәңре булсын.

Таңана олуг Шөгер илтабарның иң яраткан хатыны иде. Иренә ул бердәнбер ир бала табып бирде. Шуның белән бүтәннәрнең һәммәсен күләгәдә калдырды. Угланына унбиш яз тулган җәйдә, Тәңре олуг Шөгер илтабарны үз янына алды. Шөгер атаның угланы тиздән ил тәхетенә утырыр. Углан атасы кебек үк озак еллар хакимлек итәр. Аңа төркиләр

дөньясында булган бөтен кан-кардәш ырулар килеп баш орыр. Остазы Кандыр атаны Сарман углан уң ягына утыртыр. Кандыр би аның ярына күчеп килер.

Әле күптәнме әнә шулай дип хыялланып йөри иде Сарман углан. Әмма ул дигәнчә булмады. Аксакаллар, Сарман угланны яшьсенеп, тәхеткә Таңананы утырттылар. Бу хакта ишеткәч, Сарман углан анасы катына килде һәм аңа, Кандыр атага кияүгә чыгарга кирәк, дип әйтте. Углының авызыннан бу сүзләрне ишеткән ана, рәнҗүен сиздереп: «Илтабар исеменнән хөкем йөртер көн килмәде әле сиңа, балам, тыел!» — диде.

Шул хәлдән соң Сарман углан остазы Кандыр ата хакында анасына бер тапкыр да сүз катмады. Кандыр ата исә үз җәйләвенә — Өске илгә кайтып китте. Ә бит Таңана риза булган хәлдә Өске җәйләүгә угланны җибәреп, үзе төп илдә дә кала ала иде...

Килерме, тыңлармы Кандыр ата Сарман угланны, килерме Төп илне мидәннәрдән якларга? Юл буена шуларны уйлап барды Сарман углан.

Кичкә таба дала тагын да киңәя төшкән кебек булды — углан зәңгәр тасмадай бормаланып аккан Чулман елгасы буена килеп чыкты. Атын юырттырып, елга буена төште, малкайны эчерде. Елга өстендә акчарлаклар кычкыра, үрдәкләр бакылдый, казлар каңгылдый. Башка вакытта булса, Сарман углан атын үз иркенә куеп, симез каз-үрдәкләрне укка алыр иде, бүген исә ул аларны гүя күрмәде дә.

Аты эчеп туйгач, Сарман углан ярга күтәрелде һәм беравык сабыр гына баргач, җилле генә юырттырып, яр буйлап китте. Ул арада кояш баеды, Сарман углан, путасына таккан капчыктан бер ташны алып, суга атты. Илгә әйләнеп кайтырга аңа дүрт туар көн калды. Бишенче таш атылуга, илгә әйләнеп кайтмаса, массагетлар илтабары Таңана угланын эзләтергә җибәрер һәм ыру куштаннары аны, бик тиз табып, илгә алып кайтырлар, аксакаллар боерыгын төгәл үтәмәгән өчен, хөкем итәрләр.

Сарман углан тиздән Кандыр ата җирләре башланачагын чамалап белә иде. Ил — саксыз, дала — җайдаксыз булмый, тиздән аны Кандыр ата сакчылары чик буенда туктатырлар. Шулай дип уйлап бетермәде Сарман углан, каршысында дүрт җайдак пәйда булды.

— Юлчы кая юл тота? — дип сорады арадагы куштаны, алгарак чыга төшеп.

— Юлбашы Кандыр ата ярына, баһадир,— диде Сарман углан.

— Чапкычымы, узышчымы?

— Чапкычы да, узышчы да түгел, Төп илдән хәбәр китерүче.

— Хәбәрең игелеклеме, яманмы?

— Яманга — яман, игелеклегә — игелекле, баһадир.

— Кардәш кеше — түремдә, кунак булыр илемдә. Йомышың сорамыйм. Атың кем дийк, юлчы?

— Атым, кардәш, Шөгер илтабар угланы Сарман баһадир буламдыр.

— Игелегең белән илгә кил, олуг Шөгер илтабар угланы Сарман. Кунар өең миндә булыр. Яңа көн тууга, Кандыр ата ярына илтермен. Инде белеп тор, баһадир, сәне алып китүче каравыл алып Таптимер буламдыр.

Кояш чыгып, көнне каршы алгач, Сарман угланны Кандыр ата ярына алып килделәр. Чәч-сакалы чалара башлаган ир уртасы Кандыр ата аны аягүрә басып каршы алды, кочагына алып сөйде. Шуннан соң гына ыруның аксакалларын чакырырга боерды. Барысы да кереп утырышкач, Сарман угланга йомышын җиткерергә кушты. Илче барысын да түкми-чәчми сөйләп бирде.

— Нә йомыш белән генә килмәсен, углан әүвәл ант эчсен,— диде аксакалларның берсе.

— Ант эчсен, ант эчсен! — диештеләр калганнары.

Шундук алтын төпсәгә салып, ике йомры китерделәр. Йомрыларда кымыз иде. Сарман углан хәнҗәрен чыгарды, бармагын төртеп канатты һәм тамчы-тамчы йомрыларга тамызды. Шуннан кымызны тәмләп карады һәм Кандыр атага сузды. Кандыр ата да эчемлекне тәмләп карады, аннары янәшәсендә торган ияр өстенә түкте, икенче йомрыны Сарман угланга бирде — илче йомрыдагы эчемлекне үзе утырган тумәр өстенә сипте.

— Әүвәлгесен кылды, килерен кылсын,— диде аксакаллар.— Уңай ягың кем белән?

— Остазым Кандыр ата, каным акканчы уңаем синең якта булыр. Тәңрем белән ант эчәм.

— Кандыр ата, ышанма угланга. Таңана угланны алдаган,— диде аксакалларның берсе.— Бөек Киргә каршы сүз катмагандыр. Ир-ат бер алдашса, хатын-кыз ике алдашыр ди. Углан — монда, ә Таңана Кир янына җыенып ятадыр. Кан кардәш булса да, былтыр үзе синнән баш тартты. Миданнәр шаһыннан йөз чөермәс, аның даны-шөһрәте бөтен дөньяга таралган. Таңана — хыянәтче!

Сарман углан әкрен генә тумәреннән күтәрелде һәм шушы яман сүзләрне әйткән ап-ак сакаллы картка текәлеп карады, әмма шундук кире урынына утырды. Аксакалның сүзләрендә ул кисәк хаклык күрде. Чынлап та шулай булса?.. Анасы, аннан котылу өчен генә, углын Кандыр ата иленә җибәргән булса?..

Сүз сөрешнең кай тарафка таба кузгалуын күреп, Кандыр ата торып ук басты.

— Хөрмәткә ия аксакал Тугрыл, монда угланның языгы бармы? Юк! Углан безгә хәбәр китергән. Таңана безне Төп илне явыз Кирдән саклаарга чакыра. Чакыру — аның эше, ә менә бару-бармау — безнең эш. Әйт, Тугрыл, әйт сүзең, сән бару ягындамы, бармау ягындамы?

— Мин ни, мин кардәшләргә ярдәмгә бару ягында, Кандыр.

— Кылдыкмы шулай, аксакаллар?

— Кылдык, Кандыр, кылдык...

— Инде тыңла, Сарман углан. Кандыр атаң бүгенге көннән алып ике тапкыр җиде көн, җиде төн узган вакытка Төп илдә булыр. Мин әйттем.

Таңана өчен борчулы көннәр башланды. Ил чигендә сакта торучы алыплар хәбәр ташый торалар: миданнәр шаһы Бөек Кир бихисап гаскәре — чирүе белән Аракс елгасы буйлап Төп илгә таба килә. Кай төбәктә тукталыр, кай тирәләрдә елганы кичәргә итәр? Әнә шул сорау борчый иде Таңананы. Телиме моны, теләмиме Бөек Кир, барыбер елга аша күпер салыр. Елга аша җәнлек ауламыйлар. Кай тарафта күпер салыр Бөек Кир, шул төбәктә орыш булыр. Шуны белү өчен, Таңана һәркөн күзәтүчеләр җибәрде. Бөек Кир елга аша күпер салганчы, Таңананың аңа сүз катасы килә иде. Ни тели шаһиншаһ массагетлардан? Чынлап та, бер Таңана өчен шул хәтле чиру белән килүеме? Әллә шул хәйлә белән массагетларның бөтен ил-җирләрен биләргәме исәбе? Ни генә булмасын, Таңана, орышны булдырмас өчен, барысын да эшләр. Ул моның өчен бөтен булган хатын-кыз хәйләсен җигәр. Бары тик Бөек Кир аның тәкъдимнәреннән баш тарткан очракта гына Таңана аның белән орышыр. Юк, җиңел генә бирмәс ул ил-халкын. Инде һични кылыр чарасы калмаса, ул аңа кияүгә чыгарга риза булыр. Бары тик халкы, туган иле генә исән калсын. Анда да ул аңа бер шарт белән кияүгә чыгар: әүвәл ул Кирне чирүе белән иленә кайтарып җибәрер, аннары массагетлар тәхетенә Сарман угланын утыртыр, шуннан соң гына үз җае белән миданнәр иленә юл алыр. Тәңре шулай язган булса, нәкъ шулай кылыр. Язмыштан узмыш юктыр.

Соңгы көннәрдә Таңана ни сәбәпледер угланы өчен артыграк кайгыра башлады. Әле аңа угланы елганы кичеп чыгар да миданнәргә ташланыр, ташланыр да әсир төшәр, әсир төшәр дә газиз башын әрәм

итәр кебек; әле Бөек Кир угланның башын кисеп, колгага утыртып, елга аша Таңанага күрсәтер кебек... Бу куркы аңа күптән түгел генә килде. Ана күңеле нидер сизенә, шомлана иде. Шуңа күрә Таңана угланны бүген күзәтчелеккә җибәрмәскә карар кылды. Уй-ниятен тормышка ашырырга теләп, ул туып килгән көнне каршы алырга, чатырыннан чыкты. Шундук аның янына җиз таз белән җиз комган тотып, хезмәтчесе килеп басты. Хезмәтчесенә күтәрелеп тә карамастан, Таңана җиңен сызганды, салкын чишмә суы белән бит-кулын юды. Шуннан соң гына туып килгән көнне каршы алды. Тәңрегә булган кайгысын җиткергәч, әйләнеп, елганың түбән ягына бакты. Анда түбән таба төшеп баручы угланның ермак чирүен күрүе булды, әчеттереп, йөрәге кысылып куйды. Җитмәсә шул яктан ниндидер яман тавышлар килгән төсле тоелды. Әллә соң ыстан шулай уянамы? Шулай гына бугай, Таңана ыстан тирәли күз йөртте. Сугышчылар, хатын-кызлар, бала-чагалар, карт-корылар чатыр-тирмәләреннән чыга, туып килгән көнне каршы ала да үзенә, иленә, ыру-кардәшләренә игелекле көн теләп, елгага таба юнәлә иде.

— Эремчек белән кымызмы, балыкмы, казылыкмы бирим, илтабарым? — диде ашчысы, баш орып.

— Атым китерергә боер,— диде Таңана, ашчы ягына карамый гына.

Күп тә үтми, Таңанага Кашка бияне китерделәр. Массагетларның илтабары ир-атларга хас житезлек белән атка атланды, чуклап үргән тезгенен кулына алды. Шунда Таңана янына җансакчысы килде.

— Нә булды, батырым? — Таңана тыныч булырга теләде, әмма җансакчысын күрүгә үк, йөрәге кысылып куйганын тойды.

— Таңана, сөенче! Кандыр ата алыплары белән елганың өске ярына килеп ыстан туктады.

— Өске ил бие Кандыр өчен минем чатыр ишеге һәрчак ачык булыр, баһадирым. Шулай дип җиткер Кандыр атага,— диде Таңана, җансакчысының соңгы сүзләрен ишетмәгәнгә салышып.

Җансакчысы китеп барды, Таңана югарыдан янә ыстанга күз йөртеп чыкты. Түр төбәктә аксакаллар табын тирәсенә җыела иде. Таңана атын шунда таба юнәлтте. Аксакаллар Таңананы аягүрә басып каршы алдылар, табын янына дәштеләр. Таңана атыннан төште, тезгенен хезмәтчесенә ташлап, табын янына килде, кадерле кунаклар өчен генә җәелә торган ак киезгә утырды. Ашчылар табынга азык-төлек китерә башладылар.

Таңананың кисәк кенә күңелен кырган нәрсә — Кандыр атаның аны үзенә дәшүе иде.

— Аксакаллар, катыбызга Кандыр ата килгән. Нә кылыйм, үз янына дәшә? — диде Таңана.

— Ил катына ир килгәндә, бил каешың буып бар, дигәннәр бабаларыбыз. Үзең бар, Таңана,— диде багучы карт.

— Багучым, мал — малны, кардәш — кардәшне юксыныр, дигәннәр борынгылар. Иллә миңа бер хакыйкать якын: елга тауга менми, тау елгага ишелә.

— Хак анысы, Таңана,— диде багучы карт, килешеп.— Алтын савытны атлап узулары кыендыр. Иллә, илтабарыбыз, без Кандыр ата кырына түгел, ул безнең кырга килгән. Илен яраткан — ирен дә яратыр, дигәннәр.

— Багучым, Кандыр ата минем ирем түгел, бары тик кан кардәшем. Килер бер көн, ир-канатны үзем сайлармын. Безгә бүген ул хакта уйларга оят булырга тиештер. Киңәшегез өчен игелегем алыгыз. Боерам: һәр җәя-ук йөртердәй, сөңге-кылыч күтәрердәй ир-ат орышка әзерләнсен. Илгә мидән шаһы Бөек Кир явы килә. Чирү саны җитмеш мең сугышчыдан торадыр. Әйтер сүзем шул иде сезгә, аксакалларым.

— Илтабар хаклы,— дип атылып чыкты аксакал Тургай.— Кандыр ата катына үзем барам. Килсен Таңана катына. Алда орыш торганда, тәхет бүлмиләр.

Кандыр ата аксакалларның киңәше белән килеште. Кичке якта, як-ягына җидешәр батыр тезеп, Таңана чатыры катына килеп туктады. Бер-берсенә сиздерми генә Төп ил тәхете өчен көрәш алып барган баһадир ир-ат һәм массагетларның илтабары Таңана икәүдән-икәү генә бик озак сөйләшеп утырдылар. Ахыр чатырдан чыктылар. Икесенең дә өстендә хәрби кием иде. Ак тай китерергә куштылар. Аннары бабалар каберлегенә юнәлделәр. Анда алар ак таш өстенә яткырып, ак тайны чалдылар һәм кылыч-хәнҗәрләрен изге канга буяп, бабалар кабере өстендә соңгы тамчы каннарына хәтле җир-суны сакларга дип ант эчтеләр. Дошманга бирешмәскә, инде дошман алардан көчлерәк булып, җиңә башласа, орыш кырында ятып калырга, әсир төшмәскә, Бөек Кирне куандырмаска!

Таңана кардәше Кандыр атага ни дә булса вәгъдә итмәде, әмма бик үк өзеп тә бетермәде. Ир-ат анты — кан белән, хатын-кызның — җан белән үлчәнә дип уйлавы иде. Кыскасы, ул ничек тә орышны булдырмаска тырышачак иде, ә моның өчен Таңана барысын да эшләр. Кирәк икән, явыз Кирнең үзенә кияүгә чыгар.

Икенче көнне бар булган чирүе белән илтабар Таңана елга буйлап түбән төште. Миданнәр шаһы Бөек Кир елга аша йөзмә күпер салып ята иде инде. Аръякта — тоташ сөңге урманы, күп илләрне буйсындырып, канат астына җыйган Бөек Кир массагетлар илен яуларга килгән иде. Күп орышларда катнашып чыныккан, җиңү татысыннан башканы белмәгән миданнәр. Бирге якта — гүзәл Таңана җитәкчелек иткән, дөнья халыкларына бик үк билгеле булмаган массагетлар. Көченә нык ышанган һәм үзен дөньядагы барлык кешедән дә өстен, хәтта аллага тиң күргән, моңа кадәр бер тапкыр да, беркемнән дә җиңелмәгән миданнәр шаһы Бөек Кир йөзмә күперне бер дә курыкмыйча, массагетларның күз алдында сала иде. Европаны, ярты Азияне канат астына җыеп бетерә язган каһарман фарсылар «ит ашаучылар» дип атаган ниндидер массагетлардан куркып торсынмы?!

Елга аша көпә-көндез йөзмә күпер салып ятучы миданнәрне күргәч, Таңана янына сөрәнчесен чакырып алды һәм аның исеменнән оран салырга кушты.

Таңана сөрәнчесе:

— Миданнәр шаһы! — дип оран салды.— Салдырма елга аша күпер! Кем белә, бәлкем син бу җирдә мәңгегә ятып калырсың. Кайтып кит чирүеңне алып туган илеңә, орынма безгә... Әгәр дә мәгәр син, миданнәр шаһы Бөек Кир, массагетлар белән орышырга исәп тотасың икән, монда күпер салып маташма, елганы без күрсәткән җирдән кич. Без моннан өч көнлек юл-ара агымга каршы чигенербез. Орыш кырыбыз шунда булыр. Орышны үз ягыңда алып барырга телисең икән, өч көнлек юл араны чирүең белән үзең чиген — орыш кырыбыз шунда булыр!

Бөек Кир массагетлардан бу сүзне ишеткәч, чатырына аксакалларын, вәзирләрен җыйды, алардан киңәш сорады:

— Чирүем белән елганы кичеп чыгаргамы, әллә инде өч көнлек юл-ара үтеп, массагетлар белән үз ягыбызда орышыргамы?

— Күрәм-күзәтәм дә, Бөек Кир, без бу илдә дәүләт төзи алмабыздыр. Җир исәбенә ил төзеп булмый. Көтеп алыйк баскан җиребездә массагетларны,— диде аксакалларның берсе.

— Хак әйтә, хак әйтә,— дип куәтләде аны калган аксакаллар.

— Ярый,— диде Бөек Кир.— Минем әсир Лидия патшасы белән дә киңәшәсем килә. Аны чатырыма чакыртыйммы икән?

— Киңәшле эш таркалмас, чакырт, Бөек Кир,— диеште аксакаллар.

Шул мәлдә вәзир сүз сорады. Бөек Кир аңа баш кагып кына рөхсәт бирде.

— Безгә монда орышырга ярамаган бер хикмәт бар, шөһрәтлебез,—

диде вәзир ашыкмый гына.— Массагетларның ил башында гүзәлләрнең гүзәле хатын-кыз тора. Мине, шөһрәтлебез, хәрби киемдәге хатын-кыз һәрчак куркытып килә. Андый хатын-кызны тик шул очракта гына буйсындырып була: мәхәббәт белән. Хода сиңа, шөһрәтлебез, бөтен дөнья халкы белән идарә итү мөмкинлеген бирде. Шулай булгач, хатын-кызга кылыч күтәргәнче, аны әүвәл мәхәббәт белән җиңеп карасагыз... Кылычың үткер булганчы, телең татлы булсачы, дигән шагыйрь. Ирләр хатын-кызны күз белән сөйсәләр, тел белән җиңәләр. Әйткән ди бер ир-атка бер гүзәл хатын: татлы ширбәт биргәнче, татлы телең бирсәңче.

— Ни сөйлисең син, вәзир? Массагетлар илтабары мине бөтен дөнья алдында хур итте: яучыларымны борып кайтарды. Мин — хаким, мин шөһрәткә ия кеше, ә шөһрәт ул, юлбарыс кебек, һәрчак яшь ит сорап тора. Мин шаһиншаһ, мин шөһрәткә ия, минем аллалар шикелле хөкем йөртер әмәлем бар!

— Ходага тезләнеп теләк теләү дә җитә, хатын-кызның йөрәген исә бары тик саф мәхәббәт белән генә җиңеп була, шөһрәтлебез.

— Вәзир, ул варвар хатын, гүзәллеге белән ай-кояшка тиң булса да, эчкерсез мәхәббәтемне кабул итмәгәч, бөтен ил-йортым алдында...

— Шөһрәтлебез Бөек Кир, сабыр итегез. Килер ул мәхәббәт Таңанага да. Сабыр төбе — сары алтын, килер сезгә ул горур хатын.

— Картлар гына сабырлык белән көтеп ала мәхәббәтне. Минем сабырым төкәнде, вәзир. Ул тәкәббер хатын елганы кичкәч үк алдыма килеп егылмаса, көч белән алырмын!

— Ил-халкын көч белән алсагыз да, йөрәген көч белән әсир итә алмассыз, шөһрәтлебез. Йөрәкне бары тик мәхәббәт белән яулыйлар.

— Мин буйсынмас йөрәкләрне көч белән әсир итәргә яратам, вәзир. Әллә синдә ике башмы, шаһиншаһың белән бик кыю сөйләшә башладың!

— Хаталандым, шөһрәтлем. Гүзәллек иң әүвәл горурлык икән ул, шуны аңламый хаталандым бугай.

— Гүзәллек — ул җиңү, варварларны буйсындыру, чибәр кызларын кол итү. Әһә, менә Лидия патшасы да килә. Ул әйтсен миңа ни кылырга тиешлегемне.

— Бөек Кир,— диде Лидия патшасы Крез.— Мин, әсир төшкән көнне үк, сезгә бәла-каза китермәм дип ант эчкән идем. Киңәшем дә ихлас күңелдән булыр. Сездән җиңелеп, тәхетемне, ил-йортымны югалттым. Язмышым аяныч, мин күргәнне башка берәүгә күрергә язмасын. Инде киңәшемне тыңлагыз, Бөек Кир. Әгәр дә мәгәр, үзегезне аллалар рәтенә куеп, үлемсез саныйсыз икән, мин сезгә киңәшче була алмыйм. Аллалар алдында мин көчсез, алар миннән йөз чөерделәр. Ничек телисез, шулай кылыгыз. Әгәр дә мәгәр, Бөек Кир, үзегезне безнең кебек гади кеше итеп күрәсез икән, иң әүвәл бер нәрсәне исегездән чыгармасагыз иде: дөнья, тәгәрмәч тугымындагы ялгау кебек, әйләнә дә бер баса. Моның белән шуны әйтергә телим — дөньяда гел бер халык кына бәхетле була алмый. Сез буйсындырган вавилоннарның дан-шөһрәтеннән һәммә халык тетрәп торыр иде. Бүген алар аягыгыз астында.

— Бөек Кир,— дип кабаланып күтәрелде аксакалларның берсе.— Әсир төшеп, бар хокуктан мәхрүм ителгән Лидия патшасы киңәшләрен тыңлаганчы, әүвәл аксакалларның сүзенә колак салыр идегез. Кем сезне шаһиншаһ итте? Кем сезне алтын тәхеткә утыртты? Мидәннәр. Без булдык. Шулай икән, әүвәл безнең киңәшне тыңлагыз. Без исә сезгә елга аша күпер салмаска, аны кичмәскә, массагетларны бире чыгарга мәҗбүр итәргә дигән киңәш бирәбез. Ил кадерен — җир саклар, дигәннәр бабаларыбыз.

— Бөек Кир, мин дә киңәшемне әйтеп бетерим, андый эш таркалмас. Теләсәгез, алырсыз киңәшемне; теләмәсәгез, җаныгыз кушканча кылырсыз. Бөек Кир, мин сезгә аксакаллар биргән киңәшнең киресен эшләргә тәкъдим итәм. Бар булган чирүегез белән елганы кичегез дә массагетларны ил түрләренә чигенергә мәҗбүр итегез. Бу киңәшемдә

ике мәгънә ятадыр. Бөек Кир. Беренчедән, бу як ярга чыккан массагетлар сезне җиңә калалар икән, инде беркайчан да кире илләренә әйләнеп кайтмаслар, монда торып калырлар, ул гынамы, үз җирләрегезне яуларга керешерләр. Икенчедән, чын куәткә ия ир-атлар хатын-кызны беркайчан да үз катына чакырып китермәгәннәр, һәрчак яулап алганнар. Иллә максатыгызга җиңел генә ирешү өчен, мин сезгә бер хәйлә кулланырга тәкъдим итәм. Белгәнемчә, Бөек Кир, массагетлар исерткеч эчемлекләр кулланмый. Елга аша йөзмә күперне салыгыз. Сез елганы кичә башлау белән, массагетлар илтабары сүзендә торыр — иле түренә чигенер. Шуннан соң сез чиреүгез белән бер көнлек юл-ара үтәрсез дә мул итеп табын әзерләрсез. Табынга эчемлекне кызганмассыз. Аннары табын янында бер өлеш әсирләрдән торган сугышчыларыгызны калдырырсыз да кире елганы кичкән төбәгегезгә әйләнеп кайтырсыз. Массагетлар түзмәсләр, табын янында калган чирүегез янына килерләр. Килерләр дә орышка ташланырлар. Җиңәрләр, аннары җиңгән шатлыктан табынга сыйланырга утырырлар. Алар исерешкәч кенә, сез әйләнеп килерсез дә аяктан егылган массагетларны кырып ташларсыз. Шулай итеп, сез Таңана чирүенең бер өлешеннән җиңел генә котылырсыз. Ул гынамы, чирүегез йөрәгенә җиңү коткысы салырсыз. Әйтер сүзем, бирер киңәшем шул иде минем сезгә, шаһиншаһ.

Бөек Кир кул селтәде, һәм Лидия патшасы Крезны алып киттеләр. Миданнәр шаһы, башын күтәрмичә, бик озак уйланып утырды. Ахыр ул башын күтәрде, аксакалларына күз йөртеп чыкты, аннары:

— Вәзир калыр, сезгә китәргә мөмкин,— диде.

— Бөек Кир, мин Лидия патшасы киңәше белән килешәм,— диде вәзире.

— Боерам, вәзир. Елга аша күпер салырга, ә массагетларга, өч көнлек юл-ара ил түрләренә күчәргә дип оран салырга!

Таңана сүзендә торды. Бөек Кирдән шул хәбәрне ишетүгә, өч көнлек юл-ара артка чигенде, һәм ыстан туктады. Туктады да янына Кандыр атаны чакыртты. Бераздан алар Сарман угланны дәшеп алдылар. Бик озак өчәүдән-өчәү генә киңәштеләр. Һәм иң әүвәл ермак чирүе белән Сарман угланны күзәтчелеккә җибәрергә булдылар.

Иртәнге якта, туып килгән көнне каршы алгач, Сарман углан үзенең баһадирлары белән күзәтчелеккә чыгып китте. Шуннан углан әйләнеп кайтмады.

Ә анда менә мондый хәлләр булды.

Сарман углан бер көнлек юл-ара узуга, миданнәргә тап булды. Һәм күп тә үтми, көчле ермак чирүе белән Кирнең алгы гаскәрен кырып бетерде. Бер генә мидән сугышчысын да әсир итмәделәр, илгә басып кергән дошманнарга карата ачулары яман иде. Сарман угланның дошман белән тәүге тапкыр күзгә-күз очрашуы иде, ул аеруча ярсынып орышты. Мидән сугышчыларын кырып бетергәч, җиңү шатлыгыннан табынга утырдылар. Һәм гомерләрендә беренче тапкыр миданнәрнең эче эчемлеген татып карадылар. Татлы да, эче дә кебек иде эчемлек. Тагын-тагын салып эчтеләр, исерештеләр, җырладылар, биеделәр, аннары кайсы-кая тәгәрәштеләр дә йокыга талдылар. Күп тә үтми, Бөек Кир төп алае белән әйләнеп килде һәм йоклап яткан массагетларны һичнинди югалтусыз кадап, чәнчеп үтереп бетерергә боерды. Бары тик затлы киенгән бер кешене калдырырга, битенә су бөркеп уятырга кушты.

Салкын су бөркүгә, Сарман углан сикереп торды һәм билендәге хәнҗәренә үрелде. Әмма баһадирның билендә хәнҗәре, путасында кылычы юк иде. Углан табын тирәли кан эчендә яткан иптәшләрен күрде дә, очлымын салып ташлап, чәчләрен йолкый-йолкый еларга тотынды. Әсир төшерелгән угланның бу кыланышын күреп, вәзир аның кул-аякларын бәйләргә әмер бирде. Угланның кул-аякларын бәйләп, шаһиншаһ каршына китерделәр.

— Вәзир, бу кем? — дип кинаялэп сорады Кир.

— Массагетларның шаһинә угланы, шөһрәтлебез.

— Ә син, вәзир, массагетлар беркайчан да әсир төшми дигән идең түгелме? Инде бак, кем басып тора каршыбызда?

— Әйткәнемчә, гүзәлләрнең гүзәле Таңана угланы, шөһрәтлебез.

Бөек Кир, зөбәрҗәт ташлы алтын балдак кигән имән бармагы белән күккә төртә-төртә:

— Таңана угланы!— дип кабатлады.

Мидәннәр шаһының башында алтын тәңкәләр, затлы ташлар белән бизәлгән очлаеп килгән баш киеме иде. Алтын тәңкәләр бизәгән түшен кара сакалы каплый, көмеш җепләр белән тукылган тукымадан тегелгән чапаны аяк очларына кадәр житә, кан кызыл итек башында да алтын бишташ. Ике ягында ике җан сакчысы. Уң эргәсендә — вәзире, сулында — баһадиры. Бөек Кирнең каршында — ике сакчы арасында, кул-аяклары бәйләнгән Сарман углан. Гаҗәбе шул иде: мидәннәр шаһы угланга, хатын-кызларга карагандай, сокланып карады. Әүвәл ул угланның яшьлегенә сокланды, аннары гәүдә-сынына. Ә инде йөзеннән бөтенләй күзен ала алмый торды. «Ай-кояшка тиң гүзәл хатыннан бары тик шундый балалар гына туадыр»,— дип уйлады ул, гүзәл хатын Таңананың йөзкыяфәтен күз алдына китерергә тырышып. Яучыларын массагетлар иленә җибәргәндә, аннан әйләнеп кайтып, Таңананың гүзәллеге хакында вәзире исе китеп сөйләгәндә дә, Бөек Кир бу хәлгә бик үк ышанып җитмәгән иде. Алай да вәзиренең сүзләре күнелен җилкендереп куйгандай иткән иде. Күп тапкырлар уйланды ул. Адәм баласы шулкадәр матур була аламы? Аладыр, күрәсең, аның алдында әнә нинди матур егет басып тора. Бусы күзалмастай булгач, Таңана үзе ниндәен гүзәл икән? Чын-чынлап ай-кояшка тиңләрлекме массагетлар илтабары Таңанада гүзәллек?!

Бөек Кир, кулын маңгаена куеп, кояшка карый һәм көлемсерәп куя.

— Вәзир, массагетлар нинди аллага табыналар?

— Көн-Кояшка, шөһрәтлебез. Көн яктысында үлү алар өчен дан.

— Варварларның гореф-гадәтләрен белүең әйбәт, вәзир. Таңана алдыма килеп егылмаса, мин аның көнгә табынган халкын төнлә белән суга батырып үтерәчәкмен. Бер генәсен дә калдырмам. Шундый-шундый халык бирелә яшәгән дип, тарихта гына калыр. Көнгә табыналар диденме әле, вәзир?.. Ахмак халык, кояш бер аларга гына яктыртамы аллә?! Массагетлар беркайчан да әсир төшми имеш, һә-һә-һә, бу кем? Кем алдымда басып тора, вәзир?! Массагетлар баһадиры түгелме! Ә бит Таңана шушындый сугышчылар белән миңа каршы тормакчы! Әй, син, варвар, дәш, әллә телеңне кистеләрме?!

— Шөһрәтлебез, сезгә әйткән идем инде, массагетлар...

— Әйе, шул, куллары бәйле. Әй, чишегез әсирнең кул-аякларын, нәрсә карап каттыгыз!

Кул-аяклары чишелүгә, Сарман углан кеш тиресе белән каелган өс киемен рәтләде, ашыкмый гына күбәсен салды, шуннан соң гына, күтәрелеп, күккә карады. Зәп-зәңгәр күк йөзендә, нәкъ аның баш очында бөркет талпына иде. Табигый, горур кош кан исен сизеп килгән. Бу бик тә яман билге иде. Димәк, бирелә тагын да катырак орыш булачак. Мәгәр угланга инде илгә әйләнеп кайту юктыр. Мидәннәрнең исерткеч эчемлегенә алданып, ул иң гайрәтле иптәшләрен, ә Таңананың иң көчле чирүен харап итте. Моның өчен аны аксакаллар кичермәс. Бу хәлдән соң кем аңа ил тәхетен бирсен!

Әсирнең күккә карап торуына барысы да гаҗәпләнә калдылар, һәммәсе дә күккә бактылар. Шул мәлдә Сарман углан уң ягында баскан сакчының хәнҗәрен суырып алды да күкрәгенә кадады.

— Бөек Кир, ул үз-үзен үтерде! — дип кычкырып җибәрде сакчы.

Әмма соң иде инде. Сарман углан җирдә кан эчендә ята иде. Бу хәлне күреп, Кир сикереп үк торды.

— Вәзир?! Бу ни хәл бу?!

— Шөһрәтлебез, кисәткән идем ич...

— Бу хәл мөмкинме! — Кир бөтен нәфрәтен сакчыларга юнәлтте: — Ташлагыз елгага үзен! — дип боерды ул җан сакчыларына.— Вәзир, сөрәнче Таңанага оран салсын. Угланың үз-үзен үтерде, Бөек Кир җавап көтә, диген!

Миданнәр сөрәнчесе оран салды. Массагетлар миданнәргә килеп житәр-житмәс туктап калдылар. Сөрәнче, кояш баеганчы, тагын-тагын оран салды. Әмма массагетлардан җавап булмады. Кир тәмам пошаманга калды. Ул уйлаганча барып чыкмады. Угланны Таңанага биреп, гүзәлнең күңелен яуларга иде исәбе. Барысы да челпәрәмә килде. Кем уйлаган уналты язы да тулмаган угланны үз-үзен үтерер дип...

Кир чатырына керде, юлбарыс тиресенә түренде. Шактый җылы төн булса да, ул бизгәк тоткандай калтыранды. Аның күз алдыннан үз-үзен үтергән углан китми иде. Массагетлар барысы да шундый тәвәккәл булсалар?! Җиңел булмас миданнәргә аларны җиңүе. Әмма ул аларны барыбер җиңәр, барыбер Таңананы буйсындырыр, аннары иленә алып кайтып китәр.

Төнге дала җиленә чатыр ефәге лепердәп куя, түр якта утка май салучы кол йокымсырап утыра. Җил көчәйгән арада чатыр эчендә шыксыз шәүләләр йөгерешә, җиңү куанычыннан салган эчемлектән әз генә баш шаулый. Кир, әсир төшкән Лидия патшасы Крезның киңәшен тотып, дөрес эшләде: массагетларның бер өлеш чирүе юк ителде. Гомумән, Кир дошманны бүлеп-таркатып җиңәргә ярата иде. Берәүләрне хәйлә белән җиңде, икенчеләрен — бүләкләр биреп, өченчеләрен — юха тел белән, ә тегесенә дә, монысына да буйсынмаганнарына көч кулланды. Массагетларны хәйлә белән җиңеп булмады, инде орышырга, көч кулланырга калды. Ә бит Таңана куенына керергә генә торганда... Бу тәкәббер углан барысын да харап итте.

Бик озак йокыга китә алмый интегеп ятты Кир. Бары таң алдыннан гына калыгып, әмма күп тә үтми, яман төш күреп, уянып китте. Төше бик сәер иде: сараендагы алтын тәхетендә утыручы вәзиренең угланы Дарийны күрде ул. Дарий аның алтын тәхетендә утыра, ә Кир Дарийның бары тик вәзире икән. Күргән төшен янәдән күзаллауга, Кир кычкырып ук җибәрде. Шундук чатырга җан сакчылары килеп керделәр, утка май салучы кол, күзләрен тозландырып, сикереп торып басты.

— Төш юраучыны, төш юраучыны китерегез!

Күп тә үтми, җан сакчылары җилтерәтеп, тәмле йокысыннан уятып, төш юраучыны китерделәр. Кир аңа үзе күргәнне сөйләп бирде. Йокысын бүлдерүгә кәефе киткән юраучы көйләп-такмаклап:

— Шөһрәтлебез Бөек Кир, бер дә борчылмагыз, аллалар тарафыннан җибәрелгән төш түгел бу,— дип сөйләп китте.— Инде ил-йортың тыныч булсын дисәң, киңәшем шул: вәзиреңне илгә кайтарып җибәр. Кайтсын да угланын төрмәгә япсын. Аның угланы Дарийны гаепле дип табасың икән, массагетларны җиңеп, илгә кайткач, җәзасын үзең бирерсең.

Миданнәр шаһы төш юраучысына ышана иде, ул шундук вәзирен чакыртты һәм аңа:

— Угланың илдә миңа каршы коткы алып бара икән, вәзир. Сиңа кайтып китәргә, угланыңны төрмәгә тотып ябарга боерам,— дип әмер бирде.

Вәзир һични аңламады, шулай да каршы дәшмәде, Бөек Кирнең холкын яхшы белә иде.

— Шөһрәтлебез,— диде вәзире, шаһиншаһның үзеннән ни теләвен ишеткәч.— Сезгә кул күтәрергә җөрьәт итүченең, угланыммы ул, башка берәүме — кайту белән башын кистерермен.

— Юк, вәзир, башын кистермә, кылынган хәл хак булса, җәза бирүне үземә калдыр.

— Кушылганның барысын да эшләрмен, шөһрәтлебез. Инде мине дә тыңлагыз: массагетларның илтабары Танана белән килешергә тырышыгыз. Болынны — чәчкә, шаһ сараен гүзәл хатын бизәр, диләр.

— Вәзир, мин монда житмеш меңле чиру белән ниндидер вәхши хатынга баш иярга килмәдем. Юлында бул!

Көн туып, кояш күтәрелә башлауга, массагетлар, бөтен елга буен каплап, мидәннәр өстенә килә башлагач, Бөек Киргә гомерендә беренче тапкыр сәер бер курку кагылды. Ул нидәндер баш тарта, ниндидер ялгышлык кыла кебек иде. Әмма бу тойгы озакка бармады. Ул Сарман угланның алтын тояклы атын соратып алды. Озын сыйраклы, ак бәкәлле, алтын тояклы туры айгыр аның иясенә булган кодрәтне аңа да бирер кебек иде...

Алтынтоякка атлангач, Бөек Кир гаскәренә күз ташлады. Сугышчылары да туры карарга куркалар шикелле тоелды аңа. Янә күңелгә шом иңде. Әллә соң шаһинәгә булган мәхәббәте шулай күңелен борчыймы? Вәзире аңа, Тананның гүзәллегеннән күз камаша, дигән иде. «Ялган!» — дип уйлады Кир, янә бер тапкыр чирүен күздән кичереп, үзен кулга алды һәм аның алдыннан атлатып китте.

— Без җиңәрбез! — дип кычкырды ул.

Әмма чирүе аны ни сәбәпледер куәтләп алмады. Кир моны эче белән тойды. «Әллә соң дошман атына атланганга яратмадылармы?» — дип, үз-үзен юатырга теләде ул. Юк, Кир җиңәр, аңарда — дөньяда булмаган корал. Бөек Кир атын юырттырып чирүен әйләнеп килде. Шул вакыт массагетлар ягында чирүе каршында ап-ак атка атланган Танана күренде. Тананның башында алтын очлым, очлым якты җәйге кояш нурларына чагыла,— ялтырап-ялтырап китә. Шаһинә чирүен Кир кебек үк орышка өнди иде. Кир хәтта аның тавышын ишетте.

Дошманнар бер-берсен ап-ачык күрәләр. Кир сөрәнчесен чакырды, аның сүзләрен кабатлап, сөрән салырга кушты.

Сөрәнче Бөек Кирнең сүзләрен кычкырып туктауга, ниһаять, Танана сөрәнчесе телгә килде. Мидәннәр сөрәнчесе Танана сүзләрен кабатлый иде.

— Канечкеч Кир, син угланымның башына җиттең. Горурланма алай, бу гадел җиңүең булмады. Син аны яман эчемлегеңне эчереп алдадың. Шул исерткечне йотып алгач, сез, мидәннәр, авызыгызга ни туры килсә, шуны лыгырдый башлыйсыз, үзегезне күккә чөеп мактыйсыз, булмаган даннарыгыз белән кәпрәясез, тотнаксызланасыз. Кинәшемне тотмадың, Кир, илеңә кайтып китмәдең, инде хәзер үзеңә үпкәлә. Мин синең белән орышырга булдым! — дип оран салды массагетлар сөрәнчесе.

Юк, варварларның бу мәсхәрәләвенә түзә алмады Кир, чирүе алдыннан янә:

— Баһадирларым, без күп илләрне буйсындырдык, массагетларны да җиңәрбез. Коралларыбызның үткенләгеннән татып карадылар инде алар. Без, мидәннәр, дөньядагы иң гайрәтле, иң батыр халык! Без җиңәрбез! — дип кычкыра-кычкыра чаптырып китте. Бер уздыы шулай чирүе каршыннан Кир, ике, өч. Әйе, котыртырга, котыртырга, тагын-тагын котыртырга! Чирүенең гайрәте тоташ бер ташкынга әверелгәч кенә, дошман өстенә җибәрергә.

Кир янә массагетлар ягына күз ташлады. Дошманнары аңа күбәү, бик күбәү кебек тоелды. Вәзире аңа әйткән иде. «Кирәк чакта массагетлар гүя җирнең үзеннән туалар, тиз арада барлык елга-тугайлардан, дала-чүлләрдән, тау араларыннан бер төбәккә җыелалар да, тоташ бер ташкын булып, дошманга өермәдәй ташланалар. Массагетларның атлары житез, мәргәннәре күп санлы, кылычлары үткен, сөңгеләре озын, калканнары җиңел, нык, таза... Бер кузгалгач, алар туктый белмиләр, орышта үлеп калу — алар өчен дан...» Вәзире аңа янә әйтте: Киргә кадәр

яшәгән бер патша да, бер шаһ та ыру башында хатын-кыз торган илләргә яу чапмаганнар. Ә Кир менә илтабарлары хатын-кыз булган илне яуларга килде. Массагетларның алыплары барысы да бер төстәге атта, киемнәре дә бер үк төстә — аларны хәтта җирдән аеруы да кыен. Таңана һаман чирүен дәртләндерә, аның түшендәге көмеш тәңкәләр җем-җем итеп китә. Һәр массагет алыбының очлымында ак каурый, сөңгеләре урман кебек куе, гүя күкне терәп торалар иде. Варварлар чирүендәге тәртипкә хәтта Кир дә көнләшеп куйды. Ниһаять, Бөек Кир алдагы рәттәге укчыларына кузгалырга боерды.

— Алга, дошманга ук яудырырга! Алга, алга!

Барабан, думбра кагалар, сорнай кычкырталар. Шул тамаша кыздырудан, шаулаудан тамырлардагы каннар кайный башлагандай тоелды. Алыплар үз-үзләрен белештерми башладылар. Алар кузгалды. Кан кайнарланган саен, куллар ирексездән кылыч-коралга үрелә, күзләрне кан баса — кеше үз үлеменә каршы китә. Аңа каршы дошманы килә. Я ул сине, я син аны. Канга — кан, җанга — җан!

Ук-җәячеләрнең уклары беткәч, ике яктан да сөңгечеләр кузгалды. Кир, укчылар алышканда, күрде: массагетларның мәргәннәре төзрәк ата, күп тә үтми, мидән укчылары сафы сирәгәеп калды. Кир кулын күтәрде, җайдакларына кузгалырга боерды. Әмма бер мәлдән аз гына ашыга төшүен аңлады. Массагетларның укчылары мидән атлыларын, төз атып, чүпли башладылар. Шул чак иң кыю, иң батыр мидән атлылары, массагетлар сафын ертып керделәр һәм дошманны кылыч белән уңлы-суллы турый башладылар. Әмма мидән җайдаклары аз иде, массагетлар аларны бик тиз сөңгегә күтәрделәр. Бу хәлне күреп, Кир үз тавышын үзе ишетмәс дәрәҗәгә җитеп кычкырды. Ул әле сул як канаттагы чирүен, әле уң ягындагысын, әле төп алаен алга җибәрде, әмма һөҗүм һәрчак йотылып, эреп бетте. Шулчак массагетлар ташкын булып һөҗүмгә күчтеләр. Күк күкрәгәндәй тупылдап атлар чапты, тузан купты, оран авазлары, өермә булып, һавага күтәрелде. Кир мая гаскәрен кузгатты. Мәгәр алар да кире борылдылар, мидән җайдакларына каршы ут чаткыларыдай уклар яуды. Массагетлар белән мидәннәр очрашкан мәлдә барысы да буталды, чуалды, чәбәләнде, кисеш, кадаш, кырылыш китте. Яман итеп атлар кешнәде, сөңгегә алынган сугышчылар аһылдап аудылар, кан чәчә-чәчә, башлар җиргә тәгәрәде.

Кир барысын да күрде, күзәтте. Күзәтте һәм куанып бетә алмады — мидәннәр массагетларны кысрыклый башладылар. Шул чак елганың өске ягыннан, бөтенләй көтмәгән тарафтан массагетларның янә бер атлы чирүе килеп чыкты. Кирнең тулганага — камалышка эләгүе бар иде. Кир кылычын күтәрде. Теләсә нинди тулганадан шаһны алып чыгарга өйрәтелгән йөзләгән җан сакчысы Кирне уртага алды. Мидәннәрнең бер өлеше, елга буйлап һөҗүм иткән атлы массагетларга каршы китте. Мәгәр төп орыш кырындагы чирү сафы сирәгәйде. Шунда Кир үзенә таба килүче ак атка атланган Таңананы күрде. Массагетлар илтабарын да йөзләп җан сакчысы уратып алган иде.

— Алга! — дип, Кир җан сакчылары белән Таңанага каршы ташланды. — Алга, алга!

Варварлар белән Бөек Кир һич тә үзем орышырмын дип уйламаган иде. Ул аларны бер селтәнүдә җиңәргә дип килде. Фарсыларның иң оста шагыйрьләре аның җиңелмәс чирүе хакында мәдхияләр әйттеләр, дөнья бетереп, Кирне мактадылар. Халык арасына чыктымы, куштаннары аңа: «Дөнья хакименә дан!» — дип кычкырдылар. Кир үзе Таңананы әсир итәр, әсир итәр дә күктәге ай-кояшка тиң хатынны сараена алып кайтыр. Алып кайтыр, әмма бер тапкыр да янына кермәс. Ул аны ир-ат күзенә күрсәтмичә саргайтып үтерер.

Калганы хакында уйлап бетерә алмады Кир, каршына чаптырып килүче ап-ак атны күрде. Атта гүзәлләрнең гүзәле Таңана үзе иде. Як-ягында җан сакчылары.

Кир жан сакчыларына:

— Массагетлар шаһинәсенә тимәскә, мин аның белән ни кылырга үзем белермен! Бүлеп алыгыз шаһинәнең алыпларын! — дип кычкырды.

Әмма шунда бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Алтынтояк, Кашка бияне күргә, кешнәп җибәрде. Таңана Кашка бияне далага борды. Кир атына кылыч сырты белән сукты.

— Һоп, алдыр!

Алтынтояк өздереп чаба башлады. Ул бик тиз Таңананың атын куып җитте. Атлар ун-унбиш адым ара калдырып, далага очтылар. Аларга бераү дә иярмәде, дөресрәге, ияра алмады. Җитез һәм оста мидән алыплары Таңананың жан сакчыларын бүлеп алып калганнар иде.

— Таңана! — дип кычкырды Кир.— Таңана! Бирел!

— Кир, канечкеч Кир! Син кеше түгел, син аждаһа!

Таңана күз ачып йомганчы җәясенә ук элде, керешен тартты. Кир очып килгән укка чак кына калканын куеп өлгерде, чыбыгы алтын төскә буялган ук аның калканына килеп кадалды.

— Таңана, бирел! — дип янә кычкырды Кир, җил көчен җиңәргә тырышып.— Бирел, Таңана!

Шунда Таңана атын якынайта төште. Кир илтабар хатынның йөзен күрде. Күрде дә таң калды. Таңана чынлап та гүзәлләрнең гүзәле икән ләбаса! Маңгаена кара тап төшкән ап-ак аттагы Таңананы ни белән чагыштырырга да белмәде Кир. Ул менә хәзер генә кылган ялгышларын аңлады. Аның әле бу кадәр гүзәл хатын-кызны бер тапкыр да күргәне юк иде.

— Таңана, бирел! Бирел, Таңана! Мин сине мәмләкәтемә алып китәрмен, тәхетем янына үземә тиң тәхет куйдырырмын. Таңана!

— Кир, ишетәсеңме, Кир! Син далама мәхәббәт эзләп түгел, үлемең эзләп килдең. Син аны табарсың, Кир! Монда, минем даламда. Син хәйлә белән угланымны үтердең, канечкеч бәндә!

— Мин аллаларга тиң шәхес, Таңана! Бирел миңа, үкенмәссең!

— Юк, Кир, юк! Алтынтояк, ташла җайдагыңны, ул иян түгел, Алтынтояк!

Таңана кисәк тезгенен тартты, Кашка бия үрә торып, туктап калды. Алтынтояк алга омтылды, әмма икенче мәлдә инде үрле-кырлы сикерәнергә тотынды. Өстеннән исе-тавышы ят кеше егылып төшкәч, көтмәгәндә аның өстенә килә башлады. Егылса да, сикереп торып, кулына алырга өлгергән кылычын Кир атның күкрәгенә юнәлтте. Әмма ат туктый алмады, күкрәгенә чытырдап кылыч керүен дә сизмичә, алтын тояклары белән шаһның башына типте.

Яшелле-зәңгәрле кеше тавышына, үлем мәхшәре белән ярсынган ат кешнәвенә Кашка бия сагышлы итеп җавап кайтарды. Таңана атын Алтынтояк тартышып яткан җиргә борды. Әмма аты, үлем белән тартышып яткан ике җан янына җитәрәк, пошкырынырга тотынды, килешсез итеп, куркынып артка чигенде. Таңана атыннан төште, кан эчендә яткан гәүдәләр янына килде. Җиде йөз меңле чиру белән массагетларны буйсындырырга килгән мидәннәр шаһиншаһы Бөек Кир ат астында үлеп ята иде. Кирнең башындагы затлы ташлар белән бизәлгән очлымы үлән арасына тәгәрәгән, йөзен, кара сакалын кан каплаган, күзләре акаеп күккә баккан, гүя массагетлар алласы Тәңредән кылган языкларын кичерүне сорый иде.

Таңана орыш кырына күтәрелеп карады. Кандыр ата үз алае белән югарыгы яктан көтмәгәндә килеп чыкканнан соң, җиңелә башлаган мидәннәр елгага таба чигенәләр. Күпер башын кулына алып өлгергән Кандыр ата берсен дә якын җибәрми, кая барырга, ни кылырга белмәгән Кир өере ике үлемнең берсен сайлый: берәүләре авыр киемнәре белән суга сикерә, икенчеләре массагетларның очлы сөңгеләренә кадала иде. Өченчеләре исә, коралларын җиргә ташлап, капланып ята — әсир

төшәләр. Таңана карашын янә кан эчендә яткан Киргә төби, кызганып, Алтынтоякка карый. Атның тоякларын алтын төскә табгач сәүдәгәре буяган иде. Ат шундый акыллы иде ки, Тәңре янына киткән ире, бу ат кеше телен аңлый дип, аның белән сөйләшә иде. Таңананың хәтта Алтынтояктан көнләшеп куйган чаклары да булгалады. Кинәт Таңананың карашы Кирнең кулындагы канлы кылычка төште. Таңана кинәт калтыранып китте, ачу-нәфрәте күңеленнән ташып чыкты.

— Канечкеч Кир, син минем илемне дә, йөрәгемне дә яулый алмадың. Илемә мәхәббәт түгел, үлем алып килдең һәм ул үлемне монда үзең дә таптың. Ирем булырга теләдең — була алмадың. Чөнки синдә йөрәк, ирләргә хас мәрхәмәт юк иде. Бары тик мәкер, данга сусау, ят халыкларга мыскыллы караш кына бар иде. Сине үлемгә тәкәббер горурлык китерде, Кир. Тәкәбберлек, илгә килгән ачлык кебек, кая гына барсаң да, сине эзәрлекләп йөрде һәм минем илемдә куып җитте. Чөнки кылган бер явызлыкка ике яманлык килер диләр. Һәм ул сиңа килде, Кир. Син бүген кан эчендә ятасың. Мин каберең ташына, бездән соң яшәгән халыкларга гыйбрәт булсын өчен: «Мәхәббәтне кылыч белән яуламыйлар»,— дип уйдыртып калдырырмын.

Яңа көн тугач, Таңана җан сакчыларыннан Сарман угланның гәүдәсен таптыртты. Аксакаллар угланга иң затлы киемнәрен кидерделәр. Угланның, аксакаллар исәбе буенча, теге дөньяда Тәңре алдына барасы бар иде. Углан Сарман янына үзе белән һәлак булган алыпларын, яраткан аты Алтынтоякны күмделәр, яннарына өч көнлек ризыкнигъмәт, затлы савыт-сабаларын, коралларын куеп калдырдылар. Шуннан соң гореф-гадәт буенча һәр алып кабер өстенә бер очлым балчык китереп салды. Әнә шулай тип-тигез далада массагетларның каберләре өстендә һәйкәл-курганнар барлыкка киләчәк.

Бары тик шуларны эшләгәч кенә, Таңана янына биләрен җыйды һәм уй-теләген җиткерде.

— Аксакалларым, сезгә әйтер сүзем шулдыр: илдә илтабар булып Кандыр ата калыр. Мин ыруым белән мидәннәр иленә күчеп китәм. Аларның елга аръягындагы җир-сулары, дала-тугайлары — орыш кырында кан койган угланым, алыпларыбыз өчен түләү булыр. Аксакалларым, игелек бирегез!

Дөньяда иң куркыныч дошманны җиңгән Таңанага берәү дә каршы әйтергә кыймады, барысы да беравыздан:

— Игелегебез сиңа, Таңана, игелегебез сиңа! — диештеләр.

Шуннан күп тә үтми, Таңана үз ыруын алып елганы кичеп чыкты һәм яңа җирдә тамыр җибәрде.

* * *

Безнең эрага кадәр 530 елда булган, үз заманы өчен гаять зур һәм куәтле бу сугыш хакында буыннан-буынга сөйләгәннәр, атаклы тарихчы Геродот исә бик тәфсилләп язып калдыра. Ул мидәннәр дип атаган халыкны галимнәр соңыннан фарсылар дип таныта, ә мидәннәрне җиңеп, елганың көньягына күчеп чыккан массагетларны берәүләр — сармат, икенчеләр — скифлар, кытай укымышлылары исә сөн дип атый.

# Нажар Нәҗми

## Париж өстендә

*Казан дәүләт университеты профессоры*
*Миркасыйм Госмановка*

Без Эйфельдә... Уч төбендә кебек
Бөтен Париж — Җир һәм ил даны.
Әнә Бастилия... Монмартр... Конкорд...
Ә эргәдә Марс яланы.
Париж — тарих... Күпме күкрәү үткән,
Күпме исем монда яшьнәгән.
(Парижны да күрми торып, димен,
Моңа тиклем ничек яшәлгән?)
Без биектә... Без — башкорт һәм татар,
Без зур милләт Париж өчен дә.
— Сөйлә әле,— диден,— «Татар телен»,
Яңгырасын Париж өстендә...
Без татар һәм башкорт — кан кардәшләр,
Миндә исә тибә ике кан:
Үзем башкорт, әмма туган телем
Татарлашып килгән тумыштан.
Язык түгел беркем алдында бу,
Туры килгәч язмыш язмышка;
Ә язмышлар, «тел, лөгать вә әхлак»
Бер тамырдан, бер үк сулыштан.
Без әле дә бер үк сулыштабыз,
Чит бер илдә — француз җирендә,
Ярсып-ярсып, шигырь укышабыз
Я башкорт, я татар телендә.
Аста Париж... Син уйларың белән
Алып киттең мине Казанга.
Париж түбәсеннән киттең алып,
Бүгенгедән үткән заманга.
Кайдан карарга соң зур Казанның
Ак бүгенен, кара үткәнен —
Сөембикә манарасыннанмы,
Манарасыннанмы әллә
Баумандагы кызыл чиркәүнең?
Юк, карыйк без яңа биеклектән —
Син укыткан биек бинадан.
О, университет! Альма-матер,
Күпләр мәшһүр аңа бинаән!
Күз алдында менә Сөембикә,
Тукай, Җәлил, «Ирек мәйданы»,
Әнә Болак, Идел, Яңа бистә,
Арча кыры, «Печән базары».

---

**НАҖАР НӘҖМИ** *(1918) — күренекле башкорт шагыйре, башкорт, татар, рус телләрендә басылган күп санлы китаплар, татар әдипләре турында шигырьләр, мәкаләләр авторы. РСФСРның М. Горький, Башкортстанның С. Юлаев исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты.*

Казанда да купме кукрәү үткән,
Күпме исем балкып яшьнәгән!
Бер уйласаң, Парижны да күрми,
Яшәп булган... Ә бит яшәлгән!

Без — Эйфельдә — аста кайный Париж —
Исемендә дөнья тарихы.
Бу мәл Казан ничек кайный икән?..
Казан, Казан — татар Парижы!..

## Мескен бүрек

Мескен бүрек... Нигә икән
Аңа шулай дигәннәр?
Әллә микән аны, димен,
Гел мескеннәр кигәннәр.

Бала чагым. Ул һаман да
Еллар һәм юллар аша,
Арттан ияреп килә дә
Күз алларыма баса:

Киндер күлмәк, ялан тәпи —
Мин коеп куйган кебек.
Башымда мескен этидән
Калган шул мескен бүрек.

Ә ул күптән минем белән
Зар елап саубуллашты —
Хәтта кама бүрекләр дә
Бизәде минем башны.

Әмма, ни кылсам да, эшем
Пешеп бетмәде кебек.
Гомер буе мескен бүрек
Баштан төшмәде кебек.

## Алар өчәү иде

Алар өчәү иде: Хәсән Туфан,
Сибгат Хәким, Кайсын Кулиев.
Күз алдымда Туфан карашлары,
Сибгат йөзе, Кайсын көлүе.

Алар өчәү иде... Ә өчесе бер җан —
Җан-агайлар миңа, җан-дуслар.
Өчесе дә кеше йөрәгендә
Нур балкыткан алтын йолдызлар.

Алар өчәү иде... Өчесе дә
Гомеремә булды өч терәк.
Күңелемә — күңел, җырыма — җыр,
Йөрәгемә моңлы бер йөрәк.

Исән чакларында мин аларның
Барып күрдем туган җирләрен.
Вафат булгач, туган җирләренә
Һәр берсесен барып җирләдем.

Әмма алар терелэрдән тере —
Үлем юк ул, юк бит җырларга.
Мин үлгәчтен, алар өчесе дә
Килер кебек мине җирләргә.
Үлем юк ул, юк бит җырларга!

## Сукыр лампа

Ут сүнде дә, шәм кабыздым...
Караңгылык басты өйне.
Яктыга да, яхшыга да
Без күнегеп беткән инде.

Шәм кабыздым... Өй эченә
Иңде гүя үтелгән чор:
Әти йорты, сукыр лампа —
Сукыр якты, караңгы нур.

Әти йорты... Алда кәгазь,
Кулда каләм — тәүге белем.
Шушы сукыр яктылыкта
Күз ачылган башлап минем.

Яктылык та, яхшылык та
Артмый икән бәндәләрдән...
Ә бит сукыр лампадан да
Якты төшкән тәрәзләрдән.

*

«Шагыйрь үлеменә» дигән шигырь
Язгач шагыйрь шигъри таңында:
«Ул акылдан язмаганмы?» — дигән
Хак-падиша шагыйрь хакында.

Дөньялар бит, һай, үзгәреп тора
Безнең өстән төште патшалар.
Хакимнәр дә хәзер башка инде,
Шагыйрьләр дә хәзер башкалар.

Без дә берәр шигырь язсак икән
Шагыйрьлектән үрнәк алырлык:
«Акылыннан язмаганмы ул?» дип
Әйтә-әйтә хәйран калырлык...

*1985—1986*

## Барлас Камалов

# КҮРӘЧӘК КҮЗ АЧТЫРА

**хикәя**



Үз күзләремә үземышанмаган мизгел булып алды. «Метеор»дан дебаркадерга күтәрелгәндә, бик-бик азга гына егет чагыма кайткан төсле булдым. «Улмы бу?» Миемдә сорау яшене сузылды. Шуңа җавап биргәндәй, үз-үземне битәрләп, елмайдым: «Тинтәк! Ул хәзер бик олыгайгандыр инде. Утыз дүрт ел гомер узды лабаса!»

Чаллы шәһәре пристанендә, теплоходка утырганда, ничек күрмәдем соң мин аны? Хәер, миннән алданрак кергән булгандыр ул. Мин бит иң азактан диярлек ишек буендагы креслога чумдым. Ярар, ул кадәресе үткән инде. Туктатыйммы хәзер үзен, сез кем, кай яклардан дип сорашыйммы? Болай тинтәкләнеп, кешене җайсыз хәлдә калдырмаммы?

Тәвәккәлләдем. Адымнарымны тизләтеп, аны куып җиттем.

— Гафу итегез. Исәнмесез! — дидем.— Сәерсенмәсәгез, сезгә бер соравым бар иде.

Юк, ул әллә ни сәерсенмәде. Туктады, исәнләште.

— Тыңлыйм сезне...

— Сез Дания Галиевнаның кызы түгелме?

— Нәкъ үзе, Руфия.

— Алайса танышыйк әле, без якташлар бит. Хәбиров. Ильяс Нургалиевич.

— Очень приятно,— диде ул саран гына елмаеп. Аның кәгазьдәй ак, тигез вак тешләре күренеп калды.— Руфия Хафизовна. Фамилиям әтиемәниемнеке. Әнине белгәч...

— Мин — аның укучысы.

— Шулаймыни?

— Унынчы класста аңардан немец теле укыган идем. Ташкыяда. Сез Казанда яшисезме?

— Чаллыда. Ташкыяга кайтып барышым. Әби янына. Тик соңардым менә. Безнең якка поезд иртән генә буласы. Гостиницага урнашырга иде. Сезнең Казанда ул проблема инде...

Бу тиклесе минем өчен зур бәла түгел иде.

— Теләсәгез, елга порты кунакханәсенә урнаштыра алам.

— Бик рәхмәт әйтер идем...

---

БАРЛАС КАМАЛОВ *(1930) — прозаик. Татарстанның атказанган культура работнигы. «Күршеләр», «Канатлы кырмыска», «Өметең өзелмәсен»* *һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Руфия кунакханәгә урнашкач, ресторанда тамак ялгап утырганда, мин менә нәрсәләр белдем: Дания Галиевна да, Хафиз агай да вафат икәннәр инде. Дания Галиевнаның әнисе сау-сәламәт яши бирә икән әле. Сиксән бусагасын атлаган. Руфия ханым Мәскәү автотөзелеш институтын тәмамлагач, Горькийда һәм Тольяттида эшләгән, Чаллыга кайтканына өченче елы. Кияүдә булган, теплоход капитанында. Аерылышканнар. Күптән.

Кеше чыраена гел генә кадалып утырыр хәл юк, шулай да әледән-әле Руфиягә карап куям, аңарда укытучымның йөз сызыкларын, сөйләшү рәвешен, хәтта фикер сөрү үзенчәлеген күрәм һәм тоям. Ханым минем карашымнан тайчанмый. Әңгәмә агышының үзе өчен кулай бер бормасын туры китереп, минем хәлләрне сораштыра башлый. Республика эчке эшләр министрлыгында эшләвемне әйтәм.

— Хезмәтегез ансаттан түгел,— ди Руфия.— Юрист өлешенә тигән көмешнең ни икәнен чамалыйм мин. Бигрәк тә тикшерүчеләрнең. Хатыныгыз кем?

— Врач иде.

— Нигә «иде»? Дөнья куйдымыни?

— Әйе шул. Үпкәсендәге яман шеше...

— Шулай инде. Кешеләр Айга менәргә өйрәнделәр, рактан котыла алу юлын таба алмыйлар...— Ул аз гына тын торгач, сорап куйды.— Балаларыгыз үсеп беткәндер инде?

— Ике кызым да кияүдә.

— Әйе...— Руфия авыр сулап куйды. Үз язмышына кагыла идеме бу уфтану, миңа теләктәшлек идеме, төшенеп җитмәдем.— Дөнья без дигәнчә генә түгел шул, түгел!..

Аның соңгы җөмләсе минем күңелгә пәке белән сызып җибәргәндәй итте. Моннан утыз дүрт ел элек, кырык тугызынчы елның август азагында, мин юридик институтка укырга киткәндә, нәкъ шул сүзләрне Дания Галиевна әйткән иде. Уфтанып кына түгел. Күзе тулы яшь килеш...

* * *

Мин, армия хезмәтенә тугыз класс белем белән генә киткән район үзәге шәһәрчеге Ташкыя егете, солдаттан кайткач та, аттестат алыйм дип, унынчы класска укырга кердем. Бу ниятемә әни дә каршы килмәде, ризалык бирде.

Өзелеп торгач, уку җиңел булмаса да, җәмәгать эшләреннән читләшә белмәдем. Драмтүгәрәккә дә бик теләп, тәм табып йөрдем. Шунда мин түгәрәкне җитәкләгән Дания Галиевнаның сүрелмәс яшьлек хисе белән янып йөрүен бөтенләй башка бер ноктадан күрдем. Гаҗәеп ашкын, ачык күңелле иде безнең чит тел укытучыбыз. Ул дөньяга гашыйкларча карый, беренче күз салганда һич искитмәслек ваклыкларда да матурлык күрә белә иде. Чәчәкләрнең төсен генә түгел, шул төстәге төсмерләрнең дә һәммәсен тоя, кош сайравын нотага салырлык дәрәҗәдә нечкәләп тыңлый иде. Сөйли башласа, авызына гына каратып тота, безне үз хыялларына ияртеп, еракларга алып китә... Сәхнәдә ул тормыштагы Дания булуыннан туктый. Образга шул кадәр керә һәм бирегә, аның үзен онытасың, бу хатынны әсәр героинясы итеп тоя башлыйсың. Җиргә генә ябышып яшәү аңа ят, ул гүя канатлы җан иде.

Кырык тугызынчы елның июнь башында — чыгарылыш имтиханнары бара иде инде — Пушкинның туган көненә багышлап, мәктәп сәхнәсендә «Су кызы»ннан өзек уйнадык. Тегермәнче — Зөфәр Әхмәтов, князь — мин. Ә тегермәнченең кызы — Дания Галиевна.

Сайлаган репертуарыбыз мәктәп сәхнәсе өчен ни чама ярагандыр,

без укытучыларыбыз һәм укучылар белән шыгрым тулы зал каршында ялган мәхәббәт тарихын уйнадык.

Укытучыбыз:

«Да!... вспомнила: сегодня у меня
Ребенок твой под сердцем шевельнулся»,—

дип өзгәләнә-өзгәләнә муеныма сарылды. Мин — ничек кенә булса да табан ялтыратырга карар кылган Князь — аны кочаклап үптем дә, читкә тайпылдым.

Нәкъ шул минутның кабатлануын икенче көнне кичерермен дип уема да китермәгән идем.

Тарихтан имтихан тапшырып — «бишле» алып чыккан идем. Дания Галиевна мине тәбрикләде дә, сөйләшә-сөйләшә мәктәп капкасыннан чыгып киттек. Сүзгә шул тикле мавыктык бугай, өйләренә кадәр озата кайтканымны искәрми дә калдым. Алар үз йортлары белән торалар иде. Хафиз агай, район орлыкчылык лабораториясе мөдире, колхозларда икән. Дания Галиевна мине өйгә дәште. Чәй өлгертте. Шунда мине өнсез калдырырлык итеп: «Яратам мин сине! Өйләнешик. Бу йорттан мин иртәгә үк китәргә риза»,— диде һәм ике куллап муенымнан кочып алды. Күңелемдә нинди өермә купканны тасвирлау читен. Куәтле магнитка эләккән идем. Укытучымны кочагыма алдым.

Шашынудан айныгач, наянлыклары өчен орышылган балалар кебек, икебез ике урындыкка барып утырдык. Беренче булып ул сүз башлады.

— Я, җавабың нинди булыр? — диде.

Мин җавап бирерлек хәлдә түгел идем. Дөресрәге, җавабым юк иде. Шулай да иреннәрен тегеп куйган кеше төсле утырырга ярамаганын чамалап:

— Берни дә әйтә алмыйм әле мин, Дания Галиевна,— дидем.— Һич көтелмәгән хәл...

Ул, урындыгын алып, каршыма ук килеп утырды. Тезләр тезгә орынып калды. Мин читенсенү тойдым, ләкин сер бирмәскә кирәген төшенә идем. Дания Галиевна очкынланган күзләре белән карашымны тотты. Күзгә-күз төбәшеп калдык.

— Сине нәрсә шикләндерә? — диде ул мәсьәләне тәмам шәрәләндереп.— Минем синнән дүрт-биш яшькә өлкән булуыммы? Укыйсым бар, семьяга башымны бәйләп интегермен, дип куркасыңмы? Әниең каршы килерен күз алдына китердеңме? Я булмаса минем әрсезләнүем, башлап тәкъдим ясавым нәфрәт уяттымы? Әллә боларның һәммәсе бергәме?

Мин һаман җавапсыз идем. Тик югалып калу халәтем узды. Сыныммы туры тотып, ир-егетләрчә җитди утыра башладым. Аның нинди дә булса җавап ишетми торып тынычланмасын да яхшы аңлый идем. Шуңа күрә:

— Мондый чакта җавапны бер кизәнүдә генә биреп була микән? — дидем. Шул сүз җитә калды, Дания Галиевна фикерен дәвам итте:

— Миңа шундый ышаныч каян киләдер, белмим, тик сине бәхетсез итмәсемне сизәм. Укуыңа комачау булмаячакмын. Монысын өзеп әйтә алам. Мин эшләрмен, минем белгечлегем буенча шәһәрдә дә урын җитәрлек. Син бик тырышып укырсың. Квартирага урнашырбыз. Ул ягын үзем көйләрмен...

Бу көнне мин өзеп кенә һични димәдем. Тел күтәреп әйтер сүзем юк иде. Аның каравы, миемне биләп алган уйлар бихисап иде.

Изге тамыры бармы әллә Дания Галиевнаның? Минем үзенә соклануымны, аңа карап сихерләнүемне ничек сизгән? Мин бит аңа, чибәр дә, акыллы да туганымны яраткан шикелле, сөйләп аңлаткысыз мөнәсәбәттә идем. Табигать гүзәллеген яраткан төсле ярата идем, матурлык өлгесе итеп, җанга рәхәт бирүче итеп. Өйләнергә уйлап түгел. Хатыным итеп күз алдына да китереп карамыйча. Нindидер бер илаһи ярату иде бит ул.

Әгәр Дания Галиевна тәкъдим иткән юлны сайласам? Иң беренче

булып әни каршы төшәр идеме икән? Төшәр иде. Ул болай да мине искән җилдән дә көнләшеп үстерде шикелле. Әти фронтка киткәч һәм аннан әйләнеп кайта алмагач, мин аның карап торган бердәнбер юанычына әйләнгән идем. Тормышымның мәгънәсе дип йөргән улы үзенең укытучысына, ир хатынына, балалы хатынга өйләнсен әле!..

Дус-ишләр, яшьтәшләр дә аңламас иде. Начар уйлар иде. «Өйрәнчеккә бәрәнчек булып авызланган да инде бу малай, шуннан башын аралый алмаган. Ә тегесенә... кайнар канлы яшьрәк ир кирәк булган. Ир өстеннән ир итеп тоткандыр да боргаланырга җайлары калмагандыр...» диярләр иде. Мине гаилә тормышын җимерүдә гаепләячәкләрен дә көт. Хәер, бу җәһәттән иң элек Дания Галиевнаны каһәрләячәкләр иде.

Укытучыларымның һәммәсе гаҗәпләнеп бот чабарлар идеме?

«Егет — башлы,— дип, мәсхәрәле елмаючылар да табылыр иде.— Стипендиягә яшәп изаланмаска уйлаган. Укытучы акчасына көн итәргә җыена...»

Имеш-мимешнең, гайбәтнең чиге булмас иде. Монысына шикләнмәскә мөмкин.

Моның тиклесе — минем Дания Галиевнага өйләнүгә читтән караш мәсьәләсе. Ә үзем? Үзем бәхетле була алырмынмы? Аның рухи дөньясын түгәрәк итәрлек көч табылырмы миндә? Аны бәхетле итәрлек кодрәткә ияме соң мин?

Руфия мәсьәләсе? Барыннан да битәр, шул сискәндерергә тиеш түгелме соң мине?

Башым катты. Институтка документларымны тапшыргач, Ташкыяга кайтмадым. Имтиханнарга әзерләндем, нужа куучыларга кушылып, баржа бушаттым, көнлек ихтыяҗларымның очын-очка ялгап барырлык акча эшләдем. Җиткән егет башым белән район промкомбинатында бухгалтер булып эшләүче әниемнең ярдәменә салынып ята алмый идем ич инде мин!

Уку елы башланыр алдыннан өйгә, әни янына кайтып килдем. Шул көннәрдә Дания Галиевнаны да күрдем. Үзем теләп, күрәсем, сөйләшәсем килеп. Шунда мин аның тәкъдименә кире җавап бирдем. Ипләп, йомшаграк итәргә тырышып. «Быелга сезнең вариантны сайлый алмыйм әле»,— дидем. Шул чакта авыр сулап, тирән көрсенеп әйтте инде ул. «Дөнья без дигәнчә генә түгел шул. Түгел!» — диде.

Аннары да очрашмадык түгел без аның белән. Студент чагында Ташкыяга кайткан саен мәктәбебезгә керми калмый идем. Ләкин Дания Галиевнаның миңа булган ашкын хисләре сүрелгән иде инде. Кайчандыр ялкыннары күккә үрелеп дөрләгән учак урынында яңгырлар юган салкын көл генә калган иде. Әйе, ләкин... аның йөрәгендәге учак, тормышның аяусыз бер каршылыгы булып, минем күңелгә күчте. Мин өйләнгәч тә, кызларым дөньяга килгәч тә, Дания дигән гүзәл зат уемнан китмәде, хыялымнан югалмады, үзенә чакырып, өндәп, ымсындырып торды. Хатыныма карата хөрмәт-ихтирам кайнарлыгы җитмәүгә дә шул хәл сәбәп булмадымы икән? Ниһаять, аңа карата битарафлык белән чиктәш мөнәсәбәтем аның күңел кыйбласы үзгәрүгә этәргеч ясамадымы?

Шундыйрак нәтиҗә ясыйм: кырык тугызынчы елның җәендә җаным тәрәзәсенә Даниядән рухи көмеш сыланып калды булса кирәк. Саф пыяла чагында җан тәрәзәсеннән киң дөнья күренә. Көмеш сыландымы, пыяла көзгегә әверелә, һәм кеше анда фәкать үзен генә күрә башлый. Мин дә үз-үземне генә күреп яшәдем шикелле ул елларда...

* * *

Чынлыкта Руфиягә кунакханә номерының кирәге дә калмады. Без озаклап Казан урамнарында йөрдек. Бик күп нәрсә сөйләштек. Әйтер-

сең лә эч серләребезне уртаклашыр өчен ерак-ераклардан махсус кайтып очрашкан идек.

Төн уртасы дип тормадык, минем квартирага кайттык. Хәзинәдә бары белән өстәл әзерләдек һәм таң сызылганга кадәр сөйләшеп утырдык. Руфия әледән-әле урамга караган тәрәзә буена барып килде һәм яңа көн тууын көтте.

Күк гөмбәзенең көн туар итәгендә баштарак сыек аксыллык хасил булды. Аннары анда шәмәхә-алсу тасма сузылды. Минуттан-минутка ул тасмада кызыллык арта барды. Ниһаять, офык читеннән ук-нурлар сирпелде, кояш күмәченең кырые күренде. Җәелеп аккан Идел буе иртәнге нурга чумды. Су өсте, биниһая зур көзгене хәтерләтеп, күз чагылдырырлык балкый иде.

Мин күңелемдә дә моңарчы булмаган балкыш яралуын тойдым. Шушы таңда күзләремнең дөньяга бөтәнчә ачылуын сизгәндәй булдым. Бу хакта Руфиягә сөйлисем килде, мәгәр тыелып калдым. Яшь җилкенчәк чагым түгел ләбаса! Урынлы-урынсыз сүзләрем белән әңгәмәдәшемнең кәефен җибәрермен. Үземә карата калыпланырга да өлгермәгән фикерләрен пыран-заран китерүем бар, дип уйладым.

Шулай да уйлар тәңгәл килсә килә икән! Руфия дә ул көнге җәйге таңны кабатланмас бер матурлыгы белән кабул иткән булып чыкты.

— Нилектән икән, бүген таң минем өчен серле дә, тылсымлы да булып атты? — диде. Һәм, танышып китүебездән соң беренче тапкыр булса кирәк, миңа томырылып, өздереп карады.

— Мин дә нәкъ шул сорауны бирергәме-юкмы дип тора идем, Руфия,— дидем.

Иртәнге җидедә мин аны Ташкыяга озаттым.

— Берсекөнгә Уфа поезды белән киләм,— диде ул вагонга менеп баскач һәм кул болгады.

«Каршыла!» димәде. Каршыламый калмасымны белгәнгәдер.

*Август, 1986.*

# Әмир Мәхмүдов

## Әни

Тиз үтте җиләкле җәйләрең,
Суынды ясалган чәйләрең...
Юксына күк сине ал гөлләр,
Җырыңны үз итте топольләр.
Син киттең. Моң китте. Җәй китте.
Без ничек яшәрбез җәйләрсез?
Таңнарда пышылдый чишмәләр:
«Җәйләрсез яшәве, ай, җайсыз...
Тормышны җәйләрсез җайларсыз...»
Җәйләрсез калсагыз, аңларсыз:
Җәйләрсез бу тормыш, ай, җансыз.
Көнчеләр тырыша төшләргә.
Ис китми үтмәгән төшләргә.
Серемне сөйләргә син кирәк:
Җәйләр күк, кер, Әни, төшләргә...

## Мәңгелек моң кебек

*Сибгат Хәким истәлегенә*

Изге Хәким! Кинәт ятим калдык,
Югалттык күк газиз әтине...
Ләкин
Мәңгелек моң кебек үлемсез син,—
Халык күңеленең хакиме!

## Мәхәббәт рәсеме

Зәңгәр күкләрдә тәгәрәп,
Чайкалып туйгач кояш
Офык артында югала,—
Болытка башын куйгач.
Көнозын печән исеннән
Башы әйләнеп, кыз бала,
Яры кочагында, эреп,
Кояш кебек югала...

---

ӘМИР МӘХМҮДОВ *(1947) — «Матурлык тантанасы» исемле шигырь китабы авторы. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә эшли. Филология фәннәре кандидаты. Казанда яши.*

## Зиратта

Тирләп-пешеп печән чаба
Бер ир заты зиратта.
— Сөякләремне турама! —
Диде үлән ир-атка.

## Бабай

Өйдәге терәүләр сынган,
Бабай үзе терәү булган...
Ак сакалы ак кар сыман,
Йөзен җыерчыклар сарган.
Өе исән, имин дөнья...
Чәй эчкәндә, бабай гына
Тетрәп ауган олы якта,
Яңа өйгә күчәр чакта.

## Хисләр

Минем хисләр гүя кайнар дәрья...
Еллар аша сиңа юл алам.
Бар дөньяны айкап барган кораб
Упкыннарга төшеп югалмас!

**Майя Вәлиева**

# ГАРЛАВАЧ

хикәя

I



Январь урталарында яз килде. Бернечә көн диңгез ягыннан ябалак-ябалак юеш кар яуды; ул җирне каплады, бик тиз эреде, һәм юлларда ябышучан көрән пычрак хасил булды. Кечкенә поселокның балчыктан салынган өй стеналары кабарды һәм томыкланды. Җил куакларның чәнечкеле ботакларында чыңлады һәм, ыжгырып, болганчык диңгез суына ташланды.

Беркөнне Рөстәм болдырга чыкты һәм хәйран калды. Күптәнге томанның зәңгәр рәшәсе сары җир өстенә җәелгән. Чип-чиста күк йөзендә диңгезнең зәңгәр сызыгы эреп бара. Диңгез чиккән. Ул ерак киткән, һәм ачык калган комлыклар көмешсыман слюда кебек ялтырыйлар. Поселок җанланды: киртә абзарда дөяләр кычкыра, карлыгачлар чыбыкка тезелеп чыркылдаша, хатын-кызлар, кычкырып сөйләшә-сөйләшә, келәм туку фабрикасына эшкә бара.

Бу аның Төрекмәнстанда беренче язы иде. Монда, тыюлыкка ул университет бетергәч билгеләнде һәм, биология фәненә кагылышлы әдәбият тутырылган биштәрен асып, кышлакка килде. Авыл аңа дөнья читендә югалып калган кебек күренде: көнбатышта Каспий диңгезе җәелеп ята, ә калган барча тарафтан тавыш-тынсыз һәм аксыл коры комлы очсыз-кырыйсыз сахра уратып алган.

Тыюлыкның барлык хезмәткәрләре дә үзәк усадьбада — бернечә йөз чакрымда урнашкан кечкенә шәһәрчектә яши. Ә Рөстәм кошлар тормышын кышлау урынында өйрәнергә булды һәм авыл читендәге бәләкәй генә балчык өйдә урнашты. Кайчагында, бик арган минутларда, ул үзен дөньядан аерылган итеп тоя, кайдадыр олы шәһәрләр булуына шикләнеп карый, хәтта аңа бөтен Җир шары чүлгә әйләнгән кебек була, һәм ул туган телен дә онытыр шикелле. Тиздән Рөстәм кышлак кешеләрен таный башлады һәм очрашканда баш кага торган булды: «Сәлам!» Ул ярыйсы гына төрекмәнчә сукалый, ничек тә булса кешеләр белән аралашу һәм, үзеңне ялгыз хис итмәс өчен, анысы да ярап тора.

Ул барыннан да бигрәк Дәлили күленә тартыла иде, ә аңа җан әсәре булмаган сахра буйлап көне буе барасы. Авылда исә аны тотып

---

МАЙЯ ВӘЛИЕВА *(1962) — прозаик, рус телендә басылган «Кара эт турында хикәя», «Торна тавышы» китаплары авторы. Казанда яши.*

калырдай бернәрсә дә юк. Шунлыктан, газикка мөмкин кадәр күбрәк азык-төлек, җылы киемнәр төяп, күлгә юл тотты. Анда начар гына каравыл өе — алачык янында алар әйберләрен бушаттылар, тиз генә капкалап алдылар, һәм Рөстәмне ике-өч атнага ялгыз калдырып, Комар китеп тә барды.

Күл котсыз зур, яр буйларындагы корыган саргылт камыш бамбук үсентеләрен хәтерләтә. Камышлыкта су тавыклары яшеренә һәм, кешеләрдән читкә йөзеп китеп һәм ашыга-ашыга аяклары белән суны ишеп, килешсез кыска канатларында авыр күтәреләләр. Аларның кара-кучкыл тыгыз тәннәре кояшта ялтырый. Рөстәм, яссы төпле кечкенә көймәдә яткан килеш, аларның чумганын һәм куышканнарын, мәзәк итеп сикерешкәннәрен бик озак күзәтә. Кара калкавычлары белән су өстендә меңләгән чүрәкәй, үрдәк һәм каз көтүләре чайкала.

Кояш көньяктан диярлек чыга. Аксыл шәмәхә Хорасан таулары артыннан әкрен генә күтәрелеп, ул көзгедәй тигез Дәлили өстенә төшә. Һәм торган саен кайнарлана барып, иртәнең әфлисун төсендәге болытларын яндыра.

Төнлә суынган тимер мичне тергезеп, Рөстәм капкалап алды һәм кошларны күзәтергә китеп барды. Бәрхет кебек йомшак, нәфис үлән җир өстен каплаган, качыр тоягы куаклары еракта үтә күренмәле шарларга охшаган. Зәгыйфь үсемлек кабарган бөреләре һәм әле йомшак, тар, яшькелт-зәңгәр яфраклары белән өметләнеп кояшка омтылган. Көндез кояш нурлары шулкадәр нык кыздыра, хәтта кызынырга да була. Берәмләп һәм көтүләре белән чүлдә дөяләр йөри. Алар ябага коя һәм шуңамы бик бетерешкән кебек күренә. Горур башларын югары күтәреп, өркәчләрен селкеткәләп һәм каты муеннарын сузып, азык күзлиләр.

Көннәрнең үткәне сизелми дә. Дәлилидәге күнегелмәгән, аңлаешсыз тормыш Рөстәмнең йөрәген соклану белән тутыра. Ул озаклап, шаккатып, сай сулыкны тутырып йөзгән соры каз көтүенә карый. Уйсулыкта уйнаган шакалларны күзәтә; алар гамьсезлекләре һәм киң күңеллелекләре белән әсәрләндерәләр, ишегалдында куышып йөргән этләрне хәтерләтәләр.

Кич белән, арган һәм кояшта мәлҗерәгән хәлдә, алачыгына кайта. Көнбатышта, бөтен күк йөзендә, шәфәкънең алсу учагы дөрли. Караңгы төшкән саен, учак ныграк яна һәм шунда, сихри күренеш булып, Хорасан тауларының иң биек ноктасы — ап-ак карлары белән ялтырап, Әл-Борса түбәсе күренә. Кояшның соңгы нурларында туган бу сихри күренеш алар белән бергә юк та була. Әйтерсең лә, кемнеңдер боерулы кул тибрәтүенә буйсынып, шакаллар хоры үзенең төнге симфониясен башлый һәм бик озак дәвам итә. Әкрен генә төн килә һәм, сүнеп баручы янгын төсле, күк йөзендә Зөһрә йолдызы гына җемелди. Рөстәм алачыгына керә һәм керосин лампасын якты итеп яндырып куя. Ә юка стена артында төне буе шакаллар өреп һәм улап чыга.

Каравыл өендә аның белән яшәгән бердәнбер җан иясе — бәләкәй генә Каспий кәлтәсе иде. Ул җылыга ияна һәм һәрвакыт утка чыга торган булды. Әллә аны элегрәк берәрсе кулга ияләштергән инде, ул Рөстәмнән һич кенә дә курыкмый, һәм стена чыгынтысына утырып, үзенең кечкенә соры күзләре белән кешене күзәтә. Рөстәм аңа чи ит кисәкләре ашата. Кәлтә елан аларны бик рәхәтләнеп ала һәм күз ачып йомганчы кабып та йота. Рөстәм аңа уена беренче килгән исемне кушты — Шушу һәм көтелмәгән күрше барлыкка килүенә бик шатланды. Шушу белән икәү күңеллерәк бит.

Бервакыт Рөстәм чүлдә бер картны очратты. Ул ашыкмый гына теркелдәүче бәләкәй ак ишәккә атланган иде. Аның өстендә кара төстәге төрекмән чапаны, башында йонлач бәрән бүрек. Җыерчыклар яргалаган коңгырт-көрән йөзе һәм куе ак сакалы ихтыярсыздан игътибарны

жәлеп итә иде. Ул әле бик бетәшкән кеше түгел — киресенчә, киң жилкәле һәм нык гәүдәле, мәһабәт карт агач кебек. Карт Рөстәм янына килде һәм, кызыксынып, аның чыраен күзәтә башлады.

— Әссәламегаләйкем! — дип исәнләште Рөстәм.

— Вәгаләйкемәссәлам, — дип жавап кайтарды карт. — Бу урын сиңа ошыймы?

— Әйе. Мин аны өйрәнәм.

— Яхшы, — дип елмайды карт. — Ә син... Шушы табигать кебек, шәфкатьле бул, улым.

Чыбык белән кагылуга, ишәк тау бите буйлап түбән таба элдертте. Рөстәм, кулын каш өстенә куеп, карт зәңгәрсу рәшә эченә кереп югалганчы, аның зур бүрегенә карап торды.

«Гажәп, — дип уйлады Рөстәм. — Ул монда нишли икән?»

Шушы карттан гайре ул бу чүлдә бүтән беркемне дә очратмады.



## II

Гарлавач үзенең аранында күптән ялыкты. Борын тишекләрен киңәйтеп, ул абзарның бәләкәй тәрәзәләреннән һәм ярым ачык ишектән кергән һаваны комсыз рәвештә сулады. Юеш жылы жир, тирес һәм тагын нидер исе килә, аңардан тамырларында кайнар кан кайный, һәм бу тыелгысыз ургылган көчтән үз-үзен кая куярга белмичә, ат кечкенә аранда арлы-бирле йөренде, алгы аяклары белән такта стенага бәргәләде. Тыгыз мускулларны тутырган көч бәйге таләп итә, ул бөтен гәүдәсе белән калтыранып куя, ярсу белән стенага борынын һәм ян-ягын ышкый, һәм кинәт, тырпайган очлы колакларын сагайтып, киеренке муенын югары күтәреп, туктап кала.

Бу язда Гарлавачка алты яшь тулды. Ул аукционнарда кеше ышанмаслык зур бәяләргә сатыла торган саф чабышкылар нәселеннән түгел. Аның тамырларында борынгы көнчыгыш атлары — данлыклы һәм нык ахалтекиннәр каны ага, ләкин бер заман аның ата-бабалары үзбәк карабаирлары — гади эш атлары белән кушылган иде. Карабаирлар киңчә, тәбәнәк, бөкрерәк зур башлы, алар Гарлавачның какча, килешле төзелешенә нык тәэсир иткәннәр, ләкин нәселләренә гажәеп чыдамлылык һәм көч, кыргый, тыелгысыз чабыш дәрте бүләк иткәннәр.

Гарлавач — ялык-йолык итеп торган кара туры. Ахалтекиннәр аңа буй һәм ефәк сыман йонлы юка тире биргәннәр, ә аның астында кан тамырлары ятьмәсе белән тарттырылган таш сыман мускуллар бүртеп тора. Аның гәүдәсе озын, яссы савырлы, тар, ләкин калку күкрәкле. Таза, төз муенын ул югары тота, ә инде ыргылып чапканда, аны гәүдәсе белән бер тигезлектә суза. Кара күзләре ачулы һәм шат ялтырыйлар иде.

Гомеренең барлык алты елын да Гарлавач Карадәгиштә үткәрде һәм бу кечкенә авылга шактый дан китерде. Әле ике яшьтә үк, зур чабышта беренче мәртәбә алдан килеп, ул бәхәссез жиңүче булып калды — бөтен Көнбатыш Төркмәнстанда Гарлавачны узардай ат табылмады, чын мәгънәсендә карлыгач[1]. Аның белән янәшә нинди(ләрне) генә куеп карамадылар. Кыргыз чабышкылары да, йөгерек аяклы жиңел делибүзләр дә һәм матур карабахлар да — барысы да Карадәгишнең озын торыклы, эре сөякле шушы айгырына оттырдылар.

...Ниһаять, шыгырдап абзар ишеге ачылды, һәм Гарлавач ат караучы Корбанмәмәтнең жиңел адымнарын таныды. Ат шатлыгыннан кешнәп жибәрде, тыела алмыйча тыпырчына башлады.

— Хәзер, малкаем, хәзер... Кояшка чыгарырмын үзеңне... Яз жит-

---

[1] Гарлавач — карлыгач (төрекмәнчә).

кән инде. Җәнлекләргә дә, кошларга да — барысына да кояш кирәк, — дип назлап сөйләнә-сөйләнә, карт аран капкасын ачты.

Шат юртып, Гарлавач тышкы киртәгә атылып чыкты, ә анда өч бия, пошкырына-пошкырына, саз таптыйлар иде инде.

Кояштан һәм борынына килеп бәрелгән исләрдән исереп ул тоныкланган күзләре белән агач киртәләр аша еракка, яшел төтен эчендә эрегән калкулыкларга таба карады. Сыерчыкларның чыр-чулы көтүе, алдан сүз берләшкән тәртипсез балалар кебек, аның баш түбәсеннән генә очып үттеләр. Кисәк кенә җилкенеп, Гарлавач баскан урыныннан киртәгә ыргылды һәм, каты тояклары белән бәреп, өске агачны чәрдәкләп ташлады.

— Әй, әй, Гарлавач! — дип кычкырды Корбанмәмәт һәм чыбыркысын әләктереп, ат артыннан йөгермәкче булды.

Ләкин Гарлавач ерак иде инде. Гүя җир үзе аны алга этеп-этеп җибәрә сыман тоелды, ул аяклары белән чак кагылып, чокырлар һәм калкулыклар аша очып кына чыгып, атлыгып чаба иде. Каны торган саен ныграк кайный, исертә, акылын томалый иде. Дөяләр, чәнечкеле үләнне әкрен генә күшәүдән туктамыйча, аптырап һәм уйчанланып җирән айгыр артыннан карап калалар. Авыл читендәге ат абзары отыры кечерәя барып, бөтенләй күздән югалды, ә алда якты кояш нурына коенган очсыз-кырыйсыз сахра җәелеп ята иде.

Гарлавач кояш батканда гына әйләнеп кайтты. Ат абзары янында туктап, эчкә баткан корсагын дерелдәтеп, кычкырып кешнәде. Аның тавышына Корбанмәмәт һәм аңа ияреп, караңгы чырайлы тәбәнәк бер кеше чыкты. Гарлавач шундук үзен чабышларга йөртүче Нурбирде тавышын танып алды.

Тәҗрибәле ат өйрәтүче Нурбирде ничә еллар инде Гарлавач белән ярышларга йөрде. Кем белә, әгәр аның белән башка берәү чапса, ат җиңәр идеме икән?!

— Син аны артык үз иркенә куясың, Корбан! Ул нишләптер начар күренә. Кыш көне ябыкканмы шунда? Коры сөяккә калган,— диде Нурбирде, канәгатьсез рәвештә атның сыртына кулын тидереп.

— Сөякчел инде, анысы дөрес. Тик ул һәрвакыт шулай. Аның каравы, ничек ялтырый. Комда аунагандыр, тилекәй.

— Тиздән чабыш, Корбан. Әгәр җиңсә, аны Ашхабад ат заводы алачак. Ә бу бик отышлы. Бәясенә бөтен бер ферма төзеп булачак.

— Син нәрсә? Ул ничек бу җирләрдән башка яшәсен? Аның тамырлары монда бит. Сагыштан үләр. Бәлки аның бөтен көче дә үзебезнең табигатьтән, шушы җирдәндер, ә?

— Ташласана, Корбан! Ат — ат инде ул. Аны шулай бәяләгәнгә син сөенергә тиеш. Бүген председатель белән сөйләштек — чабышка әзерләргә кирәк. Аңа көчле көндәшләр булачак, — дип, Нурбирде Гарлавачны ялыннан сыйпады.

Кешеләр сөйләменең чишмәдәй челтерәве Гарлавачка рәхәт иде. Ул арыды, аның йокысы килә башлады һәм, йокыга тала барган хәлдә, ул яңадан кояш һәм очсыз-кырыйсыз сахра күрде...

## III

Комар туйга өч малае белән килде. Юл уңаенда, Дәлилигә кереп, Рөстәмне дә ияртте.

Ажияб тигезлегенә бүген нидер булган кебек. Кешеләр машиналарда, ишәк һәм атларда килә торды, һәм шау-шулы, ыгы-зыгылы шатлык дала тынлыгын күмде. Терекөмеш кебек җитез кап-кара малайлар зур шат этләр ияртеп килгән, соңгылары исә ачусыз гына тирә-юньгә өргәлиләр. Рөстәм шау-шулы халык төркеме, дулкынланган егетләр һәм

көмеш сакаллы картлар, яшел, шәмәхә ялтыравык күлмәкләр кигән озын чәчле хатын-кызлар арасында йөрде һәм зур игътибар белән чуар ыгы-зыгыны күзәтте. Репродуктордан дутарлар моңы яңгырады. Саф һавада ак бүрек кигән ерак Хорасан таулары аермачык күренә иде.

Җайдаклар чабышка әзерләнә иде. Аларның тавышы егермедән артык атның кешнәве һәм тынгысыз пошкыруы астында күмелеп кала. Атлар янында, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, куллары белән һава ярып, ир-ат бәхәсләшә. Аттан атка күчә-күчә, алар бармак белән төртеп күрсәтәләр, сыртларыннан сыйпыйлар. Күбесен бүген кем беренче киләчәге кызыксындыра, — чөнки данлыклы Гарлавачның көчле көндәше пәйда булды — ул Ашхабадтан китертелгән ахалтекин токымлы Пулатлы. Озын, нәзек аяклы, сыгылмалы озын муенлы һәм кечкенә какча башлы, алтын сыман төстәге чигелгән матур дирбияле чаптар бөтен игы белән җирле атлар янында аерылып тора иде. Аның янында Гарлавач ябык һәм озын булып күренә. Аның тыгызланган мускуллары юка тире астында калтырый, һәм, борын тишекләрен киереп, борчылып һәм ачуланып, Гарлавач колакларын шомрайта. Аның кап-кара йоны кояшта зәңгәрсу төсмердә ялтырый. Корбанмәмәт атның муеныннан яратып сыпырды:

— Нәрсә, дулкынланасыңмы? Ярый...

Борчулы хисләр биләп алды картны. Гарлавачның килгән атка бирешүе белән карт һич кенә дә килешә алмады. Ләкин бу җиңүе белән Гарлавач мәңгегә картны ташлап китәчәк, ә моны исә Корбанмәмәт акылына да сыйдыра алмый иде. Чибәр Пулатлының бәйгене отачагына аның иманы камил. Һәм менә шуңа күрә дә йөрәге сыкрый.

Карт Гарлавачның ялын һәм койрыгын тарады да Нурбирдедән сорап куйды.

— Беренче киләсеңме?

— Әлбәттә, — дип өзде җайдак.

Дулкынланып, Нурбирде инде ничәнче мәртәбә тезгенне һәм иярне тартыбрак бәйләде.

Гарлавач бәйгеләрне бик ярата иде. Ул чабышта көчен җәлләми, чөнки бәйге аны үзенең ярсуына алып кереп китә. Сабырсызлык белән бәйге көткән Гарлавач хәзер дә ярсу һәм үҗәтлек белән чабышка ашкына, әгәр дә Нурбирде әз генә кулын бушатса, ул инде ут булып кайнарланган атны тыеп тота алмас иде.

Ара түгәрәк буенча. Бәйге башланасы багана янына атлар тәртипсез рәвештә тупланган. Алар, кысылып, бер-берсенә бәрелеп, чиныйлар һәм ыржайган авызларын югары күтәрәләр, тешләшәләр, тибенәләр. Җайдаклар тезгенне ныграк тарткан саен, аларның сабыры төкәнә бара.

Ату тавышы һаваны ярды. Атлар, үкерүче ташкын булып, алга ыргылдылар һәм шундук тузан болытына күмелделәр. Тыелгысыз, тәртипсез ташкын тигезлек буенча тәгәрәп китте дә минут саен сузыла барды.

Гарлавач, җайдакларны бер-бер артлы артта калдырып, тигез, эре адым белән чапты. Хәзер аның алдында биек, аксыл Пулатлы гына әлдертә һәм аның тояк астыннан чыккан тузан Гарлавачның күзенә тула иде. Әкренләп алар башка көндәшләреннән аерылдылар һәм кайдадыр еракта, артта, саңгырау һәм авыр гөләү ишетелде. Алар зур, җиңел кошлар кебек бер генә мизгелгә кояш нурлары чагылган арыклар өстеннән дә очып үттеләр. Тезгенне тарткалап, Гарлавач Пулатлыны узып китмәкче булды, ләкин Нурбирде аны артта тотып торды. Гарлавачның җирән йоны каралды, ян-ягында һәм муенында ак күбек бәреп чыкты, тозлы тир күзләрен әчеттерде. Тояклары белән юл кантарларын туздырып, атлар көчле ыргым белән калкулык өстенә күтәрелгәч, Нурбирде тезгенне җибәрде һәм аяклары белән йомшак кына кагылып, Гарлавачны алга каулады. Иркенлек тоеп, Гарлавач кинәт ыргылды. Нурбир-

де атка таба тагын да иелә төште һәм алар хәзер икесе бергә кушылып, тартылган кыл кебек җиргә ятып диярлек очалар иде. Ике ыргылуда ат тирдән каралган Пулатлыны ярты гәүдәгә узып китте. Якында гына аның борын тишекләре киң ачылган, маңгаенда ак сызык беленеп торган очлы башы күренеп үтте. Пулатлы гырлап, ләкин тирән һәм көчле сулыш ала иде, Гарлавач аның әле көче күп икәнне күрде. Колагына көндәшенең очлы тояклары чыкылдавы чалынды. Хәзер атлар берберенә шулкадәр якын торып, янәшә чаптылар ки, менә-менә алар бәрелешерләр дә, кайсыдыр икенчесенең тояклары астында калыр кебек тоелды. Соргылт җир аларга таба оча, һәм чуар, шау-шулы кешеләр ташкыны котылгысыз аларга таба агыла иде. Гарлавач тагын бер ыргылды һәм Пулатлыны әз генә узып китте. Һәм алар шулай фиништәге кешеләр төркеменә бәреп керделәр — алдан каратуры Гарлавач, бер генә секундка соңрак — Пулатлы.

Нурбирде, өзәңгегә басып, шатлыгыннан кычкыра иде. Алар янына йөгереп килгән Корбанмәмәт Гарлавачны муенынннан кочаклап:

— Булдырдың, Гарлавач! Арымадыңмы? — диде һәм атның иренен нән күбеген сөртеп алды.

Еш-еш сулап, Гарлавач аңа таба башын иде.

— Минем атым арыймы соң? Беркайчан да! — диде Нурбирде һәм атның муенынннан сыйпады. — Аның кебек атны бөтен Төрекмәнстанда таба алмыйсың. Йөзләгән Пулатлыны тезеп куй — барысын да узачак.

Нурбирденең сүзләре Пулатлыда чапкан җайдакка килеп тиде. Оттыруына рәнҗегән хәлдә, ул ачудан кычкырып җибәрде.

— Синең ул ишәгең бер түгәрәктән ары чаба алмый! Син чын бәйгенең нәрсә икәнен дә белмисең!

— Нәрсә? Мин чабышның нәрсә икәнен белмимме? Минем атның койрыгына тагылып ярышучылар — бер син генә түгел.

— Икенче әйләнешкә синең нәселсез атыңның көче җитмәячәк!

— Киттек! — дип, Нурбирде тегенә җикерде һәм атын кисәк борды.

Корбанмәмәт ике кулы белән дә өзәңгегә ябышты һәм кычкырып җибәрде:

— Туктагыз...

Нурбирде аягы белән этеп җибәрүдән карт җиргә ауды. Чыбыркы шартлавы һаваны ярды һәм Корбанмәмәт ераклаша баручы ат тояклары тавышын гына ишетте.

Газаплы һәм салмак ару кинәт кенә килмәде. Ул әкренләп бөтен гәүдәгә тарала иде һәм Гарлавач аякларының үзенеке түгел икәнен, гәүдәсеннән аерылуын тойды. Янәшәдә генә Пулатлы тонык ыңгырашу белән чаба. Гарлавач абына башлады, кинәт аның бөтен барлыгы чабуга карыша башлады, һәр яңа сикерештә куркыныч яшеренгән иде. Ләкин Нурбирденең куллары бу коточкыч чабышны туктатырга уйламый да — ул аны алга әйди. Һава җитми азаплады, кайнар һәм авыр сулыш атның бөтен эчен яндырды, ниндидер зур, каты төер тамак төбенә килеп терәлде. Күзләре томаланды, кызыл куыклар шартлап чәчелә башлады. Камчы башка, муенга бәрә, ләкин Гарлавач рәнҗү дә, авырту да сизми иде. Яңадан бугазга төер килеп тыгылды, ул бөтен гәүдәне тутырып зурайды. Менә шунда Гарлавач, бүтән чыдый алмыйча, җиргә ауды. Ул киселгән агач кебек егылды — зиһене сүнеп, караңгылыкка чумды.

## IV

Караңгы төшкәндә, Рөстәм әле юлда иде. Кояш баеды, ләкин куәтле ал төс җир астыннан балкыган кебек, һәм бу бәллүр балкышта Әл-Борса түбәсен кемнеңдер нәзек пумаласы сызып куйган сыман.

Бернича минуттан бөтенесе дә югалыр, шәфәкъ(нең) соңгы яшькелт шәүләсенә күмелер. Рөстәм жиргә сикереп төште һәм, Комар белән саубуллашып, ишекне япты. Машина кисәк кенә кузгалып китте дә караңгылыкта юк булды. Башка китерә алмаслык тынлык чигәләрне кыса иде. Рөстәм күзләрен Дәлилидән алалмыйча, тукталды. Хәрәкәтсез күл үзенең зурлыгы белән күк йөзенә охшаган иде. Әйләндереп капланган таулар аска таба — яңа туган айның нечкә ак урагына таба карап тора иде.

Шакаллар йөрер вакыт житте. Яр буендагы камышлар, куе куаклар арасында нәзек елак аваз ишетелде, аңа дистәләгән бүтән авазлар кушылды. Шунда ук, куркынып, йокы аралаш, казлар көтүе каңгылдады.

Рөстәм яр буена утырды. Су караңгыланды һәм анда тоньк йолдызлар әкрен генә калтырады. Рөстәмне Гарлавач турындагы уйлар бимазалый иде. Якты кояш, күбеккә баткан атлар. Кара туры атның куркыныч, жансыз гәүдәсе... Чүлдән аны арбага салып алып кайттылар. Ямьсез аерылган аяклары арба жаена чайкала иде. Гарлавач үле кебек тоела, бары тик зур ачылган коңгырт күз читендә яшь тамчысы күренә. Ниндидер карт, елап, арба артыннан атлый. Рөстәм үзе дә бугазына килеп терәлгән күз яшьләрен көчкә йотты.

Ул хәзер дә бичара хәлгә төшкән ат турында уйланды. Әйтерсең лә нәзек агач ботагы шартлап сынды. Ул үзен тагын да ялгызрак итеп тойды. «Нишләп тере жанны һәлак итү шулай жиңел икән, нишләп ул шулай яклаучысыз һәм нәзберек икән?!»

Фотоаппарат һәм күзәтү торбасы алып, Рөстәм иртә-таңнан каравыл өеннән чыкты. Яссы төпле көймәгә утырды да әкрен генә күл уртасына таба йөзеп китте. Томан салмак кына эреде, Рөстәм, су чәчрәтмәскә тырышып, әкрен генә иште. Томан эчендә, күтәрелеп килүче кызгылт-сары кояш нурларында, ул суда тын гына утыручы беренче аккошларны күрде. Алар, муеннарын сузып, канатларын жәеп уяналар, каурыйлары күз камаштыргыч ак булып ялтырый. Су тавыклары ыңгырашып сирәк-мирәк суга чумалар. Баш түбәсендә бернича шөлди сызгырып үтте, кайдадыр еракта, аргы ярда казлар кычкыра иде. Рөстәм авыр төннән котылуның сөенечен тойды. Су өстендә шат нурлар уйнады, күл иртәнге жиңел шадра белән капланды. Ул бик ерак йөзеп китте һәм кинәт күзенә ялтыравак нәфис — алсу сызык күренде. Бу — кызыл казлар иде. Зур көтү сай жирдә туклана, һәм ул аларның иелгән кәкре муеннарын, нәзек аякларын да аера. Кызыл казлар һавага күтәрелә башлады. Алар йөгереп барганда, йөзләрчә канатлар чагылып үтте. Кошлар көтүе, сихри алсу төсләрен ялтыратып, томанлы зәңгәр күктә әкияти сурәт барлыкка китерде. Алар, сулкылдап торган жанлы нәрсәне хәтерләтеп, я өчпочмакка охшап, я шар кебек түгәрәк хасил итеп, я нәзек тасманы хәтерләтеп, күл буйлап очалар. Аннары, кара ноктапарга әверелеп һәм акрынлап кояш нурларында эреп, һаман югарыга күтәреләләр иде.

Рөстәм, көймә төбенә ятып, бик озак күккә карап торды, елмайды, аннары жиңелчә чайкалган су тавышын, аның йомшак кына көймәгә килеп бәрелүен тыңлады.

## V

Гарлавач үлмәде.

Ул Корбанмәмәтнең көннәр буе яныннан китмәвен, төрле үләннәрне кайнатып эчертүен һәм тәненә сылавын белмәде. Гарлавач үзе белән ни булганын хәтерләми иде. Куркынган хәлдә, хәрәкәтсез килеш ул көннәр буе араның бер почмагында басып тора, башын түбән иеп йокымсырый, ә ишеккә кешеләр килгән чакта калтырап стенага сөялә иде. Ул Корбанмәмәттән генә курыкмый һәм аның ягымлы кагылуы атка рәхәтлек бирә. Гарлавач, аптырап, үз гәүдәсен ят малныкыдай итеп

тоя; күкрәгендә ниндидер зур әйбер кереп укмашкан, ул сулыш алырга һәм аяк атларга комачаулый. Ул бөтенләй ризык капмый диярлек, Корбанмәмәт зур авырлык белән аны кулдан ашата иде.

Кайчагында аңында бик үк ачык булмаган күренешләр хасил була: аны чакырып торучы яшел киңлек күз алдына килә. Ул югарыга, күзне камаштыра торган кечкенә тәрәзәгә карый һәм тын гына, ишетелер-ишетелмәс кенә ыңгыраша, пошкырына. Бервакыт Корбанмәмәт Гарлавачны араннан алып чыкмакчы булды, ләкин ат, нукта күреп, кыргый җанвардай, карттан читкә тайпылды. Аның аңын, бөтен барлыгын, боз кебек салкын дәһшәт белән тотырып, ниндидер коточкыч яктылык ярып үтте.

Көн артыннан көн узды, абзар тышында җәй җитте. Кояш, торган саен кайнаррак була барып, түбәләрне кыздырды. Чебен һәм кигәвен көтүләре очына, туган һәр көн шулар белән көрәштә үтә башлады. Гарлавач тирләүдән юпь-юеш булды. Гадәти эсселекне ул беренче тапкыр шулай авыр кичерде. Бөркү һава аның бугазын кыса, акрынлап миен эретә, менә шундый хәлдә аның хәтерендә инде еракта калган тормышы өзек-өзек калкып чыга иде.

...Ул язда Гарлавачка дүрт яшь тулды. Бервакыт, Корбанмәмәт картны алдалап, ул чүлгә чыгып чапты. Ярсыган, шаулаган язгы көч белән тулы хәлдә, әйтерсең, комсыз рәвештә нидер эзләде. Ялгызлык аны беренче мәртәбә талчыктырды, яңгыравык кешнәве, төпсез зәңгәр күк йөзе белән очрашып, өскә күтәрелеп китә иде. Чүлдә ул кыргыйланган кечкенә иран атлары көтүен очратты. Дәүләт чикләрен белмичә, андый малкайлар еш кына Хорасан тавы битләреннән Төрекмәнстан тигезлекләренә күченәләр иде. Ашкынулы бу атлар озын ял кебек сузылып, җилдәй җитезлек белән авыллар һәм сарык көтүләре яныннан чабып үтәләр, колхозларның малларын өркетәләр, күпчелек вакыт аларны да үзләренә ияртәләр иде.

Ярсулы буйсындыру теләге Гарлавачны чабып узган өер артыннан шундый көч белән ыргылдырды ки, ул аны әллә ни көч түкмичә куып та җитте һәм килгән уңайга, котырынып кешнәп, койрыгы җирдән сөйрәлеп барган тәбәнәк гәүдәле җирән айгырга ташланды. Гарлавачның очлы тояклары, нык теше һәм дуамал яшьлеге бар иде. Ул чабып барган уңайга әлеге айгырга үзенең таш күкрәге белән китереп бәрде һәм аны аяктан екты.

Яулап алган өердә өч бия һәм берничә яшь айгыр бар иде. Гарлавач каймак кебек акбүз бия янына килде. Аның төз, нык аякларында һәм арт санында нәфис соры алмалар беленеп тора иде. Сыртына беркайчан да кеше кулы тимәгән, атлас кебек акбүз тәнендә ияр һәм дирбия эзләре дә юк иде. Буйсынмас, горур биянең күзләрендә исерткеч гаҗәеп очкын балкый, — кулга ияләштерелгән гадәти атларда ул беркайчан да булмый.

Гарлавач аны үзе белән алып китмәкче иде, ләкин бия өердән аерылырга теләмәде. Гарлавач көтүне алып барган карт алмачуар бия артыннан иярергә мәҗбүр булды. Үзенең туган якларыннан Гарлавач отыры ераклаша барды.

Атлар диңгез ярына килеп чыктылар. Гарлавачның беркайчан да диңгез күргәне юк иде һәм ул аның шомлы, үзенә чакырып торучан очсыз-кырыйсыз киңлегенә хәйран калды. Үзсүзле өркеткеч дулкыннар, шаулап, ярга килеп бәреләләр. Бу аның чүленә караганда да ниндидер ышанычсыз һәм бик зур нәрсә иде. Ул үзенә чакыра, ләкин шомландыра, аптырашка сала. Бары диңгез өстендә, кычкырышып, кошлар гына очып йөри һәм аларның чөй сыман канатлары киң җәелгән. Гарлавачтан аермалы буларак, кыргый атлар бу гаҗәеп нәрсә белән беренче мәртәбә генә очрашмыйлар, ахры, тозлы су чәчрәтеп, диңгез буйлап сай судан чаба, ашыгып һәм чыр-чу килеп, диңгез эченә кереп баручы кошлар көтүен куркыталар иде.

Кинәт дингез үзенең бертуктаусыз агылып торган җырын пышылдаудан туктап, йокыга талгандай тынып калган бер кичне дә хәтеренә төшерде Гарлавач. Йокымсыраган йомшак дулкыннар ялкау гына яр буенда бәрелешәләр, ике зур кояш әкрен генә бер-берсе белән кушылалар. Гарлавачның башы ак биянең җилкә калкымында ята, һәм аңа, моннан соң беркайчан да насыйп булмаганча, бик рәхәт һәм тыныч иде.

Гарлавачның юкка чыгуы турында бөтен районга хәбәр ителде һәм күп тә үтмичә, аны кыргый атлар өерендә күреп алдылар. Гарлавачны тотарга Корбанмәмәт үзе килде. Күрү белән, Гарлавач аны исенә төшерде, һәм, шатланып, ышаныч белән иясе янына таба атлады, йөгән кидертте. Зур, ябык машинада Корбанмәмәт аны яратып башыннан сыйпады. Ак бүз биясен дә, кыргый ат көтүен дә Гарлавач яңадан беркайчан да күрмәде.

...Авырлык белән күзләрен ачып, Гарлавач стенага тайпылды. Аның араны янында өч кеше кычкырып һәм кайнарланып бәхәсләшәләр иде.

— Менә нәрсә, Корбан, без инде күп көттек, бүтән булмый. Мин бит аны теге вакыйгадан соң шундук гамәлдән чыгарып ташладым, чөнки ул өметсез, — диде Карадәгиш зоотехнигы Сапаров. — Кара, инде кешеләрдән дә читләшә.

— Их, Нури, үзең шундый яшь, институтта укыдың... — дип Корбанмәмәт сүз башлаган иде, ләкин председатель Ходайназар Мәмәтевич аны туктатты.

— Файдасыз хайванга ризык исраф итү эш түгел. Вакыт бирдек, Корбан, чөнки син хөрмәткә лаек кеше... Күрәсеңме, ат күтәрәмгә калган кебек, аягында көчкә тора. Иң хәчтерүш дөядән дә файда күбрәктер. Бүген аны исәптән чыгарам, шоферны җибәрәм дә кызыл Арватка ит комбинатына илтерсез.

— Сез Гарлавачның кем икәнен оныттыгызмы әллә?! Әле ничә мең таңкәгә сатарга җыенган идегез! Ул үз гаебе белән шушы хәлгә төштеме әллә? Әгәр дә без аның яхшылыгын яманлык белән кайтарсак, ничек җир йөзендә яшәрбез? Ат та кеше кебек, ул да гаҗизләнә... Сез бит, әйбәт токым үрчеткәнгә дигән мактау грамоталарын Гарлавач аркасында алдыгыз! Бөтен тирә-юньгә шауладыгыз...

— Ташласана, картлач, мин үз хуҗалыгымда кечкенә генә чыгымнарга да юл куймыйм. Атмы ул, сарыкмы — без аларны баш саны белән йөртәбез. Әгәр дә миндә эшлисең икән, таләпләремә буйсын, — дип, Ходайназар Мәмәтевич картның иңенә көпшәк кулын салды.

— Тагын бер ай вакыт бир, үтенәм, — диде Корбанмәмәт саңгырау тавыш белән.

— Сорама да, — дип, аны кисәк туктатты Ходайназар Мәмәтевич. — Исәптән чыгарырга дидем, исәптән чыгарырга. Озакламый машина җибәрәм.

Карт, алар киткәч аранга керде. Башы түбән иелгән ат әкрен генә аның янына килде, иңенә борынын төртте, авыр сулады. Аның күзләре сүнгән һәм җансыз иде. Бәлагә тарыганнан соң, Гарлавач бик нык үзгәрде. Йоны төссезләнде, ян-ягында каты кыршау кебек кабыргалары төртеп чыкты, сырты үзенең элекке матур кыяфәтен югалтты, бөтен гәүдәсе ипсез, ямьсезләнде, әйтерсең, Гарлавач хәзер инде яшәми, ә бары сулыш кына ала иде.

— Гарлавач, нишләттеләр алар сине, мескенкәем? Мин аларга сине үтерергә ирек бирәммe? Ул чагында минем карт сөякләремә җирдә дә, күктә дә тынгы булмас. Нигә дәшмисең? Әйтче берәр нәрсә!

Гарлавач башын түбән иде.

— Үзең китсәң икән ичмаса... Хәтерлисеңме, син далага китеп югала идең? Бернәрсә дә хәтерләмисең шул... Сиңа хәзер барыбер. Араның да пычранган. Җыештырырга кирәк... Минем үземә дә авыр инде, картайдым. Син дә картлар кебек...

Аһ-ваһ килеп, Корбанмәмәт абзардан чыгып китте. Аран ишеген

ачык калдырды. Гарлавач та әкрен генә араннан чыкты, тар коридорны үтте, капка төбендә тuктады.

Кич җиткән. Чүлдә тыныч, җылы, кояш баеп килә, таулардан салкынча һава агыла иде. Гарлавачның кайнар тәненә җиләс сулыш тиеп киткәндәй булды. Ул тирә-ягына гаҗәпләнеп карады. Караңгыланып килүче чүл аны үзенә тартты, һәм ул күзе караган якка атлап китте. Җайсыз, әкрен генә, әйтерсең, кызган ташларга басып бара иде.

Корбанмәмәт чиләк, себерке тотып әйләнеп кергәндә, аран буш иде.

— Гарлавач! — дип дәште карт. Абзардан йөгереп чыкмакчы иде, кире уйлады.

— Менә китеп тә бардың. Бөтенесен дә аңладың, акыллы хайван.

Карт утлыкка утырды һәм йөзен кулы белән каплады. Һәм шулай тын гына, хәрәкәтсез генә бик озак онытылып торды.

## VI

Әкрен генә, назлап кына көз якынлашты. Үзе белән тынлык һәм җиләслек алып килде. Анар өлгерде. Йорт тирәләрендәге бакчалардан дәү-дәү кавыннар җыелды.

Октябрь башында Рөстәм Дәлилигә кайтып килде. Җәйне ул Каспий диңгезендә, тыюлыкның утрауларында үткәрде, кабат Дәлили күлен күргәч, боларның барысы да аның йөрәгенә якын булуын, туган туфракның йомшак наз белән күңелен җылытуын тойды.

Кояш бер үлән дә калдырмаган. Бары дөя чәнечкесе — янтак кына сакланып калган.

Бервакыт күл буенда Рөстәм ялгыз ат шәүләсен күрде. Якынрак килгәч, үз күзләренә үзе ышанмады. Гарлавач? Юк, ул аны танымыйча булдыра алмый. Маңгаендагы менә бу кашкасы... Ул бу какча, киң танаулы башны таный, әлбәттә.

— Гарлавач! — дип эндәште Рөстәм.

Ат кыргый караш ташлады, колакларын шомрайтты. Агач кебек каткан аякларын көчкә сөйрәп, сузылган кулдан җайсыз гына читкә тайпылды. Рөстәм ягымлы быдырдап, сиздермичә генә атка якынлашты:

— Курыкма, Гарлавач, син әйбәт бит, акыллы. Син кайдан болай, үзең килдеңме?

Бәхеткә каршы кыр сумкасында ипи кисәге табылды. Атның борын тишекләре комсыз калтыранып куйды — Гарлавач ач иде. Ул ипигә үрелде, кеше кулына орынудан гәүдәсе тартышты, шулай да муенчак кидерүгә карышмады. Ул бик хәлсез, кинәт пәйда булган һәм үзенә ипи биргән кешегә карышырга көче юк иде.

— Я, киттек, киттек. Мин сине рәнҗетмәм. — Рөстәм әкрен генә бауны тартты һәм җиңелчә карышуын тойган хәлдә, атны артыннан ияртте.

Дәлилидән Карадәгишкә чаклы ара байтак иде. Гарлавачның ничек монда килеп чыгуы, чүлдә берүзе булуы һәм аны беркем дә эзләмәве хакында Рөстәм шактый баш ватты. Анда барып, барысын да белеп кайтырга карар кылды.

Абзар буш иде. Бары киртәләгән абзарда берничә бия ялкау гына йөренә һәм ак сакаллы бәләкәй карт кына җыештырына. Рөстәм бу картны исенә төшерде. Яз көне шул елады бит инде.

— Әссәламегаләйкем! Әйтегез әле, сез монда эшлисезме? — дип сорады Рөстәм.

— Эшлим.

— Гарлавач кайда соң хәзер?

— Гарлавач? — картның күзләре очкынланды. — Нигә аның хакында сорашасың?

— Мин аны яз көне күргән идем.
— Ә, яз көне... Хәзер юк инде ул.
— Кайда соң ул? — дип кызыксынды Рөстәм.
— Китте. Китте дә кире кайтмады.
— Аны беркем дә эзләмиме?
— Хәзер ул кемгә кирәк? Мин карт инде, аны аякка бастырырга көчемнән килми. Совхоз аны барыбер иткә тапшырыр иде, ярый инде, irектә үлсен.
— Абзый, ә сез ул атны яхшы беләидегезме?
— Әйе. Мин бит аны колын вакытыннан бирле карап үстердем. Ул иркә бала кебек иде. Мин аны гел үз иркенә куя идем. Аның холкы да йомшак, ягымлы...
Карт әле бик озак Рөстәмгә Гарлавачның тарихын сөйләде.
Дәлилигә Рөстәм соң гына кайтты. Керосин лампасы янында, стена аша Гарлавачның такта абзарда авыр сулавын, аяк тавышын тыңлап, бик озак утырды.
Әлбәттә, язга хәтле бу алачыкта калу хыялый саташу белән бер. Кечкенә тимер мич бу мескен алачыкны җылыта алырмы? Ләкин поселокка китү — атны ташлап калдыру дигән сүз. Ул бит инде атка ярдәм кулын суздь. Хыянәт итсенме?! Кешеләр инде ничә мәртәбә... Әгәр ул аны дәвалый алса? Бөтен хафалары өчен бүләк булыр иде. Кыш буена бик күп китап укып чыгарга, җәй көне җыелган язма материалны эшкәртергә мөмкин. Әгәр аңа калса, бу бит әле төньяк котыпта кышлау түгел. Фәкать Төрекмәнстанның көньягында гына.
Рөстәм Дәлилидә калырга хәл кылды.
Хәзер бөтен көннәр дә бер төрле башлана. Ул яман үҗәтлек белән Гарлавачның аягына массаж ясый, отыры адымын кызулата барып, бик озак ачык һавада йөртә. Хәрәкәтләрендә тора-бара катып калганлык һәм тоткарлану бетте, ләкин әле һаман элекке хәленә килә алмады. Дөрес. Рөстәмнән бөтенләй курыкмый, хәтта артыннан чүлгә дә баргалый. Гарлавачка бигрәк тә күл буена бару ошый. Көзен Дәлили караңгы чырайлы һәм соргылт төскә керә. Хорасан таулары яңгыр элпәсе артына кача, аларның сүрән түбәләре болытларга тиеп тора. Кичләрен шәфәкъ лимон төсенә буяла, Рөстәм Әл-Борса түбәсен ничек кенә күрергә тырышмасын, теләгенә ирешә алмый иде. Еш кына, җилгә иярең, кыска вакытлы яңгыр килә, ул стенага һәм түбәгә коела, шул чакларда Рөстәм үзен Төрекмәнстанда дип түгел, ә көзге урман эчендәге бәләкәй йортта кебек хис итә. Саргылт урман калган якта инде күптән кыш җиткәндер, әкрен генә кар явадыр...
Җил дөя чәнечкеләрен шыбырдата, житез болытларны куа, ачык зәңгәр тәрәзәләр калдырып, аларны өзгәли, тузгыта, шул тәрәзәләрдән кайчак бер мизгелгә генә аксыл кояш үрелеп карый.
Тар сукмактан алар Гарлавач белән бергә яр буена чыктылар, уйчан гына суга карап, бик озак тордылар. Җил атның озын җирән ялын туздыра, Рөстәмгә якын ук килгән дә борынын әкрен генә аның иңбашына куйган иде.
Салкын җил кыш исе алып килгән бер кичне Рөстәм алачыгының тәбәнәк ишек бусагасында утыра иде. Ул ак ишәккә атланган бер кешенең әкрен генә үзенә таба якынлашуын абайлады. Рөстәмгә аның кыяфәтендә ниндидер сер бар шикелле тоелды. Юлаучы якынлаша төшкәч, Рөстәм аны таныды: ишәккә атланган бу кешене ул яз башында ук Дәлили яры буенда күргән иде. Картның йөзе тагы да каралган, ә сакалы агара төшкән.
Алар исәнләштеләр. Кунакны шат каршылап, Рөстәм аңа чәй тәкъдим итте. Юлаучы ишәктән төште, үзенең киезен алды, үзе генә белгән нәрсәгәдер елмаеп, алачыкка керде.
— Һаман берүзеңме, улым? Өйрәнәсеңме? — дип сорады ул Рөстәмнән.

— Әйе, берүзем. Әле өйрәнер нәрсә дә юк, кошлар килеп җитмәгән.

— Беләм, беләм. Берүзең, кешеләрдән башка ямансу түгелме соң? Тиздән кыш җитәр. Ялгызыңа монда авырга килер.

— Мин ат белән бит. Бик каты чирле ул, нишләргә дә белгән юк. Ни белән генә дәваламадым инде, файдасы гына тими.

— Ат — яхшы ул. Ә ни булган аңа? — дип кызыксынды карт, чәйнектән касәгә чәй агызып.

— Куып эшт⁻н чыгарганнар аны. Тере мәет кебек.

— Миңа күрсәт әле син аны, — диде карт, әкрен генә кузгалып.

Рөстәм керосин лампасын алды, һәм алар такта абзар янына килделәр. Озын күләгәләре тонык кына яктыртылган стенадан үтеп китте, зәгыйфь ут яктысы Гарлавачның кара шәүләсенә, очлы колаклы һәм ялтыравык күзле башына төште. Бахбай, карттан сагайган карашын алмыйча, авыр сулап тынып калды.

— Яхшы ат, — дип уйчан гына әйтеп куйды карт. — Олы чире бар, авыр. Бер көндә генә дәвалый торган чир түгел.

Алар каравыл өенә кайтканда, мич өстендәге чәйнек күңелле генә сызгыра иде. Нидер хәтеренә төшерергә тырышкандай, карт сары ялкынга текәлгән.

— Әйе. Яхшы ат. Үз гомеремдә мин мондыйларны бик сирәк очраттым. Улым, колак сал әле, бер нәрсә сөйлим үзеңә.

Бу хәл бик күптән булган диләр. Ул заманнарда юлларда машиналар да, ә елгаларда күперләр дә юк икән. Кошлар һәм җәнлекләр көтүләре белән йөргәннәр, ә үләннәр һәм агачлар кайда үсәселәре килсә, шунда үскәннәр. Җәнлек-кошларны кул белән тотып сыйпаганнар, алар кешеләрдән курыкмаган, барча тереклек бер зур гаилә кебек яшәгән. Ул чакта кешеләр җәнлекләр һәм кошлар белән бергә гомер иткән, бер-беренә дә кардәшрәк булганнар.

Иректә яшәгән атлар үлән чемченеп йөргән, су эчкән. Җир өстендә чабар өчен аларның нык тояклары, җилдә һәм суыкта туңмас өчен калын йоннары булган. Шатлыктан муеннары белән уралышканнар, иркәләшкәннәр. Ачуланышып тибенгәннәр. Алар шуны гына эшли белгәннәр. Азык тулы араннар да кирәк булмаган. Менә кешеләр атларны буйсындыра башлаган. Малкайларның тәннәрен яндырып, келәймә сугарга тотынганнар, ялларын кыркый, тоякларын кисә, тышаулый һәм йөгәнли, аранга күнектерә, авызлык белән интектерә, чыбыркы һәм камчы белән кыйный, юыртып һәм сикереп чабарга өйрәтә башлаганнар. Тыңламасалар — ач тотып һәм кибектереп тилмерткәннәр. Шуннан атлар чирли һәм үлә башлаган. Камыт кигезгәч, авызлык чәйнәргә, тезген өзәргә, ачуланып кырын карарга һәм тешләргә өйрәнгәннәр. Ләкин атлар моңа гаеплемени? Бары мәхәббәт һәм шәфкатьлелек кенә бу атка ярдәм итә ала. Онытма шуны, улым.

Алар ишек төбенә чыктылар һәм каяндыр караңгыдан юлаучы янына әкрен генә акбүз ишәк килеп басты. Карт аңа атланды да аяклары белән аның янтыгына орынды. Сүнеп баручы төссез күк йөзе яктысында картның кара шәүләсе әле бик озак шәйләнеп торды.

Озакламый кар ява башлады. Рөстәмнең Гарлавачны үзе белән аласы килмәгән иде, ләкин ат тоягын үҗәтлек белән сарай стенасына бәрергә тотынгач, Рөстәм кире борылды һәм аның янына керде. Гарлавач йонлач һәм җылы. Рөстәм аның күзләре дымлы ялтыравын күрде.

— Бахбайгынам, алтыным, күзләрең елтырый башлады бит. Син тагын чабарсың! Без синең белән ерак-еракларга китеп барырбыз, әйеме? Акыллым, син курыкма, терелербез.

Гарлавач алгы аякларын алыштырып баскалады, озак һәм шаулатып сулыш алды.

Кышын үрдәкләр, аккошлар, казлар тирә-якны шау-шу һәм ыгы-зыгы белән тутырдылар. Кичләрен камышлыкта иран чыпчыклары чыр-

кылдаша һәм талаша, ә үлән арасында, үзләренең җайлы оялары янында, башка кошлар йомшак кына сызгырыша иде.

Рөстәм әкренләп Дәлилидәге тормышына күнекте. Монда кыш чыгу хәзер инде аңа нindidер гадәттән тыш һәм коточкыч булып тоелмый башлады.

* * *

Гыйнвар уртасында тагын яз килде. Күлләр, ерактагы таулар кебек, ачык зәңгәр төскә керде. Шашкан каз һәм үрдәкләрнең бихисап көтүләре су өстендә айкалды: алар я кинәт күлгә төшә, я шарт-шорт иткән коры тавыш чыгарып очып китәләр. Яр буендагы карт агач бөреләрен кабартты.

Гарлавачны борчу һәм аңлаешсыз халәт биләп алды. Әйтерсең лә, эчендә нидер эреде һәм аны калтыратып, кинәт кенә бөтен тәненә ага башлады. Күкрәге әрнеп җәфалады һәм Гарлавач, янтыгы белән стеналарга бәрелә-бәрелә, сарай эчендә йөренде. Аның сизгер борын тишекләренә хуш исле җылы җил килеп бәрелде. Бугазы кытыкланды һәм йөрәк турыннан чәчрәп көчле кешнәү авазы агылды.

Рөстәм ишекне ачуга, Гарлавач шатланып аңа таба сузылды. Ияр бәйләп, аның югары күтәрелгән башына йөгән кидерткән арада, атның тынгысыз алгысынуы үскәннән-үсә барды. Сыртында рәхәт авырлык һәм җиңелчә тезген какканны тоеп, Гарлавач бик теләп урыныннан кузгалды һәм тигез адымнар белән атлап китеп тә барды. Аны элекке, күптән онытылган хисләр давылы чолгап алды, курку һәм кыюсызлыгын җиңә барып, тыелгысыз һәм көчле теләк барлыкка килде. Аяклары элеккечә җиңел һәм нык иде. Ашкынып типкән йөрәге кабыргаларына бәрелде — Гарлавач кыюсыз гына юыртып китте! «Я, я, менә шулай кирәк», — дип, назлы куллар аңа көч биреп торды һәм тезгенне, үз дигәненә ирешергә теләп, отыры катырак тота иде. Гарлавач, дулкынланып, колакларын шомрайтты, авызлыкны йомшартыр өчен башын күтәрде һәм шулчак аның алдында җылы һәм кояшлы иркенлек пәйда булды: аны киеренкелек биләп алды һәм ул тынсыз калды. Ул үз тоякларының тигез басуына колак салганда, назлы куллар аны тагын алга өндәде. Аларның йомшак, ләкин көчле ихтыярына буйсынып, Гарлавач җиңел һәм салмак сикертеп чабуга күчте.

Шулчак кинәт барысын да исенә төшерде — бөтен барлыгы белән ашкынулы, куанычлы бәйгегә ыргылды.

Русчадан **Рәфкать КӘРАМИ** тәрҗемәсе.

# Нияз Акмалов

## Кый-гак-к!

1

Әллә күзен ишеттем мин,
Әллә инде язын,—
Нинди афәт куркыткандыр
Ул табигать казын?

Күзме, язмы — анысы барыбер,
Ишетүем кыйбат! —
Һаваларны кыеп алды
Шомлы аваз:
— Кый-гак-к!

Баласының һәлакәтен
Сизеп алган ана —
Ул да шулай соңгы чиктә
Өнсез аваз сала.

Әнкәй, әнкәй! Миңа да бит
Бик күптәннән таныш
«Сак бул, балам, сак бул!..»— дигән
Үзәк өзгеч тавыш.
Әллә ул каз җуйды микән
Бергә очкан парын,
Без яшьлектә җуйган кебек
Җанның газиз ярын?
Тәүге югалтудан бирле
Миңа шундый таныш
«Хуш, мәңгегә!..»— дигән шушы
Үзәк өзгеч тавыш.
Йөрәкнең дә кайчагында
Кычкыруы кыйбат.
Һаваларны кыеп алды:
— Кый-гак-к!

2

Шомлы авазларга, юкса,
Күптән ияләштек.
Әллә инде «Кый-гак-к!..» диеп
Аваз салды яшьлек?
Әллә инде аваз салды
Мәхәббәттә көю —
Яшерен янып, яшерен көеп,
Чын йөрәктән сөю.
Әллә инде ялгызлыкның
Белгәч төгәл хакын,
Аваз салды — ирсез генә
Бала тапкан хатын?
Әллә инде аваз салды
Кырык яшьлек буйдак?
Аваз салды ятим сабый —
Уеннардан уймак?
Йөрәк ишетергә тиеш,
Ишетмәсә колак! —
Һаваларны кыеп алды:
— Кый-гак-к!

3

Нинди афәт куркыткандыр
Ул табигать казын? —
Әйтерсең лә, яңгырады
Аның «СОС» авазы.
Йөрәк ишетергә тиеш,
Ишетмәсә колак,—
Әллә инде Казанымда
Аваз салды Болак?
Аваз салды безнең якның
Миләш-баланнары,
Ык буйлары, Идел яры,
Кама аланнары.
Әллә инде аваз салды
тайлар, чаптар атлар,
Аваз салды туып-үскән
Газиз туган яклар.
Аваз салды безнең якның
һәрбер иркә гөле,—
Әткәм теле, әнкәм теле,
Ата-бабам теле.
Әллә инде аваз салды
Соңгы тургай җыры?
Солы кыры, арыш кыры,
Илем-анам кыры.
Йөрәк ишетергә тиеш,
Ишетмәсә колак! —
Һаваларны кыеп алды:
— Кый-гак-к!

---

НИЯЗ АКМАЛОВ *(1954) — яшь шагыйрь. «Учак» исемле шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

4

Нинди афәт куркыткандыр
Ул табигать казын? —
Кайсы яктан ишеттем мин
Аның «СОС» авазын?
Көнчыгыш та, Көнбатыш та
Бездән шактый ерак.
Бик якында яңгырады:
Ливан... Иран... Гыйрак...
— Кый-гак-к!
Әйтерсең лә табаларда
Пешә майлы коймак,—
Сандаллардан корал төшә...
— Кый-гак-к!
Кешелекнең баш очына —
Чираттагы «коймак».
Таба — кызган, май салынган...
— Кый-гак-к!

5

Әллә күзен ишеттем мин,
Әллә инде язын,—
Нинди афәт куркыткандыр
Ул табигать казын?
Җылы якка очмый ул каз,
Оча дөнья буйлап.
Безнең якның «СОС» авазы
Күчә дөнья буйлап.
Ә галәмдә Җир үзе дә
Безнең яктай тыйнак.
Тыйнаклыгы әйбәт, ләкин —
Безнең якның кыр казыдай
Кычкыруы кыйбат!

...Һаваларны кыеп алды:
— Кый-гак-к!
Кый-гак!
Кый-гак-к!

## Сират күпере

Әйтеп сөйләш, кешем! Үз гомереңдә
Күперләрне күрдең ничә төрдә?
Ишеткәнең бармы Сират күперен?
Ә без менә бүген шул күпердә.
Ахирәттә генә имеш, дидең,
Күперләрнең була андый төре...
Дөньялыкта куып кертте менә
Шул күпергә сине үз мәкереңң.
Моңарчы да күпме күпер кичтең,
Тик аерма бүген бары шунда:
Сират күпере — инде соңгы күпер
Тарих дигән озын марафонда.
Тукталырга синең хәлең дә юк,
Хакың да юк бугай инде, кешем,—
Эстафета таягыдай итеп,
Тоттырдылар сиңа атом төшен.
Сират күперләре кылдан нечкә,
Кыл нечкәрә бара — кырыс шартлар!
Вакыт үзе хаким! Бу уенда
Булмаячак, димәк, фальстартлар.
Табигатькә рәхмәт — алдый белми,
Ымсындыра һаман тере суга.

Без сугабыз байтак кануннарга,
Алар, кайтып, безгә кире суга.
Без чабабыз тирләп, янып, сусап,—
Тере сулар әмма чирап тора.
Саф чишмәләр — ярда. Яр — күренми.
Чирап торган суга чират тора.
Без — күпердә. Сират күперендә!
Оттырганны монда упкын йота.
Аргы яр да, бирге яр да ерак,
Марафонда — соңгы эстафета!
Кемнәр алда дисәм — аз күренә,
Кемнәр кылда дисәм — күп күренә.
Өелешеп кереп киттек менә
Кылдан нечкә Сират күперенә.
Без кичәргә тиеш бу күперне,
Без эчәргә тиеш тере суны!
Без белергә тиеш үзебезнең
Ни хакына болай тырышуны.
Сират күперләре кылдан нечкә,
Кылдан нечкә, кылычтан да үткен!
Аргы яр да, бирге яр да ерак.
Без барабыз. Аста — төпсез упкын...

❃

Иң борынгы бөек философлар
Йолдыз санап яшәр урында,
Калын-калын трактатлар язган
Дәүләт төзелеше турында.
Ул дәүләтләр күптән җимерелгән,
Кичә туган — бүген искергән.
Төсләр, хисләр алмашынган саен,
Фәлсәфәгә бүтән төс кергән.
Фән агачы үскән, тамырлары
Җиргә һаман ныграк бәйләнгән.

Фән дигәнең фәлсәфәгә тарган,
Фәлсәфәсе фәнгә әйләнгән.
Без борынгы түгел, без — бүгенге!
Галимнәрдән, ләкин, сер кача.
Бар дөньяга урта белем кергәч,
Гыйлем ягы калды уртача.
Җирне, күкне, айны, йолдызларны
Бергә сөеп яшәр урында,
Философлар һаман нидер яза
Дәүләт төзелеше турында...

## Үлчәүдә

*Венесуэланың 22 яшьлек кызы Барбара Паласиос 1986 елда Панамада узган «Мисс вселенная» конкурсында планетаның иң чибәр хатын-кызы булып танылды.*

Син бар, димәк! Шушы планетаның
«Ул — бердәнбер...» дигән чибәре!
Кайсы чишмәләрдә битең юдың,
Кайсы якның йомшак җилләре
Иңнәреңнән назлап үтте сине,
Чәчләреңне сыйпап таратты?
Кайсы фәрештәләр әфсен әйтте,
Нинди алла сине яратты?!

Илдән-илгә йөр син, бар дөньяны
Гүзәллегең белән шаккатыр.
Күз кырые белән генә мин дә
Карар идем сиңа бер тапкыр.
Синең өчен шәһит китәр идем,
Колың булыр идем, көлмәсәң.
Мин, чыннан да, шулай итәр идем —
Бу дөньяны бераз белмәсәм...
Ә дөньяда алыш-биреш кайный,
Шаулап-гөрләп барган ул сәүдә
Матурлыкны читләп үтәме соң?!
Читләп үтми, егылып үлсә дә!
Очраткан да сине, янәшәңдә
Хак килешә бүген ул сәүдә.
Нечкә билең, калку күкрәкләрең
Яткан чакта шушы үлчәүдә —
Бер бичара, сине күрер өчен,
Соңгы малын тотып суйгандыр;
Кемдер, бәлки, бары сиңа атап,
Көмеш читлек ясап куйгандыр.
Кемдер анда синең чибәрлектән
Шакмак-шакмак алтын койгандыр;
Бер мескене, сине күрүгә үк,
Җаны җылынганын тойгандыр...
Сәүдә — кырыс: керсез яшьлектән дә,
Хыялдан да хәтта хак эзләр.
Төрле яктан төрле уйлар белән
Төбәлгәндә сиңа ят күзләр —
Айлы төнең, керсез газапларың
Урамнарда ялгыз йөргәндер,—
Бикле ишекләрдән кералмыйча,
Уйларыңа гына кергәндер.
Кергәндер дә, күкрәгеңә тулып,
Авыр итеп сулап куйгандыр.
Яшьлек, бәлки, үзенең матурлыгын
Үлчәүләргә кергәч җуйгандыр.
Сәүдә — кырыс: билеңне дә үлчәр,
Илеңне дә үлчәр ул сәүдә.
Чын мәхәббәт, ләкин, билен бирми,
Чын матурлык — менми үлчәүгә!
Мин бәхәскә хәтта кермәс идем,
Гүзәл гөлләр җирдә сулмаса.
Син дә мине, бәлки, аңлар идең,
Бу кадәр үк чибәр булмасаң.
Илдән-илгә йөр син, бар дөньяны
Гүзәллегең белән шаккатыр.
Безнең якның болын гөлен сиңа
Бүләк итәр идем бер тапкыр...

## Безнең якка ул чак...

Кыр өстеннән китерделәр аны,
Бульдозерлар белән сөйрәтеп,—
Без малайлар атлар көткән чакта,
Йөргән чакта тайлар өйрәтеп.
Кыр өстеннән китерделәр аны —
Тупыллардан биек манара.
Без беренче тапкыр һушлар китеп
Карап торган идек аңарга.

Ат онытылды!.. Ул чак май-мазуттан
Өс-баш бетте, битләр каралды.
Беренче кат безнең күз алдында
Атлар качты, көтү таралды.
«Разведчиклар нефть эзли монда!..»—
Аттан шәбрәк чапты бу хәбәр.

Безнең өчен диңгез була иде,
Инештәге суны бусалар.
Без бу якка килгәч, ничә тапкыр
Ат көтүе китте таралып.
Ә аннан соң... күлдә балык бетте,
Казлар кайтты судан каралып.
Безнең якка ул чак вышка килде —
Чиркәүләрдән биек манара.
Офык артын күрер сыман булып,
Үрмәләгән идек аңарга...

Туган якка кайтсам — онытылам,
Кайтам кебек малай чакларга.
Безнең якта хәзер атлар түгел,
Бәбкә дә юк инде сакларга...

*

Яхшы атлар үргә чабып менә,
Томырылып үрнең башларына.
Бәкәлләре канап-канап кала,
Бәрелә-бәрелә үрнең ташларына...

Яхшы атлар үрдән әкрен төшә,
Төшлек бавын күкрәк белән тыеп.
Үр менгәндә тойган авырлыкны
Тагын бер кат йөрәк белән тоеп...

## Гөнаһ

Бернәрсәгә дәгъва кылмыйм бүтән,
Исбатламыйм һичбер нәрсәне,—
Кешеләрнең төгәл санын белсәк,
Гөнаһларның, димәк, бар саны.

Шул бер гөнаһ җанда йөри безнең,
Шул бер гөнаһ күздән гел бага.
Һәр кешедә иң зур гөнаһ тик шул:
Үз вакытында килмәү дөньяга...

## Соңгы хат

*«Сыгылмагыз әле, сабыр канатларым...»*

С. Сөләйманова

Соңгы хатым сезгә, соңгы хатым.
Соңарачак ул да, соңласа.
Мин бу хатны язмас идем, бәлки,
Сабыр канатларым сынмаса.
Һәм бу хатны язмас өчен миңа
Тышау кирәк, йә бер авызлык.
Сынды, сынды сабыр канатларым,
Һәм сындырды аны явызлык.
Сандугачлар качты тал-тирәктән,
Моржа оя шул ук чәүкәгә.
Мунча ташы кебек кыза дөнья,
Себеркеләр уйный ләүкәдә.
Сүнде, сүнде күзнең учаклары,
Кышлар тупылы мамык очыра.

Каян синдә шундый усаллык дип
Сорау бирүең бар бу чорга.
Кадимиләр үзенең тәгъбирендә,
Карагруһлар үзенең көчендә.
Мин мең гасыр яшәдемме әллә
Инде шушы гомерем эчендә?
Мин беркемгә әле әйтмәгәндә,
Уйламаган чакта бу хакта,
Кемдер инде җавап язган кебек
Мин язалмый йөргән бу хатка.
Мин бу хатны, бәлки, язмас идем,
Сабыр канатларым сынмаса.
Соңгы хатым сезгә, соңгы хатым,
Соңарачак ул да, соңласа...

# Нур Әхмәдиев

# РАФИС

хикәя



Дөресен әйткәндә, Рафис эшкә бүтән җиргә дә урнаша алыр иде. Үзенең бу адымы белән ул әти-әнисенең хәтерен дә калдырды сыман.

Әйе, күпләрне гаҗәпкә калдырды Рафис Таһиров. Ничек инде «ун ел буена бер генә «дүрт»ле алмыйча диярлек укы, мәктәпне алтын медальгә тәмамла да, теләсә-кайсы югары уку йортының ишеге синең өчен киереп ачып куелганда гына, институтка документларыңны да җибәреп карама, имеш. Гаҗәпләнерлек шул. Әнә ич, аттестатында кәкребөкре «өч»ләдән гайре билге күрмәгәне дә, институтка керү өчен, ничекләр генә тырышмый. Ятып калганчы, атып кал ди торганнардыр. Физика һәм математика буенча район чемпионы исемен алган, республика олимпиадаларында баштагы өч урыннан да түбән төшеп карамаган Рафис Таһиров дигән чибәр егет, һичшиксез, Мәскәү я Казан университетына укырга керергә, берничә елдан «фән йолдызларының» берсенә, үзен укыткан мәктәпнең горурлыгына әверелергә тиеш иде. Ә ул әнә нәрсә ди:

— Берәр ел эшлим әле, аннан күз күрер.

Их, киребеткән, тискәре, ташбаш малай син! Эшләргә, майга-тузанга батып йөрергә өлгермәм дип куркасыңмыни?! Әнисенең теленнән бу сүзләр ычкынмаса да, аның гаҗәпләнү һәм үпкә белән каравыннан Рафис моны бик ачык сизде.

Әтисе белән сүз ирләрчәрәк барды.

— Ярар, эшлим дисең, сүземдә торам дисең икән, әйдә безнең цехка. Слесарь итеп алам.

— Син ачуланма, әти, бармыйм мин сезнең цехка.

— Ничек инде бармыйм? Ә син беләсеңме безнең цехның ниләр башкарганын? Бездән башка нефть чыгарып булмаганын?

— Әти... син мине аңламадың... Әгәр ул цехның начальнигы син булмасаң, керер идем мин анда. Ләкин... начальнигы — син бит. Эшкә анда керсәм, минем үз исемем дә калмаячак, «начальник малае», «Таһиров малае», дип кенә йөртәчәкләр.

Ата кеше борын астына әле күптән түгел генә мыек төртә башлаган улының дәлилле фикеренә, тормышта үз юлын үзе табарга омтылуына сокланып каравын сиздермәскә тырышты:

НУР ӘХМӘДИЕВ *(1946) — «Аһәң», «Бал яңгыры» һ. б. шигырь китаплары авторы. Әлмәттә яши.*

— Я, хуш, шулай да иттек ди. Инде кая урнашырга телисең?

Рафис, әтисенең күзенә караган көе, бераз дәшми торды. Соңыннан:

— Беләсеңме,— диде ул, акланган тавыш белән,— промыселларга барган идем, унсигез яшь тулгач килерсең диделәр. Жир асты ремонты уздыру цехында да...

— Аны сиңа мин дә әйтә алган булыр идем. Сорасаң, әлбәттә.

— Үзең белү начармыни, әти? Автоматлаштыру цехына кеше кирәк түгел. Белештем.

— Андагылар белән үзем сөйләшермен. Алырлар...— Өлкән Таһиров, хәзер үк хәл итәргә җыенгандай, телефон трубкасына үрелде.

— Әти! — Рафис әтисенең каршысына килеп басты.— Минем Ханнан Кадыйрович малае булып йөрисем килми.

— Нигә? Гарьләнәсеңме әллә Ханнан малае булуыңа?

— Син — бик әйбәт кеше дә, әти...

— Рәхмәт, салпы якка салам кыстыра беләсең икән.

— Мин — чынлап. Тик... тик, аңламыйсыңмыни, минем бары Рафис Таһиров кына буласым килә. Миңа бит тагын биш айдан унсигез яшь тула. Ә унсигездә Гайдар инде күптән полк белән командалык иткән, Шамил Усманов генерал дәрәҗәсенә күтәрелгән диләр.

— Салават Юлаевның ике хатыны булган дип тә өстә!

— Анысы да хак, әти. Ә син үз улыңның һаман әтисенә аркаланып яшәвен телисең.

Суйды, чалкан яткырды бу малай актыгы! Ханнан Кадыйрович шаяру тонына күчеп сорады:

— Инде, Рафис иптәш, эшкә кая керергә уйлыйсыз?

Әле генә кайнарланып, үзенең шәхес икәнлеген исбатларга тотынган Рафис, салкын суга төшкән мәче баласы шикелле, шиңеп, бөрешеп калды.

— Уйлыйсы юк инде,— диде ул аннан әкрен генә.— Мин... мин... пар һәм су белән тәэмин итү цехына урнашам. Гаризамны идарәнең кадрлар бүлегендә калдырып кайттым. Иртәгә килергә куштылар.

— Кем итеп алдылар инде?

— Минем бит мәктәптә өйрәнгән һөнәрем бар. Слесарь-сантехник.

— Кем итеп дисең? — Ханнанның болай да зур күзләре соң чиккә җитеп ачылды. «Дисең» сүзе нечкәреп, ничектер ярым чыелдап, ярым ысылдап чыкты. Тавышының алай чыгуыннан ул үзе дә оялып куйды.— Сантехник дисеңме? — дип сорады ул, бугазына утырган төердән котылгач.

— Әйе, әти.

— Ә сез, Рафис Ханнанович, бу эшнең романтикасын әйбәт беләсезме? Сантехниклар кран алмаштырып, муфтага сүс урап кына йөрми, тыгылган бәдрәфне дә чистарта, су тулы коеларга да төшәләр.

Рафис, янып торган күзләренә өстәмә очкыннар чыгарып, әтисенә текәлде. Шунда Ханнан үзе өчен көтелмәгән бер ачыш ясады: улы чибәр һәм мәһабәт булып үсеп җиткән икән ләбаса. Тфү-тфү, күз тимәсен тагын!

— Әти, син мине башкалар шикелле эшли алмас дип уйлыйсыңмы, әллә андый эшкә керешүем түрәлек абруеңа сугамы?

Кара син аны, шайтан малаен! Болай телгә осталыгын сиздергәне юк иде бит моңарчы. Мәктәпнең комсомол оешмасы секретаре булып сайлангач өйрәнде микәнни? Мондый сорауны бары тик вөҗданы саф һәм үзенә нык ышанган кешеләр генә бирә ала. Юк, начар малай үстермәгәннәр алар. Укыса-укымаса да, бу малай югалачак түгел. Ул инде кеше булып, шәхес булып формалашкан.

— Ярый, улым, мин каршы түгел, ничек теләсәң, шулай ит. Җаны теләгән — елан ите ашаган. Тик әйт әле: нигә син быел ук укырга кермисең? Әллә сере, берәр сәбәбе бармы?

Рафис, кызара төшеп, күз карашын аска төбәде. Әле яңа гына унынчы класска күчкән Рәмзия белән алдагы елда икесе бергә укырга керергә сүз куешканнарын әтисенә ничек әйтсен ул? Ләкин җавапсыз да калырга ярамый иде.

— Эшләп карыйм әле бирәр ел диде́м бит инде.

— Әллә Рәмзия җибәрмиме? — Ханнан улының Рәмзия белән дуслыгын белә иде.

— Ну, сине, әти! — диде Рафис үпкәләгән тавыш белән.— Уйлап та чыгарасың инде. Андерсен!

— Ярый, бетте, бетте! — Ханнан, беләбез без сезне дигән төсле, шаяртып, кашын сикертте һәм, улының җилкәсеннән җиңелчә кагып куйды. Бу аның хуплавын аңлата иде...

Рафис баштагы берничә көндә цех белән танышты, инструктаж алып, хәвефсезлек техникасы кагыйдәләрен өйрәнеп йөрде. Рөхсәт итсәләр, боларның ул барысын бер көндә ерып чыгар иде дә бит, тәртипне бозарга ярамый диделәр.

Рафисның эш киеме киюе үзе бер маҗарага әверелде. Келәттә аңа яраклысы юк иде, шуңа күрә кырык алтынчы урынына илленче үлчәүдәге форма тоттырып җибәрделәр. Кигәч, шаклар катты: чалбарының төбе тезенә кадәр салынып тора, балаклары ун сантиметрлап озын. Курткасының җиңеннән кулы күренми дә. Эшче дигәч тә, сантехник дигәч тә... Бу кыяфәттә ничек кеше арасына чыкмак кирәк? Ялгыш Рәмзия очрап куйса!

Ике дә уйлап тормыйча, Рафис тегү машинасына ябышты: бөкте, кыскартты, тарайтты — ничек итсә итте, эш киеме үзенә сыланып ук тормаса да, оялмыйча киярлек хәлгә килде.

Рафисның бүген йөрәге түзмәде, ул җиденче яртыда ук цехта иде инде. Әле кешеләр берән-сәрән генә иде, биш-ун минут үтүгә, күзгә күренеп арттылар. Озакламый төп цехтан читтәрәк урнашкан авария-диспетчерлык хезмәте бинасы яны вокзалга охшап калды. Участок эшчеләре — брезент киемнәре, калын табанлы ботинкалары белән килбәтсез күренгән эретеп ябыштыручылар, иңнәренә сумка асып, кулларына торба ачкычы тоткан сантехниклар, дөнья мәшәкате белән бирегә килгән халык арасында юньләп күзгә дә чалынмый. Йомыш кемнәрне генә китерми монда: типсә тимер өзәрдәй әзмәвер агайлар дисеңме, колак яфракларына алтын алкалар аскан фырт апайлар, таякка таянган әби-бабайлар дисеңме! Алар дежур диспетчер утырган бүлмә тәрәзәсе каршына тезелгәннәр дә чиратлап үз гозерләрен әйтәләр.

Мондагы — диспетчерлык пункты янындагы ыгы-зыгы Рафиска бик кызык тоела.

Слесарьларны икешәр-өчәр кешелек төркемнәргә бүлделәр дә адреслар буенча җибәрә башладылар. Рафисны кырык-кырык биш яшьләр чамасындагы Гайнанга беркеттеләр.

Участок башлыгы аңа:

— Менә, Гайнан дус, сиңа бер яшь иптәш бирәбез,— диде.— Рафис исемле бит әле син? Әйе, Рафис. Вәт менә Рафиска һөнәреңне өйрәт. Кара аны, тегенди-мондый булмасын. Яшь егетләр безгә көн саен эшкә кереп тормыйлар.

— Соң, туган...

— Юк, син минем нәрсә әйтергә теләгәнемне аңладыңмы?

— Аңладым да...

— Аңласаң, бетте. Бүтән кабатламыйм.

Гайнан үз итеп, якын итеп: «Әйдә, энекәш»,— дип эндәшкәч, моңа кадәр Рафиста булган кыенсыну, ятсыну хисе юкка чыкты.

Сәгать сигезгә эшкә йөрүчеләр әле юлда гына. Ә Рафислар инде тулы сугышчан хәзерлектә. Гайнан абыйсы кулында эш кораллары, сүс, резина прокладка, муфта, сырлы торба башлары һәм башка шуның ише нәрсәләр салынган кыр сумкасы, ә Рафис тыгылып калган торбаларны чистарта торган корыч чыбык, озын саплы ачкычлар тоткан. Бу минутта аның өчен шушы ачкычлардан да кирәклерәк бер генә корал да юктыр сыман.

Рафислар барып кергән иң беренче квартира, иртән участокка килеп, ваннасыннан су агуына зарланган әбинеке иде. Әби юкка зарланмаган, су шаулап ага. Тынычлык яратучы карчыкның гына түгел, Рафис кебек яшь-җилкенчәкнең дә колагын томаларлык.

Монда озак торырга туры килмәде. Гайнан абыйсы, вентильне ябып, су килүне туктатты да, Рафиска аңлата-аңлата, көйләп тә куйды. Белгән кешегә әллә нәрсәсе юк икән лә аның!

— Булды, әбкәй, рәхәтен күр.

Карчык башта, ышанмагандай, ванна ишегенә колагын куеп, тыңлап торды, аннан соң рәхмәт укырга тотынды:

— Кулларыгыз сызлаусыз булсын, балакайлар, эшегездә фәрештәләр юлдаш булсын. Җан тынычлыгымны алган иде бит шул каһәр. И, балалар, чәем кайнаган, чәй эчеп китегез. Бүген көне дә бик бөркү булырга охшаган.

— Юк, әбкәй, рәхмәт, әле эш күп,— дип җавап бирде Гайнан.— Рафис, әйберләреңне җый.

Ямашев урамында эш катлаулырак булып чыкты. Гайнан, килә-килешкә үк, Рафисны подвалга алып төшеп китте. Андагы борылмалар буйлап кесә фонаре белән яктыртып бара торгач, уңлаган задвижка урнашкан бер почмакка барып төртелделәр.

— Менә бусын карап кал, энекәш. Әгәр мин кирәк дип әйтсәм, төшеп, сәгать теле уңаена борырсың.— Ябу уңаена Гайнан задвижканы борып күрсәтте. Һәм аты-юлы белән сүгенеп куйды: — Һәрбер юнәлештә һич югы берәр вентиль куйсалар, бөтен йортның суын туктатып та торасы булмас иде, корт чаккырлары!..

— Ә нигә куймаганнар?

Гайнан, яңа гына күргәндәй, аңа сәерсенеп карады:

— Булмаганга! Проектлары шәп, тик төзи башласалар, аны йөзгә үзгәртеп бетерәләр. Әллә вентиле җитәрлек кайтмый, әллә кайтып та, «сул»га олактыралар, синең белән минем кебек сантехник братка җәфаланырга гына кала. Салкын суы әле, ярар, рәтләп бетерүгә, ачтың да җибәрдең, шуның белән вәссәлам. Менә кышын квартираларда пар бетсә! Линияне туктатмыйча төзәтеп булмый, туктата башласаң, кайбер урында бер подъездныкын гына түгел, бөтен йортныкын ябарга туры килә. Соңыннан, ачып җибәргәч, иң өстәге катка менеп, һәр квартирада радиаторың һавасын чыгарырга кирәк. Эшендә брак чыкса, шуны ике-өч тапкыр кабатлыйсың. Һавасын чыгармый торып, йорты җылынмый, бер квартира аркасында йорттагы бөтен кеше туңып утыра. Менә шулай, энем. Кабул итү комиссиясенә нәрсә аңа — кул куйды да котылды. Чиләнергә безгә кала.

Рафисларның төшкелектән килүен өлкән мастер Газизов көтеп тора иде.

— Озак йөрисез,— диде ул шелтәләгән тавыш белән, гәрчә төшке ял бетәргә әле биш-ун минут калган булса да.— Хәзер әнә агрегаты белән Исмәгыйльне алыгыз да Фрунзе урамына барыгыз. Почмак йортта, син аны беләсең.— Газизов башы белән ишарәләп, Гайнанга күрсәтте.— үзәк торбалары ярылган, подвалны су баса башлаган. Тагын берәр кеше биримме, әллә...

— Кирәкми, безнең Рафис — ут егет,— диде Гайнан абыйсы тиктомалдан мактап.

— Сез атлый торыгыз алайса, Исмәгыйль хәзер килеп җитәр.

Өлкән мастер әйткәндә үк күңеленә килгән иде, чыннан да, подвалын су баса торган йорт Рәмзияләрнеке булып чыкты.

Ишегалдында чагыштырмача тын иде. Зурлар эштә, бала-чага пионер лагерьларына, балалар бакчасына, авылларга таралышып беткән. Нәни арбада бала йоклатучы ике хатын һәм бер-берсе белән гәпләшүдән тәм табып, көннәрен уздыручы биш-алты карчык кына күренә иде.

Слесарьлар якынлашкач, үз йортларында гына түгел, поселоктагы хәлләрдән дә хәбәрдар бу карчыклар башта әңгәмәләрен туктатып, берничә секундка тынып калдылар да, узара бүлдерә-бүлдерә, акыл өйрәтә башладылар:

— Икенче подъездан керегез, анда әле су басмаган.

— Син нишләп, Галиматтәй, олы башың белән юкны сөйләп торасың? Анда караңгы бит. Лэмпечкәсе юк. Батырасың киләмени аларны?!

— Әстәгыфирулла тәүбә, диген, Зәйнәп, нишләп минем батырасым килсен ди. Авызың ни әйткәнне колагың ишетми.

Шулчак Рэмзиянең әбисе кулын каш өстенә куеп карады да Рафисны төсмерләп алды:

— Бәй, улым Рафис, син түгелме соң бу?

— Исәнмесез,— диде Рафис.

— Эшлисеңмени?

— Әйе.

— Түрә малае башың белән подвалда саз ерып йөрмәсәң. Атаң юньлерәк эш тапмадымыни үзеңә?

Рафисның җен ачуы чыкса да, тыелып калды. Беренчедән, өлкән кеше, икенчедән, Рэмзиянең әбисе ич ул. Нинди дә булса җавап бирел өлгергәнче, Гайнан абыйсы карчыкның авызын томалады:

— Эшнең юньсезе юк бит аның, әбкәй. Синеңчә, мин юньсезмени?

— Тәүбә, тәүбә, әйттем исә кайттым. Нишләп сине юньсез диим? Димим. Әтисе зур кеше булганга гына әйтәм.

Агрегат килгәнне көтеп тормастан, слесарьлар подвалга төшеп китте. Гайнан үз участогындагы йортларда кайда ни урнашканлыгын туган-тумачасын белгән шикелле белә иде.

Подвал, чыннан да, караңгы. Үч иткәндәй, ник бер лампочка янсын. Килеп керү белән күз берни күрми, ярый әле кесә фонаре бар, шул коткара. Бераздан күз ияләнә тагын, кечкенә тәрәзәләрдән төшкән саран яктылыкта бәрелми-сугылмый йөри ала башлыйсың. Аяк астына урыны-урыны белән шактый су җыйналган. «Күнитекнең ялтыравы бетәр инде. Рэмзия күрсә...» Рэмзиянең сүз әйтмәгәнен дә белә Рафис, тик пычранып беткән, шыксыз кыяфәттә аңа бик күренәсе килми, шул ук вакытта күңеленең кайсыдыр почмагы бу теләгенә каршы да төшкән сыман. Күрсен әйдә, нәрсә булган күрсә, ул бит эшче кеше, мәктәп баласы түгел.

Уйга бирелеп, искәрмичәрәк калган икән, маңгае белән шап бетонга! Күзеннән Рэмзия түгел, утлар күренде. Моны алдан атлаучы Гайнан да сизде.

— Син, энекәш, саграк атла, башыңны бәреп куйма. Күз чыгару да кыен түгел безнең эштә. Нәчәлник малае өчен бик үк кулай түгел инде ул подвалда йөрү. Ә ансыз булмый. Без бит — подвал академиклары,— диде ул, шаярта төшеп.

Ләкин Рафис аның шаяртуын мыскыллау дип кабул итте.

— Гайнан абый, әгәр тагын нәчәлник малае дисәгез, мин башка кешегә беркетүләрен сорыйм.

— Бетте, бетте, энекәш. Ә син — шәп егет!

— Ник?

— Пычрак эш дип тормагансың.

— Кеше эшләгән нигә миңа ярамасын?

— Нигә укырга барасы итмәдең? Әллә аттестатыңда билгеләр аерткан сөт төсле сыек идеме?

— Юк, алай ук начар түгел иде.

Яктыртып бара торгач, торбаның ярылган төшен эзләп таптылар. Задвижка төбеннән бәреп чыккан икән.

— Әһә, синмени әле ул, җанкисәгем? Хәзер, хәзер көйгә китерәбез без сине.

Ләкин Гайнан уйлаганча ансат кына булып чыкмады. Фонарь яктысында задвижкага якынлашуга, кинәт эт өреп җибәрде һәм усал итеп

ырылдап куйды. Кѳтелмәгәнлектән икесе дә, сискәнеп, артка сикерделәр. Гайнанның фонаре, кулыннан тѳшеп, суга чумды. Рафис, ирексездән, Гайнан абыйсына сыенуын, йѳрәгенең дѳп-дѳп тибүен тойды.

— Нинди эт бу? — диде үзе дә сизмичә пышылдауга күчкән Гайнан, фонарен эзләп алганнан соң.— Задвижкасы шунда бит аның.

— Маһ-маһ, кил әле монда, кил! — дип, кыяр-кыймас, тагын бер адым ясамакчы иде абзый, усал ырылдау туктатты аны.— Нәрсә калган сиңа монда? Бар, якты дѳньяга чык. Эт кебек ѳреп ятма сасы подвалда. Бар, бар, безгә эшләргә кирәк монда, аңлыйсыңмы? Күрмисеңмени подвалны су басканын? Кешеләрнең келәтенә су керәчәк бит, юләркәй.

Эт чигенмәде, кырыйга да китмәде. Бозау кадәр эт белән ике слесарь күзгә-күз карашып басып тора бирделәр. Эткә рәхәт, ул корыда, ә алар...

Кырыйданрак яктырткач, этнең ни ѳчен болай ярсуы ачыкланды. Аның артында чи-чи килеп ятучы балалары бар икән.

— Менә шушыдыр инде эт тормышы,— дип сукранып куйды Гайнан. Үзенә карата әйттеме ул моны, эткә каратамы, Рафис, аңлап бетермәде.

Тора-бара Рафис этне танып алды. Бу бит шушы ишегалды малайларының кышын ат урынына җигеп тә, атланып йѳреп тә әвәрә килә торган этләре. Ишек тѳбендә Рәмзияне кѳткәндә күргәләгәне, хәтта бер-ике тапкыр сыйпап та караганы бар. Тукта, исеме ничек иде соң әле? Памирмы? Юк, Казбек. Әйе, Казбек бит.

— Казбек,— дип дәште Рафис булдыра алган кадәр ягымлырак тавыш белән.

Эт, исемен ишетүгә, башын күтәреп, колакларын тырпайтты һәм Рафиска карады.

— Казбек исемле ул, шушы ишегалдыннан. Казбек, Казбек,— кулын сузып, Рафис эткә якынайды. Ул этнең теләсә кайсы минутта ѳреп җибәрүенә әзер иде. Ләкин Казбек ѳрмәде, Рафисны ул да таныды, күрәсең, муенын алга таба сузды, тик баскан урыныннан кузгалу турында уйлап та карамады.

Казбек янына килеп, Рафис аның башыннан, ияк астыннан, сыртыннан сыпырды. Кешеләрдән качып, аулакта балалаган эт иркәләүгә, назга үзе дә сусаган иде ахрысы, Рафиска сырышып, рәхәтләнеп тора бирде. Шунда аның балаларына карады: иске фуфайка ѳстендә күзләре дә ачылып бетмәгән дүрт кѳчек бер-берсенә сыенып яталар.

— Задвижканы ябалмассыңмы? — диде эт белән Рафисның бик дустанә мѳнәсәбәтен күргән Гайнан абыйсы.

Әйтүе ансат ансатын. Рафис задвижкага таба аягын атларга да ѳлгермәде, Казбек усал ырылдап җибәрде. Анда барырга сиңа да рѳхсәт юк, янәсе.

— Кире борыл! — үзенә беркетелгән яшүсмернең балага таруыннан коты алынган Гайнан, кирәге чыкса дип, торба ачкычын кысыбрак тотты.

Балалары янына якын бармагач, Казбек тынычланды, бүтән ырылдамады.

— Син, апай, яктыртып тор, мин аңа дәвасын табармын.

Гайнан кайдандыр таяк табып алган, шуның белән куркытмакчы иде исәбе, әмма Казбекның тѳсе бѳтенләй үзгәрде, усалланды. Әле генә Рафис янында иркәләнеп торган эттә балаларын саклау инстинкты шул кадәр кѳчле иде ки, урыныннан аны тере кѳе берничек тә кузгатып булмаячагын аңладылар.

— Да... кыз да утызда...— Гайнан бүтән әйтер сүз тапмады.

Су сизелерлек артты. Алар кергән чакта әле коры булган кайбер урыннар инде су астында калды. Шушы тизлектә агуын дәвам итсә, тагын ѳч-дүрт сәгатьтән Казбекның балалары да тончыгып үләчәк.

Артта берәүнең суны чупылдата-чупылдата килгәне ишетелде. Исмәгыйль икән.

— Я, нәрсә булган?

— Задвижка тѳбеннән бәргән.— Гайнан яктыртып күрсәтте.

— Каяле, карыйм әле.— Исмәгыйльнең алга таба бер адым атлавы булды, Казбек усал итеп өреп куйды.
— Нинди эт бу?
Исмәгыйльгә хәлне аңлаткач, Гайнан:
— Нишлибез? — дип сорады.
— Ни генә эшләсәк тә, тиз кыланырга кирәк. Су итек кунычыннан керә башлагач, соң булыр. Әгәр урам башындагы задвижканы ябып карасак?
— Аны ябып, ни отабыз? Ничә йортны сусыз тотаргамы? Һәм ничә көнгә? Этне моннан куып җибәрми торып, берни дә эшли алмаячакбыз.
— Ә ничек куабыз?
Исмәгыйль бераз уйланып торды да:
— Мин хәзер,— дип чыгып китте.
Ун-унбиш минуттан ул кире керде.
— Кызганычын кызганыч та бит, бөтен йортны су басканын көтикмени? Син, Гайнан, берүк миңа яктырта күрмә, фонареңны эткә юнәлт. Үзегез урыныгыздан кузгалмагыз. Хәзер. Ярый әле Габбас өйдә иде, мылтыгын биреп торды.
Рафис шунда гына аның ни эшләргә җыенганын аңлап алды. Габбас мылтыгын төбәп тора иде.
— Атма!
Рафис Исмәгыйль янына ничек барып җитүен дә, мылтыкка ничек асылынуын да сизми калды.
— Син нишлисең, малай актыгы?! — Исмәгыйль, Рафисның якасыннан алып, кырыйга этәрде.— Маңгаеңа ядрә ала яздың бит. Кит, комачаулама!
— Атмыйсың! — Рафисның бугазына төер тыгылды, күзен яшь пәрдәсе томалады. Бәхетеннән, подвалда караңгы иде, күрмәделәр.
— Туктагыз әле сез,— дип арага керде Гайнан,— сугышмагыз да, талашмагыз да.
— Әллә минем җан кыясым килеп тора дип беләсезме? — диде аңа каршы Исмәгыйль.— Этнең балалары үсеп җиткәч, күченгәнне көтеп торабызмы? Әйт, алайса нишлибез?
— Син иң башта мылтыгыңны хуҗасына кертеп бир.— Гайнан, күрәсең, бер карарга килергә өлгергән иде.— Аннан резагыңны алып төш.
Исмәгыйль каршы әйтеп тә, төпченеп тә тормады. Унбиш-егерме минутлардан, суны чапылдата-чапылдата, шлангларын сөйрәп кереп җитте. Рафисның күзләре иярләнгән, фонарьсыз да ярыйсы күрә башлаган иде.
— Хәзер болай итеп карыйбыз,— серне эт ишетмәсен дигәндәй, Гайнан пышылдауга күчте.— Син газыңны кабызасың да, эт өстенә барасың. Уттан курыкмый калмас ул, бүре кавеменнән бит. Берәр төрле кысрыклап булса, балаларын әнә тегендә алып куябыз. Моннан балаларын күчерсәк, аннан соң подвалда ник аның белән кышламыйсың, бүтән ырламас.
Ләкин Казбекны куркытуы алай ук җиңел түгел икән. Ул пешә, чигенә, әмма балалары яныннан узмый, ялкынга каршы сикерә. Гайнан берничә тапкыр көчекләрне алырга дип үрелеп карады, Казбек ирек бирмәде, соңгысында хәтта җиңеннән каптырды.
Менә шунда Рафис, үзе дә уйламыйча, мәсьәләне хәл итте. Казбек белән Гайнан җиң өчен тартышканда, Рафис көчекләргә таба иелгән итте һәм чыгып йөгерде. Казбек аның артыннан ыргылды. Куып җиткәндә, Рафис инде подъездга чыгып өлгергән, ләкин куллары буш иде. Эт, алдануын аңлап, чиный-чиный, кире ташланды. Шушы берничә секунд Гайнан белән Исмәгыйльгә көчекләрне читкәрәк күчерергә мөмкинлек бирде.
Ярсыган эт, көчекләрен урынында тапмагач, тешләрен шыгырдатты, Гайнаннар бер-берсенә сыенып, һөҗүмне кире кагарга хәзерләнде. Чөнки

эт менә-менә алар өстенә сикерер сыман иде. Тик этләр исне әйбәт сизә, балалаган чакта бу сыйфатлары тагын да көчәя төшә. Казбек та кайдадыр якында, шушында гына бик таныш һәм дөньяда иң тәмле ис сизеп алды. Слесарьларны онытып, балалары янына китеп барды. Әле генә, тешләрен шыгырдатып, күзләрендә ачу яшеннәре уйнаткан, кешеләрне өзгәләп ташларга торган куркыныч ерткычтан балаларын исән-сау күрү шатлыгыннан нишләргә белмәүче бәхетле анага әверелде дә калды Казбек. Ул шыңшый, елый, кызыл телен чыгарып, көчекләрен ялый. Үзе, әледәнәле шикләнеп, кешеләр ягына карап ала.

Слесарьларның, бәхетле ана белән аның балаларына карап, озак юанып торырлык вакытлары юк иде. Әле эш башланмаган да, сәгать инде дүртенче киткән.

Гайнаннар ничек эшләргә икәнен белә. Суны туктатып, торбаның ярык җирен ямап куясын Рафис та чамалый. Ләкин инде эш сәгате чыгып бара. Йортны сусыз калдырырга да ярамый. Җитмәсә, торбаның ярыгы стенага караган, резак белән һич керер хәл юк. Нишләргә?

Подвал тәрәзәсеннән өлкән мастер Газизовның башы күренде:

— Бетәме, егетләр? Сезнең янга төшеп булмады, су икән. Агрегатны алып кайтырга машина җибәримме?

— Башламадык та бит әле, Зәйнулла Хәбирович.— Исмәгыйльләр, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, вакыйганы сөйләп бирделәр.

— Аңладым, егетләр. Инде сез дә мине аңлагыз: йортны ничек тә бүген сулы итәргә кирәк. Администрация һәм профсоюз белән үзем сөйләшермен.

— Ярар, кирәк икән, кирәк. Без — солдатларча.

— Ә син, Таһиров, дүрт тулуга кайтып кит.

— Мин башкалар белән бергә кайтам, Зәйнулла абый,— диде Рафис аңа каршы төшеп.

— Ярамый, Таһиров, ярамый. Унсигез яше тулмаганнарны эш сәгатеннән тыш эшләтергә безнең башка тай типмәгән. Ярый, мин Коноваловлар янына киттем.

Ямарга җайлы булсын өчен, торбаны стена яклап лом белән бераз каера гына башлаганнар иде, тузуы шул хәлгә җиткән икән, лом тигән урыны тагын тишелеп чыкты.

— Абау, искегә тисәң, исең китә,— диде Гайнан.— Болай гына котылып булмаячак икән безнең. Дүрт-биш метрын кисеп алып, яңа торба ялгарга туры киләчәк. Син, Рафис апай, кайт участокка, срочно биш метр озынлыкта шушындый торба җибәрсеннәр.

— Кемгә әйтим?

— Мастерлар китеп бетмәгәндер. Китсәләр, дежурный кала, аңа әйт. Тиз йөрергә тырыш. Ә без аның бусын кисеп ташлый торабыз.

Рафис никадәр ашыкса да, участокта сине бик көтеп тормыйлар икән. Дежур машина ягулык салырга киткән, ә башкаларының эш сәгате чыгып, өйләренә таралышканнар.

Торбаны китергәч, Гайнан:

— Булдырдың, егет! — дип мактап куйды.— Син түзгән, түзгән, торбаның ике башын каптырганчы тотышып тор инде. Бу кадәр озынга үземнең генә хәл җитмәс. Аннан китәрсең.

Рафисның бүген кич Рәмзия белән киного барасы исенә төште. Сигезенче яртыда шушы йортның ишеге төбендә очрашырга сүз куешканнар иде алар.

Ул торбаны каптырганнан соң да кайтып китмәде. Башлаган эшне, бергә эшләгән иптәшләрен ярты юлда ташлап калдырса, үзенә дә, өлкән иптәшләренә дә, хәтта тынычланып, балалары янына яткан Казбекка да хыянәт итәр сыман иде. Аннан соң Рафисның, эшне тәгәлләгәч, торбадан су килүен, йорттагы кешеләрнең шатлануларын үз күзләре белән күрәсе, җиңүче сыйфатында чыгып, шул шатлыкны уртаклашасы килде. Торба алып килгәндә абайлады ич: кешеләр эштән кайтып юыныр-

га, ашарга пешерергә тели, су булмагач, чиләк тотып, күрше йортка йөгерәләр.

Исмәгыйль, күзен битлек белән каплаган да, әле өстән, әле аркасы белән җиргә ятып, торбаны ябыштыра. Электродның торбага тиюеннән якты очкыннар чәчри һәм подвалның түшәмендә, стеналарында шәүләләр биешә. Күз белән ул яктыга туп-туры карарга ярамый диләр. Авырттыра икән. Подвалның үзенчәлекле сасы һәм дымсу исенә металл эрегән, янган, көйгән ис кушылды.

Ниһаять, Исмәгыйль битлеген салды:

— Бетте ахры.

— Хәзер тикшереп карыйбыз аны.— Гайнан задвижканы ачты. Торба эченнән шаулап су киткәне ишетелде. Яңа гына ябыштырып куйган урын күзгә күренеп тирләде.

Слесарьлар ябыштырган җөйне яктыртып, капшап, хәтта тыңлап та карадылар. Тишек калмаганмы?

Яктыга чыгуга, Рафис, беренче эш итеп, Рәмзияләр ишек төбенә күз салды, үзенә арты белән утыручы сөйгәнен күреп, йөрәге сикереп куйды. Сәгатенә карагач, сискәнеп китте: сигез тулырга егерме минут. Нәрсә уйлый икән? Рәмзия соңарган өчен үпкәләгәндер инде.

Хәзер үк кыз янына барасы, эндәшәсе килде. Тик кунычыннан ук кызыл балчыкка баткан итегенә, торба тутыгы һәм лай буялган киеменә карагач, икеләнеп калды: «Әллә, күзенә чалынганчы, өйгә таяргамы? Ә бәлки шушы көе барырга да: «Исәнме, Рәмзия. Вакытында килә алмадым, эштән бушап булмады, сезнең өйне сулы иттек»,— дияргәме? Юк, пычрак кием белән, бу кыяфәттә күренүе уңайсыз».

Инде кайтып китәргә дә уйлаган иде, Гайнан абыйсы эшне бозды. Ул:

— Я, Рафис, сау бул. Инде кызлар янына барсаң да була,— диюгә, егетнең исемен ишеткән Рәмзия борылып карады да, елмаеп, аның каршысына килеп басты.

— Галиҗәнаб эшче сыйныфына сәлам! — диде ул, күрешергә кулын сузып.

— Исәнме, Рәмзия,— Рафис та үзенә сузылган кулны кысарга үрелде, ләкин ярты юлда туктап калды. Һаман да пычрак бияләйләрен салмаган икән. Бер селтәнүдә бияләйләреннән котылды да кызның кулын учына алып кысты. Бу кулларның беркайчан да аңа бу кадәр кечкенә, кайнар һәм йомшак тоелганы юк иде әле.

Балконнан Рәмзиянең әбисе кычкырган тавыш ишетелде:

— Рафис улым, ходайның рәхмәте, су булды. Әйдә, кереп, чәй эчеп ал...

**А. А. Ефремов,**
КПССның Кама Тамагы район комитетының беренче секретаре

# ТАУ ЯГЫ

Таллы-куаклы, ерганаклар белән челтәрләнгән туган төбәгебез куеныннан акрын гына тибеп торган саф сулы кизләү-чишмәләр, челтери-челтери, Үләмәгә ашыгалар. Эреле-ваклы йөзләрчә чишмәләрдән көч алган Үләмә, Иделгә бик якын булуына карамастан, суларын аңа капма-каршы якка агучы Зөягә илтеп коя. Тау ягыннан егәр алгач кына, Зөя үзенең олы туганы, киң, алкын Идел белән кушылу бәхетенә ирешә. Чал Идел белән Кама очрашкан җирдә 1201 квадрат километр мәйданны биләп урнашкан безнең Кама Тамагы районы.

Райондашларыбыз туган якларының бай тарихы белән хаклы рәвештә горурланалар. Иделнең тормыш итү өчен уңайлы булган уңъяк ярларын кешеләр бик борынгы заманнарда — моннан 40 мең еллар элек үк үз иткәннәр. Борынгы кешеләрнең Красновидово авылы янында табылган торак урыннары шул турыда сөйли. Антоновка, Сөйки авыллары тирәсендә дә археологлар борынгы кабиләләр яшәгән җирләрне таптылар.

VIII гасыр урталарына таба Урта Идел буйларына, шул җөмләдән безнең төбәккә дә Азов диңгезе буйларыннан һәм Төньяк Кавказ далаларыннан татар халкының борынгы бабалары болгарлар һәм аларга союздаш кабиләләр күченә башлый. Борынгы Болгар чорыннан калган археологик истәлекләрнең күплеге районыбызның үзенә күрә бер үзенчәлеге, аның бай тарихи үткәне турында сөйли. Халык андый истәлекләрне хәзергә кадәр зурлап, кадерләп «изгеләр урыны» яки «изгеләр зираты» дип атый.

Болгар кабиләләренең Тау ягына килеп төпләнүе соңгы дәверләрдә дә дәвам иткән. Мәсәлән, борынгы татар шәҗәрәләрендә Аксак Тимер Биләр шәһәрен алгач, болгар бәкләреннән берсе Инсанның үз ыруы белән безнең якларга күчеп китүе хакында мәгълүматлар теркәлгән.

Ата-бабаларыбыз елга-күлләргә, алар ярындагы авылларга, тирә-юньдәге тау, калкулык кебек җирләргә матур-матур исемнәр сайлаганнар, кайберләренә борынгы ыру-кабилә атамаларын биргәннәр. Борынгы бортас кабиләсенең исемен үзендә саклап калган Олы һәм Кече Бортас авыллары яисә дастаннарда чагылыш тапкан алыплар чоры турында искәртеп торучы Бишалап кебек авыллар, ерак үткәнне тарих төпкелләрендә күмеп калдырмыйча, безнең көннәргәчә алып килеп җиткергәннәр. Болгар дәверендә үк төбәк халкы иген иккән, мал асраган, аучылык, балыкчылык, кыргый умарта кортларыннан бал суырту, ягъни чолыкчылык, бакчачылык белән шөгыльләнгән. Түләк исемле батыр белән Сусылу дигән чибәр кыз арасындагы мөнәсәбәтләргә корылган һәм урта гасырларда иҗат ителгән мәшһүр «Түләк — Сусылу» дастанының 1969 елда Олы Кариле авылында табылуы якташларыбызның борынгы заманнарда ук язма сүзгә, китапка тирән ихтирам, олы мәхәббәт саклауларын күрсәтә.

Идел буе калкулыгына урнашкан безнең район рельефның характеры белән республикабызның иң ергаланган өлешләреннән санала. Эрозиядән тыш ул карст формалары белән дә катлауланган. Моңа мисал итеп Сөйки авылы янындагы шактый атаклы тау куышларын китерергә була. Бу куышлар Иделнең уңъяк текә яры астында, гипс һәм доломитлар катламында хасил булган. Карст упкыннары шулай ук Мор. Каратай авылы тирәсендә дә күзәтелә. Мәсәлән, 1943 елда Сөйки инеше янындагы урманда 21 метр тирәнлектәге карст упкынлыгы хасил булды.

Районда табигый уңдырышлы катламы чагыштырмача юка булган җиңелчә ачы

туфрак күпчелек мәйданны алып тора. Иң киң таралган файдалы казылма — гипс. Аның егерме чакрымнан артыкка сузылган ятмалары Иделнең уң яры буйлап Антоновка авылы һәм Кама Тамагы эшчеләр поселогына кадәр аралыкта урнашкан. Гипс ятмаларын ачык ысул белән эшкәртүгә гасыр башында ук керешкәннәр. Беренче штольня 1911 елда салына. Хәзерге вакытта рудник районның иң зур промышленность предприятиеләреннән санала. Ул Ярославль, Дзержинск, Ульяновск, Свердловск һәм башка шәһәрләрне чимал белән тәэмин итеп тора. Елга уртача 700 мең тонна гипс ташы чыгарыла.

Шундый бай, бәрәкәтле җирдә яшәсә дә, патша Россиясе шартларында халкыбыз җирсезлектән, хокуксызлыктан иза чиккән.

Гасырлар буе дәвам иткән сыйнфый көрәштән безнең төбәк кешеләре дә читтә калмаган, әлбәттә. Феодаль һәм милли изүгә түзә алмаган халык еш кына патша властена актив каршылык күрсәтә. 1670—1671 елларда С. Разин, ә 1773—1775 елларда Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында актив катнаша. Татарлар Идел буеның башка халыклары: руслар, чувашлар, марилар һ. б. белән тыгыз бәйләнештә торып, самодержавиегә һәм алпавытларга каршы көрәш алып баралар. Бәки авылында туып үскән, соңыннан чукындырылган Давыдов Е. Пугачевның якын көрәштәше булып әверелә. Үзе җитәкләгән отряд белән ул Богырыслан-Бөгелмә якларында патша гаскәрләренә каршы сугыша. Батыр якташыбыз 1774 елның апрелендә әсир төшә. Аның гомере Казан төрмәсендә өзелә.

XIX гасыр урталарында, крепостнойлык бетерелгән чорларда ярлы крестьяннар чыгышы безнең якларда да кискен төс ала. Князь Гагаринның хосусый милке саналган Тәмте һәм аның күршесендәге биш авыл крестьяннары алпавытның управляющиена буйсынудан катгый рәвештә баш тарталар, устав грамоталарын алмыйча, үзләрен кичекмәстән йолым түләүгә күчерүне таләп итәләр. Көрәш барышында крестьяннар арасыннан Ефимов, Семенов, Киселев кебек җитәкчеләр күтәрелеп чыга.

Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы фронтларында да райондашларыбыз актив катнаша. Шундыйларның берсе Кече Кариле авылында туып үскән Һади Маликов. 1917 елда большевиклар партиясе сафына баскан Һ. Маликов Тәтеш өязендә Совет властен урнаштыруда катнаша. Петроградта М. Вахитов белән бергә Үзәк Мөселман комиссариатында эшли. 1918 елда ул В. И. Чапаев, К. А. Мерецков һәм башкалар белән бергә Мәскәүдә яңа ачылган Генераль штаб академиясендә укый, аннан соң Ленин чакыруы буенча фронтка китә. Соңыннан Һ. Маликов Төркиядә, Иранда совет илчелегендә эшли, хәрби атташе була. 1934 елдан башлап ул Көнбатыш Кытай гаскәрләре башкомандующие янында баш хәрби советник булып тора.

Даныш авылында туып үскән Мөхәммәт Әблиев тә гражданнар сугышы фронтларында авыр көрәш юлын уза. Урта Азияне басмачылардан тазарту өчен барган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Соңыннан ул хәрби комиссар буларак ак финнәр белән сугыша. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк М. Әблиев хәрәкәттәге армиядә, укчы дивизия политбүлеге начальнигы. Ватаныбыз азатлыгы өчен һәлак булган язучы-драматургның атаклы «Шәмсекамәр» драмасы 1937 елдан алып бүгенгә кадәр профессиональ һәм үзешчән театр сәхнәләрендә уйналып килә.

Безнең яклар ил күләмендә билгеле күп кенә атаклы шәхесләр исеме белән бәйле. 1797 елда сөргеннән кайтышлый биредә күренекле рус язучысы А. Н. Радищев тукталган. 1888 елның җәендә Красновидово авылында үзенең дусты һәм остазы М. А. Ромась янында яшь Алексей Пешков яшәгән. Шул ук елны бу авылга М. А. Ромась белән Себердә сөргендә дуслашкан язучы В. Г. Короленко килеп киткән. Әдәбиятка революция хәбәрчесе булып килеп кергән яшь Горькийның монда алган тәэсирләре соңыннан бөек художникның күп кенә әсәрләрендә чагылыш тапкан. 1979 елда Красновидово авылында М. Горькийның музей-йорты ачылу бөек рус язучысы истәлегенә тирән ихтирам билгесе ул. 1919 елның июлендә «Кызыл йолдыз» агитпароходында Кама Тамагына Н. К. Крупская килә. Агитпароход коллективы халык арасында киң күләмдә агитация һәм пропаганда эшләре алып бара: газета, листовкалар тарата, урыннардагы партия һәм совет оешмаларына практик ярдәм күрсәтә. 1936 елның җәендә районда партиябезнең күренекле эшлеклесе, Ленинның көрәштәше Р. С. Землячка булып китә.

Районыбызда беренче колхозлар 1928 елда оештырыла, ә 1930 елда ул тоташтан коллективлаштырыла. Авылны социаль үзгәртеп корудагы бу катлаулы бурычны тормышка ашыруда партиянең волость һәм район комитетларының беренче секретарьлары Флегонтов, Толстяков, Исаевларның, К. Шаһиев, Г. Таҗетдинов, Б. Кәримов, «Урал» (хәзерге «Кама» исемендәге) колхозының беренче председателе З. Мостафин һәм колхозлашу хәрәкәтенең башка бик күп активистларының зур өлеше бар.

Якташларыбыз Бөек Ватан сугышы фронтларында авыр сынауны лаеклы үттеләр.

Районнан 12 243 кеше фронтка китте, һәр өч сугышчының берсе кире әйләнеп кайта алмады. 400 якташыбыз орденнар белән бүләкләнде. 35 кеше солдатларга бирелә торган иң югары бүләк — сугышчан Дан ордены кавалерлары булды. Без батыр якташларыбыз — Советлар Союзы Геройлары М. А. Чирков, С. П. Спирьков, Н. П. Иванов һәм каһарманлык үрнәкләре күрсәткән башка бик күп гаярь ир-егетләр белән хаклы рәвештә горурланабыз.

Район хезмәт ияләре тылда да фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәттеләр. Кирельское авылы комсомоллары Т. Порфильева һәм А. Глонина «Кызлар — тракторга!» дигән чакыру ташлыйлар. Авыр елларда игенчелектә югары уңышларга ирешкән Мәдинә Кадыйрова звеносы (Ленин исемендәге колхоз) республикада иң яхшылардан.

Сугыштан соңгы чорда халык хуҗалыгын торгызуда һәм үстерүдә яңа уңышларга ирешелде. 1966 елда җидееллык планнарын уңышлы үтәгән өчен Мичурин исемендәге колхоз председателе Н. В. Лисин Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды. Н. В. Лисин артта калган хуҗалыкны кыска гына вакыт эчендә республикадагы иң яхшы колхозлар сафына бастырды.

Хәзерге вакытта районда 13 колхоз, 3 совхоз, 9 промышленность предприятиесе һәм 7 төзү оешмасы бар. Районда барысы 19 960 кеше яши.

КПССның XXVII съезды карарларын тормышка ашыра барып, район хезмәт ияләре хуҗалык итүнең яңа ысулларына күчәләр; үзгәртеп кору һәрбер өлкәгә үтеп керде. 1986 елда дәүләткә ашлык, ит һәм башка продуктлар сатуның еллык планнары уңышлы үтәлде. Ватан амбарларына 23 мең тонна ашлык салынды. «Ирек» колхозы 1985—1986 елларда терлекләрне кышлату буенча Бөтенсоюз ярышында җиңүче дип табылды. Бу җиңүдә дуңгызчылык комплексы мөдире, коммунист И. Х. Вафинның, дуңгыз симертү осталары И. М. Айсина, К. Х. Вафина һәм башкаларның зур тырышлыгын билгеләп үтәргә кирәк.

Районыбыз — күпмилләтле Ватаныбызның культурасына да үзеннән сизелерлек өлеш керткән як. Җырга-моңга бай, мәшһүр «Кыйссаи Йосыф»ларны укып үскән бу төбәктән Октябрь революциясенә кадәр үк әдәбият-культура әһелләре үсеп чыккан. 1850 елда Яңа Сала авылы мулласы Хаммат хәзрәт гаиләсендә дөньяга килгән Фатих Халиди татар әдәбияты тарихында икенче пьеса — «Радде бичара кыз» драмасын иҗат итә. XX йөз башы татар драматургиясендә үсеш алган реаль образлар, картиналар беренче тапкыр буларак сурәтләнгән бу пьесаны халкыбызның сөекле шагыйре Г. Тукай Уральск мәдрәсәсендә вакытта ук яратып укыган, кайбер рольләрне шәкертләргә уйнап та күрсәткән.

1893 елда Балчыклы авылында туып үскән шагыйрь Габдрахман Сөнгати беренче бөтендөнья сугышы фронтларында хәбәрсез югала. Татар совет әдәбиятын атаклы романнары һәм драма әсәрләре белән баеткан күренекле әдипләрдән Ибраһим Гази һәм Туфан Миңнуллинны белмәүчеләр сирәктер. СССР Фәннәр академиясенең Космик тикшеренүләр институты директоры, Ленин премиясе лауреаты, академик Р. Сәгъдиев, физика фәннәре докторы А. Маненков, фән кандидатлары Н. Борһанова, З. Рәмиев, Э. Сәйфуллин, режиссер С. Өметбаев, язучылар А. Салмин, М. Саттаров, Татарстанның атказанган артистлары Р. Тимерханова, Ф. Сөләйманова, Э. Галимова, Р. Мифтаховлар да иҗатка беренче илһамны туган төбәкләрендә алганнар. РСФСРның халык художнигы, ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Бакый Урманченың да бала чаклары безнең якта узган.

Район үзәге Кама Тамагы эшчеләр поселогы (элекке Богородское авылы), тарихи мәгълүматларга караганда, XVII гасыр башларыннан билгеле. Ул вакытта балыкчылар авылы булган Богородское XIX гасыр ахырында Казан губернасының зур һөнәрчелек үзәгенә әверелә. Хәзерге вакытта Кама Тамагы эшчеләр поселогы елданел матурая, үсә бара. Соңгы елларда гына да район китапханәсенең һәм редакциянең яңа биналары файдалануга тапшырылды, «Чәй йорты» ачылды, поселокның үзәк мәйданы төзекләндерелде, үткән ел анда бөек Ленинга монумент ачылды.

Хәзерге вакытта районда егерме урта, ике музыка мәктәбе, ике профессиональ-техник училище эшли.

Бүген районыбыз яңа төзелешләр мәйданын хәтерләтә. Уникенче бишьеллыкта зур үзгәрешләр көтелә. Халык хуҗалыгын үстерүгә 80 миллион сум капитал салулар планлаштырыла. Мөһим объектлардан район үзәгендә һәм Куйбышев исемендәге затонда больницаларны төзеп бетерү, газ үткәрү, барлыгы 2600 урынга исәпләнгән мәктәпләр, кирпеч заводы кору күздә тотыла. Аэродром, Куйбышев исемендәге затонда йөк причалы төзү инде тәмамланып килә. 85 километрлы юлга таш җәю күздә тотыла, 55 километр озынлыкта хуҗалыкара юллар салыначак. Район үзәген республикабызның башкаласы Казан белән тоташтыручы 66 километр озынлыктагы асфальт-бетон юл һәм башка күп кенә социаль культура-көнкүреш объектларын сафка бастыру планлаштырыла.

## Җәмит Рәхимов

# АЛМАГАЧНЫҢ АЛМАСЫ

Бу көнне ул күптән көтте. Моннан әллә ничә еллар элек чормага мендереп бәпкә артына кыстырган урагын алып төште, тузанын сөртеп, бармак бите белән тешләрен барлады, үткерлеген чамалады, аннан койма төбендәге кычыткannарны урып карады. Элеккерәк еллар булса, тимерчегә биреп тешәтеп тә алыр иде. Хәзер ни, кайдан тапмак кирәк урак теше торган тимерчене?

Урагын өйалдына кертеп куйды да түргә узды Фаизә. Үзе белән бергә картайган сандыгын ачып, аннан кырыкмаса кырык төрле кием-салым, чүпрәк-чапрак актарырга тотынды. Әһә, менә ич эзләгәне — кырга эшкә йөргәндә бәйли торган алъяпкычы. Теге елларда җиңсәләре дә була торган иде. Алары сакланмаган. Хәер, кирәге дә юк, ул заманнардагы сыман сутый куасы түгел лә. Актарына торгач, күлмәкләре арасыннан зур ак яулыгын сайлап алды. Аннан күлмәген киеп, яулыгын элеккечә маңгаена ук төшереп бәйләде: чын уракчыныкы төсле булсын! Күлмәген бөрмәгә кыстырып ук куймакчы иде дә, ул уеннан кире кайтты. Чынлап торып уракка җыенмый ла! Шунысы исенә төшкәч, ашыга-кабалана чишенде һәм уракка киясе киемнәрен өйалдына чыгарып куйды, авыр эштән котылгандай, җиңел сулыш алды — ярый әле оныклары, улы, янсә килене кайтып кермәде. Баягы кыяфәтендә күрсәләр, әнкәй ычкына башлаганмы әллә дип, шөбһәләнерләр, тиле.

Көткән көне килеп тә җитте. Менә ул кордашлары Зәкия Динекәева, Маһитап Гыйрфанова, Гыйзелҗиһан Сәгъдиевалар белән дугасына кыңгыраулар таккан атта басуга таба җилдерә. Яннарында гармунчы егет, арттагы олауда — борынгыча киенгән кызлар, егетләр — колхозның агитбригада членнары. Уен-көлке — нәкъ бәйрәмдәгечә. Уракка төшкән көн. Бары да колхоз оешкан еллардагыча. Тик уракчы хатыннарның битләрендәге җыерчыклары һәм күкрәкләрендәге орден-медальләр генә башка чор икәнен белдереп тора.

Авыл читеннән үк башланып киткән очсыз-кырыйсыз арыш басуы башындагы чирәмлеккә комбайннар тезелгән. Көненә-вакытына туры китереп язылган өндәмәләр. Авылның барлык механизаторлары да, колхоз җитәкчеләре дә шунда җыелган.

Беренче көлтә бәйрәме. Җыр-бию дә бар. Әмма күбрәк эшлекле сөйләшү. Уракчылар алдында торган бурычлар, техниканы уракка хәзерләү буенча барган социалистик ярышка йомгак, алдынгыларны бүләкләү. Фаизә Насыйбуллина кебек ветеран уракчыларның исә бүген үз вазифаларын сынатмый гына башкарып чыгасылары бар. Утнысуны кичкән ир йөрәкле бу хатыннар быел гына механизаторлар сафына кушылган яшьләрне җир хуҗалары рәтенә басулары белән котларга һәм шул изге, игелекле эшләренә фатиха бирергә тиешләр. Алар авыл мичендә күпереп пешкән ипи тотып, яшьләр каршына киләләр. Тегеләре ипине татып карый. Аннан инде чын күңелдән котлау, егетләргә иң изге, иң садә теләкләр.

Өлкән хатыннарның вазифасы моның белән генә төгәлләнмәде әле. Җылы сүзләр тәмамлануга, алар басу башына килде, җилкәләрендәге ураклар ялт кына кулларына күчте.

Фаизә дә, үзенең ничә яшендә икәнен онытып, моннан күп еллар элеккечә, дугалы атны күмәрлек булып күкрәп утырган арышларга иелде, «ә» дигәнче, беренче учмасын кистереп тә алды. Монда җыелганнар, бигрәк тә, яшьләр, инде онытылып беткән бу борынгы эшнең ничегрәк башкарылуын күреп тә өлгермәделәр, Насыйбуллина инде көлтәсен тутырып, аны бәйләп тә куйган иде. Әнә ул бәхетле елмаеп, көлтәсен күтәреп алды, аны күкрәгенә кысты һәм колхоз җитәкчеләренә таба атлады...

...Борын-борыннан үзенең уракчылары белән дан тотты Зәй-Каратай. Алай да Фаизә кебек осталары бармак белән генә санарлык иде. Уракка ул үзенә унөч яше тулган

җайдә тотынды. Шундый кешеләр була: эшкә тумыштан ук кулы ятып тора, аларны әйрәтеп чиләнәсе дә юк. Фаизә нәкъ шундыйларның берсе иде. Ничек эшлиләр соң моны дип тормады, чәнти бармагын да кисмәде, беренче көнне үк әтисе Суфиян агадан калышмый урак урды. Кызының уңганлыгыннан башы күккә тиде игенченең. Горурлануы юкка булмады Суфиян аганың. Кызы Фаизә, нинди генә эшкә тотынмасын, янып-ялкынланып эшләде. Башкарганы төгәл, чиста, күлеп тора сыман. Шулары күңеленә бигрәк тә хуш килде ата кешенең.

Авылда күмәк хуҗалык оешып, гаиләсе белән башлап колхозга кергәч, кызы Фаизәнең уңганлыгы тагы да күренә төште. Үзеңә эшләгәндә ни, җирне үлчәп тормыйсың, беткәнче урасың да — вәссәлам. Колхозда исә эшләгәнең исәпкә алынган була. Барыннан да күбрәк майтаргансың икән, алының башында кызыл әләм җилферди. Ашыкмыйпошмый, әлкен-селкен эшләүчеләргә дә бәһасы бар — андыйларның җир башына чыпта әләм кадап китәләр. Юк, беркайчан да андый көнгә төшмәде Фаизә, алынындагы кызыл әләм аны яңадан-яңа уңышларга илһамландырды.

Зәй-Каратай егетләреннән күпләрнең күзе кыза иде бу уңган кызга карап. Мондагыларныкы гына микән? Тирә-күрше авыллардан да сүз салып караучылар булмады түгел. Әмма берсенең дә каршына сикереп төшмәде Фаизә, сабыр гына үз сәгатен көтте.

1937 елда, ялга дип, Мәскәүдән авылдашлары Морзахан Насыйбуллин кайтып төште. Яшьләрнекен кем белә: әллә егет читкә киткәнче үк вәгъдә бирешкәннәр, әллә инде шул кыска гына вакыт эчендә сүз куешырга өлгергәннәр — гөрләтеп туй үткәрергә туры килде. Алай да соңы күңелсез булды — колхоз ударнигы Фаизә Мәскәүгә үк китеп барды.

Башкала зур, күркәм, матур, ыгы-зыгылы. Күрим, күңел ачыйм дисәң, театр-концертлары, цирк-музейлары, башка тамашалары җитәрлек. Шулай да Зәй-Каратай түгел. Үләннәре каерылып үскән шау чәчәкле тугайлар да, бәрәкәтле башаклары белән күңелне иләсләндереп торган кырлар да юк монда. Морзахан һәркөн төзелешкә китеп олага. Яшь хатыны белән иркенләп йөрергә ял көннәре генә кала. Өйдә ялгызы торганда туган як болыннарын, басу-кырларын сагынып йөдәде Фаизә. Сагышы сары булып йөзенә сукты бугай, хәлен ире дә сизми калмады.

— Эшкә кер, Фаизә, кеше арасында күңеллерәк булыр,— диде ул, хатынын назлап.

Ире янына төзелешкә керде Фаизә. Монда да эшнең рәтен-чиратын тиз чамалады, башкалардан калышмады, хәтта премияләр алгалый башлады. Әмма ни дисәң дә, таш, кирпеч, цемент тузаны эчендә кайнау — Зәй-Каратайның хөр басуларында тургайлар җырын тыңлап, хуш исләр дөньясында эшләү түгел инде. Йөрәгеп һаман сагыш корты кимерде Фаизәнең.

Әнә шулай калага ияләнә алмыйчарак яшәп яткан көннәрнең берендә Морзаханга повестка китерделәр. Көтелмәгән хәл түгел иде бу. Нишлисең, ир-егет, вакыты җиткәч, ил сагына барырга тиеш. Артыгын елашмый гына аерылыштылар: Морзахан Кызыл Армия сафларына китеп барды, Фаизә исә авылга кайтырга карар итте. Ирен туган-тумачалары арасында көтеп алуы җиңелрәк булыр сыман тоелды. Яраткан эш исә җанга үзе бер шифа: күңелне сагыш басканда — юатучы, башка хәсрәт төшкәндә — киңәшче сыман. Авылга кайтуга, ярсып-ярсып, кабат үз бригадасында эшли башлады Фаизә.

Яшь хатыны барын, тиздән әти буласын исәпкә алганнармы, армиядән тиз борылды Морзахан. Ләкин теге чактагыча хатынын ансат кына Мәскәүгә алып китә алмады. Җаны теләгән эшкә тиенгәч, оҗмахка кергәнмени Фаизәсе — кала хакында ишетәсе дә килми. Нишләсен, авылда калды Морзахан, бригадада атлар карый башлады. Зәй-Каратай да инде Морзахан чыгып киткән еллардагы боек авыл түгел. Колхоз тәмам ныгып җиткән, җырлашып эшлиләр, мул итеп икмәген алалар. Алалар дип, дугаларына кызыл флаглар тагылган атларда өйгә үк китереп бушаталар уңышны. Тормыш ямьле, күңелле. Нур өстенә нур дигәндәй, беренче балалары дөньяга килде, тормыш тагы да матурланып китте.

Ни аяныч: улының «Әт-тә» дигәнен ишетү насыйп булмады Морзаханга. Каһәрле бер көн әнә шул бәхеттән мәхрүм итте аны. 1941 елның 22 июне иде ул. Сугыш башлануның икенче көнендә үк биштәрен җилкәсенә асты, сөеклесе белән нәни улын кысып кочакләды да Бөгелмәгә агылучы олауларга таба ашыкты.

Ул китте, Фаизә исә сигез айлык улын кочаклап торып калды. Шул килеш озак, бик озак басып торды ул урам чатында. Өенә кергәч тә Зәфәрен куенына кысып утырудан башкага кулы бармады. Шул хәлендә йокысыз төн үткәрде. Иртәнге якта тәмам чуалган уй киләбенең очына чыкты сыман. Әйе, болай өзгәләнү-бәргәләнүдән бер мәгънә дә юк. Бала кочаклап утырып кына әллә ни кырып булмас. Яшәргә кирәк. Яшәүнең чыганагы исә бер генә — хезмәт. Басуда әнә тары уталып бетмәгән. Инде арыш та баш кыскан, борчак кузакланган. Барыбыз да шулай коелып төшсә, кем җыеп алыр ул игеннәрне? Эшкә әйткәннәрен көтеп тормады, нәниен кабык кәймәле бәләкәй арбага салды да тары басуына китте. Зәфәрен җир башындагы каеннар күләгәсенә куйды да утауга ябышты.

Утау бетеп тә җитмәде бугай, арыш урагына төштеләр. Әмма бу җәйдә «Уңыш» колхозында элеккеге көчнең яртысы да калмаган иде. Урак сузылды. Ул арада бодай, башка сабан ашлыкларының башаклары пеште. Басуга караңгыда киләләр, кич күз бәй-

ләнгәч кенә китәләр. Алай да өлгереп булмый. Өендә карчык-корчык булганнар кырда кунып эшли башладылар. Фаизәгә исә монда калырга юк. Тәмам төн булгач, арбасын тартып, өенә кайта. Баласын нигез буенда гына калдыра да сыер ээләргә чаба. Каршы алучы булмагач, анысы да көтүдән кайтмый башлады. Сыер савып, аш пешергәнче яр-ты төн житә. Әле анда да ятарга юк: бала искеләрен чайкарга, идәнне сөртеп алырга кирәк. Ә иртәгесен инде, таңнан, күз ертып, тагы кырга. Кайчан йоклангандыр да кай-чан ял ителгәндер ул елларда?!

Улы башта, утау чорында, тургай сайраганны тыңлап ята иде. Урак өстендә исә башак шавы, иген арасыннан пырхылдап очып чыккан бүдәнәләр белән мавыкты. Әллә еламады да инде? Еламыймы соң, елагандыр. Тик уттай эш өстендә кем бала тавышын тыңлап торсын?

Һай ул еллар! Игеннәрне урып-бәйләгәнче, көлтәләрне кибәннәргә куйганчы, кара күз житә, сугуы кышка кала. Анысы тәмам февральгә кадәр сузыла. Аннан атлар белән Бәгелмәгә ашлык ташыйлар. Дөрес, балалы булгач, юл йөрмәде Фаизә. Аның каравы, көннәр язга авышкан иң кыен, иң азыксыз чакта атлар карап чиләнә торган иде.

Икмәкнең җыеп алынган кадәресе фронттагыларга озатыла, үзләренә бүләргә такы-токы гына кала. Әле алган кадәрен дә... Хәтерендә, берсендә Фаизәгә өч пот солы са-ламы тигән иде, аласы итмәде, «колхоз базары» фондына калдырды. Монысы — алар, «Уңыш» колхозы членнары, уйлап чыгарган нәрсә. Хезмәт көненә тигән ашлыкны, кем күпме булдыра ала, шул кадәр колхоз амбарында калдыралар да, базарга илтеп саталар. Уфа базарына барып җиткән чаклары булды хәтта. Шулай тырыша торгач, өч йөз мең сум акча тупладылар һәм аны Кызыл Армиягә бүләк иттеләр. Хәзер уйлап тора да, исе китә Фаизәнең. Үзе нәрсә ашады икән соң әлеге елда? Казлары, башка мал-туары, бак-часы бар иде шул. Кырык сутый бакчаны ай яктысында казып-чәчү, шундый ук төннәр-дә утау-өю дә уен түгел.

Яшьтән крестьян хезмәтенең рәтен, тәмен-ләззәтен белеп үскән Фаизә авыр сугыш елларында тагы да ярсып, дәртләнеп эшләде. Хәер, бер ул гына түгел, замандашлары-ның барына да йөкнең авыр башы әлекте ул чакта. Тормышлары, башкарган эшләре, кылган гамәлләре легендага тиң иде ул чор хатын-кызларының. Бер караңгыдан икенче-сенә кадәр баш күтәрми эшлиләр, урак өстендә исә ае-ае белән кырда кунып-төнеп ята-лар. Шул арада уен-көлке белән бер-берен юатырга, олы хәсрәтләрен онытып торырга да вакыт табалар бит әле. Ә көн аралаш килеп торган кара кайгылы кәгазьләр әле бер-сен, әле икенчесен изеп ташлый. Күпме көч, ихтыяр ныклыгы кирәк ул хәбәрләрне кабул итәргә! Фаизәгә дә килде андый үзәк өзгеч хәбәр. Ул да сыгылып төште, ләкин сынма-ды — ун кат үҗәтләнебрәк эшенә ябышты.

Сугышның зәхмәте, үзе туктагач, тагы да яманрак сизелә икән. 1946-1947 нче ел-лар алдагыларыннан кыенрак та булдылар сыман. Хактыр да; сугыш китергән җимерек-лекләр өстенә 1946 елның корылыгы өстәлде — игеннәр уңмады. Хәлләр тәмам мөш-келләнде. Әнә шундый, каян тартсаң, шуннан өзелә торган бер вакытта Фаизәне звено башлыгы итеп билгеләделәр. Бу инде үзең өчен генә борчылмыйча, звенодагы унике хатын-кыз өчен дә хафалану, дөнья кадәр өстәмә эш дигән сүз. «Уңыш» колхозында звенолар башка кайбер хуҗалыклардагы кебек кәгазьдә генә түгел. Звено үз җиренең тулы хуҗасы иде. Чәчәләр, аерым карап, уңышын да үзләре җыеп алалар — кыскасы, һәр бөртек өчен көрәш бара. Җитәкче башкалар белән бер рәткә эшләү өстенә, иртән барына да эшкә әйтеп чыга, кичен башкарган эшләрен үлчәп, исәпкә ала, хезмәт көне яза. Ягъни барыннан иртәрәк торып, кичен басудан иң соңгы кеше булып китә. Баш-кача ярамый. Үзең койрыкта сөйрәлсәң, нинди абруе булсын ди звено башлыгының?

Фаизә зарланмый-сукранмый тарта бирде. Күңелендә тагын бер уй бөреләнде. Ул — звеноны үрнәк итү. Серен акрын-акрын дуслары Нуриәсма Нуртдинова, Хәдичә На-сыйбуллина, Фәйрүзә Хаковага ачты. Хупладылар. Звенога мәшәкатьләр, яңа чыгымнар артты.

1948 елда Фаизә Насыйбуллина звеносы чәчүне иң отышлы чакта башкарды. Агрегат-лар кырә алмастай урыннарда орлык борынгыча кулдан сибелде. Хатын-кызлар иңнә-ренә тубал асып, үзләре чәчтеләр. Утавы тагы да четереклерәк булды: һәр басу, эскәк бе-лән чистартылгандай, җентекләп чүп үләннәрдән арындырылды, багана төпләрен кө-рәк белән кабат казып чыктылар. Игеннәр күкрәп үсте. Әмма аларны югалтусыз җыеп аласы бар иде әле. Басудагы һәр башак өчен көрәш башланды, сукканда бер генә бөр-текне дә югалтмаска тырыштылар. Бодай аеруча уңган иде. Тик, көннәре артык кызуга китте, шунлыктан, көлтә бәйләгәндә, бодайның башагы сынып, җиргә коелып йөдәтте. Көлтәләрне чык төшкәч яки иртән, дым кипкәнче, бәйләргә булдылар, ә көндезен шул ук бодай басуында башак чүпләделәр — кырдан тәүлек әйләнәсенә китмәделәр. Тырыш-лыклары бушка булмады — һәр гектардан утызар центнер уңыш җыеп алдылар. Колхоз идарәсе барысын да диярлек бүләкләде. Фаизә Насыйбуллина Ленин орденына лаек булды.

Тора-бара колхоз эшләре шактый җиңеләйде: машиналар артты, кыр эшләре техника җилкәсенә салынды, ашлык чистарткыч машиналар да электр көче белән әйләндерелә башлады. Алай да игенчеләргә кул кушырып утырырга туры килмәде. Зәй-Каратай

буровойлар, нефть промыселлары уртасында утрау сыман булып калгач, яшьләрнең күбесе нефтьче һөнәренә тартылды. Билне тагы да буыбрак, җиңне сызганыбрак эшкә тотынырга туры килде Фаизә яшьтәшләренә. Элеккечә, зарланмады да, сукранмады да Насыйбуллина, һаман дәртләнеп иген икте, терлек азыгы үстереште. Пенсия яшеннән шактый узып, улы тәмам ир булып җиткәч кенә, картлык ялына китте ул.

Шунысы куанычлы: Фаизәнең һәм аның замандашларының еллар буе алны-ялны белми, булсын дип, ихластан эшләүләре үкенечкә калмады. Кырыс сугыш елларында да артык өшәнмәгән «Уңыш» колхозы, тәмам ныгып, районда гына түгел, республикада абруйлы хуҗалыклар рәтенә басты. Авыл күзгә күренеп үзгәрде — хәзер инде аның үзәге кала урамы сыман. Як-яклары яшеллеккә күмелгән урамнарга асфальт түшәлде, тыкрык башы саен — су колонкалары. Йортларга газ керде, өй түбәләренә телевизор антенналары менеп кунаклады. Соңгы елларда тагы бер бизәк өстәлде авылга — йорт саен диярлек гаражлар калкып чыкты. Муллыкка сөенеп, җырлап яши торган заман. Тик барыбер күңеле тынгы белми Фаизәнең. Җанын телгәләгәне — яшьләрдән кайберәүләрнең авылдан йөз чөерүе.

Дөрес, үзләренә килгәндә, бер дә борчылыр урын юк. Аның бердәнбере — Зөфәре, бишектә үк тургай моңын, башаклар шавын тыңлап үскәнгәме, һич икеләнми, шөбһәләнми колхозда эшли башлады. Армиядән кайтуга ук, тракторына да, машинасына да укыды Зөфәр. Ахырда шоферлыкны сайлады һәм ялгышмады. Шул эшкә кулы ятып тора: машинасы һәрчак төзек, чиста. Үзе көндәм, ни кушсалар, шуны үтәми калганы юк. Әнисе сыман ук эшкә бирелгән. Җыелыш-киңәшмәләрдә, бәйрәм-тантаналарда һәрчак мактап телгә алына, бүләкләнми калмый. Хәтта хөкүмәтебез бүләгенә — Өченче дәрәҗә Дан орденына да лаек булды. Шуларның барын истә тотып, колхоз коммунистлары үз сафларына алдылар Зөфәрне.

Башта шикләнебрәк яшәде Фаизә. Өйләнер дә, хатыны белән шәһәр ягына авышырлар дип шөбһәләнде. Ләкин тормыш юлдашын да авылга төс биргәнен сайлады Зөфәр — укытучы Сылуны. Инде унсигез ел яшиләр. Килен авыл мәктәбендә.

Авылның баш урамында заманча гүрничәдә яшәп яталар Насыйбуллиннар. Йорт-җир көләп тора, донья җиту, нигъмәттән өстәлләр сыгылырлык. Алай да мәшәкать кимегәне юк бу эшчән гаиләдә. Таң атуга, улы белән килене — эшкә, оныклар мәктәпкә ашыга. Фаизә апа мал-туар тирәсендә әвәрә килә, тавык-чебешләрен ашата, аннары төшке аш хәстәрен күрә башлый. Кайтуларына әзер торсын! Ул арада иң кечкенә онысы Фәнил кайтып җитә, бераздан уртанчысы — Рамил, ниһаять, өлкәне Дамир күренә. Килене белән улы да кайткач, табын тәмам түгәрәкләнә. Сөр түгел, донья булгач, үткәннәр күңеленә бөелеп, ямансулап та куйгалый Фаизә. Сагыш басса, үз бүлмәсенә кереп, ялгызы кала. Иренең инде шактый таушалган фотосурәтен кулына ала. Шунда ук — орден кенәгәләре. Берсе — үзенеке, икенчесе — улыныкы. Аларга да онытылып карап тора Фаизә, аннан эченнән генә горурланып куя: шөкер, алма агачыннан ерак тәгәрәмәде. Улы турындагы якты уйлардан сагыш болытлары тарала, күңеле аязып кала ананың.

Ләбибә Ихсанова

# ТАБИГАТЬКӘ ҺӘЙКӘЛ

Моннан берничә ел элек Таулы Алтай шәһәрендә балалар язучыларының зур җыелышы үткәрелгән иде. Анда төньяк, Ерак Көнчыгыш һәм Алтай өлкәсендә яшәүче балалар язучыларының иҗаты турында кызыклы сөйләшүләр булып, миңа да шул яклардагы берничә прозаикның китапларына күзәтү ясарга туры килде.

Эчтәлеге белән төрле-төрле булган бу әсәрләрне берләштергән олы бер проблеманың табигать булуы мине гаҗәпләндермәде. Салкын диңгезләр, кара урманнар, биек тауларга якын җирләрдә яшәгән авторлар кулында командировкаларга гына барып җыйган материал түгел, алар шунда туып-үскән, туган якларына мәхәббәт ата-ана канынннан күчкән, иҗат көчләрен шул табигатьтән алганнар, үзләрен дулкынландырган мәсьәләләр турында язып чыкканнар. Бу китапларның төп герое — кул тимәгән матурлыгы һәм кырыслыгы, кыргыйлыгы, көче һәм көчсезлеге белән табигать үзе дип әйтергә дә мөмкин булыр иде. Әсәрләрдә, башлыча, табигать һәм кеше арасында көч сынашу, акылы, тапкырлыгы, түземлеге, физик көче аркасында кешенең җиңеп чыгуы турында сүз бара. Аларны укыганда, мин Гомәр Бәширов, Җәвад Тәрҗеманов, Фәнис Яруллин, Фаил Шәфигуллин, Габделхәй Сабитов, Гәрәфи Хәсәнов, Габдулла Шәрәфи, Альберт Хәсәнов һ. б. каләмдәшләремнең иҗатын күңелдән кичердем. Аларның әсәрләрендә табигать йомшаграк, кулга ияләшкәнрәк, ярдәмгә мохтаҗрак булып күренде.

Моның шулай икәне гаҗәп түгел. Без бит индустриаль төзелешләр интенсив үскән, урбанизация күренешләре тормышыбызга көннән-көн күбрәк керә барган төбәктә яшибез. Ә болар барысы да, ике башлы таяк кебек, бер яктан яшәү рәвешебезне җиңеләйтсәләр, икенчедән кеше өчен зарур булган табигать байлыкларына шактый гына кире йогынты да ясыйлар.

Шуңа күрә дә инде табигатьне саклау проблемасы бүгенге көндә иң актуаль проблемаларның берсе булып тора. Бу мәсьәләне хәл итүдә өлкән буын кешеләр генә түгел, яшь буын да бик теләп катнаша. Без моның матур мисалларын әдәби әсәрләрдән күреп киләбез.

Тагын шунысы да бар, татар балалар әдәбиятында кеше һәм табигать гармониясен сөйләү традициясе бик күптәннән, беренче дәреслекләргә кергән әдәби әсәрләрдән үк килә. Алар башлыча табигать гүзәллеген, шул гүзәллекнең кеше рухына йогынтысын җырлаганнар. Г. Тукайның ничәмә-ничә буын балалар укып үскән һәм гомергә күңелдә калган «галибәнә яктырып ал таң ата...» дип башланган шигырен искә төшерик. Г. Ибраһимов әсәрләрендәге җыр кебек укыла торган табигать күренешләре, А. Алишның табигать серләрен ачкан матур әкиятләре — болар барысы да соңгы елларда иҗат иткән язучыларга йогынты ясамый калмагандыр, һәм аларның әсәрләрендә табигать белән көрәштән бигрәк, аны яклау, беренче матурлыгы, байлыгы белән саклау мотивлары өстенлек алу да шул традициянең дәвамы булса кирәк.

Соңгы ун-унбиш ел эчендә татар балалар әдәбиятында табигатьне саклау темасына һәм язучылар, һәм журналистлар тарафыннан төрле жанрда күп кенә китаплар басылып чыкты. Кешеләр алдына төрле-төрле сораулар куйган, проблемалар кузгатырга тырышкан бу әсәрләр турында иркенләп сүз йөртерлек мөмкинлекләр бар хәзер. Геройлар психологиясендәге үзгәрешләр үзләре генә дә кызыклы бер сөйләшүгә нигез була алыр иде.

Өлкәнрәк яшьтәге язучылар хәтерлидер әле: илленче-алтмышынчы елларда татар балалар әдәбиятын «һаман да шул чебиләр дә песиләр турында» дип тәнкыйтьлиләр иде. Хикмәт балалар ярата торган шушы сөйкемле җан ияләре турында күп

язуда түгел, алар турында хәзер дә аз язылмый, хикмәт исә шул еллардагы шигырьләрнең (ни өчендер ул вакытта хикәяләр аз язылды) күбесенең игез балалар кебек бер-берсенә бик охшаш булуларында иде. Шигырь песи баласы турында булса, ул һичшиксез матур, китапның нәни герое аның белән уйнарга ярата, әгәр инде әтәч турында сүз барса, әтәчнең тавышы көчле, кикрикүк, мин торам иртүк дип, баланы йокысыннан уята, шуңа күрә ул мәктәпкә дә соңга калмый. Мин, миңа, минеке... Җан иясләренең дә тормышы бала ихтыяҗына буйсындырылган, шушы кечкенә эгоистка хезмәт итәр өчен генә яратылган кебек языла иде ул әсәрләр.

Билгеле, мондый тенденцияләр бер безнең балалар әдәбиятына гына хас түгел. Рус балалар әдәбиятының танылган берничә вәкиле андый күренешләрне моннан бер-ике ел элек «Литературная газета» битләрендә тәнкыйтьләп тә чыккан иде...

Мондый әсәрләрдән аермалы буларак, табигать темасына яңа герой алып килгән язучыларның берсе, минемчә, Фаил Шәфигуллин булды. Аның хикәяләрендә укучылар үзләренең эчке дөньяларына якын тормышны күрделәр, үз тиңнәре белән очраштылар, геройларның кичерешләрен бик рәхәтләнеп уртаклаштылар, табигать гүзәллеген тоярга өйрәнделәр. Җитмешенче еллар башында «Яшь ленинчы» газетасы тарафыннан иң яхшы хикәяләргә уздырылган конкурста аның «Ак мөгез» хикәясе бүләкләнде. Эчтәлеге белән артык катлаулы булмаса да, драматик көче белән укучыга нык тәэсир иткән кечкенә күләмле бу әсәр язучының үз иҗатында да борылыш ясаган кебек булды.

Шул еллардан Фаил Шәфигуллин балалар прозасында ныклап эшли башлады. Әдәбиятка шагыйрь буларак килгән һәм өлкәннәр өчен күп кенә уңышлы шигырьләр иҗат иткән Фаил балалар өчен дә матур әсәрләр яза алуын күрсәтте. «Ак мөгез» хикәясендә ул җаваплылык хисе зур булган һәм максатына ирешүдә кыенлыклардан курыкмаган бала образын сурәтләүгә ирешә. Бер вакыйгада үзенә күрә көрәшче сыйфатлары күренеп киткән яңа образ иде ул. Сүз урманда пошиларга азык бирергә килгән малайның, ату тавышын ишеткәч, браконьер эзеннән китүе турында бара. Урман бүресе кебек тәҗрибәле һәм хәйләкәр, олы яшьтәге кеше белән көч алышу турында уйламый малай. Ул бары тик урман авызына чабып чыккан пошилар белән браконьер арасына төшәргә генә тырыша. Ачык аланда бу адәмгә пошиларны атып алу җиңел булачак, шуның явыз ниятенә комачау итәргә кирәк. Һәм малай теләгенә ирешә дә, пошиларны һәлакәттән коткарып кала, әмма үзе кинәт купкан буранда адашып юлын югалта, хәлдән таеп, агач төбенә килеп утыра һәм үлем йокысына тала. Бәхеткә каршы, укучыны тетрәндерәчәк хәл булмый кала, йөзенә җылы сулыш бәрелүдән уянып киткән малай каршысында торган урман патшасын шәйләп ала.

Пошиларның бала янына килеп чыгуын очраклы хәл дип тә карарга булыр иде, әмма без аларның, кыргый хайваннарга хас булганча, үтә нечкә сиземләү белән, малайның исеннән танып, аны эзләп килүләренә күбрәк ышанабыз. Чөнки алда автор безгә бала белән шушы сизгер хайваннар арасындагы дуслыкны, аларның берберләренә ияләнешеп бетүләрен әйткән иде бит. Үзе мәрхәмәтле кешегә табигать тә мәрхәмәтле була бит шул.

Йомшаклык, ярдәмчеллек кеше күңеленә бала вакыттан салына. Ишегалдындагы чебиләр, ак маңгайлы, тупый борынлы көчекләр, иртә язда бөртеп чыккан тал песиләре, кашлак җирләрдәге беренче сары чәчәкләр, тагын шуның кебек көн дә күреп, ияләнеп беткән, аяк астында аунап яткан әйберләр, күренешләр белән керә ул кеше җанына. Кайвакытларда боларның барысын да маңгай күзе күрсә дә, күңел күзе күреп бетерми. Бигрәк тә балаларга хас нәрсә ул. Аларда акылдан бигрәк хис алданрак йөрүчән була, күп хәрәкәтләрен инстинкт җитәкли. Шуңа күрә, кайчагында үзләре дә сизмәстән, ярамаган эш тә эшләп куйгалыйлар. Менә шул чагында яшь геройга тәҗрибәле, акыллы өлкән кешенең киңәше ярап куя да инде. Фаил Шәфигуллинның «Бал» дигән хикәясендә бу хакыйкать ышандырырлык итеп сурәтләнә. Беркатлы, ачык авыз малай күрше егете ачкүз Әнвәргә ияреп, урманга, кыргый умартадан бал алырга бара. Кичке салкын төшеп килгән урманга җиткәч, Әнвәрнең тел яздыруына алданган малайның күңел күзе ачыла барып, әбисенең әйткән сүзләре йөрәгенә борчый башлый. Малай көндез кайтып, урманда очраткан корт оясы турында сөйләгәч, әбисе: «Кышлык азык җыеп калырга ашыгалар. Димәк, яңа оя инде ул, яшь кортлар оясы», — дип әйткән иде бит. Ә Хәбир белән Әнвәр аларның кышлык азыкларын алырга дип баралар, зәһәр салкыннарда ач калдырырга. Үсмер малайның олы яшьтәге кешегә каршы торырлык физик көче булмаса да, рухи көче шактый нык була. Егетнең кыйнап ташлавыннан да, караңгы урманда ялгыз калдыруыннан да курыкмый Хәбир, чын-чыннан характер ныклыгы күрсәтә. «Әнвәр Хәбирне аяк чалып, терсәге белән генә төртеп екмакчы иде дә, тик Хәбир тиен җитезлеге белән читкә сикерде, аяк астында тырпаеп торган ботакны алып өлгерде. Тиеп кенә

кара!» Әлләниләр эшләтсәң дә, Хәбир корт оясын күрсәтмәс инде, моны яхшы аңлый егет, малайның кыюлыгы алдында чигенергә мәҗбүр була.

Шундыйрак хәл авторның «Бер малай, өч аргамак» повестенда Борһан белән Рәсим арасында да булып ала. Бу әсәрдә автор әхлак мәсьәләсен башка чаралар белән, авыл көнкүрешендәге мөнәсәбәтләр ярдәмендә чишә. Бер карасаң, повестьта табигать хозурлыгын сурәтләгән бер генә урын да юк кебек. Ләкин укучы дымлы яз һавасын, буразнадан күтәрелгән юеш балчык исен, әрәмә төпләрендәге җиләс күләгәләрне барыбер тоя.

Дөньядан да, эшеннән дә ямь тапмаган караңгы чырайлы, явыз кеше Борһан белән уракка чыккач, сөекле аты Карлыгач ямьшышннан бигрәк Рәсим үзе өчен курка. Борһанны ачуландырмаска, аның каһәренә юлыкмаска тырыша. Беренче заттан язылган повестьта шундый сүзләрне укыйбыз: «Кызык, күпмегә җитәр икән сабырлыгым. Бер генә каршы сүз дә әйтмим, бер сүз әйтсәм, тәпәләп ташлаячак инде ул мине. Аннары барысы да үзеннән-үзе хәл ителәчәк». Юк, аның сабырлыгы бетеп, Борһан каһәреннән Карлыгачны якларга теләвен сөйләми әле бу юллар. Аның явызлыгын сәбәп итеп, эштән китәргә уйлавы гына малайның. Ләкин кансызлыкка, гөнаһсыз җан иясен газаплауга Рәсим кебек юаш малай да түзә алмый. Борһан чик-чаманы белми кылана башлагач, аның мәрхәмәтле күңеле явызлыкка каршы баш күтәрә.

Икенче бер вакытта инде ул, һич икеләнмичә, рәхимсез бәндәнең каты кулыннан да курыкмыйча, сөйгән атын яклап чыга. «Күз алдымнан Карлыгачның курку катыш ялвару тулы карашы чагылып узды. Мин, үз-үземне белештермичә, ат белән чыбыркы арасына барып кердем һәм шунда ук, авыртуга чыдый алмыйча, бөгелеп төштем», — ди Рәсим. Ләкин малайның җиңелүе түгел, җиңүе була бу. Юашлыктан кыюлыкка таба ясаган беренче адымы, явызлыкка каршы торырлык көч тапкан моменты, беренче чирканчык алуы. Күр әле син аны, Борһан кадәр Борһанга да каршы торырга мөмкин икән бит!

Фаил Шәфигуллинның хикәя һәм повестьларына кергән табигать күренешләре — әсәрләргә лирик тон бирү яки аның канвасын матурлау өчен генә алынган бизәк түгел. «Фирүзә» әкияте, «Кырмыска турында баллада», «Тамгалы бүре», «Верочка» хикәяләрендә дә без табигатьне авторның фикерен укучыга җиткерүдә, геройларның характерын ачуда кулланылган, туктаусыз хәрәкәттә булган актив бер чара дип кабул итәбез. Әгәр ул табигатьнең бер мизгелдә катып калган фотосурәтен генә биргән булса, укучы күңелен шул кадәр тартмас иде. Фоторәсемне бит бер караганда гына карыйсың да альбомны ябып куйгач — онытасың. Җансыз әйберне күңелендә кемнең саклап йөртәсе килсен соң. Фаил әсәрләрендәге табигать күренешләре исә кешенең уе, гамәле, җаны белән үрелеп бирелә, характер үзенчәлекләрен ачыграк итеп күрергә булыша.

Балалар үзләре сугыш елларында гына яисә тыныч тормышта, гадәттән тыш фаҗигале хәлләр булганда гына батырлык күрсәтергә мөмкин дип уйлыйлар. Мондый карашның нигезенә балалар язучылары да ярдәм итте кебек. Кайбер әсәрләрдә батырлыкка сусаган малайларның, үзләренең кемлеген күрсәтү өчен генә, йөзә белмәгән килеш тә суга сикерүләрен, куркудан калтырана-калтырана булса да сәгатьләр буе караңгыда утыруларын, тагын шундый юмористик хикәяләргә генә нигез булырдай вакыйгаларны, чын драматик буяуларга манып сурәтли бирдек. Менә имеш характер ныклыгын сынау, менә имеш батырлыкка әзерләнү! Ә чынлабрак, күңел күзе беләнрәк карасаң, батырлык күрсәтерлек хәлләр бүгенге тормышыбызда да тулып ята икән ләбаса! Батырлык ул куркыныч туганда гына, минуты, секунды белән барлыкка килгән гадәттән тыш көч түгел икән. Әнә шулай, бала вакыттан бирле, кечкенә генә булса да, гаделсезлекләргә каршы тора-тора тәрбияләнә икән ул гүзәл сыйфат. Геройлар бит күктән төшмиләр, геройлар җирдә туалар, абынасөртенә, борын каната-каната үсеп характер чыныктыралар. Язучының бурычы исә, — шагыйрь әйтмешли, тонна-тонна руда арасыннан эзләп табылган җәүһәрләр кебек, кызыклы характерлар табу, типиклаштыру, бөтен матурлыгы белән укучыга күрсәтеп бирү.

Фаил Шәфигуллинның табигать темасына язылган хикәяләрендәге Тәлгать тә, Хәбир дә, Рәсим дә һәм башка геройлар да әнә шундый малайлар. Аларның зур үскәч тә сынатмасларына ышанасың.

Фаилнең кечкенә күләмле хикәяләрендә, барысында да дип әйтерлек, бер персонаж алына һәм аның алдында торган кыенлыкларны җиңеп чыгуы сурәтләнә. Ләкин бу язучының һич тә үз-үзен кабатлавы түгел. Кояш нурын җиде төрле төскә таркатып һәм аның һәр төсен аерым-аерым күреп булган кебек, «бала характеры» дип аталган катлаулы төшенчәне ул төрле моментта, төрле яклары белән күрсәтеп биргән. Батырлык сыйфатын да балалар төрле-төрле юллар белән үзләштерә икән бит. «Ак мөгез» хикәясендәге Тәлгать хайваннарны яратуы аша ирешә аңа, Хәбир исә кылган

эшенә үкенү, ә Рәсим явызлыкка нәфрәт аркасында куркуны җиңә.

Ә менә «Ак маңгайлы бүреләр» повестенда вакыйгалар колачлырак. Анда ялгыз бер баланың башыннан үткәннәрен түгел, олы бер коллективның мавыктыргыч та, маҗаралы да, кирәкле дә булган эшләрен сурәтли автор. Биредә бер яки берничә җан иясен яклап чыгу турында түгел, бәлки авыл табигатенең кеше аяк басмаган, шомлы сазлыклар артында посып утырган, кош-кортлары, агачлары, җанварлары белән кыргый матурлыгын югалтмаган бер почмагын саклап калу, әсәрдәге персонажлар теле белән әйтсәк, колхоз тыюлыгы ясау турында сүз бара. Зуррак масштабта күтәрелгән мәсьәлә булса, бу билгеле, укучы балалар кулыннан гына килә торган эш булмас иде. Биредә исә хөкүмәт законнары, колхоз, район җитәкчеләре ярдәме белән хәл кылына торган мәсьәлә түгел, сүз, зурмы-кечкенәме, билгеле бер күләмдәге җир турында бара. Фаил мәсьәләнең практик ягына кагылмый, чама белеп, балалар көче җитәрлек кенә участок сайлап ала. Аның өчен балаларның инициативасы кыйммәт. Сабан туйларында да бит көрәшне башта бала-чагадан башлыйлар. Кайчагында балалар башлап җибәргән уеннарның зурлар кулына күчкәч, бик җитди генә эшләргә әйләнү очракларын да беләбез. Балалар һәрвакыт уйнарга яраталар. Бик мөһим эшләрне дә алар чын мәгънәсендә уенга корып эшлиләр һәм аны ялыктыргыч процесстан җанга ләззәт бирә торган рәхәт бер нәрсәгә әверелдерәләр. Алардагы бу сыйфатны балалар әдәбияты элек-электән уңышлы файдаланган. Фаилнең дә геройлары уйный-уйный гына табигать хозурына килеп керәләр һәм авыл янында гына булса да, кеше аягы басмаган утрауда, сәяхәт кыла башлыйлар.

Танылган балалар язучысы, табигать белгече Виталий Бианкиның: «Уен — балалар стихиясе. Әйдәгез, алар белән бергә сәяхәт уеннары уйныйк. Һәм һәр сәяхәттә үзебезгә таныш булмаган илнең «җирле халкы» — хайваннары, үсемлекләре, ташлары, кар бөртекләре белән танышыйк», — дигән сүзләре бар.

«Ак маңгайлы бүреләр» повесте абыйлы-энеле ике малайның разведчиклар булып уйнавыннан башлана. Шул уенда без нәкъ В. Бианки әйткәнчә сәяхәт кылып, Каратамак сазлыгының кошларын, куяннарын, агачларын, җиләкләрен күрәбез һәм, үзебез дә сизмичә, шушы әкияткә тиң урынны явыз кешеләрдән, браконьерлардан саклаучы яшел патрульләр дөньясына килеп керәбез.

«Ак маңгайлы бүреләр» — арабыздан бик иртә киткән Фаил Шәфигуллинның балалар өчен язган соңгы әсәре. Һәм автор әйтерсең лә бүген дә үзе белән бер төркем балалар ияртеп кеше кул-аягы тимәгән бер урынга килгән дә, бу — Каратамак сазлыгы, менә монысы — зәңгәр су уртасында сырты белән утыртып куелган таракка охшаганы — усак урманы, теге тирән тарлавыкны күргәнегез бармы әле, карагыз әле бу җиләкләрнең эрелекләрен дип, күрсәтеп йөри, аларга шушы гүзәллекне сакларга, явызлардан кул тидертмәскә васыять әйтә.

Балаларның бик реаль тормышын сурәтләгән бу әсәр баштан ук күңелләрне ымсындырып торган серлелек белән өртелгән. Табигать күренешләрен сурәтләү алымнары да, ак маңгайлы бүреләр кыйссасы да бу серлелекне арттыра гына бирә. Революциягә кадәр үк әле, Саңгар алпавытының явызлыгына чыдый алмыйча, урманга качып киткән ау эте Акмаңгайдан туган эт-бүреләр авыл халкына зыян китермиләр, алар турында «...ачка үлсә үләр, туган ягына зыян-зәүрәт салмас», — дип, яратып, сөйли авыл халкы.

Акмаңгай да кешеләрдән күргән яхшылыкны онытмаган, токымына да шул хисне биреп калдыра алган. Авыл халкы акмаңгайлы бүреләр турында күп сөйләсә дә, аларны үз күзе белән күргән кеше турында хәбәр бирми автор. Разведчиклар булып уйнау белән мавыккан ике малай гына эңгер-меңгер төшә башлаган агачлар арасыннан аны шәйләгән кебек булалар. «Бозау чаклы башын авыл ягына борыбрак, нәрсәдер искәргәндәй, тирән чокырга төшә торган сыртның нәкъ түбәсендә сын кебек хәрәкәтсез басып торган җанварның Каратамак бүресе булуында шик юк иде», — дигән юллар да әле чынлыкка җавап биреп бетерми. Курыкканга куш күренә дигәндәй, коты алынган малайларның күзенә (ни генә әйтсәң дә бүре бит!) агач төбенең дә бүре булып күренүе бар. Хәер, үз күзләрең белән күрүдәмени хикмәт, шушы әкияти җанварга карата кызгану катыш соклану кичергән кешеләрнең олы хисе турында бу әсәр. Яхшылык символы булып гәүдәләнгән табигать баласының комсыз браконьер кулыннан һәлак булуы турында.

Атларны, бүреләрне һ. б. кайбер җанварларны таштан сынландырган, мәйданнарга куйган җирләр бар. Әгәр Фаил Шәфигуллин сурәтләгән авыл кешеләре үзләренең туган табигатенә һәйкәл куярга уйласалар, аны нәкъ повестьтагыча итеп, биек яр башында горур басып торган акмаңгайлы бүре кыяфәтендә эшләрләр иде кебек...

библио графия

# ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА

«Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томы Борынгы һәм Урта гасырларны үз эченә алган иде. Инде менә кулыбызда аның икенче томы[1]. Беренчесе кебек үк күрер күзгә күркәм, тотар кулга саллы күренә (40 табак тирәсе!). Ул XIX гасыр әдәбиятын яктыртуга багышланган.

Мәгълүм булганча, XIX йөз — тарихыбызның гаять катлаулы һәм каршылыклы чоры. Аның асылын феодаль-крепостнойлыктан капитализмга күчә бару, сыйнфый һәм милли изүнең тагын да көчәюе, буржуаз-демократик һәм мәгърифәтчелек хәрәкәтенең активлашуы тәшкил итә. Чорның бу төр үзенчәлекләре теге яки бу дәрәҗәдә әдәбиятның да төп юнәлешләрен, рухын билгеләгән, аның идея-эстетик табигатендә тирән эз калдырган.

XIX йөз — күп гасырлык татар мәдәниятенең Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйри, Хөсәен һәм Габделгалләм Фәезхановлар кебек энциклопедист әдипләрен, Ә. Каргалый, Ш. Зәки, Г. Кандалый, М. Акмулла шикелле талантлы шагыйрьләрен, М. Акъегет, З. Бигиев, Ш. Мөхәммәдев, Ф. Халиди кебек сәләтле каләм әһелләрен биргән мөһим этап. Борынгы һәм Урта гасыр мәдәни традицияләрен тагын да үстергән, Шәрык, рус әдәби казанышларын мул файдаланган XIX йөз әдәбияты бөек Тукайлар, Ибраһимовлар тууда төп таяныч, хәлиткеч фактор булды. Татар совет әдәбияты үсешендә дә узган гасыр әдәбиятының зур роль уйнавы бәхәссез. XIX йөз әдәбиятының казах, каракалпак, башкорт, үзбәк, комык һәм кайбер башка халыкларның рухи үсешенә дә билгеле бер йогынты ясавын онытырга ярамый. Совет кешеләрендә матур әхлакый сыйфатлар тәрбияләүдә, аларның эстетик зәвыкларын үстерүдә, тарихи күзаллауларын киңәйтүдә һәм тирәнәйтүдә XIX йөз әдәбиятының бүген дә тәрбияви әһәмияте зур.

XIX йөз татар әдәбиятын гыйльми яктан өйрәнүгә Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Р. Фәхретдинев, Г. Газиз, Г. Рәхим, Г. Сәгъди, И. Нуруллин, М. Госманов, Ш. Садретдинов, С. Хафизов һ. б. галимнәр үзләреннән зур өлеш керттеләр. Аларның фикер-күзәтүләре һәм табышлары томда, нигездә мул һәм иркен файдаланылган. Узган гасыр әдәби мирасын тикшерүдә аеруча мәрхүм Мөхәммәт ага Гайнуллинның күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеген ассызыклап китәргә кирәк. Рецензиянәнә торган хезмәттә дә ул һәм том җитәкчесе, һәм автор буларак чыгыш ясый. Аның монография-дәреслекләре, гыйльми концепцияләре, гомумән, китапның нигезенә салынган һәм башка авторлар өчен дә теге яки бу дәрәҗәдә таяныч, юл күрсәткеч булып хезмәт иткән.

Әдәбият тарихы — күпкырлы һәм катлаулы күренеш, ул үзенә комплекслы якын килүне таләп итә. Зарури бу принцип әлеге хезмәттә шактый дәрәҗәдә сакланган. XIX йөз әдәбияты, үзенең асылына, шул чордагы реаль урынына һәм вазифаларына нисбәтле рәвештә, иҗтимагый тормыш контекстында, күп төрле бәйләнеш-элемтәләрдә карала; андагы эчке үзгәрешләр, төп тенденцияләр җәмгыятьнең, халыкның үсеш ихтыяҗлары белән аңлатырга тырышыла. Моңа, бер яктан, әдәбиятчы галимнәрнең башка фәннәрдәге гыйльми казанышларны иркен файдалануы, икенче яктан, томда философ, телче, китап белгече һәм тарихчыларның автор буларак катнашулары ярдәмендә ирешелә.

Томның зур өлеше М. Гайнетдинов, М. Гайнуллин, Р. Әхмәтов һәм Ф. Мусин тарафыннан язылган. Ә, гомумән, бу хезмәтне язуда барлыгы 15 автор катнашкан. Шуларның дүртесе Казан дәүләт университетыннан, сигезе Институтның — әдәбият, ә калганнары — башка секторлардан. Шулай да әле гыйльми көчләрне туплау буенча файдаланылмаган мөмкинлекләр калган. Мәсәлән, Казан һәм Башкорт дәүләт университетларының татар әдәбияты кафедраларында XIX йөз әдәбияты өлкәсендә махсус эшләгән яисә эш-

---

[1] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 2 нче том. XIX йөз татар әдәбияты. (СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, һәм тарих институты.— Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1985.— 575 б. Том редколлегиясе: Гайнуллин М. Х. (җаваплы редактор), Ханзафаров Н. Г. (җаваплы редактор урынбасары), Гайнетдинов М. В., Әхмәтов Р. Ә.

ләп килүче иптәшләрнең томнан читтә калуы һич тә аңлашылмый. Аларның китапта автор буларак катнашулары аерым өлешләрдәге компилятив моментларны киметүгә һәм хезмәтнең сыйфатын тагын да камилләштерүгә ярдәм иткән булыр иде.

Авторлар коллективының эшчәнлеген оештыруда, хезмәтне әзерләүдә һәм китап итеп дөньяга чыгаруда Г. Ибраһимов исемендәге институтның әдәбият секторы хезмәткәрләренең, баш һәм том редколлегияләренең, нәшрият хезмәткәрләренең зур хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк.

Хәзер томның эчке корылышына күз ташлыйк. Ул, бер яктан, XIX йөз әдәбиятының үз төзелешенә, икенче яктан, әдәбият тарихларын язуда тупланган жанр казанышларына нигезләнгән. Китапның «Кереш» һәм «Йомгак» өлешләрендә иҗтимагый тормышка нисбәтле рәвештә XIX гасыр әдәбиятындагы төп тенденцияләр, үзгәрешләр, үзенчәлекләр күрсәтелә; татар әдәбиятының СССР халыклары әдәбиятларының берсе буларак үзара бәйләнешләрдә каралуына, патша Россиясендәге халыкларның азатлык хәрәкәтендәге ролен күрсәтү юнәлешендә тикшерелүенә басым ясала. «Кереш»тә XIX йөз татар әдәбиятын өйрәнү тарихы да яктыртыла. Шулай да әле бу өлешкә тулылык, тәнкыйди анализ җитенкерәмәгән. Бер генә мисал китерик. «XIX йөз татар әдәбияты ядкарьләре» дигән хезмәттә (Казан, 1982), яңа факт-мәгълүматларга нигезләнеп, Ш. Зәки 1821 елда туган дип әйтелгән иде (15—16, 25 бб.). Томда исә бу фикер кабул ителмәгән: иске дата, ягъни 1825 ел алынган (170 б.). Ни өчен шулай? Моның сәбәбе дәлилле рәвештә аңлатылырга тиеш иде.

Китапта XIX гасыр әдәбияты, моңа кадәрге фәндә кабул ителгәнчә, ике зур чорга бүлеп карала: XIX йөзнең беренче яртысындагы (1800—1860) һәм икенче яртысындагы (1861—1905) татар әдәбияты. Шунысын да искәртик: Россиядәге азатлык хәрәкәтенә нигезләнгән бу ике кисәк арасында «кытай стенасы» юк. Алар үзара керешкән, бер-берсе белән табигый рәвештә кушылган. Аерым әдипләрнең эшчәнлеге ике чорда да дәвам итә. Шулай да мондый бүленеш, гәрчә ул бик үк төгәл булмаса да, гомумән алып караганда, әдәбиятның идея-тематик эчтәлегенә һәм поэтик табигатенә туры килә.

Томда XIX йөз әдәбиятының һәр ике чоры да ил һәм халык тормышындагы мөһим иҗтимагый-тарихи вакыйгаларга, мәдәни хәрәкәткә күзәтү белән башлана, төрле чыганаклардан гыйбрәтле генә факт-мәгълүматлар китерелә.

Декабристлар күтәрелешенең, Казан университеты эшчәнлегенең, рус революцион-демократик хәрәкәтенең һәм кайбер башка мөһим күренешләрнең татар иҗтимагый һәм мәдәни тормышында нинди роль уйнаулары китапта шактый дәлилле яктыртыла. Авторлар, «престижлы», ил күләмендә билгеле вакыйгалар белән беррәттән, татарның үз эчке тормышындагы мәгърифәтчелек, «абыз-агайлар», дини бәхәсләр, вәисевчелек кебек катлаулы, каршылыклы күренешләргә дә җитди игътибар итәләр һәм аларның иҗтимагый асылын, социаль сәбәпләрен ачарга омтылалар.

Әдәбиятның үсеше, яшәеше, җәмгыятькә тәэсир көче мәгариф һәм матбагачылык белән тыгыз бәйләнешле. Шуңа күрә күзәтү өлешләрендә бу мәсьәләләр хакында сүз алып бару табигый һәм урынлы. Ә. Кәримуллин язган бүлекчәләрдә татар китапларының катлаулы тарихы кыскача, әмма гыйльми тирәнлектә бирелә. Мәгариф мәсьәләсе исә, күрәсең, махсус бүлекчәләр багышланмау аркасында, тараурак яктыртылган.

Иҗтимагый-тарихи һәм культура хәрәкәтенә күзәтүдән соң беренче кисәктә «Әдәбият үсешенең төп тенденцияләре» дип исемләнгән зур күләмле, бай эчтәлекле бүлек килә. Алга таба чорның төп алты шагыйре монографик планда карала.

Билгеле булганча, XIX йөзнең беренче яртысындагы әдәбиятта поэзия хакимлек итә. Ә инде аннан соңгы чорда хәл үзгәрә: поэзия белән беррәттән, проза ныклап үсеп китә, драма әсәрләре барлыкка килә. Икенче кисәкнең структурасы нәкъ менә шушы үзенчәлеккә корылган да. К. Насыйриның энциклопедик эшчәнлеге «Иҗтимагый-культура хәрәкәте» бүлеге белән тыгыз бәйләнештә, андагы мәсьәләләрне конкретлаштыру рәвешендә килә. Алга таба проза, поэзия (шунда ук хатын-кыз шагыйрәләргә махсус бер бүлекчә дә бирелгән) һәм драматургиягә аерым-аерым күзәтү ясала. Аларның тәүгесенә мөнәсәбәттә алты, икенчесенә бәйләнештә биш әдипнең тормышы һәм иҗаты махсус бүлекләрдә тикшерелә. Ә инде драматургия өлешендә күзәтү һәм монографик материаллар бергә туплап бирелгән. Гомумән, томның икенче кисәгендәге монографик бүлекләрдә шул дәвер әдәбиятының күренекле вәкилләре карала. Шулай да әле биредә уйлыйсы урыннар бар. Мәсәлән, күренекле мәгърифәтче Ф. Халиди,— драматург булу белән беррәттән, «Мең дә бер кичә», «Мең дә бер сәхәр», «...Ләйлә вә Мәҗнүн...», «Кемгә тиеш?» һәм башка күп санлы тәрҗемә, оригиналь китапларның авторы да. Ул татар әдәбиятын һәм әдәби телен үстерүгә, киң катлау укучыларын дөнья әдәбиятының мәшһүр ядкарьләре белән таныштыруга үзеннән зур өлеш керткән. Кызганычка каршы, Ф. Халиди томда сәхнә әсәрләре авторы буларак кына карала. Аның күпкырлы һәм бай иҗат мирасы исә үзеннән-үзе махсус бүлектә, җентеклерәк яктыртуны сорап тора.

«Балалар әдәбияты» бүлеге (Ф. Ибраһимова) факт-мәгълүматларның билгеле бер дәрәҗәдә системалаштырылуы һәм анализлануы белән игътибарга лаек. Автор XIX йөз татар әдәбияты белән генә чикләнми: Урта

гасырларга да экскурс ясый, рус, төрек әдәбиятлары белән бәйләнешләрне, кайбер типологик охшашлыкларны да күрсәтә.

Тел — әдәбиятның төзү материалы, М. Горький сүзләре белән әйткәндә, аның «беренчел элементы». Шуңа күрә әдәбият тарихына мөнәсәбәттә әдәби тел һәм стиль мәсьәләләре хакында махсус сүз алып бару урынлы һәм кирәк. В. Хаков һәм И. Бәширова тарафыннан язылган «Әдәби тел һәм матур әдәбият стиле» бүлеге нәкъ әнә шул заруриятне күздә тотып томга урнаштырылган да. Анда XIX йөз әдәби тел үсешендәге төп тенденцияләр, юнәлешләр күрсәтелә, поэзия, проза һәм драма төрләренең теле махсус бүлекчәләрдә карала, прозада хикәяләү үзенчәлекләре хакында кызыклы гына күзәтүләр ясала. Әмма әле бу бүлекне тагын да тирәнәйтү, камилләштерү мөмкинлекләре калган. Анда бер үк фикернең, фактик материалның кабатлану очраклары бар. Безнең фикеребезчә, проза әсәрләренең теле һәм хикәяләү үзенчәлекләре өлешләрен бергәрәк җыеп та бирергә мөмкин иде. Чөнки хикәяләү — проза теленең төп хосусиятләреннән берсе. Бүлектә әдәби төрләрнең генә түгел, ә мәдхия-мәрсия, газәл, касыйдә, мөнәҗәт, сәяхәтнамә кебек жанрларның тел үзенчәлекләре хакында да аерым күзәтүләрне күрәсе килә.

Китап ахырында бирелгән елъязмада (Н. Ханзафаров) әдәбият һәм культура тормышына мөнәсәбәтле төп факт-мәгълүматлар, вакыйгалар теркәлгән, аларның һәрберсенең чыганагы күрсәтелгән. Бу елъязма XIX йөз әдәбиятын эзлеклерәк һәм тулырак күзаллауга ярдәм итә.

Куанычка каршы, соңгы елларда татарча чыккан фәнни китаплар да күрсәткечләр белән тәэмин ителә башлады. Моның матур бер үрнәген без беренче томда күргән идек. Икенче томда «Исемнәр, аноним һәм киң таралган әсәрләр күрсәткече» белән тәэмин ителгән (Ә. Муллаянова, Н. Ханзафаров). Мәгълүм булганча, бу төр күрсәткеч китап белән эш итүдә шактый җиңеллек тудыра.

Томда күренекле әдип-галимнәрнең рәсемнәре, төрле басма һәм кульязма хезмәтләрнең аерым фотокүчермәләре урнаштырылуны да хупларга кирәк. Алар, нигездә, уңышлы сайланган. Тик аерым битләрдәге (34, 52 бб.) иллюстрацияләр тоныграк чыккан.

Китаптагы бүлекләрнең үз эчләрендә кечерәк кисәкләргә бүленеп бирелүләре дә эчтәлекне кабул итүдә уңайлык тудыра.

Томда Ш. Мәрҗанинең мондый сүзләре китерелгән: «һөнәр вә мәгариф кайда булса, шунда барып тәхсил итәргә (өйрәнергә.— Х. М.) кирәк. Гыйлем белән мәгарифнең хас ватаннары, хас лисаннары (телләре.— Х. М.) юк» (227 б.). Күп кенә халыклар кебек татарлар да башкаларның казанышларын өйрәнеп, үз байлыклары һәм тәҗрибәләре белән уртаклашып яшәгәннәр һәм яшиләр. Бу объектив күренеш XIX йөз мәдәнияте өчен дә хас. Мәсәлән, күренекле әдип һәм журналист Ф. Кәрими Чистай мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Истамбул университетында белем ала. Үз туган теленнән тыш төрек, гарәп, фарсы, рус, француз телләрен иркен сөйләшерлек үзләштерә. 1899 елда Көнбатыш Европа илләре буйлап сәяхәт кыла, культура истәлекләре белән таныша. Казан артындагы мәшһүр Ташкичү мәдрәсәсенең укытучысы Шәмсетдин Кашкари Каһирәгә барып чыга һәм атаклы әл-Әзһәр университетында 7 ел буе фарсы теле укыта. Мәгърифәтче Х. Фәезханов Россиянең күренекле галимнәре белән аралашырлык һәм Петербург университетында дәресләр алып барырлык дәрәҗәгә ирешә. XIX йөз татар укучылары арасында Көнчыгышның күп санлы ядкарьләре киң таралыш таба; алар тәрҗемәдә генә түгел, оригиналда да укылалар, милли әдәбият үсешенә зур йогынты ясыйлар. Рус, Көнчыгыш Европа мәдәни казанышлары белән кызыксыну көчәйгәннән-көчәя бара.

1922 елда язылган бер хезмәтендә Г. Ибраһимов — «башка туфракта туып та, бездә үз әдәби малымыз кабиленнән булып киткән әсәрләр» хакында болай дигән иде: «Болар бездә гаммәнең (халык массасының.— Х. М.) кыйммәтле җан азыгы — үзләшкән әсәрләре булганга, әлбәттә, шул вакытның тарихын тулы белү өчен, бездә өйрәнелергә — дәреслеккә кертелергә, әдәбият тарихымызга, кайдан килүләре әйтелеп, тикшерелергә тиешләр»[1]. Бөек әдипнең бу киңәше томда билгеле бер дәрәҗәдә исәпкә алынган. Һәм күзәтү, һәм монографик бүлекләрдә һәрбер автор диярлек татар әдәбиятының интернациональ бәйләнешләренә, читтән кергән әсәрләрнең идеологик-эстетик вазифаларына шактый игътибар итә. Китапта «Әбугалисина», «Тутыйнамә», «Мең дә бер кичә» кебек ядкарьләр хакында кызыклы гына белешмәләр бар. Шулай да, томны укыганнан соң, XIX йөздәге әдәби бәйләнешләр, аеруча Шәрык мәдәнияте белән бәйләнешләрдәге төп тенденцияләр һәм идея-эстетик принциплар хакында әле системалы, чагыштырмача бөтенлекле күзаллау туып җитми. Моның, безнең уебызча, ике төп сәбәбе бар. Беренчесе — бу мәсьәләнең фәндә махсус рәвештә, җентекле өйрәнелмәве. Томдагы мәкаләләрнең авторлары үзләре дә бу хакта урынлы искәртәләр (245, 255, 257 бб.). Икенче сәбәп — китапта әдәби бәйләнешләрне үзәккә алган махсус бүлекнең булмавы. Шуның нәтиҗәсендә бар булган факт-мәгълүматлар да тараурак, проблемалы анализдан читтәрәк калган.

Китап үзенең эчтәлеге, рухы белән, гомумән, тикшерену, эзләну характерында. Ул нәрсәләрдә күренә соң?

Беренчедән, аның фактик нигезе шактый

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. 5 т. Казан, 1978, 356 б.

бай. Авторлар Мәскәү, Ленинград, Казан, Ташкент, Уфа һәм кайбер башка шәһәрләрнең архивларында һәм китапханәләрендә саклаучы күп санлы документларны, кульязма һәм басма материалларны гыйльми әйләнешкә кертәләр (бу аеруча М. Гайнетдинов тарафыннан язылган бүлекләргә хас). Шуның нәтиҗәсендә XIX йөз әдәбияты турында мәгълүмат тагын да байый, тагын да тулылана төшә. Томда моңа кадәр татар әдәбият фәнендә бөтенләй яисә тиешенчә игътибар ителмәгән Низаметдин Сираҗетдин улы, Рәхмәтулла бине Әмирхан, Нигъмәт Ибраһимов, Әхмәтбик, Колмөхәммәт, Җамалетдин Сабави, Мөхәммәтшәриф Габдерәшит улы, Фәхретдин бине Мифтахетдин, Мәүлекәй Юмачиков һәм башка әдипләр телгә алына, аларның тормышлары һәм иҗат эшчәнлекләре хакында шактый мәгълүмат бирелә. Шунысы мөһим: бу төр әдипләр арасында махсус бүлеккә лаеклылар да бар икән. Баһави, Гомәр Мөхәммәт улы, Баһаветдин Вәисев — әнә шундыйлардан. Китапта аларның катлаулы, каршылыклы иҗаты, иҗтимагый тормыш һәм әдәби контекстка нисбәтән, уңышлы гына тикшерелә, әдәбиятка керткән яңалыкларына басым ясала. Мәсәлән, Гомәр Мөхәммәт улы сәфәрнамәләрендә буржуаз прогресс идеаллары гәүдәләнеш табу, рус, Европа мәдәни казанышларына йөз тоту, реаль тормышны үзәккә кую искәртелә. Ә инде Баһаветдин Вәисев иҗатына тәнкыйди, сугышчан рух, иҗтимагый-политик тормыш белән тыгыз бәйләнеш хас булу күрсәтелә.

Икенчедән, моңа кадәр укучыларга билгеле әсәрләр хакында да томда күп кенә яңа фикерләр, кызыклы күзәтүләр бар. Менә XIX йөзнең икенче яртысындагы прозага күзәтү мәкаләсе һәм М. Акъегет, З. Бигиев хакындагы бүлекләр. Мин аларның Ф. Мусин тарафыннан язылганын күреп, әүвәл бераз аптырап калдым. Ни өчен? Чөнки бу чор прозасы хакында М. Гайнуллинның күп кенә хезмәтләре бар. Ә нигә алар гына томга урнаштырылмаган? Яңа автор өстәп нәрсә әйтә алыр? Әмма Ф. Мусин язган бүлекләрне укыганда, бу төр шикләнүләр юкка чыга. Ул, М. Гайнуллин хезмәтләренә һәм совет әдәбият фәненең теоретик казанышларына нигезләнеп, XIX йөз прозасының яңарак якларына игътибар итә, андагы күренешләрне төрле бәйләнешләрдә карый, аерым типологик күзәтүләр дә ясый. Шушындый ук хәл Әхмәт Уразаев-Кормаши (М. Гайнетдинов), Мифтахетдин Акмулла (Р. Әхмәтов) һәм кайбер башка бүлекләрдә дә күзгә ташлана.

Өченчедән, авторлар әдәби процессны һәм конкрет әсәрләрне анализлау барышында кеше образының бирелеше, эстетик идеал, иҗат методлары (аеруча мәгърифәтчелек реализмы), синкретизм, традиция һәм новаторлык, әдәбиятның тормыштагы роле кебек эстетик төшенчәләр хакында да мөһим генә фикерләр әйтәләр.

Әдәбиятны эчке хәрәкәттә, иҗтимагый ихтыяҗлар белән бәйләнешле процесс рәвешендә карарга омтылу күренә. Әмма кайвакыт аерым әдәби күренешләр тиешенчә бәйләнми яисә онытылып кала, шуның нәтиҗәсендә берьяклы, бәхәсле моментларга юл куела. Китапта, мәсәлән, татар әдәбиятында мәсәл жанры XIX йөздә генә формалаша дигән фикер уздырыла (5, 163 бб.). Чынлыкта исә мәсәлләрнең Урта гасырларда ук язылуы мәгълүм. XIV йөз шагыйре С. Сараиның берничә мәсәле бар. Генетик яктан Көнчыгыш белән бәйләнешле «Хикәяте сычкан» мәсәле, «Кәлилә вә Димнә»дәге аерым үрнәкләр татар укучыларына күптәннән билгеле. Авторларның хикәя, повесть жанрлары тууын XIX йөзгә нисбәт итүләре белән дә (7, 542 бб.) килешәсе килми. Чөнки бу чорга кадәр ук жанр табигате белән хикәягә, повестька тартым, әмма «хикәят» исеме белән аталган әсәрләр күпләп иҗат ителгән. Китапның 181 битендә мондый юллар бар: «...бу иҗат аша (сүз Ш. Зәки иҗаты хакында бара.— Х. М.) татар поэзиясенә яңа бер интенсивлык (?) белән көнчыгыш образлары керә һәм татарча яңгыраш таба: хәмер (исерткеч), чауган (шар уены), пәрванә (күбәләк), сакый (эчемлек салучы), җамаяк, шәм һ. б.». Бу төр образлар инде Котб, Хәрәзми, С. Сараи, Өмми Камал, Мөхәммәдьяр һәм башка шагыйрьләрнең иҗатларында кулланылып, күптәннән ук татар әдәбиятының үз хәзинәсенә әверелгән.

Китапта, гомумән, XIX йөз әдәбиятын Урта гасыр мәдәни мирасы белән бәйләү җитенкерәми. Ә бит ике арада типология һәм традиция нәтиҗәсендә туган уртаклыклар һәм охшашлыклар гына да шактый. Мәсәлән, Колмөхәммәтнең «Тәгърифел-вилдан» поэмасында аталар һәм балалар мөнәсәбәте Мәүла Колый һәм Габди традицияләре рухында яктыртыла (70—71 бб.). Хәрәзми һәм Кандалый, Х. Кятиб һәм һ. Салихов, Габди һәм Я. Емельянов, М. Колый һәм Б. Вәисев иҗатларында да үзара аваздаш якларны билгеләү кыен түгел.

Китапта төрле характердагы басма һәм кульязма чыганаклардан күп санлы өзекләр, мисаллар китерелгән. Аларның бирелеше, аңлатылышы, гомумән, бәхәс уятмый. Авыр текстларның янәшәдә тулы тәрҗемәсен бирү дә хуплауга лаек.

Китапның берничә урынында фактик төгәлсезлек җибәрелгән. 251 биттә «1898—1899 елларда» Риза Фәхретдинев үзенең күп томлы «Асар»ын язган диелә. Ә инде 321 биттә әлеге библиографик белешмәнең бу елларда языла башлавы гына искәртелә. Аның беренче кисәге — 1900, икенчесе — 1901, калганнары аннан соңгы елларда басыла. Революциядән соң язылган кисәкләре нәшер ителмичә кала. 237 биттә Хәсән Фәезханов хәзерге «Горький өлкәсе Краснооктябрьск районы Сабачай (Сафаҗай) авылында туа» диелгән. Бу авыл инде күптәннән Пильна районы составында, аның рәсми исеме —

Красная Горка. С. Күкләшев хрестоматиясе 1845 елда төзелгән дип кистереп әйтү дә (31, 55, 112 бб.) бәхәсле. Кайбер кисәкләр һәм бүлекләр арасында да гыйльми яктан аерымлыклар күзгә ташлана. Ш. Зәки, Г. Кандалый, К. Насыйри, Ф. Халиди, Ф. Кәрими, Ш. Мөхәммәдев иҗатларын, мәсәлән, яңарак аспектларда һәм бәйләнешләрдә әле тагын да тирәнрәк тикшерү мөмкинлекләре калган. XIX йөз әдәбиятының поэтикасы да әле ныграк, җентеклерәк яктыртуны көтә.

Төрле авторлар тарафыннан язылган күмәк хезмәтне басмага хәзерләгәндә, фикер кабатлануларыннан котылу мөһим мәсьәлә булып тора. Том җитәкчелеге һәм редакторлар моңа җитди игътибар иткәннәр. Бары берничә урында гына бер үк фикернең, фактик материалның кабатлануы күзгә ташлана (174, 178, 179, 222, 233—234, 251, 272, 284, 316 бб.).

Томда шулай ук бер үк сүзне төрлечә язу очраклары да бар: рәгыять — халык, масса (119 б.), рәгъят (403, 478 б.); Нәваи (112, 174 бб.), Нәвои (143, 251 бб.); җәбен — куркак (222 б.), җөбен (272 б.) һ. б. Безнеңчә, боларның рәгыять, Нәваи, җәбен формалары дөрес.

Китапның тел-стиле, гомумән, уңай тәэсир калдыра. Шулай да әле анда төзәтүгә мохтаҗ урыннар бар. Беренчедән, гәрчә бик сирәк булса да, кытыршырак, авыр аңлаешлырак җөмләләр очрый. Икенчедән, урынсызга чит сүзләр куллану фактлары да бар: гуман (158, 469, 500 бб.), придан (306 б.), химера (230 б.), акцент (472 б.) һ. б. Боларның бит үз телебездә кешелекле, бирнә, буш хыял, басым дигән аңлаешлырак формалары бар. Публицистизм (63 б.) протестчыл (198 б.), критицизм (289 б.), Богоутдинов (236 б.) һ. б. кебек атамалар да авыр яңгырый.

XIX йөз татар әдәбияты тарихын үз эченә алган икенче том — мәдәни мирасыбызны өйрәнү юлында зур һәм җитди хезмәт. Аңа, алдарак искәрткәнебезчә, тикшеренү, эзләнү рухы хас. Шуңа күрә аерым бәхәсле моментларның, каршылыклы урыннарның булуы да гаҗәп түгел.

«Нинди дә булса проблеманың хәл ителеше—ул бер үк вакытта яңа проблеманың куелышы да»,— ди бөек Гете. Икенче том — әдәбият фәнебезнең зур казанышы. Анда күп кенә мәсьәләләр хәл ителгән. Әмма шуның белән бергә алдыбызга күп кенә яңа проблемалар да килеп баскан. Шунысы мөһим: аларның күпчелеге авторларның үзләре тарафыннан да күрсәтеп барыла. Китапның «Кереш»ендә үк, мәсәлән, болай диелә: «...әле XIX гасыр татар әдәбияты тарихы мәсьәләләре тагын да төплерәк өйрәнүне көтә: әлегә кадәр күп кенә кульязмалар, кайбер аноним басмалар тиешенчә тикшерелмәгән, байтак әсәрләрнең төп текстлары хәзерге алфавит һәм орфография белән басылмаган хәлдә кала килә» (9—10 бб.). Том җитәкчесе Мөхәммәт ага Гайнуллинның бу хак сүзләренә кушылмый һич мөмкин түгел. Урта гасыр һәм XIX йөз әдәби ядкарьләрен, бу дәвернең мөһимрәк тәрҗемә әсәрләрен күптомлыклар яисә хрестоматияләр рәвешендә әзерләп чыгару эшләрен дә тизләтәсе бар. Татар поэзиясе антологиясенең татар һәм рус телләрендәге тулыландырылган икенче басмасын да укучылар күптәннән көтә. Кыскасы, эшләнгән эшләр күп, әмма башкарасылары тагын да күбрәк.

Әдәбият тарихының икенче томы дөнья күрү — мәдәниятебез тормышында мөһим вакыйга. Ул әдәбиятыбызның олылыгын, байлыгын янә бер мәртәбә раслый, офыкларыбызны киңәйтә, күңелебезне, зиһенебезне баета. Укучылар һәм укытучылар, галимнәр һәм әдипләр, журналистлар һәм культура әһелләре өчен генә түгел, ә киң масса өчен дә кирәкле һәм файдалы китап бу. Шуңа күрә аны ныграк пропагандаларга, җентеклерәк өйрәнергә, гомумән, иҗтимагый тормыш агышы белән актив мөнәсәбәткә кертергә кирәк.

**Хатип МИҢНЕГУЛОВ**

# ЯҢА СҮЗЛЕК

*Рус белән тормыш кичердек сайрашып,*
*Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.*

Габдулла Тукай

Илебезнең башка төбәкләрендәге кебек, Татарстан территориясендә дә төрле милләт вәкилләре яши. Бер гаилә булып яшәүче СССР халыкларына хас булган социаль һәм рухи бердәмлекнең иң характерлы үзенчәлекләреннән берсе — илебездә яшәүче төрле милләт вәкилләренең рус телен икенче ана теле итеп кабул итүләре.

Рус теле аралашуда, культура үсешендә куәтле тел коралына гына түгел, ә күпмилләтле совет халыкларын бергә туплау, уртак максатка юнәлдерү, аларны совет һәм дөнья мәдәнияты казанышларына җәлеп итү чарасына да әверелде. Шуңа күрә башка милләт халыкларында рус телен өйрәнүгә, аның байлыгына, сәнгать көченә ия булуга омтылыш арткannan-арта бара.

Икетеллелек мәсьәләләрен хәл итүдә, милләтара рус телен өйрәнүне җиңеләйтүдә һәм тизләтүдә тәрҗемәле сүзлекләр бигрәк тә әһәмияткә ия. Мондый төр сүзлекләргә ихтыяҗ үскәннән-үсә бара. Киң катлау укучылар, шулай ук педагоглар, радио-телевидение, матбугат хезмәткәрләре, язучылар, тәрҗемәчеләр, тел-әдәбият белгечләре дә мондый сүзлекләрне иң кирәкле кулланма итеп кабул итәләр.

Сугыштан соңгы елларда тәрҗемәле сүзлекләр төзүдә хәзерлекле белгечләр катнашып, күләмле, тирән эчтәлекле, бай сүзлекләр барлыкка килде. Бу төр сүзлекләр төзүдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләре зур тырышлык куйдылар. 1955-1959 елларда 80 мең чамасы сүзне үз эченә алган 4 томлык, ә 1971 елда 50 меңгә якын сүз кергән бер томлык русча-татарча сүзлекләр дөнья күрде.

Фән-техника революциясе, кешелек җәмгыятенең прогрессив үсеше, тормышыбыздагы күп төрле яңалыклар һәм телнең сүзлек составын даими үзгәртеп, тулыландырып һәм яңартып торалар. Яңа терминнар, тәгъбирләр, сүз тезмәләре өзлексез туып тора. Соңгы унбиш елда гына да рус теле лексикасы, шул исәптән татар теленең сүзлек составы да шактый яңарды. Шунлыктан яңа сүзлек төзү мәсьәләсе көн тәртибенә басты. Ниһаять, 1984 елда (икенче басмасы 1985 елда) Мәскәүнең «Рус теле» нәшриятында яңа «Русча-татарча сүзлек» басылып чыкты (төзүчеләре: Ә. М. Ахунҗанов, Р. С. Газизов, Ф. А. Ганиев, Л. Т. Мәхмүтова, М. Г. Мөхәммәдиев, Х. Н. Мөхәммәтшин, К. С. Сабиров, Ф. Х. Хәсәнов. Нәшрият редакторлары: Л. А. Богданова, Д. П. Лукашевич).

Ул киң кулланышта йөрүче рус сүзләренең, сүзтезмәләрнең, фразеологик гыйбарәләрнең, табышмакларның һәм мәкаль-әйтемнәрнең тәрҗемәләрен үз эченә ала. Сүзлекнең полиграфик яктан эшләнеше, югары сыйфат белән басылуы игътибарны җәлеп итә. Яңа сүзлек структур төзелеше, техник-лексикографик башкарылышы ягыннан да уңай якка үзгәргән диясе килә. Русча-татарча сүзлекнең нигезендә яткан лексикографик принциплар фәнни җирлеккә корылганнар, анда сүзлекләр төзү практикасында тупланган бай тәҗрибәгә һәм традицияләргә таянып эш ителгән.

Сүзлекнең кереш өлешендә күрсәтелгәнчә, аның нигезенә И. С. Ожеговның «Словарь русского языка»сы (М., 1977) алынган.

Төзүчеләр лексикографик чыганаклар буларак рус теленең башка сүзлекләрен, 1977—1981 елларда чыккан өч томлык аңлатмалы сүзлекне, моңа кадәр дөнья күргән русча-татарча, татарча-русча, диалектологик, фразеологик, синонимик, алынмалар һәм терминологик сүзлекләрдән дә уңышлы файдаланганнар.

Яңа сүзлек алдагыларыннан лексик материалның күләме белән генә түгел, бәлки сүзлек мәкаләләренең тулылыгы һәм яңача эшләнеше белән дә аерылып тора.

Күпмәгънәле рус сүзләрен мәгънәләргә аеру нәтиҗәсендә тәрҗемәдәге синонимнарның саны һәм иллюстратив материалларның күләме арткан.

Ике телле сүзлекләрдә, нигездә, туры (эквивалент) тәрҗемә төп урынны алып тора. Бу тәрҗемә итеlә торган сүзләрнең мәгънәләрен аларга тәңгәл килә торган сүзләр белән тәрҗемә итү дигән сүз. Әйтергә кирәк, төзүчеләр бу эштә татар теленең синонимик байлыгын киң файдаланганнар. Авторлар кирәкле урыннарда чаманы белеп кенә искергән (архаик), диалекталь һәм гади сөйләм сүзләре белән тулыландыралар. Бу юл белән тасвирлама тәрҗемәдән котылалар һәм рус теленең стилистик төсмерләрен бирә алуга ирешәләр. Мәсәлән, сверстник — яшьтәш, кордаш; порез — киселгән урын, яра, җәрәхәт; простофиля — беркатлы кеше; ачык авыз, җебегән, пешмәгән.

Ләкин кайбер сүзләрнең мәгънәләрен биргәндә синонимнар белән мавыгу да күренә. Мәсәлән, просвещенный — мәгърифәтле, укымышлы, укыган, белемле, югары культуралы; кузнечик — чикерткә, сикерткә; кальян — кальян, хурхур.

Соңгы сүзнең (кальян) тәрҗемәсен генә алып карыйк. Тәрҗемәдәге һәр ике сүз дә аңлашылмый. 1979 елда чыккан аңлатмалы сүзлеккә мөрәҗәгать итәбез. «Кальян» сүзе «көнчыгышта тәмәке тарту приборы (анда төтен су аша чистарып уза)» дип бирелгән. «Хурхур» сүзенең мәгънәсе әлеге сүзлектә дә бирелмәгән. Гомумән, мондый очракларда кулланышта булмаган искергән синонимик вариантлар эзләү уңышлы түгел.

Сүзлектә кайбер русча яки интернациональ сүзләргә, фәнни-техник терминнарга (татар теленә турыдан-туры тәрҗемә итәргә мөмкинлек булмаганда) аңлатма бирелгән. Андый сүзләр телебездә шул халәтләрендә кулланылыш тапканнар, ә инде укучыга киңрәк планда аңлатып бирүне уңышлы һәм кирәкле дип әйтәсе килә. Мәсәлән, антология — антология (төрле авторларның сайланма әсәрләре җыентыгы); аполитизм — аполитизм (политика мәсьәләләре белән кызыксынмау, иҗтимагый-политик тормышта катнашудан баш тарту); коллоид — коллоид (кристалланмый торган матдә) кебек мисалларда аңлатма-тасвирлама бирү укучыны башка сүзлекләрне актарып, вакыт сарыф итүдән коткара.

Сүзлектә рус телендәге искергән һәм гади сөйләмдәге сүзләргә бераз урын бирелгән. Шуның белән беррәттән рус телендәге яңа сүзләр дә киң кертелгән. Мәсәлән, лининиана, видеотелефон, межконтинентальный, околоземный, дискотека, вирусолог һ. б. Дөрес, шактый гына сүзләр төшеп тә калган. Алар арасында яңалары да, электән үк рус теленең лексик фондында булганнары да бар. Мәсәлән, интеркосмос, цветомузыка, левак, консультативный, рантье, кантональный, малотоннажный, агропромышленный, душегуб, тепляк, металлокорд, таймаут, аэробус, турбоход, интервенционист, лангуст, дестабилизация, эксплуатационник, влагосберегающий, блицкрик, автосамосвал, диетсестра, бракодел, плунжер һ. б.

Русча-татарча сүзлектә лексик берәмлекләрнең нинди лексик һәм стилистик катламнарга керүен күрсәтеп, авторлар сүзләрнең мәгънәви һәм сөйләмдә куллану үзенчәлекләрен ачканнар. Мәсәлән, анемия — аз канлылык (медицина термины); архаизм борынгы сүз (лингвистик); барин 1. (помещик) алпавыт, барин 2. (хозяин, господин) хуҗа (искергән сүзләр) 3. әфәнде, хуҗа әфәнде (сөйләмдә, эндәшкәндә) 4. ялкау, барин (кимсетү, түбәнсетүдә); интерпретатор интерпретацияләүче, аңлатучы, ачыклап бирүче (китап теле) дип күрсәтелгәннәр.

Сүзлекләрдә татар теленең фигыль формаларын чагылдыру — шактый катлаулы мәсьәлә. Төзүчеләр, рус теле фигыльләренә төгәл адекватлар эзләгәндә, татар теленең үз закончалыкларыннан, юнәлеш категорияләреннән һәм тезмә фигыльләрдән файдалану мөмкинлекләрен искә алганнар. Мәсәлән, вильнуть — болгап кую, селкеп кую; вилять — болгау, селтәү; сверкать — ялтырау, балку, җемелдәү, җем-җем итү; сверкнуть — балкып (җемелдәп) кую, җем-җем итеп алу һ. б. Бу һәр очракта да шулай була алмый, билгеле, чөнки сүз сөйләмгә кергәч, аның төрле мәгънә төсмерләре аерылып чыга.

Фразеологик әйтелмәләрне, тотрыклы сүз тезмәләрен биргәндә дә төзүчеләр мәгънә үзенчәлекләреннән чыгып эш итеп, сөйләү телендәге тел байлыгына мөрәҗәгать иткәннәр. Мәсәлән, продать за чечевичную похлебку — сукыр бер тиенгә сатып җибәрү; после дождичка в четверг — кызыл кар яугач; будь он неладен — каһәр суккыры; догоняй ветра в поле — тотарсың коерыгын; долг платежом красен — бәйрәм ашы каракаршы; ала белсәң, бирә дә бел. Рус сүзләренең мәгънәләрен ачудагы камиллек мөстәкыйль сүзләрдә генә түгел, ярдәмче сүзләр тәрҗемәсендә дә күзгә ташлана. Моны предлогларның һәм алкушымчаларның бирелешендә ачык күрергә мөмкин. Мәсәлән, 1971 елгы сүзлектә по бәйлегенең 12 мәгънәсе күрсәтелгән булса, яңасында 18 мәгънә бирелгән. По алкушымчасы элеккеге сүзлектә бөтенләй күренми, соңгысында исә 5 мәгънәсе күрсәтелә. Шушындый үзгәреш-үсешне башка предлоглар, сүз кисәкләре компонентлары мисалында да күрсәтеп була.

Русча-татарча сүзлекнең практик әһәмиятен һәм кыйммәтен күрсәтә торган тагын бер сыйфат — рус сүзләре янында грамматик информациянең бай булуы, ягъни фигыльләрнең башкарылуы һәм кулланылышы, рус приставкаларының татарчага тәрҗемә ителү ысуллары, ир һәм хатын-кыз, милләт вәкилләренең исемнәрен аерып бирү һәм рус сүзләрендәге басымның булуы. Барлык сүз төркемнәре дә грамматик билгеләр белән тамгаланган.

Сүзлектәге кайбер сүзләрнең тәрҗемәләре тулысынча бирелеп бетмәү фактлары да күзәтелә. Мәсәлән, длиннорукий — озын куллы» дип кенә бирелгән, ләкин ул күчерелмә мәгънәдә дә йөртелә һәм «карак, урлашучан кеше» турында да шулай дип әйтелә.

Аферист «аферачы, аферист» (афера белән шөгыльләнүче) дип бирелгән. Биредә шулай ук «алдакчы кеше, карак» дигән мәгънәләрен дә күрсәтергә кирәк иде.

Квартет муз. квартет 1. дүрт тавыш яки дүрт инструмент өчен язылган музыка әсәре 2. дүрт кешелек музыкантлар төркеме дип бирелә. Ләкин бу сүз хәзер музыкантларга гына кагылмый, төрле спорт ярышларында катнашучы 4 кешедән торган спортчылар командасы турында да «квартет» диләр (мәсәлән, чаңгычылар — эстафетада, велосипедчылар һ. б.).

Первенец «беренче бала, баш бала» дип күрсәтелгән. Бервакытта да «баш бала» димиләр, «Өлкән бала, олы бала, зур бала (зурысы, өлкәне) дип йөртәләр.

Самокат сүзе шул килеш, ягъни «самокат» дип кенә калдырылган. Дөрес, бу сүзнең шундый мәгънәсе дә бар, ләкин кайчандыр велосипедны да «самокат» диләр иде. Аннан соң Г. Тукайның «Исемдә калганнар»ында бу сүз карусель (кәмит) мәгънәсендә дә кулланылган.

Һичшиксез, болар гына яңа сүзлекнең фәнни кыйммәтен, аның практик әһәмиятен киметмиләр. Сүзлекнең киң катлау укучылар тарафыннан хупланып каршы алынуы әнә шул хакта сөйли.

**Фәрит МИҢНУЛЛИН**

# ӘХЛАКЫЙ ЭЗЛӘНҮЛӘР

1905 елгы революция җилләре белән әдәбиятка килгән Фатих Әмирхан татар халкының азатлык көрәше тарихында, культура һәм мәгариф үсешендә, милли сүз сәнгате, әдәби тәнкыйть һәм публицистика формалашу юлында онытылмаслык эз калдырды. Совет әдәбиятының бүген ирешкән уңышлары яктылыгында да Ф. Әмирхан кебек фидакарьләрнең эшчәнлеге яңадан-яңа сыйфатлар белән ачыла, өр-яңа ракурста балкый башлый.

Соңгы унбиш-егерме елда татар әдәбият белеме Ф. Әмирхан иҗатына даими игътибар биреп килә. М. Гайнуллин, Х. Хисмәтуллин, Й. Нигъмәтуллина, А. Сайганов, И. Нуруллин әдипнең иҗатын тикшерү һәм укучыга җиткерү юлында зур тырышлык куйдылар. Наил Вәлиев хезмәте[1] дә шушы өлкәдәге эшчәнлекнең лаеклы дәвамчылары барлыгын исбатлый. Шунысы әһәмиятле, автор Ф. Әмирхан иҗатына багышланган хезмәтләргә таянган хәлдә үз концепциясен булдыра, яңа аспектлар аша әдипнең иҗат үзенчәлеген ачуга ирешә. Авторның тикшеренүләре, башлыча, ике төп проблема яссылыгында бара: беренчесе: автор һәм герой мөнәсәбәте, икенчесе, герой һәм чор проблемасы, ягъни чорның аерым ситуацияләренә бәйләнештә геройларның «рухи сынау» узулары.

Әлеге концепция нигезендә Ф. Әмирханның иҗади үсеш юлын гына түгел, гомумән, әдәби традицияләрнең яңа шартлардагы үзенчәлекле дәвамлылыгын, әдәбияттагы уңай герой образының эволюциясен күзәтергә мөмкинлек туа.

Әдәбиятта яңа идея-эстетик позицияләргә күчү үткәнне бөтенләй инкарь итү исәбенә бармады. Ф. Әмирхан иҗаты моның ачык мисалы була ала. Аның әсәрләрендә мәгърифәтчеләрнең төп идеяләре — дини фанатизмга һәм кадимчелеккә каршы көрәш, рус һәм Европа культурасына йөз тоту, хатын-кыз ирекен яклау, мәгърифәткә дан җырлау, фән һәм техниканы үстерү һ. б. үзәккә куелганнар иде. Ф. Әмирхан иҗаты татар әдәбиятында мәгърифәтчелекнең прогрессив идеяләрен критик реализмга китереп ялгаучыларның берсе буларак аеруча зур әһәмияткә ия. Н. Вәлиев әдип иҗатындагы идея-художество чыганакларын иң элек әдәбиятыбызның үткәндәге традицияләрендә — К. Насыйри, Ш. Мәрҗаниләр күтәреп чыккан, М. Акъегет, З. Бигиев, Г. Ильясилар әдәби формада укучыга җиткерергә теләгән демократик идеяләрдә булуын нигезле исбат итә. Әсәрләрендә заманның иң үткен һәм актуаль проблемалары чагылыш алуына Ф. Әмирханның актив җәмәгать эшлеклесе булып, татар тормышының үзәгендә кайнавы да ярдәм иткән.

Ф. Әмирхан әдәбият-сәнгатьне алга җибәрү чараларын чынбарлыкның реаль картиналарын ачуда, көнбатыш, аеруча рус классик язучылары иҗатына, рус революцион-демократик тәнкыйтенә мөрәҗәгать итүдә күрә. Н. Вәлиев бу уңайдан Й. Нигъмәтуллина фикерен үстереп, Ф. Әмирхан иҗатына И. С. Тургенев тәэсире зур булуын күрсәтә. Чынлап та, XX гасырның унынчы елларында татар тормышы Россия XIX йөзнең икенче яртысында кичергән политик шартларга гаять охшаш булган этапка килеп керә: мәйданга яңа кешеләр, искелек тарафдарлары белән кискен көрәшкә күтәрелгән алдынгы вәкилләр чыга. Әлеге ситуацияне анализлау, аның асылына төшенү өчен Ф. Әмирханның XIX йөз күренекле язучысы, кеше психологиясенең остасы И. С. Тургенев йогынтысын кичерүе гаҗәп түгел. Искелек һәм яңалыкның бәрелеше, ягъни «аталар» һәм «балалар» проблемасы Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасында аеруча киң һәм тулы яңгыраш ала. Әсәрне анализлау Н. Вәлиевка «Ф. Әмирханның Тургенев традицияләре юнәлешендә иҗат итүе бәхәссез» дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Шулай ук күпмедер дәрәҗәдә, әдипнең әсәрләрендә Л. Н. Толстой, Ф. М. Достоевский, Н. Г. Помяловский иҗатындагы мотивлар белән аваздашлык булуы да әйтелә. Болардан тыш, «рус әдәбияты һәм Ф. Әмирхан» аспектында сүз алып барганда, икенче бер

[1] Валеев Н. В мире нравственных исканий. Казань, 1985, 120 б.

күренекле психолог Л. Н. Андреевка тукталу кулай булыр иде. Л. Андреевның капиталистик җәмгыятьтә шәхеснең трагедиясен, аның газаплы бәргәләнүләрен сурәтләгән иң яхшы әсәрләре Ф. Әмирхан игътибарыннан да читтә калмаган. Кара реакция чорында аптырап, югалып калган киләчәккә ышанычларын югалткан геройларның халәте, үз-үзләрен тотышлары Ф. Әмирхан мөрәҗәгать иткән зур темаларның берсе иде. Шул максаттан чыгып әдип, 1909 елда Л. Андреевның «Рассказ о семи повешенных» әсәрен («Асылган җиде кешеләр хикәясе» исеме белән) тәрҗемә итә. Сүз башында Ф. Әмирхан әсәргә аңлатма бирел, «...әдәбиятны кәеф-сафа өчен моталага итүчеләр[1] ул нәрсәләрне көтмәсеннәр», — дип искәртә һәм бу типтагы әсәрләрне «безнең хәзерге тормышыбызның нифаксыз[2] көзгеләре», — дип атый. Кырыс чынбарлык, киеренке, кискен мизгелләрдә кешеләрнең үз-үзләрен тотышы әдәбиятта актуаль бер темага әверелгән вакытта, көчле психологизм белән сугарылган тәрҗемә әсәрләр татар язучылары өчен мөһим тәҗрибә мәктәбе булдылар.

Хезмәтнең тагын бер тикшерену объекты — вак буржуаз интеллигенциянең ике арада чайкалуы темасы. Бу уңайдан автор төп игътибарны күчеш чорындагы геройларның әхлакый эзләнүләренә юнәлтә. Гомумән, социаль-экономик үзгәрешләргә мөнәсәбәттә татар интеллигенциясенең халәтен күзәтү Ф. Әмирхан иҗатында гына түгел, шул чор татар әдәбияты өчен иң актуаль һәм иң катлаулы проблема иде дисәк тә, һич хата булмас. Ф. Әмирханның яраткан һәм якыннан белеп, асылына төшенеп язган өлкәсе бар — ул да булса татар интеллигенциясе, аның тормышы һәм социаль үзгәрешләргә мөнәсәбәте. Беренче җитди сынаулар каршында ук калтырап төшкән интеллигентларның, вак җаннарын саклау ниятеннән революциядән ваз кичүгә барып җиткән элементларның битлекләрен йолкып, асылын ачу зарурлыгы әдәбиятта яңа тема — урталыкта чайкалучы ихтыярсыз типларны фаш итү темасын көн тәртибенә куйды.

Ф. Әмирхан җимерелгән иллюзияләр, тормышка ашмаган хыяллар фонында интеллигентның психологиясе, эш-хәрәкәте белән чын-чынлап кызыксына башлый. Бу җәһәттән, Н. Вәлиев Ф. Әмирхан талантының үзенчәлекле бер ягын ача: язучы татар әдәбиятында беренчеләрдән булып «артык кеше» тибын иҗат итә. Әлбәттә, әдәбиятчының «Кадерле минутлар» хикәясендәге Рәшад образын «артык кешеләр» рәтенә куюы белән килешмәскә мөмкин. Безнең уебызча, Рәшад, башлыча, тормышның кырыс яклары белән бәрелешкә кермәгән, хис-тойгылар дөньясында гына яшәүче лирик герой. Ул язучының ирекле, саф, матур мәхәббәтне яклау идеясенә иллюстрация булып кына бара. Рәшад — чынбарлыктан, карашлар, фикерләр бәрелеше хөкем сөргән реаль тормыштан читтәрәк торучы романтик образ. «Артык кеше» булу өчен, чынбарлык белән бәрелешкә кереп, сынауларны уза алмый җиңелгән герой булу кирәк. Ясә инде яшәп килгән тәртипләр белән көрәшергә көчең юк икән, оппозициядә булса да тору зарур. Ә менә «Картайдым» исемле хикәядәге Мостафа образында чынлап та «артык кешенең» типик чалымнары бирелә.

«Урталыкта» романында Ф. Әмирхан төп сурәтләү объектын искелектән аерылган, ә яңа тормыш өчен көрәшүчеләр сафына баса алмый урталыкта калган төркемгә — күләгәдә, төссез мохиттә яшәүче интеллигенция катлавына юнәлтә. Әдип шул «дөнья»ның типик вәкиле булган Хәсән Арслановны алгы планга чыгарып, буржуаз җәмгыятьнең тирәнгә яшерелгән җинаятен — кешене рухи гарипләндерүен фаш итә. Әмма бу җәһәттән, Н. Вәлиевнең Хәсәнне романның уңай герое дип билгеләве белән һич тә килешәсе килми (шунысы да бар, әдәбиятчы бу урында нигәдер «яңа кеше» белән «артык кеше» төшенчәсен бер үк мәгънәдә куллана. Безнең карашыбызча, «яңа кеше» ул, искелек тарафдарлары белән килешмәүчән каршылыкка кергән герой, прогрессив идеяләрне кайнар яклаган герой. Ә Мостафа, яки Арсланов тибындагы «артык кеше» исә — «яңа кешеләргә» иярел тә, беренче сынаулар алдында ук идея «банкротлыгына» дучар булган кыйблясыз геройлар алар). Хикәяләү дәвамында Хәсән Арсланов ихтыярсыз, иренчәк, коры эч пошулар белән үз җанын кыйнаучы, бәхәсләшергә сәләтсез, «анысы алай инде...» принцибы буенча яшәүче тип булярак ачыла. Ф. Әмирханның мондый геройларны сурәтләү объекты итеп алуы очраклы түгел иде. Яңа революцион күтәрелеш чорында, авыр репрессияләрдән соң көч җыйнау дәверендә кемнең кем икәнлеген ачыклау, алгы көрәшләрдә нинди позиция сайлаячагын билгеләү зарур. Урталыкта калып, ике як тарафыннан да читкә тибәрелгән «артык типларның» тарихи урыннарын ачыклау шул мәсьәләнең мөһим бер тармагы иде.

Арсланов алдында ике юл ачыла: яки үзендә көч һәм ныклык табып, яңа идеаллар өчен көрәшкә кушылу, яисә реакция ягына авышу. Н. Вәлиев Арслановның кайсы юл белән китәчәген фараз итми, мәсьәләне ачык калдыра. Әлбәттә, беренче версиянең булуы мөмкин түгел. Аумакай, принципсыз типның нык ихтыярлы революционерга әверелүен көтү катгый инкарь

---

[1] Моталага итүчеләр — укучылар
[2] Нифаксыз — алдаусыз

итела. Революцион көчләр нығып, кем-кемне мәсьәләсе янә көн тәртибенә басканнан соң бөтен барлыгыңны көрәшкә багышлау, хәтта гомереңне дә кызганмау таләп ителгән хәлиткеч моментта Арслановлар, вак җаннарын саклар өчен, теләсә нинди түбәнлекләргә һәм хыянәткә барырга әзер булачаклар. Революциянең күтәрелеш этабында хәрәкәт итеп, көрәшче, хәтта җитәкче-оештыручы ролендә йөргәннәр дә кырыс сынау чорында югалып, куркып калырга мөмкиннәр. Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» (1914) романында шундый активистлардан Баязид карый ахырда провокаторга әверелә, Нигъмәт казый шөһрәт сөюче эксплуататор дин әһеле булып китә һ. б. Бу юнәлештә күзәткәндә әдәбиятчының «рухи сынау» ситуациясе «социаль сынау» ситуациясеннән аергысыз» дигән фикере бөтен тулылыгы белән ачылып китә.

Ф. Әмирхан талантының характерлы тагын бер ягы — аның көчле сатира остасы булуы. «Фәтхулла хәзрәт» повесте язучының үз иҗатында гына түгел, бәлки бөтен татар әдәбиятындагы иң яхшы сатирик әсәрләрнең берсе булып тора. Шунысы куанычлы: Н. Вәлиев повестька анализ ясаганда, әдәбият белемендә инде әйтелгән фикерләр белән генә канәгатьләнеп калмый. Әдәбиятчыларның бердәм билгеләвенчә, «Фәтхулла хәзрәт» повестенда Ф. Әмирхан, татар җәмгыятендә феодализм калдыкларын фаш итеп, искелеккә зур удар ясады. Н. Вәлиев үзенең тикшеренүләрендә тагын да арырак китә: «автор һәм герой» проблемасы аша күзәтеп, ул язучының үз героена мөнәсәбәтен өйрәнә. Бу җәһәттән, Н. Вәлиев Ф. Әмирханның искелектән көлүе усал да, шул ук вакытта күңелле дә көлү булмыйча, «күз яшьләре үтәли көлү» икәнлеген билгели. Әдәбиятчы Фәтхулла хәзрәтнең дини фанатик, надан, әхлаксыз тип икәнлеген әйтү белән бергә, аның кеше буларак кызганыч икәнлеген дә ача. Дөрестән дә, иске тормыш сакчысы Фәтхулла хәзрәт шул тирәлекнең кызганыч корбаны да иде. Бу урында Фәтхулла хәзрәтне язучының «Габделбасыйр гыйшкы» исемле хикәясендәге Габделбасыйр образы белән бәйләнештә карау уңышлы булыр иде. Габделбасыйр, иң иске мәдрәсәләрнең берсендә «укып» ятучы шәкерт, үзе бер тапкыр да күрмәгән, белмәгән кызга гыйшык тота. Хыялдагы очрашулар, сөйләшүләр Габделбасыйрның хәлен көлке дә, аяныч та итеп күрсәтәләр. Буш куык хыяллар белән генә яшәүгә дучар ителгән шәкертнең кызганыч бер җан иясе икәнлеген дә шәрехли язучы. Габделбасыйр да — иске мәдрәсә корбаны, шәхесе сындырылган, акылы томаланган рухи гарип адәмнәрнең берсе. Ул да котылгысыз рәвештә Фәтхулла хәзрәткә әйләнеп бара. Менә ни өчен дә Ф. Әмирхан андый типларның мескенлеген, чарасызлыгын сатира уты астына алса да, аларны кеше буларак кызгана да. Язучыны борчый, ачындыра торган, аның игътибарын җәлеп итәргә мәҗбүр иткән зур темаларның янә берсе иде бу. Шуңа күрә язучының сатирасы да «күз яшьләре аша» көлү, кешелекле көлү булып чыга.

Шул рәвешчә, Н. Вәлиев Ф. Әмирхан поэтикасының яңа сыйфатларын ачып, укучы игътибарын язучы иҗатындагы күләгәдәрәк кала килгән якларга юнәлтә. Ул Әмирхан геройларының рухи тормышына үтеп кереп, кызыклы фактларны ача, образлар дөньясының үзенчәлеген күрсәтә.

**Фәрит БӘШИРОВ.**

# ВАКЫТЛАР ЧИКСЕЗ, ГОМЕРЛӘР КЫСКА...

Гадәттә, теге яки бу әсәр турында сүз чыкса, тәнкыйтьчеләр язучы шәхесен, аның биографиясен, холык-фигылен күз уңында тотып эш итәләр. Мондый күпьяклы фикерләү, кагыйдә буларак, үзен аклый да. Чөнки язучының иҗат биографиясенә тирәнрәк үтеп керү юллары ачыла. Әмма мин бу мөмкинлекләрдән мәхрүм: Альберт Сафин — күргән-белгән кешем түгел. Һәм аның иҗаты турында да фәкать «Күз карашы»[1] китабына кергән әсәрләреннән чыгып кына фикер йөртәм.

Вакытлар чиксез, гомерләр кыска, хәтта бик кыска. Туу һәм үлем арасындагы вакыт—гомер кеше гомере дип атала да инде. Шул араны экспресс тизлеге белән үтеп китәбез дә мәңгелеккә кереп югалабыз...

Мин юкка гына фәлсәфәгә бирелмим, моңа мине А. Сафинның «Зәңгәр ут яктысында» исемле повесте этәрде. Зур тизлектә үткән гомернең язы булган кебек көзе дә бар. Ә әсәрдә гомер язында башланган вакыйга безне җәйләр аша көзгә алып бара. Мин — шул вакыйганың шаһиты. Хикәяче дә минем янда утыра шикелле. Ә вакыйга безнең күз алдында үтеп тора, тәрәзә артындагы дөньяда бара. Зәңгәр ут яктысы аша шунда багабыз.

Гадәттә, беренче зат «мин» исеменнән хикәяләүгә күнеккәнбез. А. Сафин исә, бу стереотип фикерләүне инкарь итеп, әсәрне автор хикәяләвенә кора һәм укучыга ышанып, үз итеп «син» дип дәшә. Шушы урын-

[1] Сафин Альберт. Күз карашы. Казан, 1986.

да игътибарны бик мөһим бер детальгә юнәлтеп үтик: автор вакыйганы сөйләп бара, ә син тыңлыйсың. Шуңа карамастан, хикәяләүче әсәрдәге герой буларак кабул ителә. Аны һич кенә дә язучы Альберт Сафин шәхесе белән бутамыйсың. Әсәрдәге автор — әсәрнең герое, аның хикәяләвен тыңлап барганда, үзеңне дә шул әсәр герое итеп тоясың. Бу — безнең классик әдәбиятта булса да, яшьләр иҗатында сирәк күренеш. Хикәяләүнең мондый алымын куллану повестьның формасына йогынты ясаган һәм аны шактый үзенчәлекле иткән. Әйдәгез, игътибарны шул үзенчәлекләргә борыйк.

А. Сафин, повесть исемен язганда, җәяләр эчендә «төн хикәяте» дип тә куя. Бу юкка түгел, ә әсәрнең кысасын билгеләү өчен эшләнә. Дөресрәге, укучыны аз-маз гына булса да хикәяләү алымына төшендерү максаты куела. Повестьның структурасы: «Кереш», «Беренче төн», «Көн», «Икенче төн», «Сәхрәгә чыгар идем», «Шатлыклы иртә», «Көн» һәм «Өченче төн» эзлеклелегендә бирелә. Башламы да, ахыры да кышкы мизгелне тасвирлаудан гыйбарәт. Вакыйга: «Ике тәүлек буе котырынган буран, үзеннән соң өй, лапас тирәләрендә, капка яннарында, тыкрыкларда биек кар көртләре белән бергә авыл өстендә сәер тынлык калдырып, ниһаять китеп барды.

Кичке эңгердә куера барган бу тынлык синең өчен ят һәм яңа, ирексездән күңелләрдә ялгызлык хисе уятыр дәрәҗәдә олы һәм тирән булып тоелды»,— дип башлана. Һәм болай тәгәлләнә: «Шул ук көнне китеп бардың син.

Автобус тәрәзәсе артындагы иксез-чиксез басуларга карап бара торгач, яңадан күзләреңне йокы басты: яңадан онытылдың. Уянып киткәндә, автобус һаман ялан буйлап бара иде. Әллә нидән көн караңгылана башлаган. Кичке эңгергә төренгән ак кырлар, еракта карасу урман сызыгы һәм нindидер авыл сүрән тынлыкта оеп калган сыман күренә. Нигәдер, сиңа автобус кире борылган да, урау юллар белән үзеңне яңадан авылыңа алып кайтадыр сыман тоелды... Тотынып, эленеп калыр нәрсә таба алмый, буш кырлар буйлап җәяүле буран йөгерә башлады».

Күренә ки, вакыйга кышкы буранлы, шыксыз бер төндә тәмамлана. Героебыз, Син, хәтта үзенең барыр кыйбласын да югалткан. Хәзер без Синнең язмышын беләбез һәм тормышта ориентиры югалуын, аның фаҗигасен аңлыйбыз. Шушы җәһәттән автор белән килешәбез. Бусы әсәрнең ахырында. Ә менә башламга килгәндә, бәлки, икенчерәк алым-мизгелне сайларга кирәк булгандыр? Вакыйга балачак хатирәләреннән башлана икән, ник гомер языннан кереп китмәскә? Май ае кебек якты, җылы башлана бит гомер язы — балачак. Синнең дә шундый нарасый, чишмә кебек саф, һәм керсез чагы булгандыр. Кеше гөнаһлы булып тумый лабаса. Әнә шул мизгелдән сәфәр чыгып, караңгы кышкы төнгә карый барсак, без геройның фаҗигасен тулырак аңлар идек дип уйлыйм. Гомумән, «Күз карашы»ндагы кереш аерым бер бүлек кебегрәк бирелгән һәм «Беренче төн» бүлеге белән логик бәйләнешне югалта төшә. Әсәр үзәге таралудан бу очракта хикәяләү алымының аеруча уңышлы булуы коткара.

Сабыйлык еллары тиз үтә, күз ачып йомган ара гына. Альберт Сафин кеше гомерен, төннәргә бүлеп, төнге төш-хатирә итеп ала икән — балачакны җәй башы — июнь төне фонында ачса, отар гына иде. Елның бу фасылында төн кыска икән — әсәрдәге «Беренче төн» дә чагыштырмача кыскарак булыр иде. Фикер үсеше шулай таләп итә. «Икенче төн» — гомер уртасы. Язучы бу очракта Синнең бар булмышын ачып бирергә омтыла. Шул максаттан чыгып, ул «Сәхрәгә чыгар идем», «Шатлыклы иртә», «Көн» бүлекләрен бер-бер артлы җыеп бирә. Ә аннары — кыска гына «Өченче төн». Бу юлы А. Сафин логикага буйсынган: гомер әле дәвам итә, төп героебыз Син әле яшь, димәк, өченче төн, төш-хатирә дәвам итә, язмышлар әле языла.

Укучылар игътибарын тагын бер үзенчәлеккә, минем карашка бик мөһим саналган вакыйгалар бирелешенә юнәлтер идем. Соңгы вакытта язучыларыбыз еш кына әсәрдәге вакыйгалар үсешен анык сюжетка кормый гына күрсәтәләр. Ягъни герой тормышыннан өзек-өзек моментлар гына алына һәм алар үзара логик бәйләнештә тәкъдим ителә. Мисал өчен күренекле язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» әсәрен алу да җитә. М. Мәһдиев бу әсәренең жанрын билгеләгәндә, повесть дип куйган. Мин аны эссе дип атар идем. Көнбатыш әдәбиятында эссе, жанр буларак, күләмле әсәрләр йөзен дә билгели — яки бездәге роман жанрына тәңгәл килә. Ә безнең татар әдәбиятында эссе повестька бәрабәр булып туды. «Күз карашы» да жанры ягыннан «Торналар төшкән җирдә» әсәре белән охшаш.

Без үскәндә, сугыштан соңгы елларда, бабайлар чабата үрә иде. Берәүләр аны җиде буй юкә тасмасыннан, икенче берәүләр — тугыздан, өченчеләр — уникедән үрер иде. Эш ничә тасмадан үрүдәмени — чабатасы булу мөһим диярсез. Юк шул. Бар хикмәт тә чабатаны ничә тасмадан үрүгә бәйле иде. Уникедән үрелгәне матур, чөнки аның тасмалары тар, нык була. Бу чабаталарны кызлар кичке уенга кияләр иде. Укучы: чабата белән әдәби әсәр арасында нинди охшашлык?— дип сорар. Әсәрләрнең дә матурлыгы андагы вакыйгаларның оста үрелүенә бәйле бит.

А. Сафин үзенчәлекле форма табып (чабатаның да калыбы була), вакыйгаларны

шактый уңышлы үрә алган. Нәтиҗәдә без әсәрнең төп рухын, авторның хикәяләү интонациясен тоябыз. Ә нәрсә соң ул төп рух? А. Сафинның хикәяләү интонациясендә нинди сер бар?

Төп рух — әсәрнең идея эчтәлеге, авторның әйтергә теләгән фикере. Шуны да искә алып үтик: әсәрнең идея эчтәлеге вакыйгаларны хикәяләү, сөйләп бирү эчтәлеге белән тәңгәл килми. Болар — икесе ике нәрсә.

Повестьның төп рухына, авторның иң изге фикеренә төшенергә ярдәм иткән бер өзеккә игътибар итик:

«Адәм баласы шаулы эшләр белән гөрләгән чорлардан көнләшә, балачагын сагынган күк, үткәннәрен сагына.

Чынбарлыкка кайткач исә, бүгенгесен таный алмый тора. Үзе шикелле чираттарда торучы, дефицит эзләүче, корсагы шыплап тулганчы ашарга яратучы, ярты гомерен диванда йоклап үткәрүче ишләрен күрә дә гаҗәпкә кала.

Кемнәр соң алар? Нигә болар? Кемнәргә болар?

Безнең заман сагынулар заманымыни? Рухыбыз җуелган, кыйблабыз югалган, уебыз качкан. Биргәнне ашыйбыз, күрсәткәнне карыйбыз, ишеткәнне тыңлыйбыз. Җаныбыз тыныч. Тормышыбыз әйбәт. Сүнәбез...

Күңелеңнән өзелеп төшкән әрнү йөрәгеңә килеп кадалды.

Кулларың белән битеңне капладың.

Юк, болай түгел ич инде! Син тагын үзеңнең мөмкинлегеңне аңлый башладың.

Белеп торасың бит: сагынулар чоры түгел безнең заман. Юк. Син уйлаганча, астыртыннар, хәйләкәрләр, мал өчен җанын фида кылырга әзер булган яман бәндәләр заманы да түгел бу. Кайчан да булган алар — яманнар. Тик аларны кем хәтерли? Кем белә? Ә бит, дөресен генә әйткәндә, синең шикелле дәшмәсләр аркасында ишәяләр түгелме соң алар? Хәер, син үзең дә яман кеше бугай әле. Акланма. Алдашканың юк, урлаганың юк, имеш. Ә берәр кешегә игелек кылганың булдымы соң синең? Адашканга юл күрсәттеңме бәрәр тапкыр? Җылы сүз, киңәш белән кемнең күңелен күтәрдең? Кемне өзелеп яраттың, кем өчен яшең түктең син? Әйе, әйе. Бары үзең өчен генә. Газаплан, ныгырак газаплан...»

Кыскасы, фәнни-техник революция заманында яшәгән кеше анасын, туган авылын, халкының җыр-моңын онытса, үзенүзе югалта. Шуңа күрә аның эчке табигате дә җимерелә дигән фикер алга сөрелә әсәрдә. «Кеше шәхес буларак таркала, аның «мин»е югала. Әнә, фаҗига бусага артында гына тора»,— ди автор. Бусы — әсәрнең идея эчтәлеге, төп рухы. Ә вакыйгалар эчтәлеге: ата-анасының җылы кочагында үскән Син шәһәргә китә, эшкә урнаша, заманча квартирада заманча итеп яши башлый. «Заманча» яшәве нәтиҗәсендә хатыны белән аерыла. Онытылып карамакчы була. Шәраб алып кайта да телевизор карый. Телевизор карый да, шәраб эчә. Күпмедер мизгелгә шәраб пары һәм җиңел музыка героебызны татлы халәткә күмә, якты моңсу хыялларга күтәрә. Бар да онытыла. Тик үз-үзен генә оныта алмый. Киресенчә, ялгыз һәм читкә тибелгән итеп тоя. Мескенлектән һәм көчсезлектән үз кабыгына кереп бикләнә, ак дөньяга чыгуга бернинди өмет юк. Һәм ул үз-үзеннән курка башлый. Шәхес деградация кичерә. Уелып төшеп уйланырлык урын бар монда. Чөнки һәр шәхеснең югалту — безнең өчен фаҗига. Бәхәссез, «Күз карашы»— замандашларыбызның рухи сафлыгы өчен борчылып язылган әсәр. Һәм шул борчылу хикәяләү интонациясенә дә сеңгән: автор эчке бер сагыш белән үткәннәргә караш ташлый. Татар халкының җан өзгеч җыры «Уел» да әсәргә юкка килеп кермәгән: «Эчемдә генә минем утлар яна, ник җилкенә икән бу йөрәк».

Җыентыкка кергән «Хыял», «Исәнме, әни!», «Уел», «Китү», «Юлда» һәм башка хикәяләр дә кызыклы. Бу әсәрләрендә А. Сафин художестволы детальләр аша образларны төгәл бирә алган. Аларның эчке дөньясын яктыртып җибәргән. Шул ялтырап киткән бер мизгелдә геройларның холык-фигылен күреп калабыз. Мәсәлән, «Исәнме, әни!» хикәясен автор: «Карчык авыр итеп көрсенеп куйды, нәрсә эшләгәнен үзе дә белештермәстән, яңадан мич капкачын ачты да, суынмаганнармы икән дип, пәрәмәчләрен карады»,— дип тәмамлый. Уйлап баксаң, монда сүз һич кенә дә мич һәм андагы пәрәмәчләр хакында бармый. Мәгънә бик тирәндә ята. Зөләйха карчык мичне түгел, ә йөрәген ачып күрсәтә кебек. Ул пәрәмәчләр түгел, ә хисләр, иң изге хисләр суынырлык, дип курка шикелле. Улы Нәгыймгә килсәк, аның бәгырендә анасына карата бернинди дә җылы калмаган, күптән суынган. Җанны тетрәндерерлек факт. Бу — атом бомбасы кебек куркыныч нәрсә! Аннан да куркынычрак нәрсә бар икән әле: «Әгәр дә аналарның балаларына карата булган хисләре суынса, без нишләрбез?» Язучы менә нинди олы сорау бирә укучысына. Аналарның хәтерен калдырмыйк, күңелләре көр булсын дисәк, туган йортка, туган нигезгә эзне суытмыйк, ешрак кайтыйк. Ә анда торып калсак, газиз җиребез рәхмәтле генә булыр.

Укучы Альберт Сафин иҗаты белән якыннан танышса, күңеле баер.

Мин бирелә китаптагы берничә әсәрне генә күздән кичердем, чөнки укучыны яңадан-яңа ачышлардан мәхрүм итәсем килмәде — ә андый ачышлар бу җыентыкта җитәрлек.

**Радик НУРЕТДИНОВ.**

# ЯШӘҮ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

Бүгенге дөньяның иң зур парадоксы: кеше һаман көчәя, гайрәтләнә бара, ә Җир гүя торган саен кечерәя, көчсезләнә. Хәер, парадокс та түгел, шул бер үк процессның ике ягы бит бу: кеше зурайганга, Җир бәләкәйрәк булып күренә бит. Элек иксез-чиксез тоелган океан-дәрьялар, кара урманнар, чүлләр — барысы да, бүгенге куәт, бүгенге тизлекләр белән чагыштырганда, югалып кала кебек. Һәммәсе кеше кулы җитәрлек һәм... кеше кулыннан үтәрлек. Чөнки кеше кулында дөньяга ямь бирү, Җирне тагын да матуррак итү өчен барлыкка китерелгән нәрсәләр генә түгел. Кеше кулында һәммә җан иясен минут эчендә юк итәрлек меңләгән утлы өермәләр дә бар. Тимер капчыкларга шыплап тутырылган килеш, алар үз сәгатьләрен, дөньяны тоташ ут итәр көннәрен көтеп яталар.

*Табылмасмы, димсең, кызыгучы*
*Капчык бавын чишеп карарга?..*

«Өермәләр» дигән шигырендә Рәфикъ Юнысов әнә шундый сорау куя. Һәркайсыбызның җан тынычлыгын алып торган сорау, балаларыбызга күз салган саен искә төшә торган уй.

Рәфикъ яңа җыентыгына горур исем куйган: «Җирдә яшим»[1]. Аның лирик герое Җирдә яшәве белән горурланып кына калмый, шуның белән үзенә олы миссия йөкләнгән булуын да тирән тоя, азга гына да исеннән чыгармый. Аңа планета язмышы, кешелек язмышы өчен глобаль борчылу, хәвефләнү хас. Хәер, «лирик герой» дигән булып, сүз бизәкләп торуның кирәге дә юктыр бу очракта, шагыйрь үз исеменнән, XX гасыр ахырында гомер итүче, Җирдә яшәүче ир-ат, Рәфикъ Юнысов исеменнән сөйли.

Дөрес, бу тема яңалык түгел, гомумән хәзерге поэзиядә дә, аерым алганда татар шигъриятендә дә ул киң мәйдан яулады, үзәк урыннарның берсен алды. Р. Юнысов та мөрәҗәгать итә:

*Үзе аучы, үзе аккош —*
*Үз-үзенә мылтык төбәп,*
*Басып тора кешелек!*

Гади генә сүзләре белән шагыйрь киеренкелекнең соң дәрәҗәдә кискенләшүен һәркемгә барып җитәрлек итеп ярып сала. Шигырьләренең исемнәренә игътибар итик: «Ялвару», «Куркам», «Сөйләшик әле ирләрчә!», «Саклагыз!», «Тормыш яна Җирдә»... Алар күп нәрсә сөйли.

Нәрсәдән курка, нәрсә хакында ялвара соң автор?

*Кызган, зинһар, кагылма!*
*Кеше, тимә кешегә!*
дип инәлә ул, чөнки:
*Калкансыз яши кеше,*
*Ак күлмәк киеп кенә.*
*Тәнендә тормыш уты —*
*Шәм уты кебек кенә.*

Куркуы да шәхсән үзе өчен түгел: «Куркам, Җирем, синең өчен!» Чөнки «амбразуралар киңәя... инде миллиард күкрәкнең дә җитмәве бар капларга!»

Нигә кешеләрнең күңелендә гел изге уй гына түгел, ни өчен кешеләр бер-берсенә дуслык кулы гына сузмый? Ни өчен:

*Килеп тора хәбәр: бер көн — шатлык,*
*Икенче көн кайгы иленнән?*

Ни өчен «әкиятләрдән укып белгән калаларда — көл һәм төтен»? Ни өчен әле безгә «ике меңенче елдан да бүгенгегә карый алсак иде» дип ярым өмет белән теләк теләргә кала? Сораулар, сораулар...

Ә бит Җирдә тыныч яшәү мөмкин. Бер шигырендә автор моны тәкрарлап әйтә:

*Кешеләр дәшә кешеләргә,*
*Илләр илгә дәшә:*
*«Мөмкин ахры Җирдә*
*Тыныч яшәү,*
*Мәңге тыныч яшәү!»*

Ләкин моның өчен эш кирәк, ныклык күрсәтү кирәк. Синең күзгә карап, җиһан бөек эшләр көткәндә, тынычлыкка болай гына өметләнеп, кул кушырып утыру акланмый, гафу ителә алмый. Һәм шигырьләрдә безгә янап торган зур дәһшәт турында кисәтү көрәш зарурлыгын раслау белән бергә үрелеп бара. Аларның берсе «Усал бул, яхшылык» дип аталу тикмәгә генә түгел. Шагыйрь яхшылыкны кыю да, усал да, уяу да булырга чакыра. Шунсыз булмый, чөнки яхшылык әдәп йөзеннән калдырган форпостны яманнар ала, чөнки начарлык тик яхшылык исеменнән генә сөйли, аның имзасын куя, чөнки яхшылыкның йомшаклыгы яманга ачкычлар суза...

Шагыйрь зур масштаблар, ераклыклар белән эш итәргә ярата. Бу җәһәттән аның «Галактикадашларга» дигән шигыре фикер куәте белән аерылып тора. Чыннан да, төпсез, иге-чиге күренмәгән Галәм каршында Кояш системабыз, хәтта галактикабыз да бик кечерәеп кала, кысыла, андагы җан ияләре бер-берсенә якыная.

*Авылдашлар кебек бит без*
*Чиксез Галәм каршында!..* —

дип мөрәҗәгать итә шагыйрь. Бу шигырь шул ук циклга караган «Яктаплар» белән авазлаш. Тик соңгысы Җиргә якынрак, бу юлы пространство күз карашы колачларлык дәрәҗәдә тарая, конкретлаша. Кос-

[1] Рәфикъ Юнысов. Җирдә яшим. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1985.

мик тузаннарны туздырып, атларыбыз Галәм буйлап чапканда, берәр якта очраячак Җир ететен, гәрчә ул Африкадан, Америкадан булса да, якын күрше, якын кеше итеп күрәчәкбез ләбаса. Шулай икән, Җирне бүлешү, бер-береңне бетерү өчен корал туплау бөтенләй аңлаешсыз, гайре табигый бер эш булып чыга түгелме? Автор бу фикерне чәйнәп каптырмый, әмма «Ә мин үзем Җирдә яшим — Кояш системасында» дигән баш астында бирелгән «космик цикл»га кергән шигырьләрен укыгач, үзеңнән-үзең шундый уйга киләсең, бүгенге көннең, чынбарлыкның чәбәләнгән төеннәре турында ныклабрак уйлыйсың, аларны чишү өчен җаваплылыгыңны аныграк тоясың.

*Әсәрләнеп, көтеп, моңаеп*
*Басып торам Галәм каршында,*
*Бәрәңгесез бакча башында.*

Җир һәм кеше. Шушы ике олы образ бөтен китап буенча бара. Зәңгәр планетасы шагыйрьгә бер күк җисеме булган өчен генә түгел, Кешесе белән якын, газиз. Тере дөньяның, эволюциянең иң зур казанышы булган Кешегә шагыйрь лаеклы эпитетлар эзли:

*Кеше бит ул. Җанлы моң!*
*Җир миллиард ел эзләгән*
*Аның һәрбер чалымын.*

Менә шундый ул Кеше. Ә аның яшәве? Шундый гали затның яшәве дә гади көн итү генә булырга тиеш түгел.

*Яшәү — бары яну:*
*Вакыт — бездә,*
*Без — вакытта тиеш яныргa!*

Кешене... кешедән сакларга кирәк. Бер мизгелдә суны, күкне, хәтта Кояшны югалттырырдай үлем коралыннан гына түгел, көндәлек тормышта да. Көндәлек тормышыбызда да шартлаулар булып тора, җаныңны алмаса да, каныңа тоз сала, күңелеңне җәрәхәтли. Исеме үк «Шартлау» дип куелган шигырь моның тетрәндерерлек мисалы: Язгы матур көн. Лимонга чират торалар. Карт фронтовик килеп таныклыгын күрсәтә һәм алга үтә. Менә шунда:

*Мина кебек ачы чиелдап*
*Яңгырады тавыш:*
*— Кертмәскә!*
*Күп йөриләр алар! Бетмәсләр!..*

Очрап тора торган ситуация. Кайсыбыз гына күрмәгән, күрмәмешкә салышмаган! Ә бит күз алдыбызда җинаять эшләнә. Ил өстенә яу килгәндә, «соңгы киртә булып торып баскан» солдатка нахак сүзләр ташлана:

*— Сугышканнар, имеш! Исән-саулар!*
*Сугышканы аның кайтмады!..*

Алдыбызда — дошман. Моны дошман гына әйтә ала. «Әнә шундыйлар бит җан саттылар тамак хакына. Исән икән алар, яши икән, яла булып илем, халкыма!» Менә әлеге дошман тагын агулы ук кебек яман сүзе белән җәрәхәтли. Ветеранны гына түгел, башкаларны да. Шагыйрь моның өчен үзен дә гаепле хис итә. Бу тойгы ирексездән укучыларга да күчә. Гүя син дә моңа шаһит булгансың, гүя син дә гаепле. Үз-үзеңә, әйләнә-тирә дөньяга ничектер кырысрак, таләпчәнрәк карый башлыйсың. Әдәби әсәрнең көче дә шундадыр.

Хәзерге поэзиядә киң ассоциациялелек өстенлек итә. Ул шундый киң, хәтта кайвакыт очына да чыгып булмый. Р. Юнысов шигырьләре икенчерәк, ул киң ассоциациялелек белән мавыкмый, фикерен кистереп, өзеп әйтә. Нәрсә укыдым соң әле, моны ничек аңларга дип баш ватып торасы юк. Дөрес, «Автоинспекторга», «Акчарлак» кебек бигүк барып җитми торган шигырьләр дә очрады.

Мәсәлән, «Акчарлак» шигыре алтышар юллы ике строфадан тора. Болай караганда икесе дә матур гына, мәгънәсе дә ачык, образлылык та бар. Тик шагыйрь үзе аларның икесен бергә ничек бәйли торгандыр, һич аңлап булмый. Беренче строфада хатын-кыз өчен «ят аллаларга табыну, чит таборларга тагылу» кызык икәнлеге турында сүз бара. Ә икенче строфада — көчсез җилдавылны яратучы акчарлак. Бүтәннәргә ничектер,— миңа калса, бередә мәгънәви бөтенлек юк. Һәрхәлдә кат-кат укып, уйланып та, күрмәдем мин аны.

«Оча вакыт әниләре», «Син» белән «мин» кебек шигырьләрдә исә Рәфикъка хас булмаганча катлауландырып язу сизелә. Мондый очракларда шигырьнең табигый агышы бозыла, образларның мәгънәсенә төшенергә омтылып, шигырь укуыңны онытып җибәрәсең. Шигырь икән — инде ул шигырь булсын, эстетик ләззәт тә бирсен, күңелеңне дә сафландырсын! Тырышып чәйнәрлек түгел, суырып йотарлык булсын!

Р. Юнысов поэзиясе — фикерле поэзия, аның көче шунда; тик менә шушы көчле як, нормаль укучының теше үтәр дәрәҗәдән узып, шигырьнең җегәрен югалтмасын, диясе килә.

Кәефне кырган тагын бер кечкенә деталь. Шигърият өчен образлы тел — иң мөһим нәрсә, узган гасырдагы бер остабыз әйткәнчә, сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән. Шулай да образлылыкның «кояш имүгә» кадәр барып җитүе, кемгә ничектер, миңа бик ошап бетми. Җыентыкка ул ике урында очрады: «Кояш имә әнә бөреләр!..» («Тормыш яна җирдә») һәм «Һәр яфрагы кояш имә» («Бара имән»). Сүз дә юк — кыю, оригиналь образ, тик шулай да кояшны имезәсе килми, егетләр! Күктә, кул җитмәс биеклектә торсын инде ул, шуннан торып илһам бирсен.

Шигырьләрне укыганда, бер нәрсәгә игътибар итәсең: аларда өндәү билгеләре күп икән. Өндәүсезләре берән-сәрән генә. Ләкин ул өндәүләр берсе дә «ура» сүзе

янында түгел. Чөнки шигырьләрдә аның исе дә юк. Өндәүләр дә — шул ук борчылу, хәвефләнү, уяулыкка чакыру тамгалары.

Р. Юнысовның беренче җыентыгында матурлыктан ләззәтләнү, мәхәббәт шигырьләренә киңрәк мәйдан бирелгән иде. Бу юлы исә искәртү, кисәтү, чакыру, өндәү мотивлары өстенлек итә. Шагыйрь бүгенге турында ныграк уйлана, кешелек алдындагы иң олы проблеманы үзе кылуга үзеннән дә өлеш кертергә тырыша икән, моны аның иҗади үсеше, шигъриятенең җитдиләнүе дип бәяләргә кирәк.

**Ирек БӘДРЕТДИНОВ.**

# ХЫЯЛ АТ КАНАТЫНДА...

Кеше шулай инде: һәр иске елны тарихка озатканда, үзенең нәрсәләр кылганын хәтереннән үткәрә. Табышлары өчен ихластан шатлана, ялгышлары өчен үкенә, ачыргалана. Алга уңышларын ишәйтү бурычын билгели. Бер үк вакытта: «Яңа ел ничек булыр, нинди шатлыклар, нинди бәхетләр алып килер?»— дигән уй да кичерә.

Госман Садәнең 1985 елда Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган беренче китабын мин дә: «Шагыйрьнең «Мәхәббәт елы»[1] нинди икән? Шигъриятендә заман рухы, чор сулышы сизеләме? Табышлары күңелгә хуш киләме?»— дигән сораулар белән кулга алдым.

Китап дүрт бүлектән тора. Беренче бүлекне тулысы белән табигать лирикасы били. Шагыйрь анда гомер һәм аның кадере, яшәү һәм аның мәгънәсе турындагы уйлануларына табигать күренешләре аша килә. Без анда үткән белән хәзергене тоташтыручы вакыт нәкъ кояшның үзе кебек булган алтын бөртек, җылы сөт исенә чумган, күге зәңгәр, ае бөтен авыл киче һ. б. шигъри күренешләр белән очрашабыз.

Дөрес, бу күренешләр аерым гына торганда, гадәти булып күренәләр. Әмма алар бер-берсен тулыландыргач, баеткач — барысы бергә табигать һәм шигърият гармониясен хасил итәләр, поэтик бөтен булып оешалар.

Тагын шуны күрмичә калып булмый: кояшлы җылы яңгырдан соң зәңгәр күктә мәһабәт салават күпере калыккандай, шушы гүзәл табигать фонында шагыйрьнең лирик «мин»е үсеп чыга. Ә лирик «мин» исә —«Җир куәтен туплаган, ага-ага туймаган чишмәдән илһам алган» һәм бер үк вакытта «хыял сүнмәгәнме кешеләрдә, әштә, көрәштә?» дип борчылучы иҗтимагый гамьле замандашыбыз ул. «Кар суларын тезеннән ярып язларына таба каршы барган» лирик герой — шушы туган җирне, шушы туган илне тагын да ямьләү, тагын да матурлау өчен бөтен барлыгы белән янып-көеп яши, җирдә нык басып тора.

Китапның икенче бүлеген Җир язмышы, ил иминлеге турындагы шигырьләр алып тора. Шагыйрь Освенцимдагы өем-өем җитен төсле аксыл, басудагы алтын арыш сабагыдай сары, иртә яуган ап-ак кардай иртә чаларган сабый чәчләрен карап йөри. Шул чәчләргә кагылган җил матәм көен тарата. Бу авыр көй аның йөрәге аша үтә.

Яудан кайтмый калган батырлар истәлегенә багышланган «Пилотка турында баллада» әсәрен дә тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Анда авыр көннәрнең кырыс һәм драматик төсе дә, бүгенге тыныч хезмәт сулышы да, яу батырларын онытмаска чакыру да чагылыш тапкан:

> Егылды... кайтмады кырык ир.
> Хәтердә каһәрле кырык бер.
> Гариф карт караган офыкка,
> Егетләр болгыйлар пилотка.

Өченче бүлектәге мәхәббәт лирикасы үзенә хас бер нечкәлек белән сурәтләнгән. Аларда таушалган һәм, күп йөри торгач, штампка әйләнеп беткән төче сүзләр юк. «Бәре шәһәре кызына», «Караидел — урман иле», «Төшләремә җылы яңгыр керә», «Мәхәббәт елы» һ. б. шигырьләр шагыйрьнең интим хисләрне сыгылмалы һәм моңлы итеп сурәтләве белән күңелгә хуш киләләр.

Дөрес, бу китапта «Иген кыры», «Кулъяулык» шикелле шигъри табышлары чамалырак булган, шагыйрьнең мөмкинлегеннән түбәнрәк язылган һәм «Үлән», «Яз» кебек артык гади хакыйкатьләр расланган шигырьләр дә очрыйлар. Шулай ук шигырьләрдәге «чакта — болынлыкта», «дулап — җайдак» шикелле рифмаларны да уңышлы сайланган дип булмый.

Теләк рәвешендә тагын шуны да әйтәсе килә: шагыйрь вакыйгаларга нигезләнгән сюжетлы шигырьләрдә үзен иркенрәк сизә. Моны авторның «Пилотка турында баллада», «Бер гомернең өч туе», «Язгы җыр» әсәрләре ачык сөйли. Шагыйрь киләчәктә поэма жанрына мөрәҗәгать итсә, һич тә оттырмас иде. Бу заманны һәм дәверне катлаулырак һәм тулырак күрсәтергә мөмкинлек бирер иде. Автор үз иҗатында эре характерлар тудырыр, шигырь сөючеләрне тагын да шатландырыр иде. Моның өчен анда көч сизелеп тора.

**Әзһәр ГАБИДИ.**

[1] Госман Садә. Мәхәббәт елы. Казан, 1985 ел.

**Фәһимә Хисамова,**
филология фәннәре кандидаты

# ХӘЗИНӘДӘ НИЛӘР БАР?

## ТАТАР ХАЛЫК СӨЙЛӘШЛӘРЕН ӨЙРӘНҮНЕҢ КАЙБЕР ЮМГАКЛАРЫ

Төрле төбәкләрдәге җанлы халык сөйләшләрен (диалектларны), аларда сакланып килә торган тел җәүһәрләрен барлау, фәнни аңлатма бирү, сөйләшләрнең барлыкка килү тарихын ачыклау тел гыйлеменең әһәмиятле бурычларыннан берсе булып тора. Диалектларны өйрәнү халык тарихын яктырту белән дә турыдан-туры бәйләнгән.

Тарихи-иҗтимагый шартларга бәйле рәвештә татар теле төрки телләр арасында беренчеләрдән булып өйрәнелә башлый. Аның тәүге грамматикалары XVIII йөзнең икенче яртысында, XIX йөз башларында дөнья күрә. XIX йөздә А. Г. Бессонов, В. В. Радлов, С. Е. Малов, Г. Әхмәров, Н. Ф. Катанов кебек галимнәрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар диалектологиясенә дә нигез салына. Октябрь революциясеннән соң диалектларны өйрәнүгә Җ. Вәлиди, Л. Җәләй кебек галимнәр зур өлеш кертә.

Татар сөйләшләрен һәрьяклап монографик планда өйрәнү 50 нче еллардан башлана, һәм хәзерге вакытта бу эшнең мөһим бер этабы инде уңышлы тәмамланган дип санарга нигез бар.

Соңгы 30-35 ел эчендә СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре тарафыннан Рязань өлкәсеннән алып Чиләбе һәм Курган өлкәләренә кадәр таралган татар сөйләшләре монографик планда тикшерелеп чыкты. Бу эшнең нәтиҗәсе буларак, 14 000 нән артык сүзне эченә алган диалектологик сүзлек төзелде, аерым диалектларны, сөйләшләрне өйрәнүгә багышланган монографияләр дөнья күрде[1], күп төрле тематик җыентыклар басылып чыкты[2], фәнни журналларда һәм җыентыкларда күп санлы мәкаләләр урын алды. Хәзерге вакытта татар халык сөйләшләренең ике томлык атласы төзелеп, басарга әзер хәлгә китерелде. Күренекле тюрколог, институтның тел секторы мөдире Л. Т. Мәхмүтова җитәкчелегендә алып барылган шушы зур эшчәнлекне ачыграк күз алдына китерү өчен, соңгы вакытларда гына дөнья күргән кайбер хезмәтләр белән якыннанрак танышыйк.

«Татар диалектологиясе буенча материаллар» (Казан, 1983) исемле хезмәт — сөйләм теле үрнәкләрен үз эченә алган җыентык. Бу җыентыкка урта диалектның бөре, эчкен, минзәлә, абдуллин, каргалы сөйләшләре һәм мишәр диалектының байкыбаш, шарлык, һәм Тамбов өлкәсендә таралган сөйләшләре буенча тупланган текстлар кертелгән. Турыдан-туры халык теленнән язып алынган, шул сөйләш үзенчәлекләрен бөтен нечкәлеге белән чагылдыра торган, нигездә тарихи-этнографик һәм фольклор характерындагы бу материаллар телчеләр өчен генә түгел, тарихчылар, этнографлар, фольклорчылар өчен дә кыйммәтле. Җыентыкка диалектолог галимнәр Ф. С. Баязитова, Д. Б. Рамазанова, З. Р. Садыйкова, Т. Х. Хәйретдинова, Ф. Ю. Юсупов тарафыннан магнит тасмасына язып алынган текстлар тупланган. Бу хезмәтнең укучылар өчен кызыклы ягы тагын шунда, ул соңгы берничә дистә ел эчендә татар диалектларын өйрәнүнең кыскача тарихы, диалектологларның эш йомгаклары турында җыентыкның төзүчесе һәм редакторы Л. Т. Мәхмүтованың кереш мәкаләсе белән ачыла.

---

[1] Мәхмүтова Л. Т. Опыт исследования тюркских диалектов. М., 1978; Юсупов Ф. Ю. Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре. Казан, 1979; Рамазанова Д. Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984.

[2] Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1962; Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1974. һ. 6.

Татар теленең урта һәм мишәр диалекты нигездә Татарстанда һәм Татарстан белән чиктәш булган Идел буе — Урал тирәсе өлкәләрендә һәм автономияле республикаларда таралган. Бу статистик мәгълүматлар белән дә туры килә. 1979 елда халык санын алу мәгълүматларына караганда, татар халкының гомуми саны 6 миллион 317 мең кешене тәшкил итә. Шулардан 1 миллион 672 мең кеше — Татарстанда (якынча 26 процент); 830 625 кеше — Горький, Ульяновск, Куйбышев, Саратов, Волгоград, Пенза, Киров, Рязань, Тамбов өлкәләрендә һәм Мордва, Мари, Удмурт, Чуваш автономияле республикаларында; 940 мең кеше — Башкортстан АССР да; 731 708 татар — Урал тирәсендәге Пермь, Свердловск, Чиләбе, Курган, Оренбург өлкәләрендә яши. Күп санлы экспедицияләр нәтиҗәсендә тупланган материалларны өйрәнеп һәм архив документларына, һәртөрле тарихи-этнографик материалларга һәм фәнни әдәбиятка нигезләнеп, диалектологлар Идел буе-Урал төбәген татар халкының бергә тупланып яши торган төп регионы дип билгелиләр.

50—60 нчы елларда төп игътибар Татарстанда һәм Татарстаннан көнбатыштагы өлкәләрдә таралган сөйләшләрне өйрәнүгә юнәлтелә. Рязань өлкәсеннән алып Вятка (Нократ) елгасына кадәр булган бу территориядә тикшеренүчеләр түбәндәге сөйләшләрне аерып чыгаралар:

1) урта диалект: казан арты сөйләшләре (Татарстанның Казан арты районнары һәм Мари АССР); тау ягы сөйләшләре (Татарстанда Иделнең уң ягындагы Тау ягы районнары); керәшен татар сөйләшләре (Казан арты һәм подберезье керәшеннәре); нократ сөйләше (Киров өлкәсе); касыйм сөйләше һәм бастан сөйләше (Рязань өлкәсе);

2) мишәр диалекты: темников сөйләше (Мордва АССРның көньяк-көнбатышы); ләмбәрә сөйләше (Мордва АССРның көньяк-көнчыгышы); кузнецк сөйләше (Пенза, Саратов, Волгоград өлкәләре); хвалын сөйләше (Ульяновск өлкәсе); сергач сөйләше (Горький өлкәсе); чүпрәле сөйләше (Татарстанның көньяк-көнбатышы һәм Чувашия АССР); мордва-каратай сөйләше (Татарстан); чистай сөйләше (Татарстан һәм Куйбышев өлкәсе), мәләкәс сөйләше (Ульяновск өлкәсе), керәшен татар чистай сөйләше (Татарстан).

Икенче регионга Вятка елгасыннан алып көнчыгышта Чиләбе һәм Курган өлкәләренә кадәр таралган сөйләшләр керә. Архив материалларыннан һәм тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Башкортстан АССРның көнбатышында, Свердловск, Пермь, Чиләбе, Курган, Оренбург өлкәләрендә XVI йөздән башлап (Казан, Сембер, Пенза губерналарыннан һәм кайбер башка үзәк өлкәләрдән татарларның көнчыгышка күпләп күчеп утыруларына бәйле рәвештә), үзенчәлекле татар халык сөйләшләре барлыкка килә. Җирсезлектән, күтәрә алмаслык авыр ясактан, көчләп чукындырудан качып, буш җирләр, ирек, бәхет эзләп күпләп күченүләр милли-колониаль изү аеруча көчәйгән чорда — XVII—XVIII йөзләрдә масса төсен ала. Шул ук чорда көнчыгыш районнарга мишәрләрне һәм кайбер башка халыкларны күпләп күчереп утырту көнчыгыш чикләрне саклау, яңа җирләрне яхшырак үзләштерү максатында дәүләт тарафыннан да оештырыла. Көнчыгышка, Урал якларына күпләп күченүләр XX йөз башларына кадәр дәвам итә.

Татар халык сөйләшләрен өйрәнү максаты белән Башкортстан АССРның көнбатыш районнарына беренче экспедицияләр 1954—57 елларда күренекле галим Л. Җәләй тарафыннан оештырыла (Л. Т. Мәхмүтова, Ә. Ш. Әфләтунов, Җ. Алмаз җитәкчелегендәге экспедицияләр). 1968—79 елларда Башкортстан АССРның көньяк-көнбатыш, төньяк-көнбатыш, төньяк-көнчыгыш районнарында таралган татар халык сөйләшләрен җентекләп тикшерү тормышка ашырыла (Д. Б. Рамазанова, Ф. С. Баязитова, Ф. Ю. Юсупов, Т. Х. Хәйретдинова җитәкчелегендәге экспедицияләр). Өйрәнү махсус программа нигезендә алып барыла. Тикшеренү нәтиҗәләре әлеге регионда 321 торак пунктның 254 ендә татар теленең урта диалект сөйләшләре, 56 сында мишәр сөйләшләре, 11 ендә катнаш татар-мишәр сөйләшләренең урын алуын күрсәтә. Диалектологлар БАССР территориясендә татар теленең түбәндәге сөйләшләре таралуын аерып күрсәтәләр:

1) урта диалект: минзәлә сөйләшенең дәвамы (Янаул, Краснокамск, Калтасы районнары, Агыйдел елгасының аргы ягына кадәр); бөре сөйләше (Калтасы районының көньяк-көнбатышы, Борай районы, Балтач районының күпчелек өлеше, Янаул районының бер өлеше, Тәтешле, Караидел, Бөре, Мишкә районнары, Агыйдел елгасыннан беркадәр көньяккарак булган урыннар); кама буе керәшеннәре сөйләшенең бакалы урынчылыгы (Бакалы районы); минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы (көньяк-көнбатыш Башкортстандагы кайбер районнар).

2) мишәр диалекты: «ц» лаштыручы байкыбаш сөйләше (Балтач районының көньяк-көнчыгышы, Караидел һәм Мишкә районнарының бер өлеше); «ч» лаштыручы стәрлетамак сөйләше (Дәүләкән, Стәрлетамак, Аургазы, Чишмә, Кырмыскалы һ. б. районнар). Татар теленең мишәр диалекты сөйләшләрен махсус өйрәнгән галим буларак, Л. Т. Мәхмүтова «ц» лаштыручы байкыбаш сөйләше вәкилләренең патша хөкүмәте тарафыннан махсус күчереп утыртылган нижегород (сергач) мишәрләре нәселен дәвам

итүчеләр булуын, ә «ч» лаштыручы стәрлетамак сөйләше вәкилләренең нигездә пенза мишәрләреннән икәнлеген билгеләп уза. Бу фактлар тел күренешләре, халыкта сакланган риваятьләр белән генә түгел, архив документлары белән дә раслана. Шунысы да кызыклы; күрсәтелгән мишәр сөйләшләрендә һәм урта диалектның бөре һәм бакалы сөйләшләрендә башкорт теленең йогынтысы бөтенләй дип әйтерлек сизелми.

Салават, Мәчетле, Кыйгы, Дуван, Белокатай районнарының күп кенә авыллары казан татарлары һәм мишәрләр тарафыннан нигезләнгән булса да (татар диалектологиясендә бу төбәк урта диалектның златоуст сөйләше дип билгеләнә), андагы сөйләштә башкорт теленең дә беркадәр йогынтысы бар. Мәсәлән, ч урынына с куллану (сәй эсәбез). Бу сөйләшләрне өйрәнү татар һәм башкорт телләренең үзара тәэсир итешүе юнәлешендә кызыклы гына материал бирә, шул ук вакытта татар һәм башкорт телләре эчендә аларның урынын билгеләү галимнәр арасында кайбер фикер каршылыкларын да китереп чыгара. Ләкин лингвистик география ысулы белән халыкның бүгенге җанлы сөйләм теленнән язып алып тупланган тел материалларын татар һәм башкорт телләре белән системалы рәвештә чагыштырып өйрәнү телчеләргә бу бәхәсне объектив хәл итәргә тулы мөмкинлек бирә. Санап кителгән сөйләшләрне татар диалектлары системасында караулары белән диалектологлар һичшиксез хаклы. Киләчәктәге фәнни тикшеренүләр (мәсәлән, төрки телләрнең диалектологик атласын төзү, эксперименталь өйрәнүләр) бу нәтиҗәне тагын бер кат раслаячагына тулы нигез бар.

БАССР белән чиктәш булган башка өлкәләрдә яшәүче татарлар сөйләшләрен өйрәнү дә кызыклы нәтиҗәләр бирә. Свердловск, Пермь, Чиләбе, Курган, Оренбург өлкәләрендә руслар, башкортлар һәм башка халыклар белән янәшә татарлар да оешкан тестә, шактый зур төркемнәр булып яши.

1979 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, Свердловск өлкәсендә татарларның саны 179347 кешегә җитә. Бу өлкәдә яшәүче татарлар тел үзенчәлекләре буенча шулай ук бердәй түгел. Архив чыганакларыннан күренгәнчә, бирегә беренчеләрдән булып әле XVI йөздә үк дәүләт хезмәтендәге (йомышлы) татарлар күчеп утыртыла. XVI йөз ахырларыннан XVIII йөз башларына кадәр бирегә Казан губернасыннан, Көнгер өязеннән, Пермь губернасыннан татарлар күчендә. Шул ук вакытта көнчыгыштан себер татарларының күчеп утырулары турында да мәгълүматлар бар. Кыскасы, Свердловск өлкәсендә яшәүче татарларның аерым этник төркем булып формалашуында казан татарлары, мишәрләр, себер татарлары катнаша. Бу хәл аларның аерым сөйләшләре барлыкка килүгә дә үз йогынтысын ясамый калмый, билгеле. Диалектологлар аны урта диалектның красноуфим сөйләше дип билгелиләр.

Пермь өлкәсендә яшәүче татарларның (статистик мәгълүматлар буенча барысы 157 726 кеше) сөйләшләре формалашу шактый борынгы чорларга карый. Тарихи, этнографик, археологик материалларга һәм тел фактларына нигезләнеп, телчеләр бу региондагы татарларның сөйләше формалашуда барыннан да элек казан татарлары хәлиткеч роль уйнаган дигән нәтиҗәгә киләләр. Әле Болгар дәүләте чорында ук Идел буе һәм Пермь төбәге үзара тыгыз элемтәдә була. Идел буеннан татарларның бу якларга күченеп утырулары тарихның кискен борылыш чорларында — башта Болгар тар-мар ителгәч, соңрак — Казан ханлыгы яулап алынгач аеруча активлаша.

Оренбург өлкәсендә татар авыллары төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш районнарда күбрәк. Диалектологлар бу төбәктә урта диалектның абдуллин, каргалы сөйләшләре һәм мишәр диалектының шарлык сөйләше дә урын алуын билгелиләр. Казан, Пенза, Сембер губерналарыннан татарларның бирегә күпләп күченеп утырулары XVIII йөзнең 30 нчы елларында башлана (чик буйларында ныгытылган пунктлар төзү, ямщиклык хезмәтен оештыру һ. б.). Соңгырак чорларда исә, буш җирләр эзләп, сәүдә максатларында һ. б. ш. ирекле күченүләр дә активлашып китә. 1964—69 елларда һәм 1983 елда үткәрелгән экспедиция материалларына нигезләнеп, тикшеренүчеләр оренбург татарларының үз тел үзенчәлекләрен тотрыклы саклаулары турындагы нәтиҗәгә киләләр.

Чиләбе һәм Курган өлкәләрендә яшәүче татарларның сөйләшләрен өйрәнү буенча экспедицияләр шулай ук 1965—67 елларда оештырыла. 1979 елда исә бу төбәктә таралган татар халык сөйләшләрен өйрәнүгә багышланган монографик хезмәт басылып чыкты[3]. Галимнәр биредә өч сөйләш — нугайбәк, эчкен, сафакүл сөйләшләре булуын билгелиләр. Нугайбәк сөйләше үзенең төп үзенчәлекләре буенча татар теленең урта диалектына карый. Ул нигездә Чиләбе өлкәсенең Нугайбәк һәм Чибәркүл районнарында таралган. Тарихи хезмәтләрдә бу төбәк халкының чыгышы Казан ханлыгы яулап алынганнан соң ук христиан диненә күчерелгән Арча төбәге татарларыннан булуы турында мәгълүматлар бар.

Эчкен һәм сафакүл татарлары исә нигездә патша хөкүмәте тарафыннан күчерелеп утыртылган йомышлы татар-мишәрләрдән тора. Эчкен татарлары үз тел үзенчәлекләрен

---

[3] Юсупов Ф. Ю. Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре. Казан, 1979.

шулай ук тотрыклы саклыйлар. Сафакүл татарлары исә чыгышлары буенча шул ук татар-мишәрләрдән булсалар да, аларның сөйләше турыдан-туры телгә карамаган сәбәпләр аркасында шактый үзгәрешләр кичергән, төп үзенчәлекләре буенча башкорт теленә якынайган.

«Татар диалектлары буенча материаллар» дип исемләнгән әлеге җыентык турында сүзне йомгаклап, тагын бер кат әссызыклап үтәсе килә: җыентыкка кертелгән кереш мәкалә — асылда диалектологларның соңгы берничә дистә ел эчендә башкарган эшләре турында иҗат хисабы ул. Киң территориягә таралган татар халык сөйләшләрен җентекләп өйрәнеп чыгу, халык тарихына бәйле рәвештә аларның формалашу үзенчәлекләрен өйрәнү һәм, ниһаять, ике томлык татар сөйләшләре атласын төзү — болар барысы да зур булмаган коллективның чын хезмәт батырлыгы дип бәяләнергә хаклы.

Укучыларның игътибарын юнәлтергә теләгән икенче хезмәт конкрет бер төбәктә — Башкортстан АССРның көньяк-көнбатыш районнарында таралган татар сөйләшләрен өйрәнүгә багышланган[4].

Төрле тарихи-иҗтимагый шартлар басымы астында дүрт гасыр дәвамында бәхет, ирек эзләп, туктаусыз көнчыгышка, Урал буйларына агылган татарларны һәм башка халыкларны анда нинди язмыш каршы алган? Алар үз телләрен ничек саклаганнар? Кемнәр алар: «типтәрләр», «казан кешеләре», «мишәрләр», «яңа башкортлар» яки «әтәмбәй башкортлары»? Ни өчен күп кенә татар авылларында «башкортлар урамы», «типтәр очы», «казан кешеләре очы» бар? Хезмәтнең зур бер бүлегендә шушы һәм күп кенә башка сорауларга төгәл җаваплар алырга мөмкин.

Башкортстан АССРның көнбатыш районнарындагы татар халык сөйләшләре галимнәрнең игътибарын күптәннән ук җәлеп итеп килә. Әле XIX гасыр ахырларында ук бу сөйләшләрне махсус өйрәнгән А. Г. Бессонов, Н. Ф. Катанов кебек тюрколог-галимнәр әлеге төбәктә таралган сөйләшләрнең күпмедер дәрәҗәдә башкорт теле тәэсирен кичергән казан татарлары теле булуын раслыйлар. Шул ук сөйләшләрне махсус өйрәнгән күпчелек башкорт галимнәре дә (Ә. Ә. Юлдашев, Җ. Г. Киекбаев, Н. Х. Ишбулатов, С. Ф. Миржанова, Т. М. Гарипов) бу сөйләшләрнең формалашуында татар теленең хәлиткеч роль уйнаганлыгын, анда башкорт теленә хас үзенчәлекләрнең чикле булуын һәм нигездә лексикада, күпмедер дәрәҗәдә фонетика өлкәсендә генә чагылуын билгелиләр. 1981 елда басылып чыккан башкорт теленең академик грамматикасында да[5], БАССРның төньяк-көнбатыш районнарында таралган сөйләшләрнең асылда татар халык сөйләшләре булуы аерым әссызыклана.

Бу төбәктәге тел үзенчәлекләре татар галимнәре тарафыннан 50 нче елларда өйрәнелә башлый (Л. Т. Мәхмүтова, Җ. Алмаз, Ә. Ш. Әфләтунов җитәкчелегендәге экспедицияләр). Тикшеренүчеләр бер үк вакытта бирегә яшәүче халыкның төрле исемнәр белән аталып йөртелүенә дә (типтәрләр, бобыльләр, казан кешеләре, яңа башкортлар h. б.) игътибар итәләр һәм, тел фактларына, халык арасында яшәп килә торган төрле риваятьләргә таянып, бу «чуарлык»ның нигезендә халык буларак аерымлык түгел, ә бары тик җиргә, җир биләүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән төрле иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең үзенчәлекле чагылышы икәнен күрсәтәләр.

Д. Б. Рамазанова, мәсьәләгә тирәнрәк тукталып, шушы фикерләрне архив документлары белән дәлилли. Мәскәү, Оренбург, Пермь һәм Уфа шәһәрләрендәге архивларда саклана торган документлар белән танышу, Урал тирәсе регионы тарихына багышланган күп санлы фәнни әдәбиятны җентекләп өйрәнү авторга бирегә барган катлаулы иҗтимагый һәм этник процессларның тарихын тулы яктыртырга һәм ышанычлы рәвештә үз фикерләрен белдерергә мөмкинлек биргән.

Тарихчылар әлеге регионның XII—XIII йөзләрдә Болгар дәүләте составына керүен, һәм анда яшәүче халыклар белән болгар кабиләләре арасында генетик уртаклык булуын билгелиләр (А. П. Смирнов, h. В. Юсупов, Р. Г. Кузеев, Р. Г. Фәхретдинов h. б.). Болгар дәүләте монголлар тарафыннан тар-мар ителгәч, андагы халыкның көнчыгышка таба күчүе аеруча көчәя. Көнбатыш Башкортстанда яшәүче халыкларның тел буенча, этнографик яктан (ягъни материаль һәм рухи культура буенча) Идел буе татарлары белән уртаклыгының нигезе дә шул чорларда ук салына башлый. Бу уртаклык Алтын Урда, Казан ханлыклары чорында тагын да тирәнәя. Алтын Урда дәүләте җимерелгәч, бу җирләр Казан ханлыгы составында кала. Шуннан соңгы чорда, ягъни XVII—XIX гасырларда (хәзерге Башкортстан АССР территориясе рус дәүләтенә кушылганнан соң), алда күрсәтелгәнчә, Идел буеннан татарларның һәм башка халык вәкилләренең күчеп утырулары аеруча масса төсен ала. XVII гасыр башында инде күчеп утырган татарларның саны шушы җирләрдә яшәүче башкортлардан артып та китә. Бу тарихи фактлар

[4] Рамазанова Д. Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984.

[5] Грамматика современного башкирского литературного языка. М., 1981, 13 б.

тикшерелә торган хезмәттә күп санлы архив материаллары җирлегендә документаль рәвештә раслана.

Идел буеннан һәм башка үзәк өлкәләрдән хәзерге Башкортстан АССР җиренә күчеп утырган халыкларның анда төпләнеп калу мөмкинлекләре күп төрле була. Шулардан шактый киң таралганы «припуск» юлы белән урнашу. Килгән кешеләр төркеменең арада берсе җир хуҗасы — вотчинниклар белән махсус килешү төзи. Күчеп килүчеләр шушы килешү язуы нигезендә вотчинникның җирендә, яки аның белән бер үк авылда яши башлыйлар. Мондый килешү нигезендә урнашу «припуск» дип, килешү язуы «припускная запись» (җиргә кертү турында язу) дип, ә шул юл белән килеп утырган кешеләр исә «припущенник» дип аталганнар. Хезмәттә мондый юл белән килеп урнашучыларның күләме, чыгышлары белән кайсы төбәктән булулары турында архив документларыннан алынган күп кенә кызыклы мисаллар, саннар китерелә. Уса юлы Уран илүе (волосте) башкортларының 1688 елда язган хатларында, мәсәлән, соңгы берничә ел эчендә генә дә, Казан, Зөя, Уфа өязләреннән күчеп килгән татарларның, мари, удмуртларның башкорт җирләрендә кырыкка якын авыл булып урнашулары әйтелә. Уфа өязендәге Мөшегә авылы җир биләүчеләренең хатында төрле өязләрдән күчеп килүчеләрнең 20 авыл булып аларның җирләрендә яшәүләре турында хәбәр ителә. Мондый мәгълүматлар тарихчыларның тикшеренүләрендә дә күпләп китерелә. Тарихчы С. М. Васильев хезмәтендә, мәсәлән, Казан һәм Уса юлларындагы һәм башкорт илүендә берничә дистәдән алып берничә йөзгә кадәр авыл булып, күчеп килүчеләр яшәве турында фактлар китерелә.

«Бобыльләр», «типтәрләр» дигән иҗтимагый төркемнәр дә асылда шул ук күчеп килүчеләрдән торган. Җир хуҗалары белән килешеп, яки алардан сорамыйча ук, теге яки бу җиргә хуҗа булып яши башлаган яңа күчеп килүчеләр, җир юнәтеп, беркадәр йорт-каралты тергезүгә, «бобыль ясагы», ягъни шул чорда крестьяннар түләгән налогның бер төренә язылганнар.

Типтәрләр 1730 елдан башлап дәүләткә махсус «типтәр ясагы» түләп торучы аерым иҗтимагый катламны тәшкил иткәннәр. Алар арасында этник яктан төрле милләт вәкилләре — күпчелеге татарлар, шулай ук марилар, руслар, удмуртлар һ. б. булган. Тикшеренүчеләр (С. М. Васильев, Р. Г. Кузеев, Ә. Ә. Юлдашев һ. б.) татар-типтәрләрнең тел, материаль һәм рухи культура һ. б. яклардан барыннан да элек казан татарларына бик якын булуын һәрвакыт аерым билгеләп үтәләр.

Д. Б. Рамазанова үзенең хезмәтендә «припущенник», «типтәр», «бобыль» исеме астында йөргән төркемнәрнең социаль хәлен аларның аермалы якларын, үзенчәлекләрен мөмкин кадәр тулы һәм нигезле ачыкларга тырышкан. «Припуск» актының шул ук сату-алу икәнен авторның күп санлы фактлар нигезендә дәлилләп күрсәтүе аерым әһәмияткә ия. Күчеп килүченең теге яки бу җир хуҗасы (вотчинник) биләмәсенә мәңгегә урнашуы һәм вотчинник хокукында ул җирдән гомер буе файдалануы шул ук сатып алуга тиң булган һәм бу хәл яңа җир хуҗасына алга таба башкорт сословиесенә күчү өчен мөмкинлекләр тудырган.

Күчеп килүчеләрнең башкорт сословиесенә күчәргә омтылулары нәрсә белән аңлатыла соң? Тарихи хезмәтләргә, архив документларына нигезләнеп, Д. Б. Рамазанова бу мәсьәләгә дә ачыклык кертә. Эш шунда ки, Казан ханлыгы яулап алынгач һәм башкортлар рус дәүләтенә кушылганнан соң, Ык һәм Агыйдел бассейннарыннан алып хәзерге Башкортстан АССРның көнчыгыш чикләренә кадәр булган шактый зур регион аерым административ-территориаль берәмлек — Уфа губернасы составында кала. Шушы төбәктә яшәүче һәм җир биләү хокукы булган барлык халык (ягъни вотчинниклар) «башкиры» дип йөртелә. Шул рәвешле (нигездә XVII гасырда) төрле халыкларны, барыннан да элек башкортларны, татарларны үз эченә алган башкорт сословиесе аерым социаль төркем буларак формалаша башлый. Тарихи хезмәтләрдә бу иҗтимагый катламның билгеле бер вакытка Идел буендагы башка халыклар белән чагыштырганда өстенлекле (привилегияле) сословие булып калуы да күрсәтелә; аларга үз җирләрен вотчинниклар хокукында биләүне дәвам итәргә рөхсәт бирелә, бары тик җир сату тыела, чагыштырмача җиңел ясак салына һ. б.

Д. Рамазанова китабында һәртөрле иҗтимагый катлау вәкилләренең — бобыльләрнең, типтәрләрнең, йомышлы мишәр-татарларның башкорт сословиесенә күчүләре турында архив документларыннан алынган күп кенә мисаллар китерелә. Мәсәлән, Уфа өязе, Казан юлы Турай авылы татары Колмәт Еналиев 1677 елда бобыль ясагын ясаксыз кешеләргә күчерә һәм үзе оклад ясагы түли башлый, ягъни җир биләүче хокукын ала. Аның улы Якуп Колмәтов инде 1708 елгы документта башкорт дип язылган.

Типтәрләр һәм йомышлы мишәрләрнең дә авыллары-авыллары белән башкорт

---

[6] Васильев С. М. Припущенники на башкирских землях в I половине XVIII в. Канд. диссертация. М., 1950.

сословиесенә күчүе — шулай ук тарихи факт. Мәсәлән, Сәфәр һәм Тирмә авыллары мишәрләре (хәзерге Чишмә районы) XIX гасырга караган документларда инде (җир биләүчеләр сословиесенә күчүләре нәтиҗәсендә) башкортлар дип язылганнар. Ә аларның бабалары исә 1659 елларда ук патша хөкүмәтенә хезмәткә язылган (йомышлы) татар-мишәрләр булган. Архив документларында Халикәй һәм Яңа Муса авылы халкы да «мишәр-башкортлар» (башкиры из мещеряков) дип йөртелә. Бу хәл шул чор халык санын алу мәгълүматларында да чагылыш тапкан. XVIII гасыр архив документларында күчеп килгән кешеләр исәбенә башкортларның саны икеләтә арту турында теркәп калдырылган мәгълүматлар нәкъ шул турыда сөйли. Кыскасы, әлеге регионда «башкорт» сүзе ике төрле мәгънәдә — башкорт халкын, башкорт этносын белдерү өчен һәм сословие атамасы буларак кулланылган. Башкорт этносын күчеп килүче башка халык вәкилләреннән (барыннан да элек татарлардан) аеру өчен шуңа күрә ул вакытта ук инде «чын башкортлар», «яңа башкортлар» кебек атамалар кулланылган. Хәзерге көнгә кадәр, әйтик, бу төбәктә типтәр-рус, типтәр-мари, типтәр-чуваш авыллары һ. б. яшәп килә. Бер-беренә бик якын кардәш халыклар булса да, Идел буеннан һәм башка үзәк өлкәләрдән күчеп килгән татарларны да, башкорт сословиесенә күчүләренә карап, башкорт этносы составында карау өчен нигез юк. Д. Б. Рамазанова хезмәтендә моның бик ачык дәлилләре китерелә. БАССРның көнбатышында яшәүче татарлар республиканың көнчыгышындагы башкорт халкыннан күп яклап — материаль һәм рухи культура, гореф-гадәт, антропологик җәһәттән һ. б. нык аерылып торалар. Алар татар теле үзенчәлекләрен тотрыклы саклыйлар, милли аңнары буенча үзләрен башкорт халкыннан аерып карыйлар.

Хезмәттә бу төбәктә хәзер дә гамәлдә йөри торган «казаннар», «казан кешесе», «түбәннәр», «алатырлар» кебек атамаларга да тарихи-иҗтимагый яссылыкта тулы аңлатма бирелә. «Казаннар», «казан кешесе» дигән атамалар XIX гасыр урталарында яки соңрак килеп утырган татарларга карата кулланыла. Алар шактый соң, әйтергә кирәк, җирләр бүленеп, үзләштерелеп беткәч килгәннәр, шуңа күрә бик аз җирле булганнар, төрле кәсеп белән көн күргәннәр. Еш кына бу төркемнәр үз араларындагы баш кеше исеме белән аталып киткәннәр: «мөлкәйләр», «әптерәшитләр» һ. б., яки «яңалар» дип йөртелгәннәр. «Түбәннәр», «алатырлар» атамалары күчеп килгән мишәрләрнең аерым төркемнәренә карата кулланылган (Темников, Алатыр өязләреннән килгән мишәрләр).

Китапның «Башкортстанның көньяк-көнбатыш районнарында таралган татар сөйләшләре» дип исемләнгән икенче бүлегендә әлеге төбәктәге 200 гә якын авылның сөйләш үзенчәлекләре өйрәнелгән. Автор материалның кайсы авылдан алынган булуын төгәл күрсәтеп барган, һәм бу авылларның исемлеге китап ахырында китерелгән.

Башкортстан АССРның көньяк-көнбатыш районнарында таралган урта диалект сөйләше тикшеренүче тарафыннан минзәлә сөйләшенең дәвамы булган бәләбәй урынчылыгы дип билгеләнә. Сөйләш үзенчәлекләре, бай материал нигезендә җентекләп тасвирланган.

Төбәктәге мишәр сөйләшен (стәрлетамак сөйләшен) җентекләп өйрәнү аша автор биредә барган этнолингвистик процесслар турында гаять кызыклы нәтиҗәләр китерә. 300 ел дәвамында туктаусыз күченеп килгән мишәрләрнең бу җирләрдәге казан татарлары белән аралашулары нәтиҗәсендә барлыкка килгән әлеге сөйләш өч төркемгә аерыла. Беренче төркем — Туймазы районының Максут, Имән-Күпер, Калталы һ. б. авылларында һәм Бәләбәй районының Иске Сүлли, Абдулкәрим, һ. б. авылларындагы мишәрләр. Сан ягыннан аз булганга күрә, аларга казан татарларының тәэсире көчле булган. Нәтиҗәдә биредә мишәр сөйләшенә хас үзенчәлекләр аерым сүзләрдә генә сакланган. Икенче төркем — XVIII—XIX йөзләрдә күчереп утыртылган һәм хәзер нигездә аерым авыллар булып Баулы, Стәрлетамак, Бүздәк, Миякә районнарында яшәүче мишәрләр. Алар үз тел үзенчәлекләрен шактый тотрыклы саклыйлар (Салих, Түбән Чүте, Слак, Әбдерәшит, Нигъмәтулла, Бузат, Зәйпәкүл һ. б. авыллары). Өченче төркем исә борынгыда ук дәүләт тарафыннан күчереп утыртылган һәм XVIII йөздә көньякка табарак күченгән йомышлы мишәрләрдән торган. Боларга Аургазы, Чишмә районнарындагы аерым авыллар керә. Бу төркем авылларның сөйләше мишәр диалекты үзенчәлекләрен берникадәр саклаган хәлдә, татар әдәби теленә дә шактый якынайган.

Халык сөйләшләрен өйрәнү, һәрьяклап тасвирлап, дөньяга чыгару — гаять әһәмиятле һәм кирәкле эш. Без күзәткән хезмәтләр шушы юнәлештә фәнгә зур өлеш, җитди казаныш булып тора.

•••••••••••••••••

# ТӨСЛӘР БАЛКЫШЫ

Казан каласы яннарында гаҗәеп гүзәл почмаклар бар. Шуларның берсе — Зәңгәр күл. Бу тын почмакны табигать музее итәсе иде дә бит... Юк, хәзер анда бернинди транспорт йөрми, һәммә нәрсә ташландык хәлендә. Табигатьнең искиткеч гүзәл урыны... чүплеккә әверелгән.

Ә бит бар иде Зәңгәр күлнең бәйге тоткан, шаулаган чаклары... Казан елгасы буенда гына, нарат урманы куенында гына, асылташлар белән уратып алынган бриллиант шикелле, куе яшеллек эчендә зәп-зәңгәр күл ята. Суы чишмә суыннан бер дә ким түгел, сап-салкын; үзе бәллүрдәй саф, үтә күренмәле; халык телендәге «Зәңгәр күлнең төбе юк икән» дигән сүзгә бик үк ышанып җитмәсәң дә, төбенә ташланган бакыр акчаң никадәр озак төшкәнен үз күзең белән күрә аласың. Йөзек кашыдай нурланып-балкып торган бу озынча күл сине тәмам сихерли, шунда син табигатьнең гүзәллегенә сөенәсең, матурлыгына сокланасың, кодрәте алдында баш иясең.

Мәшһүр рәссамыбыз Тавил Хаҗиәхмәтовның да кайчандыр Зәңгәр күл тирәләренә барып йөргәнен, тик минем шикелле, сокланып кына калмаганын, бәлки акварель буяулар белән рәсемгә дә төшергәнен әле шушы арада гына белдем. Моңарчы да яраткан рәссамнарымның берсе булган, сәнгатьнең бу өлкәсендә ярыйсы ук мая туплаган, ә инде китап ясауда тиңен белмәгән оста хакында үз фикеремне язарга утырдым.

Татарстанның халык рәссамы Тавил Гыйниятулла улы Хаҗиәхмәтов 1936 елның 3 февралендә Саба районының Йосыф-Алан авылында туа. Вакытында аның әтисе дә, бабасы Хаҗиәхмәт тә, олы бабасы Ихсан да (ул баба 25 ел буена патша армиясендә хезмәт иткән, Кавказда Шамилгә каршы сугышып йөргән, шуннан соң Тенеки авылына кайтып, башлы-күзле булып, төпләнеп калган) һәммәсе дә көмешче булган. Гәрчә төп һөнәрен ташламаса да, Мәртен авылының Шәмсенур исемле бер сылуына өйләнеп җибәргәч, Гыйниятулла абзый таулы-чокырлы, көлсу туфраклы Тенекидән, бераз уңдырышлырак туфраклы авыл эзләп, Йосыф-Аланга күченә, шунда йорт җиткезә, 120 төп алмагач утырта, крестьян тормышы белән яшәп ала. Тик инде алма бакчалары утыртса да, үзенең күңеле утырмый Гыйниятулла абзыйның. Утызынчы еллар азагында ул, ишле гаиләсе белән, Казанга күчеп килә. Бөек Ватан сугышы елларында авиация заводында эшли: көмешче булуы монда да ярап куя — иң нечкә ябыштыру эшләрен ул башкара. Сугыштан соң ул корыч коючы була. Әмма нинди генә эштә эшләмәсен, көмешче һөнәрен гомере буе ташлый алмый Гыйниятулла абзый. Тавил атлы малае аның яссы бер металл кисәгеннән нинди матур бизәнү әйбере — сәнгать әсәре ясавын, әлбәттә, биһуш булып, сокланып карап тора, ә инде эш коралы тота башлагач, әтисенең кул арасына да керә, әз-мәз ярдәм итә, булыша. Әнә шулай ата-бабадан килә ул сәнгатькә мәхәббәт, гүзәллекне кечкенәдән үк аңлый башлау...

Хәер, моның белән генә дә чикләнми әле. Туган авылы, тәпи басып йөри башлагач та кинәнгән чирәмле урамы, аннары тагын авылның өстенә авам-авам дип торган мәһабәт урманы, ул урман уртасындагы биниһая матур күле дә бар бит әле. Йосыф аланы дигәннәре ул нәкъ әнә шул урман аланына һәммә кешенең соклануыннан килеп чыкмады микән әле? Ара ерак булмагач, авылга кайта-китә йөриләр Хаҗиәхмәт бабайның оныклары. Ул авылның һавасы, андагы ямь, кошлар сайравы, андагы яшел чирәм генә дә тартмый булачак рәссамның күңелен, әнә шул бай табигать арасында яшәүче авыл халкы да сокландыра Тавилне. Сабыр гына, әдәпле генә аңгәмә корып утырырга да, табигатьне яратарга да башлыча ул шунда өйрәнә. Бу рәссамның акварель, гуашь яки темпера буяулары белән язган йөздән артык рәсемнәрендә кара чыршы, нарат, имән, каен, карама, юкәләрне күргәндә, гүя сокландыргыч бер гүзәл урман эченә барып керәсең, гүя кошларның берсен берсе уздырып чут-чут итеп сайраганын ишетәсең. Хаҗиәхмәтов акварельләреннән ачылган үзенә бертөрле моң вә нәфислек, һичшиксез, туган якларының илаһи матурлыгына барып тоташадыр, чөнки сабый чакта күңелгә уелган бизәкнең ямьсезен дә, ямьлесен дә һичбер нәрсә юып бетерә алмый.

Аннары тагын әлеге дә баягы Зәңгәр күл тирәләрендәге сокланголч табигать бар бит әле. Бу якларны да Тавил сабый чактан ук ярата-күрә белгән икән. Ихтимал, егетнең чын рәссам булып җитлегүенә дә нәкъ әнә шул гүзәллек тәэсир иткәндер. Табигатьнең сихри серлелеген чагылдырган рәсемнәрнең һәммәсенә дә аерым-аерым тукталу һич мөмкин түгел. Кайсыберләренә генә илтифат итик. Арада бер яктылык бөркеп торган картина «Көз-күл» дип исемләнгән; аяз күк йөзе күлдә чагыла; оптимизм тулы бу рәсемгә киңлек-иркенлек хас. Ә менә «Упкын» дигәнендә су үзе генә түгел, агачлар да, куаклар да, үләннәр дә, шомлы шик белдергәндәй, сагаеп калган. «Яфраклар коелганда» дип аталганы, киресенчә, мажор тонда язылган; биредә гаҗәеп дәрәҗәдә оста сайланган төсләр гармониясен күреп сокланасың.

Әйе, табигать елның һәр фасылында үзенә бер ямьлелек, үзенә бер гүзәллек тәшкил итә. Әнә шул күренешләрне Тавил искиткеч зур осталык белән гәүдәләндерә. Күлне тасвирлауга багышланган рәсеме «Яз» дип кенә атала, кыска гына исем; ләкин шул әсәрендә рәссам табигатьнең уяну вакытын тулаем күз алдына китереп бастырырлык күренеш иҗат итә: биек һәм төз наратлар гүя, көннең җылынуын — кояшның елмаюын абайлап, урман ешлыгыннан язны каршыларга чыкканнар да тубыктан кар суын ерып баралар. Җәйге көнне тасвирлаган «Урман итәге»ндә төсләр алай күп тә түгел: иң алда сыек яшел чирәмлек, ул чирәмлекне ярып узган юл нарат кәүсәләренә тәмам аваздаш; күксел-яшел урманнан өстәрәк — җәйге болытлар агыла, урманның калынлыгына, зурлыгына ишарә итә алар... Көз көненә багышланган «Усаклар яна» әсәрендә карасу чыршынаратлар олы гына урман фонын тәшкил итә, әнә шул фонда усаклар кичке кояшта балкып яна, юк, усаклар янмый, төсләр яна, әнә шул дөрләп янган алсу-кызыл ябалдашлы агачлар ярдәмендә яшеллек тә киңәеп, ачылып китә икән ләбаса! «Тирән күл» исә төсләрнең үткенлегенә, ягъни контрастка корылган: яр буенда үсеп утырган агачлар күезәңгәр суда көзгедәге кебек чагыла; агачларга иңгән сарылык инде көз кергәнен абайларга мөмкинлек тудыра; чынлап та, агач кәүсәләре карала төшкән икән шул; су өстенә авышып, тасраеп торган кәкре агач кына алгы планда аксылланып күренә. «График пейзаж» дигәне дә шул ук күлне тасвирлый: төз наратлар янында ике-өч бөртек кеше дә бар, һәм алар күл уртасындагы йөзмә утрауга текәлгәннәр...

Хаҗиәхмәтовның күп кенә рәсемнәре, миңа калса, әкияткә тартым. Әйтик, «Яфраклар сөйләшә» дигән исемне укыгач, моның шулай икәненә һичбер шигең калмый — син ирексездән тукталып, яфраклар сөйләшүенең серенә төшенергә теләгәндәй, озаклап, онытылып карап торасың. «Карт өянкеләр»е — гүя алыплар, гүя баһадирлар. Әкият дөньясы «Ноктюрн» дигән әсәрендә аеруча нык чагылыш тапкан: искиткеч ямьле бер табигать почмагы, яфраклар коела башлаган, әмма яшеллек әле һич тә бирешәсе түгел; һәрхәлдә, куелык бимазалап, күзеңә кереп интектерми; суның аксыл-зәңгәр төсләрдә бирелүе, бер караганда, бераз сәеррәк тоела, күңелеңнән генә, әллә инде рәссамның буявы җитмәгән дип уйлап аласың; әмма җентекләбрәк карый торгач, суның агышын-хәрәкәтен бүтән төсләр фонында гаять үзенчәлекле бирү өчен, нәкъ менә аксыл итү зарур булганына төшенәсең, бу илаһи матурлыкны иҗат итүченең төсләрне тоюына сокланып туя алмыйсың... Автор үзе бу хакта болай ди:

«Монда инде төсне уйламыйсың, әлеге мизгелне тотып калырга тырышасың — дөньяда синең өчен бүтән берни юк!— Шунда рәссам, тәэсирләнеп, бүгенге хезмәтенә, ягъни китап эшләүгә күчә:— Китапта да шул ук яну бит инде ул, фанатикларча яну... Кереп китәсең дә бер китапка, онытасың төп эшеңне — картина язуны...»

Чыннан да шулай: Тавилнең китапка ясаган рәсемнәрен акварельләреннән аерып карау — бер бөтенне икегә бүлү, ясалма бүлү шикеллерәк нәрсә булыр иде. Чөнки соңгы елларда китапны матурлау-бизәү өлкәсендә Тавил Хаҗиәхмәтов — һич тиңе булмаган, югары культурага ирешкән оста ул. Чирек гасыр буе әледән-әле яңалык эзли, бүтән рәссамнарны кабатламау гына түгел, хәтта әле үзе ясаган китапларны да кабатламаска тырыша. Моның нәтиҗәсе буларак, бу эштә аның үзенә генә хас камил бер почерк барлыкка килә. Чыннан да, татар халык әкиятләрен, Г. Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый», М. Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә», А. Алишның «Сертотмас Үрдәк», Н. Исәнбәтнең «Мыраубай батыр маҗаралары», Ш. Галиевнең «Тылсымлы көзге», Г. Хәсәнов һ. б. язучыларның күп санлы китапларын бу рәссам гаҗәеп матур итеп бизәде. Аларның барчасына да ачык төсләр, эчтәлекне рәсемдә сөйләү-чагылдыру һәм сабыйлар дөньясын белеп эш итү хас. Бу сыйфатлар Тавил рәсемнәре белән басылып чыккан һәр китапта чагыла. Шул ук вакытта әлеге китаптагы рәсемнәр һич тә кабатланмый, аларның һәркайсы бик нык үзенчәлекле, һәм әнә шул үзенчәлекләре нәни укучыларны серле дөньяга җитәкләп алып керә.

Шунысы кызык: әгәр дә ул зур күләмле әсәрләрендә һәммә детальне дә төп-төгәл ясап бетермәсә, ягъни тамашачының үзенә уйланырга урын калдырса, хыялланырга, күз алдына китерергә мөмкинлек бирсә, китап өчен эшләгән рәсемнәрендә мәсьәләгә бөтенләй бүтәнчә килә: һәр эшендә төгәллек, һәр детале тәгаен җиренә җиткереп эш-

ләнгән булыр аның. Бу хәл, минемчә, эшеңне тамашачылар, укучылар (бигрәк тә нәни укучылар!) ничегрәк кабул итәр икән, аңлаешлы булыр микән дип уйлана белүдән килә.

Тавилнең үз балачагы сугыш елларына туры килә. Ни кәгазь юк, ни карандаш яки буяу юк. Әле хәтта ризыкка һәм кием-салымга кытлык заман. Тавил күбрәк өйдә утыра. Кышкы суыкларда бигрәк тә. Радио тыңлый, сугыш хәлләрен үзенчә аңлый һәм әнә шул аңлаганнарын аерым «картиналар» итеп, ак кәгазь урынына... тәрәзәнең каткан пыяласына төшерә. Булачак рәссамның дөньяны күзаллавы иң әүвәл шул сурәтләрдә чагыла.

Аннары инде мәктәптә укый башлый. Химиклар сарае янындагы 89 номерлы татар мәктәбенә шактый араны трамвай белән йөреп укый.

Ул мәктәптәге әдәбият укытучысы Шәфа апа Кометованы (соңыннан ул завуч, аннары директор була) Тавил хәзер дә хәтерли әле. Укучыларны җәмәгать эшләренә тарта белүче, әдәбиятны чын күңелдән сөюче, үзе искиткеч чибәр укытучы түгәрәкләр оештыра, матур итеп укырга, хәтта шигырьләр язарга да өйрәтә. Ана теленә һәм әдәбиятка мәхәббәт уяткан бу асыл затның юбилей тантанасы көнендә Тавил аңа үз рәсемнәре белән дөнья күргән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабын бүләк итә.

Рәссам булырга хыялланып, Тавил Сәнгать училищесына укырга барып керә. Диплом эшен майлы буяу белән ясый һәм «Төшке аш» дигән исем бирә. Чабылган җирдә, чүмәлә төбенә чалгычылар төшлеккә җыелган, кайсы ни рәвештә ял итә. Рәссам ул чакларны искә төшереп, болай ди:

«Бабайны бик интектердем инде кояшта яткырып... Авылдашларга да нык эләкте: минем геройларым — чын колхозчылар инде үзләре...»

Рәссамнарның күпчелеге училищены тәмамлау белән чикләнгән бер заманда, илленче елларда, Тавил ярты юлда бүленеп калырга теләми һәм Ленинградка барып, И. Е. Репин исемендәге Сәнгать институтына имтиханнар тапшыра. Анда уку дәверендә сәнгатьнең тарихын өйрәнә, бөек рәссамнарның хезмәтен, эшләү ысулларын һәм техникасын үзләштерә. Кайчандыр Казанда укып киткән профессорлар Г. М. Платунов, Л. Н. Овсянников һәм М. А. Таранов та, егетебезнең каян килгәнен белгәч, бигрәк үз итәләр, эшкә өйрәтәләр.

Дөнья сәнгатен өйрәнгәндә, сәгатьләр-көннәр буе Эрмитажда, Рус музеенда йөргәндә, ул музейлардагы тиңсез гүзәллеккә сокланып кына калмый, мәшһүр әсәрләргә мөкиббән китү белән генә чикләнми Тавил, өйрәнә-күзәтә торгач, акрынлап һәр бөек рәссамның ничек итеп шундый да зур иҗади уңышка ирешүенә төшенә башлый. Хикмәт аларның техник яктан камиллекне яулап алуларында гына түгел икән, хикмәт һәр даһиның үз халкыннан аерылмавында, тугрылыклы улы булуында икән ич! Техник алымнарны, эшләү ысулларын халкыңның тарихын аңлау белән бергә кушып эш иткәндә генә, күркәм нәтиҗәгә ирешү мөмкин икән ләбаса! Чыннан да, һәр даһи рәссам үз халкының үткәнен һәм бүгенгесен бөтен җаны-тәне белән аңлап, яратып, шуны үзенең әсәрендә зур осталык белән чагылдыра алган очракта гына күркәм нәтиҗәгә ирешә һәм исемен мәңгеләштерә.

Моны аңлагач, Тавил дә халыкның үткәненә күз сала, авыз иҗаты белән кызыксына башлый. Туган якларга кайткан саен, сусаган мал су буенда кайнашкан кебек, һаман этюдлар ясый, табигать күренешләрен рәсемгә төшерә, үзлегеннән татар халык әкиятләрен өйрәнергә керешә. Күңеленә иң хуш килгәне «Салам Торхан» әкияте була. Рәссам бу әкиятне үзе аңлаганча сурәтләп тә куя: акварель һәм гуашь белән алты рәсем ясый. Әкиятләргә кагылышлы сүз чыкса, Тавил дәртләнеп китә: «Зур тема ул! Моңарчы кыюсызланыбрак торган идем әле. Хәзерге тәҗрибә белән халыкның тапкырлыгын беркатлы юморга юл калдырмыйча ачып салу — олуг хыялым!»— ди.

Халкыбызның үткәнен өйрәнгәндә, рәссам, әлбәттә, гореф-гадәтләргә дә, кием-салымга да бик нык игътибар итә. Ныклап өйрәнү-үзләштерү бер заман ярап та куя, икенче төрле итеп әйткәндә, кулланыш таба. Әгәр бүген Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең җыр һәм бию ансамбле артистлары сәхнәдә ут уйнатып бөтереләләр икән, тамашачы аларны хуплап кул чаба икән, монда Тавилнең дә өлеше юк түгел, чөнки алар өстендәге костюмнарның авторы — нәкъ ул.

Тавил Хаҗиәхмәтовның күпкырлы иҗатында иң зур кыенлык тудырганы, мөгаен, костюмнар мәсьәләсе булгандыр. Н. Фәттахның «Кол Гали» трагедиясен сәхнәләштергән чагында Татар дәүләт академия театры Хаҗиәхмәтовны чакыра. Костюмнарны уйлап табасы була. Моннан җиде-сигез йөз ел элек яшәгән әби-бабаларыбызның киемнәре беркайда сакланмаган... Борынгы таш балбалларны өйрәнеп, әзме-күпме күз алдына китерергә мөмкин булмасмы дип өметләнеп, рәссам Тува, Хакасия якларына сәяхәткә чыгып китә. Украина далаларын да урап кайта. Бер караганда, болай сәяхәт итүләрнең кирәге дә юктыр сыман: фантазия белән генә дә кием-салымны уйлап чыгарып була ич инде! Әмма Тавил эзләнүсез-нисез генә уйлап чыгарган костюмга риза түгел. Фәкать дөнья бетереп эзләп кайткач кына, шул заманда гомер кичергән шәхесләрне үзенчә күз алдына китергәч кенә, шул персонажларны автор әйтергә теләгән төп идеягә буйсындыргач кына, костюмның һәр детален буяу белән кәгазьгә төшерә башлый. Һәр костюмны бит әле сәхнәдә барачак вакыйгаларга да, ул рольне башкарачак артистка да, персонажның нинди сыйныф вәкиле булуына да бәйләп эшлисе; шул ук вакытта

ясаган костюмнарың чынбарлыкка тәңгәл киләме, үзара бәйләнәме, алар һәммәсе бергә бер бөтен, ягъни ансамбль тәшкил итәме? Димәк, фәкать эзләнү, өйрәнү, табу, чишү генә образны сәхнәгә чыгарырга, тамашачыга тәкъдим итәргә мөмкинлек тудыра; фәкать реаль чынбарлыкны гәүдәләндерү генә җиңүгә китерә, иҗат иясенә ләззәт бирә. Хаҗиәхмәтов тәкъдим иткән костюмнарны театр халкы бик сөенеп кабул итә.

Шуннан соң инде тарихи сәхнә әсәрен куярга хәзерлисе-фәлән булса, Тавилне генә чакыралар. Т. Миңнуллинның «Канкай углы Бәхтияр» дигән тарихи драмасын куярга җыена башлагач та, костюмнар ясауны аңа тапшыралар. Гәрчә Пугачев хәрәкәте без яшәгән көннәрдән чама белән ике йөз ел гына элгәрәк булып узса да, ул заманны тулаем күзаллау өчен, рәссамга шактый эзләнергә, уйланырга туры килә. Бәхтияр Канкаев һәм аның көрәштәшләре ничек киенгәннәр икән? Бүгенге тамашачы аларны ниндирәк кыяфәттә күзаллый икән дә, нинди киемнәр кидерсәң, кабул итәр икән? Төрле сыйныф вәкилләре, әлбәттә, бер үк төрле киенә алмаган. Аларның һәркайсына (әйтик, крестьяннарга, укымышлы халыкка, хөкүмәт даирәләренә) бары тик шул сыйныфка гына хас төсләр гаммасын, килбәт-рәвешен уйлап табарга кирәк була.

Тавилнең Курчак театрына эшләгән эшләре тәмам хәйран калдыра. Бу театрда Габдулла Тукайның «Кәҗә белән Сарык» әкиятен сәхнәгә кую теләге уянгач та, рәссам эшен кем башкарып чыга алыр икән, дип уйга калалар. Чөнки зурлар өчен куела торган спектакльләрдә артистлар уйнаса, монда артистлар үзләре күренми, тамашачы алдында фәкать алар кулындагы курчаклар гына «уйный»; шуңа күрә бу очракта рәссамның эше костюм рәсемен ясау белән генә чикләнми, ә курчакның нинди булырга тиешлеген дә билгели.

Рәссам, шактый баш ваткannan соң, әкияттәге «төп геройларның» сурәтләрен сабый балаларга ошарлык итеп кәгазьгә төшерә: җитез генә Кәҗә, аңгыра Сарык, килбәтсез генә усал Бүре килеп чыга. Аннары инде рәссам спектакльдә катнашачак башка образларны иҗат итәргә керешә, нәтиҗәдә: ыспай гына кыяфәтле һәм, әлбәттә, сакаллы авыл карты — Бабай, аның янында мөлаем йөзле, әдәпле генә татар карчыгы — Әби, аннары инде өс-башы гаҗәеп затлы булуга да карамастан, иләмсез зур башлы, мичкәдәй корсаклы, адәм мәсхәрәсе бер тип — Бай образлары хасил була. Декорацияләрен дә искиткеч кызыклы итеп, җете төсләрдә хәл итә һәм шуның белән үзенең нәни тамашачыларын чын-чынлап әкият дөньясына алып кереп китә.

Театр спектакльләренә оформление ясау өлкәсендә бөтен дөньяга мәшһүр булган А. Бенуа истәлекләренә караганда, аның дусты һәм шундый ук талант иясе Лев Бакст театр костюмнары өчен уйлап тапкан һәр бизәкне, ювелир шикелле, үзе үк чүкеп утыра икән (Александр Бенуа размышляет. М., «Советский художник», 1968, 504 б.). Нәкъ шуның сыман, безнең Тавилебез дә әлеге «Кәҗә белән Сарык» әкиятендә катнашучы персонажларның образларын кәгазьгә төшереп кенә калмый, бәлки һәр курчакны папье-машедан үз кулы белән ясап һәм үзе теләгәнчә киендереп, театрга тапшыра. Моның хикмәтен күп кеше аңламый торгандыр, ә миңа калса, бу вакыйга үзе генә дә — рәссамның үз эшенә никадәр тирән кереп киткәнен, башы-аягы белән гашыйк булганын, хезмәт сөйгәнен, онытылып эшләвен дәлилли торган бер деталь. Бу сурәтләр, гәрчә әллә ни күп санлы булмасалар да, Т. Хаҗиәхмәтовның шәхси күргәзмәсендә дә игътибар үзәгендә булдылар. Тамашачыларның шушы рәсемнәр алдында озаклап тукталып, көлешә-көлешә карап торулары, һичшиксез, Тавилнең рәссам буларак зур талант иясе икәнлеген, бөек Тукай әкиятләренә тәңгәл китереп, сәхнә законнарын истә тотып, уңышлы рәсемнәр иҗат иткәнлеген күрсәтә.

Т. Хаҗиәхмәтов бөек шагыйребез Габдулла Тукайның әкият геройларын, шигырь персонажларын тасвирлап кына да калмый, бөек шагыйрьнең портретын да ясый: агачка уеп эшләнгән портрет рәссамның иң яңа хезмәтләреннән санала; бу инде без күнеккән портретларга һич охшамаган, бу фотография дә түгел, бәлки азатлык җырчысының иҗатын ныклап үзләштергәннән соң рәссам күз алдына китергән илаһи образ; монда шагыйрьнең бөеклеге дә, мәгърурлыгы да төсмерләнә.

Тавилнең көмешчеләр нәселеннән килүен остаханәдәге бик күп нәрсә раслый. Кайчагында аның янына сугылсаң, гап-гади бер металл кисәген йә чүки, йә бәләкәй генә станокта кырдыра-шомарта торган вакытына туры киләсең дә, аның тик тора белмәвенә гаҗәпләнәсең, әмма ул шомартып азапланган тимер кисәгеннән нинди нәрсә килеп чыгасын һич күз алдына китерә алмыйсың. Рәссам үзе тыйнак кына елмая: берәр нәрсә килеп чыгар әле, янәсе... Ә инде икенче керүеңә — гүзәл сәнгать әсәре әзер була, синең игътибарыңны үзенә җәлеп итә; аның витраж яки бүтән затлы нәрсәгә әверелеп куюы бик ихтимал.

Хәер, кәгазь-картон яки агач ише материалны да Тавил гаҗәеп оста файдалана. Аның бәләкәй форматлы картон кисәгенә искиткеч җете төсләр белән эшләп куйган «Тын табигать» дигән әсәре моңа ачык мисал була ала. Килешле генә вазага кып-кызыл роза чәчәкләре утыртылган; өстәл өстендәге китап тышында тез чуккан яшь кенә хатын-

кыз сурәте; роза чәчкәләре, күзгедә чагылып, өстәмә төс бизәге хасил итә; биредә, гомумән, төсләрнең контрасты гаҗәеп дәрәҗәдә көчле чагылыш тапкан, шуңа күрә үзе кечкенә, үзе төш кенә бу рәсем җете төсләрне бер гармониягә буйсындыру идеясенә таянып иҗат ителгән, камил әсәр буларак бәяләнергә тиеш диясе килә.

Сынлы сәнгать әһелләре арасында Тавил Хаҗиәхмәтов укымышлы, ягъни татар әдәбиятының үткәне белән тирәнтен кызыксынучы һәм бүгенгесен әйбәт белүче кешеләрдән санала. Берәр язучының портретын эшләргә яки аерым бер әсәрен иллюстрацияләргә алына икән, Тавил инде ул авторның бөтен иҗатын ныклап өйрәнмичә туктамый. Фәкать шулай тирәнтен сөргәндә генә әдипнең образын тулаем күзалларга мөмкин дигән фикердә бу рәссам. Әнә шул рәвешле, әдәбиятыбыз тарихын ныклап өйрәнү нәтиҗәсендә, рәссамыбыз Кол Гали, Утыз-Имәни, Мифтахетдин Акмулла образларын уңышлы иҗат итүгә ирешә. Бу язучыларның портретларына карагач, аларның нәкъ борынгы заманда яшәгән хөр фикерле шагыйрьләр икәнен, олуг философлар икәнен бернинди шигең-шөбһәң калмый. Т. Хаҗиәхмәтов ясаган портретлардагы шәхесләр бер-беренә һич тә охшамыйча һәм һәркайсы бүгенге көнгәчә сакланган поэзияләренә, моңнарга лаек булып күз алдына килеп басалар. Язма поэзиябезгә нигез салучы бөек шагыйрь Кол Галинең 800 еллыгы уңае белән ЮНЕСКОның информацияләр бюллетенендә нәкъ менә Т. Хаҗиәхмәтов эшләгән портреты канунлаштырып бирелү факты үзе генә дә рәссамның дөнья күләмендә олы җиңүгә ирешүен исбатлый.

Тавил Хаҗиәхмәтов башкарып чыккан һәр китапта оста рәссамның почеркы, югары культурага ия булган кулы сизелә. Шул ук вакытта ул китапларның һәркайсы үзенчәлекле, гаҗәеп оригиналь бизәкләре белән бүтәннәрдән һичшиксез аерылып тора. Менә Дәрдмәнднең «Исә җилләр» дигән исем белән дөнья күргән мәҗмугасы; биш бүлеккә ясалган биш рәсемнең һәрберсе яңа әсәрләр дөньясына алып керә һәм шул бүлектә чагылган төп идеяне тасвирлый. Һади Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы оригиналда һәм рус телендә аерым басма итеп бирелгән. Анда шигъри юллар бик иркен урнашып, күп очракта мәгънә ягыннан бер бөтен тәшкил итәләр. Ә инде рәсемнәргә килгәндә, алар фәкать бөтендөнья хезмәт ияләре кичергән олуг кайгы — бөек Ленин вафат булу сәбәпле матәм көннәренә багышланган: менә 21 гыйнвар — ал байраклар түбән иелгән, яше-карты олы кайгы кичерә...

Сибгат Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дип аталган шигырьләр җыентыгы да Такташ китабына авазداш сыман тоела. Бу җыентыкны матурлау-бизәүдә рәссам шул тикле камиллеккә ирешә ки, әлеге басма башкалада үткәрелгән конкурста II дәрәҗә дипломга лаек табыла. Патриот шагыйрь Муса Җәлилнең 70 еллыгына багышлап татар һәм рус телләрендә аерым-аерым «Моабит дәфтәрләре» бастырып чыгарыла. Бу басмаларда рәссам авторның үз-үзен аямыйча Ватан азатлыгы өчен фашизмга каршы көрәшен аермачык чагылдыруны максат итеп куя һәм шул изге максатына ирешә дә: Мусаның автографы да, кан белән язылган искиткеч шигъри юллар да, ул юллар иҗат ителгән шартларны чагылдырган гомуми кырыслык та, китапның оформлениесен куәтләп, героик симфония тәшкил итәләр. Бу басманы кулына алган бер генә кеше дә тетрәнү кичерми калмагандыр.

Т. Хаҗиәхмәтов китапларны аерым сувенир басма итеп әзерләгәндә, нәкъ менә халыкчанлыкка, илаһи гадилеккә, бөек самимилеккә ишарә ясый. Талантлы замандашыбыз Туфан Миңнуллин җыйган лирик җырлар китабы «Сандугачым-былбылым» да Т. Хаҗиәхмәтов оформлениесендә искиткеч бер камил төс алган.

Табигый таланты һәм хезмәт сөюе аркасында Тавил китап бизәү эшендә искиткеч зур камиллеккә ирешә һәм әнә шуның белән татар китабының культурасын бер баскычка югары күтәрә.

Әмма Т. Хаҗиәхмәтовның яулаган үрләре әле моның белән генә дә чикләнми. Ул «Ялкын» журналын матурлау-бизәү эшендә дә үзенең көч-сәләтен күрсәтә. Бүгенге көндә журналның һәрбер санын балалар гына түгел, олылар да ихлас күңелдән яратып карый һәм укый. Бу журналның оформление ягыннан илебез күләмендә үткәрелгән конкурста икенче урынны яулап алуы үзе генә дә күпне аңлата булса кирәк. Рәссам һәр санда матурлык-гүзәллеккә яшь буынның күзен ачарга, эстетик белем бирергә тырыша. Тематик яктан бу рәсемнәр искиткеч бай. Арада укучыларны интернациональ рухта тәрбияләү максатын күздә тотып эшләнгәннәре дә аз түгел. Әнә шулардан авыз иҗатына багышланганнарын «Тылсымлы чишмә» дигән исем белән 1984 елны махсус китап итеп чыгарырга мөмкин булган икән, бу инде рәссамның эшләгән эшләре ни дәрәҗәдә югары икәнне күрсәтә. Әлеге китапны татар халык мәкальләре җыелмасы булган «Хезмәт батыр» белән янәшә куярга мөмкин. Аныкы да Тавил рәсемнәре белән чыкты, аныкының да тәрбияви роле әйтеп бетергесез зур.

Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Тавил Хаҗиәхмәтовның дәртләнеп эшли һәм яңадан-яңа үрләр яулый торган чагы.

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ.**



Багъбостан Мөэминова мәктәбе
(Трофимов тыкрыгы, 9 йорт)

# БАГЪБОСТАН МӘКТӘБЕ

Оренбургның Трофимов тыкрыгы. Әллә ни күзгә ташланып тормаган йорт. Беренче карашка ул күршеләреннән берни белән дә аерылмый кебек. Әмма беренче карашка гына. Заманында халык теленә «Багъбостан мәктәбе» булып кергән әлеге бина мәгариф тарихында үзенчәлекле урын били.

Бишенче елгы революциянең шифалы җилләре тәэсирендә бу бинада татар кызлары өчен Оренбургта беренче җәдит мәктәбе ачыла. Күренекле шагыйрь Сәйфи ага Кудаш сүзләре белән әйткәндә, «татар романнарының берсендә аллә кайчан ук героиня булып тасвирланырга хаклы» Багъбостан Вилдан кызы Мөэминова оештыра ул мәктәпне.

Күп гасырлар буе абыстайлардан дин сабагы алган меңәрләгән татар кызларына бары тик Бишенче елгы революциядән соң гына дөньяви мәктәпләрдә уку мөмкинлеге ачыла. Дөрес, аңа кадәр үк кайбер кызларыбыз Петербург, Мәскәү, Казан гимназияләрендә, төрле югары курсларда белем алганнар. Касыймнан Сара Шакулова хәтта Париждагы мәшһүр Сорбонна университетында уку шәрәфенә ирешә. Әмма андый бәхетле кызлар санаулы гына була.

Хатын-кызларга, бигрәк тә рус булмаган халыкларга белем бирү юлында кыл да кыймылдатмау гына түгел, бәлки дистәләрчә кирталәр куйган патша хөкүмәте тыюларын җиңеп, карагруһ дин әһелләренең бәддогасыннан курыкмыйча, халык мәгарифе мәйданына аяк баскан татар хатын-кызлары XX йөз башында күренә башлый. Элек Вятка губернасына кергән Иж-Буби авылындагы беренче кызлар мәдрәсәсе укытучысы М. Нигъмәтуллина, Казанда татар кызлары өчен ачылган икенче мәктәпне оештыручы Л. Хөсәенова, кызлар гимназиясе ачу теләге белән янып, озак вакытлар Петербург-Казан чиновникларының бусагасын таптап, теләгенә ирешкән Ф. Аитова, Петербургның Мариинский гимназиясен тәмамлап, Буа өязендәге Бикмураз авылында рус-татар мәктәбе ачкан Ш. Зәмдиханова, М. Мозаффария, А. Мәхбүбҗамал, И. Гайнуллина, М. Мөштәриева, М. Сәгыйтова, Ф. Адамова һәм Бәгъбостан Мөэминова — әнә шундыйлардан. «Һәммәсе татар хатыны тәрәккыятенең алгы сафына чыккан мөхтәрәм затлардыр», дип язды алар турында Галимҗан Ибраһимов.

Татарстанның хәзерге Азнакай районы Мәндәй авылының ярлы крестьян гаиләсендә бишенче бала булып 1884 елда дөньяга килгән Багъбостанга, теләгенә ирешү өчен, нинди генә каршылыкларны җиңәргә, диндарләрнең нинди генә кара ялаларына дучар булырга туры килмәгән. Ләкин батыр йөрәкле Багъбостан өркеп калмый: хатын-кызлардан тарихта беренче тапкыр буларак, Диния назарәтендә имтихан тотып, мөгаллимәлек хокукы ала, кызлар мәдрәсәләрендә уку-укыту эшләре белән танышу өчен Төркиягә бара һәм мөселман хатын-кызларыннан аңарчы һичкем аяк басмаган төрек хөкүмәте мәҗлесенең (парламентының) утырышында чыгыш ясый, үз мәктәбенең эше белән таныштыра.

Әнә шулай җан атып йөрү нәтиҗәсез калмый, әлбәттә. Бик тиз даны таралган Багъбостан мәктәбенә илнең төрле төбәкләреннән белемгә сусаган татар, үзбәк, башкорт һәм кыргыз-казах кызлары агыла. Ун ел вакыт эчендә аның мәктәбен 1212 кыз тәмамлап чыга. Шуларның 149 ы мәктәпне тәмамлап мөгаллимә булып эшли башлый. Шуның өстенә ул укытучылар хәзерләү өчен кыска вакытлы курслар да оештыра. Бу курсларны тәмамлаган 198 кыз да мөгаллимә булып китә.

Ш. Бабич хөрмәтләп, сөеп әйткәнчә, «мәктәп тотып үскән ханым» Багъбостан Мөэминова ялгызы гына бу эшләрне җиңеп чыга алмас иде, әлбәттә. Демократик татар матбугаты аның хатын-кызлар мәгарифе өлкәсендәге фидакарь эшчәнлеген хуплап каршы ала. Тормыш иптәше һәм революциягә кадәр төрле фәннәрдән дәреслекләр төзеп бастырган алдынгы укытучы, шагыйрь Гобәйдулла Рәдүдинең әчкерсез ярдәмен тоеп эшли ул. Оренбургтагы татар культурасы эшлеклеләреннән Риза Фәхретдинев, Фатих Кәрими, Кәбир Бәкер, Борһан Шәрәф, Нургали Надиев, Ибраһим Терегулов һәм башкалар да аңа һәрвакыт ярдәм кулы сузалар, мәктәбендә яки курсларында дәрес бирәләр.

Багъбостан Мөэминова мәктәбендә сабак алган йөзләгән хатын-кызлар Бөек Октябрь революциясеннән соң татар совет мәктәпләрендә эшлиләр, партия-совет һәм халык хуҗалыгының төрле тармакларында җиң сызганып хезмәт итәләр.

*З. Мөхәммәтҗанова рәсеме,*
*Җ. Миңнуллин тексты.*

## Фәридә Салитова

# ТЕАТР ҺӘМ МУЗЫКА

Татар драма театры үткән юл музыка сәнгате белән аерылгысыз бәйләнгән. Төзелгән көненнән үк ул үз тирәсенә халыкның иң яхшы иҗат көчләрен туплый, милли профессиональ музыка үсешенә шартлар тудыра. Беренче татар музыкантлары һәм булачак композиторлар «Сәйяр» һәм «Нур» труппалары янында инструменталь ансамбльләр оештыралар. Тәнәфесләрдә популяр классик музыка, маршлар, бию көйләре, халык җырларыннан тезмәләр яңгырый. Соңрак музыка спектакльләргә дә үтеп керә һәм музыкаль-драматик пьесалар театр репертуарында аерым урын тота башлый. Тора-бара алар үзенчәлекле милли музыкаль драма жанры тууга китерәләр.

Татар музыкаль драмасының нигезе халык уеннарына, музыка һәм театр элементлары сакланган йолаларга: барыннан да элек җыенга һәм сабантуйга, җыр фольклорының кайбер төрләренә (мәсәлән, кара-каршы җырлау) барып тоташа. Ә драмада халык музыкасын файдалану мөмкинлегенә иң элек драматург Мирхәйдәр Фәйзи игътибар итә. Аның 1917 елда куелган «Галиябану» музыкаль драмасы җырның поэтик һәм образлы эмоциональ эчтәлегенә нигезләнә. Спектакль барышында яңгыраган халык көйләре революциягә кадәрге татар авылының көнкүрешен сурәтләүдә киң мөмкинлекләр ача. Кайбер көйләр авыл яшьләренең кичке уены кебек күренешләрдә фон хезмәтен үти. Башыннан ахырына кадәр диярлек якты, лирик тонда яңгыраган шул аһәң соңгы күренештә трагик төсмер ала, геройлар язмышындагы фаҗигане тагын да тирәнрәк кичерешләр дулкынына күтәрә.

«Галиябану»дагы музыка — М. Фәйзи әсәрләре буенча куелган башка спектакльләрдәге кебек үк, тамашага бизәк кенә түгел, ә бәлки аның мөһим компоненты, аерылгысыз өлеше. Һәр яңалыкны сизгер тотып ала белгән Галимҗан Ибраһимов та драматургның хәрәкәт белән музыканы органик куша алуын, шулай итеп әсәрләрендә эмоциональ тәэсир көчен һәм халыкчанлыкны көчәйтүен билгеләп үткән иде.

Беренче татар профессиональ музыканты, композитор һәм педагог Солтан Габәши спектакльләргә оригиналь музыкаль оформление булдыруда мөһим өлеш кертте. Г. Рәхим һәм Ф. Бурнашның «Бүз егет», «Таһир-Зөһрә» пьесалары буенча «Сәйяр» труппасы куйган постановкаларда төрле вокаль һәм инструменталь номерлар да яңгыраш тапты.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң татар драма театры милли профессиональ музыканы үстерүнең төп мәйданына әверелде. Октябрьдән соңгы унъеллыклар Татарстанда драма һәм музыка сәнгатенең үзара тәэсир итешүе, бер-берсен баетуында якты сәхифәләр булып калды. 1922 елда Татар дәүләт драма театрында (соңрак Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры) татар совет музыкасы классигы Салих Сәйдәшевның музыкаль бүлек мөдире һәм дирижер сыйфатында иҗади эшчәнлеге башланды. Шушы чордан театр сәхнәсендә эзлекле рәвештә музыкаль-драматик спектакльләр куела, алар репертуарда төп урыннарны ала. Композитор алтмыштан артык музыкаль сәхнә әсәре иҗат итә.

Егерменче еллар башында театрда тәүге тапкыр профессиональ музыкантлардан симфоник оркестр оештырыла, вокал һәм музыка теориясе буенча актерлар белән дәресләр үткәрелә башлый. Ул еллардагы музыкаль драматик репертуар милли сәхнә сәнгатендә аерым урын тотучы, синтетик пландагы башкаручыларны үстереп чыгарды. Талантлы артистлардан С. Айдаров, Г. Әлмөхәммәтов, Г. Кайбицкая, Р. Кушловская, С. Садыйкова һәм башкалар иң югары актерлык осталыгына ия булып кына калмыйча, вокал һәм еш кына хореографиядә дә камиллеккә ирештеләр.

Салих Сәйдәшевның күренекле драматурглар Фәтхи Бурнаш, Таҗи Гыйззәт һәм бигрәк тә озак еллар буена театрның баш режиссеры булып эшләгән Кәрим Тинчурин белән нәтиҗәле иҗади дуслыгы ТДАТ спектакльләрендә музыка һәм драманың гармонияле кушылуына сәбәп булды. Музыка һәм хореография чараларын актив куллану тамашачыны мавыктыру һәм күңел ачу өчен генә файдаланылмый, ул халыкның үткәнен һәм бүгенгесен тагын да аңлаешлырак, социаль конфликтларны тагын да калкурак күрсәтүгә хезмәт итә иде. «Башмагым», «Асылъяр», «Сак-Сок» һәм башка музыкаль драмаларга С. Сәйдәшев язган музыка бу әсәрләрне яңача яңгырату мөмкинлеге бирә, катлаулы сюжет коллизияләрен калку итеп гәүдәләндерә. Музыканың драматургиядәге функциясе үсә бара. Фольклор нигезеннән файдаланса да, спектакльләрдәге ариягә тартым вокаль формалар, ансамбльләр, оркестр һәм хор эпизодлары композиторларның халык көйләренә гаять дәрәҗәдә иҗади якын килүне таләп итәләр.

Егерменче елларның икенче яртысы татар сәнгатендә музыкаль драманың чәчәк атуы белән тарихка кереп калды. Бу әсәрләр республикада гына түгел, ә театр гастрольләре вакытында Советлар Союзының башка төбәкләрендә дә киң җәмәгатьчелекнең югары бәясенә лаек булдылар.

1926 елда К. Тинчурин һәм С. Сәйдәшевның «Зәңгәр шәл» музыкаль драмасының премьерасы күрсәтелә. Милли сәнгатьтә беренче тапкыр буларак, анда образның эволюциясе музыка чаралары белән күрсәтелә. Булат характерындагы үзгәрешләрне музыкаль гәүдәләндерү өчен композитор аның вокаль партиясенә революция елларындагы җырлар һәм маршлар аһәңен дә кыю кертә. «Зәңгәр шәл»нең музыкаль драматургиясендә умыртка сөяген Булатның өч ариясе тәшкил итә. Алар спектакльнең идея һәм эмоциональ-мәгънә үзәген тәшкил итеп, тамашачының игътибарын кульминация нокталарына юнәлтәләр.

«Наемщик» музыкаль драмасы (1928 ел) С. Сәйдәшевның театр өчен язган башка күләмле әсәрләре шикелле үк оригиналь музыкага нигезләнгән. Т. Гыйззәтнең киң колачлы халык драмасын музыкага салганда, композитор рус классикасының опера эстетикасы принципларына таянып эш итә. Спектакльнең төп музыкаль күренешләрен яңгырашы белән үзара бәйләнгән, әмма тәэсир көче белән нык аерылып торган халык хоры тәшкил итә, аның тирәсендә башка номерлар оеша. Күренешләр алышынган саен, халык образы эволюция кичерә, героик-драматик образлар өстенлек ала. Сурәтләү чараларында баш геройларга бирелгән номерлар мөһим. Менә Батырҗан партиясе. Аның тәүге ариясе беренче хорның кырыслыгыннан героик күтәрелешкә борылыш ясый. Аннан соң ария спектакль буенча үтәли үсеш элементына әверелә, халыкның музыкаль характеристикасы булып яңгырый башлый.

«Ил» музыкаль драмасында (1929 ел) С. Сәйдәшев һәм К. Тинчурин яңадан татар халкының авыр үткәненә мөрәҗәгать итәләр. Ләкин бирелә дә шат күңелле җырлар, биюләр, якты лирик арияләр аз түгел. Сюжет нигезен болай кору сәхнә күренешләрендәге максатны композиторның үзенчә аңлавыннан, аны тар рамкалардан чыгарырга омтылудан килә. Шул ук вакытта музыка драматург һәм режиссерның ниятенә каршы килми, ул халыкның иң мәрхәмәтсез заманнарда да тормыш сөючәнлеген, киләчәккә ышануын гәүдәләндерә. «Ил»дәге музыкаль образлар утызынчы еллар совет сәнгатенә хас якты тормышчанлык белән сугарылган, аларда яңа тормыш, азат хезмәт шатлыгы гәүдәләнә. С. Сәйдәшевнең хәзерге заман темасына язылган спектакльләргә иҗат иткән музыкасында бу яңа тенденцияләр тагын да тулырак чагылыш таба.

һ. Такташның «Камил», Г. Кутуйның «Күк күгәрчен», Г. Минскийның «Шлем», Ш. Камалның «Таулар», Р. Ишморатның «Данлы чор», В. Киршонның «Җилләр шәһәре» пьесаларында җыр һәм маршлар аеруча киң урын ала, эчтәлекне ачыкларга ярдәм итә. Г. Зөлкарнәевнең «Өермә»сендәге кебек үк, аларның күбесендә оркестр башкара торган күләмле музыкаль номерлар — увертюра, бию сюитасы, антрактлар яңгырый. К. Тинчурин белән Р. Ишморатның «Тургай» пьесасында беренче бишьеллыклардагы төзелеш, анда иңгә-иң торып эшләүче күп милләт вәкилләре сурәтләнә. Композитор шушы теманы бөтен тулылыгы һәм үзенчәлеге белән чагылдыру өчен эзләнә, татар сәнгатендә яңа тематиканы музыка чаралары белән аңлатырга омтыла. Кайбер кыенлыклар булуга карамастан, байтак музыкаль номерлар үз-үзен аклый гына түгел, ә бәлки туган илгә мәхәббәт хисен җырлаучы массовый күренешләрнең тирән мәгънәви асылын ачарга ярдәм итә. Әсәр нигезенә салынган халыклар дуслыгы идеясе СССР халыклары биюләре темасына хореографик сюита белән тагын да баетыла.

«Кандыр буе» спектакле (К. Тинчурин, С. Сәйдәшев) бүгенге көнгә кадәр сәхнәдә заман темасын гәүдәләндерүче иң яхшы әсәрләрдән санала. 1932 елда куелган бу музыкаль драмада героик, лирик һәм жанр образлары — барысы бердәм оптимистик рухта яңгырый. Гомуми эмоциональ тон да, композиция дә, персонажлар составы да, көлкеле ситуацияләрнең күплеге дә — аны оперетта жанрына якынайта.

Көчле үсеш алган татар музыка сәнгате утызынчы еллар уртасында драма театры сәхнәсе белән генә чикләнеп калмыйча, күп жанрлы юл белән үсә башлый. 1939 елда Татар дәүләт опера һәм балет театры ачыла, музыкаль рольләрне башкаручыларның күбесе шунда күчә. Драма театры нигезендә драматик репертуар белән эш итә. Ләкин театр өчен музыка язу әле һаман да Татарстан композиторларының яраткан жанры булып кала бирә. Бу өлкәдә С. Сәйдәшев кенә түгел, төрле елларда А. Ключарев, Җ. Фәйзи, М. Мозаффаров һәм шулай ук театрның музыка бүлеге җитәкчеләре булып торган Ә. Абдуллин һәм Б. Мулюков уңышлы эшлиләр.

Татар дәүләт академия театрының хәзерге постановкаларында да музыка куллану тотрыклы традиция булып яшәп килә. Бу яктан Х. Вәлиуллин, А. Монасыйпов, Ш. Шәрифуллин һәм М. Яруллиннарның төрле спектакльләргә язган музыкасы аерым урын тота. Бер үк вакытта музыкаль-драматик спектакльләр кую дәвам итә. Театр сәхнәсендә кат-кат яңартылган бу әсәрләр үзләренең тормышчанлыкларын раслыйлар һәм безнең көннәрдә дә зур уңыш белән баралар. Театрның баш режиссеры, СССРның халык артисты

М. Сәлимҗановның күпкырлы иҗади эшчәнлегендә музыкаль драмаларга мөрәҗәгать итүе — очраклы хәл түгел. К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» һәм «Казан сөлгесе» пьесалары буенча, С. Сәйдәшев музыкасына нигезләп Ф. Әбүбәкеров тарафыннан эшләнгән музыкаль оформление белән куелган спектакльләрне тамашачылар, шул исәптән яшьләр дә, яратып карый. Хәзерге заман тамашачысын да милли традицияләр, халык тормышкөнкүрешенең нечкәлекләре, җыр һәм музыка, биюләр җәлеп итә.

Тагын шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: соңгы вакытта яңа әсәрләр тудыру юлы белән дә музыкаль-драматик спектакльләр куюх традициясен яңартырга омтылу сизелә. Аларның берсе сыйфатында «тере музыка» пьесасын (режиссеры К. Зәйнуллин) күрсәтергә мөмкин. Бу — Татар дәүләт академия театры һәм аның даими тамашачылары өчен гадәти үк булмаган спектакль. Баш рольдә Татар дәүләт филармониясенең дирижер Р. Салаватов җитәкчелегендәге симфоник оркестры чыгыш ясый.

М. Таҗетдиновның Салих Сәйдәшевкә багышлап язган бу пьесасы — биографик хроника гына түгел. Автор үз алдына мәшһүр композиторның тормыш юлын күрсәтүне генә максат итеп куймый, ә ул кичергән хисләрне музыкаль-драматик композиция белән тасвирларга, аның рухи дөньясын ачып бирергә омтыла. Спектакльләрдәге барлык сурәтләү чаралары С. Сәйдәшев иҗаты традицияләренең тормышчанлыгын, ул калдырган мирасның һич кимемәс сәнгатьчә кыйммәтен раслауга багышлана. Әсәрнең жанр үзенчәлекләрендә, оркестрның күп планлы яңгырашында, һәм ниһаять, музыканы тирән аңлаучы, күтәренке рухлы геройлар образында композитор иҗатының тарих белән, совет халкы язмышы белән җанлы бәйләнеше ачык чагылыш таба. Спектакльдәге вакыйгалар кырыс сугыш елларында, ә икенче өлеше халкыбызның иң якты һәм бөек бәйрәме — Җиңү көнен бәйрәм итү фонында бара. Шунлыктан, сәхнәдә тасвирлана торган моңсу мәхәббәт тарихы шәхси драма буларак кына кабул ителми. Пьеса кайсы ягы беләндер егерменче еллардагы музыкаль драмалар сюжетын хәтерләтә башлый. Миңа калса, монысы да очраклы хәл түгел, ә авторларның заманында С. Сәйдәшев музыкасы яңгыраган әсәрләрдәге ассоциацияне тудырырга омтылуы дип бәяләргә кирәк. Композиторның әсәрләре бөтен игътибарны замандашыбызның бай һәм күпкырлы эчке дөньясын яктыртуга юнәлтә.

Шулай итеп музыка һәм драма бәйләнешенең татар театр сәнгатендә тирән тамырлары бар! Бу җанлы традиция әле хәзер дә милли сәхнә осталары иҗатына көч бирә, илһам өсти.

**Сәлам Алишев**

# КҮРЕНЕКЛЕ ТАРИХЧЫ ҺӘМ ӘДИП

Күренекле тарих галиме һәм язучы Газиз Салих улы Гобәйдуллин Казанда 1887 елның 27 июнендә сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. 8 яшендә аны Казанның «Халидия» мәдрәсәсенә бирәләр. Ул анда гарәп, фарсы, төрек, татар телләрен өйрәнә һәм 1904 елда аны тәмамлап чыга. Бу елларда инде иске мәдрәсәләргә дә яңа фикерләр, алдынгы идеяләр үтеп керә башлый. 1905—1907 елгы революция якынлаша. Әтисенең мулла итәргә теләвенә каршы чыгып, Газиз дөньяви гыйлем алырга омтыла. 1906 елда ул сигез класслы гимназия курсы өчен үзлегеннән имтиханнар бирергә карар кыла. Төрле фәннәр буенча хәзерлек эшендә аңа студент-большевик Н. С. Гассар ярдәм итә. Зирәк акыллы егет тырышлыгы аркасында гимназия күләмендә имтиханнарны уңышлы тапшыра һәм 1909 елда Казан университетының юридик факультетына укырга керә. Университеҭта зур түземлек белән немец, француз, латин телләрен өйрәнә. Татар әдәби хәрәкәтеннән дә читтә тормый. Шул елларда ул матбугатта үзенең кыска юмористик хикәяләре, рецензияләре белән катнаша башлый.

Университетның юридик факультетында бер ел укыгач, ул тарихчы профессорлар М. М. Хвостов һәм Н. Н. Фирсовларның киңәше белән тарих-филология факультетының тарих бүлегенә күчә һәм алар җитәкчелегендә тарихи эзләнүләр алып бара башлый. Гыйльми тикшеренүләрендә аңа профессор Н. Ф. Катанов та ярдәм итә. Уку елларында ул үзен фәнгә чын күңелдән бирелгән, сәләтле һәм тырыш кеше итеп таныта. Уку белән бергә Газиз мәктәпләрдә балаларга тарих укытырга да вакыт таба. Студент елларында Г. Гобәйдуллин татар яшьләренең демократик иҗтимагый хәрәкәтендә дә актив катнаша. Күп көч түгеп, Ш. Мәрҗанинең 100 еллык юбилеена зур җыентык бастырып чыгаруны оештыра.

Дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып, Г. Гобәйдуллин 1916 елда беренче дәрәҗәдәге диплом белән университетның тарих бүлеген тәмамлый. Бу вакытка инде аның байтак тарихи, әдәби, публицистик әсәрләре дөнья күргән була. 1914 елдан башлап ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих укыта, ләкин университет бетергәч, аңа рәсми рәвештә дәүләт уку йортларында эшләргә рөхсәт итмиләр. Автобиографиясендә ул «властьлар миңа ышанычсыз кеше дип карыйлар иде, губернатор миңа, Казаннан китеп, үземә эшкә урнашырга кушты»,— дип яза. Тарихчы Троицк шәһәренә китеп, андагы укытучылар хәзерләүче семинарияләрнең берсендә укыта башлый, биш класслы татар мәктәбе «Вазифа»ның мөдире булып эшли.

Февраль революциясеннән соң ул Казанга кайта һәм Октябрь революциясенең җиңүен дә монда каршылый. Октябрь революциясе аңа фәнни-тикшеренү эшләрен киң җәелдерергә мөмкинлек бирә. 1917—1918 елларда аның «Тарих гомумидән корун әүлия», «Тарих әдьян», «Россия тарихы» һәм башка дәреслек китаплары, «Төрекме, татармы?» кебек фәнни хезмәтләре һәм хикәяләр җыентыгы басылып чыга. Чехларны Казаннан кугач, ул 1919 елда Казан университетының тарих кафедрасына аспирантурага керә.

1917—1919 елларда Г. Гобәйдуллин, татар тарихын тирәнтен өйрәнү белән бергә, марксизм-ленинизм нигезләрен үзләштерә башлый, шул нигездә Татарстан тарихының феодализм дәверен, аның үзенчәлекләрен тикшерә.

Г. Гобәйдуллинның дөньяга карашлары Октябрь революциясенә кадәр Казандагы татар милли интеллигенциясе һәм социаль мохит йогынтысы астында формалаша. Аңа шулай ук 1905—1907 еллар революциясе дә нык тәэсир итә. Бу чорда ул Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Колахмәтов һәм башка күренекле революцион-демократлар белән дуслаша, Х. Ямашев, С. Н. Гассар, Г. Сәйфетдинов кебек большевикларны да белә. Ләкин идеологик яктан ул алар дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Аның университеттагы остазлары Н. Ф. Катанов, Н. Н. Фирсовлар революцион хәрәкәттән читтә торалар, фән белән генә

шөгыльләнүне мәгъкуль күрәләр. Социаль чыгышы да моңа тәэсир иткән булырга тиеш. Революционер булмаса да, ул иҗтимагый хәрәкәттән дә читләшмәгән. Төрле түгәрәкләрдә катнашкан, мөселман укучыларының Бөтенроссия съездында Г. Гобәйдуллин Россия мөселман укучылары Союзы бюросының председателе итеп сайланган.

Октябрь революциясеннән соң Г. Гобәйдуллинның идея үсешендә яңа этап башлана. Шуның нәтиҗәсендә аның тарихи хезмәтләренең иң яхшылары да совет елларында иҗат ителгәннәр. Аспирантурада укыган чорда ул Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең даими әгъзасы итеп сайлана, укуын педагогик хезмәттән аермыйча Кызыл Армиянең Казандагы пехота курсларында укуукыту эшләре мөдиренең ярдәмчесе булып эшли.

Аспирантураны уңышлы тәмамлаганнан соң Г. Гобәйдуллин Көнчыгыш академиясендә, Көнчыгыш педагогия институтында һәм татар коммунистик университетында укыта. 1921—1925 елларда ул Татарстан АССР Җир эшләре комиссариатында авыл хуҗалыгы буенча укыту идарәсе начальнигы урынбасары, Мәгариф халык комиссариатының Гыйльми үзәге фәнни хезмәткәре һәм Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте председателе урынбасары вазифаларын башкара. Шул ук елларда аның зур гына фәнни хезмәтләре дөнья күрә: «Татар тарихы» исемле хезмәте 1922, 1924 һәм 1925 елларда өч мәртәбә тулыландырып басыла. Ул Гали Рәхим белән бергә өч кисәктән торган «Татар әдәбияты тарихы» исемле дәреслек китаплары да яза. Шул ук елларда Г. Гобәйдуллин татар тарихында сыйныфлар һәм сыйнфый көрәш темасын күтәреп чыга. «Татарларда сыйныфлар тарихы» дигән хезмәте партиянең Татарстан өлкә комитетының агитация бүлеге карары белән бастырыла.

Төрле сәбәпләр аркасында Газиз Гобәйдуллин 1925 елда гаиләсе белән Казаннан Бакуга күчеп китәргә мәҗбүр була. Монда ул Көнчыгыш тарихы буенча доцент итеп эшкә кабул ителә, ә бер елдан соң инде Әзербайҗан Югары Педагогия институтының тарихи-иҗтимагый бүлегенең деканы итеп билгеләнә. Тагын бер елдан соң ул профессор дәрәҗәсен алуга ирешә һәм Әзербайҗан дәүләт университетының Көнчыгыш факультеты деканы булып эшли башлый. Шул ук 1927 елда ул I Бөтенсоюз тюркология съездында катнаша һәм зур доклад белән чыгыш ясый. Октябрь революциясенең 10 еллык юбилеен Г. Гобәйдуллин тарихчы галимнәрдән беренче татар профессоры дәрәҗәсендә каршы ала. Аның докторлык диссертациясе булып «Үзбәк халкының килеп чыгышы мәсьәләсе» дигән хезмәте саналган.

1925—1926 елларда ул Үзбәкстанга югары уку йортларында эшләргә һәм Үзбәкстанның Гыйльми Үзәге Мәгариф Үзәк бюросы председателе итеп чакырыла, аны шулай ук Мәскәүгә СССР халыкларының этник культураларын һәм телләрен өйрәнү комитетына да чакыралар, ләкин ул Бакуда кала. Монда Г. Гобәйдуллин фәнни-педагогик эшчәнлек белән беррәттән, күп кенә җәмәгать эшләре алып бара; СССР Үзәк Башкарма Комитетының Коммунистик академиясе каршындагы тарихчы-марксистлар җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы, Көнчыгышны өйрәнү ассоциациясе члены, СССР халыкларының этник культурасын фәнни-тикшеренү институты, Татарстанны өйрәнү җәмгыяте члены һ. б. Ул тарихчы-марксистларның I Бөтенсоюз конференциясендә хәлиткеч тавыш бирү хокуклы делегат булып катнаша. Бөтен әзербайҗан Советларының XI съездына делегат була. Ә 1931—1933 елларда Әзербайҗан ССРның I чакырылыш эшче-крестьян һәм кызылармеец депутатларының Ворошилов районы Советының депутаты булып эшли. 1928 елда Г. Гобәйдуллин Сәмәрканд дәүләт университетының мөселман Көнчыгышы кафедрасының, ә 1930 елда Мәскәү университетының штаттан тыш профессоры итеп сайлана. Мәскәүгә, Сәмәркандка һәм Ташкентка барып-килеп лекцияләр укый, Көнчыгыш тарихы буенча махсус курслар, семинарлар алып бара. Бер үк вакытта күп кенә фәнни хезмәтләр язып бастыра. Алар рус, әзербайҗан, үзбәк, татар телләрендә дөнья күрә. 1934 елда Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты чакыруы буенча ул Казанга, Университетта һәм марксизм-ленинизм фәнни-тикшеренү институтында эшләргә кайта. Монда ул «Татарстан тарихы»н язуда катнаша. Ләкин бу эш туктатыла һәм Г. Гобәйдуллин яңадан Бакуга китә һәм С. М. Киров исемендәге Әзербайҗан дәүләт университетының Якын Көнчыгыш тарихы кафедрасы мөдире булып эшли башлый. Күренекле тарихчы, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Гобәйдуллин 1938 елның 16 сентябрендә вафат була.

Г. Гобәйдуллинның тарихи иҗатында берничә юнәлеш бар. Халкыбыз тарихының феодализм дәверен тикшерү белән бергә ул тарих фәне тарихы һәм тарихи чыганакчылык өлкәсендә дә актив эшли. Октябрь революциясенә кадәр дөнья күргән «Марко Поло турында тәҗрибә» — әнә шундый әсәрләрнең берсе. Шуңарга охшаган, ләкин икенче характердагы һәм әле 1910 елда ук язылган «Ибн Халдун һәм Аристотельның «Политикасы» дигән хезмәте дә Г. Гобәйдуллинның чыганаклар белән эшләүдәге беренче тәҗрибәләреннән иде. Ш. Мәрҗани турындагы мәкаләләре исә татар галименең тарих фәнен үстерүдә тоткан урынын, аның фәнгә, сәнгатькә карашларын ачып бирәләр.

Тарихи тикшеренүләрен Г. Гобәйдуллин совет чорында да дәвам иттерә. Ул 1922—1925 елларда чыгарылган Каюм Насыйри турындагы җыентыкларның оештыручысы һәм

авторларының берсе була. 1923 елда «Татар календаре» дип аталган хезмәттә ул Кулиев белән берлектә В. И. Ленин, М. Вахитов, К. Насыйри, Г. Тукай һ. б. турында мәкаләләр бастыра. Историография өлкәсендәге хезмәтләреннән аның «Идел буе төрки-татар телендә тарихи әдәбиятның үсеше» дигән хезмәте дә хәзергә кадәр әһәмиятен югалтмаган.

Икенче бер юнәлеш итеп тарихчының татарларда сыйныфлар тарихын өйрәнүен санарга кирәк. Г. Гобәйдуллин — «Татарларда сыйныфлар тарихы», «Татарларда сыйныфлар тарихы өчен материаллар», «Татарларда сәүдә сыйныфы тарихыннан», «Татарларда феодал сыйныфның таркалу тарихыннан» дип аталган хезмәтләр авторы. Бу хезмәтләрдә ул татар феодал җәмгыятенең сыйныфларга бүленешенең барышы, эксплуатация төрләре һәм башка мәсьәләләрне тикшерә. Татар җәмгыятенең элек-электән сыйныфлардан торганлыгын, алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең антагонистик характерда булуларын күрсәтү ул вакыт политик әһәмияткә ия булган мөһим мәсьәлә иде. Чөнки татарларда сыйныфлар юк, бөтен татарлар да бер мөселман халкы булып яшәргә тиеш дигән буржуаз пропаганданың шаукымы егерменче елларда да әле дәвам итә иде.

Тарихчы профессорның сыйнфый көрәш тарихын тикшерүгә багышланган хезмәтләре дә игътибарга лаек. Әйтик, ул Пугачев восстаниесе турында гына да биш хезмәт язды. Г. Гобәйдуллин Россия крестьяннарының һәм шул җөмләдән Татар крестьяннарының сыйнфый көрәшләрен Европа крестьяннары хәрәкәтенең бер өлеше итеп тикшерә.

Югарыда саналган хезмәтләре Г. Гобәйдуллинны марксизм-ленинизм методологиясе, тарихи материализм нигезендә эшләүче тарихчы итеп күрсәтәләр.

Г. Гобәйдуллинның тарихи иҗатында зур урын тоткан тагын бер юнәлеш — төрки халыкларның килеп чыгуы мәсьәләсе. Бу өлкәдә тикшеренүләрен ул бөтен гомере буена дәвам итте. Университетта укыганда ук ул «Дәүләтләрнең һәм милләтләрнең килеп чыгышы мәсьәләләре» дигән тема өстендә эшли башлаган була. Шуннан соңгы елларда да ул бу тема өстендә эшләвен туктаусыз дәвам иттергән. Аның борынгы болгарлар, хәзәрләр, татарлар, үзбәкләр һәм башкалар турында аерым әсәрләре бар. Мәсәлән, «Татарларның килеп чыгышына карата», «Татарларның килеп чыгышы һәм Алтын Урда», «Төрекме, татармы?» һәм башка хезмәтләре китап булып та, журналларда да басылганнар.

Г. Гобәйдуллин иҗатындагы тагын бер юнәлешкә тукталмый мөмкин түгел: ул да булса татарларда иҗтимагый фикер үсеше тарихын өйрәнү. Ул Мәрҗани, Насыйри эшчәнлеген янсә историографик әсәрләрне тикшерүдә генә түгел, ә бәлки татар иҗтимагый фикер үсешендә аерым урын алып торган темаларны өйрәнүдә дә чагылыш тапты. «Татар фикере тарихыннан», «Империалистик сугыш вакытында панисламизмның бетүе», «Яңа татар әдәбияты һәм Ф. Әмирхан», «Гаспринскийның идеологиясе мәсьәләсенә карата» һәм әдәбият тарихына багышланган хезмәтләре әнә шул мәсьәләне тикшерүгә багышланган. Бу хезмәтләрдә ул иҗтимагый-политик фикер үсешендә буржуаз юнәлешләрнең реакцион асылын фаш итә.

Г. Гобәйдуллин феодализм чоры тарихын өйрәнүче галим булды. XX гасыр башы татар тарихчылары күбрәк политик тарихны, ә Г. Ибраһимов революцион хәрәкәт тарихын яктыртсалар, Г. Гобәйдуллин бу темалар белән берраттән, социаль-экономик үсеш тарихына да зур игътибар бирде. Халкыбызның феодализм чорындагы социаль-экономик тормышын без күбрәк һәм тулырак итеп беренче тапкыр аның иҗатында күрәбез. Ул шулай ук беренчеләрдән булып татар әдәбияты тарихын өйрәнде, культурабыз тарихына яңа материаллар бирде.

Аның иҗаты тарихчы буларак та, язучы буларак та Октябрь революциясеннән соң киң колач алды һәм идея эчтәлеге ягыннан элеккеге этаптан аерылып торды.

Татарстанда марксистик тарих фәненең үсеше Г. Гобәйдуллин исеме белән тыгыз бәйләнгән. XX гасырның егерменче елларыннан башлап ул буржуаз методологиядән ваз кичеп, төрки халыкларның социаль-экономик үсеше тарихының мөһим мәсьәләләрен марксистларча аңларга омтылды.

Г. Гобәйдуллин — тарихчы галим булу белән бергә, әдәби иҗат белән дә актив шөгыльләнгән шәхес. Аның кыска юмористик һәм сатирик хикәяләре матбугатта 1907 елдан ук күренә башлыйлар. «Г. Газиз хикәяләре» исемле җыентык 1918, 1919, 1930, 1958 елларда басылды. Әдәбият өлкәсендә дә аның тоткан юлы, юнәлеше бар иде. Иң беренче чиратта ул юмор һәм сатира хикәяләре остасы иде. Г. Гобәйдуллин хикәяләренең күпчелеген искелектән, обыватель-мещан гореф-гадәтләреннән көлү тәшкил итә. Совет власте елларында ул үзенең сатира угын яшь Совет властена каршы төрле ысуллар белән астыртын көрәшүче эчке дошманнарга каршы юнәлдерә. Халык властеннан алтын-көмешләрен качыручы сәүдәгәр дә, большевикларның бетүен көтеп ятучы карагруһчылар да, чит илгә китәргә хыялланучы «эчке эмигрант» та һәм башка шундый кире типлар аның сатира угы астына алыналар, фаш ителәләр. Олы галим һәм үзенчәлекле язучы Г. Гобәйдуллинның күп әсәрләре, шул җөмләдән публицистик язмалары, тәнкыйть мәкаләләре һәм шулай ук кайбер тарихи хезмәтләре гарәп хәрефләре белән язылганлыктан, хәзерге укучы алар белән таныша алмый. Аларны барлап, туплап, хәзерге шрифтка күчереп, ә үзбәк, әзербайҗан телләрендә дөнья күргәннәрен, тәрҗемә итеп, яңадан бастырып чыгару — безнең киләчәктәге бурычыбыз.

# БҮГЕН ДӘ ХӘРӘКӘТТӘ



Күпкырлы иҗат эшчәнлеге алып барган Ф. Туйкинның тормышы һәм иҗаты мәдәниятыбыз тарихында мәгълүм урын алып тора.

Фазыл Кәрим улы Туйкин 1887 елның 22 июнендә Татарстанның хәзерге Лениногорск районы Зәй-Каратай авылында мөәзин гаиләсендә дөньяга килә. М. Әхмәтҗанов тарафыннан җыелган риваятьләр һәм документаль чыганакларга караганда Ф. Туйкинның ерак бабалары бу төбәккә Иж буйларыннан күчеп килгәннәр. Җиде яшендә әтисез калган Фазыл башта авыл мәдрәсәсендә, аннан — Уфада «Хәкимия», соңыннан Казанга күчеп, җәдит мәдрәсә «Мөхәммәдия»дә белем эстәгән. «Мөхәммәдия»дә ул татар әдәбияты һәм журналистикасы тарихында тирән эз калдырган шәхесләр: Фатих Әмирхан, Вафа Бәхтияров, Гарифҗан Мостафин, Нургали Мамин, Кашшаф Патиев, Ибраһим Биккулов, Ризван Ибраһимов (Алушев)лар белән бер чорда укый.

1904 елда Мөхәммәдия мәдрәсәсенең урта сыйныфын тәмамлагач Ф. Туйкин туган авылына кайта һәм 1909 елга кадәр мөгаллимлек итә. 1909—1911 елларда Ф. Туйкин Бөгелмә өязенең Ташлы авылында, 1911—1912 елларда Уфада, аннан Бөгелмә өязенең Кара Елга авылында балалар укыта. Февраль революциясеннән соң, ул укытучылык эшен Бөгелмә шәһәрендә дәвам итә һәм гомеренең соңгы елларына кадәр шәһәр мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбиятыннан дәресләр бирә.

Татар матбугатында Ф. Туйкинның беренче шигырьләре 1906-1907 елларда Уральск шәһәрендә чыккан «Фикер» газетасында дөнья күрә. Яңа революцион күтәрелеш елларында аның иҗаты аеруча активлашып китә. Әйтик, 1912 елда гына да аның дүрт китабы дөнья күрә. Казанда «Сугышчы Сатыш әфәнде» дигән хикәя, «Ватан каһарманнары» исемле драма, «Җырлар әхтәрисе» исемле җырлар җыентыклары һәм Уфада «Тормыш корбаннары» дигән тагын бер сәхнә әсәре басылып чыга. Шуннан соңгы 25 ел эчендә барысы өч китап: 1915 елда Уфада «Нардуган» исемле шигырь җыентыгы, 1919 елда Оренбургта абыйсы Кәбир Туйкин белән берлектә язган «Төрек тарихы» дигән дәреслек, Казанда 1922 елда «Салих бабай» исемле бабалар өчен бер пәрдәлек пьесасы дөнья күрә.

Нинди орлык чәчсәң, шундый уңыш аласың. Ф. Туйкин да нәкъ шул закончалыкны белеп яшәгән. Укучыларын әдәбиятны, тормышны яратырга, тарихны белеп үсәргә өндәгән. Тарих — бөтен фәннәрнең анасы, туган җирен яраткан һәр кеше — үз тарихын да белергә тиеш, дигән фикерне әйткән. Саный китсәң, Ф. Туйкинның күп әйбере тарихка нигезләнеп, патриотизм һәм горурлык хисләре белән сугарылып язылган.

Әйтик, «Ватан каһарманнары». Эпик характердагы, киң колачлы әсәр. Ул татарларның 1812 елгы Ватан сугышында катнашуына багышланган. Ил өстенә кара яу килгәндә аның иминлеген саклап, төрле милләт халыклары дәррәү дошманга каршы күтәрелә. Халык күңелендә ватандарлык, патриотизм хисләре өскә бәреп чыга. «Җеннәрен өзәргә», «көлләрен күккә очырырга», «муеннарын асларына китерергә кирәк». «Барыбыз да бер кашык каныбыз калганчы сугышабыз»,— ди авыл егетләре французларга каршы сугышка күтәрелгәндә. Ф. Туйкин бу хисләрне, билгеле, уйлап чыгармаган, бөек тарихи вакыйгада актив катнашкан татар халкының тормышыннан алган. Явыз илбасарларга карата һәркемдә әнә шундый нәфрәт уяна. Үзара киңәшеп сөйләшәләр дә, гап-гади бер татар

авылы ир-атлары дошманга каршы, ярсып, яуга күтәреләләр. Ил язмышы өчен җаваплылык, тирән оптимизм әсәрнең төп пафосын тәшкил итә.

Язучы үзенең бу әсәрендә мәхәббәт дигән изге хисне дә читләтеп үтми. Әсәр ахырында ике зур бәйрәм: авыл кешеләренең французларны җиңеп, күбесенең туган җирләренә исән-сау әйләнеп кайтуы, һәм Солтанкай белән Бибикамалның туе белән тәмамлана.

Кызганычка каршы, бу әсәргә хәзергә кадәр төпле анализ, гадел бәя бирелгәне юк әле. Әдәбиятыбыз тарихында бу әсәр хакында тарихи жанрга катнашы булмаган, тарихи шәхесләрсез, 1812 елгы Ватан сугышы турында барса да «бөтен вакыйга бер ерак татар авылында бара»[1] дию белән генә чикләнделәр. Дөрес, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан «Ватан каһарманнары» шул заман татар драматургиясе ирешкән дәрәҗәдән кайтышрак. Әмма аның әдәбиятыбыз, драматургиябез тарихында үз урыны, әһәмияте бар. Әсәр 1812 елгы Ватан сугышының 100 еллыгы көннәрендә дөньяга чыга. Әлеге факт үзе генә дә зур әһәмияткә ия. Ни өчен? Игътибар итик: бу олуг юбилей уңаеннан ул вакыттагы татар укучысына нинди тарихи драмалар яисә тарихи хезмәтләр тәкъдим ителгән соң? Драматургиябез тарихында «Ватан каһарманнары» әлегә кадәр 1812 елгы Ватан сугышына багышланган бердәнбер драма әсәре булып кала бирә. Ф. Туйкинның бу темага драма әсәре язуы да очраклы хәл түгел дип уйларга кирәк. Чөнки ул әле 1905 елда ук 1812 елгы Ватан сугышында катнашкан татар солдатлары тарафыннан чыгарылган мәшһүр «Рус-француз сугышы бәете»нең 1858 елда язылган нөсхәсен тапкан була. Бу — беренчедән. Икенчедән, шул елларда дөнья күргән кайбер тарихи хезмәтләрнең исемнәренә генә күз төшерик: Н. Дучинский «Мөбәрәк патша император I нче Александр 1812 елда», Е. Посилинин «Дин, патша вә Ватан өчен 1812 елда булган мөкатдәс сугыш». Рәсми тарих фәне 1812 елгы сугышта император, аерым полководецларның ролен тасвирлау, аларга мәдхия җырлау белән шөгыльләнгән вакытта Ф. Туйкин Россия империясендә икеләтә-өчләтә изүгә дучар ителгән халыкка, ягъни бөек рус халкы белән берлектә явыз дошманга каршы күтәрелгән һәм тарихның төп шәхесе булган халыкка драмада үзәк урынны бирүе үзе үк бик күп нәрсә турында сөйли. Әдипнең халык массаларының тарихтагы ролен тирән аңлавын ачык чагылдыра. Бу ноктадан карaганда «Ватан каһарманнары» нәкъ шул елларда бөек Тукай тарафыннан игълан ителгән

«Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез»,

дигән мәшһүр юлларына аваздаш. 1912 еллар — Россиядә хөкемдарлык иткән династиянең 300 еллык юбилее бәйрәменә хәзерлек белән мәшгуль килгән еллар икәнен дә истән чыгармыйк.

Ф. Туйкинның безгә мәгълүм булган тарихи әсәрләренең икенчесе «Сугышчы Сатыш әфәнде» хикәясе. Ул тагын да борынгырак дәвергә — болгарның тәмам тураздырылып, бөлгенлеккә төшү вакытына карый.

Хикәядә Болгар дәүләтенең тәмам бөлгенлеккә төшеп, туздырылып, нигездән үк җимерелүе турында бәян ителә. Әсәрнең сюжеты мавыктыргыч, кызыклы итеп корылган. Хикәянең беренче бүлегендә «Бетмәс-төкәнмәс һөҗүмнәр» нәтиҗәсендә Болгар җире хәвефкә төшсә дә, Болгар шәһәре әле гөрләп яши. Без моны хикәядәге кайбер персонажлар тарафыннан сөйләнгән сүзләрдән беләбез. Әмма беренче бүлектә төп вакыйга Болгар шәһәренең үзендә түгел, бәлки каядыр башкаладан шактый ерактагы Дәүләт исемле бер авылда бара.

Дәүләт авылы халкы иген игә, мал асрый. Ләкин халыкның тынычлыгы югалган. Һиндидер хәвеф көтелә. Менә-менә дошман яулары килеп чыгарлар да, аларның бөтен җир-суларын тартып алырлар сыман.

Һәрбер авылда булган кебек, Дәүләт авылында да бер аксакал бар. Аны авылдашлары сугышчы Кармыш агай дип, олылап, йөртәләр. Кармыш агай тыныч күренергә тырыша, халыкны да тынычландыра. Боларның батыр халык икәнен искәртеп: «Сугыш булса да борчылырга кирәк түгел, без инде дошман җиңә алудан үткән. Менә фәлән сугыш ничек куркыныч иде, анда да ирек бирмәдек, аның өстенә никадәр малларын алдык»,— ди. Кармыш бабайның сүзләре аның улы Сатышка бик нык тәэсир итә. Ул көннәр буе «йөгерек кара атына» атланып болыннарда сугыш уены уйный. «Әй, берәр сугыш булса» дип хыяллана.

Көннәрдән бер көнне Болгар иленә дошман килгәнлеге ишетелә. Болгар шәһәреннән, батыр ирләрне яуга чакырып, чапкыннар килә. Сатыш бу хәбәрне ишетү белән коралларын алып, атына атланып, Болгар шәһәренә чыгып китә. Юлда адаша, ялгыш дошман яулары өстенә килеп чыга. Әсир төшә. Ун ел гомерен әсирлектә үткәрә. Аннан соң кача. Ул кире әйләнеп кайтканда Болгар шәһәре дә, аның туган авылы Дәүләт тә урыннарында булмыйлар инде.

---

[1] Татар әдәбияты тарихы. 3 т. Казан, 1986. 382 б.

Әсәр тыныч хикәяләү тонында, өченче заттан язылган. Җөмләләр озын. Хикәя романтик рухта. Хикәянең стиле беркадәр борынгы. Шәрык әдәбиятын, «Мең дә бер кичә» шикелле әкиятләрне, легендаларны хәтерләтә. Ләкин төп вакыйганың тарихи булуы укучыны реаль дөньядан аермый, хикәянең ышандыру көчен арттыра. Хикәядә диалоглар аз. Ләкин булган кадәресе үзенчәлекле. Автор диалогларда «диде», «дип», «ди» шикелле ярдәмче фигыльләрне бик сирәк куллана. Бу яктан караганда, аның хикәясендәге диалоглар драма геройларының сөйләшүләрен хәтерләтә. Халык иҗатына тартым бик матур алымнар куллана.

Автор кайбер урыннарда, З. Бигиев әсәрләрендәгечә, турыдан-туры укучыга эндәшү ысулын да куллана. Мәсәлән: «Мөхтәрәм укучылар! Бу сугышчының да кем икәнен белергә телисездер инде?»

Ниһаять, хикәянең тарихилыгы нидән гыйбарәт соң? Автор үзе бернинди чыганакларны да күрсәтми. Вакыйганың елы да анык түгел. Дошманнарның кем булуы да билгесез. Болгар шәһәренең гөрләп яшәве һәм көннәрдән бер көнне җир йөзеннән юкка чыгу факты гына хикәянең тарихилыгын раслаучы бердәнбер дәлил. Дәүләт авылы — шартлы авыл. Болгар шәһәренең урнашкан җире дөрес күрсәтелсә дә, хикәядә бернинди дә тарихи документлар файдаланылмый булса кирәк. Автор күбрәк үз фантазиясе тудырган образларга, вакыйгаларга мөрәҗәгать итә.

Сугышчының сөңгеләр, кылычлары белән кораллануы, сунарчыларның тире киемнәр киеп йөрүе, яшүсмер егет Сатышның чын Болгар сугышчылары кебек ак чикмән киеп билен бәйләве, башына тирән бүрек, аягына күн итек киюе, кечкенә гәүдәле йөгерек атка атлануы һәм тагын башка бик күп детальләр Ф. Туйкинның Болгар тарихыннан шактый мәгълүматлы кеше һәм шул мәгълүматларны әдәби әсәрдә оста куллануы турында сөйли.

Ф. Туйкинның «Сугышчы Сатыш әфәнде» хикәясе туган илгә мәхәббәт, патриотизм идеясе белән сугарылган. Кайдадыр туган иле барлыгын тоеп яшәү кешеләргә караңгы әсирлектә нинди генә авыр, газаплы хезмәтләргә дә түзә алырлык куәт, яшәү көче бирә. Сатыш бөтен җаны-тәне белән туган иленә омтыла. Аның уйлары да, хисләре дә еракларда калган Ватаны, туган иле турында. Ниһаять, егет әсирлектән качу бәхетенә ирешә. Ләкин ул коточкыч фаҗигане, иң зур бәхетсезлекне — туган илне югалту кайгысын күтәрә алмый. Аның өчен инде яшәүнең бернинди кызыгы калмый. Ул туган ил туфрагына егылып, мәңгегә күзләрен йома. Автор әнә шулай итеп үзенең хикәясендә кешегә туган илсез яшәү юк дигән идеяне үткәрә.

Моннан тыш Ф. Туйкинның «Тормыш корбаннары», «Салих бабай» (балалар өчен) исемле кыска пьесалары бар. Ф. Туйкин шулай ук сәнәкчеләр вәхшәтенә нигезләнеп, тагын бер сәхнә әсәре яза. Ул әсәр — Карабаш һәм Бәкер авыллары укытучыларының, туганнан туган абыйлары Фатыйх һәм Хуҗаназыйр Туйкиннарның сәнәкчеләр тарафыннан атып (икенчесенең вәхшиләрчә җәзалап) үтерелүе тәэсирендә туа. Исеме дә «Мәгариф корбаннары» дип атала. «Без шул әсәрне («Мәгариф корбаннары»н) үзебез ике мәртәбә (соңгысын 1934 елның январенда Зәй-Каратай мәктәбе сәхнәсендә) уйнадык»,— дип язган иде Азнакайдан Әхсән ага Туйкин. Шушы ук фикерне Әнәс Туйкин да раслый. Ләкин әсәрнең кулъязмасы да, матбугатта басылган варианты да әлегәчә табылганы юк.

Әдәби жанрларның төрле өлкәсендә каләмен сынап караган, балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә җиң сызганып иҗат иткән әдип. Төрле газета-журнал битләренә сибелеп калган шигырь, җыр, легенда, поэмалар белән берррәттән хатын-кызларның укымышы, тормыш-көнкүреш шартларына кагылып, мәктәптә балалар укытуның торышы турында тирән уйланып язылган мәкаләләре белән дә танышканнан соң, Ф. Туйкинның гаять үткен күзле, киң карашлы, хезмәтен ихлас күңелдән бирелеп башкаручы булуына инанасың.

Халкыбызның рухи байлыгын, аның гасырлар буе тупланып килгән уй-теләкләрен, дөньяга карашын чагылдырган халык авыз иҗаты җәүһәрләрен җыю, өйрәнү һәм матбугатта чыгару — «гыйльми, мәдәни эшләрдә бөгелеп хезмәт итәргә белен буган Бөгелмә тел-әдәбият укытучысы»[1] Фазыл Туйкин эшчәнлегенең мөһим бер тармагы. Ф. Туйкин халык авыз иҗаты үрнәкләрен җыю һәм өйрәнүгә фольклористиканың тар бер тармагы итеп кенә карамыйча, мәсьәләгә киңрәк якын килә. Халык авыз иҗаты җәүһәрләренең гомумкультура өлкәсендә тоткан урынын, әһәмиятен ассызыклап, ул үзенең бер хатында: «Татар мәдәни байлыгының нәүбәт көтеп ята торган бу җанлы байлыгы киләчәк өчен күп кенә материаллар бирә алачак»,— дип яза (№ 938 Т, 11 б.). Татар фольклористикасы тарихында Ф. Туйкин беренче чиратта мең дә бер йөз җыр тупланган һәм өч тапкыр басылып чыккан «Җырлар әхтәрисе» (Казан, 1912), «Җырлар мәҗмугасы» (Уфа, 1914) һәм «Шура», «Безнең юл», «Мәгариф» кебек журналларда басылып чыккан мәка-

---

[1] Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 938 Т, 15 б. (Алга таба бу китапханәдәге кулъязма чыганакларының номерлары һәм бит саннары текстта җәяләр эчендә күрсәтеләчәк).

ләләре белән билгеле. Халык җырларына хас якты сагыш, туган илнең матурлыгына соклану хисләре белән сугарылган үз шигырьләрен туплаган «Нардуган» җыентыгы исә 1915 елда дөнья күрә. Ф. Туйкинның әдәби әсәрләренә Г. Ибраһимов революциягә кадәр үк игътибар иткән: 1914 елда үзе төзеп чыгарган «Яңа әдәбият» исемле альманахка, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Дәрдмәндләр белән бергә, Ф. Туйкинның да «Агыйдел буйларында» исемле шигыре кертелүе нәнә шул хакта сөйли. Ә 1922 елда Ф. Туйкин шигырьләре ике җыентыкта Г. Тукай, С. Рәмиев, М. Гафури, Н. Думави, С. Сүнчәләй, М. Укмаси, Ә. Сәгъди әсәрләре белән бергә басылып чыга.

Соңгы елларда билгеле булган фактларга караганда, Ф. Туйкинның бу өлкәдәге хезмәтләре югарыда санап үтелгән китап-җыентыклар белән генә чикләнми икән. Мәсәлән, ул 1918 елда «Ил әдәбияты» исемле җыентык төзеп Казанга җибәрә. Ләкин Г. Ибраһимов язганча, «Фазыл Туйкә иптәшнең «Ил әдәбияты» дип җыйган кыйммәтле материаллары байтак ятты-ятты да, басар өчен чара булмаганлыктан, рәнҗеп, шелтәләп үзенә кире сорап алды» (Әсәрләр, 5 т. Казан, 1978, 492 б.). Егерменче елларның икенче яртысында Ф. Туйкин «Озын көйләргә халык җырлары» һәм «Халык әдәбиятын гыйльми, әдәби яктан тикшерү» исемле хезмәтләр язып, Казанга, Гыйльми үзәккә җибәрә. Соңгысы дүрт табак чамасы күләмле, 11 бүлектән торган китап була. Гыйльми үзәк янындагы халык әдәбиятын карау комиссиясенә җибәрелгән китаплар арасында Ф. Туйкин тарафыннан җыелган 1200 чамасы мәкаль дә була (№ 938 Т, 22 б.). Ф. Туйкинның «Халык әдәбиятын гыйльми, әдәби яктан тикшерү» исемле хезмәтен замандашлары, билгеле фольклор белгечләре югары бәялиләр. Мәсәлән, Хәсән Гали бу хезмәткә язылган рецензиясендә (№ 938 Т, 19 б.) «Халык әдәбиятының теориясенә кайта торган мондый бер әсәр хәзергәчә татар телендә чыкканы юк. Шунлыктан бу әсәрне бастырып дөньяга чыгару бик матлуб» (кирәкле) дип билгеләп үтә. Әмма, кызганычка каршы, әдипнең югарыда саналган хезмәтләре, төрле сәбәпләр аркасында, дөньяга чыкмый калалар.

Ф. Туйкин халык авыз иҗатының бер өлеше булган балалар фольклоры турында да кызыклы гына фикерләр әйткән шәхес. Аның бу мөһим мәсьәләгә багышланган мәкаләсе 1927 елда «Безнең юл» журналында дөнья күрә. Мәкаләдә санамыш, такмаза кебек үзенчәлекле жанрларга билгеләмә бирелгән, аларның шигъри төзелеше һәм кыйммәте ачыкланган, кайбер үрнәкләренең килеп чыгышы турында да әһәмиятле мәгълүматлар теркәп калдырган.

Әдәбиятыбыз һәм тарихыбыз өчен кыйммәтле тарихи ядкарьләрне җыю һәм матбугатка чыгару өлкәсендә дә Ф. Туйкин мәгълүм эш күрсәткән шәхес. Дөрес, ул бу өлкәдә замандашлары — мәшһүр кулъязма китап мәҗнүне — Сәид Вахиди яки Вәли Зәбиров дәрәҗәсенә ирешмәде. Әмма бу юнәлештә дә аның исемен әдәбиятыбыз тарихы белән аерылгысыз итеп бәйләгән үз табышлары, үз казанышлары бар. Әйтик, XVII йөз татар әдәбиятының күренекле вәкиле шагыйрь Мәүлә Колый әсәрләре хакында беренче булып матбугатта фикер әйтүче Ф. Туйкин булды. Ф. Туйкин Татарстанның хәзерге Әлмәт районы Сөләй авылында XIX йөз урталарында яшәгән Вилдан Мөхәммәтьяров кебек әдәбиятыбыз тарихында аз билгеле шагыйрь турында да кызыклы мәгълүматлар теркәп калдырган. Гаять дәрәҗәдә мавыктыргыч итеп язылган һәм әһәмиятле тарихи мәгълүматларны үз эченә алган XVIII йөз татар тарихи ядкаре «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе»нең борынгы бер нөсхәсе сакланып калуына да без Ф. Туйкинга бурычлыбыз.

Ф. Туйкинның күпчелек әсәрләре һәм, гомумән, эшчәнлеге өчен хас булган тарихилык, тарихи тематика аның өчен ят түгел, ә табигый күренеш иде. Чөнки Ф. Туйкин әдәби әсәрләр иҗат итү, халык авыз иҗатын өйрәнү, борынгы кулъязмалар җыю белән бергә тарихи эзләнүләр белән дә теләп шөгыльләнгән шәхес. Тарихи хезмәтләреннән аның хәзергә кадәр сакланып калган һәм басылып чыккан бары бер китабы гына билгеле: ул туганы К. Туйкин белән берлектә язылган һәм 1919 елда Оренбургта дөнья күргән «Төрек тарихы» исемле хезмәт. Бу китап Бөтенроссия мөселман укытучыларының Икенче гомуми съездында кабул ителгән «Алты сыйныфлы ибтидаи мәктәп программасы»на туры китереп, дәреслек итеп, төзелгән.

Дәреслек революциягә кадәр үк языла башлый һәм ул өч кисәктән торган хезмәт итеп уйланыла. Кызганычка каршы, «Төрек тарихы»ның беренче — төрки халыкларның борынгы заманнардан алып Чыңгыз хан дәверенә кадәр булган тарихын тасвирлаучы кисәге генә басылып чыга. Калган ике кисәгенең язмышы әлегә кадәр билгеле түгел.

Китапның кереш өлешеннән Ф. Туйкинның тарих фәненә мөнәсәбәтен, аңа нинди югары бәя бирүен һәм әһәмиятен тирән аңлавын ачык күрергә була. «Тарих... бөтен фәннәрнең анасы вә иң әһәмиятлесеседер»,— дип язалар авторлар. «Ана сөте кадәрле үк кирәкле булган милли тарихымыз» «сәяси вә дини максадлар белән чуалтылган»,— дип искәртүләре белән авторлар үз чорында татар тарихы өлкәсендә туган хәлне дөрес аңлауларын күрсәтәләр.

«Төрек тарихы» үз заманы өчен традицион, мәгълүм тарихи чыганакларга нигезләнеп язылган хезмәт. Дәүләтләр, илләр тарихын асылда политик тарих рәвешендә

генә бәян итүе белән дә, бу дәреслек үз заманындагы татар тарих фәне өчен характерлы булган күренешнең ачык чагылышы иде. Әмма ул вакытларда дөнья күргән күпчелек тарихи хезмәтләрдән аермалы буларак, «Төрек тарихы»нда тарих фәненең төрле тармаклары турында кыскача мәгълүматлар бирелгән, тарихи чыганаклар турында да гомуми төшенчәләр китерелә, шулай ук тарих фәненең үсешенә мәгълүм күләмдә тәэсир итүче башка фәннәр, авторларның үз сүзләре белән әйткәндә «тарихка иң нык булышлык иткән фәннәр» дә атап үтелә. «Киләчәкне төшенер өчен, аның көзгесе булган үткәнне төшенергә кирәк» — авторларның төп фикерләренең берсе әнә шул. Әгәр Пушкинның тарихка илтифатлы мөнәсәбәт саклау — культуралылык билгесе, дигән карашын искә төшерсәк, Ф. Туйкин үз заманының иң культуралы кешеләреннән берсе булган дип, һич икеләнмичә, әйтә алабыз.

Тынгысыз җан Ф. Туйкинның эшчәнлеге югарыда язылганнар белән генә дә чикләнми әле. Соңгы вакытта аның, агасы Кәбир Туйкин белән берлектә, Татарстанда үсә торган төрле үсемлекләрдән гербарий төзүе һәм 350 ләп үсемлекнең татарча исем-аталмаларын туплавы да билгеле булды (№ 938 Т, 16 б). Ләкин аларның бу хезмәтләре дә үз вакытында дөнья күрми кала һәм хәзергә кадәр кайдалыгы да мәгълүм түгел.

Үткәннәр балкышы бүгенге көн призмасында чагылып, киләчәкне яктырта. Чынлап та, Әгәр йөз ел элек туган каләмдәшебез укучылары, туганнары хәтерендә матур истәлекләр мирас итеп калдырган икән, хезмәте белән безнең күңелләрдә бүген дә ихтирам уята алган икән — димәк, ул кеше дөньяга юкка килмәгән һәм юкка яшәмәгән.

«Минем әтинең (Ф. Туйкинның бертуган абыйсы Кәбир Туйкинның) унөч, Фазыл абыйның җиде баласы була. Моннан тыш, бездә әтиләрнең өлкән туганнарының балалары торып укый иде. Гаиләбез ел әйләнәсенә 32-35 кешедән тора. Һәм бу тату гаилә бары тик әбиебез вафатыннан соң гына икегә бүленеп яши башлады». Бу юллар Мәскәүдә яшәүче Әнәс Кәбирович Туйкин хатыннан.

Ф. Туйкинның Ташкентта торучы укучысы, кардәше Саимә Әхмәтова менә нәрсәләр яза: «Фазыл абыйдан 1929—33 елларда укыдым. Икенче баскычта ул безнең класс җитәкчесе иде. Дәрестән соң калып, шигырь язу, җыр түгәрәкләре оештыра. Дүрт юллы җырлар язып карагыз ди.

Исә җилләр, үсә гөлләр,<br>
Иртәләрен су сипкәч.<br>
Өзелә эчләр, түгелә яшьләр,<br>
Туган җир искә төшкәч.

«Игътибар иттегезме, ике юлы табигатьне тасвирласа, калган ике юлы үз уйларыңны аңлата»,— диюе әле дә хәтеремдә. Ул безне колхоз эшенә ярдәмгә алып бара иде. Җырлый-җырлый егерме-утыз көн кыр эшләрендә булышабыз. Гомумән, Фазыл абый сөйләшергә дә, җырларга да бик оста, күңелле кеше иде». «Җырлага оста иде»,— дигән сүзне икенче бер хат, абыйсы Кәбирнең улы — Әнәс Туйкин язмасы белән дә раслап китәргә була. «Фазыл абый шигырьләр язу белән генә чикләнми, көйләр дә чыгара иде. «Тургай» дип аталган җыр хәтердә калган. Җырның көен дә, сүзләрен дә үзе язды. Скрипкада — гармунда яки мандолинада үзе уйнап, үзе җырлый да иде». «1917 елда без яндык. Бөтен каралты-кураны яңадан төзергә туры килде,— дип дәвам итә Әнәс ага икенче хатында.— Йорт-җирне таудан таш чыгарып төзедек. Фазыл абый таш эшен дә, балта эшен дә, калай эшен дә, мич чыгаруны да үзе башкарды. Аннан өйрәнеп калган һөнәрләрне без әле дә кулланабыз».

«Тамыры нык агачның ябалдашлары куе була»,— ди халык. Фазыл Туйкинның бер улы Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булуын, икенче улының күп еллар мәктәп директоры булып эшләвен (хәзер ул да вафат), бер кызы, өч оныгының фән кандидатлары булуын әйтсәк — Туйкиннар нәселе, Туйкиннар фамилиясе абруеның һаман да югары, һаман да ил белән бергә булуын ачык аңларбыз.

**Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА,**<br>
**Җәүдәт МИҢНУЛЛИН.**

## Роберт Миңнуллин

# БАЛАЧАК ШАГЫЙРЕ

Күреп белмәгән әдип турында язу авыр икән. Хәтта ул бик танылган булса да, аның иҗатын яратсаң да, яхшы белсәң дә... Күренекле балалар шагыйребез Бари Рәхмәт хакында моннан ун ел элек «Татарстан яшьләре» газетасына бер тапкыр язып та чыккан идем инде. Ләкин ул шагыйрь турындагы гомуми уйлануларым гына булган икән. Дөресрәге, соклану хисләре генә булып чыккан. Әле менә яңадан укып карадым да, күңелдә ниндидер канәгатьсезлек калды. Бари Рәхмәтнең иҗаты мин элек уйлаганча гына түгел. Безнең әдәбиятта аның урыны, әлбәттә, түрдәрәк. Чөнки аның шигырьләре — балаларыбызның күңел түрендә. Ә инде балалар күңеленә юл табу, аңа үтеп керә алу бәхете бик сирәкләргә генә тия торгандыр.

Каләмгә тотыныр алдыннан аның китапларын яңадан бер тапкыр карап чыктым. Күбесен болай да беләм икән. Аның турында язылган мәкаләләрне эзләп карадым. Бик аз икән. Р. Кукушкин, Ш. Галиев мәкаләләре һәм юбилейлар уңаеннан чыккан кечкенә-кечкенә истәлекләр... Бармак белән генә санарлык. Шагыйрьнең замандашлары белән дә очраштым, каләмдәшләре белән сөйләштем... Хатыны Гайшә апа янына барып килдем. Кайбер истәлекләрен ул сөйләде... Сибгат ага Хәким белән сөйләшеп утырган чакларны искә төшердем. Балалар әдәбияты турында сүз чыкканда, Бари Рәхмәтне телгә алмый калмый иде... Акрын-акрын гына шагыйрьнең образы күз алдына килә башлады.

Тыйнак, йомшак табигатьле иде, диләр. Шаян сүзле, уен-көлкене бик ярата иде, диләр. Ничек алай булгандыр ул? Югыйсә, шаян табигатьле кешеләр күп сүзле була торган иде. Б. Рәхмәтнең сәхнәдән шигырь укуы бик күпләрнең исендә калган. Үз шигырьләрен укырга бик яраткан икән. Тукай клубында уздырылган шигырь кичәләрендә еш чыгыш ясаган. Радио аша да еш сөйли торган булган. Берәр язмасы сакланмаган микән дип белешеп караган идем, юк шул — сакланмаган. Бигрәк тә мәктәпләрдә — балалар алдында шигырь укырга яраткан ул. Шәүкәт Галиев истәлекләрендә менә мондый юллар бар: «Бари абыйның үз шигырьләрен сәхнәдән укыган чагы күз алдымда. Әле бер сүз әйткәнче үк, күзләре, ирен читләре белән елмаюга, халык җанланып куя, үзе дә сизмәстән елмаеп җавап бирә, рәхәт бер дулкынга көйләнә».

Шагыйрьләрне язмыш үзе сайлый. Күп бездә олы язмышлы, кызыклы язмышлы шагыйрьләр. Һәрберсе үзе бер тарих, үзе бер дөнья. Бер-берсенә һич тә охшамаган язмышлы шагыйрьләр. Яшь-яшь килеш әдәбиятка килеп дан-шөһрәт казанган талантлы шагыйрьләрне уйлый башласам, күз алдына Бари Рәхмәт баса, аның иҗат биографиясе күңелгә килә. Бөтенләй башка төрле язмышлы, әдәбият кануннарына бик үк сыеп бетми торган биографияле шагыйрь. Татар балалар поэзиясенең соңлап килгән бәхете.

Аның иҗат юлына караганда, тормышы баерак та, гыйбрәтлерәк тә икән. Иҗат язмышы башкаларныкы кебек булмаса да, биографиясендә башка әдипләребез белән охшаш яклар бик күп. 1897 елның 29 маенда хәзерге Казахстан ССРның Гурьев өлкәсендәге Жилая Коса поселогында туган малай шундагы мәдрәсәдә укып йөри. Татар дөньясының шаулаган чагы, мәдрәсә шәкертләренең дә яңалыкка, яктылыкка омтылган бер вакыты. Мәгърифәткә тартылган яшьләрнең Тукайны укып шашкан, канатланган чорлары. Бари да Тукай шигырьләрен укып белә, үзенең беренче өйрәнчек шигырьләрен дә язып карый. Өстәвенә, шушы якларга сөргенгә җибәрелгән, соңыннан балалар шагыйре һәм педагог булып танылган Фәрит Ибраһимов белән якыннан танышып ала. Танышып кына да калмый, аңардан русчага өйрәнә, татар әдәбияты белән ныграк таныша. Тукай белән ныклап кызыксынуы да шунда башлана. Бөек шагыйрьне яраткан, иҗатына табынган Ф. Ибраһимов ул вакытта ук инде, Тукайга ияреп, шигырьләр яза, ул шигырьләрен «Ак юл» журналында бастырып та чыгара. Аның Тукай һәм шигърият белән мавыгуы Барига да күчә.

Гомумән, Б. Рәхмәтнең балалар поэзиясенә килүенә Тукай, Фәрит Ибраһимов һәм «Ак юл» журналы сәбәпче булгандыр. Мөхтәрәм язучыбыз Нәкый ага Исәнбәтнең татар балалары өчен чыккан ул беренче журнал турында бик яратып, аны күкләргә күтәреп сөйләгәнен, журналның редакторы Фәхрелислам Агиевны олы хөрмәт белән искә алганын тыңлаганым бар. Бу — аңлашыла да. Нәкый ага шул журналны укып үскән, иң беренче ши-

гырьләрен шунда бастырган язучы. «Ак юл»дан башланган беренче тәҗрибәләре, татар балаларына булган олы мәхәббәте Н. Исәнбәтне балаларның зур әдибе итте. «Ак юл» — Бари Рәхмәтне дә әдәбиятка алып килгән игелекле журнал. Үзенең иҗатын ул 1914 елда басылган «Бәйрәм котлы булсын» дигән шигырь белән башлап җибәрә. Беренче шигырьләрен шушы журналда бастыра башлый, аның актив авторына әйләнә. Шуңа күрә дә үзен канаты астына алган әлеге журналга шагыйрь гомере буена рәхмәтле булып кала.

Шагыйрь язмышы! Илебездәге кискен борылышлар, үзгәрешләр, авырлыклар, көрәш юллары Бари Рәхмәтнең дә тормыш юлына эверелә. Кызылармеец, хәрби газета хезмәткәре, эшче, бухгалтер; Бөек Ватан сугышы юллары — солдат, хәрби корреспондент, госпиталь... Шагыйрьнең иҗат юлы гаять тә бормалы, сикәлтәле. Аның матбугатта шактый басылганнан соң да югалып торган чаклары күп була, бөтенләй онытылып та тора. Әмма шагыйрь күңелендә яткан хәзинә соң булса да тышка ташып чыга, шигырь китаплары булып укучылар күңеленә барып ирешә. Башлангыч чор иҗатында ул революцион күтәренкелек белән сугарылган шигырьләр иҗат итә. Соңрак лирик, сатирик һәм юмористик шигырьләр яза... Әмма сатира-юмор турында сүз чыкканда, без хәзер Бари Рәхмәт исемен телгә дә алмыйбыз диярлек. Ә бит аның сугыш елларында, шулай ук илленче-алтмышынчы елларда күп кенә шигырьләре халык арасында шактый популяр иде. Бигрәк тә үзешчән сәнгать концертларында еш яңгырыйлар иде алар. 1957 елда чыккан «Шигырьләр» дип аталган китабы укучыларның яраткан китабына әйләнде. 1916—56 елларда язылган шигырьләре тупланган йөз битле әлеге җыентык чын мәгънәсендә талантлы шагыйрь кулы белән язылган. Лирик шаянлык, тапкырлык, киная хәтта Бөек Ватан сугышы елларында язылган шигырьләренә дә килеп керә. Темасы, вакыйгасы белән лирик, моңсу, сентименталь булырга тиешле әсәрләрен дә оста гына итеп «елмайта» белә ул. Ирексездән, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи кебек шагыйрьләрнең шул елларда язылган шигырьләре искә төшә. Нишлисең, татар шагыйрьләре үлем белән күзгә-күз очрашкан вакытта да елмая белгәннәр. Дошманнан ачы көлү, җиңүгә тирән ышаныч, оптимистик рух, халыкчан шаянлык аның сагыну-сагышларына да, сугыш кырларында күргән газапларына да «елмаю» өсти. Бик күп фронтовикларны бәхетле иткәндер ул шигырьләр. Сугыш авырлыкларын, югалту газапларын вакытлыча гына булса да онытырып торганнардыр алар. Сугыштан соң да яратып укыдылар ул шигырьләрне. Б. Рәхмәтнең шулай ук сугыштан соң язган сатирик-юмористик шигырьләре дә Ш. Галиев, Г. Афзал кебек юмор осталары иҗаты белән аваздаш булды. Алар бүген дә актуальлекләрен югалтмаганнар.

Сатира-юмор белән балалар поэзиясе арасында ниндидер бер серле уртаклык бар. Үзендә балалык сыйфатларын саклап кала алган, балаларга хас шаянлыкны, тапкырлыкны, беркатлылыкны югалтмаган шагыйрь генә сатира-юмор әсәрләре яза аладыр мөгаен. Кайсы гына күренекле балалар шагыйрен алып карасаң да, үзләренең әдәби эшчәнлекләрен сатира-юмордан башлаганнар. Тукай, Маршак, Михалков, Ш. Галиев. Аларның һәркайсы, үзләре дә сизмәстән, танылган балалар шагыйрьләре булып киткәннәр. Шундыйлар арасында, әлбәттә, Б. Рәхмәт тә бар.

Ул бездә балалар әдәбиятына чын мәгънәсендә җитди хезмәт итеп караган, зур әзерлек белән килгән иң беренче шагыйрь булгандыр. Тукай иҗаты белән фольклорга гына йөз тотмыйча, ул рус поэзиясенә дә игътибар итә. Үзе белән бер чорда иҗат иткән К. Чуковский, С. Маршак, С. Михалков, А. Барто кебек шагыйрьләрдән дә балалар шигыренең серләренә өйрәнә, аларның кайбер шигырьләрен татарчага тәрҗемә дә иткәли. Нәтиҗәдә, Б. Рәхмәт татар балаларына — яңа шигъри дөнья, ә балалар поэзиясенә яңа шигъри сүз алып килде. Яңа шигырьләр, заманча шигырьләр иде алар. Тематик яктан да, образлар системасы ягыннан да, балалар психологиясен шигъри юлларга күчерү нисбәтеннән дә ул новаторлык үрнәкләре күрсәтте. Шигырьләрдә бала үзе күренә башлады. Бала сүзләре белән олыларча кыланучы яисә бала булырга тырышучы лирик герой түгел, ә чынчынлап Бала образы иде ул.

Балалар шигырендә риторика, гомуми газета лозунглары өстенлек иткән, балалар китаплары марш атлап йөрүче балалар, ура-шигырьләр белән чуарланган бер чорда аның шигырьләре кайберәүләр өчен, бәлки, сәеррәк тә булып тоелгандыр. Чөнки алар гадәти шигырьләр түгел иде. Ул чакта бит күп шагыйрьләр үзләре уйлап чыгарган балалар дөньясы белән балаларга якын килергә тырышып карадылар. Ләкин ул дөньяның ясалма булуы, чынбарлык белән туры килмәве тиз ачыкланды. Ә Бари Рәхмәт, киресенчә, әдәбиятка балаларның үзләреннән килде. Ләкин, һәрбер яңалык шикелле үк, Б. Рәхмәт шигырьләре дә соклану хисләре белән бергә аптырау да тудырды. Ышанмыйчарак караучылар да, җитешсезлек эзләүчеләр дә аз булмады. Гомере буена аз-маз гына язышып килгән, бер чакта да актив шагыйрьләр рәтендә йөрмәгән килеш ничек инде ул кинәт кенә талантлы шагыйрьгә әйләнсен? Картайгач каләмгә тотынган кешеләрнең кем икәннәрен беләбез, янәсе. Хәтта балалар матбугатында да аның шигырьләрен аңламаган очраклар була. Шигырьләре башкаларныкына охшамаган, балалар кабул итәр микән дип шикләнәләр. Шигырьләрен кире алып кайтып киткән чаклары да була шагыйрьнең. Алып кайтып китә дә шуларны ук балаларга укып карый. Яраталар! Ни өчен дисәң, шагыйрьнең шигырьләре кебек үк, балалар үзләре дә — заман балалары бит!

Г. Ахунов илленче елларда язган бер мәкаләсендә менә мондый бер факт китерә:

«Яшермичә әйтәм: балалар язучыларының әсәрләрен күп укыйлар, китапханәләрдән алып та, кибетләрдән сатып алып та укыйлар. Баулы китап кибетендә китаплар сатучы Мәрфуга Әминова иптәш балалар китапларына таләпнең зур булуын әйтте. Ә. Бикчәнтәеваның «Дачада», Бари Рәхмәтнең «Бакчада күңелле» исемле китапларын чират торып алып бетергәннәр. Ә алар Баулы кибетенә 10-15 данә генә түгел, икешәр йөз кайткан...»

Китабыңны чират торып алсалар, олы бәхет инде ул! Минем дә шул елларда исемә төште. «Якуп белән вакыт» исемле шигырьне ятлап, укучыларның район смотрында җиңеп чыккан идем. Ул вакытта шигырьнең авторын да искәрмәгән булганмын. Бари Рәхмәтнеке булган икән бит, рәхмәт яугыры! Әле үзе исән чакта ук аның иҗаты белән таныш булганмын икән. «Бакчада күңелле» исемле җыентыгын да яратып укыганмын. Әле шул елларда чыккан китапларын күргәч, яңадан искә төште. Һәрбер татар баласы кебек мин дә Бари Рәхмәт шигырьләрен укып үскәнмен.

Әйткәнемчә, безнең балалар поэзиясен Б. Рәхмәт яңа алымнар, яңа чаралар белән баетты. Мәсәлән, балалар шигъриятенә беренче булып циклар алып килде. Балалар әдәбияты белгече Равил Кукушкин үзенең «Канатлы дөнья» китабында шагыйрьнең бик күп үзенчәлекләрен ачып бирә. Менә шуларның берсе: «Шунысы әһәмиятле, Б. Рәхмәт әсәрләре балалар өчен дә, олылар өчен дә бердәй кызык. Зурлар өчен бала чакны искә төшерә торган җылы, мөлаем рухлы, елмаюлы шигырьләр... Ә балаларга алар дөньясын чагылдыруы, конкрет детальләргә корылуы, аларча фикер йөртүе белән кадерле».

Бүгенге шагыйрьләрнең шигырьләрен укып карыйм да, таныш рифмалар, таныш темалар, образлар, шигъри детальләр, таныш алымнар күзгә чалынып китә. Бигрәк тә — яшьләрдә. Шул исәптән, үземнекеләрдә дә...

Бер сөйләшү истә калган. Ничектер минем шигырьләр турында сүз чыкты. Шагыйрь дусларның берсе шактый гына мактау сүзләре әйткәннән соң, тәнкыйть тә әйтергә кирәк тапты. «Йолдызлар саныйбыз» исемле шигырьдән бер өзекне алды да, мондый санап китүләр шигырьнең бәясен төшерә дигәнрәк фикер әйтте. Киләчәктә санаулардан сакланырга киңәш итте. Шул чакны янәшәдә утырган Ш. Галиев, сүзсез утыруымнан файдаланып: «Ярар, ярар, искә алырмын!» — дип әйтеп ташлады. Бүлмәдә утыручылар әлеге сүзләрдән дәррәү көлешеп алдылар. Бу вакыйганы, Ш. Галиевнең әлеге кечкенә шаянлыгын искә төшерүем юкка гына түгел. Чөнки шагыйрь дустыбыз әлеге «кимчелек»нең балалар поэзиясендәге махсус бер алым булуын, бу шигъри алымның беренче үрнәкләре Б. Рәхмәт поэзиясендә үк кулланылганын белсә, уңайсыз хәлдә дә калмас иде. Бу алым — балалар шигырендә иң элек картина тудыру, шигырьдә сөйләнгән вакыйганы ныграк күз алдына китерү өчен кулланыла. Аннары ул шигырьнең хәрәкәтчәнлеген, динамикасын арттыру өчен дә кирәк. Ш. Галиевнең үзенең дә шактый шигырьләре чыннан да шул алым белән язылган. Яшь шагыйрь Афзал Нигъмәтуллинда да бар андый шигырьләр. Аннан соң киләчәк шагыйрьләрдә дә булыр дип уйлыйм.

Бари Рәхмәт, миңа калса, Тукай шәкерте. Әгәр дә игътибар беләнрәк карасаң, аның шигырьләре Тукайның балалар өчен язылган әсәрләре белән шактый аваздаш икәнен күрербез. Балалар шигърияте өчен кирәк сыйфатларның күбесен ул Тукайдан алган... һәм Шәүкәт Галиевкә тапшырган. Б. Рәхмәт — балалар әдәбиятында Тукай белән Ш. Галиев арасында торучы, аларның иҗатын бергә тоташтыручы шагыйрь. Ул үзенең шигырьләрен балалар поэзиясенә Шәүкәт Галиев килсен өчен яза башлагандыр кебек. Аны кызыксындырыр өчен, балалар шигыренең мөмкинлекләрен, аның серләрен сөйләр өчен, балалар поэзиясе пәрдәсенең бер читен ачып күрсәтер өчен язгандыр кебек. Әгәр дә поэзиядә Бари Рәхмәт булмаса, Ш. Галиев балалар өчен яза башлар иде микән? Ә бит Б. Рәхмәт шигъри эстафетаны, чыннан да, Ш. Галиевкә тапшырып китә.

«Бари Рәхмәт табутын алган самолет Мәскәүдән Казанга юнәлде. Балалар язучысы Гариф ага Гобәй белән икәүләп без шагыйрьне Туган җир өстеннән, йолдызлар астыннан озата кайттык. Бари аганың күккә соңгы күтәрелүе иде бу, минем исә, беренче очуым булды. Ул чакта минем балалар өчен бер юл да язганым юк иде. Бу хакта уйлыйм да хәзер, ниндидер мәгънә күргәндәй булам. Әйтерсең лә, шушы биеклеккә Бари Рәхмәт үзенең сүзсез васыятен иңдергән...» Күренекле балалар шагыйре Шәүкәт Галиевнең үз сүзләре бу.

Ә Бари Рәхмәт 1957 елның 26 маенда, 60 яше тулырга өч көн калганда вафат булды. Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә. Зур залның сәхнәсендә, кайнарланып шигырь укыганда. Шигърияте чәчәк аткан бер вакытта. Олы иҗат дәрте белән янып йөргәндә. Әмма аның үлеме дә шигъри үлем булды. Кайнап торган бер халәттә, тантаналы шигъри мохиттә йөрәге тибүдән туктады. Шигъриятен турыдан-туры шигырь сөючеләргә калдырып китте ул. Көчле кул чабулар, алкышлар астында. Ул алкышлар шагыйрьнең үлеменә түгел, аның татар балаларына калдырган үлемсез иҗатына иде.

Аның шигырьләре бүген дә дәресләрдә, мәктәп сәхнәләрендә, балалар бакчаларында яңгырый. Радио-телевидение тапшыруларында сөйләнә. Китаплары чыгып тора. Менә әле дә Татарстан китап нәшриятының быелгы планына аның яңа китабы кертелгән. «Балалар китапханәсе» сериясеннән чыгачак ул. Шул сериядән Тукай белән Ш. Маннур китаплары дөнья күргән иде. Инде менә — Бари Рәхмәтнеке! Димәк, аның шигырьләрен яңа буын балалары да укыячак.

**Розалия Нуруллина**

# ТУГРЫЛЫК

«Бик әйбәт булган». Тамак төбендә тоткарланыбрак чыга торган тонык тавыш белән әйтелгән бу сүзләр әле һаман ишетелә төсле... Гази ага Кашшаф нинди дә булса бер яңа хәбәр ишетсә, шулай ди торган иде. Яхшы хәбәрме, берәр әшәкелек турындамы — барыбер! Бары әйтелү рәвеше һәм тавышының төсмере генә аның бу хәбәргә мөнәсәбәтен белдерә. Менә шушы сүзләр, минемчә, Гази Кашшафның характерын да, тормыштагы позициясен дә аңларга ярдәм итә. Ул сабырлык белән, кешеләргә яхшылык теләп, миһербанлы яшәде.

Гази абый бик тыйнак, атылып-бәрелеп гаепләргә ашыкмый, хәтта кайчагында артыграк сабыр дип тә уйланыла иде. Ләкин менә хәзер аның эшләрен, сүзләрен хәтердән кичергәндә күренә: сабырлык аның үзенә бик җиңел булмаган, башкаларны аяганга үзен кулда тоткан ул. Әмма кирәк чакта, дәшми мөмкин булмаганда, мәсьәләне хәл итү өчен аның сүзе таләп ителгәндә, ул гадәтенчә салмак кына, ләкин катгый карарга килеп үз фикерен әйтә иде. Шулай бер чакны тарих-филология факультетының партия җыелышында ниндидер студентка карата гаять кискен чара күрү турында сүз барды. Эшнең инициаторы — декан урынбасары Ренат Газиевич Кашафетдинов. Студентны яклап сөйләүчеләр булды, ләкин Ренат Газиевич үз фикереннән кайтмый. Шуннан бер мәлне бөтен зал тынып калды — трибунага Гази Кашшаф атлый иде...

Гази ага гаделсезлекне үзе эшләми генә түгел, ул барында башкалар да йөгәнсезләнергә җөрьәт итмиләр иде. Аның өлкән буын язучыларыбызга хас бу сыйфаты — кешелеклелек дәрәҗәсен югары тоту, идеалга тугрылык, татар әдәбиятының сафлыгын саклауга да хезмәт итте.

Гази Кашшафның дүрт дистә ярым ел дәвамында әдәбиятка күрсәткән хезмәте — киң күңелле һәм кешелекле яшәешнең иң дәлилле мисалы. Ул тәнкыйтьче буларак танылды. Авыр, мәшәкатьле һәм әдәбият үсеше өчен кирәк булса да, күп кенә тар күңелле язучылар тарафыннан сөелми торган хезмәт бу. Гази Кашшаф тәнкыйтьтә нәтиҗәле эшләде. Аның тарафыннан дистәләп китап, йөзләп мәкалә һәм рецензия язылган.

Гази Кашшаф иseме матбугатта 1928 елдан башлап күренә. Язганы — хикәя, рецензия. Беренче китаплары 1940 елда дөнья күргән. Бу елда берьюлы өч китабы чыккан: «Каләм мастерлары», «Шәриф Камал», «Чүл буенда». Соңгысы повесть. Димәк, ул үзе дә әсәрләр язган. Әдәбиятны эчтән торып белү, әсәр туу процессын үз күңеленнән кичерү аңа язучылык хезмәтенә сак һәм ихтирамлы караштa торырга ярдәм иткән. Гази Кашшафны язучылар «нечкә зәвыклы, әзерлекле тәнкыйтьче» дип бәялиләр. Бу дәрәҗәгә ирешүдә әдәбиятны тирәнтен аңлавыннан тыш, үз иҗат тәҗрибәсе дә ярдәм иткәндер.

Гази Кашшафның исеме татар әдәбияты тарихында үз урынын алган икән, ул моңа табигый сәләте өстенә гаять дәрәҗәдә эшчәнлеге аркасында иреште. Ул сәләтен матур әсәрләргә әверелдерә алды.

Чын тәнкыйтьче буларак ул сәнгать дәрәҗәсенә ирешкән әсәрләр күрергә теләде, яхшыны эзләде һәм тапты. Ләкин ул таләпчән тәнкыйтьче дә иде. Менә без М. Әмирнең «Тормыш җыры» пьесасы буенча куелган спектакльгә рецензияне укыйбыз. Драматургиянең алтын фондына кереп калган әсәрдә тәнкыйтьче автор тарафыннан эшләнеп җитмәгән якларны дөрес күрсәтеп биргән. Һәм... Мирсәй Әмир белән Гази Кашшаф якын дуслар иде.

Бу мисал безгә Гази Кашшаф мирасының икенче тармагы турында сөйләргә юл ача. Ул гомеренең соңгы яртысында театрга якынайды, театр тормышын җентекләп

күзәтеп барды, аның таләпчән дусты булды. М. Горький урамындагы салкын иденле коммуналь квартирада яшәп калуы да бу йортның театр күршесендә булуы белән дә аңлатылса кирәк. Яңа квартира даулау мәшәкатеннән курку гына тотмагандыр аны бирედә, һәрбер яңа спектакльне карап, репертуар, режиссура, артистлар уены, музыкаль оформление нисбәтеннән үсешен күзәтеп бару өчен уңай булгандыр бу.

Гази Кашшаф тарафыннан язылган рецензияләр һәм сәхнә сәнгате турындагы мәкаләләр үзләре генә дә Татар дәүләт академия театрының бөтен бер чоры тарихын тәшкил итәләр.

Гази Кашшафның исемен безгә аеруча кадерле иткән эше — Муса Җәлилнең васыятен тулы үтәве. Җәлилнең батырлыгы, соңгы сулышына чаклы Ватан улы булып калуы хәбәре килеп җиткәч тә, Гази Кашшаф, аның иҗатын өйрәнеп, 1957 нче елда китап итеп чыгарды. Бу китапта Муса Җәлилнең иҗаты бөтен татар һәм ил әдәбияты фонында егерменче еллардан алып Ватан сугышы елларына чаклы барган катлаулы көрәш һәм чыныгу фонына куеп карала. Муса Җәлилнең җитлегү юлы, бөтен дөньяны сокландырырлык каһарманлыгы революция елларында башланган көрәшнең логик нәтиҗәсе буларак күрсәтелә.

Шуннан соңгы еллардагы туктаусыз эзләнү, сорашу, дистәләрчә кешеләр белән хат аша һәм барып-күреп очрашу, фактларны тикшерү, чагыштырып карау, архивларда актарыну... Ә юллар ерак. Ул Урта Азиягә, Европа илләренә барып җитә. Гаять чыдам, хезмәт сөючән һәм дусының васыятен үтәүне изге итеп санаган кеше генә сыңар аяк белән шуның кадәр юл йөри ала, мәшәкать чигә ала!

Муса белән әсирлектә очрашкан, бергә булган һәм көрәшкән кешеләрне табу, алар исән чакта сүзләрен, истәлекләрен алып калу васыятьне үтәүнең мөһим бер тармагы. Икенчесе — шагыйрь үзе атап әйткәне — аның әсәрләрен җыю, туплау, тәртипкә салу һәм җыентыкларын бастырып чыгару.

1955 елда Гази Кашшаф 26 ярым табак күләмендә Муса Җәлил әсәрләренең беренче томын чыгара. Аннары тагын ике том, барысы — сиксән табакка якын. Искәрмәләр белән, хронологик нигездә фәнни эшләнгән басма бу. Аннары татар һәм рус телләрендә Муса Җәлил әсәрләренең берничә басмасы, шагыйрьнең тормыш һәм көрәш юлын гәүдәләндергән фәнни-документаль китаплар дөнья күрде. Соңгыларында Муса Җәлилнең тиңдәшсез көрәше, иптәшләре турында бик күп яңа фактлар тупланган, дошман тылында әсирләр тарафыннан алып барылган катлаулы көрәшнең бөтен бер күренеше җанлы булып күз алдына килеп баса. Муса Җәлил турында истәлекләр китабын әзерләп чыгаруның да әһәмиятен әйтеп торасы юк. Гомеренең соңгы көннәрендә дә Гази Кашшаф Муса Җәлилнең 70 еллык юбилеена чыгарылачак томнарын әзерләү өстендә эшләде.

Гази Кашшафның үз язучысы дип, ягъни ул аерата игътибар белән һәм гомер буе өйрәнгән, иҗатын пропагандалаган язучысы дип Шәриф Камалны әйтергә кирәк. Ул, аның иҗатын өйрәнеп, хезмәтләр язды, әсәрләрен туплап, укучыга тәкъдим итте.

Гази Кашшафның татар әдәбиятына күрсәткән хезмәте күп. Бүген әдәбият мәйданында исемнәре танылган байтак авторларга юл башында ул ярдәм итте. Гази ага озак еллар дәвамында «Казан утлары» журналы редакторы булып тору дәверендә һәм Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы, журналистика кафедрасы укытучысы буларак күп кенә яшь сәләтләрне үз мәктәбе аша үткәрде. Аларның исемнәрен санап тормастан, бүген безнең әдәбиятта бер тармак булып әверелгән юнәлешне башлаучылар — Бөек Ватан сугышы кырларында каһарманлык күрсәткәннәрнең исемнәрен барлап, сугыш батырлары турында документаль әсәрләр язучыларга гына тукталыйк. Журналистика бүлегендә читтән торып укучы Шамил Рәкыйповка Үзәк оборона архивына барырга, мәгълүм булмаган исемнәрне табарга киңәш бирүче нәкъ менә Гази ага Кашшаф булды. Аннары Шамилгә башкалар килеп кушылды, дистәләрчә яңа исемнәр туган илгә танылдылар.

Яшәү хозурлыгы хәрлектә,
Гомер озынлыгы ирлектә...

Муса Җәлил шигырьләре арасыннан Гази Кашшафның аеруча игътибарын җәлеп иткән бу шигъри юллар белән аның үз гомер юлын да бәяләргә була. Ул озак яшәмәде. Үзенең 70 еллык юбилеен аның шулкадәр күрәсе килгән иде. Хәзерләнгән иде ул аңа, көткән иде... Без бүген менә аның сиксән еллыгын үзеннән башка гына искә алабыз. Ләкин ил күңелендә аның гомере озын булыр. Чөнки ул ир булып, зур кеше булып яшәде.

## Рафис Корбанов

# САБАН ТУЕНДА

### Үзем башлыйм

Сабан туе! Сабан туе!
Шундый кызык, күңелле!
Ник чыкмаска көрәшергә,
Әллә мин ир түгелме?!

Ексалар да, үпкәләмим —
Димәк, миннән көчлерәк.
Көрәш өчен билдә — ныклык,
Беләкләрдә көч кирәк!

Батыр калу өчен әле
Миңа бераз иртәрәк...
Тик шулай да сабан туен
Үзем башлап җибәрәм.

### Тәкә качкан

Аратаны җимергән,
Бәйләп куйган җиреннән
Чыккан тәкә мәйданга!
Калды бар да хәйранга.

Көрәшергә уйлыймы
әллә инде үзе дә?
Чөеп атар, әләксәң
Кәкере мөгезенә!

Ул арада тәкәне
Тотындылар куарга.
Тик мөгезбай тоттырырга
Уйламый да боларга.

Мәйдан буйлап йөгерә,
Элдерепме элдерә!

Мин булсам, тотар идем,
Барын да отар идем,
Әгәр тәкә тотуны
Берәр ярыш дисәләр...

Ә ярышта җиңүчегә
шул тәкәне бирсәләр!

## Колга башындагы этэч белэн сөйлэшү

Кызганам мин, этэч, сине
Барыннан да бигрэк,—
Үзем алып төшэр идем,
Колгасы биегрэк.

Күпме кеше арасыннан
Берэү табылмасмыни?
Сине шул колгадан алып
Төшүче булмасмыни?

Син шулай да, этэч, анда
Моңайма инде алай:
(«Колга юеш, бераз кипкэч,
Менэм»,— диде бер малай.

Сабантуй беткэнче колга
эле җитэр кибеп тэ.)
Сабан туен күзэт, ул бит
Шэп күренэ биектэн.

## Бакчалар

Бу бакчада ни үсэме?
Гөллэр, чэчэклэр үсэ.
Энилэргэ бирелэсе
Күпме бүлэклэр үсэ.

Э бусында ни үсэме?
Бу — яшелчэ бакчасы.
Бар табынга куеласы
Яшелчэнең барчасы.

Э бакчаның монысында
Карлыган, куралар күп.
Алмалары ерактан ук
Чакырып торалар күк.

...Нинди бакча дип тормагыз
Инде бусын, күрсэгез:
Бу бакчада ни үсэме?
Бусында — без үсэбез.

## Койма

Кайсы уйлап чыгаргандыр,
Белмим, кайсы коргандыр.
Эйтерсең лэ койма кормый
Яшэп булмый торгандыр.

Исем китми, торсын эйдэ,
Урамнарны аерып.
Эллэ кайчан куйдык инде
Бер тактасын каерып.

Таһир абый көн дэ килеп
Кадаклап куйган була.
Бүтэн моннан йөрмэгез дип
Орышкан, тыйган була.

Туры юлы шуннан булгач,
Урыйммы соң койманы?!
Каердым да чыктым тагын
Бер тактасын мин аның.

Каеруын да каердым,
Каерып чыккан өчен,
Чалбар балагын аерып,
Койма да алды үчен!

# УКУЧЫ СҮЗЕ

* * *

«Әтил суы ака торур» һәм «Сызгыра торган уклар»ны бүләк итеп, Нурихан Фәттах гаять зур эш эшләде. Менә хәзер яңа әсәр — «Кубрат хан». Романның азагында Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Хәтер белән мәхәббәт — үлемсез, мәңгелек»,— дигән сүзләре игътибарны җәлеп итә. Өстисе килә: хәтер — ул кешенең, халыкның әхлакый тәҗрибәсен буыннан-буынга тапшыручы бердәнбер канал. Хәтер югалу — кешелек һәм аның тарихы югалу. Менә шул яктан күз тотсак, тарихи нәфис әдәбиятның зарурлыгы, аның әһәмияте чагыштырмасыз зур. Әмма «Кубрат хан»ның мөһимлеге аның тарихи роман булуында гына түгел. Язучы, борынгы материал белән файдаланып, бүгенге проблемаларны күтәреп чыга.

Бүгенге көндә бар халыкларны дулкынландырган проблема — тынычлык өчен көрәш — романның үзәк темасы. Сугыш мәсьәләсенә роман персонажлары төрлечә карый. Беренче карашка бер-берсенә каршы-каршы торган ике төп герой да орышка бер үк мөнәсәбәттә күренәләр. «Кубрат исән чакта яу чабу булмастыр»,— ди хан. Ә төптәңре Ирсан берничә мәртәбә «төрки бер-берсен кыра»,— дип өзгәләнә. Әмма бу мәсьәләдә Кубрат ханны да, ханлыкның баш идеологы булган Ирсанны да саф күңелле дип кабул итеп булмый. Шул ук Ирсан ханга да, илханнарга да яу чабуның кирәклегенә ишарә итә.

Грек карты Симокатта да сугышның мәгънәсезлеген аңлый. «Бертуган төрки халыклар ни бүләләр?» — ди ул. Автор бу карттан сугыш мәсьәләсендәге икейөзлелекне фаш итүче бик акыллы сүзләр әйттерә: «Бер куллары белән орышны котлыйлар аллалар, икенче куллары белән аны җуялар». Ә әсәрнең төп идеясен Илбарыс уйлануларында тоя укучы. Орыш һәрчак якыннарны аера, бар изге нәрсәне таптый. Кояш астында һәркемгә дә урын җитәрлек. Мул тормышны кылыч түгел, хезмәт китерә. «Җиңеп җиңелгән иде Болгар бу сугышта» — моның инде автор сүзе. Сугышның мәгънәсезлеген шуннан да оста итеп аңлатып булмас, минемчә.

Язучы моннан тыш та бик мөһим фәлсәфи мәсьәләләргә җавап эзли, укучыны уйландырырлык җитди сораулар куйгата. Автор үзен укучыдан югары куймый — тирән фикерләрне үтеп барышлый гына әйтеп китә ул. Дидактикасыз, тәртип белән генә. Укытучы Константин: «Ришвәт халыкның дәүләткә булган ышанычын югалта, гаделне кимсетә, яманга юл ача»,— ди. Әңгәмәдән соң Кубрат хан аңлый: Константинны юкка гына иленнән сөрмәгәннәр. Кубрат ханның горурлыгы аның уенда күренә: «Болгарларның эчке эшләрен болгарлар гына хәл итә ала». Философ Фасиан, моңа чаклы бөтен сәләтен Болгарны Византиягә буйсындырырга юнәлткән булса да, Болгар тәртибенең чери башлаган империя тәртипләреннән күп өстен икәнен аңлагач: «һәр халыкның мөстәкыйль дәүләт төзергә хокукы бар»,— ди. Укучы күрә: Фасиан — акыллы, белемле дипломат кына түгел, ул теләсә нинди четерекле эшләрне дә җайга салырга сәләтле.

Романны укыганда, игътибарлы укучы адым саен әйтемнәр, афоризмнар, мәкальләр белән очраша. Алар укучыны уйландырган, әсәрне бизәгән кебек үк, авторга хас булган югары бер сыйфатны күрсәтәләр — кыска сүзлелекне.

Сүземне бетереп, шуны әйтәсем килә: «Сызгыра торган уклар»ны Н. Фәттах бик озак көттерде. Мөсәгыйт Хәбибуллинның икенче җимешен алай озак көтмәбез дип өметләнәсе килә.

**А. ИБРАҺИМОВ.**
Ульяновск шәһәре.

* * *

Язучының төркиләр тарихын эзлекле рәвештә һәм тырышып өйрәнүе миңа мәгълүм булганга, моның нәтиҗәсе мине бик кызыксындыра иде. Моңарчы бүгенге тормыш турын-

да язып килгән әдипнең борынгы темага алынуы укучыда ихтыярсыз сынаулы караш уятуы табигый. Хәлбуки «Кубрат хан» романының беренче бүлекләре үк күңелне үзенә иартеп, шик-шөбһәләрне юкка чыгарды.

Автор мавыктыргыч сюжет вакыйгалары тапкан, тарихтан мәгълүм булган кыскажыйнак хәбәрләргә реаль, тормыш ситуациясе рәвешен биргән, илебезнең көньяккөнбатыш киңлекләрендә, Азов һәм Кара диңгез, Төньяк Кавказ, Көньяк һәм Урта Идел буйларында VII гасырда барган тарихи-этник процессларны җанлы тормыш картиналары аша гәүдәләндерүнең тәвәккәл һәм кыю тәҗрибәсен ясаган. Аның бу эше һәрьяклап кайнар хуплауга лаек. Беренчедән, ул хәзерге укучыларда үзләренең болгар бабалары турында тулырак беләсе килү кебек табигый ихтыяҗга җавап бирә, замандашыбызның белемен, тарихи күз күремен киңәйтә.

М. Хәбибуллинның хәзерге проза өлкәсендә туплаган тәҗрибәсе аның беренче тарихи романында гаять тулы ачыла. Вакыйгаларның логикалы һәм кискен үсеше, үзгәреше, алмашынышы сюжет киеренкелеген тәэмин итсә, буйдан-буйга сузылган каһарман һәм персонажлар аның бөтенлеген хасил итә. Кубрат хан, аның кызы Чәчкә, Илбарыс буйтур, ханбикә Аппак, төптәңре һәм илханнар, Византия императоры Ираклий һәм грек илчеләре үзләренә хас характер төсмерләре белән бирелгән. Әсәрдәге кешелек мөнәсәбәтләре Мөсәгыйтнең элекке әсәрләренә караганда психологик яктан бәерак эшләнгән.

Автор безнең күз алдына Болгар иле язмышындагы зур борылыш чорын китереп бастыра. Олы яшьтәге зирәк һәм кырыс Кубрат хан Болгарның иҗтимагый, сәяси, хәрби һәм хуҗалык ягын ныклы нигезгә кору өчен авыр, тырыш һәм катлаулы көрәш алып бара. Византия һәм Хәзәр каганлыгы кебек ике көчле дәүләт арасында илнең ышанычлы киләчәген тәэмин итү теләге аның барлык сәяси, дипломатик һәм хәрби чараларның үзәгендә ята. Бу көрәшнең кискенлеге, күрше дәүләт хөкемдарларының мәкерле эшчәнлеге (бу өлкәдә Кубрат хан үзе дә кимен куймый) каһарманнарның катлаулы һәм трагик язмышында чагыла. Әсәр сугышның рәхимсез һәм мәгънәсез асылын күз алдына бастыра. Бу уңайдан язучы уздырган идеяләр илебезнең тынычлык өчен бүгенге героик көрәшенә аваздаш яңгырый.

«Кубрат хан» романында безнең әдәбиятта инде моңарчы күренгән персонаж исемнәре һәм этнографик төшенчәләр дә күзгә чалына. Кайбер исемнәр Н. Фәттах әсәрләре аша инде безгә таныш. Әйтик, Чәчкә һәм Аппак кебек хатын-кыз исемнәре «Кол Гали» трагедиясендә һәм «Әтил суы ака торур» романында инде очраган иде. Аларның икенче автор әсәрендә кулланылуын ничек бәяләргә соң? Авторның фантазиясе чикле дипме, оригинальлек җитенкерәмәү дипме? Минемчә, Болгар тарихының зур-зур ике дәверен бербесенә бәйләү, күчемлелек чарасы итеп аңлау дөресрәк булыр. Үзеннән элек язылган әсәрләргә ихтирам чагылышы дип тә карарга кирәк.

**Н. ХИСАМОВ.**
Казан шәһәре.

* * *

«Кубрат хан» романын һәр кеше кызыксынып укый. Шул фикер төрле яшьтәге кешеләр белән сөйләшкәндә дә расланды. Татар әдәбиятында тарихи романнар бик аз. «Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар», «Кубрат хан» һәм тагын бер-ике китап. Тарихи роман — халыкта патриотизм тәрбияли торган чагыштыргысыз әһәмиятле бер әдәби жанр, халыкның үзаңын үстерүдә зур роль уйный. Үз тарихын белмәгән халык — тамыры корыган агачка охшашлы. Безнең халык тарихында бик кызыклы чорлар яктыртылмаган әле. Болгарның төзелеш чоры, дин кабул итүе, болгар халкының Субудайны җиңүе, Батый гаскәренә каршы торуы (Идел-Урал халкы аңа 3 елга кадәр каршы тора). Шундый вакыйгалар хакында яңа китаплар чыкса, бик шат булыр идек.

**М. ЯМАЛЕТДИНОВ.**
Куйбышев шәһәре.

* * *

Журналның 1986 елгы саннарында бик кызыклы повестьлар, романнар һәм хикәяләр укыдык. Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романы, Фәнис Яруллинның «Кыйгак, кыйгак каз кычкыра» повесте, Мәгъсүм Хуҗинның «Төп нигез» хикәясе һәм башка күп кенә әсәрләрне бик кызыксынып укыдык. Мин Лениногорск районы, Зәй-Каратай авылында туып үстем. Авыл тормышы турында язылган әдәби әсәрләрне яратам. Халкыбыз кичергән авырлыкларны сурәтләгән әсәрләр күбрәк булсын иде.

Ире хатынына, йә булмаса хатыны иренә хыянәт итү турында күп язалар, шуңа күрәдер инде, бу хәлләр тормышта да модага кереп бара.

Авыр заманнар турында күбрәк языгыз, халкыбыз батырлыгы үрнәгендә батырлыкка өйрәтегез яшьләрне.

**И. МАКСУТОВ.**
Казахстан ССР, Кызыл Урда шәһәре.

* * *

Мин М. Хәсәновның «Язгы аҗаган» дигән романын зур кызыксыну белән укып чыктым. Менә шундый романнарны экранлаштырсаң, безнең әдәбиятка киң катлау укучыларның кызыксынуы артыр иде, милләтебезнең дә үзаңы һәм абруе артыр иде.

Күптән түгел телевидение аша «Аспарух хан» дигән болгар фильмын күрсәттеләр. Ә Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан» дигән романын экранлаштырсаң, ул да әлеге фильмнан ким булмас иде.

**М. ГАЛИЕВ.**
Свердловск шәһәре.

* * *

«Язгы аҗаган» романы басыла башлагач, журналны сабырсызланып көтеп алдык. Чират торып укыдык. Романда бик гыйбрәтле вакыйгалар, аяныч хәлләр, аяныччы гомерләр турында гыйбрәтләр күп. Безнең халкыбызның үткәне, бу матур көннәргә нинди фаҗига, авырлыклар аша килеп җиткәне ап-ачык чагыла.

Яхшы кешеләр, ни кадәр генә авыр хәлдә калсалар да, югалмаганнар, яхшылык җирдә ятмый дигәндәй, яхшылык, кешелеклелек барыбер җиңгән.

Миңа Иргалинең кешелеклелеге, беркайчан да югалып калмавы, һәрвакыт егет булуы, кешеләргә фәкать яхшылык кына эшләве бик ошады. Ир кеше югалып калмаска, көчле характерлы булырга, һәрвакыт, һәркайда зур таяныч булырга тиеш. Иргалиләр кебек!.. Хатын-кызлардан Гөлүсә образы сокландырды. Гөлүсәнең мәхәббәте һәркемне сокландырырлык. Тик Гази гына йомшаклык күрсәтүе аркасында яшьлек мәхәббәтен югалта һәм икесе дә гомерлек утта яналар. Әнә шундый характерлы булуы аркасында Гази авыр хәлләргә дучар булып тора һәм тормышы да аяныч хәлдә тәмамлана.

Бу романда рус һәм татар халкы арасындагы дуслык һәм бу дуслыкның элек-электән килгәнлеге, аларны бәйләүче сәбәпләрнең сере — кешелеклелек, яхшылык, яхшы күңеллелек икәне дә ачыла.

Туган ил, туган туфракка мәхәббәт, туфрак тартып Себер хәтле Себерләрдән әйләнеп кайта алган Рәхимҗан бик яхшы бирелә. Әмма Гази белән Гөлүсә кавыша алмыйлар. Бик кызганыч. «Эх, сугыш булмаган булса!» — дип әрнеп куя йөрәк. Алар соңгы минутларда гына булса да очраштылар.

Роман бик ошады, рухи азык бирде. Мин аны бик бирелеп, шул геройлар белән бергә шатланып, газапларын да алар белән бергә кичереп, дөньямны онытып укыдым.

Рәхмәт Сезгә, Мәхмүт Хәсәнов, рәхмәт, хөрмәтле редакция!

**З. ГОМӘРОВА.**
Брежнев шәһәре.

* * *

Менә татар әдәбияты Иргалиле, Газилы, Гөлүсәле булды. Болар әдәби образлар галереясенең түреннән үзләренә тиешле урынны алырлар да: «...без — «Язгы аҗаган»нан! — дип, кулларын каш өстенә куеп, «Арыш башак кыскан чакта...» уйнаган аҗаганнарны күзәтеп торырлар кебек.

Шәйхи Маннурның «Чын сөю бармы?» дигән лирик повестенда керсез, саф мәхәббәтнең үрнәкләре бер бәйләм чәчәк итеп бәйләнгәнен күргән идек. Без ул бәйләмгә Гази белән Гөлүсә мәхәббәтен дә кушабыз.

Гази, мәхәббәтенә актык сулышына кадәр тугры калып, сөюгә тап төшерми. Әдәбиятта Гази белән Гөлүсә мәхәббәтенә тәңгәл килә торган мәхәббәт бар микән?

Әсәрне укыгач, миндә шундый фикер туды: «Язгы аҗаган» романы Мәхмүт Хәсәновны иң хөрмәтле язучыларыбыз рәтенә куя. Чөнки әсәр — колачлы, вакыйгалар тыгыз, теле, сөйләм рәвеше гүзәл. Авторга, Шәһи булып сөйләр өчен генә дә Коръән сурәләрендә актарынып, көнне төнгә ялгарга туры килгәндер. Миңсылуның тайга туфрагында ятып ка-

луы, Газиның газап белән көтелгән очрашудан соң дөнья куешы — болар әсәрдәге вакыйгаларның «агыш узәне»нә туры килә.

Ләкин өендә дә, төшендә дә таң йолдызы Чулпанга багып, «...Чулман, Чулман, ...туган туфрагым — Чулман!» — дип тилмереп гомер иткән Ирггалинең туып-үскән якларына бер кайтып килә алмаганлыгы кешене аптырашта калдыра. Орденнары тагылмаган имеш тә, шуңа күрә стансага төшмәгән икән. Шул да булдымы сылтау? Ышандырмый.

«Өч аршын җир»дәге Мирвәли булып Мирвәли хатынының васыятен үтәү йөзеннән авылына өч аршын җир теләнергә кайта ич. Иргали — Мирвәлигә охшап, бар мөлкәтен атып-ватып, яндырып, үзе суын эчкән коега төкергән кешедәй, авылын ташлап чыгып киткән ходай бәндәсе түгел ләбаса. Әллә аның Чулман якларына кайтып, төпләнеп калганлыгын сурәтләүче вакыйгаларны романның «үлчәме» сыйдыра алмыймы?

Себер белән Чулман якларын бер-берсенә каршы куймыйм мин. Себер — татар халкының яшәп килгән төбәкләреннән берсе.

Шундый матур әсәрне әдәбиятыбызга бүләк иткәнегез өчен тәбриклибез Сезне, Мәхмүт!

**Х. АРСЛАНОВ.**
Үзбәкстан ССР, Җизак шәһәре.

ХӨРМӘТЛЕ МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ!

Сезнең «Язгы аҗаган» романын дүрт ай көтеп, түземсезлек белән укып чыктым. Романыгыз тарихи чынбарлыкны үз эченә алган. Дөресрәге, романыгыз сокландыргыч. Сезгә рәхмәтләремне белдерәм. Романдагы Газиның язмышы — минем язмышка охшаган.

Иҗатыгызда зур уңышлыклар, саулык-сәламәтлек теләп,

**Г. ФӘХРЕТДИНОВ.**
Ташкент шәһәре.

* * *

Журналда басылган әсәрләрне күп еллар инде зур кызыксыну белән укып барам. Тәнкыйть материаллары, очерклар, публицистик мәкаләләр, истәлекләр матур тел белән, аңлаешлы язылган була. Соңгы елларда «Татарстан — туган төбәгем» рубрикасы астында басылган мәкаләләр укучыга зур мәгълүматлар бирде.

Узган елда Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романы басылып чыкты. Безне сөендерде бу әсәр.

Иргали образы үзенең тормышчанлыгы, сафлыгы, дөньяда кешеләрчә яши белүе белән җәлеп итә, онытылмый, күңелдә кала. Кеше өчен көрәшүче буларак, авылга кайтып керү белән, тизрәк иң якын кешесен эзләп таба, үлемнән, ачлыктан коткара. Аннан соң, өч гаиләне (Миңсылуны да кертсәк) ачлыктан коткару өчен үзенең күңеле кушкан юлны сайлый. Рәхимҗанны да куып чыгармый, ә ул чагында урта хәлле крестьянны кулак белән бутау еш булган бит. Тормышка формаль карау — әле дә күп кешеләрне елата. Ә Иргали шул заман, шул чор кешесе, тормышны дөрес аңлавы белән күңелгә якын. Язучы моны укучылар күңеленә шулай җиткерә алган.

Журнал тышлыгындагы рәсемнәрне дә төрле тәрбияви чаралар үткәрүдә киң кулланам. Журналның һәрбер номерын көтеп алам.

**Л. ТАҺИРОВА.**
БАССР, Чакмагыш районы,
Рәҗәп авылы.

* * *

М. Хәсәновның «Язгы аҗаган» романын мин кырык эшемне кырык якка ташлап укыдым. Романдагы геройларның исемнәре җисемнәренә туры килә.

Иргали физик яктан таза, көчле, эш сөя, кешеләрне ярата. Уңган, ирен бер сүздән аңлый, хәленә керә белгән, сабыр холыклы Гөлниса. Җизнәкәем дип өзелеп торган балдызкае Миңсылу. Гомер буе Газины гына яратып яшәгән Гөлүсә.

Иргали тормыш алдында зур сынаулар уза. Башка сыймаслык фаҗига кичерә: аны кеше үтерүдә гаеплиләр, Себергә сөрәләр. Тормыш аны сындырып сыный. Гази белән Гөлүсәнең мәхәббәте «Чын сөю бармы?» дигән сорауга «бар» дип җавап бирерлек итеп язылган.

Язучы үзенең геройларын бик оста сурәтли. Алар бар да укучы күз алдына үз төсләре, үз рухлары белән килеп басалар. Бу инде язучының халык белән нык аралашуын, күп эзләнүләрен раслый.

**Җ. МӨХӘММӘТОВА.**
Азнакай.

* * *

«Казан утлары»н 10 ел дәвамында даими алдырып, укып барабыз. Аннан фикерләр алышабыз. Сүз, әлбәттә, яхшы дип табылган әсәрләр турында бара. Аннан, мин укытучы бит әле: теге яки бу әсәрнең яхшы урыннарын өлкәннәр белән дә, балалар белән дә укыйбыз.

Бәхет турында әңгәмә үткәрдем. Әңгәмәгә нигез итеп Ф. Яруллинның «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра» әсәре алынды. Әсәрнең аерым урыннарына туктала-туктала сөйләштек. Укучылар әсәрдән бик канәгать калдылар. Үз бәхетләрен авырлык белән тапкан геройларга сокландык. Сүз уңаенда әйтеп үтәм: Фәнис Яруллин әсәрләрен эчке дулкынланусыз уку мөмкин түгел. Нәкъ тормышның үзе! Ә бит төптән уйласаң, автор нинди авыр очракны без ышанырлык гади итеп бирә алган. Кыз кешенең егет кеше булып йөрүе — сирәк хәл. Ә автор безне ышандырырлык дәлилләр тапкан.

Әгәр 1986 елда басылган иң яхшы әсәрне әйтүемне сорасагыз, мин, һичшиксез, «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра»ны атар идем.

**Г. ХӘММӘТНУРОВ.**
БАССР, Нуриман районы.

* * *

«Казан утлары» журналының даими укучысы буларак, уй-фикерләремне, теләкләремне җиткерәсем, борчыган сорауларга җавап табасым килеп, сезгә хат язарга булдым. Журналның уңышлары куандыра, ә нәрсәдер җитеп бетмәсә, борчылу тудырмый калмый. Журналда әдипләребезнең әсәрләре беренче сынау үтә, бәһа ала.

Без журналны көтеп алабыз. Әмма борчу тудыра торган мәсьәләләр бар. Китапларның да тиражы кими. Китап тиражын билгеләгәндә, кибетчеләрнең заказы белән генә чикләнмәскә, ә бәлки, әдәбият сөючеләрнең дә теләкләрен исәпкә алырга, алар белән якыннанрак аралашырга кирәк. Үзеннән-үзе аңлашыла: мондый адым Татарстан чикләрендә генә калырга тиеш түгел. Узган елгы 9 нчы санда басылган Т. Әйдинең «Һөнәрле Әләзән»е моңа ачык мисал. Бу иптәшнең нәтиҗәле хезмәте мактауга лаек һәм үрнәк булырлык. Хәрби-патриотик темага караган эзләнүләре өчен Самат Шакир һәм Шамил Рәкыйповны олы хөрмәт белән исемләп китәсе килә.

Тагын тарих мәсьәләсе. Казанда да, Мәскәүдә дә болгар-татар тарихына карата фәнни әсәрләр басыла килде. Һәм көтмәгәндә бу юнәлештә авангард ролендә башкорт галимнәре булып чыкты («Народы Поволжья и Приуралья». М., 1985).

Тыйнак булу — татар халкына хас сыйфат. Ләкин артык тыйнаклык чикләнгәнлеккә китермиме? Надан старшина биргән язуга нигезләнеп кенә Риза Фәхретдиневне башкорт галиме һәм әдибе дип йөртә башладылар. Т. Ялчыголның дәреслекнең янында да тормаган һәм тарих фәнендә күптән тәнкыйть утына тотылган шәҗәрәсенә нигезләнеп, Кол Галине башкорт, ә «Кыйссаи Йосыф» поэмасын башкорт әдәбиятына кертергә тырышалар. Кол Галидән башлап революциягә кадәр иҗат иткән әдипләрнең дә байтагына шундый дәгъва белдерелә.

Безнең галимнәргә акны ак дип исбат итәргә нәрсәдер җитми. Язучылар да бу темага пассив кала бирәләр. Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур», М. Хәбибуллинның «Кубрат хан» исемле романнарын укып шатланган идек.

Халкыбызның күренекле уллары һәм кызлары турында күбрәк язылсын иде. Р. З. Сәгъдиев турында 1979 елда укыган идек. Аның тормышында кабат язарлык вакыйгалар булды бит. Шулай ук академиклар Миначев, Вәлиев, Рәхмәтуллин, политик күзәтүче Сәйфел-Мөлеков, геолог Кәримова, легендар Даян Мурзин кебек шәхесләр турында язганда яки әңгәмә оештырганда бик күңелле булыр иде. Бөек Ватан сугышы һәм хәзерге хәрби җитәкчеләр турында очерклар басылсын иде.

**Р. УРМАНОВ.**
БАССР, Дүртөйле районы.

# Маннур Саттаров

## Эштән чыгарылган түрә бәете

Төшләремдә каз таласа,
Каза күрәм өнемдә.
Каздан яман таладылар
Отчет-сайлау көнендә.

Үрмәләдем үрләргә,
Урным булды түрләрдә.
Түрдән төшмәс кебек идем,
Керми торып гүрләргә.

...Эшемә килер идем,
Эшләпәм әләр идем.
«Китерә белгән» кешене
Күтәрә белер идем.

Бажаларым, дусларым,
Үзем бүлдем постларын.
Инде хәзер яңа башлык
Утыртыр үз дусларын!

Безнең инеш тирәндер,
Тирән жире билдәндер.
Бәкернең биле турайды,
Төшәсемне белгәндер.

Йортлар салды якыннарым,
Чыгарып балконнарын.
Инде кем тартып чыгарыр,
Батканда якыннарым?

Биек-биек баскычлардан
Тотынмый менми идем.
Жалу язган кешеләрдән
Котылмый тынмый идем.

Алмагачның алмасын
Асыл кошлар алды инде.
Санаусыз маллар бар иде,
Санаулыга калды инде.

Биек тауның башларында
Чияле чыбык кына.
Портфелемне бирегез дип,
Кычкырмыйм чыгып кына.

Мин утырган креслода
Утыра хәзер бүтән.
Инде кресло бирмәсләр....
Хет булсын идә бүкән.

## «Зәңгәр шәл»

Яшел алан уртасында төз багана,
Дан өстенә бүләк алыр менгән аңа.
Үз егетен юрап торган кызлар күзе
Югарыда жилфердәгән шәлгә яна.

«Зәмзәм» суын» күбрәк йоткан «кавалер»лар
Кул-аяклап баганага сарылдылар.
— Сез, егетләр, чиратлашып менегез! — дип,
Тәртип куйган айнык ирләр табылдылар.

Инде менә беренчесе менеп бара,
Маңгаеннан шабыр-шыбыр тирләр ага.
— Кесәңдәге шешәң баса, атып бәр! — дип,
Кычкыралар иптәшләре жирдән аңа.

Ул ычкынгач, икенчесе менеп китте,
Рухландырды, куәт бирде халык башта.
Тиргәделәр шулар үзен, егылып төшкәч:
— Син әлкәшкә түгел бу шәл, аек башка!

«Салган»нарның кикрикләре шиңеп калды,
Дан, бүләккә дәгъвачылар кимеп калды.
Эчми торган бер яшь егет менеп алып,
Зәңгәр шәлне гүзәленең иңенә салды.

Эче янды моны күргән чибәрләрнең,
«Бу шәлъяулык миңа булыр» дигәннәрнең.
Ул чибәрләр инде кемгә үпкәләсен,
Яры булгач алар — Шешә сөйгәннәрнең?!

# Лэбиб Лерон

## ПАРОДИЯЛӘР

### Иҗат гамәле

Тукай яшен узып барам менә,
кылган эшкә баксаң — оятрак.
Равил Фәйзуллин.
Кыенсына-кыенсына,
Тукай яшен узып барам.
Роберт Миңнуллин.
Тукай яшен уздык инде —
Әйдә, бар кеше белсен!
Фәннур Сафин.

Р. Фәйзуллин: — Нигә әле оялырга,
Кыенсынырга әле?
Р. Миңнуллин: — Җиңел генә хәл итик без —
Ф. Сафин: — Чишик иҗат гамәлен...
Р. Фәйзуллин: — Бергәләшеп шигырь язйык —
Барысы бергә: — Кемдә кемнең эше бар?!
Р. Миңнуллин: — Алда — Такташ...
Ф. Сафин: — Алда — Җәлил...
Р. Фәйзуллин: — Аннан... Туфан яше бар!

### Борынгы һәм өр-яңа

...Мин Геракл кебек бик борынгы,
Компьютер кебек өр-яңа...

Яфрак, бөҗәк, диңгез ничек яши,
Шулай яшим мин бу дөньяда.

Гәрәй Рәхим.

Яфрак кебек калтыранам кайчак,
Китсә дә җил ялгыш орынып...
Мин суыткыч кебек өр-яңамын,
Чарльз Дарвин кебек борынгы.

Бөҗәк кебек, үлән арасыннан
Гаҗәпләнеп карыйм дөньяга.
Мин Ахиллес кебек бик борынгы
Һәм «Адидас» кебек өр-яңа.

Диңгез кебек шаулап алам кайчак,—
Дулкыннарым миңгә төрләнә.
Мин Колумб кук бик борынгы бүген,
Катамаран кебек өр-яңа.

Яфрак, бөҗәк, диңгез кебек шулай
Рәхәтләнеп яшим дөньяда:
Мин Кол Гали булып йоклыйм һәр көн —
Гәрәй Рәхим булып уянам...

**Әхәт Сафиуллин**

# ИЯЛӘНЕП КИТКӘЧ...

хикәя

Моңарчы бу йорт кешеләренең күзләренә күренү түгел, аны биш чакрымнан әйләнеп үткән Шәмсетдинов соңгы вакытта күкрәк киереп, борынын күккә чөеп йөри башлады. Йорт тирәсендә бөтерелде. Янәсе, күрегез, белегез, сезнең өчен янып-көюем, тиздән югарыга лифт белән күбәләк кебек җиңел генә менеп-төшеп йөрерсез. Йортлар идарәсе башлыгы Шәмсетдинов абзыкаегызның игелегенә тиенегез!

Чыннан да, аның күренгәләп йөрүеннән соң озак үтмәде, ундүрт катлы бу йортның лифт дигәннәре хәрәкәткә килде. Ләкин көн узды, атна үтте, тик ник бер кеше лифт идәненә аяк басып карасын! Алай гынамы соң! Утыру түгел, хәтта күрергә теләүче кеше дә табылмады. Әйтерсең алар өчен лифт бөтенләй дөньяда юк нәрсә иде.

Рәхмәт сүзләре ишетергә җыенган Шәмсетдинов, гаҗәпкә калып колак артын кашырга тотынды.

Ул һәркөн иртүк:

— Я, ничек анда безнең эшләр? — дип, беренче нәүбәттә лифтче Шәйхелислам картка шалтыратып ала торган булды.

Ләкин бер атнадан да, бер айдан соң да:

— Янына да килеп караучы юк...— дигән җавап алды.

— Ә үзең менгәләп-төшкәләп йөрисеңме соң? — дип сорады ул аптырагач.— Кешеләр лифтнең эшләвен үз күзләре белән күрсеннәр.

— Көннәр буе лифттән төшкәнем юк,— дип җавап бирде аңа Шәйхелислам карт.— Аслы-өсле йөри-йөри, башларым әйләнеп бетә...

Шәйхелислам карттан ай буе шундый бер төрле җавап ала торгач, Шәмсетдинов түзмәде, әлеге йортка үзе китте. Караса, лифттә Шәйхелислам карт чыннан да үзе генә утырып йөри. Әле өскә менә, әле аска төшә... Лифттән чакырып чыгаргач, тигез җирдә чайкала. Тәмам төсе киткән мескеннең...

«Менә аңла син бу халыкны!..— дип ачыргаланды Шәмсетдинов.— Элек бу лифтне кайчан җибәрәсез инде, ул кайчан эшли башлый дип, җанга тоз салдылар, күзне ачырмадылар. Ә хәзер, лифт эшли башлагач, ялгыш та аяк басып караучы кеше юк. Рәхәтләнеп кенә лифт белән җилдертәсе урында карт-корысына тикле, аксый-туксый булса да, баскычтан менеп азаплана бит, әй!.. Җүләрдер болар, валлаһи...»

— Туктагыз әле! — диде ул, баскыч буйлап титаклаган бер бабайны куып җитеп.— Нишләп үз-үзеңне азаплыйсың, бабай? Нишләп лифт белән йөрмисең?

— Юкка куйдыгыз аны, улым,— дип җавап бирде аңа карт.— Кирәге калмады...

— Соң, лифт эшләми, лифт эшләми дип, үзегез җелеккә тидерез түгелме соң?!

— И-и, улым, аңа ун ел вакыт үтте бит инде,— дип көлде карт.— Шул ун ел эчендә без баскычтан җәяү менеп-төшеп ияләнеп беттек шул. Хәзер безгә егерме сигез катлы йорт та берни түгел. Үземне ун елга яшәргән шикелле тоям. Шуның өчен рәхмәт яусын инде сиңа, улым...

Карт шулай диде дә елгыр гына баскыч буйлап менеп китте.

# Зәки Нури

## Гөмбәчеләр эзеннән

— Күз узды бит. Инде нинди гөмбә?
— Юкка, йөрмәм — шуны бел, карчык...
Һәм китте карт. Ярты көн эчендә
Җыеп кайтты шешә... Бер капчык...

## Тәрәзәгә карап уйлану

— Мин бит сиңа якты бирә идем.
Мине бүген нигә ваттың, Кеше?
— И пыяла! Исереккә сүз сөйләп
Тел талдырма юкка... Таптың кеше...

## «Уңай тип»

Эштә утыра, җыелышка килә,
Эчсә — яшерә, тартса — ешламый,
Кирәк санаса — елмая белә...
Ә җыеп әйтсәң — берни эшләми.

## Сәер имгәнү

Берәү, марля белән бәйләп,
Кулын муенга аскан.
— Ни булды?
— Буфетта кемдер
Аягы белән баскан!..

## Хәле мөшкел

«Башым чатный...» — диеп сыкрый,
Бик мөшкел мескеннең хәле...
— Бәлки эчкәнсеңдер кичә?!
— Юк, бүген эчмәдем әле...

## Сәер кибет

Үзе зәңгәргә буялган,
Үзе «яшел елан» сата.
Ишеге төбендә аның
Көн дә кемдер аунап ята.

## Бәйләнчек

Тагын китте. Тагын «җепшеп» кайтты ул,
Хатынныннан өч сум алып бурычка.
«Кызыл борын, әллә тагын салдыңмы?»
Дип бәйләнде кайткач... кызыл борычка.

# Аракы эчү, исерү һәм исерекбашлар турында халык мәкальләре

Авызын тыңлата алмаган исереккә колагыңны әрәм итмә.

Айнык башта айнык акыл.

Акылдан язасың килсә, аракы эч.

Акылыңа аракы түрә булмасын.

Аракы авызга черки булып керә, аждаһа булып чыга.

Аракы арысланны бөгеп салган.
Аракы белән озын йокы —
Ят та борның белән үз кабереңне үзең чокы.

Аракының катрәсе каннан яман.

Аракы сүзне озайта, гомерне кыскарта.

Аракы эчкән әҗәле җитми үләр.

Аракы эчсәң — гастрит,
Бу эшеңнән тәүбә ит.

Ахмак кеше үз кулындагы стаканга батып үләр.

Бер йоткан, ике йоткан,
Өченчесендә башын элмәккә тыккан.

Бәләкәй шешәдә шайтан баласы,
Чыгарма — килер анасы.

Адәм диңгезгә батмас, бер стакан аракыга батар.

Илла исерсәң рәхәт лә:
Чалбарың эчтән,
Ыштаның тыштан,
Башмагың башта,
Бүрегең аякта!

Ир исерсә — мәсхәрә,
Кыз исерсә — бот шәрә.

Исереккә сәлам бирмә, ул бирсә дә.син алма.

Исерек оят белмәс,
Оят белсә дә, тыйнак белмәс.

Исеректә акыл булмас, мөртәттә иман булмас.

Талантлы исерекне талантсыз аек узар.

Черек кискәгә су үтәр,
Черек кешегә аракы үтәр.

Эчмәгәндә шамакай Шаһи,
Эчкәч булган Шаһиәхмәт даһи.

Ирләр эчсә, ярты йорт яна,
Хатыннар эчсә — бөтен квартал.

Эчкән ир аракы эчмәс, хатынының күз яшен эчәр.

Исерек дус яңакка менми калмас.

Исерекне исерек мактар,
Мактавы беткәч, өстенә менеп таптар.

Исерекне кем күп эчерсә, шул даһи.

Эчү — үчү (юкка чыгу, бетү. Ред.).

*Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» китабыннан (2 том) алынды. Татарстан китап нәшрияты, 1963.*

## *Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары*



## Рәфикъ Юныс

Рәфикъ Юныс (Рәфикъ Юныс улы Юнысов) 1943 елның 1 мартында Арча районының Кәче авылында туган. Арчада урта мәктәп тәмамлый, аннан туган колхозында һәм Казанда төзелештә эшли, Совет Армиясендә хезмәт итә. Казан дәүләт университетында укып, журналист белгечлеге алгач, уналты ел «Татарстан яшьләре» газетасында эшли. Хәзерге хезмәт урыны — Татарстан китап нәшриятының фәнни-техник редакциясе.

Беренче шигырьләр бәйләме 1976 елда «Казан утлары» журналында басылды. 1982 елда — «Вакыт чылбыры», ә 1986 елда «Җирдә яшим» исемле китаплары дөнья күрде.



## Нурислам Хәсәнов

Нурислам Габдулла улы Хәсәнов 1941 елда Саба районының Шәтке авылында туган. Олы Нырсы урта мәктәбен тәмамлагач, Казанда һөнәр училищесында укый, авиация техникумын тәмамлый. Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Күп еллар Казан моторлар төзү берләшмәсендә эшли: слесарь, инженер, өлкән мастер хезмәтләрен башкара. 1976 елда Бөтенсоюз җиңел һәм текстиль промышленносте институтының электромеханика факультетын тәмамлый. 1981—1982 елларда ул — Казан телевидениесенең пропаганда редакциясендә редактор, 1982 елдан — Телевидение һәм радиотапшырулар Дәүләт комитетының Радиотелеүзәгендә өлкән инженер.

Татарстан китап нәшрияты 1982 елда Н. Хәсәновның «Энҗеләр балкышы» дип аталган хикәяләр, 1985 елда «Бәхилләрме йөрәк?» исемендәге повестьлар китабын бастырып чыгарды.



# *Культура тормышы көндәлеге*

## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

3 апрельдә Мәскәүдә, язучыларның А. А. Фадеев исемендәге Үзәк йортында Г. Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга багышланган әдәбият-сәнгать кичәсе булды.

Кичәне кереш сүз белән Г. Ибраһимов юбилеен уздыру буенча Бөтенсоюз комиссиясе председателе, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев ачты.

Аннары ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары профессор М. Х. Хәсәнов Г. Ибраһимовның иҗади һәм революцион эшчәнлеге турында доклад сөйләде.

Кичәдә РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, «Литературная Россия» атналык газетасы баш редакторы М. М. Колосов, украин язучысы В. Г. Гримич, Үзбәкстанның Хәмзә исемендәге дәүләт премиясе лауреаты прозаик П. К. Кадыйров, Казахстан Язучылар союзы идарәсе секретаре К. К. Турсункулов, Башкортстан Язучылар союзы идарәсе председателе драматург Ә. М. Мирзаһитов чыгыш ясады.

ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. А. Миңнуллин үзенең йомгаклау сүзендә Татарстан вәкилләре исеменнән татар халкының күренекле улы Г. Ибраһимов истәлегенә багышланган кичәне оештыручыларга, анда катнашучыларга зур рәхмәт әйтте.

Аннары Татарстан сәнгать осталарының зур концерты булды.

Кичәдә КПСС Үзәк Комитетының Культура бүлеге мөдире урынбасары Е. В. Зайцев, КПСС Үзәк Комитетының Культура бүлеге матур әдәбият секторы мөдире В. А. Степанов, КПСС Үзәк Комитетының Культура бүлеге инструкторы Н. Н. Митрофанов, КПСС Үзәк Комитетының Оештыру-партия эше бүлеге инструкторы В. П. Пичугин, КПСС Үзәк Комитетының пропаганда бүлеге инструкторы В. М. Леонов, РСФСР Министрлар Советының культура, сәнгать һәм матбугат бүлеге мөдире А. П. Беляков, академик К. А. Вәлиев, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнаштылар.

12 мартта М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды.

Президиумда — КПСС өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитеты бюросы членнары һәм членлыкка кандидатлар, республиканың партия, совет, профсоюз, комсомол оешмалары, иҗат союзлары, культура учреждениеләре, хезмәт коллективлары вәкилләре, илебез башкаласы Мәскәүдән, тугандаш республикалардан килгән кунаклар.

Тантаналы җыелышны кереш сүз белән КПСС өлкә комитетының икенче секретаре А. А. Родыгин ачты.

Галимҗан Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары, Г. Ибраһимов юбилеен үткәрү буенча республика комиссиясе председателе М. Х. Хәсәнов чыкты.

Җыелышта чыгыш ясадылар: Г. Ибраһимовның юбилеен үткәрү буенча Бөтенсоюз комиссиясе председателе, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев, язучы М. Мәһдиев, «Органик синтез» производство берләшмәсе машинисты Н. П. Никишин, «Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары Р. Мөхәммәдиев, Балтач урта мәктәбе укытучы-методисты В. Г. Фазлыева, Казахстан Язучылар союзы идарәсе секретаре Ш. Мортазаев, Үзбәкстан Язучылар союзы идарәсе секретаре М. Әгъзамов, Башкортстан Язучылар союзы идарәсе председателе Ә. Мирзаһитов, Казан педагогия институты студенты Г. Фәйзуллина.

Соңыннан Татарстан сәнгать осталары концерты булды.

Юбилей көннәрендә республикабыз җәмәгатьчелеге татар әдәбияты классигы, галим, ялкынлы революционер-интернационалист, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуны киң билгеләп үтте.

11 мартта СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан Язучылар союзы белән берлектә, бу юбилейга багышлап фәнни конференция үткәрде. Конференциядә Казан галимнәре белән бергә Мәскәү, Алма-Ата, Баку, Махачкала, Уфа, Йошкар-Ола һ. б. шәһәр галимнәре Г. Ибраһимовның күпкырлы иҗатын төрле яклап яктырттылар.

Конференция башланган көнне, 11 мартта, республика юбилей комиссиясенең карары белән, институтта Г. Ибраһимовның музей-бүлмәсе ачылды. Татарстан дәүләт эшлеклеләре, конференция кунаклары бу тантананың беренче шаһитлары булды.

Афзал ага Шамов Г. Ибраһимовның әдәби мирасын туплау буенча күптәннән эшләп килә. Г. Ибраһимовка 1928 елда иҗатының 20 еллык бәйрәме уңае белән «Хезмәт каһарманы» дигән мактаулы исем бирелә. Әлеге мактаулы исем грамотасының, Дәүләт художество фәннәре Академиясенә член итеп сайлану (1928 ел) уңае белән әдипнең Академиягә җибәргән язмасының, туу турында таныклыгының, автографларының, күп кенә хатларының күчермәләрен музей-бүлмәгә ул тапшырды.

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында студентларның Бөтенсоюз фәнни конференциясе булды.

ТАССР Сынлы сәнгать музеенда күргәзмә ачылды.

Казан шәһәренең Ленин районында Г. Ибраһимов исемендәге урам бәйрәме, республикабыз шәһәрләрендә һәм авылларында укучылар конференцияләре, әдәбимузыкаль кичәләр үткәрелде.

19 мартта Әлмәттә, Төзүчеләрнең техника йортында, Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга карата тантаналы кичә булды.

Әлмәт Язучылар оешмасы җаваплы секретаре Ә. Гаффар классик әдипнең тормыш юлы, иҗаты һәм җәмәгать эшчәнлеге турында сөйләде.

Кичәнең икенче өлешендә Әлмәт татар дәүләт драма театры артистлары тарафыннан Г. Ибраһимов әсәрләреннән өзекләр күрсәтелде, үзешчәннәр көче белән әзерләнгән концерт булды.

11 апрельдә Түбән Кама шәһәренең Техника йортында узган «Җидегән чишмә»нең чираттагы кичәсе Галимҗан Ибраһимовның 100 еллыгына багышланды. Кичәгә кунак булып «Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары язучы Р. Мөхәммәдиев килгән иде. Ул Г. Ибраһимов иҗаты турында сөйләде һәм тамашачыларны кызыксындырган бик күп сорауларга җаваплар бирде.

Кичәдә язучы Р. Хисмәтуллин, шагыйрь М. Шәйхи чыгыш ясады.

9—13 мартта Әлмәт, Түбән Кама, Алабуга, Брежнев шәһәрләрендә Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичәләр булып узды. Бу кичәләр ВЛКСМ өлкә комитеты һәм ТАССР Композиторлар союзы тарафыннан оештырылган иде. Анда яшь шагыйрьләр Р. Зәйдуллин, Л. Лерон, яшь композиторлар Р. Еникеева, М. Шәмсетдинова, Р. Кәлимуллин, Ф. Шәрифуллин һәм яшь башкаручылар катнашты.

17 мартта Казан дәүләт педагогия институтының 5 нче тулай торагында татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга багышланган әдәбимузыкаль кичә үткәрелде.

Кичәдә «Галимҗан Ибраһимов — психологизм остасы» дигән темага доклад белән татар әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы Фәрит Хатипов чыкты.

Кичәдә «Казан утлары» журналының баш редакторы шагыйрь Ренат Харис катнашты һәм чыгыш ясады.

Юбилей кичәләре Казан дәүләт педагогия институты студентлары педагогик практика үтә торган Казанның 35 нче, 10 нчы интернат-мәктәпләрендә, Кукмара районының Зур Сәрдек һәм Байлангар урта мәктәпләрендә дә үткәрелде.

22 мартта Оренбург шәһәренең Төзүчеләр культура сараенда Г. Ибраһимовка багышланган әдәби кичә булып узды.

Кичәдә Х. Ямашев исемендәге китапханә каршында эшләп килүче әдәбият берләшмәсе җитәкчесе Зиннур Шакиров Г. Ибраһимовның тормышы һәм иҗат юлы турында сөйләде. Классик әдип иҗаты турында укытучы Мәхмүт Әмиров, китапханәче Рәйсә Сәйфетдинова үзләренең кызыклы фикерләре белән уртаклаштылар. Г. Ибраһимовның Уфадагы еллары турында шагыйрь Иосыф Гәрәй истәлекләр сөйләде. Соңыннан төзүчеләр культура сараеның татар үзешчән сәнгать осталары концерты (җитәкчесе Р. Рәфикова) кичәнең табигый дәвамы булып яңгырады. Бу турыда безгә журнал укучысы Д. Амангильдин хәбәр итте.

Март аенда Башкорт дәүләт университетында Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә үткәрелде. Доклад белән татар филологиясе кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы Ү. И. Гыймадиев чыгыш ясады. Ул әдипнең тормыш һәм иҗат юлы белән таныштырды. Аннан соң Г. Ибраһимовның туганнары һәм шәкертләре сүз алды. Алар язучы турындагы җылы истәлекләре белән уртаклаштылар.

Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган фәнни конференция үткәрде.

Башкорт дәүләт музееның өлкән гыйльми хезмәткәре Г. Мәгафуров әдипнең туган авылы Солтанморатта (Авыргазы районы) шушы көннәрдә ачылачак йорт-музей, аның экспонатлары турында сөйләде. СССР Фәннәр академиясе Башкортстан филиалының өлкән гыйльми хезмәткәре С. Сафуанов, университет доцентлары Р. Мөхәммәтҗанов, Ә. Нигъмәтуллин, Б. Сәлимгәрәева, Р. Сибәгатов, С. Хафизов, С. Поварисов, өлкән укытучы А. Шәйхуллов чыгыш ясадылар.

## Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕ БИРЕЛДЕ

ТАССР Министрлар Советы, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, галим-марксист, татар совет әдәбияты классигы язучы Галимҗан Ибраһимов истәлеген мәңгеләштерү максатыннан, Актаныш районының «Кызыл көч» колхозы членнарының гомуми җыелышы, КПССның Актаныш райкомы бюросы һәм район Советы башкарма комитеты тәкъдимен исәпкә алып, «Кызыл көч» колхозының исемен «Галимҗан Ибраһимов исемендәге» дип үзгәртү турында карар кабул итте.

## ИҖАТ СЕКЦИЯСЕНДӘ

3 апрельдә очерк һәм публицистика секциясендә язучы Рафаэль Мостафинның Кабан күле, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында «Кабан күленең серләре» дип исемләнгән яңа китабының кульязмасы тикшерелде. Фикер алышуда катнашучылардан М. Зарипов, Д. Вәлиев, Р. Юнысов, В. Аристов, Ф. Бәйрәмова, М. Әмирханов, Ф. Латыйпов һәм башкалар китапның гаять мөһим проблема күтәрүен билгеләп үттеләр, сугышчанлыгын тагын да арттыру буенча тәкъдимнәр әйттеләр.

## ЯЗУЧЫЛАР СӘФӘРДӘ

23—26 мартта язучы Рәфкать Кәрами һәм шагыйрь Әхмәт Рәшитов Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь районында булып кайттылар. Алар районның Чүмбәли, Мәдәнә, Куйсуы һәм Семочки авыл мәктәбе укучылары алдында чыгыш ясадылар. «Чембылеевский», «Кызыл Октябрь», В. И. Ленин һәм М. Горький исемендәге колхоз хезмәтчәннәре белән фермаларда, машина-трактор паркларында иҗади очрашулар, ә кичләрен культура йортларында әдәби кичәләр үткәрделәр, китапханәләр эше белән таныштылар.

## ШИГЪРИЯТ КИЧӘСЕ

23 мартта Казан шәһәренең С. М. Киров исемендәге культура сараенда шагыйрьләр Әдип Маликов һәм Рәшит Әхмәтҗанов иҗатына багышланган шигърият кичәсе булып узды. Республикабызның сәнгать осталары башкаруында шагыйрьләрнең шигъри әсәрләре, җырлары башкарылды, аларның иҗат һәм тормыш юллары турында сөйләнде.

## ПЕРМЬ ЯКЛАРЫНДА

1—15 мартта язучы Газиз Кашапов Пермь өлкәсенең Лысьва шәһәре һәм районында булып кайтты. Анда ул Лысьва металлургия заводында эшчеләр һәм инженер-техник хезмәткәрләр алдында чыгышлар ясап, татар совет әдәбияты, «Казан утлары» журналы, классик шагыйрь Хәсән Туфан һәм аның иҗаты турында сөйләде. (Билгеле булганча, Хәсән Туфанның яшүсмер еллары шунда узган һәм ул әлеге заводта токарь булып эшләгән). Шәһәрнең үзәк китапханәсендә, китап сөючеләр җәмгыятенең «Прометей» клубында, заводның халык музеенда, Лысьва районындагы татар авылларында шундый ук очрашулар булды. Әвәте авылы клубында «Казан утлары» журналының укучылар конференциясе булып узды.

## ШАГЫЙРЬ БЕЛӘН ОЧРАШУ

25 мартта «Казан утлары» журналы редакциясендә атаклы башкорт шагыйре Нәҗәр Нәҗми белән иҗади очрашу булды. Очрашуда журнал редакциясе хезмәткәрләре һәм әдипләр Мәхмүт Хәсәен, Мәхмүт Хәсәнов катнаштылар. Җылы һәм эшлекле сөйләшү ике тугандаш әдәбиятның актуаль проблемаларына багышланды.

## ИҖАТ КИЧӘСЕ

11 мартта КамАЗ Культура сараенда Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты шагыйрь Роберт Миңнуллин иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәне кереш сүз белән Брежнев язучылар оешмасы җаваплы секретаре Ямаш Игәнәй ачты. Анда Р. Гобәйдуллин, И. Закиров, В. Әхмәтшин җитәкчелегендәге вокаль-инструменталь ансамбльләр, үзешчән сәнгать коллективлары катнашты.

Р. Миңнуллин үзенең иҗат планнары турында сөйләде, шигырьләрен укыды һәм күп санлы сорауларга җаваплар бирде.

Кичәне Алабуга дәүләт педагогия институты доценты Х. Сәлимов алып барды.

## ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КИҢӘЯ

«Казан утлары» журналы белән Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр арасындагы иҗади хезмәттәшлеккә 1983 елда нигез салынган иде. Шул чорда журнал битләрендә ачылган «ТатАЭС — әдәби пост» дигән рубрика астында барысы егерме өч әсәр — очерклар, проблемалы мәкаләләр һәм юл язмалары дөнья күрде, язучы Газиз Кашапов «Язмышыңа ышан» исемле роман иҗат итте.

Быелдан башлап иҗади бәйләнешләр тагын да киңрәк колач ала. 20 мартта, Кама Аланы урта мәктәбендә үткәрелгән очрашуда мондый хезмәттәшлекне тагын да киңәйтү, аңа шәһәр төзүчеләрне генә түгел, ә булачак станция һәм «Тататомстрой» идарәләре коллективларын да кушу турында договорга кул куелды. Аңа журналның баш редакторы Р. Харис, Брежнев йортлар төзү комбинаты начальнигы М. Бибишев, «Тататомстрой» начальнигы М. Вайнер һәм Татарстан АЭСы директоры урынбасары Л. Чащин кул куйдылар.

Мәгълүм булганча, Тат. АЭС турында журнал битләрендә басылган иң яхшы әсәрләргә төзүчеләр махсус премия булдырган иде. 1986 елда премиягә язучы И. Низамов һәм «Правда» газетасы хәбәрчесе Н. Морозов лаек булды. Очрашуда лауреатларга тантаналы шартларда премияләр тапшырылды, алдынгы төзүчеләргә журналның мактау грамоталары бирелде, алар шулай ук еллык подписка белән бүләкләнде. Урнашкан традиция буенча, журнал хезмәткәрләре Татарстан атомчыларына язучыларның автографлары куелган 120 томлы китапханә дә бүләк иттеләр.

Кичәдә тормыш һәм әдәбият арасындагы бәйләнеш, үзара хезмәттәшлекне үстерү турында кызыклы фикер алышу булды. Очрашуда КПССның Түбән Кама шәһәр комитеты секретаре Т. Наговицына, шагыйрә Э. Шәрифуллина, Татарстанның атказанган артисты В. Федотов, журналның очерк һәм публицистика бүлеге редакторы Ф. Латыйпов катнашты.

## ГАЛИМҖАН ЛАТЫЙПНЫҢ МИРАС КОМИССИЯСЕ

Татарстан Язучылар союзы шагыйрь Галимҗан Латыйпның мирас комиссиясен төзеде. Комиссиягә түбәндәге иптәшләр керделәр: Җәвад Тәрҗеманов (председатель), Альберт Латыйпов (секретарь), Самат Шакир.

Мирас комиссиясе кулларында Г. Латыйп иҗатына һәм тормышына караган материаллар булган иптәшләрдән, аларны түбәндәге адрес буенча җибәрүләрен үтенә:

420012, Казан шәһәре, Комлев урамы, 14 йорт,

Татарстан Язучылар союзы идарәсе.

# ХАТЫГЫЗГА ҖАВАП

Мәскәүдән Нур Гарипов, Уфадан Талия Локманова, Ташкенттан Ринат Сөләймановлар редакциябезгә:

— Соңгы елларда кайсы татар язучыларының күп томлыклары чыкты? Аларны әле сатып алу мөмкинлеге бармы? — дигән сорау белән мөрәҗәгать иттеләр.

— Татарстан китап нәшрияты Галиәсгар Камал (1978—1982), Фатих Кәрим (1979—1981), Һади Такташ (1980—1983) әсәрләренең өч томлыкларын, Гариф Ахунов (1981—1984), Гомәр Бәширов (1981—1984), Мәҗит Гафури (1980—1983), Кави Нәҗми (1981—1984) әсәрләренең дүрт томлыкларын, Габдулла Тукайның (1985—1986) биш томлыгын нәшер итте. Г. Ахунов, Г. Бәширов дүрт томлыкларына өстәмә рәвешендә янә берәр том басылды. Хәзерге вакытта Фатих Әмирханның дүрт, Әхмәт Фәйзинең биш, Галимҗан Ибраһимовның сигез томлыкларын чыгару тәмамланып килә. Якын арада Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Атилла Расих, Кәрим Тинчуриннарның өч томлыклары да укучыларга тәкъдим ителәчәк.

Бу китапларның байтагын Татарстанның китап кибетләреннән әле дә эзләп табарга мөмкин. Чит өлкә, республикаларда яшәүчеләр почта аша җибәрүне үтенеп, Казанга мөрәҗәгать итә ала: 420057. г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга — почтой». 420084. г. Казань, ул. Баумана, 19. Магазин № 1. отдел «Книга — почтой».

**Г. Камал. 1 том.** Пьесалар. 408 бит. Б. 2 с. 2 т. Пьесалар, эстрада әсәрләре, шигырьләр. 544 бит. Б. 2 с. 30 т. 3 том. Хикәяләр, мәкаләләр, очерклар, хатлар. 328 бит. 416 бит. Б. 2 с. 30 т.

**Ф. Кәрим. 1 том.** Шигырьләр. 320 бит. Б. 95 т. 2 том. Поэмалар, балладалар һәм драма. 328 бит. Б. 1 с. 40 т. 3 том. Повестьлар һәм хикәяләр, мәкаләләр, очерклар, хатлар. 328 бит. Б. 1 с. 40 т.

**Һ. Такташ. 1 том.** Шигырьләр һәм поэмалар. 528 бит. Б. 1 с. 80 т. **2 том.** Драматургия һәм проза. 444 бит. Б. 1 с. 80 т. 3 том. Әдәбият, сәнгать тәнкыйте, публицистика, биографик материаллар, хатлар. 480 бит. Б. 1 с. 80 т.

**Г. Ахунов. 1 том.** Хәзинә. Хуҗалар. Романнар. 494 бит. Б. 1 с. 90 т. **2 том.** Повестьлар. 496 бит. Б. 2 с. **3 том.** Хикәяләр, очерклар. 448 бит. Б. 1 с. 90 т. **4 том.** Пьесалар. Әдәби портретлар. 488 бит. Б. 2 с. 10 т. **Өстәмә том.** Чишмәләр белән сөйләшү. Мәкаләләр, очерклар, аңгәмәләр. 462 бит. Б. 2 с.

**Г. Бәширов. 1 том.** Намус. Роман. 464 бит. Б. 1 с. 90 т. **2 том.** Туган ягым — яшел бишек. Повесть. 456 бит. Б. 1 с. 90 т. 3 том. Җидегән чишмә. Роман. 424 бит. Б. 1 с. 80 т. **4 том.** Повесть, хикәяләр, очерклар, мәкаләләр. 528 бит. Б. 2 с. 20 т. **Өстәмә том.** Тормыш юлында. Повесть-истәлек, мәкаләләр. 384 бит. Б. 1 с. 80 т.

**М. Гафури. 1 том.** Шигырьләр һәм мәсәлләр. (1902—1917) 536 бит. Б. 1 с. 50 т. 2 том. Шигырьләр һәм сәхнә әсәрләре. (1917—1934). 600 бит. Б. 2 с. **3 том.** Проза һәм публицистика (1902—1917). 392 бит. Б. 2 с. 10 т. **4 том.** Совет чоры прозасы. 496 бит. Б. 2 с. 30 т.

**К. Нәҗми. 1 том.** Хикәяләр, повестьлар. 352 бит. Б. 1 с. 70 т. **2 том.** Шигырьләр, поэмалар, тәрҗемәләр. 280 бит. Б. 1 с. 30 т. **3 том.** Язгы җилләр. Роман. 416 бит. Б. 2 с. 30 т. 4 том. Әдәби публицистик мәкаләләр һәм очерклар. Хатлар. 320 бит. Б. 1 с. 50 т.

**Г. Тукай. 1 том.** Шигырьләр, поэмалар. (1901—1908). 408 бит. Б. 1 с. 30 т. **2 том.** Шигырьләр, поэмалар. (1909—1913). 400 бит. Б. 1 с. 20 т. **3 том.** Проза, публицистика (1904—1906). 392 бит. Б. 1 с. 60 т. **4 том.** Проза, публицистика (1907—1913). 352 бит. Б. 1 с. 35 т. **5 том.** Истәлекләр, юлъязмалар, хатлар, мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр. (1902—1913). 368 бит. Б. 1 с. 60 т.

**Г. Ибраһимов. 1 том. Хикәяләр (1907—1929). 512 бит. Б. 98 т. 2 том.** Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. Романнар. 480 бит. Б. 1 с. 04 т. **3 том.** Кызыл чәчәкләр. Алмачуар. Тирән тамырлар. Яңа кешеләр. Повестьлар, роман, драма. 456 бит. Б. 1 с. 5 том. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр (1910—33). 616 бит. Б. 2 с. 70 т. **7 том.** Тарихи хезмәтләр. (1911—27) 540 бит. Б. 2 с. 70 т. 6, 8 томнар якын арада басылачак.

**Ә. Фәйзи. 1 том.** Шигырьләр, поэмалар. 400 бит. Б. 1 с. 90 т. **2 том.** Тукай. Роман. 544 бит. Б. 2 с. 80 т. 3 том. Драмалар һәм комедияләр. 512 бит. Б. 2 с. 50 т. **4 том.** Либретто, проза. 560 бит. Б. 2 с. 80 т. 5 том. Очерклар, мәкаләләр, истәлекләр, көндәлекләр (басыла).

**Ф. Әмирхан. 1 том.** Хикәяләр (1907—1922). 480 бит. Б. 2 с. 40 т. **2 том. Повестьлар, роман һәм драма әсәрләре. 488 бит.** Б. 2 с. 60 т. 3 том. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. (басыла). **4 том.** Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар, 392 бит. Б. 1 с. 90 т.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Татарстан китап нәшрияты 1986 елда түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:

**Сибгат Хәким.** Сайланма әсәрләр. Ике томлык. I том. 366 бит. Бәясе 1 с. 50 т. 2 том. 408 бит. Бәясе 1 с. 80 т.

**Гариф Ахунов.** Идел кызы. Трилогиянең икенче китабы. 391 бит. Бәясе 1 с. 60 т.

**Гариф Галиев.** Истә, һаман да истә. Хикәяләр. 216 бит. Бәясе 55 т.

**Шәүкәт Галиев.** Илһамым-мәхәббәтем. Лирик язмалар. 408 бит. Бәясе 1 с. 60 т.

**Марсель Галиев.** Сиңа мин кирәк. Повесть һәм хикәяләр. 294 бит. Бәясе 65 т.

**Нияз Акмалов.** Учак. Шигырьләр һәм поэмалар. 48 бит. Бәясе 10 т.

**Тәүфикъ Камалиев.** Ак өметләр. Шигырьләр. 136 бит. Бәясе 25 т.

**Барлас Камалов.** Өметең өзелмәсен. Роман. 232 бит. Бәясе 1 с.

**Хисам Камалов.** Безне өйдә көтәләр. Роман. 384 бит. Бәясе 1 с. 70 т.

**Эдуард Касыймов.** Шиңмәсен гөлләрең. Роман. 480 бит. Бәясе 1 с. 80 т.

**Нәбирә Гыйматдинова.** Талпыну. Повестьлар. 264 бит. Бәясе 60 т.

**Гамир Насрый.** Пьесалар. 256 бит. Бәясе 60 т.

**Рашат Низамиев.** Боек сер. Повестьлар һәм хикәяләр. 174 бит. Бәясе 40 т.

**Бикә Рәхимова.** Сәрвиназ. Шигырьләр. 64 бит. Бәясе 10 т.

**Әхмәт Рәшитов.** Иөрәк кыңгыраулары. Шигырьләр һәм поэмалар. 192 бит. Бәясе 85 т.

**Гәрәй Рәхим.** Үз җиремдә үз җырым. Шигырьләр, либреттолар. («Шигырь китапханәсе» сериясе). 448 бит. Бәясе 2 с.

**Фоат Садриев.** Ач тәрәзәң. Пьесалар. 144 бит. Бәясе 50 т.

**Саҗидә Сөләйманова.** Гөлбадран. Хикәяләр, повестьлар, очерклар һәм мәкаләләр. 368 бит. Бәясе 1 с. 20 т.

Тәрәзәгә чиртер мизгел. Юмористик һәм сатирик шигырьләр. 104 бит. Бәясе 40 т.

Туган җиремә. Габдулла Тукай сүзләренә җырлар. Ноталар белән. 58 бит. Бәясе 85 т.

**Лена Шакирҗанова.** Ышанам йөрәгемә. Шигырьләр. 80 бит. Бәясе 30 т.

Фатих Әмирхан турында истәлекләр. 192 бит. Бәясе 1 с.

Яраткан җырлар. Баянда уйнар өчен ноталар белән. 80 бит. Бәясе 60 т.

**Әзһәр Мөхәммәдиев.** Борынгы хазар һәм болгар-татар акчалары. Тикшеренү. 176 бит. Бәясе 35 т.

**Спартак Әхмәтов.** Асылташлар турында хикәяләр. 112 бит. Бәясе 30 т.

Умартачыга ярдәмгә. Белешмәлек. 280 бит. Бәясе 50 т.

Балалар өчен:

**Габдулла Тукай.** Эш беткәч уйнарга ярый. Шигырьләр. 24 бит, төсле рәсемнәр белән. Бәясе 30 т.

**Әхсән Баянов.** Җыр дәвам итә. Кечкенә хикәяләр. 40 бит. Бәясе 10 т.

**Рәшит Бәшәр.** Ак әкият. Шигырьләр. 32 бит. Бәясе 15 т.

**Резеда Вәлиева.** Күгәрченнәр очсын уйнап. Шигырьләр. 126 бит. Бәясе 30 т.

**Нурия Измайлова.** Мин зур үскәч. Шигырьләр. 32 бит, рәсемнәр белән. Бәясе 10 т.

**Ләбибә Ихсанова.** Милиционер малае. Повесть. 192 бит. Бәясе 50 т.

**Нәзифә Кәримова.** Җәнлекләр кайта. Кыска хикәяләр. 32 бит. Бәясе 10 т.

**Ринат Мөхәммәдиев.** Ак канатлы кояш. Нәни повесть. 24 бит, төсле рәсемнәр белән. Бәясе 10 т.

**Энҗе Мөэминова.** Дуслар җыелгач. Шигырьләр һәм табышмаклар. 56 бит, төсле рәсемнәр белән. Бәясе 30 т.

**Таһир Нәбиуллин.** Торналы туп. Шигырьләр. 24 бит. Бәясе 10 т.

**Ләлә Сабирова.** Кызарган алмалар. Хикәяләр. 31 бит. Бәясе 5 т.

**Рафис Сәлимҗанов.** Күкеле сәгать. Хикәяләр. 62 бит. Бәясе 15 т.

**Хәкимҗан Халиков.** Рәхим итегез. Шигырьләр, башваткычлар. 48 бит. Бәясе 15 т.

Әшкә бирсәң чын күңел. Мәкаләләр. 78 бит. Бәясе 10 т.

Якындагы кибетләрдә табылмаса, соратып алдыру өчен адреслар: 420057 г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга — почтой». 420084 г. Казань, ул. Баумана, 19. Книжный магазин, отдел «Книга — почтой».

# ЯКА ЧЫЛБЫРЫ

Узган гасырларда халык арасында киң таралган милли бизәнү әйберләре, шул исәптән яка чылбыры безнең көннәрдә дә зур эстетик әһәмияткә ия. Алтыннан һәм көмештән, асылташлар куеп, тирән зәвык белән иҗат ителгән бу әйберләр халык сәнгатенең тотрыклы традицияләре, татар ювелирларының гаять зур осталыгы турында сөйли.

Яка чылбыры гадәттә башка бизәнү әйберләре белән бергә кулланыла. Әлеге композициядә төрдәш элементлар һәм принциплар кабатлануы исә гаҗәеп дәрәҗәдә бербөтенлек, стиль бердәмлеге тудыра. Шул ук вакытта яка чылбырының хатын-кызлар кием ансамблендә үзенә генә хас урыны һәм үзенчәлеге бар.

Иң элек ул катлаулы композициясе, оригиналь формасы белән игътибарны җәлеп итә. Аның өске буыны, гадәттә күлмәк якасына эләктерелә торган, үзара тоташтырылган каптырмадан тора. Шул каптырмалардан аска таба нәфис чылбырлар сузыла. Алар бердән алып тугызга кадәр булырга мөмкин, ләкин биш чылбырдан ясалганы аеруча еш очрый. Чылбыр боҗралары шома металлдан кисеп яки бөтереп эшләнә, чәчәкнең таҗ яфракларын хәтерләтүче бизәкләр белән баетыла. Чәчәк үремнәре шикелле буй-буй сузылган әнә шул асылмалар чишмә агышыдай уйнаклап киләләр дә асылташлар куелган эре челтәр-тәңкәләргә барып тоташалар. Чылбырның, асылма бизәкләрнең уйнаклавы, төсләр балкышы гаҗәеп җиңеллек һәм үзенчәлекле яңгыраш хасил итәләр дә инде.

Түгәрәк рәвешендәге яки таҗ яфракларын, чәчәк аерчаларын хәтерләтүче каптырмаларны һәм челтәр-тәңкәләрне бизәкләү көмешчедән гаять зур осталык һәм хыял байлыгы таләп иткән.

Ювелирлар яка чылбыры ясаганда тәерчекләп нәкышләү алымын еш кулланганнар. Яктылык уенына корылган бу ысул үз чиратында әйбергә бәйрәмчә купшылык бирә. Нечкә металл чыбыклардан җилпәзә рәвешенә кертеп ясалган бөтеркәләр һәм чорнамнар аларга өрфиядәй җиңеллек өсти сыман.

Һәр челтәр-тәңкәгә фирәзә, сердолик, хрусталь, аметист яки башка асылташ беркетелә. Үзәккә куелган шул асылташ тирәсенә ваграклары урнаштырыла. Шулай итеп, казан татарларының халык сәнгатенә хас булган чәчәкле-үсемлекле стиль бизәнү әйберләре төзелешендә дә, асылташларны тезү алымында да чагылыш таба.

Татарстан сынлы сәнгать музее тупланмаларында яка чылбырының гаҗәеп кызыклы һәм бай үрнәкләре саклана. Алар үзенчәлекле татар сәнгатенең бай тарихын һәм камил гүзәллеген гәүдәләндерәләр.

**Людмила КОРОБЦОВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанда А. С. Пушкин һәйкәле.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотосы.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210




КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ